**Хади Такташ**

# СОЧИНЕНИЯ

В трех томах

**Том 2**

Проза, литературно-художественные критические статьи, публицистика

*Издание второе, исправленное и дополненное*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2010

**Һади Такташ**

# ӘСӘРЛӘР

Өч томда

**2 том**

Проза, әдәбият-сәнгать тәнкыйте мәкаләләре,
публицистика

*Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-3(4)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Т17

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин,*
*И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Л.М.Шәехов, Ф.И.Фәтхетдинова*

Томны төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче
*Лена Гайнанова*

**Такташ, Һ.Х.**

Әсәрләр : 3 томда / Һади Такташ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.
ISBN 978-5-298-01891-3
2 т. : проза, әдәбият-сәнгать тәнкыйте мәкаләләре, публицистика / томны төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Л.Гайнанова; кереш сүз авт. Л.Гайнанова. – Төз. һәм тулыл. 2 нче басма. – 2010. – 383 б.
ISBN 978-5-298-01893-7

Татар халкының классик язучысы Һади Такташ әсәрләренең бу томында әдипнең проза әсәрләре, әдәбият-сәнгать тәнкыйте һәм публицистик мәкаләләре туплап бирелә.

УДК 821.512.145-3(4)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
ISBN 978-5-298-01893-7 (2 т.)
ISBN 978-5-298-01891-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Гайнанова Л.Р., төзү, текст., иск., аңл., 2010

## Төзүчедән

Бу томга Һади Такташның проза әсәрләре, әдәбият-сәнгать тәнкыйте һәм публицистик мәкаләләре тупланды. Өчтомлыкның беренче басмасын матбугатка әзерләгәндә, әдипнең Татарстан берләштерелгән Дәүләт музее (хәзер Татарстан Республикасы Милли музее) архивында сакланган барлык чәчмә кулъязмалары гарәп язуыннан гамәлдәге язуга күчерелде. Әсәрләрнең күпчелеге кулъязмалардан һәм вакытлы матбугаттан алып басылган иде. Икенче басмага исә Һ.Такташның «Троцкий» исемле хикәясе өстәлде. Бу әсәрендә әдип узган гасырның 20–30 нчы елларында СССР хөкүмәте җитәкчелегендә зур дәрәҗә тоткан затны – хәрби эшләр халык комиссары Л.Д.Троцкийны – татар прозасына әдәби образ итеп алып керә.

Һади Такташ матбугатта беренче тапкыр шигырьләре белән түгел, ә мәкалә-хәбәрләре белән күренә башлый. 1917 елның 21 августында Ташкентта чыккан «Олуг Төркстан» газетасында уналты яшьлек егетнең «Бохарада уку һәм укыту эшләре» исемле мәкаләсе басыла. Һәм шуннан башлап әдип гомере буе журналистикадан аерылмый. Унсигез яшеннән ул газетаның штаттагы әдәби хезмәткәре вазифасын үти башлый.

Язучының газета-журналларда эшләү хронологиясе түбәндәгечә бара: 1919 елның көзеннән 1921 елның февраленә кадәр ул Оренбургта «Юксыллар сүзе» газетасында эшли, анда әдәби хезмәткәр, аннары җаваплы секретарь һәм вакытлыча редактор була. 1921 елда Ташкентка күчеп килә һәм анда чыккан «Белем йорты» журналында җаваплы секретарь булып эшли. 1923–1924 елларда Казанда «Чаян» журналының, 1925 елда «Октябрь яшьләре» һәм 1926 елда аның дәвамы булган «Авыл яшьләре» журналлары редакциясенең, шул ук елның октябрь аеннан 1929 елның башына кадәр «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре була. 1929 елда ул яңадан «Чаян»га кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда эшли.

Унбиш ел эчендә язучының шигырьләре, чәчмә әсәрләре, мәкаләләре басылып чыккан газета-журналларның исемлеге тагын да зуррак.

«Азат хатын» журналында эшләгән чорында, 1927 елның сентябрь аенда, Такташ Зөя шәһәренә Казан гарнизонының территориаль (хәрби) җыенына чакырыла. Ул анда беренче татар укчы дивизиясенең «Походта» исемле газетасында эшли. Беренче санда ук: «Без сыныйбыз көчебезне, сугыш теләп кайрамыйбыз тешебезне», – дип, сугышчыларга мөрәҗәгать итә. Такташның бу һәм «Өйрәнегез, белегез, әйбәт кенә йөрегез», «Үзләре кеше кебекләр, карасаң – көзге чебешләр», «Бүленергә ярамый» кебек шигырьләре беренче тапкыр «Походта» газетасында чәчмә әсәрләр, нәсер-мөрәҗәгатьләр булып басылган. Соңыннан алар, бернинди төшереп калдырулар, өстәмәләр ясалмыйча, строфаларга салынып, шигырьләр булып чыга башлый. Бәлки, бу әсәрләр талантлы шагыйрь күңелендә шигырь туу процессының мисалыдыр?

Язучы, үзенең әдәби-эстетик карашларын чагылдырган мәкаләләре белән бергә, журналларда эшләгәндә, журнал таләпләреннән һәм тематикасыннан чыгып та байтак әйберләр язган. Мәсәлән, аның «Авыл яшьләре»ндә эшләгәндә, журналга язышучы белгечләрнең булмавын күздә тотып һәм авыл кешеләренә чын күңелдән булышырга теләп язылган, җир эшләренә, радиотехникага, гигиенага караган мәкаләләре дә бар. 1925 елның 16 ноябрендә Мәхмүд Максудка язган хатында ул: «Мин соңгы вакытларда бернәрсә дә язмыйм. Арыдым, Мәхмүд. Чөнки шигырь язуга китәргә тиешле энергия «Авыл яшьләре» журналына агрономический нәрсәләр (урлап) язарга китә. Бернәрсә дә эшләр хәл юк», – дип зарланып та куя.

«Чаян» журналында эшләү чорына килгәндә, Такташны «Чаян»ны «Чаян» иткән журналист дип атарга була. Биредә язучының яңа бер ягы ачылып китә. Ул – аңардагы юмор, сатира. Такташ фельетоннарында ул чордагы проблемалар, язучының аларга реакциясе ачык чагыла. «Нэп чорында, – дип яза Х.Туфан, – Такташ һәр төнне ак күбеккә баткан атта, кулына ялан кылыч тоткан хәлдә, яңа тормышны дошманнардан саклап, урамнарда йөридер кебек тоела иде».

Кызганыч ки, Такташның Татарстан Республикасы Милли музее архивындагы кулъязмалар бүлеге тулы түгел, ләкин кулъязмаларның булган кадәресе дә тикшерүчегә гаҗәп кызык фактларны ачарга мөмкинлек бирә. Архивта очраган кулъязмалар, берәм-берәм, журналдагы әлегә кемнеке булуы мәгълүм булмаган мәкаләләрнең Такташныкы икәнлеген раслап баралар һәм журналның кайбер саннарын җаваплы секретарь тулаем диярлек үзе генә чыгарган дигән нәтиҗәгә китерәләр. Мәсәлән, «Чаян»ның 1930 елгы гыйнвар санында Такташ кулы белән язылган 4 мәкалә, август-сентябрь санында – 5, ноябрьдә – 8, декабрьдә – 7, ә 1931 елгы журналның февраль аенда – 8, март аенда 4 материал басылып чыккан.

Менә шулай бер үк санда берничә мәкаләнең чыгуы авторны имзаларын (псевдонимнарын) төрлечә куярга мәҗбүр иткән.

Такташның моңа кадәр билгеле булган әсәрләрендә (барлык шигырьләре, сәхнә әсәрләре, прозасы, мәкаләләре күздә тотыла) очраган псевдонимнары: «Мокамай», «Аллан», «Алланист», «Һади», «Һ.Т.», «Һ.Таш», «Һ.», «Так-таш», «Хәйрулла улы», «Хәйрулла малае», «Хәйрулла кызы», «Һәдия Хәйрулла кызы», «Һади туташ Тукташ», «Мокамайның якын кардәше», «Гөлчәһрә Такташ», «Ата шагыйрь», «Даһи», «Чаян», «Чаянов», «Чаян»ның беренче пом. Кәрам», «Чабата», «Точка», «Шагыйрь №1», «Камай», «Гилия», «Сак-Сок», «Дан», «Тәрҗимов», «Т.», «Ишетүче». Аннан башка Такташның имзасыз, шулай ук «Авыл малае Такташ», «Шефыгыз Такташ», «Һади Такташ+Кави Нәҗми = шагыйрьтрест» тибындагы имзалар белән басылган мәкаләләре бар.

Әмма җыелмый калган материаллар һәм ачыкланмаган имзалар да шактый булырга тиеш. Ташкентта чыккан «Олуг Төркстан» һәм аның дәвамы булган «Кызыл Байрак» газеталарының барлык саннарына да кулыбыз җиткәне юк. Шулай ук Оренбургта басылган «Юксыллар сүзе» газетасының берничә санын гына карый алдык. Хәтта Оренбургта ул газета сакланмаган. Авыр шартларда эшләп, безнең журналларга юнәлеш биргән, аларны чыгарганда эшнең иң зур өлешен үз җилкәсендә алып барган язучының барлык хезмәтләрен барлау, аларны укучыга җиткерү эше безнең изге бурычыбыз булып тора.

# ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ

*Тәмамланмаган романның бүлекләре,*
*нәсерләр, хикәяләр*

## ТАҢ ҖИЛЕ

### I

Бүгенгегә бөтенләй охшамаган, матур да, караңгы да, белемсез дә, ниндидер хыялдагы кебек ерак үткәннәр турында карчыклар теле әкият сөйли. Алар, сөйләгән нәрсәләренең әкият булмый, дөрес булуына үзләре дә ышанмаган төсле, уйланып, онытылган, ләкин бик матур төшләрен хәтерләргә теләгәндәй итеп, әкрен тавыш белән озайтып-озайтып сөйлиләр.

Һәм, дөрестән дә, алар сөйләгән Тулпан авылының үткәне бүгенгегә бөтенләй башка, төш кебек томанлы, хыял күзе үтә алмаслык зәңгәр төтен эчендә, башы белемсез матур әкият кебек тоела.

Кайчандыр Тулпан авылын очсыз-кырыйсыз киң урманнар урап алган булган. Алача ыштаннан, кизеле күлмәктән киң күкрәкле таза Тулпан егетләре, урманнарны яндырып, чирәмнәр ертып иген чәчә. Тулпан кызлары чыра яктысында төннәр буе киндер тугый, җеп җерли, җырлар җырлый булганнар.

Авылдан авылга, тимер чылбырларга аюлар тагып, аючылар йөргәннәр. Аючылар килү Тулпан авылы өчен зур вакыйга, зур бәйрәм булган. Карт аючылар авыл картлары белән төннәр буе ил хәбәрләре сөйләгәннәр. Яшь аючылар Тулпан авылына яңа җырлар алып килгәннәр. Бөтен авыл җыелып аю биеткән. Кызлар белән егетләр парлап биегәннәр. Яшь киленнәр елак балалары өстеннән аю атлатып уздырганнар.

Хәзер әбиләр сөйләгән Тулпан авылын ураган шомлы кара урманнар да киселеп беткәннәр. Авылның артыннан уйнаклап аккан Шуарләй суының ярларындагы кеше керә алмаслык баткаклыклар кипкәннәр. Май аенда бөтен Шуарләй буен ап-ак чәчәккә күмгән шомырт агачлары, каенсарлыклар, еламсыр таллар, баланнар киселгәннәр. Әбиләр җырлап җыеп йөргән кура җиләкләре, карлыганнарның эзләре дә калмаган. Еламсыр талларга уралып үскән колмаклары корыган. Алар бары, карчыкларның томанлы хыялларына уралып, Тулпан авылының борынгы җырларында ышанмаслык матур үткәннәр әкияте булып калганнар.

Урманнары киселгәч, кибәргә якынайган Шуарләй суының төпләрендә чери алмый яткан ак каеннар, аючылар йөргән чакларны хәтерләтергә теләгәндәй, балык тотучыларның ятьмәләренә асылыпerталар. Кармакларын эләктереп үзләрендә калдыралар...

Тулпан урманнарын кисеп тимер юл сызыгы үткәч, аз җирле Тулпан авылы егетләре чит җирләргә, ерак шәһәрләргә таралып беткәннәр. Аларның кайберләре шахтер, кайберләре шәлче[1], кайсылары вокзалчы[2] булып киткәннәр.

Тулпан авылының үткәннәрен искә төшерә торган җырлар да хәзер җырланмый. Авылга өйләнергә дип кайткан шәлчеләр, вокзалчылар, үзләре җырлый торган җырлар алып кайтып, борынгы җырларны оныттырганнар.

Тик картлар гына кайчакта, бергәләп буза эчеп утырганда, яшьләргә бөтенләй чит, әллә нинди ерак та, матур да, белемсез дә авылның үткәне белән бәйләнгән вакыйгалар, урманнар, аючылар турында җырлыйлар:

Аючылар, баючылар,
Кайтыгыз үз ил генәмә,
Үз илемә, үз җиремә
Карыйм күзем туйганчы,
Елыйм яшем беткәнче.
Пырагонда йөгреп җиттем,
Аючыны саурып үптем...[3]
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Юкә кисәргә баручыларның атлары тар гына юлдан әкрен генә урманга кереп киттеләр.

Бер үтелгән юллар, бер ишетелгән яфрак тавышлары уйларны, югалган, кабатланмас таңнарны матур ерак яшьлеккә кайтаралар. Күздән югалтудан куркып, ераклашкан саен хыял буяулары белән буяла-буяла үзенең чын төсен үзгәртеп, әкияткә охшап калган Рөстәмнең ятим үскән яшьлеге, урманга керү белән, йөрәк томаны уртасыннан елларның үтүе белән онытылган балалык теле белән сөйли башлады. Кайчандыр җиләк җыеп йөргән Тулпан урманнары таныш, сагынган, бик сагынган төсле аны кочаклап каршы алдылар. Рөстәмнең уйлары еллар уртасында бутала-бутала артка киттеләр. Аның йоклап туймаган тәне арбаның әкрен генә тирбәлеп баруы белән рәхәтләнә, сызлый, матур төшкә охшаган хыяллар йөрәген белемсез бер җиңеллек белән ашкындыра иде. Ул,

арбаның арткы тәгәрмәченең әйләнүенә карап, үзе дә сизми төш кебек кенә хәтерендә калган иң арткы яки иң яшь чагыннан хәтере саклап кала алган вакыйгаларны эзләп, хәтер хыялы эчендәге караңгылыкка кереп китте. Тик ул:

– Менә бу – иң яшь чагымда булган һәм гомеремнең башлангыч вакытларыннан онытылмый, бердәнбер хәтердә калган вакыйга, – дип, бернәрсә дә алып чыга алмады.

Бик күп төрле кисәк-кисәк булып сакланган вакыйгаларның кайсысы алданрак, кайсысы туган көннәренә якынрак булуы аерып ала алмаслык онытылган булып тоелды. Аның уе, менә шул аерып ала алмаслык яшьлек хатирәләре эчендә йөри-йөри, үзе белән Тулпан авылында бергә үскән яшьтәшләренең, үзе белән юкә кисәргә баручы Габбасларның, Садрыйларның гомер юллары арасында килеп чыккан каршылыкларга туктады. Бу каршылыклар аның яшьлек көннәрен икегә аердылар. Рөстәм үскән саен, авылдашлары белән үзе арасында булган бу каршылыклар үсте, зурайган саен, аны Тулпан авылының эчке тормышыннан икенче, белемсез бер якка алып китте.

Рөстәмнәрдән алда баручы Садрый чыбыркысы белән атын сукты да, туктап, Габбас белән Рөстәмне көтә башлады. Рөстәмнәр аның турына җиткәч, ул, Габбаска карап:

– Суат, ике катын картайткан үзеңне, трсидильнигыңны да күтәреп бәйли алмагансың, – диде. Үзе атны туктатмый гына Габбасның атының аркалыгын күтәреп бәйләде. Һәм, сөйләнә-сөйләнә, сикереп арбага утырды: – Әтәм, яңгырлар китсә, суат, кирәкне бирер. Син хет, карт боргц, алдатмагансың. Киемнәрне күп алгансың, – диде. Ул кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарып тезенә куйды да, «ц» авазы урынына «ч» авазы кулланып, Рөстәм белән «казанча» сөйләшергә башлады: – Әйдә, пләмәнник, берәрне чигеп алыйк. Ату чәй дә эчми кителде. Кагызың - бармы?

Рөстәм, кесәсеннән чыгарып, Леонид Андреевның «Савва»[4] дигән китабының бер битен ертып бирде. Садрыйның үзе белән болай укыган кешеләрчә сөйләшүен үзенә аерым бер зурлау яки көлү нияте белән эшләнгәнен уйлап елмайды. Садрый, гомумән, укыган кешеләрне яратмый. Аларның сукаламауларын, авыр эш эшләмәүләрен күреп торганга, «Эш сүмәс кешеләр генә укыйлар» дигән фикерне башына урнаштырып куйган кеше. Габдулла мулланың Казанда укый торган улы Нурмөхәммәтнең, крәстияннәр тирләп-пешеп йөргәндә, рус мөгаллимнәре белән су буйларында гулять итеп йөрүләре аның бу фикерен куәтли торган иң көчле мисаллардан саналадыр иде. Садрый Рөстәм турында да:

– Бак, әтәм, җир алма ашап үскән аю Ибругыиың ылыннан мулла цыгып куяр! – дип, эченнән генә Рөстәмнең «мулла булырга», ярлы бояр булырга омтылуыннан көлеп йөридер иде. Садрый Рөстәмнең атасы мәрхүм Ибраһим турында да яхшы фикердә түгел. Ул аны «Әлләзи» дип кенә йөртте. Садрыйча, әлләзинең мәгънәсе «булдыксыз кеше» дигән сүз.

Рөстәмнең атасы шахтер Ибраһим, Рөстәм кебек үк, туган авылы белән, Шәрәфләр, Габбаслар белән бөтен гомере буена килешә алмаслык зур каршылыклар белән яшәде. Ул да, Рөстәм кебек, үзен авылга кайткан вакытларында ялгыз ниндидер ят бер гаилә эчендә яшәгән кебек хис итәдер иде. Аның әллә ничә елга бер генә мәртәбә авылга кайтуы, әллә кемнәрнең тройкалар яллап кайтуы кебек, Тулпан авылы өчен зур вакыйга булмагандай, авылдан кире эшкә китүе дә билгесез каладыр иде. Авыл халкы да, гүя аның тормышында үзенә кызыгырлык әйбер тапмагандай, аны күрми, билгесез калдыра, китсә, бик тиз оныта иде.

Бәлки, авыл халкы, башкалар сәүдәдән баеп кайтканда, разъездан аркасына капчык тагып, җәяүләп акчасыз кайтуын, аның булдыксызлыгыннан санап, чит күргәннәрдер. Рөстәмнең атасында да туган авылына көченнән килмәгән нәрсәне соравы өчен нәфрәт хисләре уянгандыр. Башкаларның сәүдә итеп баеп, матур йортлар сала алулары, авылда данлыклы була алулары аңарда, аларны күралмау белән бергә, көнләү хисләре уяткандыр. Көне-төне шахтада эшләп, алар белән ярышырга теләгәндер дә, уза алмагач, йөрәгендә аларга да, үзенә дә нәфрәт хисләре уянгандыр. Бәлки, башка сәбәпләр дә булгандыр. Тик ул, нигәдер шул ук Садрыйлар, Габбаслар, Шәрәфләр белән күрше булсалар да, аралашмады. Авылга кайтуы белән кемне дә кунакка чакырмады. Аны үзен дә чакырмадылар. Очраган кешеләр белән дә ачык йөз белән исәнләшмәде. Гүя үзеннән-үзе оялган яки теләмәгән кебек кенә, күрешкән кешенең йөзенә карамый, читкә карап исәнләште. Туберкулез белән авырып күкрәгеннән беренче кат кан килгәч, ул Рөстәмнең анасына:

– Ә выт, көнне-төнне җир алма ашап, йортлар салырга акча җыйдым, – диде.

Ул бу сүзе белән гүя үзенең кемнәр беләндер узышып, авылда йортлар салдыруның юк эш икәнен, үзенең ялгышуын, авыл белән үзе арасында булган каршылыкларның авыр серен ачарга теләде. Рөстәмнең тормышы да авыл халкына бөтенләй каршы бер юл белән китте. Бу юл аны Садрыйлардан, Шәрәфләрдән, бергә үскән дусларыннан, аларның тормышларыннан, омтылышларыннан бөтенләйгә аерды. Бу аерылу яшьтән, Рөстәмнең русча, татарча укый башлаган вакытларыннан, аның татар әдәбияты тәэсире белән авыл телен ташлап, «казанча» сөйләшергә теләп йөргән көннәреннән башланды. Садрый да шул көннәрдән алып аның белән муллаларча сөйләп

йөрергә, аны үртәргә тотынды. Ләкин соңгы вакытларда гына бер вакыйга аны Рөстәм белән якынлаштырган кебек булды. Дөресрәге, Садрый Рөстәмнең бер «секрет»ын белде. Ул «секрет» шуннан гыйбарәт: Рөстәм авылдагы аңлы гына егетләрдән булган Виргасов белән моннан бер ай чамасы элек эч пошканнан станциягә таба чыгып китте. Станциядә бер эшләре дә булмаса да, алар бөтен көн буе анда йөрделәр. Бер-ике поездны карап озаттылар. Кичкә таба, станция алдында йөргән кызларга ияреп, чиркәү бакчасына барып чыктылар. Күзләп барган кызлары чиркәү бакчасына кереп киткәч, Рөстәм белән Виргасов та аны-моны уйламый бүрекләрен салдылар да чиркәүнең ишеге төбенә басып карап тора башладылар. Ишектән керүчеләр тыгызлый башлагач, алар, көлешә-көлешә, кулларына кепкаларын тоткан килеш, чиркәүдән чыгып киттеләр. Чиркәү капкасын чыгыйм дигәндә генә, каршыларына елмаеп Садрый килеп чыкты. Ул, төсенә мәгънәле сызыклар чыгарып:

– Сез, тутый кошлар, монда ни эшләп йөрисез? – диде.

Рөстәм бу, авылга кайткач, әллә нәрсәләр сөйләр дип:

– Менә тилеләрнең ничек маңгайларын җимерүләрен карап тордык, – диде.

Садрый тагын мәгънәле генә елмайды:

– Алай икән...

Ул турыда сүз озакка тартылмады. Садрыйдан аерылдылар. Садрый юл буена эченнән генә бу вакыйга турында уйлап кайтты. Бу хәбәрне авылга кайтып сөйләвенең зур кыйммәте булуын белсә дә, сөйләргә бик кызыкса да, аны бер нәрсә Рөстәм белән дошманлашудан туктатып калды.

Садрый ул – уртадан түбән тормышлы крәстиян. Гомерендә бер биш-алты мәртәбә генә гаеткә барган кеше. Ул намазны да, динне дә ара-тирә телдән ишетеп кенә белә. Гомер буенча елга аркылы үтеп йөрү өчен күчмә күпер куюдан башка халык «савап» дигән бер эш тә эшләгәне юк, муллага садака да биргәне юк. Ә гөнаһлы сүзләр сөйләүгә, усал телгә йомшаграк кеше. Алла турында, җәннәт хакында бик аз нәрсә белә. Алланы ул яшь чакларындарак үзләренең мәрхүм мәхәллә хәзрәте Ибраһимга охшата иде. Соңыннан каядыр: «Алла кешегә охшамый – колаксыз ишетә, күзсез күрә», – дип ишеткәч, бөтенләй уйларга курка башлады. Ни дә ул Алла турында сирәк уйлый, аның турында уйларга оныта, үзе шулай да Алланың барлыгына ышана иде. Бары аның динлеләр сөйләгән гөнаһларны, савапларны язып йөргән ике фәрештә[5] турында гына иманы йомшак. Ул, муллада, саваплы кешеләрдә булган кебек үк, үзендә дә ике фәрештә булуын һичбер башына сыйдыра алмый. Алланың Садрый кебек кешеләрнең сүгенеп йөрүләрен яздыру өчен канатлы ике фәрештә ияртеп йөрүенә ни булса да исе китә. Тирә-күршеләренең дә, динне белгән крәстияннәр дә: «Садрый кебек кешеләр һичбер җәннәткә керәчәк түгел, мәңге тәмугта яначаклар», – дип сөйләүләре башта аны бик нык куркытса да, соңыннан: «Киткән баш киткән инде, барыбер җәннәткә эләгеп булмас», – дип, ул турыда уйламаска, бар нәрсәне дә үзе теләгәнчә эшләп йөри башлады. Тик теге ике фәрештәнең үзендә дә булуына шөбһә белән йөрсә дә, аларны һаман хәтереннән чыгармый йөридер иде. Кайбер урында тозлырак сүгенергә туры килсә, сүгенү артыннан ук:

– Язып куегыз булмаса! – дип, фәрештәләренә карата өстәп куядыр иде.

Кайберәүләр, Садрыйның сүгенүдән соң шулай «Язып куегыз!» дип әйтеп куюының мәгънәсен туры мәгънәсендә аңлап, сүгенүне аныңча, «Язып куегыз!» белән бетереп йөри башладылар...

Тик үлек күмәргә туры килгәндә генә, Садрый көн буе агарып, сүгенмичә-нитмичә генә йөридер иде. Бу нәрсә аның «Алла зиратлар тирәсендә булса кирәк» дип уйлануыннан һәм «каберләрнең төбеннән тәмугка, җәннәткә юл бар» дип йөрүеннән иде.

Быел, 17 нче елның язында гына әле «вәлшәви» дигән халык чыккан, Алланы юк дип әйтәләр, ди, кебек сүзләр йөри башлагач кына, ул бөтенләй җиңеләеп китте.

...Дөрестән дә Алла булмаса... бит мәңге тәмугта янарга тиешле Садрый да янудан котылачак...

Ул бу турыда берәр «вәлшәви»не очратып сөйләшергә, Алланың бармы, юкмылыгы турында белергә йөри башлады. Быел Рөстәм авылга кайткач, авылда аның «вәлшәви» булып кайту хәбәре таралды. Садрый аның белән дуслашырга, Алла, тәмуг турында кешегә белдерми генә йөрәктән сөйләшергә йөри башлады. Аның белән «казанча» сөйләшүенең дә көлеп эшләнүе бетте. Ул, чын күңелдән аны зурларга теләп, шулай сөйләп йөри башлады. Рөстәмнең чиркәүгә кереп чыгуын, шул «секрет»ны сөйләми йөрүен Рөстәм өчен эшләнгән зур бер хезмәте итеп санап йөри иде. Ул бу юлы, урманда Рөстәмне ялгызын очратып, шул хакта сөйләшергә карар кылып куйды. Һәм Рөстәмгә ялагайлану йөзеннән сүзгә башлады:

– Выт, Рөстәм, син инде укыган кеше. Әйтик, безнең кебек әлләзи түгел. Патшаны төшердегез. Выт, пастуксыз куйлар да йөреми. Ә безнең кебек сукин сыннарны, примир, ницек инде волхутка ебәрәсең. Без гурлаларыбызны ценәшеп бетәрбез, – диде. Үзе эченнән генә үзенең, гөнаһлы кеше булса да, әлләзи, сукин сын түгеллеген, Рөстәмнең патшаны төшерергә һичбер катнашы булмавын, патшаны «ыскубиннар» төшерүне, бу сүзне Рөстәмне күтәрү өчен генә әйтүен уйлады.

Рөстәм Садрыйның үзе белән сөйләгәндә һәрвакыттагы кебек «ц» авазы урынына «ч» авазы кулланырга онытуын, аның чын күңелдән сөйләшә башлавы дип аңлап елмайды. Үзе дә онытылып барган авыл теле белән сөйләшергә тырыша башлады:

– Соң, Сәдрү агай, патша төште ни, төшмәде ни, барыбер вет. Эш патшада түгел. Патша ул болай күрек өчен генә. Аның бөтен мәнесе патшаның строенда. Байлар, помещикларны яклый торган кешеләрнең безнең өстә хуҗа булып торуларында.

Рөстәм, Габбас белән Садрыйның сөйләгән нәрсәләрен аңлаулары-аңламаулары турында уйлый-уйлый, мөмкин кадәр аларның үз телләре белән әкрен генә, киләчәктә нинди хөкүмәт булырга тиешлеге турында, тигезлек турында үзе белгән нәрсәләрне сөйләп китте. Садрый, Рөстәм тигезлек турында сөйләп бетергәч, тигезлекнең һичбер вакытта да булачак түгеллегенә крәстияннәр арасында мисал ителеп йөргән биш бармакның да тигез яралмавын әйтергә һәм Рөстәмне аптыратырга уйласа да өлгермәде. Сүзне Габбас алып китте:

– Эх, Рстам, Рстам, син әтәсең, тигезлек, дип. Хут сине алыйк, Госман Мокуны белән, әтик, примир, сине ницек тигез ясыйсың, ул, башы сынгыры, прахлати, умере буе пиц башыннан төшми ята. Төшкәндә дә җир алма ашарга, тышка чыгарга гына төшә... – диде. Үзе китергән мисалының гакыллы булуын, Мокун белән үзе арасында җир белән күк арасы кадәр булган аерманы, үзенең Мокун кебек кешеләр белән сөйләшергә дә җирәнүен уйлап алды.

Сүз кызып китте.

Рөстәм Мокунның ярлы булуының аның ялкаулыгыннан килеп чыккан әйбер булмавын аңлатырга теләп сөйли башлады.

Ул әкрен генә, үзе дә белми, бүгенге баш әйләндергеч сәяси вакыйгалар, үлем кырлары турында уйлый башлады.

Үткәннәргә бөтенләй охшамаган, караңгы да, белемсез дә, ниндидер хыялдагы кебек коточкыч үлем кырлары турында фронтлардан кайткан, сынган куллы, биртелгән җилкәле, ыржайган иякле солдатлар теле әкият сөйли.

Алар, сөйләгән нәрсәләренең әкият булмый, дөрес булуына үзләре дә ышанмаган төсле, уйланып, онытылган, ләкин коточкыч төшләрен хәтерләргә теләгәндәй итеп, күзләрен зур итеп ачып, басынкы тавыш белән күз алдына үлем кырларын җанландыралар...

Рөстәм белән бергә үскән киң күкрәкле, таза Тулпан егетләренең бик күбесе үзләренең иптәшләреннән олагып, шул караңгы үлем кырларында, туганнар каберендә калдылар.

Сәяси вакыйгаларны ачык итеп аңлауга хәзерлексез Рөстәмнең уйлары, бер кешедән икенче кешегә күчә-күчә, 17 нче елның сәяси фонында кешелекнең киләчәген күрергә яктылык таба алмый буталды, адашты...

---

Агач яфраклары арасына яшеренеп кенә төн килә. Тын. Җилсез урман төне. Юкә кисүчеләр, берәм-берәм агачлар арасыннан чыгып, аш хәзерләп ятучы Рөстәм тирәсенә җыела башладылар. Алар кулларындагы балталарын кайсы – җиргә, кайсы агачка чабып, әкрен генә капчыкларыннан икмәкләрен, кашыкларын чыгарып ашарга хәзерләнергә тотындылар.

Юкәдән билбау ишеп, шул билбауга балтасын кыстырган килеш, агачлар арасыннан озаеп-озаеп Морат килеп чыкты. Ул, килеп чыгу белән, чабагачка сапка дип күтәреп кайткан берничә туры, туналган юкә агачларын карт наратка сөяп куйды да чиләктә быкырдап пешеп яткан боткага карады һәм Рөстәмгә, агайларча:

– Бак, боткаңны яндырма, берсәк болгап ал! – диде. Үзе, черкиләрдән качып, төтен астына кереп утырды.

Рөстәм ботканың янмавын яхшы белсә дә, Моратның күңеле булсын өчен чиләктәге ботканы берничә мәртәбә болгап алды. Моратның йөзендә ниндидер зураю, агайлану төсе күренде.

Морат ул Рөстәм белән күрше булып бергә үсте. Рөстәмнең бик күп яшьлек хатирәләре аның белән бәйләнгән.

Аның кояш ашаудан яргаланып беткән зур борыны, кеше өстенә капланырга торгандай ике зур колагы аны әйләндереп кигән тире туннан куркып, колакларын торгызып карап торган ак йонлы куйларга охшата. Акка якын сары чәче, ак ком төсле керфекләре дә моңа ярдәм итәләр. Аңарга караган кеше иң беренче аның башын-күзен күрми, колакларын, борынын күрә. Морат көлгән вакытта да гүя колаклары, борыны белән көлә төсле.

Рөстәм яшен тизлеге белән аның бөтен гомерен күз алдыннан үткәрде. Ләкин аның табигый, үзенеке дип әйтерлек бер генә хәрәкәте дә күз алдына килеп баса алмады. Аның һәрбер хәрәкәте үз хәрәкәте түгеллеген, кемгәдер ияргәнлеген кычкырып торалар төсле. Йә ул үз яшенә туры килмәгән картларча итенә, яки аның хәрәкәтләре үзеннән яшь балаларныкына охшый. Әллә балалык итенешләре дә аңа килешеп бетмәгәнгәме, әллә борыннары үзләре табигый хәрәкәтләр ясый белмәгәнгәме, ул бик яшьтән үзе ошаткан кешеләрнең хәрәкәтләренә иярә башлады. Ул, Шәрәфи агай кебек, кулларын артка куеп йөри, атын болынга озата барганда, ат өстенә утырмый, картлар кебек башыннан гына тотып бара.

Кырда эшләп ятучы таныш, таныш булмаган кешеләргә, унике яшеннән ким булуга карамый:

– Алла хуат бирсен, бак, ницек Ходай яңгырны бирде, – дип зурларча сөйләнеп үтә.

Аны таныган кеше дә, танымаган кеше дә бу сүзнең Моратның үз сүзе түгеллеген, картларга ияреп әйтүен аңлап елмаялар. Аның буе да үз яшенә туры килеп үсмәде. Сигез яшендә чагында ул буе белән унике яшьлек балалар зурлыгында иде. Әллә шул буе артыннан эчке тормышы үсеп өлгермәгәнгәме, ул ике кеше булып үсте, сыны белән йөрәк тормышы, йөрәк хәрәкәтләре бергә кушыла алмады.

Үскәч тә, бәла аның артыннан йөрде.

Аңар егетлек тә килешмәде.

Егет булып итенгәндә, аның хәрәкәтләре, егет булуына ышандырудан бигрәк, егет вакытны үртәргә теләгәндәй, табигый чыкмадылар. Ләкин ул бар көче белән җитди булырга, үзенә егет итеп каратырга тырышты. Ул бөтен нәрсәне шул юлга файдаланды.

Берәр туйда яки өмәдә әз генә эчәргә туры килсә, авыл буе тыныч кайта, ә үз өенә җитәргә бер ун йорт калгач, күрше Җамали кебек, башын селкеп-селкеп җырлап, сүгенеп, кычкырынып ава-түнә кайта башлый. Шулай итеп күрше хатын-кызларына зур эчүчеләр кебек булуын күрсәтергә тырыша. Ә аның итенешләрен карап торган күрше хатын-кызлары:

– Бак, бак тилегә, хәзер генә теп-тере иде, өенә җитә башлагач, котырына башлады. Бак Эләмшә Ксугына, – дип башларын селкеп, көлке катыш карап торалар. Беркем дә аның дөрестән шулай исерек булуына, исергәннән шулай ава-түнә сүгенеп килүенә ышанмыйлар.

Моратның өйләнүе дә күршеләре тарафыннан кызык, көлке бер нәрсә ителеп каршы алынды. Аның туена курчак туена караган кебек карадылар. Кияү булып йөргән вакытындагы итенешләре күршеләре өчен айлар буенча рәхәтләнеп көлеп сөйләрлек вакыйга булып калды.

Өйләнүенә бер атна үтәргә өлгермәде, ул бер сәбәпсез хатынын кыйнап ташлады. Моны да ул хатынына үзен усал ир итеп күрсәтү өчен, тирә-күршеләренә үзен хатынлы ирләр кебек була алуына ышандыру өчен эшләде дип сөйләделәр...

Юкә кисүчеләр арасында бары Фәтхулла гына Моратка башкалар кебек көлеп карамый. Ул аңарда башкалар күргән көлке хәрәкәтләрне бөтенләй күрмиме яки башка берәр сәбәп беләнме, ул аның белән җитдирәк итенә. Фәтхулла – унике еллар чамасы авылдан аерылып, кайдадыр Себер якларында йөргән кеше. Ул, бәлки, Моратны белмәгәнгә шулайдыр. Ә башка юкә кисүчеләр хәтта Моратның чабагачка саплар алып кайтуыннан да көлделәр. Морат, дөрестән дә, ул агачларны бик кирәктән алып кайтмады. Ул бары юкә кисүчеләр арасындагы Шәрәфигә ияреп кенә бу эшне эшләде. Ә Шәрәфи авылда иң җитез крәстияннәрдән санала. Ул хуҗалыгына кирәкле бөтен нәрсәне үзе эшләргә, үзе булдырырга тырыша. Шуның өчен анда хуҗалыкка кирәк нинди генә әйбер булса да, бар булып чыга. Чабагачлары җиңел, таза, сәнәк саплары туры, арбасы һәрвакыт төзәтелгән була. Ул урманга барамы, яки урман яныннан үтәме, ни дә булса хуҗалыгына кирәкле бер әйбер кисеп кайта.

Юкә кисәргә килүгә дүрт-биш көн булмады, ул әллә күпме туры саплы, ботаклары өчкә-дүрткә аерылып торган сәнәкләр хәзерләп куйды. Әкият сөйли-сөйли, өч пар чабата үреп ташлады. Хәзер дә ашка кадәр юкәдән нәрсәдер ишеп ята.

Рөстәм юкә кисүчеләрнең бөтенесе белән бергә үсте. Ул һәрвакыт диярлек аларның күз алларында йөрде. Ләкин ул алар өчен чит булып, «Аю Ибругы улы цугынган Рстам» булып үсте.

Күршеләре Мораттан көлсәләр дә, ни булса да алар аны үз кешеләре итеп саныйлар. Аның алдында гакыллы булып сөйләргә дә тырышмыйлар. Ул булган җирдә алар үзләрен тыгызланган итеп тә хис итмиләр.

Рөстәм алар белән юкә кисәргә килгәч, алар икенче көнне үк аны аш пешерүче итеп билгеләделәр. Юкә кисәргә килүен ахутага, байларча дачага чыгу өчен эшләнгән эш дип карадылар.

---

Аш ашаудан соң юкә кисүчеләр, төрлесе төрле якка таралып, тәмәке тарта башладылар. Шәрәфи көндәгечә юкә чистартып чабата тукырга хәзерләнә башлады. Үзеннән читтә тезләрен кочаклап утырган Галләмгә:

– Пләмәнник, утны кыздырып ебәр әле, комарлар ашый башладылар, – диде һәм өстәп куйды: – Э, барамга алырга атлар килмәде. Придутсы аетне монда укырга. Мулла Рөстәм, аетне мулласыз укуга китап ни ди икән?..

Садрый:

– Китап-митап монда юк, мулла Шәрү. Тотабыз да ай-хайлүкне укып әттереп ташларбыз. Морат мулла булыр.

Морат, Садрыйның көлепме, чын күңелдәнме әйтүен аңламый, җитди төс алды. Соңыннан аның мулла булуы турында сүз кузгатучы булмагач, ян ягына ятып, үлән белән тешен әрчи-әрчи, җиргә карап тора башлады.

Садрыйга кодарак тиешле Габбас, Садрыйның сүзен яратмый:

– Эх, Сәдрү, Сәдрү, хут намаз турында гына кеше теле белән сүләр идең, – диде. Үзе чын күңелдән ачуланып читкә борылды. Һәм, юкә кисүчеләр арасындагы берничә абруйлырак крәстияннәргә карап, мәчет карты рәвешендәрәк: – Җәмәгать, аетне монда укырбыз, тәрәтләрне чын көңелдән алып укысак, Алла Тәлә монда укыганда да кабул итәр, – диде.

Башка картрак крәстияннәр дә дин тоту кебек зур мәсьәләдә яшьләр алдында үзләренең җитди булуларын күрсәтү уе белән аның сүзенә кушылдылар.

Фәтхулла:

– Әббәс абзый, күлмәк-ыштаннар ару түгел вет, аларны ни эшләтербез? – диде.

Габбас, Фәтхуллага җавап биргәндә, аның дин мәсьәләсенә җитди каравына хөрмәт йөзеннән аны күтәрә төшеп:

– Мулла Фәтхулла, ыштаннарны кичтән юып куярга да мөмкин, төн буе саркыр, – диде.

Садрый, ботын кашый-кашый, чын күңелдән сүзгә катнашты:

– Синең, суат, шаравырың бар. Ә выт Морат белән безнең ыштаннан башка әйберебез юк. Мин, суат, истинҗасыз йөрмим. Мин ыштанны юмый гына укырмын, – диде.

Габбас, Садрыйның ничек әйтсәң дә сүз күтәрә торган кеше икәнен белеп, аның үз теле белән бик каты җавап кайтарырга уйласа да, үзенең дәрәҗәсенә зарар китерүдән куркып:

– Денсез син, суат, денсез... Син истибрасыз түгел, гаеткә дә тәрәтсез бара торган кеше.

– Их, суат, суат, Алла Иван Сәдрүенең тәрәт беләнме, тәрәтсезме гает укып йөрүен бик тикшереп тора торгандыр... Сәдрү Алла Тәләгә бик кирәк, ти. Алла, суат, безнең туганны да белми торгандыр. Нитумшты үзе өчен ает укып йөрүне. Без, суат, аеткә барсак та, тәрәт-мәрәт алмицы, мулла артыннан калмицы, мулла куда, мы туда, цмбурахты, цмбурах[6] халык, шулай вет, Морат.

Морат Садрыйны яратса да, Садрыйдан абруйлырак картлар алдында үзен дин турында картларча уйлый торган кеше итеп күрсәтергә теләп, җавап бирми тәмәкесен төрә башлады.

Шәрәфи, көлә төшеп:

– Синең, Сәдрү, навирны гөнахларыңны яза торган фирештәләрең оятсыз сүзләреңне тыңлый-тыңлый глухиланып беткәннәрдер...

– Ә ул фирештәләр миндә бардыр дип уйлыйсыңмы? Алла Тәлә, Шәрү агай, Иван Сәдрүе белән глухуй Шәрүе өцен дөньяда дүрт фирештә симертеп ята дип уйлыйсыңмы? Юк, Шәрү, йөрәк маем, юк! Алла бәхет эләшкәндә дә безне оныткан, ден эләшкәндә дә. Киямәт көнне каршына барып цккац, үзе, этәм «Сез каян килеп цктыгыз – Мукшы Путтасыннанмы, Урыс Салазгырыннанмы?» дип аптырап калмасын...

– Эх, Сәдрү, Сәдрү, изге көннәрдә генә бераз Ходайдан куркыр идең! Сакалың агарып килә, савап эшләмәсәң дә, хут гөнах эшләмәс идең.

Садрый Габбаска җавап бирми сөйләшүләрен тыныч кына тыңлап торган Рөстәмгә карады. Рөстәм елмайды.

Урман, яшел яфраклары астына җир җылысын яшереп, тын гына, әкрен генә сулыш ала. Яфракларының шалтырауларыннан көмеш тавышлары чыгарып, күршеләренә ашыгып-ашыгып мәңге ниндидер күңелле бер нәрсә сөйләгән кебек шаулап торган усаклар күршеләре ак каеннарның йокыларын бозмаска теләгәндәй тын торалар...

Юкә кисүчеләр, көлешә-көлешә ут тирәсенә җыелып, чабаталарын чишенә башладылар. Габбас башкаларга үрнәк булу өчен башлап үзе чишенде. Башкалар да аңа иярделәр.

Садрый, чишенгән аягының бармак араларын кашый-кашый:

– Син, суат, этәсең дә, юк, Аллах Тәлә безнең аетләрне дә сортларга бүлеп капцыкларга тутырып бара торгандыр... Муллаларның, байларның гаетләрен крупцатка сала торган капцыкка фирештәләр өцен, ә безнең аетләрне, навирны, шайтаннарга ашатыр өцен тузган капцыкларга тии бара торгандыр... Примир, мин янымда укуцы кеше Иван Сәдрүе дә намаз укый белә икән дисен өцен генә авызны шапырдаткан булам, ә выт гөнахдыр, үзем цүп тә белмим. Авыз эцемнән: «Әлхәм колху[7] салкын су, мулла артыннан калмый ку, бөгел дә ят, ят та тор, җомах юлы тап-такыр», – дим дә торам. Бу нәрсәне дә бабай мәрхүм, авыр тупрагы җиңел булгыры, эрәткән иде. Примир, азанцы «иләхи ният кылдым» дип ниятләсә, ниятең ният була, ниятләмәсә, колакларны селкетәсең дә торасың. Юк, суат, намаз укып без гөнахлырак булабыз... Намаз укымасаң, мәцет тирәсенә барып Алланың күзенә күренеп йөрмәсәң, гөнахың да азрак була...

Габбас, Садрыйны чын күңелдән сөйли дип белеп, аңа йомшаграк тел белән аңлатырга теләде:

– Син, суат, алай этмә, көңелең яхшы булу кирәк. Көңелең Алла Тәләгә якын булса, дуаларны белмәсәң дә, намазың кабул була. Борын заманда бер телсез булган, ди...

Ул, сугымчы Шатай Ибругында кунакта утырганда, мөәзин авызыннан ишеткән ниндидер телсезнең чын күңелдән гыйбадәт кылуы өчен җәннәткә керүен, җәннәткә кергәч, теле ачылуын сөйләп китте. Сөйләп бетерү белән, Ибраһим:

– Әббәс абзый, выт син ул телсез мәңгегә җмахка кергән дип әтәсең, ә вет киямәт булганы юк әле. Киямәт булмый, сират күперен үтми Алла кемне дә җмахка кертми, бу ницек инде?

Габбас бу сорау алдында аптырап калды. Бертөрле дә җавап таба алмагач:

– Ансын, Ибрук, Ходай үзе белә инде, – диде.

Сәдрү, чабаталарын чишенеп бетү белән, яланаяк чыклы салкын үләнгә баса-баса, нарат ботагына элеп куйган чикмәнен алды да ут янына җәйде. Күлмәк-ыштаннарын салып җиргә ятты.

Рөстәм караңгылык эченнән аңа карады. Аның күкрәкләре сары йон белән капланган, муены тирән-тирән җыерчыклар белән тулган. Сары йоннар белән капланган муен тамырлары өскә чыгып торалар. Күкрәк итләре җыерчыкланып аска табан салынган. Ул ары-бире бер ике әйләнде дә, черкиләргә түзми чикмәнен киде һәм юкә белән билен буды.

Габбас, кулына ике буш чиләк алып:

– Ну, киттек. Иртәрәк ятырга булыр. Ату гаеткә тора алмабыз, – диде.

– Ә киемнәр янында кем кала?

– Киемнәргә ни булыр? Монда урманда чурт та юк. Адә, тизрәк барабыз да кайтабыз.

Сәдрү, күмердән тәмәкесенә ут кабыза-кабыза:

– Суат, сез барып юынып кайтыгыз. Ә без Рөстәм белән киемнәр янында калабыз. Сез каткац, без барырбыз, – диде.

Габбас кулын селтәп елгага таба юнәлде. Аңа ияреп Шәрәф, Нәҗми, Фәтхулла, Галләм, Ибраһим һәм башкалар киттеләр. Рөстәм Сәдрү белән калды. Ул арка өстенә ятты да күзләрен йолдызларга текәде. Акыл күзе җитмәслек ерак күк бушлыгы аңа яшьлеген, яшьтәшләре белән Сираҗи агай атына утырып ат кунарга баруларын, үләнгә арка белән ятып, йолдызларга карап йокыга китүләрен искә төшерде.

Ут янында тәмәке тартып ятучы Садрый да, кеше өстенә колаклары белән карый торган Морат та, кулларын гомер буе артка куеп йөрүче Габбас та, Шәрәфи дә – барысы да Рөстәмнең күз алдында үскән, күз алдында картайган кешеләр. Ул үзен белештерә башлаганнан бирле шул кешеләрнең башларыннан үткән вакыйгаларны, аларның гомер юлларын, үзенең алар арасында ятим үсүен уйлый башлады.

Атасы үлгән елны ул укып йөргән мәктәпкә рус теле укыту өчен яңа бер учительница килде. Рөстәмнәрнең йортлары яңа, чиста булганга, Рөстәмнән башка бала да, ир заты да булмаганга, ул шатланып аларга квартирага керде.

Бу моннан тугыз ел элек иде.

Ярлы бер учитель кызы, фикере белән революционерка Антонина Ивановна Тамарина Рөстәмнең анасы Гайшә абыстай белән бик тиз дуслашып китте. Моңа Антонинаның диварга тәре куймавы һәм бервакытта да чукынмавы сәбәп булды. Башта Гайшә абыстайның русча белмәве аңлашырга киртә булса да, соңга таба алар ярым хәрәкәтләр, ярым сүзләр белән көлешә-көлешә бер-берсен аңлашырга өйрәнделәр. Ә бер-ике айдан Антонина аларның якын дуслары булып китте. Ул, аларга квартирада торуы өчен акча түләп барган кебек, акча кирәк вакытларда күп санашмый акчасы белән Рөстәмнәрнең чыгымнарына да кергәли башлады. Моңар каршы Гайшә абыстай сөт, бәрәңге, икмәк кебек әйберләрен исәпләми бергәлек итте.

Шат, шаян Антонина, кыргый бер хайванны өйрәткән кебек, әкрен-әкрен Рөстәмне үз тирәсенә иләштерә, үз тирәсенә тарта башлады. Башта мөмкин кадәр Антонина белән бер бүлмәдә калырга курыккан Рөстәм тора-бара Антонина бүлмәсеннән чыкмый башлады. Яшь Рөстәм бик тиз русча сөйләргә өйрәнә һәм, шулай итеп, Гайшә апай белән Антонинаның тәрҗемәчесе була башлады. Соңыннан әкрен генә Антонина аны рус теле укытырга, аны уку белән кызыктырырга башлады. Гайшә апай башта, Антонина улымны яшереп чукынырга өйрәтмиме дип, куркып тикшеренебрәк торса да, ул-бу күренмәгәч тынычланды. Рөстәмнең татарча да яхшы укып баруы аның бу шөбһәләрен җиңде. Рөстәм елдан-ел укуга бирелә, укыган саен укуга күмелеп барды. Шулай итеп, ул ике ана кулында белемсез киләчәккә хәзерләнә, үсә, үскән саен белемсез каршылыклар эченә күмелә барды.

Аның авылдашлары барган юлдан бармавы крәстияннәр арасында үзенә ниндидер көнләү, күралмау, шуның белән бергә ниндидер читләү хисләре уятты. Рөстәмнең хыялында авылы белән, аның эчке тормышы белән килешә алмау хисләре уянды. Ул әкрен-әкрен үзе белән бергә үскән иптәшләре уйнаган уеннарның кызыклыгын, соңыннан ул берәм-берәм аларны үзләрен дә югалта башлады. Алар үзләре дә аның белән йөрүдән кызык тапмый башладылар. Аннан ераклашканнан-ераклаштылар. Ул көннәр үткән саен үзенең таза тормышлы крәстиян булуга, авылдагы Нуркәй уллары кебек данлыклы сәүдәгәр булуга булган омтылышларын югалта барды. Укымый гына үссә, бәлки, берәр җиргә китеп, шәлче, буфетчы булыр иде. Ак якалар киеп, костюмнардан авылга төшәр иде. Бөтен фикере тамагын туйдыруга, авылда абруйны күтәрүгә, башкалар белән ярышырга юнәлер иде. Аның башында боларның берсе дә калмады. Шуның белән бергә ул үзенең киләчәктә кем буласын да, кем булырга тиешлеген дә

билгели алмады. Буш вакытларында укыган романнарындагы каһарманнарның омтылышларын үз омтылышы итте. Укытучы тормышыннан берәр нәрсә укыса, укытучы булырга, инженерлар тормышыннан берәр нәрсә укыса, инженер булырга, шагыйрьләр тормышыннан берәр нәрсә укыса, шагыйрь булырга омтыла башлады. Ләкин бу нәрсәләр аның хыяллары гына иде.

Антонинаның бер техникка иргә чыгып Тулпаннан китүе аны бөтенләй ярты юлда калдырды. Антонина киткәч, матди яклары начарлашу, җирләрен уртагыннан эшләүче Сираҗи агайга да, вак-төяк чыгымнарга да акча булмавы тормышларын артык авырлаштырды. Атсыз авылда көн итәргә мөмкин булмагач, Рөстәм кардәш тиешле Исмәгыйльгә малай булып сәүдәгә китәргә булды. Ләкин ул сәүдәгә дә күңел бирә алмады. Ара-тирә кулга төшкән китапларны, газеталарны укудан башка укырга мөмкинлек булмады. Ул, бер урыннан бер урынга күчеп йөри-йөри, өч ел эчендә күп кенә җирләрдә эшләде һәм, унҗиде яшьлек малай булганы хәлдә, революцияне эшсез килеш, яланаяк «Марсельеза»[8] җырлап урамда каршылады...

Рөстәмнең уйлары шул җиргә килеп тукталгач, аның нәрсә турында уйлап ятуын белмәгән Садрый уйлануыннан туктатты. Ул, сүз әллә кайчан дәвам иткән кебек:

– Син әтәсең дә, Рөстәм, ә выт байларның күлмәк-ыштаннары ару була, акцалары булгац, сәваплары күп була. Бу дөньяда да хлапутсыз гына торалар, теге дөньяда да җмахның түрендә утыралар. Син ницек уйлыйсың?..

Рөстәм Садрыйның сүзен болай хәзерлексез генә, уртадан башлап китүен, аның үз тышына һаман шул хакта уйлап ятуыннан дип уйлады. Ә Садрый сүзендә дәвам итте:

– Выт сине, әтик, укыган кеше инде, акны карадан, караны актан аера беләсең. Дөньялыкны да, денне дә мулладан ким белмисең... Ницек инде?.. Әтәләр, шундый кешеләр цыккан, ди... Алар урыс Алласы да, татар Алласы да, тәмуг та юк дип әтәләр, ди. Ницек инде ул?..

Рөстәм Садрыйның ни өчен мондый сораулар бирүенең серен аңламады. Аның күз алдында Садрыйлар, үзенең авылдашлары белән ике уртадагы каршылыклар килеп бастылар. Бит шул ук Садрыйлар үзләре барган юлдан бармавы өчен, динсезлеге, «урыска цукынганлыгы» өчен Рөстәмне күралмадылар. Аның турында еллар буенча төрле гайбәтләр сөйләделәр. Хәзер дә Садрыйның мондый сораулар бирүе сер сынар өчен генә бирелә дип уйлап, Рөстәм:

– Андый кешеләр бар ди шул, Сәдрү агай, – дип, ике яклы итеп җавап бирде.

Ләкин бу җавап Садрыйны канәгатьләндермәде. Ул, ничек тә мәсьәләгә якынрак килергә теләп:

– Сине выт үзеңне дә денсез дип сүлиләр. Ә син үзең шул сүләгән кешеләрдән денне күбрәк беләсең. Әтик, Әббәс ул ден турында ни белә?.. Ә сине орыша... Безнең кебек кешеләр Алла турында цүп тә белмибез. Әтик, тәмуг турында да... Син, пләмәнник, цынны сүләүдән курыкма... Беләсең выт, Алла ул Иван Сәдрүе өцен җмахны әзерләп куймаган... Хур кызларын да бирмәс. Безнең кебек сукин сыннардан бу дөньяда да суган суы суырдыра, теге дөньяда да үзебезне үк яндырыр өцен тәмугына кисәү ташытып әләс-мәләс ясап бетерер...

Рөстәм Садрыйның сөйләвеннән түзми көлеп җибәрде һәм Садрыйның йөзенә карады. Һәрвакыт шаярып, бөтен нәрсәдән көлеп йөргән Садрыйның йөзе артык дәрәҗәдә җитди, уйчан булып күренде.

Рөстәм үзенең алдында туасы таңның яктылыгын сизеп уянырга хәзерләнгән кешене – үзен гомере буе изеп килгән караңгылыктан чыгарырга юл эзләүче Садрыйны күрде...

**II**

Чәчәкләр кояшка карап көләргә тырышалар.

Таң суыгы туңдырган аларны. Канатларын чыкларга чылаткан. Каеннар бәхетле алар: зур итеп үсә алганнар. Аларны бернәрсә дә кояштан каплый алмый. Алар кояшның күзенә туры карый алалар.

Каен яфракларында көмешләнгән кояш нурлары әле урман чәчәкләренең канатларына тамган чыкларны киптереп өлгермәгән. Бары юл кырыйларындагы чирәмнәрдә үскән кыр чәчәкләре генә җылынып өлгергәннәр. Алар инде кояшка карыйлар да күзләрен кысалар, ә кояш киң кырларга, чиксез яланнарга үзенең җылы канатларын җыя.

Юл буенда әле җиләкләре кызарып өлгермәгән җиләк сабаклары озын үләннәр арасыннан югарылыкка табан муеннарын сузганнар. Бары авыраеп килә торган җиләкләре генә аларны җиргә табан бөккән.

Рөстәм Леонид Андреевның «Савва» дигән китабын кесәсеннән чыгарып, әйләндереп-әйләндереп карады да укый башлады. Ул бу китапны инде бер атнадан бирле укып йөри. Укыган битләрен тәмәкегә тартып бара. Бу юлы да ул, ертылырга тиешле битенең укылмаганын белеп, алга тагын бер-ике бит укып чыгарга, шулай итеп, бүген шул укылган битләрне тартып йөрергә булды. Ләкин, укый башлагач, ул ике биттә генә тукталып кала алмады. Юллар үзләренә бәйләнгән юлларга тарттылар, битләр үзләренең күрше битләренә бәйләп, аны китапның эченә алып

киттеләр. Урманны кисеп станциягә үтә торган юл белән атының ялкау гына атлап килүенә йокымсырап кырын ятып килгән карт мукшы үләннәр арасында югары күтәрелеп торган Рөстәмнең ике аягын күрү белән сискәнеп китте. Ул, тезгеннәрен кулына алып, тирә-ягына каранды да каршы яктан ике атлының килүен күреп тынычланды. Кулына эләккән салам кисәген чәйни-чәйни, кире арбасына ятты.

Тирә-якны каплап алган очсыз-кырыйсыз киң урманнар хәзер инде куркыныч булып китте. Герман сугышыннан[9] винтовкаларын алып кайткан бик күп солдатлар юлбасарлыкка киттеләр. Семенов урманнары турында коточкыч хәбәрләр сөйлиләр. Әле моннан ике генә атна элек олы юл өстендә өч үле гәүдә тапканнар.

Крәстияннәр хәзер урманнарда йөрүдән куркалар. Төннәрдә урман урлап кайтырга барганда, бишәү-алтау җыйнаулашып кына барып кайталар. Урман арты авылларына ашлык алырга баручы крәстияннәр дә, җыйнаулашып, балталар белән коралланып, юлга чыгалар. Ашлыкларны алып кайтучы отрядлардан да куркыныч булу сәбәпле, күп урыннардан качып-посып төнлә генә үтәргә туры килә. Шуның өчен ялгыз-ялгыз урманнан үтеп баручы крәстияннәрне очрату авыр.

Уйлы-базлы юлдан дыңгырдап үткән арба тавышына Рөстәм башын күтәреп караган иде, мукшының йокымсырап килгән аты, сискәнеп китеп, юлдан читкә борылды. Мукшы, урыныннан торып, тезгеннәрен тартты да, Рөстәмгә кырын гына карап, атын сугып җибәрде. Арык, сугуга өйрәнгән ат чыбыркыга каршы койрыгын бер-ике бутады да йокымсырый-йокымсырый юлында булды.

Рөстәм башын күтәреп карауга, күз аллары караңгыланып китте. Ул, башын ял иттерү нияте белән, укылган битләренең берсен ертып алды да, арка өстенә ятып, тәмәке төрә башлады.

Аның башында «Савва» тибы буталды. Савваның чиркәүне җәһәннәм машинасы белән күтәрергә теләве, аның коточкыч сүзләре телендә әйләнде.

«Кешеләр дөньяны төрмәгә әйләндергәннәр». Шушы төрмәнең астын өскә китереп җимерергә, кешеләрне табигать эчендә ялангач килеш калдырырга... Рөстәм бу фәлсәфәне үзе киңәйтергә теләде. Аның башына «Соң, шул төрмә мәдәниятен җимергәч, ни эшләргә?» дигән сорау килде.

Арыш басуы аркылы ерактан күренеп торган янган элеваторның хәрабәләре[10] яныннан ак төтенен үзенең вагоннары өстенә ябып, кечкенә тимер юл станциясенә кереп барган поездның кычкыруы аның уйларын икенче якка борып җибәрделәр. Ул, тәмәкесен авызына кабып, читтә аунап яткан сумкасын алды да, урыныннан торып, тимер юл станциясенә табан юнәлде.

Поезд үзенең йөрешен әкренәйтү белән аның йөрәгендә ниндидер бер ашкыну уятты. Бәлки, шул поезд белән Төркестанда йә башка берәр шәһәрдә очрашкан Рөстәмнең берәр танышы үтә торгандыр.

Ул станциядә кайнап торган халыкны күз алдына китерде. Шулар арасыннан үзенә билгесез үтүчесен эзләде. Күз алдыннан йөзләрчә танышларның йөзләре чагылып үтте. Ниндидер таныш түгел матур кызларның поездан төшеп сөт сатучы марҗаларга таба йөгерүләре күз алдында җанланды. Аның адымнары тизләде. Ул поезд китүгә кадәр станциягә җитәргә ашыкты.

Ерактан кызыл гәрәбә кортка охшаган поездның паровозы, гәүдәсеннән аерылып, кычкырта-кычкырта, таллар арасына кереп югалды.

Рөстәм станциягә килеп җиткәндә, сөт сатучы марҗалар, сөтләрен сатып бетереп, балчык комганнарын капчыкларына тутырып яталар иде инде. Тик сөтләрен сатарга өлгерми калган кайбер яшь кызлар гына, бер вагон тәрәзәсеннән икенче вагон тәрәзәсенә йөгереп:

– Менә сөт, сөт кемгә кирәк? – дип кычкырып йөриләр иде.

Рөстәм, станциягә җитү белән, адымнарын әкренләтте. Кесәсеннән «Савва» китабының бер битен ертып алып, йөзендәге тирләрен сөртте һәм әкрен генә вагоннар буйлатып еракка, әллә кайларга үтүче юлчыларны карый башлады.

Кара сукнодан тегелгән френч-галифедән, кара, матур яшь кенә егет, револьвер кобурасын төзәтә-төзәтә вагоннан төште дә коймага сөялеп, үткән-барганнарга көлеп карап торучы, чәчләре алдына тузгылып төшкән бер кыз янына килеп туктады. Алар нәрсәдер турында сөйләштеләр дә шат яңгыравыклы көлү белән көлеп җибәрделәр. Рөстәм, алар турыннан үткәндә, күзләрен тутырып кызга карады. Кыз гаҗәпләнгән сыман аңарга карап алды да егетенә күзен төшерде. Һәм егетенә Рөстәмнең каравына гаҗәпләнүен белдерергә теләгәндәй итеп елмайды. Рөстәм, күз кырые белән генә кызның елмаюын күреп, үзе дә сизми кызарды. Адымнары үзләренең табигый агышларын югалтып ялгыш атладылар. Ул күзләрен станциядә чабып йөргән башка кешеләр арасында йөгертә башлады.

Менә шундый ук френч, галифедән берәү ашыгыч адымнар белән пассажирский вагонга кереп бара. Менә тагын бер яшь кенә кыз шул вагонның тәрәзәсеннән тыныч кына ары-бире чабып йөргән юлчыларны карый. Ул бу халык арасыннан танышлар да эзләми төсле. Әллә кайдан, ерактандыр ул. Бу кечкенә станциядә кайнашкан сөтче

марҗалар алар бик күп станцияләрдә аны каршылаганнардыр. Ул бары вагон эчендәге халыклар таралганга, сөйләшер кеше булмаудан гына болай карап тора төсле.

Капчыкларын күтәреп берничә мукшы пассажирский вагонга кереп маташтылар. Аларны ары җибәрмәгәч, капчыкларын җиргә куйдылар да, маңгайларыннан агып төшкән тирләрне сөртә-сөртә, вагонның бер башыннан икенче башына карый башладылар. Соңыннан алар янына тагын бер мукшы ашыгып килде. Ул, кулларын селкеп-селкеп, нәрсәдер сөйли башлады. Алар, тиз генә капчыкларын күтәреп, су эчеп яткан паровоз янына йөгерделәр.

Паровоз вагоннарга килеп бәрелү белән, куркаграк юлчылар ашыгып-ашыгып вагоннарына чаба башладылар.

Пересадникка сөялеп аптырап торган берничә мишәр егете Рөстәмне баштанаяк карадылар да берсе:

– Тегеләрдән берсе... – диде.

Икенчесе:

– Станцада эшли торган кеше түгелме? Мужт, бераз кыстырсаң, утыртыр, – диде.

Рөстәм боларның үзен комиссар дип белүләреннән көләсе килсә дә, көлү урынына ул йөзенә эрелек төсе чыгарып, кулларын артка куеп, югарыдан гына вагоннарга карый башлады. Аның өстендә яңа тегелгән күк сукнодан френч, галифесе, матур гына туфлиләр белән кара, тезенә кадәр күтәреп кигән оеклары, дөрестән дә, аны комиссарларга охшатып тора.

Рөстәмнең кинәт теге кызның көлүе исенә килеп төште. Йөрәге басынкы, авыр, ашкынулы хисләр белән тулды.

Ул матур егетләр алдында итенә белә торган гади бер кыздыр. Аның киләчәге, яшьлек матурлыгы иргә чыгу белән чикләнер, аннан... соң, көлгән икән, ни булган... Поезд биш минуттан аны еракка, бик еракка алып китәр. Ул тагын аны гомердә дә очратмас... Бәлки, ул Рөстәмнән көлүен оныткандыр да инде...

Поездда баручы кешеләрнең күбесе вагоннарына кереп утырганнар инде. Тик кайберәүләре генә үзләренең вагоннары тирәсендә парлашып йөриләр. Менә бер-бер артлы звонок шалтырый. Поезд авыр, әкрен кузгалыш белән рельслардан тәгәри башлый. Аның соңгы саубуллашуы кечкенә станцияне яңгырата. Теге, Рөстәмнән көлгән кыз да, гел тәрәзәсеннән карый-карый, паровоздан чыккан төтенгә капланып күздән югала.

Рөстәм, поезд киткәч, станциядә берничә әйләнде дә, поезд белән Мәскәүдән килгән газеталар алу өчен, станциянең эченә керде. Ул, газета сатучы хатыннан «Правда»[11] газетасын алып килеп, өстәл янына утырды.

Ишек төбендә Чека[12] агенты белән сөйләшеп торган Нәҗип янына май киемнәре киенгән бер кыз килеп туктады. Чека агенты, ике бармагы белән генә кепкасын тотып, аның белән елмаеп кына исәнләште. Алар Чека агентының бүлмәсенә кереп киттеләр.

Нәҗип ул – Рөстәмнәр авылындагы үткенлекләре белән мәшһүр бер нәселдән чыккан кеше. Ул бер кечкенә станциядә унбиш еллап гомер итә. Ул үзе беркайда да укымаган. Шулай да ул – унбиш ел эчендә шул станциянең иң зур кешеләре белән аралашып торган кеше. Элек тирә-яктагы помещикларның күбесе аның белән якын таныш булып яшәгәннәр. Кайчандыр ул тимер юлда машинист булып та эшләгән иде. Тик ул хезмәтне унбиш ел элек ташлап, ул кечкенә станциядә гомер итә башлады. Аның нәрсә эшләвен, кайдан акча алуын беркем белми. Ул һәр көнне поездга каршы чыга. Станция начальниклары аның белән бик дусларча исәнләшәләр. Поезд китүгә, ул, кулларын артка куя да, шаулап торган базар чатына туктап, гөж килеп торган халык өстенә карап тора. Соңыннан тагын базарга каршы гына топольләр эченә зәңгәр буяуга буялган йортына кереп, граммофонын борып җибәрә, үзе тәрәзәсеннән урамга карый.

Аның белән күрше булып торган кешеләрнең күбесе кайчакларда ау мылтыклары алып, озын итекләр киеп, җирән атта ауга чыгып китүләрен сөйлиләр. Тулпан авылында да, станциядә дә колактан-колакка аның турында төрле хәбәрләр йөри. Ләкин ул талашларга, сугышларга катнашмаганга, ачык килеш, кеше ишетерлек итеп, беркем дә бер хәбәр дә сөйләми.

Элек шушы станциядә кибет тоткан Тәбәнәк Хәйри аның турында бик күп нәрсәләр белә, диләр. Ләкин ул беркемгә дә бернәрсә дә сөйләми. Алар элек дус кына торганнар. Бергә эчеп, җырлап төннәрне үткәрә булганнар. Хәзер булса өстән генә исәнләшеп йөриләр. Аларның ни өчен дошманлашуын да күрше-тирә белеп бетерми. Үзләре дә артык сиздермиләр. Бары бергә эчеп, бер-берсенә кунакка йөрешмәүләреннән генә күршеләре аларның аралары бозылганлыкны сизәләр. Тәбәнәк Хәйри аның белән дошманлашу вакыйгасын гомерендә бары бер генә кешегә сөйләгән. Ул да икенче кешегә сөйләми үзенең эчендә йотып калган.

Алар ниндидер бер мәҗлестә бергә эчкәннәр дә, Тәбәнәк Хәйри үзе дә белми кызып китеп Нәҗипкә бәйләнгән. Ләкин Нәҗип үзен тыныч тоткан. Тик Тәбәнәк Хәйри: «Мин синең ни эшләгәнеңне беләм, юк, шалиш минем белән!» – дип җәелә башлагач кына, Нәҗип, аның җилкәләреннән тотып, берсүзсез озак кына күзенә карап торган. Тәбәнәк Хәйри кинәт тын калган. Мәҗлестә утыручылар бернәрсә дә аңламаганнар.

Иртән Тәбәнәк Хәйри, кибетен ачарга чыкканда, кибетенең ишеге ачык, йозагы каерылган килеш идәндә күргән. Ул, ашыгып, кибете эченә кергән дә барып кассасына ябышкан. Кассадан җитмеш сум акчасын кузгалмаган

килеш урынында күргән. Кибетендә бары биш-алты савыт яхшы сорт папирослары гына чыкмаган. Шуннан ул эшнең нәрсәдә икәнен аңлаган да беркемгә дә бернәрсә әйтмәгән. Ә Нәҗип шул төнне ауга чыгып киткән булган...

Рөстәм «Правда»дан сугыш хәбәрләре бүлеген карады да, ашап алыр өчен хәзерге көндә кибет урынына чәйханә тотучы тәбәнәк мишәргә барырга дип, урыныннан кузгалды. Шул вакытта теге кыз белән Нәҗип Чека ишегеннән аның каршысына килеп чыктылар. Нәҗип Рөстәм белән кул биреп исәнләште дә янындагы кызны тәкъдим итте:

– Танышыгыз!

Рөстәм кызның күзләренә туры гына карап кулын кысты. Үзенең исемен, фамилиясен әйтте. Кыз Рөстәм белән исәнләшкәндә аның күзенә карамаска тырышты.

Рөстәмнең хыялында яшен тизлеге белән кызык бер вакыйга чагылып үтте.

Ул кызны бер мәртәбә күргән иде инде.

Унсигезенче елның гыйнварында өяз шәһәрендә укытучылар съезды җыелды. Ирләрдән булган укытучыларның күбесе Кызыл Армиягә алынганлыктан, укытучы булып калучыларның 90 проценты хатын-кызлар. Шуның өстенә руслардан гаскәргә бармый калган ир укытучыларның да күбрәге аксак-туксаклардан гыйбарәт. Съездда матур егетләрнең кызлар алдында бәяләре югары.

Рөстәмнең тузгылып торган кара чәчләре, туры очы аз гына түбәнгә табан бөгелеп торган борыны, зур кара күзләре күпләрне үзенә тарта.

Съезд залында ул үзенең иптәше Виргасов белән чәй эчеп утыра. Алар янында үз авылларында рус теле укытучысы Климская да бар. Биш минут ял итүдән файдаланып, укытучылар парлашып залда йөриләр. Шул вакытта Рөстәмнәр авылында Климская белән бергә рус теле укытучысы Шурка килеп туктады да:

– Ә беләсең, Рөстәм, синең белән бер кыз танышырга тели, – диде.

Климская:

– Чиертте, егет, – диде һәм көлеп җибәрде.

Виргасов кызыкты:

– Кайсы кыз ул? – диде.

Шура:

– Сиңа нәрсәгә, ул Рөстәм белән танышырга тели, – диде.

Рөстәм Шурага карап елмайды:

– Кайсы кыз ул шулай үзенә эш тапмый? – диде.

Шура:

– Тукта, әнә ак күлмәкле кыз белән килә. Ләкин барыгыз да карамагыз, – диде.

Рөстәм, яшерен генә, зал уртасыннан басып килгән кызга карады. Кызның зур кара күзләре, күз тирәсендә сөңгеләнеп торган озын керфекләре Рөстәмнең күзләренә очрадылар. Рөстәм әкрен генә күзләрен алды да Шурага карап елмайды:

– Син әйт ул кызга, ул матур, сөйкемле, ләкин...

Кызлар якынлашу белән, сүзен бүлде. Рөстәм аның белән танышырга теләсә дә, янындагы иптәшләреннән уңайсызланып, кызлар үтеп киткәч:

– Ләкин мин танышырга теләмим, – диде.

Шура:

– Егетләр тарафыннан оятсызлык инде бу, – диде.

Газиз:

– Равноправие хәзер. Элек ирләр шулай танышырга теләгәндә, кызлар отказать итәләр иде, ә хәзер без шулай итәбез, – диде.

Климская, Шурага үпкәләгән сыман:

– Их син, шулай таныштыралармыни, син ул кызга аю хезмәте итәсең. Ул сиңа ышанып әйткән. Ә син кырык кеше алдында киләсең дә, шул кыз синең белән танышырга тели, дисең. Аны Рөстәмгә үзенә дә белдерми таныштырырга иде, дура, – диде.

Алар көлеп җибәрделәр. Залда шалтыраган колокол тавышы аларның сүзләрен бүлде. Укытучылар бүгенге хәлләр турында Уком секретаре Треллинның докладын тыңларга кереп киттеләр. Ә икенче көнне Рөстәмнәр шәһәрдән киттеләр. Шуннан алар бүгенгә кадәр очрашмадылар.

Рөстәм кинәт бу кызның шул вакыйганы хәтерләү-хәтерләмәве турында уйлап алды.

Нәҗип Чека агенты белән исәнләште дә кызга кулын сузды:

– И так, до свидания! – диде.

Кыз, аның күзенә карап:

– Рәхмәт сезгә! – диде.

Нәҗип залдан чыгып китте. Чека агенты да үзен сорап килгән берәү белән бүлмәсенә керде.

Рөстәм кызга сүз кушарга ашыкты:

— Сез кая барасыз?

Кыз борылып аның күзенә карады:

– Мин поезд көтәм.

Ул кулындагы күн сумкасын өстәл өстенә куйды да, якында булган бер стулга утырды һәм Рөстәмне гомердә очратмаган кеше төсле аннан кемлеген, кайда эшләвен сораштыра башлады.

Кояш батып килә. Кыз утырып китәргә тиешле поездны дүрт сәгатькә кичегеп киләчәк дигән хәбәр йөри. Рөстәм, күптән инде кайтып китәргә тиешле булса да, кыз белән сүз бәйләнеп, караңгы төшүгә кадәр станциядә калды.

Кыска язгы зәңгәр төн йолдызлар белән бизәлгән. Җил әллә кайдан, ераклардан килеп өлгермәгән әле. Станция алдын яктырткан бердәнбер газ лампасы үз тирәсенә генә яктылыгын төшергән дә, станциянең башка җирләре караңгылыкта калганнар.

Алар берничә мәртәбә тимер юл станциясе каршында әйләнделәр дә, топольләр арасына кереп, урындыкка утырдылар.

Кыз аның күзенә туры карады.

– Ә беләсез, мин сезне күптән беләм. Сезнең авылда укытучы булып торучы Шура сезнең хакта күп кенә кызыктырырлык нәрсәләр сөйләгән иде. Хәтта, ха-ха-ха... мин сезнең белән танышырга да теләп йөргән идем. Кеше, читтән караганда, һәрвакыт матуррак та, романтичныйрак та, көчлерәк тә күренә...

Рөстәм кинәт кызның күзенә карады. Ул бу сүзе белән кызның үзен кимсетергә теләвен, Рөстәмнең кайчандыр танышмавы үчен ачыграк рәвештә алырга теләвен аңлады:

– Шура сезгә, дөрестән дә, ялганлаган. Мин бик гади кеше, – диде.

Алар озак кына күзгә-күз карашып тордылар. Соңыннан Рөстәм өстәп куйды:

– Кулында гаскәре булмаган генерал ул кешедә елмаю гына уята. Чәй эчкәндә, даһи кеше белән гади кешенең аермасы булмый. Батырның батырлыгын тәмәке тартып утырган вакытында күреп булмый. Аның көчен бары баш әйләндергеч вакыйгалар эчендә генә күреп була.

Ул, кесәсеннән «Савва» китабын алып, бер битен ертты да гади генә рәвештә тәмәке төрә башлады. Ләкин йөрәгендә үзен хәзергә кадәр кыз белән гади рәвештә тотуына үкенү хисләре уянды. Ул кызның соңгы сүзенә кадәр, дөрестән дә, үзен бик гади тотты. Хәтта ул кызның үзендә бик яхшы тәэсир калдыруын да әйтергә хәзерләнгән иде. Ләкин кызның соңгы сүзләре аның йөрәгендә ниндидер бер томанлы ачу, шулай ук кыз алдында үзен саклау хисләрен уянды. Ул әкрен генә, үзе дә белми Савва роленә, кыз теләгән куркыныч та, белемсез дә, ниндидер ят, ләкин йөрәкне дулкынлатырлык бер рольгә кереп китте. Ул коточкыч фәлсәфәләр сөйләде һәм шулай итеп әкрен генә үзен кыз җитә алмаслык югарылыкка күтәрде.

Кыз Рөстәмдә Шура сөйләгән кызыктырырлык якларны башта ук күрсә дә, ул үзенең бер кимсенүен Рөстәм алдында юар өчен Рөстәмне көрәшкә, әле беркем тарафыннан язылмаган матур бер романның йөрәк каршылыклары уртасында туган дулкыннар арасына алып кереп китте.

– Тиздән мин көткән поезд килер.

– Әйе, тиздән.

– Ә ни өчен сез караңгыга калдыгыз? Сез бит китәргә телидер идегез, юлыгыз да ерак.

– Мин китәргә телидер идем. Юлым да ерак.

– Шулай да китмәдегез?

– Шулай да китмәдем.

– Ә ник китмәдегез?

– Белмим.

– Ә ник сез минем күземә карыйсыз?

– Белмим. Башка күз төшәр әйбер булмагангадыр. Ә, впрочем, сез матур кыз. Тик мин моның белән сезгә гашыйк булдым дигән нәрсәне әйтергә теләмимм.

Рөстәм кыздан күзен алды. Ләкин ул кызның яндырырлык булып текәлеп торган күз карашларын сизеп торды.

Рөстәм быел яз көне өч айга якын авылдан бер җиргә чыга алмый үткәрде. Советка булышты. Буш вакытын Рөстәмнәрнең җирләрен уртагыннан эшләүче Сираҗи агай белән кырда үткәрде. Йорт-җир тирәсен карады. Кайбер вакытларны башын күтәрмичә атналар буенча укуга күмелде.

Мәктәпләрдә укулар беткәч, Шуралар да, Климскаялар да төрлесе төрле якка таралдылар. Виргасов, язгы айларны шәһәрдә кайбер фәннәрдән хосусый укып хәзерләнеп ятуы сәбәпле, аңа да бара алмады. Башка укытучылар белән дус тормаганга, язгы айлар әллә ничек артык ялгыз үтте. Бүген менә шул ялгызлыкны яңарту, йөрәген яңа тойгылар белән тутыру уе аны станциягә алып килде.

Аның очравы яңа очрашуларга сусаган Рөстәмнең йөрәгендә ниндидер таныш, шуның белән бергә хәзергә кадәр йөрәге аркылы үтмәгән яңа дулкынлану ташкынын уятты.

Алдында утырган кыз үзенең матурлыгы, сүзгә осталыгы, русның иң әдәби теле белән сөйләшүе белән Рөстәмнең быел яз көне укыган бик күп романнардагы каһарман кызларга охшый...

Аның сүзләрендә, хәрәкәтләрендә шул каһарманнарның кайсынадыр охшау яки каһарман булырга тырышу билгеләре күзгә бәрелә. Кыз үзенең сүзләренә мөмкин кадәр романтизм буяулары бирергә, Рөстәм белән очрашуын матур романнардагы көчле мәхәббәт күренешләренә охшатырга тырышкан кебек була. Ә ул, бәлки, дөрестән дә, зур бер трагедиянең каһарманыдыр. Бәлки, бүген уйнала торган бөек сыйнфый көрәш эчендә туган яки туып бара торган аерым бер романның күренекле каһарманнарыннандыр... Кем белсен, элек ул бер зур миллионер яки шөһрәте белән бөтен Россия аристократиясе арасына таралган данлы бер помещик кызы булгандыр. Байлыклары тартылып алыну белән, ул белемсез бер тормышка ташлангандыр да романтизм хисләренә күмелергә, шуның белән юанырга, онытылырга теләп йөри торган бер кыздыр. Бәлки, ул бүгенге җимерелүне вакытлы бер нәрсә, тормышның вакытлы рәвештә чыгырыннан чыгуы дип уйлый торгандыр... Ә бер елдан ул тормыш тагын үзенең эзенә төшәр, байларга, помещикларга җирләре кайтарылыр, тагын да элекке кебек тормыш башланыр дип өмет итә торгандыр... Шуның өчен дә буталчык дәвердән күбрәк тойгылар алып калырга, башыннан кеше ышанмаслык вакыйгалар уздырып, күбрәк романнар ясап калырга омтыла торгандыр...

Рөстәмнең Франция революциясе тормышыннан бик күп романнар укыганы бар. Шул романнардагы сарайларыннан сөрелгән маркизларның сөрелеп йөргән вакытларындагы төрле кызганыч хәлләргә калулары, соңыннан бәхетле рәвештә кире сарайларына кайтулары дөрестән дә кызыгып укырлык нәрсәләр. Рөстәмнең алдында утырган кыз да, бәлки, шушы романнарны укыгандыр. Хәзер менә шул маркизлар кебек үзен хис итеп йөри торгандыр.

Рөстәмнең алдында утырган кыз турында шундый уйлар уйлавыннан үзенең дә көләсе килде. Бит аның алдында утырган кыз гади бер укытучы гына. Тик ул әллә ничек артык матур. Башка укытучыларга караганда үзен югарырак тота белә. Аннан Рөстәмнең романнар укып чуалган хыялы, үзе артык романтизмга бирелеп, үзе өчен, бәлки, шундый бер каһарман кыз тудырырга тырыша торгандыр. Соң бит гади бер мужик егет, имеш, мәшһүр бер помещик кызы белән күзгә-күз карашып утырсын әле! Ха-ха-ха...

Рөстәм көлеп җибәрде. Аның көтмәгәндә көлеп җибәрүеннән каршында утырган кыз кинәт аңа карады.

– Көләсез?

– Әйе.

– Ни өчен?

– Сезнең белән әллә кайчан сөйләшеп утырабыз, ә мин сезнең исемне дә, фамилияне дә белмим...

– Аның кирәге дә юк. Бер сәгатьтән без аерылырбыз, аннан күрешмәбез дә. Кыска бер вакыттагы очрашулар кешеләрнең йөрәкләрендә исемнәрен хәтерләтерлек эз дә калдыра алмыйлар.

Рөстәм кызның сүзенә кушылмады.

– Киресенчә, кайбер кыска вакыт эчендә кешенең йөрәге аркылы үтәли яшен булып үткән вакыйгалар еллар буенча онытыла алмыйлар... Алар кешенең йөрәген артык дулкынлатып, артык тиз үтүләре сәбәпле кеше аларны тиз генә аңлап бетерми. Яки ул вакыйга аның башында тиз генә бертөрле рәвешкә кереп өлгерми, менә шуның өчен кеше шул вакыйганы һаман кайтып-кайтып уйлый.

– Сез безнең очрашу да тирән эз калдырыр дип әйтергә теләмисез, билгеле?

– Мин алай дип әйтергә теләмим.

– Мин дә сез шулай әйтергә теләмисез дип уйлыйм.

Кыз кычкырып көлде. Рөстәм сүзендә дәвам итте:

– Кешеләр тирән эз калдырырлык вакыйгаларны үзләре теләп тудыралар. Алар үзләренең тормышларын нинди генә җирдә булса да матур итәргә, ничек тә бизәргә омтылалар. Гашыйк булсалар, мәхәббәтләре матур булсын, тирән эз калдырсын өчен су буйларына, урманнарга баралар. Икәүләп су өсләренә көймәдә чыгалар. Аларның икесендә дә гыйшыкларын матурайту өчен йөрәктә эз калдырырлык сүзләр сөйләргә омтылу тойгысы була. Ничек

тә мәхәббәтләре тирәсенә матуррак декорацияләр ясарга тырышалар. Ә безнең арабызда беренче шул очрашуыбызны матурлау, безәү омтылышын уята торган төп көч юк.

– Сез ул төп көчне мәхәббәт көче димәкче буласыз. Без сезнең белән гади очраучылар, иптәш юктан гына сөйләнеп йөрүче юлчылар дип әйтергә телисез.

– Әйе!

Кыз тагын көлде.

Рөстәм кызның көләргә хаклы булуын аңлап кызарды. Бит алар икесе дә сөйләгән нәрсәләрнең киресен уйлап баралар. Тик ике арада башланган уен гына уйларның киресен сөйләргә киртә булып бара.

Кыз аллеяда үтеп барган станция начальнигыннан поездның килүе турында сорашты, станция начальнигы, поезд бер сәгатьтән киләчәк, диде. Димәк, бер сәгатьтән алар аерылачаклар. Тагын, бәлки, бервакытта да, бервакытта да күрешмәсләр. Менә шул уй кинәт аларның икесен дә газаплый башлады. Шул мәңге дә бер күрешмәү уе аларда билгесез бер ашкыну белән газаплану тойгысы уятты.

Якын арада тагын бер очрашу күз алларында булса, алар болай дулкынланмаслар һәм бу дулкынлану йөрәкләрендә хәзерге кебек бер ашкыну белән үтмәс иде. Ә бит бер сәгать вакыт калган. Аннан соң?.. Әллә хәзергә кадәр бер-берсенә ачык килеш алып килгән уйны туктатыргамы, әллә?.. Ә нигә тыныч килеш калмаска? Бер сәгатьтән китәчәк булгач, бер-береңә булган хисләрне нигә әйтергә?..

Алар бу сорауга йөрәк тибүләрен туктатырлык җавап таба алмый бер-берсен үртәшүдә дәвам иттеләр. Поезд килү якынайган саен, аларның йөрәкләрендә дулкынлану арта барды. Кайсыдыр чигенергә, кайсыдыр үзенең позициясен бирергә тиешле иде. Тик бу нәрсәне Рөстәм кыздан, кыз Рөстәмнән көтте.

---

Җәйге таң җиле килеп өлгермәгән әле. Кояш батышы ягындагы яктылык әкрен генә кояш чыгышы ягына авышкан. Кечкенә станция күптән йоклый инде. Бер-бер артлы звонок шалтыравы гына станцияне хәрәкәткә китерде. Пассажирлар берәм-берәм станция алдына чыга башладылар, Рөстәмнең башыннан тагын бер мәртәбә «Ни эшләргә?» дигән сорау үтте. Кыз кулындагы сумкасын урындыкка куйды да, авыр гына сулап, Рөстәмгә карады. Аның күз карашларында хәзергә кадәр бирешмәскә тырышу көчен ниндидер билгесез дулкынлану, яшерен, белдерми, соңгы мәртәбә иркәләп калу, теләмәстән килгән аерылу минутларындагы җылы саубуллашу хисләре алмаштырган иде. Рөстәм аның күзенә карады, ул хәзергә кадәр тартылып килгән ике арадагы каршылыкны звонок шалтыравы җимергәнлекне аңлады һәм сүзсез генә кызны кочаклады да аның ярым йомылып килгән күзләренә карап үбәргә иелде. Кыз, үзен буган ниндидер йөрәк көченнән котылырга теләгәндәй хәрәкәт ясап, Рөстәмне әкрен генә үзеннән читкә этте дә, кузгалып, аякка басты. Рөстәм, утырган килеш ике кулы белән йөзен каплап, йөрәгенең авыртулы сызлавына түзми, үлек кебек тын калды. «Нигә кирәк иде?.. Нигә кимсенде ул? Тиле... тиле... тиле...»

Ул үзен-үзе өзгәләп ташлар хәлгә килде. Җиде-сигез сәгать мәхәббәт сатып вакыт әрәм итүенә ачуы килде. Кыз, аякка баскан килеш, күлмәкләрен, чәчләрен рәтләде дә, бернәрсә дә булмаган төсле:

– Әйдә, станциягә табан барабыз! – диде.

Алар сүзсез генә станциягә табан атладылар. Рөстәм юл буена үзенең йомшак булуын, романтик булуын гаепләп, тешләрен бер-берсенә кысып, сүзсез генә кайтты. Ул хәзер инде кызның үзен яратуын да теләми, бары кыз алдында булган кимсенүен генә акларга юллар эзли иде.

---

Караңгы станциягә килеп туктаган поезд вокзал эчен хәрәкәтләндерде. Поезд туктауга, утсыз, караңгы вагоннардан чыгучылар күренмәде. Тик вагоннан вагонга чабып, урын эзләп йөрүчеләр генә йоклап яткан юлчыларны тәмле йокыларыннан уяттылар. Вагон ишекләре янында кычкырыш-талаш китте.

– Икенче вагонга барыгыз, бездә урын юк.

– Күрше вагонда иркен!

– Кем кушты сезгә монда керергә? Документларыгыз!

– Монда делегатлар бара.

– Зинһар, мине генә җибәрегез!

Станция җанланды. Сүгенү, каргау, тартыш китте. Кеше йөртә торган вагоннар бөтен поездга ике генә булганга, Рөстәм аларга бармый, кызны утыртыр өчен, килеп, арттагы бер товарный вагонның ишегенә тотынды.

– Әй, ачыгыз!

– Кем сезгә кирәк, монда делегатлар бара?

– Документларыгызны рәхим итегез!

Рөстәмнең куркусыз тавышы вагон эчендәгеләрне шүрләтте бугай. Кайсыдыр әкрен генә вагонның ишеген ача башлады. Кеше сыярлык кына ачылган ишектән бер яһүд, башын сузып, Рөстәмгә карады. Рөстәмнең комиссарга охшавы аны куркытты булырга кирәк, ул вагон ишеген киңрәк ачты. Рөстәм, җитез бер хәрәкәт ясап, тоткага тотынды да вагон эченә керде һәм, кызга кулын сузып, аны вагонга тартып менгерде. Караңгы вагон эчендә кемдер:

– Нигә җибәрәсез, кем анда? – дип кычкырды.

Рөстәм җавап бирми, шырпысын сызып, вагонны карый башлады. Вагон эчендә аның күзенә төрлесе төрле якка башын куеп йоклап баручы кешеләр, өем-өем он капчыклары күренде.

Ул кыз белән исәнләшеп чыгарга уйлаганда гына туктап калды. Поезд аның торган авылы Тулпаннан өч кенә чакрым ераклыктан үтә. Беренче разъездга кадәр поездга утырып барырга мөмкин. Ул шуны уйлап вагоннан чыкмады һәм исәнләшергә дип түземсезлек белән көтеп торган кызга:

– Мин беренче разъездга кадәр поезд белән барам, – диде... Үзе аңа карамый, каядыр еракка, караңгылык эченә карады...

---

Фахишәләр генә ирләрдән җылы сүз дә ишетмиләр, иркәләү дә күрмиләр. Ирләр аларга һәрбер хатын-кыз өчен бик кыйммәт булган иркәләү хисләре урынына акча бирәләр. Ә фахишә булмаган хатын-кызлар ирләрдән җылы сүз, йөрәкләрен дулкынлатырлык иркәләү сүзләре ишетәселәре килә. Соңыннан шул иркәләү сүзләренә каршы алар үзләре дә хатынлык яратылышлары белән ирләргә нәрсә бирә алсалар, шуларның берсен дә аямый бирәләр.

Кыз да Рөстәмнән үзе дә белми шуны көтте. Рөстәмнең онытылып, йөрәк тавышы белән сөйләвеннән үзен яратуын аңласа да, Рөстәмне сәгатьләр буенча матур сүзләр сөйләтүгә үзе сәбәп булуын белсә дә, ул аннан, ниһаять, бу соңгы минутта үзен яратуын теле белән әйттерәсе килде. Күз карашлары белән шуны аңлатырга теләде.

Рөстәм аны бер иркәләү сүзе әйтми үбәргә теләгәч, ул аны читкә какты. Аның болай итүеннән үзен тагын бер кимсетергә теләү дип аңлады.

Поездга утырып киткәч тә шуны көтте. Ләкин ул Рөстәмнең үзеннән ераклашканнан-ераклашуын, салкынланганнан-салкынлана баруын күрде.

Кинәт ул вакытның аз калуын, йөрәктәге тойгыларны тел белән сөйләп өлгерергә мөмкин түгеллеген, разъездга туктарга дип, әкренәеп килгән тәгәрмәчләрнең моңа мөмкинлек бирмәүләрен, ул тойгыларны бары сүзсез, иреннәрнең кушылулары белән генә, теләкләрнең акылсыз дулауларына буйсынып, бер-береңнең иркенә бирелү белән генә мөмкин булуын аңлады. Бәлки, Рөстәм дә шундый ук теле белән әйтелә алмаган тойгыларының көчләве белән шулай хәрәкәт иткәндер дип уйлады... Ул әкрен генә Рөстәмнең янына килде. Аның френч төймәсенә тотынып күзенә карады. Соңыннан икенче кулын да Рөстәмнең күкрәгенә куеп, аңа тагын да якыная төште. Куллары Рөстәмнең күкрәгенә куелган килеш, Рөстәмнән җавап көткәндәй туктап калдылар... Бер секундка аларның күзләре бер-берсенә очраштылар. Кыз нәрсәдер әйтте. Вагон тәгәрмәчләре аның сүзен үзләренең тавышларына кушып ишеттермәделәр. Рөстәм күз карашы белән сүзен тәкрарлауны сорагандай итеп карады да тагын ачык вагон ишегеннән таң атып килгән якка, поезд ыргылып барган кара урманнар өстенә күзен текәде. Офыктан томрап килгән болыт, яктырып килгән таңның уң канатын каплап, тавышсыз күкне ярып уйнаган яшеннәре белән ашыкмыйча поездга табан килә. Яңгыр исе, болыт салкыны әкрен генә кырларны, урманнарны үзенең канаты белән каплый.

Поездның тәгәрмәчләре әкренләделәр. Рөстәм, саубуллашырга дип, кызга таба борылды. Ул кызның күз карашларында бирелергә теләү, әйтергә тиешле булып та, әйтелми калган йөрәк хисләренең дулавын, аларның җиңелмәслек рәвештә үзенә табан омтылуларын күрде. Ләкин бу күз карашлары аның йөрәгенә урнашкан салкынлыкны җиңә алмадылар. Ул күкрәгеннән кызның ике кулын алды да, каты гына кысып, сикереп вагоннан җиргә төште һәм эре адымнар белән поездның алдына атлады. Ул үзенең йөрәгендә нинди хисләр барын, кызны үзенең ни өчен мондый хәлдә калдыруын үзе дә аңламады.

Ул артына әйләнеп карамый гына разъездны да, паровозны да үтеп китте. Поездны яхшы ук еракта калдыргач кына борылып артына карады. Шушы вагоннарның кайсындадыр Рөстәм өчен бик кирәк бер нәрсә калган кебек тоелды һәм ул кинәт йөрәген җиде-сигез сәгать буена ашкындырган узгынчы кызның исемен дә, фамилиясен дә белмәвен исенә төшерде. Ыргылып тау астына килгән поезд аның йөрәк тибүен тагын да көчәйтә төште. Ул юлдан читкә борылды да түземсезлек белән вагоннарны карый башлады. Менә арткы вагоннарның берсенең ачык ишегеннән ак бер нәрсә күренде. Вагон якынлашканнан-якынлаша барды. Ул бөтен көченә:

– Сезнең фамилиягез ничек? – дип кычкырды.

Вагоннан башын сузып, аңа карап калган кызның:

– Дашкова! – дигән тавышы ишетелде.

Рөстәмнең башы әйләнде. Урманны шаулатып борылыштан ыжгырып кереп барган поезд аның ниндидер якын, шулай ук хыял кебек ерак бер нәрсәсен үзе белән алып киткән кебек булды. Ул сузылып җиргә ятты да, йөрәгенең белемсез ашкынуына түзми, җиргә капланды...

## III

Аның атасын Аю Ибрае дип йөртәләр иде. Бервакытны Рөстәм, анасы белән тары утаганда, аннан:

– Ни өчен безне, әни, аю халкы дип йөртәләр? – дип сорады.

– Бабаң, балам, аючы булган. Шуның өчен аю халкы дип йөртәләр, әле аючыларны төш тик кенә хәтерлим. Хәзер инде аючылар йөрми. Ә борын...

Анасы аңа аючылар турында сөйләп китте.

Элек Тулпан авылына һәр елны аю биетүчеләр килә булган. Ә көннәрнең берендә, яз башы, аючылар белән Галим атлы яшь бер аючы килгән. Зур, матур, кара күзле, кара мыеклы, батыр гәүдәле егет булган. Ул бик матур җырлый белә икән. Үзе белән Тулпан авылы ишетмәгән көйләр, йөрәк өзгеч матур җырлар алып килгән. Авылда матурлыгы белән дан тоткан Бимкәй кызы Маһирә аны яраткан. Аю биеткәндә, халыкка белдерми генә Галимгә үз кулы белән чиккән яулыгын ыргыткан. Аючы Галим, яулыкны алу белән, билгесез бер матур кызның аңа яулык ыргытуын, ул кызның бик матур булырга тиешлеген әйтеп, халык алдында җыр җырлаган һәм күзе белән кызлар арасыннан шул матур кызны эзли башлаган. Маһирә халык арасында серен белдермәгән. Бары Шуарләйдән су алып килгәндә генә Галимгә очрап:

– Сезгә яулык ыргытучы кыз бик ямьсез. Сез аны юкка мактадыгыз, – дигән.

Галим:

– Мин күрмәсәм дә, ямьсез булса да, аны яратам, – дигән.

Алар Шуарләй суына аркылы ауган каенга утырып төн уздырганнар.

Аючылар авылдан китү белән, Маһирә дә югалган.

Бер елдан соң бик ераклардан килүче Мөхәммәтҗан дигән кырыктартмачы мәшһүр аючы Галимнең ауга барганда аюлар авызыннан үлү хәбәрен, Маһирәнең туган илен сагынып җырлаган җырларын алып килгән. Шул көннән алып Тулпанда яңа җыр, йөрәк өзгеч «Аючылар» көе җырлана башлаган.

Ә унбиш елдан Тулпан авылына, олаучыларга утырып, бер хатын белән унбиш яшьләрендә яшь бер егет килгән. Ул Тулпан авылында туктаусыз җырланган «Аючылар» көенең каһарманы Рөстәмнең әбисе Маһирә булган, янындагы яшь егет аюлар авызыннан үлгән аючы Галимнең улы – Рөстәмнең бабасы Талмас булган.

Авылның Талмасны хәтерләгән карт әбиләре Рөстәмне күргәндә бабасы Талмаска охшаталар.

Рөстәмнең атасы Ибраһим атасының зур улы булган. Ундүрт яшьләрендә вакытта атасы аны:

– Харычлык кына акча табар, – дип, читтә сәүдә итүче Нуруллага малай итеп биреп җибәргән. Ул, Нуруллада ике ел эшләгәннән соң, аннан чыгып, каядыр башка урынга күчкән. Башта атасына аз-маз акча җибәргәләп торса да, соңыннан хат та язмый башлаган. Авылда аның турында дошманнар телендә төрле сүзләр йөри башлаган:

– Әле Харьковтан кайткан Сәнук улы, үзем күрдем, дип сөйли. Бик сәләмә киемнәрдән йөри, урыс кызына үләнгән, ди, кайтмыйм, дип әтә, ди.

Ана йөрәге түзмәгән, читтән килгән һәр кешедән, башына шәлен ябынып, сорап йөргән:

– Балам, кайда да улымны күрмәдеңме?.. Хат та язмый... Восе ташлады... – дигән, яулык очына яшьләрен сөртә-сөртә.

Һәр кайтканында Талмас агай аны:

– Их, Кодрү килене, кая барасың? Бар да синең ылың янында йөри дип беләсеңме? Чүпрәк баш, – дип тиргәп каршы алган.

Беренче баланы ана ярата, соңгы баланы ата ярата дигәндәй, Талмас Ибрайдан бөтенләй кул селтәгән. Ә беркөнне печәнгә чыгар алдыннан, чалгы янап ятканда, аркасына капчык аскан, иске ботинкадан, майланып беткән чалбардан, рус кыяфәтеннән Ибрай килеп кергән. Шәлдән кайтучылар, гөр килеп, станциядән тройка яллап, авылның исен китәреп кайтканда, ул разъезддан төшеп, җәяүләп кенә кайткан.

Аның болай сәләмә килеш кайтуы Талмасның йөзенә кара тап булып төшкән. Ул аның белән салкын гына исәнләшкән дә печәнгә киткән. Энеләре Габдулла белән Газиз[13] дә аның болай кайтуын үзләренә йөз каралыгы дип каршы алганнар. Ни булса да, авылда алар абруйлы егет булып санала башлаган булганнар.

Печән чабу Тулпан авылы өчен зур бәйрәм. Егетләр дә, кызлар да кыш буе сатып алган күлмәкләрен дә, шәлче абыйлары бүләккә алып килгән оекларын да печән өстендә кияргә дип саклыйлар. Болын меңнәрчә төрле төскә

киенгән кешеләр белән тула. Тулпан авылы халкы бер атна тартылган печән чабуны эшкә санамыйлар. Алар өчен иң күңелле, иң матур бәйрәм була.

Ибрайның өстенә кияргә матур киемнәре булмау сәбәпле, Талмас карт аны бөтенләй печән чабарга алып бармый.

– Син барып тырмалап кат булмаса, – дип, аны каты пар тырмаларга җибәрә.

Килгән көннән алып ул өйдә чит кеше, йортның абруен төшерүче бер ят кеше булып санала. Ул үзе дә аны нык сизә, бөтен көче белән атасына ярарга тырыша.

Аш ашаганда, атасы, аңа терәп, Җәмәлук уллары турында сөйли:

– Әтәм әле Җәмәлук Ксугын... Восе кеше булып каткан. Киемнәре дә баярныкы кебек... Бак, Ходайның хикмәте, уйламаганнан кеше булдылар.

Ибрай атасының ни өчен бу нәрсәне сөйләвен аңлый. Ашаган җирендә туктап, тәрәзәдән урамга карый башлый.

Тик Әминә карчык кына Ибрайны араларга тырыша.

– Куй инде, куй, соң, Җәмәлук Ксугына патшалар таҗын кидерсәң дә, шул ертык балак Хаҗар баласы булып калыр. Авызыннан яман сүз, ана сүгү төшми. Тапкансың кемнәр турында сөйләргә...

Ул Ибраһимга белдерми генә аны иркәли. Башка балаларыннан яшереп:

– Балам, сөткә ireккәнсең, мә парной сөт кап! – дип, аңа сөт бирә. Аның белән йомшак тел белән сөйләшә. Тик Ибраһимны барысына да ят иткән, аны туганнары арасында үги ясаган акчасыз кайтуы турында гына бер сүз дә әйтми. Ибраһим аны үзе яхшы белә. Бервакытны Ибраһим озак кырдан кайтмады. Әминә карчык борчылып ындыр артына аңа каршы чыкты. Юл буе караңгыда берьялгыз Ибраһимның җырлап килгән тавышы ана йөрәген телгәләде.

Саратовтан килгән чакта,
Күрдем Мәскәү каласын шул;
Әти, әни, оныткансыз,
Эт тә онытмый баласын.
Каз канаты ак була ла,
Ир канаты ат була шул;
Читтә йөреп малсыз кайтсаң,
Туганнарың ят була...[14]

Ә шул төнне кичен Әминә карчык аның белән бер бүлмәдә ялгыз гына калдылар.

Ул Ибраһимның алдына сөт куеп, яшенә карылып, Ибраһимның ашаганын карап тора башлады. Ибраһим ашавыннан туктады да анасының күзенә карады. Ул анасының, бары анасының гына аңа җылы хисләр белән каравын, атасы, туганнары ягыннан күрсәтелгән салкынлыкларның барын да үзенең җылы хисләре белән капларга тырышуын күрде. Ул, яшь вакыттагы кебек, анасының күкрәгенә ятып, бөтен йөрәген кисәкләгән хисләрен сөйләргә, соңгы ай эчендә эш таба алмый йөреп, шулай кайтырга мәҗбүр булуын аңлатырга теләде. Ләкин ул туганнарының шулай салкын каршы алулары уяткан әрнүле дә, авыртулы да кимсенү хисләрен сөйләргә өлгерә алмады. Күзләрен томан каплады. Ул томан, әкрен генә күз яшьләренә әйләнеп, керфекләрен чылаттылар. Ибраһим, яшьләрен агызмас өчен, күзләрен йоммаска тырышып өстәлгә карады. Ә соңыннан үксеп елый башлады...

Ул буылып-буылып үксегән чагында, анасының:

– Елама, балам. Бак, акчасыз кайту хурлыкмыни, башың сау булсын... Халыкның балалары эчеп-тузып башларын да югалталар...

Ләкин ул үзе дә аның белән бергә үкседе...

Шул көннән алып, Әминә карчык аны бар көче белән ачыктан-ачык яклый башлады. Талмас картны да үз ягына аудара:

– Үләндерик Ибраһимны, хатыны монда безгә ярдәмче булыр. Мин дә килен күрми картаям. Үзе дә тәүфыйкланыр...

Талмас карт күнде. Әминә карчыкның күз яшьләре Талмас картның йөрәгендә әллә кайчан бик якын булган баласын аяу хисләре уятты... Ибраһимны өйләндерергә булдылар...

Ләкин Ибраһимның малсыз кайтуы, киемнәренең рәтле булмавы зур йортларга башкода җибәрүгә беренче киртә булды. Шулай да Әминә абыстай улының абруен күтәрергә тырышты. Мактанырга яратмаса да, тирә-күршеләргә Ибраһимның атасына йөз сум акча бирүен, Талмас бабай алып кайткан, сандык төбендә сакланган ситсысын да улым китерде дип сөйләде. Ибраһим кыз сайлауны анасының иркенә куйды:

– Әни, син димләгәнгә мин риза, – диде.

Әминә карчык, улын тагын да бер кат кимсетмәү нияте белән, авылда ярлы гына тормышлы, бертөрле дә яманаты чыкмаган Хайбулла агайның кызына башкода җибәрде. Хайбулла агай да күп тартышмый кызын бирергә риза булды.

Гайшә үзенең матурлыгы белән башка кызлардан аерылмаса да, уңганлыгы белән күрше-тирәдә макталып йөри иде.

Озакламый туйга хәзерлек башланды. Башкоданың буш кул белән кайтмавы Ибраһимның да күңелен күтәрде.

Туй зур булмаса да, Талмас агай тирә-күршеләрнең берсен дә калдырмады. Яңа гына шәлдән кайткан Җәмәлук уллары да, Нуркәй уллары да, башкалар да катнаштылар.

Ак якалар, костюмнар кигән шәлчеләр, вокзалчылар арасында кияүнең начар киемдә утырасын уйлап, Әминә карчык беркемгә дә белдерми генә, туган тиешлесе булган Габдрахманнан костюмын, итекләрен сорап алды. Ибраһим, кеше киемнәре киеп, кияүли барырга каршы булса да, соңыннан күнде.

Кияү йортына туй җыела башлады. Җәмәлук уллары, шәлдән алып кайткан сбруйлары белән атларын киендереп, капка алдына килеп туктадылар. Алар артыннан ук пар ат җигеп вокзалчы Нуркәй уллары килеп җитте. Талмас агай Ибраһим белән кунакларны каршы алып торды. Йорт каршына яхшы сбруйлардан мөмкин кадәр киендерелергә тырышылган унбишләп ат җыелды. Йорт эчендә җанлылык башланды. Кияү килеп кергәндә, сүз кемнеңдер аты турында бара иде. Озын буйлы, костюмнар киюенә карамый мужиклыгы йөзенә чыгып торган Җәмәлук Ксугы сүзендә дәвам итте:

– Ну хайван, алаша тык алаша инде. Илле-алтмыш пот узелне тиисең дә, үзең әйбәтләп менеп утырасың да, ку айда... Кырык цакрым үтә, эһ тә итми.

Вокзалчы Нуркәй улы, Җәмәлук Ксугының сүзен тыңламаганга салынып, икенче нәрсә турында сөйли башлады:

– Шул, багам, малиең восе аякка баса башлады. Кодруны цакрам да этәм. Выргайны күрәсеңме, этәм. Малиең төзәлә башлады вет. Давай, этәм, үзен поддиржать итик. Кодруны беләсең вет, давай, ди шул. Акца бирдек тә үзенә кецкатук кына буфет ацып бирдек...

Мәҗлес кыза башлады. Бераздан картлар үзләренә бүленеп сөйли башладылар.

– Куныш, йөрәк маем, теге диланка ни эшләде?..

– Ә цурт белсен, Сәдрү маем.

– Аед Абдыругын ишеттеңме, бак, башы сынгыры, ни эшләгән?..

Шәлчеләр белән вокзалчылар Тулпан авылында күп еллардан бирле бер-берсен яратмыйлар. Бу туйда да Җәмәлук улы белән Нуркәй сүзгә килештеләр.

Үзенең аты көнгә «йөзәр монет» сәүдә итүе белән мактанган Ксукның сүзе вокзалчы Нурый улына ошамады.

– Ксук... ул кадәр үк булмас. Бераз йел ебәрә торгансыңдыр, – диде.

Җәмәлук улы, аның сүзен ишетмәгәнгә салышып, сүзендә дәвам итте.

Куныш әкрен генә җырлап җибәрде. Ул Талмас агайның күңелен күтәрү өчен анасы белән атасы турында чыгарылган «Аючылар»ны җырлады. «Аючылар»га кунакларның барысы да кушылды.

Чын күңелдән җырлаган Куныш картның күз алдына борынгы, яшьлеге белән бәйләнгән, хәзерге көндә киселеп бетә барган Шуарләй буйлары, атасы белән ауга йөргән чаклары, аючылар берәм-берәм үтә башладылар.

Борынгы җырлар җырлану белән, яшьләр җырлый башладылар. Актыкка таба, вокзалчы Нурый, Җәмәлук Ксугына терәп-терәп, шәлчеләрне үртәп чыгарылган җырлар җырлый башлады:

Шәлчеләрнең киемнәре
Әләмә дә зәләмә,
Пикарняда калац күрсә,
Күзләре артка әләнә...[15]

Җәмәлук Ксугы аның бетерүен көтте дә, бетерүе белән икенче җырны башларга ирек бирми, энесенә, яңа гына шәлдән кайткан Сәбкай Габдулына күзен кысып, үзе башлап китте:

Узелчылар нидән ядау –
Бөгелеп узел ташыйлар,
Вокзалчылар нидән симез –
Прасунка ашыйлар...[16]

Ксук яклы кешеләр көчләнеп көлеп җибәрделәр.

– Ха-ха-ха!..

– Но атте!

– Нуркәй, йөрәк маем, Ксук каты каптырды вет үзеңә. Бакцы, ни әле, вокзалчылар нидән симез, прасунка ашыйлармы, ди.

Нуркәй, кызып, буза белән кружкасын селкеп-селкеп, Ксукның теңкәсенә үтәргә теләгән позада бөтен тавышына җырлап җибәрде. Бузадан кызарган йөзе тагын да кызара төште. Маңгаенда кан тамырлары күперpermanently чыкты:

Шәлче егет шәлдән ката
Крахмаллы күлмәктән;
Үдә торганын оныткан,
Цай эцкәнен цүлмәктән...

Бу юлы инде Нуркәй яклы кешеләр көлеп җибәрде.

– Но утыртты!

– Айде, Нуркәй!

Куныш, кыздырырга теләп:

– Вот этәсең де. Юк, Нуркәй ул бирелә торган түгел, – диде.

Ксук, Нуркәйнең җырын тыңлаганда, күзләрен кан баскан хәлдә, теңкәгә тиярлек бер җыр эзләде. Ләкин вокзалчыларга карата чыгарылган бер усал җыр да хәтеренә килмәде, кызарды. Йөзеннән тирләр чыкты. Ул җыр тапмагач, бик каты сүгенергә генә торганда, Сәбкай Абдулы аны...

.....................................

.....................................

Кияү егетләре Хайбулла агайның үз йортында утырды. Күршесе солдат Мортаза йортына картларны утырттылар. Ксук белән Нуркәйне сугыштырмауны карарга Ибраһимның ике энесе Габдулла белән Газизгә кушылды. Габдулла Нуркәйне йортка керүдән элек, бер читкә алып китеп, Нуркәйдән сорый башлады:

– Нуркәй, син Ксукка бәләнмә. Аның кемлеген беләсең вет.

– Кочык курыкканмы анардан. Тыгылып баксын, тешләрен әбисенең чабатасына тутырып җибәрем.

– Ансында, канатым, сүз дә юк. Ә вет алар енаулар. Аннан соң кыйнашу-нитү белән туйны да бозарга ярамый.

Нуркәй тыңларга сүз бирде.

Кияү егетләре урынлашу белән, кодагый Сәхипҗамал абыстай, буза белән кыстап-кыстап, үзе сыйлый башлады. Ул беренче кружканы кияүгә салып бирде.

Кияү егетләр:

– Кодагый, ә үзең, ә үзең, ай, кодагый, киявеңнең хәтере калыр, яче, маем, яче! – дип, үзеннән эчүне сорадылар.

Кодагый, кияү белән чәкештереп, тынмыйчы бер кружка бузаны эчеп бетерде дә өстәлгә каплады.

– Воте, воте, күрәсезме? Сез дә, майларым, шулай эцегез, – диде. Берәм-берәм кружкасын күчереп йөртә башлады.

Җәмәлук Ксугы:

– Сәхипҗамал түти, бак, этәм, кыз асрадың, ә без килдек тә ват алып китәбез. Әмән кыз да асрамадың.

Сәхипҗамал, йөзенә оялу катыш елмаю төсе чыгарып:

– Кыз бала, Ксук, очар кош кебек, асрыйсың-асрыйсың, көне етсә, килеп алалар да китәләр. Йә, Ксук, ада эцеп ебәр, маем.

Ул тулы кружка белән буза сузды. Ксук, башын борып, шәлчеләр генә ясый торган нечкә хәрәкәтләр ясаган булып, аның кружкасын алып алдына куйды. Кулындагы калын алтын балдагын күрсәтеп кружканы күтәрде дә:

– Йә, сау бул, кодагый, – диде.

– Исәнлеккә, – диде Сәхипҗамал абыстай.

Ксук, күтәреп, тынмыйча эчте. Кружка кулдан-кулга күчеп йөри башлады. Сәхипҗамал абыстайны күрше солдат Мортаза алмаштырды.

– Но, шәлчеләр, давай. Кодагый бузаны күп куйды, тартып карагыз.

Өстәлнең очына гына утырган Иван Сәдрүе, Габбас, башка шәлдә булмаган егетләр солдатның шәлчеләрне генә сыйлавы өчен эчтән генә ачуландылар. Сәдрү, үзенә рәт җиткәч, биргән кружкасын эчмәде. Тартыш китте:

– Эцемим дигәц, эцемим!

– Качан тәүфыйкландың болай, Сәдрү? Иртәгә эчәм дисәк тә булмас. Хайбулла агайның дәүләтендә кыланып кал.

– Эцемим дигәц, эцемим, вот.

– Катарып алыш юк. Эцемәсең, кесәңә салам.

– Сал!

– Салыйммы?

– Сал!

Солдат, аны-моны уйламый, бузаны Сәдрүнең кесәсенә сала башлады. Көлешү тавышлары башланды.

Картлар ягында, икенче бүлмәдә, мәҗлес туйга охшамаганрак төстә барды. Никах укырга дип чакырылган мулла бик тиз килеп җитте. Картлар шуның өчен әз генә җырларга да өлгермәделәр. Мулла алдында әдәпсезләнмәскә тырыштылар. Никах беткәч кенә, мулланың рөхсәте белән авылның борынгы көйләрен иң оста җырлаучы сугымчы Гали сузып кына борынгы мишәр көйләреннән «Җиләз» көен җырлап җибәрде. Аның йомшак, көмеш кебек шалтырап чыккан тавышы аякларына буза төшкән картларның кан тамырлары буенча йөгерә башлады.

.....................................

.....................................

Каенсарлар буе сазлыклардан
Юргалап ла килә бер юрга.
Алып бирәм шәлләр ябынсаң,
Ябынганың саен сагынсаң.
Ак калфагын салып кыз инәлә:
«Җибәр, абзыкаем, бер юлга».
Ала сайрар идем кош булсам,
Саурап үбәр идем кыз булсам[17].

Соңгы юлларына Куныш йөзен чытып, җыларга хәзерләнгән кебек тешләрен кысып, Талмас агай да кушылды.

Хәзрәт әкрен генә картлар җырлаганны тыңлап утыра башлады.

Кияүне кыз янына озатыр вакыт җиткәндә, кияү егетләр яхшы ук кызып өлгергәннәр иде. Сәдрү шәлчеләрдән, буфетчылардан, кодагыйдан көлеп җырлар җырлый башлады:

Кодагыйның черкесе
Бар да кәзә йоныннан,
Кодагыйның салмасы
Чичибичә оныннан.

Ксук белән Нуркәй тагын бәйләнештеләр.

Бу юлы инде тавыш зурга китә язды. Тик өстәлнең читендә утырган Нуркәйне алып чыгу белән генә мәҗлес әкрен генә тынычланды.

Бераздан хатын-кызлар арасында хәрәкәт башланды. Чаршау артыннан бирелгән ишарә белән, Ибраһим кияү кыз янына барырга дип урыныннан торды. Кияү егетләр дә аякка бастылар. Алар, өстәл артыннан чыгып, кияүне уртага алып кулга-кул тотыныштылар да, җырлый-җырлый, кияүне кыз янына алып киттеләр.

Кызның чыбылдыгы янына җитим дигәндә, чыбылдык янына җыелган кызлар кинәт йөрәк өзгеч, матур дулкынланган нәфис, моңлы кызлык тавышлары белән җыр башладылар.

Бер-бер генә баса киләсең дә
Чыбылдыккаеңа җитәсең;
Чыбылдыккаеңны син күтәрдең,
Кыз гыйззәт кенәмне китәрдең...[18]

Җыр бетү белән, кияү егетләрдән кемдер:

– Кызлар, кияүгә юл бирегез! – дип кычкырды.

Кызлар икегә аерылдылар, Ибраһим, икеләнгән, ышанычын югалткан адымнар белән әкрен генә, башын җиргә иеп, чыбылдык эченә кереп китте. Хатыннардан кемдер чоланның ишеген япты. Кызыгып, тыгызланып карап торган балалар, оялган сыман, кияү белән кыз торган бүлмәгә карадылар.

Урамда кыңгырау тавышы ишетелде. Хәфизә, тыгызланып җыелып торган балаларны, хатын-кызларны этә-этә, ишегалдына ат кертте. Арбага кызның нәрсәләрен төйи башладылар.

Чыбылдык астында йөзенә ак пәрдә япкан Гайшә, кызлар чыбылдык җырын җырлый башлаулары белән, куркынган тай кебек, мендәрләр арасына барып кысылды. Йөрәге атлыгып чыгарга ашкынган кебек тибә башлады. Ул, бөтен нәрсәне онытып, мендәргә капланды да гомерендә күрмәгән бөтенләйгә ят, белемсез, үзенә якын ир булачак Ибраһимны көтә башлады. Ибраһимның аяк тавышлары ишетелмәсә дә, аның үзенә таба әкрен генә якынаюын, килеп җитүен сизеп торды. Ибраһим аның ястыктан башын күтәрергә теләде. Гайшәнең калтыранган куллары аның кулларына тиделәр. Ул әкрен генә Гайшәнең башын ястыктан алды да йөзендәге ак пәрдәсен күтәреп күзенә карады. Бер минутка аларның күзләре бер-берсенә очраштылар. Алар икесе дә бер-берсенең йөзләреннән моннан ун ел элек очрашкан вакытларындагы истә калган сызыкларны эзләргә тырыштылар. Кайчандыр яшь

вакыттагы күргән Ибраһим белән Гайшәнең балалык вакытларындагы йөз сызыклары томанлы, башка сызыклар арасында аерып ала алмаслык югалганнар, Ибраһим Гайшәне яшь вакытында күрү тәэсире белән бөтенләй башка төрле күз алдына китергән иде. Аның хыялында калган сызыклары урынына Ибраһимга бөтенләй билгеле булмаган яки ул күргән вакытта күзенә бәрелмәгән сызыклар зурайганнар. Шулай итеп, Гайшәне танымаслык алмаштырганнар.

Ишегалдында башланган шау-шу, китәргә хәзерләнү аларга сөйләшергә ирек бирмәде, Сәхипҗамал абыстай әкрен генә ишекне ачты да керергә рөхсәт сорады. Ибраһим оялган тавыш белән аңа:

– Мөмкин, – дип җавап бирде.

Гайшә кызарган йөзен анасына күрсәтми читкә борылды. Анасының:

– Йә, сау бул, кызым, рәнҗеткән булсам, бәхил! – дип, күз яшьләре аралаш әйткән сүзенә каршы сулкылдап елый башлады.

Сәхипҗамал абыстай:

– Елама, балам, Алла бәхетеңне киң кылсын, – диде дә урынга утырып дога кыла башлады.

Ибраһим да аңа иярде.

Кызның урын-җирләрен арбага төяп бетерү белән, күршеләрдән җыеп киендерелгән пар атка кыз белән кияүне утырттылар. Урамда хәрәкәт башланды. Кыңгырау тавышы күтәрелде. Кыз белән кияү утырган тарантас кузгалу белән, алар артыннан кияү егетләр утырган ат кузгалды. Җәмәлук Ксугы, Сәбкай Абдулы, Ксукның энесе Гыймад бергә утырдылар. Ксук, дрогасына утыру белән, кулына дилбегәләрне тотып, атларын сугып җибәрде һәм бик каты дилбегәләрне тартты. Авызлык белән авызлары киселеп беткән атлар дулап артка чигенделәр, арба арты белән туй карарга җыелган хатын-кызлар өстенә килә башлады. Балалар, куркышып кычкырыша-кычкырыша, утыннар өстенә үрмәләделәр. Ксукны сүгү, каргау тавышлары ишетелде. Шул арада Нуркәй, атына ялчысы Озын Хөсәен белән Карга Ибругын утыртып, кияү егетләр артыннан урын алып өлгерде. Ксук тагын, атларын сугып, Нуркәй улының атлары белән кияү егетләр арасына керергә теләде. Ләкин атлары, чигенеп, кое бурасын эләктерделәр. Кыз белән кияүне озатып баручы Солдат Мортаза кияү егетләр ияргән хәлдә ике мәртәбә мәчетне әйләнде. Мәчетне әйләнгәч, тузан туздырып, урамны яңгыратып җырлап, кызны кияү йортына алып киттеләр.

Җәмәлук Ксугы кое бурасын җимертеп, башка туйчыларны уза-уза, юлсыз бөтен урамга тузан туздырып чаптыртып китте. Кызның тарантасы янына җиту белән, аларны узмый атларын туктата төште дә, дилбегәләрен тартып, Нуркәй улының атлары өстенә борды. Ә Нуркәй улы арбасыннан сикереп төште дә кулындагы чыбыркысы белән Җәмәлук Ксугының атларына сукты. Атлар чуалдылар. Арбадагы кешеләр арбаларыннан төштеләр. Җәмәлук Ксугы яшен тизлеге белән арбасыннан сикереп төште дә чыбыркы сабы белән Нуркәй улының йөзенә сукты. Нуркәй улының йөзеннән кан чәчрәп чыкты. Алар күзләрен ут баскан хәлдә бер-берсенә ташландылар. Һәм төрле кабахәт сүзләр белән сүгенә-сүгенә сугыша башладылар. Ксук Нуркәй улын җиргә егып итек табаны белән бер-ике башына типте дә, яшен тизлеге белән кар базына сөялеп куелган казыкны алып, Нуркәй улының башына ике мәртәбә сукты. Нуркәй улы кинәт сөрлекте, тезләре җиргә бөгелде. Ул, тотынырга әйбер эзләгән кебек, ике кулын җәйде дә авыр, салмак гәүдәсе белән җиргә егылды. Маңгаенда тавык йомыркасы зурлыгында тиресе кубып чыкты. Сул як колагы төбеннән кан фонтаны атылып чыкты. Ул куллары белән җирне тырмый-тырмый бер-ике адым өстерәлде дә җиргә капланды... Кемдер:

– Үтерде мошенникны, – дип кычкырды.

Тирә-яктан кешеләр йөгерде, шау-шу купты. Туйдан җырлап кайтучылар, арбаларыннан төшеп, вакыйга булган җиргә җыела башладылар. Ксук, Нуркәйнең тын калуын күргәч, кинәт айнып китте, ул арбасына утырды да, атларын сугып, юлсыз-нисез чаптырып китте. Арттан кемнәрдер:

– Үтерде, тотыгыз үзен! – дигән тавышлар яңгырады. Кемнәрдер аның артыннан чаптылар.

Ә дүрт айдан аны Себергә – Сахалин атавына озатырга хөкем иттеләр. Семьясы да аннан калмады. Тик, аның бәхетенә каршы, бер ел да үтмәде, япон сугышы башланды[19]. Ул, сугыш вакытында төрмәдән котылып, гаскәрләр арасында сәүдә итеп, бик нык баеды. 1905 елда амнистиягә эләгеп, бик нык баеп, семьясын Тулпанга китерә килде.

## КЫЗЫЛ ГАЛСТУК

Алар ике йортта икәү тудылар. 1912 ел, 2 февральдә Сарман авылында ике ыштансыз батрак баласы дөньяга артты.

Алар туган көнне Зәйни байның сыеры бозаулады.

– Алла гынам, бозавы яхшы!

– Ходаем, бигрәк иртә сыеры бозаулаган!.. – диючеләр күп булды.

1912 елда Сарман авылында ике ыштансыз батрак баласы дөньяга туды. Ләкин Зәйни байның бозавы хакында авыз күтәреп сөйләгән хатыннар алар хакында бернәрсә дә сөйләмәде.

Бары күрше батрак хатыннары гына:

– Кара инде, болай да ашарларына юк иде... Тагы... – диделәр дә аларны оныттылар...

---

Мулла, өеннән торып кына, аларга мөселманлык паспорты биреп, берсенә – Мифтах, икенчесенә Нәҗип дип исем бирде. Мулла биргән исемне шул ук көнне Мифтахның абыйсы – Мөтү дип, Нәҗипнең апасы Нәҗук дип алмаштырдылар.

Җир идәнле ике батрак йортында, юкә бишекләрдә, чүпрәкләргә төренеп, Мөтү белән Нәҗук авызларын ачып аналарының сөт имезүләрен һәр көн көтәләр.

Алар туган көннәрендә назлана төшеп, авызларын ачып берничә елап карасалар да, эштән бушамаган аналарыннан иркәләү ала алмагач:

– Булмас, ахры, – дип, еламаска булдылар.

Бер авылда туган Мөтү белән Нәҗук ике яшьләрендә әле таныш түгелләр иде.

Алар инде назланмаска да өйрәнгәннәр.

Аналары утыртып калдырган җирдә бүре балалары кебек тик утыралар. Кайчакларда берәр нәрсәгә кызыгып, алырга дип кулларын сузалар да идәнгә тәгәриләр, ләкин еламыйлар. Елау-назлану егетлекмени ул...

---

Дүрт яшьләренә кадәр алар аналарын эксплуатировать итеп килделәр. Дүрт яшьләрендә, инде болай кеше өстендә йөк булып торырга ярамый дигәннәрдер, апалары белән иртүк торып, төтен эчендә бәрәңге әрчү кебек эшләргә катнаша башладылар. Шул көннәрдән аларның эш стажлары башлана. Мөтүгә, апасы, агалары белән кашык сугышлары ясап, кайчакта җиңелгәч, яланаяк кар өстенә дә чыгып торырга туры килгәли башлады. Ул шундый сугышларның берендә күрше байның эте белән танышты. Ләкин ул танышлык Мөтү икмәк биргәндә көчәя, икмәк бирмәсә, бетә торган иде. Ә аларда икмәк бик аз иде.

---

Яз килде.

Алар үткәргән ничәнче яз булгандыр... Алар хәтерләмиләр.

Карлар эреп, чәчәкләр башларын суза башлаганда, Мөтү белән Нәҗук күптән инде казлар саклаганда төймә уйнап утыручы кызлар янында шаяралар иде.

Мөтү нәни генә бер каз бәбкәсе белән дуслашып, сөйләшеп йөри.

Бәбкә яшел үләнне кабып өзә дә арты белән җиргә утыра.

Мөтүгә:

– Пибибиии, – ди.

Мөтү, аның янына ятып, аныңча:

– Пибииип! – дип җавап бирә.

Ата каз дигән ахмак дуслыкны белми бит. Ул Мөтү күрмәгәндә генә арттан озын-озын атлап муенын сузып килде дә, Мөтүнең күлмәк артыннан эләктереп, канатлары белән кыйный башлады. Көтелмәгән бу дошманга Мөтү нәрсә диярgә белми кычкырып җибәрде.

Аны дошманнан коткаручы үзе белән бер көндә туган Нәҗук булды. Алар шулай итеп таныштылар, актыктан бик дуслаштылар...

---

Ата казлар кыйнауга күп еллар үтте. Мөтүнең атасы 14 нче елда сугышка алынды[1]. 17 нче ел революциясеннән соң аның атасы кызыл гаскәрдә йөреп, революция беткәч, бер заводка эшкә керде. Берәр ел эшләгәннән соң, ул үз янына бөтен семьяларын алдырды. Мөтү заводтагы эшче балалары укый торган мәктәпкә керде.

---

24 нче елның язын Сарман авылы бик күп яңалыклар белән каршылады; авылда кооператив ачылды. Кызыл гаскәрдән кайткан кешеләр үзләре белән бик күп яңа хәбәр алып килделәр. Комсомоллар ячейкасы төзергә йөри башладылар. Китапханә ачылды.

Яз урталарында авылга беренче мәртәбә кызыл галстук килде. Беренче мәртәбә Ленин юлыннан барырга, коммунизм өчен киләчәк сугышларга «һәрвакыт хәзер» булырга ант биргән беренче яшь ленинчы килде. 24 нче елның язында авылны караңгы очыннан алып чыгачак күп миллионлы отрядның беренче сандугачы – яшь пионер Мөтү килде.

Ул үзе белән алып килгән икенче кызыл галстукны үзен ата каз кыйнаганда яклаган батрак улы Нәҗуккә бирде. Аңар пионерлар хакында сөйләп, аны пионер ясады.

12 нче елда Сарман авылында алар дөньяга килгәндә, аларны беркем дә авызга алмады.

24 нче елның язында алар хакында бөтен авыл сөйләде.

Ике кызыл галстук урамнан үткәндә, Сарман авылы ниндидер бер хәзергә кадәр булмаган яңалык сизде.

Алар икәү авылның караңгы бер җирендә беренче мәртәбә бер авылның якты киләчәге хакында пионер җыры җырладылар.

## УЛ АНЫ ОНЫТТЫ

*Бу хикәяне Радикка[1] багышлыйм*

Хәмдия яшь вакытында күргән бер авыл этәчен хәтерли. Ул этәч күптән үлгәндер, бәлки.

Хәмдия Иләш авылындагы бер эт малаен хәтерли. Ул эт малае картайгандыр да беркөнне аякларын сузып үлгәндер.

Хәмдия үткән көннәреннән бик күп нәрсәләрне хәтерли. Тик ул бер нәрсәне онытты.

Егерме икенче ел кергәндә[2], Хәмдиягә унбер яшь иде. Аларда ашарга икмәк юк иде.

Егерме икенче ел кергәндә, Хәмдиянең атасы икмәк эзләп китте дә юлда үлде.

———

Хәмдиянең анасы матур булганга, атасы үлгәч, өч баласы белән тол калган Галим дигән бер кулак аны хатынлыкка сорады. Аның анасы, ашарга икмәкләре булмагач, аңарга барырга риза булды, күрше-ярылар да:

– Инде барыбер ачтан үләрсең, аңар барсаң, ичмасам, тамагың туяр, – диделәр.

Байның үзендә дә өч баласы булганга, ул Хәмдияне үз йортына алырга риза булмады. Анасы да аңар күнеп, авылның икенче очында торучы әбиенә җибәрергә булды. Әбиенең ике улы фронтта үлгән, калган берсе кызыл гаскәрдә булып, әби берьялгыз тора.

Хәмдия анасына бернәрсә дә әйтмәде. Ул үзенең өзгәләнеп беткән бишмәтен киде дә әбиенә китте һәм, карт әбисенең сөякле кулларына башын куеп, үзенең бәхетсезлегеннән тыела алмый елады.

Кыш үзе белән кар алып килде.

Кыш килү белән, ачлыктан бик күп кешеләр үлә башладылар. Хәмдиянең әбисе дә, башка бик күп әбиләр кебек, ачлыкка түзә алмый, аякларын сузып ятты да үлде.

Хәмдия ялгыз калды.

———

Хәмдиянең абыйсы шәһәрдә, ләкин нинди шәһәрдә, Хәмдия аны белми. Хәмдия әле дөньяда бары бер-ике генә шәһәр бар дип уйлый. Ләкин ул шәһәрне бик яхшы дип белә.

– Шәһәрдән гел яхшы нәрсәләр генә алып киләләр.

– Шәһәрдә ак икмәк кенә ашыйлар, ди.

Шәһәрдә булган авыл малайлары да шәһәрне бик мактап сөйлиләр.

Хәмдия, әбие үлгәч, анасына кайтырга теләмәде. Ул әбидән калган икмәк кисәкләрен җыеп бәйләде дә абыен эзләп шәһәргә китәргә булды.

– Шәһәрдән гел яхшы нәрсәләр генә алып кайталар.

– Шәһәрдә ак икмәк кенә ашыйлар, ди.

Хәмдия сораша-сораша шәһәргә килеп җитте. Хәмдия шәһәрне үз авыллары кебек кечкенә дип уйлый иде.

Хәмдия абыемны табармын дип уйлаган иде.

Тик шәһәргә кереп югалды.

Хәмдиянең анасы, иргә чыккач, әбиләргә айга бер генә килеп чыга торган булды. Ул, әбинең үлүен ишеткәч килсә дә, туклык исереклеге белән исеннән чыгарган баласын таба алмады.

Әүвәлге көннәрдә елады. Соңыннан көннәр үттеләр...

Шәһәрдә базар. Минзәлә крәстияне базарга сатарга китергән кәҗә «Мәнзәләәә...» дип Минзәләне сагынып еласа да, аны бер спекулянтка суярга дип сатып җибәрделәр.

Хәмдия шул базарда икмәк сорап көн буе утырса да, аңарга икмәк бирүче булмады, ул җиргә егылды.

Хәмдияне туңып яткан җиреннән больниска алып киттеләр. Ул анда ун-унбиш көннәр ятып терелгәч, балалар йортына җибәрелде. Хәмдия монда үзенә бик күп иптәшләр тапты.

---

Көннәр килделәр дә киттеләр.

Айлар үзләре белән ачлыкны алып киттеләр. Еллар Хәмдияне үстерделәр.

Хәмдия балалар йортында пионерлыкка язылды. Пионерлар отрядының вожатые бер комсомолка Хәмдияне бик яратып үзенә кызлыкка алды һәм аның исемен Марсельеза дип алмаштырды.

Хәмдия инде ундүрт яшькә басты.

Яз.

Тавык чебиләре инде, аналарыннан аерылып, «Чирык, чирык...» җырын ялгыз-ялгыз җырлап йөриләр. Үрдәк малайлары, су ярына ятып, кояшка күзләрен кысалар.

Куй малайлары, аналарының имезергә теләмәүләренә карамый, кыйнашып-кыйнашып имәләр.

Егерме дүртенче елның матур язы.

Пионер отрядлары зур шәһәрләрдән лагерьларга таралып беттеләр.

Зур гына бер пионер отряды бер авылдан ерак түгел генә урманга килеп туктады.

Кояшта җылынып яткан чәчәкләр беренче мәртәбә килгән пионерларның аякларын үптеләр.

Авыл малайлары, һәммәсе бер киемгә киенгән бик күп балаларның урманга килеп төшүләрен ишеткәч:

– Кемнәр икән инде ул киянирлар? – дип, җыелып-җыелып лагерьга килә башладылар.

Марсельеза (Хәмдия), килгән балалар арасында кинәт үзенең иптәш балаларын танып, аларга ташланды.

Марсельеза (Хәмдия) инде туган авылының кайда икәнен оныткан иде. Аны әллә кайчан үлгән дип белгән авыл балалары ни диярgә белмәделәр.

---

Марсельезаның ничектер үлми калган яшьлек иптәше Зәйнәп кычкырып елап җибәрде...

Урманга килгән балалар арасында үзенең баласы Хәмдиянең булуын ишеткән анасы тары утаган җирдән урманга китте. Ул урманда пионерлар арасыннан Хәмдияне эзләсә дә таба алмады. Аның күзенә Марьсельеза килеп төшү белән:

– Балам! – дип ташланган иде, Марсельеза:

– Минем кулак хатыны анам юк. Минем кулак әтием дә юк, – дип, вожатыйга: – Әнкәй! – дип эндәште.

Пионерлар отряды, кырларга барып, крәстиян хатыннарына тары уташып күп кенә булыштылар.

Бу урманда өч-дүрт көн яткач, җомга көнне икенче авылга күчеп китәргә булдылар.

---

Юл авылдан үтәргә туры килде. Халык ял иткән көн булганга, авыл очыннан барабан сугып килүче отрядны ишеткәч, урамга чыктылар.

Хәмдиянең анасы да башына шәлен ябынган килеш эшен ташлап чыкты. Менә пионерлар отряды үтә.

Менә иң алдан кызының икенче анасы – вожатый килә. Аның янында байрак илтүче кем?

Аның кызы Хәмдия.

Ул анасы торган йортка күзен төшерде дә, анасын күрүдән элек, тәрәзәдән карап торучы байны күрде һәм тиз генә күзен алды. Анасын ул күрергә дә өлгермәде.

Туктарга теләгән аяклары тиз-тиз атладылар. Отряд үтеп китте.

Әнә инде алар авылны чыгалар.

Хәмдиянең анасы тәрәзә капкасына капланды да үкси башлады. Аның кызы Хәмдия аны онытты.

---

Әйе, Хәмдия (Марсельеза) аны онытты. Марсельезаның кулак хатыны анасы юк. Аның анасы хәзер пионерлар отрядының вожатые яшь бер комсомолка.

**ТРОЦКИЙ**

*(Булган вакыйга)*

Тагын еллар үтәрләр.

Безнең баштан үткән вакыйгаларны хәзерге көндә күлмәк койрыкларын төйнәп кояш астында йөргән нәни авыл балалары әкият итеп кенә сөйләрләр.

19 нчы елда киң Россия кырларында туп ядрәләре җиргә төшеп ярыла иделәр дә үзләре белән ак кар катыш кара җирне күккә күтәреп ташлыйлар иде.

19 нчы елда кар бураны, кырлардан кырларга себерелеп, авылларны, тимер юлларны күмеп куя иде дә тимер юлга якын авылларга көрәкләр тотып әрчергә эш ясыйлар иде.

19 нчы елда карга күмелгән йортлар эченнән ертык чикмәннәргә төренгән яшь егетләр, чыгып, өязгә табан китә иделәр дә бер айдан алардан мин Деникин фронтында дигән хәбәр генә килә иде.

Сәйфулла бай әле дә төшендә Чеканы күреп куркып уяна.

Ибруш әле дә, авылга портфельле берәр кеше килгәнне күрсә, тиз генә өенә нәрсәләрен яшерергә йөгерә башлый, ләкин хәзер ул вакытлар үткәнен исенә төшереп сулап куя.

Мин ул вакытта әнинең «Иман шарт» битләрен тәмәкегә тартып йөридер идем.

Пенза губернасында яз башында казлар йомырка салалар. Пенза губернасындагы казлар йомырка салалар да сәке астындагы ояларында өч-дүрт атна чебиләр көтеп утыралар. Аларның ул вакытта эчләре бик поша.

Ялгыш кына сәкегә барып сөялгән авыл малайларының ыштансыз ботларыннан алар эш юктан эш булсын дип кабып алалар, авыл малайлары, билгеле, эш юктан эш дип кычкырып елыйлар.

19 нчы елда күмеп куйган Николай акчалары өстендә чеби көтеп утырган кулакларның эчләре бик поша иде.

Алар, «өметсез» хәбәрләр килгән саен, хатыннарын кыйныйлар. Соңыннан, хәбәр тагы ишетергә дип, авыл советына китәләр иде.

Кайсы ай булгандыр. Ләкин 19 нчы ел иде. Без, нәрсә эшләргә белми йөргән авыл малайлары, советта суган боткасы пешереп яталар.

Үзен «кечкенә Николай» итеп хис иткән авыл председателе борчак атып утыра:

– Кадеремне генә белмисез, – ди. – Мин булмасам, – ди, – авылда бер ат калмаган булыр иде. Үзем авырлыкны күрәм инде, – ди. – Минем белән бөтен комиссарлар знакумка, әле шәһәргә чакыралар да, сезнең өчен бармый әрәм булып ятам, – ди.

Үзен, каһәр сукканны, себерке белән кусаң да, китәсе юк. Украина ягыннан сәүдә итеп кайткач, авылда председатель булды да бөтен авылны взятка бирергә өйрәтеп бетте.

Шунда таякка таянып утырган берничә «эш» белән килгән кулаклар аның сүзен җөпләп утыралар.

Председатель, аларның сүзләрен тыңламаганга салышып, подписен матурлап куярга маташа.

Ул инде председатель булганнан бирле шул авыру белән авырый. Шуңарга дөнья кадәр кәгазь әрәм иткәндер.

Соңгы көннәрдә ниндидер бер комиссарның койрыклы подписен күргән булырга кирәк, подписенә койрык арттырып куя башлады.

Бүген дә шулай подписьләрен куя торгач, соңгысы матур чыкты бугай, башын кәкрәйтеп читтән карап торды да, каләмен читкә куеп, тагын сөйли башлады.

– Мине мондагы ялан аяклар берсе дә арестовать итә алмый. Мин – губисполком члены, мандатларымны гына чыгарып салам. Мине губисполкомнан башка берәү дә арестовать итә алмый. Шуның өчен дә мин мондагы ялан аякларны эшкә дә куймыйм, – дип бик каты җибәрелә башлаган иде, минем аңа упродком инструкторының идән астына ябып куюын күрү искә төште дә, шаркылдап көлеп җибәрдем. Председатель миңа борылып караган иде, ишектән гаскәри киемдә, френч, галифедан өч кызыл гаскәр белән бер комиссар килеп керде. Бу комиссар миңа әллә ничек таныш кебек тоелды. Председатель, үзенең безгә күрсәткән эрелеген онытып, тиз генә урыныннан сикереп торды, без дә аякка бастык. Берничә дизертир мыштым гына ишектән чыгып сыздылар, комиссар, өстәлгә якын килеп, русча:

– Кем сездә председатель?

Безнең председатель ярты русча, ярты татарча:

– Моя председателем, чум дила, тауарищ?

Комиссар аңарга тыныч кына:

– Сез арестованы.

Председатель:

– Как тоес? Мандат даешь. Ни имешь... – дип озая башлаган иде, комиссар аңарга җавап бирмәде. Шунда утырган десятскига:

– Хәзер ике ат җиктер, – диде.

Председатель, ашыгып-ашыгып, минем белән янымда утырган берәүгә:

– Хәзер атларыгызны җигеп килегез, – дип җибәрде. Үзе комиссарга: – Тауарищ, пайдум мене, там бултаем, – дип нидер сөйләнеп калды.

Урамга чыккач, минем иптәш кычкырып көлеп җибәрде.

– Менә сиңа губисполком члены, – диде.

---

Мин ашыгып атны җигеп килүгә, ике красноармеец, председательне уртага алып, минем янга утырдылар.

Комиссар минем иптәшнең атына бер кызыл гаскәр белән утырып алдан китте.

Мин шәһәргә барабыз дип уйласам да, алдан баручы юлны авылның икенче очына табан тотты.

Авылны чыкканчы сөйләшми бардык. Соңыннан председатель, миңа табан әйләнеп:

– Сезнең өчен шулай газап чигәм, ялан аяклар, тимер юлга утын ташытмаган өчен шулай итә торганнардыр, – ди.

Мин:

– Соң нигә кулакларны кызганасың? Икешәр ат симертеп сәүдә итеп ятмасыннар, безне, бер атлы кешене дә, тынычта куймыйсың, – дидем.

Председатель ачуланып мыгырдады. Соңыннан кызыл гаскәрләргә әйләнеп, йомшак кына русча:

– Бу комиссар кем? – дип сорады.

Кызыл гаскәрләр дә:

– Болай бер комиссар инде шунда... – дип куйдылар.

Җил. Җил безнең колакларга килеп сызгыра да, бураннан койрыклар ясап, йортларны, тимер юлларны күмәргә китә.

Председатель, бераз баргач, тагын йомшаграк тавыш белән:

– Кайда барабыз? – дип сорый.

Кызыл гаскәрләр:

– Ерак түгел, шунда гына, – диләр.

Председатель тынмый. Пышылдап кына:

– Соң ничек, бирсәк, аламы?

Кызыл гаскәриләр кычкырып көләләр:

– Нигә алмасын... – диләр.

Без станциягә барабыз дип торганда гына, алдан баручылар юлны тагын икенче якка бордылар.

Мин яхшук туңа башладым. Бераздан кыр уртасында утлар күренә башлады.

Председатель, тынычсызланып:

– Кая барабыз соң? – ди.

Кызыл гаскәриләр:

– Менә шунда бер авылга! – диләр дә көләләр.

Бераздан без кыр уртасында туктаган бер поездга килеп җиттек. Комиссар чанадан төшүгә, икенче бер комиссар, аның каршына килеп:

– Товарищ Троцкий! – дип нәрсәдер сөйли башлады.

Минем күзләр шар булды. Председатель Троцкий исемен ишеткәч куркуыннан нәрсә эшләгәндер, белмим. Ләкин мин карга утырып, үземне белештерми:

– Троцкий?! – дип кычкырып җибәрдем.

Иптәш Троцкий әйләнеп карады да вагонга керде.

Мин, аның артыннан карарга дип йөгергәндә, кадалып җиргә егылдым. Берничә кызыл гаскәрләр, килеп, мине күтәрделәр.

– Нәрсә булды? – диләр.

Мин, нәрсә дә әйтә алмый килеп, атыма утырдым. Кайтканда, минем иптәш чанасына аягүрә баскан да дөнья җимереп кычкыра:

– Троцкий минем чанага утырды, Троцкий минем белән сөйләшеп барды, – ди.

Без икәү, бер чанага утырып, эт аягы махорка төреп, җырлап кайттык. Аерылганда, мин:

– Давай кызыл гаскәргә китәбез! – дидем.

Ул минем сүзгә дәртләнеп кушылды.

Икенче көнне авыл секретаре өяз газетасында иптәш Троцкийның шул хактагы мәкаләсен укыды. Мәкаләсендә: Троцкийның поезды, тимер юлны кар күмгәнгә бара алмый, кыр уртасында туктаган. Ул үзе белән берничә кызыл гаскәрне алган да ерак түгел будкадан барып, бу участкада карны кайсы авыл әрчергә тиешлекне сораган. Будошник безнең авылны күрсәткән дә, Троцкий җәяүләп безнең авылга килгән... Председательне реввоенсоветның приказына буйсынмавы өчен төрмәгә япкан...

———

Еллар тәгәрәделәр. Мин икенче мәртәбә Троцкийны Мәскәүдә трибунада очраттым. Беренче май бәйрәме иде. Ул бөтен дөнья хәлләре турында озак сөйләде. Мин, аңарга ерактан карап:

– Ә хәтерлисеңме, Троцкий иптәш, без бит синең белән бергә буранда контр, взятка алучы авыл председателен арестовать итеп барган идек, – дип эчтән генә сөйләнеп тордым.

Янымдагы иптәшләргә шул вакыйганы сөйләсәм дә, ышанмадылар, көлделәр.

———

Тагын еллар үтте. Революция мине үстерде. 20 нче елда кызыл гаскәрдә комсомолга кереп, сугышлар беткәч, рабфакны бетереп, университетка кердем. Университетка керү алдыннан ячейкабыз мине партиягә член итеп бирде. Бүген ячейка миңа троцкизм хакында доклад укырга тапшырды. Менә минем алдымда Троцкийның «1905 ел» дигән әсәре.

19 нчы елда киң Россия кырларында үлем сугышлары иде.

19 нчы елдагы утын белән ягылган поездлар ашыгалар иде.

Әле мин 19 нчы елда гына сука калагы хакында уйлап йөрүче малай идем...

Троцкий иптәшне чанада алып баручы минем иптәш, авыл малае, хәзер зур бер шәһәрдә [солдатлар] командиры. Еллар үтү белән, ул егет, бәлки, тагын югарырак үрмәләр. Чөнки тормыш үзенә кирәкле кешеләрне үзе тудыра.

## КОЯШ КӨЛМИ ДӘ, ЕЛМАЙМЫЙ ДА

II Интернационал кызы, Англия короленең икенче хатыны Макдональд[1], Англия тәхетенә наследник китерергә йөргән елларда мин пароход борынына утырып тәмәке тартып бара идем.

Теге шагыйрьләр язган кебек, пароходта әллә нәрсәләр юк: күңелсез, йоклыйсы килә, йокларга урын юк.

– Кояш көлә.

– Кояш елмая, – диләр.

Аны шагыйрьләр шулай ялганлыйлар.

Авыл малайлары да, аналарының берәр нәрсәсен сыптырып тотылгач:

– Кояштыр, алмадым, – диләр, кояшны якасыннан тотып шаһитлыкка өстериләр.

Ә кояш күрми дә, белми дә, елмаймый да.

Әгәр кояш күрә, белә, елмая торган бер нәрсә йә бер хайван булса, ул, безнең җирдә эшләп йөргән тилелекләребезне карый-карый, батарга кичегер иде.

Ә җирнең теге ягындагы кешеләр тик кояш көтеп утырсыннар.

Кояш күрми дә, белми дә, елмаймый да.

Аның йөзе һәрвакыт бертөсле. Ул батарга да кичекми.

Ә мин, күрә, белә, елмая торган хайван, авылдан ял итеп кайтканда, Самараны карый-карый, пассажирский пароходка кичектем һәм мин пароход борынына утырып тәмәке тартып барам. Кояш көлми дә, елмаймый да. Югарыда беренче һәм икенче класска билет алган кешеләр баралар.

Түбәндә матросларның стенгазеталары бар.

Кайчандыр мин сукачы малай идем.

Безнең кырлар күлләр, урманнар белән уралган.

Ләкин шунда сукалап йөргәндә, бервакытта да чәчәкләргә карап, «аһ, нинди матур чәчәкләр» дип сокланып карап тормаган идем (бугай).

Чәчәкләргә күмелгән җирләрне агач сука белән ертып, чәчәкләрне йөзләре белән йөзтүбән күмеп йөрдем. Аларның матурлыгы турында бер генә дә исемә килмәде.

Ял иткәндә шунда җиргә ятып кулга эләккәннәренең дә канатларын йолкып ташлыйдыр идем.

Ә хәзер...

Кояш көлми дә, елмаймый да.

Ә минем көләсем килә, кычкырып-кычкырып көләсем килә.

Чөнки мин пароход борынында утырып тәмәке тартып барам.

Кайбер шагыйрьләр үзләренең романнарындагы геройларны пароходта очраштырып гашыйк итәләр, матур каюталарда үбештерәләр...

Тел белән мәхәббәтләрен сөйләүчеләр дә мәхәббәтләрен йә җилкән көймә койрыгына бәйләп сөйлиләр, йә пароход палубасына утырталар.

– Пароход матур, – диләр.

– Пароходта бик матур кызлар була, – диләр.

Пароходка утыру белән, минем шул гашыйк була торган хайваннарны күрәсем килә. Ләкин ары-бире карангаласам да, андый нәрсәләр күзгә күренмәде; халык, берсе өстенә берсе утырып, урын өчен талашып, дөнья җимереп баралар.

Җитмәсә, матур гына бер туташ белән сөйкемле генә егет, урын өстендә талаша-талаша, борынлашыр дәрәҗәгә җиттеләр.

Акча белән эшсезлек бер җиргә җыелган җирдә мәхәббәт йомырка сала, диләр. Гыйшык-мәхәббәт беренче һәм икенче класска билет алучыларның кесәләрендә йөри торгандыр, бәлки, дип, югары менмәкче булдым. Ләкин теге шагыйрьләрнең романнарындагы геройларына вино ташып йөрүче герой-швейцар, минем билетымны карап, югарыга җибәрмәде:

– Нельзя! – диде.

Мин, югары менә алмагач:

– Бәлки, берәрсе мәхәббәт трагедиясе белән палубадан Волгага сикереп төшәр әле, – дип, югары карый башладым.

Ләкин шул арада ике татар агай-энесе арасында кызык бер картина булып алды.

Аларның берсе хатыны белән бара икән, икенчесе – хатынсыз. Хатынсызы хатынлысының хатынына, ата-баба йоласы дип, күз төшергән. Хатынлысы моны күргән дә:

– Ник минем хатынга күз кысасың? – ди.

Тегесе:

– Күрдеңме? – ди.

Һәм хатынлысы хатынсызының колакларына ябыша.

И...

китте.

Алар, бер-берсенең борыннарын канатышканда, берсе-берсенә:

– Ах, спекулянт, контр!

– Ах, буржуй!.. – дип, берсен-берсе контрлыкта гаепләштеләр.

Тик аларның кайсы контр иде? Аны «милләт тарихын язучыларыбыз» тикшереп язарлар.

Ә хәзер кояш бу күренешне күреп көлмәде дә, елмаймады да.

Мин пароход борынында тәмәке тартып барам.

Анна миннән алган журналны карап бара.Ул – рус кызы. Аның янында кечкенә сеңлесе дә бар. Сеңлесе туберкулез белән авырый.

Мин аңарга карыйм да:

– Үзе нәни, – дим, – үзе туберкулез белән авырый...

Ә Анна журналын читкә куя да, минем яныма утырып, аякларын селкә-селкә, Волга ярларын карый. Ул – крәстиян кызы. Комсомолка. Ачлык елны Ташкентка барган, анда идәннәр юып тамагын туйдырган. Көннәрнең берендә Ташкент музыка мәктәбенә идән юучы булып кергән, соңыннан...

Ул аякларын селкә-селкә сөйли:

– Анда мин беренче мәртәбә пианино күрдем һәм, музыка мәктәбенең мөдире күрмәгәндә генә, пианино бармакларын баса башладым, – ди.

Ә соңыннан, айлар үтү белән, ул музыка мәктәбенә гариза биргән.

Ап-ак сакаллы музыка профессоры:

– Мин сигез яшемнән музыкага өйрәнә башладым, алай да... Син егерме яшеңдә... – дигән.

Аяк-кулы белән тыпырчынып алмаска тырышкан. Ләкин Анна мәктәпкә кергән. Ә ике елдан соң ак сакаллы музыка профессоры Аннага бирелгән.

«...музыка мәктәбендә ике еллык гомерендә кеше ышанмаслык бер көч күрсәтте...» дигән рекомендация кәгазенә кул куйган. Хәзер Анна Самара, Нижний[2] аркылы Мәскәү консерваториясенә бара.

Ул егерме яшенә кадәр пианино күрмәгән.

Ул егерме яшенә кадәр скрипка тавышы ишетмәгән.

Ә хәзер, минем яныма утырып, аякларын селкә-селкә, Волга ярларын карый. Ә сеңлесе туберкулез белән авырый.

Мин пароход борынында тәмәке тартып утырганда, идән юучы комсомолка Анна аякларын селкеп барганда, Европада:

– Большевиклар сәнгатьне җимерәләр, мәдәниятне таптыйлар, – дип «утын кисәләр» иде.

Минем башка Аннаның тәрҗемәи хәлен куеп, Чемберленның[3] үз адресы белән шундый бер хат язу уе төште: «Шулай, Чемберлен агай, сезнең нечкә куллы мамзилләрегез генә уйнарга тиешле пианиногызда калын бармаклары белән идән юучы безнең Анна уйный».

Цилиндр кимәсәк тә инде, «сезнең» нечкә аһәңле флейталарыгызны сыбызгы урынына сызгыртабыз!

Сезнең «аксөякләр генә уйнарга тиешле» дип белгән «мөкатдәс сәнгать коралларында» безнең урамнардан җыелган детдом балалары әйттерәләр.

«Килер бер көн, сез дә безнең концертка билет алырсыз!» Ләкин мин аңа хат язмадым. Чөнки Чемберлен ул нәрсәне үзе дә яхшы белә. Ул бары сүз юктан сүз дип кенә кычкыра.

Ә кояш көлми дә, елмаймый да.

Ул бервакытта да батарга кичекми.

Ә кешеләр пароходка кичегәләр.

Урамнардагы төрле кызыкларны карый-карый, өйләренә кайтып ашарга кичегәләр. Алай гына түгел, кешеләр яшәргә, хәтта шатланырга, бәхетле булырга да кичегәләр.

Юк, алай түгел, без, бәлки, гашыйк булырга, рәхәт яшәргә кичегә торганбыздыр, ләкин революция ясарга, иске тормышны җимерергә кичекмибез. Үз вакытында эшлибез.

Кояш бервакытта да кичекми.

Без дә җиңү көннәренә минутлар белән барабыз.

Инде кояш көлә, елмая дигән сүз –

ялган!

Кояш көлми дә, елмаймый да.

Ә без көләбез, һәм безнең көлүдә туачак яңа тормышның симфониясе яңгырый.

## КЫШ ҖЫРЫ

Җил күзен очраган берәүнең борынына тузан тыгып йөридер иде, хәзер инде һөнәрен үзгәрткән: урамда йөрүчеләрнең борын очларына кар йоннары ябыштырып йөри.

Кыш салкын булыр, диләр дә, мыеклар аягүрә торалар.

Кыш музыкасына биергә туры килер, ахры.

Ләкин барыбер чәчәкләрен ияртеп яз килер, барыбер без тагын ялангач, комга ятып, үрдәк малайлары кебек кояшка күзебезне кысарбыз.

Ыштаннарын муеннарына тагып, яз буе ыштансыз, ата казлар белән сугышып йөргән авыл малайлары, телләре белән тәрәзә пыялаларын эретеп, бер күзләре белән генә урамга карыйлар.

«Курыкмагыз, кечкенә сукбайлар!»

Барыбер, барыбер яз килер, һәм сез тагын да алма, кыяр бакчаларына дүрт аякланып кунакка йөрерсез!

– Күңелсез булмасын!

– Кышны биеп уздырыгыз! – ди дә җил, «телеграф баганаларына» утырып, телеграф чыбыкларында кыш җырын җырлый, йорт трубаларын сызгырта.

Малайларга күңелсез булмасын өчен:

– Мәктәптән кайткач шуарсыз инде! – ди дә таулар өеп куя.

Тәрәзәгә төрле яфраклар, чәчәкләр рәсемен төшереп:

– Менә болар инде сез ярата торган яз көнендә була торган нәрсәләр! – ди дә үрти.

Мәхәббәтне урамнардан, бакчалардан җылы театрларга өстерәп кертте.

Мәхәббәтнең бәясе күтәрелде.

Бер сум, ике сумнар тирәсендә йөри.

Гашыйк булырга теләдеңме, театрга билет өчен бер сумыңны рәхим ит!  Юк икән, яз башында булачак мәхәббәт урожаен көт.

Тормыш урамнардан, бакчалардан бүлмәләргә күчте.

Тик теләнчеләр генә урамда калды,

Урамда теләнчеләр йөриләр.

Нәни генә балалар, кулларын сузып:

– Абый, бер тиен генә бир! – диләр.

Кайсыгыздыр миңа кайчандыр:

– Ачлык елларында минем кечкенә энем, әтиләр үлгәч, шәһәргә киткән дә югалган... Хәзер белмим кайда? – дип сөйләгән иде.

Ә бәлки, шуларның берсе сезнең энегездер һәм урамнардан узганда сезнең күзегезгә карый торгандыр.

Язын сандугачлар утырган агач ботакларында карлар таган ясап сәленәләр.

Ата казлар, бер аякларына гына басып, озын муеннары белән ары-бире карангалыйлар да карга утыралар.

Кыш урамга чыккан кешеләрнең борыннарын кызартып кызык итә.

Язын урам буйлап нәни байракларын җиргә өстерәп йөргән октябрятлар кыш әкиятен укыйлар.

Мин теләнче кыз турында сезгә сөйлим.

Егерме беренче елда кыш булган.

Урамда йөргән йөз меңнәрчә теләнчеләрнең икесе килеп коммунист Хәлилнең ишеген какканнар һәм ишектән бер рус карчыгы белән бер яшь кенә рус кызы килеп кергән.

Хәлил ул вакытта мәсьүл бер урында эшләп паек алган.

Хәлил миңа хатыны алдында көлеп-көлеп сөйли:

– Алар керүләре белән ишек төбенә тукталдылар. Кыз башын түбән иде. Мин, аларның сорауларын көтми, бүген генә алып кайткан паек икмәгеннән бер кисәген суздым. Кызның анасы, икмәкне алып, өзлексез рәхмәтләр укыды һәм борылып чыгарга җыенды. Ләкин кыз миңа күз яшьле тавыш белән:

– Миңа теләнеп йөрергә уңайсыз, сезгә, бәлки, аш пешерергә, өегезне карарга кеше кирәктер. Мин аяк туфрагыгыз булыр идем, – диде һәм минем күземә карады.

Мин ни эшләргә белми аптырап калдым.

Ә бераздан паекны рәтләбрәк тотканда, билгеле, ике кешегә җитәрлек дип уйладым да риза булдым. Кыз ни эшләргә белми шатланды. Шулай итеп, миндә калды. Ә паек ике кешегә генә җитәрлек булганга, анасы:

– Балам, син генә булса да бәхетле бул! – дип чыгып китте...

Шулай итеп, теләнче кызы аңарга көн дә аш әзерләп, бүлмәсен җыеп, ачлык елында ике кешелек күңелле генә бер тормыш төзегән.

– Соңыннан?

Кыз Хәлил булмаганда гына аның китапларын караштыргалый башлаган, көннәрнең берендә Хәлил сөйли:

– Миңа һәрвакыттагы кебек эштән кич сәгать тугызда кайтырга туры килде. Кайтсам, шул, ни күзем белән күрим, кызыең урынны бик рәтләп кенә түшәгән дә, чәчләрен таратып, минем урынга менгән дә яткан, һәм рәхәтләнеп йоклап ята.

Ул ары-бире башын кашып әйләнгәләгән дә, башка ятар урын тапмагач, менеп аның янына яткан. Икенче көнне иртән алар ирле-хатынлы булып торганнар.

Еллар йөзләрен алмаштыралар, фрак кигән еллар блуза кияләр.

Хәлил һәрвакыттагы кебек собраниеләргә йөри, кыз Хәлил бүлмәсендәге китапларны карый.

Хәлил ячейкаларда доклад ясый, кыз курсларга йөрергә вакыт таба.

Комсомолка була.

Шулай итеп, Октябрьнең тугызынчы кышында Ленинның «Һәрбер асрау хөкүмәт белән идарә итә белергә тиешле»[1] дигән җанлы лозунгысы үсә.

Инде Октябрьнең унынчы кышында ул җанлы лозунг урамга чыгар.

Ә хәзер Хәлил миңа бүген телефонда сөйли:

– Кил, Надя бер «разбойник» дөньяга китерде, дөнья җимереп кычкыра, – ди.

Димәк, аларның паек белән башланган тормышлары бу ел чәчәк аткан.

Ә урамда теләнчеләр йөриләр:
– Бу ел кыш салкын булыр, – диләр.
Ә
җилнең эче поша,
кырдан кырга оча,
ул, үзен-үзе юатырга теләп, киң кырда
диңгезләр рәсмен бизәргә тырыша;
дулкыннар ясый,
тагын боза,
дулкыннарны башка бер урынга күчереп карый,
ошатмый да пыр туза...
Җилнең эче поша,
килеп юлга поса.
Юлчыларның печән бәйләмнәрен
белдермичә урлап китә ул.
Бәйләм куып килгән юлчыларны
карлы кырда кызык итә ул:
бәйләмне туктаткан була,
җитим дигәндә генә тагын алып китә,
юлчылар сүгенәләр...
Җилнең эче поша,
кырларны диңгезгә охшатырга тырыша,
дулкыннар ясый.
Дулкынланган нәфис карлы кырда
әрем сабаклары моңая:
– Күкләр зәңгәрләнер,
йолдызлар болай усал карамаслар,
карлар эрер,
кояш якынлар да, яз килер.
Барыбер яз килер...

Песи малайлары көн буе койрыкларын сөңгеләп идән буйлап шаярып йөриләр-йөриләр дә йоклар өчен җылыга, аналары янына, мич башына үрмәләргә тырышалар.

Сикерәләр дә
егылып төшәләр,
тагын сикерәләр,
тагын егылып төшәләр.

Актыгыннан идән буйлап озын мыеклы авызларын ачып елап йөриләр-йөриләр дә икенче урын эзлиләр – җылы бүрек эченә укмашып яталар.

Кич ат карарга чыкканда, крәстиян агайлар бүрекләрен киярgә дип күтәрәләр дә, песи малайлары лап-лоп итеп идәнгә егылып төшәләр һәм сәке астына себертәләр.

– Ах, мур кыргырлары! – дигән тавышлар гына төнге диварларга барып бәреләләр.

Ә диварның тышкы ягында кыш тәрәзәдән карый. Нәни авыл малайлары өсләренә ябынган туннары астыннан борыннарын өскә чыгаралар да тагын яшерәләр, әкият тыңлыйлар:

– ...булган, ди, бер патша, бик усал булган, ди, үзе алтын сарайларда көне-төне гыйше-гашрәт кылган, ди.

– Ә нәрсә ул, абый, гыйше-гашрәт?

– Йә, тик тор, тыңла, сөйлә, абый!

– Ә халкы ачлыктан, ялангачлыктан кырылган, ди, җитмәсә, патша, үзенең һәм яраннарының байлыкларын арттырыр өчен, башка патшалар белән сугышкан, ди, ә халкы ачлыктан, ялангачлыктан кырылган, ди. Көннәрнең берендә халык арасында шау-шу купкан, ди. Ярлы халык арасыннан Ленин атлы берәү чыгып, үзенең иптәшләре белән патшаны төшереп, бөтен халыкка тигез, бәхетле тормыш төзергә кирәк дип, халыкны патшага каршы сугышка чакыра башлаган...

– Әй, абый, бу әкият түгел, чын эш ич!

– Әйе, бу әкият түгел, чын эш. Ә аны моннан сигез ел элек буржуйлар:

– Бу эш булачак түгел, бу – әкият, – дип йөриләр иде.
– Йә, сөйлә, абый!
– Ләкин бүлдермәгез, яме? Шуннан соң...
...................................
Кышкы төннәр әкият сөйлиләр.
Ә кайчакта чәчәкләрнең оста бакчачысы – кояш – үзенең кырларына карый.
Ә кырларда, нәфис нурдан дулкыннарга карап, әрем сабаклары моңая:
– Чәчәкләр күкрәрләр,
җилләр болай усал булмаслар,
карлар эрер...
Кояш җиргә якынлар да, барыбер яз килер.
Ә хәзергә –
күңелсез булмасын.
– Кышны биеп уздырыгыз! – ди дә җил, телеграф баганаларына менеп, телеграф чыбыкларында кыш җырын җырлый.
Биергә туры килер, ахры.
Ләкин барыбер яз килер, барыбер без тагын да эштән бушаган көннәрне, ялангач килеш комга ятып, үрдәк малайлары кебек, кояшка күзебезне кысарбыз.

## ПРОТОКОЛЛАР ЭЧЕНДӘ ХИКӘЯ

Туганмын.
Сөннәтләргә кирәк булгач, кычкырттырып сөннәтләгәннәр дә, шуның белән мөселманлык паспортын биреп, күлмәк койрыгымны төенләп, якты кояш астына җибәргәннәр. Ә Николай II[1] гә минем тууым турында бер хәбәр дә җибәрмәгәннәр. Шуның өчен, билгеле, бөтен Россиянең патшасы минем тууым, дөньяда яшәргә теләвем, ыштанымны муеныма тагып, иләк белән балык тотып йөрүем турында бернәрсә дә белмәгән, белергә дә теләмәгән. Әткәй мескеннән налогны алган да алган... Ә безнең кебек миллионнарча ыштансыз йөргән малайларның бәхетләрен бәрәңге койрыгына бәйләп калдырган...
Чәчәкләр дә ашарга телиләр,
Чәчәкләр дә яшәргә телиләр,
Тавык чебиләре дә ашарга телиләр,
Тавык чебиләре дә яшәргә телиләр...
Без дә яшәргә теләдек һәм шуның өчен дә
Канлы фронтларга ташландык.
Язмышны, тормышны, сәнгатьне, бөтен нәрсәне үз кулыбызга алдык. Аптырап тормадык, биисе урында балериналарыннан шәбрәк биедек. Судья буласы урында туры хөкемле судья булдык. Кыйнашасы урында борыннарны аямадык. Ә еллар үтте дә үтте...
19 нчы ел.
Мәктәп советы йортындагы төтеннән борыныңа теләсәң нәрсә тыгып куй. Ләкин озын сөйләүче озын мөгаллим үзенең сүзендә дәвам итә. Мәсьәлә бүген дә утын хакында, иртәгә дә шул хакта булыр, берсекөнгә дә... Кыш буенча мәктәп советының көн саен мәҗлесе җыелган, һәр мәҗлестә утын хакында мәсьәлә куелган, озын сөйләүче озын мөгаллим, һәр мәсьәлә куелган саен, өчәр-дүртәр сәгать нотык сөйләгән. Ләкин утын һаман юк, булмас та, диләр.
Мәсьәлә бүген дә утын хакында.
Озын сөйләүче озын мөгаллим, теле белән Европада, Америкаларда әйләнеп бер-ике сәгать сөйләгәннең соңында, тел төбен тагын утынга китереп терәде. (Без ул вакытта озын сөйләргә өйрәнәдер идек.) Башка мөгаллимнәр дә сөйләүдә аны уздырырга теләп утырсалар да, вакыт соң иде.
Иртәгә җыен була, мәсьәләне җыенда халык алдында куярга дигән карар чыгарылды һәм крәстияннәрнең үз күзләренә карап сөйләр өчен ике мөгаллим сайланды.

**Авыл советының диварында Ленинның рәсеме тора**

Авыл советының караңгы бер диварында Ленинның рәсеме тора. Артык игеннәрен, артык сыерларын кызыл гаскәрләргә биргән крәстиян агайлар советка килгән саен аның йөзенә карыйлар... Дивардагы Ленин аларның йөзләренә тыныч карый.

Минем бер иптәшкә доктор иснәтми авыр бер операция ясаган иде. Операция вакытында иптәшем авыртуга түзә алмый, үзен-үзе белми кычкыра, докторны теленә ни эләксә, шуның белән сүгә башлады. Ләкин доктор аңарга:

– Төзәлергә телисеңме? – диде.

Иптәшем:

– Телим, – диде.

Доктор:

– Төзәлергә теләсәң, түз! – диде аңарга...

Авыл советының караңгы диварында Ленинның рәсеме тора. Ул тыныч карый.

– Төзәлергә телисезме? Түзегез! – ди ул.

Крәстияннәр авыр булса да түзәләр...

Менә шул елларга хәзер җиде ел үтте. Җиде калын пәрдә шул елларда булган бик күп вакыйгаларны үзенең артына яшергән. Еллар артыннан өстерәлеп йөреп, мин тагын да озын сөйләүче озын мөгаллим торган авылга кайттым. Көтелмәгәндә минем кулыма шул еллардагы авыл советының протоколлары килеп төште. Аның карасы саргаеп килә торган юлларыннан үткәндәге эзләремне эзли башладым...

Җыенда халыкка утын турында сөйләргә сайланучы мөгаллимнәрнең берсе мин идем. Мин совет йорты янына килеп җиткәндә, авылның мәшһүр кыйнашчысы Исмай агай, кемнеңдер ата-бабасына хәтем укып, дөнья җимереп, тавыш күтәреп ятадыр иде. Ул, коммунист булгач, икмәк бирәләр икән дигән хәбәрне кайдандыр ишеткәч, коммунист булган икән. Ләкин бер-ике ай көтеп тә икмәк бирелмәгәч, үзен партия бик нык эшкә җигә башлагач, коммунистлыгын ташлады.

Минем иптәшем мөгаллим миңа таба ашыгып килә дә, бер читкә алып китеп, бүген җыенда авыл советына сайлаулар буласын, председательнең җыенга бары үзе яклы булган кулакларны гына җыюын, башка крәстияннәргә хәбәр итмәвен ашыгып кына сөйләде дә:

– Каршы кул күтәрәбез, аның кемлеге турында минем кулда шәп кенә нәрсәләр бар, – диде.

Без, кайбер аңлырак крәстияннәрне үз ягыбызга аудару өчен, халык арасына киттек.

Иске председатель, җыенга үз кешеләре генә килүне күреп булырга кирәк, шат йөри. Очраган берсенең хәлен сораша, ул безне күрү белән дә хәл-әхвәлне сорашырга тотынды. Сүз койрыкланып барганда гына, өяздән килгән агитатор-организатор мәҗлесне ачык итеп игълан итте. Председатель, бездән аерылып, халык уртасына кереп югалды...

– Беренче мәсьәлә – авыл советына председатель сайлау. Кандидатлар күрсәтүегезне сорыйм!

Мишәр агайлар дөнья җимереп шаулаша башладылар.

– Иске председательне яз, иске председательне!

– Әләмшә Ксугын, яхшы малай ул!

– Шатай Ибругын!

– Каз карак Абдулын, ул яхшы егет!

– Кит моннан, каз карак булгач, яхшы буламы?

– Синең казыңны урладымы?!

– Кемнекен урласа да, яхшы нәсел түгел.

– Ә синең нәселең нинди, ана...

Кандидатлар сайлау ике сайлаучының борыннарын канатышу белән бетте. Агитатор-организатор көч-хәл белән халыкны туктатуга, күрсәтелгән кандидатларны тавышка куя башлады.

– Беренче кандидат иске председатель Хәсән Кастыров, яхшы, булган егет, аның яклы булган кешеләр кул күтәрсен!

– Харуш!

– Харуш!

– Кемнәр каршы?

Каршы кул күтәрүчеләр булмады. Тик без генә, агитаторның алдына чыгып, кул күтәрдек. Бу көтелмәгән вакыйга агитаторны да, халыкны да шаштыра язды.

– Ни өчен сез каршы?

– Беренче, ул контрреволюционер, кулак, авылда контрреволюционный хәбәрләр тарата, авыл кулакларын разверсткадан саклый, дезертирлар асрап ята, аларда сыйланып йөри. Спекулянтларга төрле документлар эшләп

бирә, Украинадан сәүдә итеп кайткач, авылга председатель булды да бөтен авылны взятка бирергә өйрәтте... – диде минем иптәшем.

Ләкин мишәр агайлар аңарга артык сөйләргә ирек бирмәделәр.

– Долой, хулиганнар! – дип дөнья җимерә башладылар.

Без совет йортына кердек. Бер төркем кулаклар да безгә иярделәр. Иптәшем керү белән урындыкка утырды да тыныч кына тәмәке төрә башлады. Бер биш-алты кулак, йомрыкларын йомарлап, безгә таба килә башладылар.

Көтелмәгәндә өяз милициясендә эшләүче бер авылдаш чыгып, өстәлгә револьверын чыгарып куйды.

– Бу иптәшләр өстенә төшкән һәрбер йодрыгыгыз өчен авылдагы унбиш кулак җавап бирерсез! – диде.

Гайрәтләре йомрыкларына төшкән егетләр чигенделәр. Ә бераздан совет бүлмәсендә без өчәү генә калдык...

Утын мәсьәләсе бүген дә чишелмәде. Иртәгә дә шулай булыр. Озын сөйләүче озын мөгаллим тагын сәгатьләр өстендә йөрер.

Кич булуга, мине авыл советына чакырдылар. Минем иптәшне дә чакырганнар. Советка барып керү белән, бүлмәдә совет сторожы белән минем иптәш сугыш хәлләрен сөйләшеп утыралар иде. Иптәшем, миңа каршы килеп, сүзсез генә ике кәгазь күрсәтте. Аның берсе авылның мәшһүр сәүдәгәренә бирелгән: «Бу егет авылның иң ярлы кешесе, иген алырга бара. Сельсовет аның шулай булуын дөресли», – дигән. Икенче кәгазе дә шундый ук бер нәрсә. Без алга планнар төзи башладык. Бүлмәгә председатель, агитатор, озын сөйләүче мөгаллим белән тагын бер мөгаллим килеп керде. Агитатор безгә:

– Плохо, ребята! – диде.

Без җавап бирмәдек. Ул бүген чыккан мәсьәлә турында третейский суд[2] ясалачагын белдерде һәм сүзендә дәвам итте:

– Начар кешеләр икәнсез, авыл халкы бөтенесе сезгә каршы тамга җыярга йөриләр, – диде.

Минем иптәш:

– Сез дә кул куярсыз дип ышанам, – диде.

Агитатор:

– Әйе, миңа да туры килер шул, – диде һәм: – Яхшы эшчеләргә крәстияннәр начар карамыйлар, – диде.

– Ә сез җыенда нинди крәстияннәр булуын беләсезме, сезгә председательнең үзен яклаучы кулакларны гына җыюы, аңарга каршы булган кешеләргә сайлау булуын белдермәве билгелеме? – диде.

Агитатор бу сүзгә җавап бирү урынына абыйларча үгетләргә кереште:

– Сез яшьләр, ялгышуыгыз мөмкин. Бу эшне килешү белән бетерергә кирәк, – диде.

Минем иптәш тыныч кына урыныннан торды да:

– Сез кем буласыз? – диде.

Агитатор, аерым мәсхәрәле тавыш чыгарып:

– Мин сайлау кампаниясен уздырырга өяздән җибәрелгән агитатор-организатор булам!

– Коммунистмы?

– Ие!

– Ышанмыйм! Без аны контрреволюционерлыкта, взятка алучылыкта гаепләдек. Коммунист булган кеше шул ук вакытта бездән председательнең контрлыгы, взятка алуы турында документлар сорарга тиешле иде. Ә сез...

Ул, фуражкасын алып, чыга башлады, председатель ярты елаган тавыш белән:

– Эх, егет, егет, нигә мине батырырга телисең, сиңа ни усаллыгым тиде. Атаңнан ат җиктермим, разверстка вакытында калдырам, ә син...

– Ат җиктермәвең белән начар эшлисең. Кыскасы, бу нәрсәне икенче урында тикшерербез, – диде минем иптәш.

Озын сөйләүче озын мөгаллим эшне килешеп бетерү турында озайтып сөйли башлаган иде, без чыгып киттек.

Сахраларны яңгыраткан авыр туп арбалары кай җиргә барып тукталыр, әлегә билгесез... Шуның өчен дә киң шәһәр урамнары үзенең эченә тирә-як авыллардан сакаллары үсеп килә торган чабаталы егетләрне җыя да, җыйнак, җитез отрядлар төзеп, көрәш мәйданына җибәрә.

Без өяз комитеты йорты алдына туктадык. Баскычтан менеп килгәндә, безгә таныш агитаторыбыз очрады. Ул безне күрү белән нишләргә белмәде. Исәнләште, кесәсеннән папирос чыгарып сыйларга теләде. Без, берәрне яндырып, югары атлый башладык. Ул бездән калышмады. Өяз партия комитеты секретаре бүлмәсенә керү белән, ул да керде һәм безне секретарь белән таныштырып, мактарга кереште.

– Болар ... авылының иң алдынгы егетләре... – дип сөйли башлады.

Без партия секретареннан бүлмәдә ялгыз гына калуны сорадык...

.....................................

**Менә шул елларга хәзер җиде ел үткән**

Җиде калын пәрдә шул елларда булган бик күп вакыйгаларны үзенең артына яшергән. Еллар артыннан өстерәлеп йөреп мин тагын озын сөйләүче озын мөгаллим торган авылга кайттым. Озын сөйләүче озын мөгаллим тагын да озынрак сөйләргә өйрәнгән. Тик хәзер инде аны безнең кебек ачыгавыз тыңлаучылар гына юк.

Сугыш чукмары Исмай агай, Мәскәүгә барып, ары-бире сәүдә итеп, киемнәрен рәтләп кайткан да авылда кулларын кесәсенә тыгып йөри. Хәзер инде аңарга коммунист дияргә дә ярамый. Коммунист диденме, тота да кыйный.

Ул вакытта авылда мөгаллим булып торган берәү хәзер мулла булган да, әле күптән түгел генә мәхәлләсе арасында гошер хакында җәнҗал чыккан. Ул гошерне ун кадак алырга теләгән, крәстияннәр:

– Башка муллалар сигезәр кадак куйганнар, без дә шулай гына бирәбез, – дигәннәр.

Мулла:

– Җәһәннәм кисәүләре, мәлгуньнәр, Алладан айыйсыз, башка муллаларның доходлары зур, аннан соң аларның мәхәлләләрендә көн саен диярлек үлек була, сезнең, каһәр сукканнарның, берегез дә үлми бит, – дигән.

Яшьләр:

– Ах син, убыр! Әле безнең үлүне телисең икән, – дип тотып кыйный язганнар.

Хәзер инде биргәннәренә риза булып тора, ди...

Минем иптәш мөгаллим Мәскәүдә Тимирязев институтын[3] бетереп ята.

Агитатор-организаторыбыз хәзерге көндә өяздә тәмәке белән сәүдә итә.

Ә авыл советы диварындагы Ленин инде алтмыш йортка күчкән.

Һәр күчкән йортның иң якты диварында үзенә урын алган.

Мин авылдан киткәндә диварга кадап калдырылган Ленин рәсемен әнкәй җиде ел саклаган һәм, үзенчә аны матурларга тырышып, кызыл сөлге белән урап куйган.

## АЛАР ҖИҢЕЛДЕЛӘР

Яз уяна.

Тау битләрендә соңгы карлар эриләр.

Мәликә җиңгинең кече улы Әхмәт кичә үк яланаяк урамга чыгып керде. Бүген дә катык чүлмәген җимергән өчен, Мәликә җиңги чыра белән кыйнарга әзерләнгән иде. Шуны күрде дә, аягына-ниенә кими, урамга себертте.

«Яз килү белән малайларны кыйныйм дисәң дә кыйнап булмый шул; тотып, бирим дигәндә генә, урамга чыгалар да себертәләр. Икмәк урларга кайтканда гына тотып, бирмәсәң, кичен дә лапаста кунып калалар... Ә кышын инде, эләктергәндә, йөрәгең басылганчы бирәсең...» дип уйлый-уйлый, Мәликә җиңги Әхмәтне кыйнарга алган чырасын читкә ташлады да өстәл әзерләргә тотынды.

Көн караңгыланып килә, өстәлгә менеп баскан самовар кайгысыз-нисез үзе теләгән җырны җырлап чәй эчүчеләрне көтә.

Җыенга дип чыгып киткән Җиһанша җизни үзенең улы Зөбәйгә кабарган ачуын юлга ятып корсагын ялап ятучы песидән алды. Иркәләнүгә өйрәнгән песи Җиһанша җизнинең:

– Хайванкай, юлга ятып торма, әйдә, өйгә кер, – дип күтәреп алып керүен көткәндә, ачуыннан күзенә бернәрсә күренмәгән Җиһанша җизни, үзе дә белми, аның койрыгына басып җибәрде. Песинең дөнья җимереп кычкыруына куркудан чәчләре үрә торган Җиһанша җизни, аны эләктереп алып:

– Мә сиңа, мур кыргыры, мә, мә, мә, мә! – дип, песинең кай җире кычытса, шул җиренә биреп, ыргытып җибәрде. Үзе ашыгып өйгә кереп югалды.

Мәликә җиңги, иренең ачулы кайтуын йөзеннән аңлап:

– Көтә-көтә зарыгып беттем, чәем дә суынды инде, ни эшләп бу кадәр соңладыгыз? – диде.

Җиһанша җизни, өстеннән киемен сала-сала:

– Ни эшләп, ни эшләп... Ил күзенә күренерлегем калмады... Кайда барсам, шунда: «Уллар асрадың, ил башына бәла булдылар», – диләр... Чыгарлыгымны калдырмадылар, бәдбәхетләр... Бөтен җыен улыңны тирги, ни җитәр Салма Сәпкай улы да, авызын кәкрәйтеп: «Большевикка чукынган улың авылның бөтен серләрен шәһәргә белдереп тора... Бик белекле булган... Юк, башка авылның каманислары үз авылларын якларга тырышалар... Алар синең улың кебек авызларында чебеннәр уйнатмыйлар», – дигән була. Бөтен авыл шаулый. Дезертирларны тоттыруны да улыңнан күрәләр... Чыгарлыгым калмады инде, – диде.

Мәликә җиңги үзе дә иренең сүзен җөпләп улын хурлашырга теләсә дә, Җиһанша җизнинең артык кызып китүеннән куркып:

– Әле зурлары зурлар инде, алар белән бернәрсә эшләп булмый, бу кечкенә шайтаның да кулдан ычкына башлады бит, – дип, Әхмәттән зарлана башлады.

Җиһанша җизни, чәй янына утыргач, бераз басыла төште. Ул улы Зөбәйне сүгүче кайберәүләрне үзе дә сүккәләп алды. Ана бит, Мәликә җиңги дә картының сүз уңаена улларын яклап китте:

– Сиңа әйтәм, яшьләр бит, заманнар да бит үзгәрде. Аллага ышанмавын ышанмыйлар да бит, ә шулай да караклык юлында йөрмиләр, – диде.

Җиһанша җизни, Мәликә җиңгигә кырын карап, нидер усал бернәрсә әйтергә теләсә дә, сүзен әйтми чәен эчеп җибәрде.

Йорт эче караңгыланып килә иде инде. Җиһанша җизни, чәен эчеп бетерүгә, урындыкка басып, диварга эленеп куйган герле сәгатьнең башыннан нәрсәдер эзли башлады...

Мәликә җиңги белән Җиһанша җизнинең карт көннәребездә ярдәмче булырлар дип үстергән уллары, революция булу белән, «бозылдылар» да киттеләр.

Берсе, Кызыл Армиягә язылып, хәзер инде өяз шәһәрендә продразверстка[1] отрядының башлыгы булып эшли. Үзе коммунистлыкка язылды. Анысы гына берни булмас иде, авылга килеп, икмәк, атлар җыю белән «теңкәне корытып бетерә». Мәликә җиңги белән Җиһанша җизнинең «халык күзенә чыгарлыгын калдырмый».

Икенче улы Гали булса, көне-төне Җиһанша җизнине:

– Син – контр, – дип үрти дә тора.

Яшьрәк булса, Җиһанша җизни аны бөгеп биргәләр иде дә, хәзер җиңә алуына ышанмый. Аю кадәр булып үсеп килә. Шулай да зур улы Зөбәй шәһәрдә чагында йортта ул үз хөкемен йөртә. Ә Зөбәй авылга бер-ике көнгә килеп киттеме, Гали котыра башлый. Бөтенләй канат җәя. Кечкенә Әхмәт булса, яшь әле, аны Мәликә җиңги үзе генә дә җиңә ала.

Җиһанша җизни сәгать артыннан кирәкле кәгазьләрен алып төшүгә, аның күзе шәмаилләр арасында диварга элеп куйган Ленин рәсеменә килеп төште...

---

Ә еллар яңаның җиңүен алып килделәр. Ленин рәсемен бик күп крәстияннәр үзләре теләп диварларына элеп куйдылар...

Бер-бер артлы үткән сигез елның һәрберсе авылның ертык якаларын ямый-ямый үтте.

Мәликә җиңги элек улларының динне югалтып, Аллага каршы барулары өчен тәмугта янасыларын уйлап күз яшьләре түкте. Соңыннан аны икенче уйлар газаплый башлады. Аның карт йөрәге килен дәүләте күрергә теләде. Ләкин улларының авылдан өйләнергә ниятләре булмауны сизгәч, ул өметләре дә югалды. Картлык, ялгызлык куркынычы аны газаплый башлады: картлык көнебездә ни эшләрбез?.. Улларыбыз икесе дә коммунистлыкка киттеләр... Кем безгә ярдәм итәр... дигән уйлар аның көне-төне күз яшьләрен түктерде.

Ә беркөнне Мәликә җиңги белән Җиһанша җизни алмашындылар да киттеләр.

Вакыйга болай булды.

Үзләренең улларыннан кул селтәгән Мәликә җиңги белән Җиһанша җизни картая башлауларыннан зарлана-зарлана иген суккан вакытларында, авыл почтальоны 10 сумлык повестка китереп бирде.

Повестка теге атасы өеннән куып чыгарырга теләгән «тәүфыйксыз» уллары Галидән иде. Ул хатында «Кадерле әти, әнием, –дигән, – укулар бетүгә, – дигән, – эшкә кердем. Сезгә менә акча җибәрәм, – дигән. – Аз җибәргән өчен гафу итегез, – дигән, – сезгә сәламәтлек теләп калам» дигән.

Бу хат ата белән ананың күңелен йомшартты. Киләчәккә өметле уйлар уятты. Җиһанша җизни дә:

– Яхшы атаның уллары хур булмаслар, аталары эзенә кайтырлар әле, – дип куйды.

Улларыннан тагын бер-ике рәт акча килгәч, карт белән карчыкның күңелләре бөтенләй күтәрелде. Сигез ел буена җыенга бармаган Җиһанша җизни ара-тирә җыеннарга да барып килгәли башлады. Мәликә җиңги, карты җыеннарга баргалап йөри торгач, аның авызыннан ара-тирә:

– Советларны, карчык, сүгеп булмый шул, ни булса да безнең ише кешеләрнең файдаларын күзәтәләр, – дигән сүзләрне ишеткәли башлады.

Инде советлар Җиһанша җизнинең налогын да киметкәч, тагын советларның берничә файдасын күргәч, ул инде совет яклы булып китте. Әле беркөнне Салма Сәпкай улы белән талашкач, аңа:

– Баржуй! – дип тә ычкындырды.

Җиһанша җизнинең советлануы Мәликә җиңгигә дә тәэсирсез калмады.

Беркөнне советтан кайтуга, Җиһанша җизни:

– Шәһәрдән ниндидер бер хатын килгән, сезне җыеп нидер сөйләмәкче була, ди. Эшеңне бетергәч, сиңа да, карчык, барып килергә ярый, – диде.

Ә Мәликә җиңги – андый җыелышларга гомердә бармаган кеше. Ул, икеләнеп торса да, барырга булды.

Мәктәп йортына килеп керүгә, ул анда күп кенә хатын-кызлар җыелганны күрде. Ул килеп кергәч, авылның мөгаллимәсе шәһәр киеменә киенгән хатынга:

– Менә шул инде безнең Мәликә җиңги, аның ике улы да коммунист, – дип таныштырды.

Мәликә җиңги кызарды. Соңыннан шәһәрдән килгән хатынның коммунист уллар анасы Мәликә җиңги белән башкаларга караганда артык йомшак сөйләшүе аны эретеп җибәрде. Җитмәсә, мәҗлес ачылуга, аны, никадәр тартышса да, председатель итеп тә сайлап куйдылар.

---

Өйгә кайткач, Мәликә җиңги, шатлыгы эченә сыймый, картына бөтен нәрсәне сөйләп бирде, Җиһанша җизни хатынының начальник булуына эчтән генә бераз көнләшсә дә, үзенең дә совет тирәсендә дәрәҗәсе үсүен, әле күп кешеләрнең:

– Җиһанша агай, сине киләсе сайлауда председатель итеп сайласак, ничек булыр икән, – дип әйтүләрен исенә төшереп юанып куйды. Хатынына да ул турыда әйтмәкче иде, сайлауларга кадәр сабыр итәргә булды.

---

Канатлары чыкларга чыланган чәчәкләр җәйге кояшка карап көләргә тырышалар, ә кояш аларга күзен кыса, кояш бүген яхшы төшләр күреп уянган булырга кирәк – шаяра.

Баскычка утырып, чабаталарын кага-кага аякларын киенеп ятучы Җиһанша җизнинең борынына кояш нурлары кереп кытыклады, ул борынын күтәрде дә төчкереп җибәрде. Тагын, тагын төчкерде, тәне рәхәтләнеп китте. Ул тагын бер төчкерим дип кояшка күзен кысып караган иде, ләкин бу юлы төчкерә алмады. Тик борын эчен кытыклап кәефен генә бозды. Ул сыерын көтүдән озатып кайтучы карчыгына:

– Карчык, мин бүген тиз кайта алмам, советның собраниесен уздырасы бар, син инде аш әзерләп куярсың. Уракка бүген чыгып булмас, ахры. Шулай да тимерчедән уракны алып кайтырга кирәк булыр, – дип сөйләнә-сөйләнә аякларын киенә башлады.

Мәликә җиңги, үзенең бүген кооперативта эшләренең күплеген, бүген кооператив правлениесе җыелышы буласын исенә төшереп:

– Карт, минем дә бүген кооперативта собранием бар. Эшләр бик артка кала бит, – дип, йорт эшләре турында сүз ачты.

Җиһанша җизни:

– Карчык, йорт эшең дип халык эшен ташлап булмый инде, ни дә бит, халык ышанып сайлап куйган, авыр булса да, алып барырга кирәк, – диде.

Алар, шулай сөйләнә-сөйләнә иртәнге чәйне эчеп, көнне башладылар...

Җиһанша җизнинең йорты алдына килеп туктаган атка каршы чыгучы булмады. Гали үзенең иптәше Сәлимәгә:

– Менә шул инде безнең дворец, – дип күрсәтте.

Корзиннарны күтәреп төшкән Гали өйне бикле тапты; кырдадырлар, ахры, дип уйладылар.

Ләкин яшен сөртә-сөртә күрешкән күрше карчык:

– Әниләрегез, балаларым, кәмититкә киткәннәрдер, чакыртырга кирәк булыр, – диде.

Гали үзе китте. Ул совет ишегеннән атасының:

– Советлар үз хөкүмәтебез, ул безгә бу эштә ярдәм итәр, – дигән тавышын ишетте...

---

Еллар үзенекен итте. Җиһанша җизни белән Мәликә җиңги җиңелделәр.

---

Кичен чәй эчеп утырганда, Мәликә җиңги үзенең килене Сәлимәгә Гали белән атасының талашуларын көлдерә-көлдерә сөйләп үтте...

Җиһанша җизни үзе дә мыек астыннан гына көлеп утырды...

**КАРАБОРЫННЫҢ ДУСТЫ**

**Ахмаклар**

Сыер дигәнең бик ахмак нәрсә бит ул, яхшылыкны белми, аңарга ашарга гына булсын; корсак өчен кырык мәртәбә үләргә әзер. Яшь көтүче Әйдүк аларга:

– Ахмаклар, сыбызгы борыннар, мошнайлар, үзегез өчен бит, авылга аклар килсә, кызыл камыт киясегезне белмисезмени, – дип сөйләнеп маташса да, сыерлар, авылга аклар киләсен, килгәч, аларга уңайсыз буласын аңларга теләмәделәр. Урмандагы кигәвеннәргә түзми, авылга таба чаптылар. Әйдүк белән Караборынны – эт малаен арытып бетерделәр.

**Караборын танымады**

Әйдүк, көтүне бер җиргәрәк җыеп, бәрәңге пешерергә уйлады. Караборын аның ут ягарга маташуын башын борып-борып карап маташты да кинәт колакларын торгызып өреп җибәрде. Әйдүкнең колак йоннары үрә торды: «Инде аклар килеп җитте», – дип уйлады. Тик Караборын танымады, ялгышты. Килүчеләр Озын Хөсәен, Әйдүкнең атасы һәм берничә авыл егетләре иделәр. Алар ут янына килеп утырулары белән сүзгә башладылар.

Тәбәй Җамали улы Ибрай:

– Байлар сыйлап-сырлап үзләренең хайваннарын алып калырлар. Бөтен бәла безнең өскә төшәчәк. Болар большевиклар яклы дип ут өрүчеләр дә күп булыр.

– Шулай шул, – диде Әйдүкнең атасы, Ибрайның сүзенә кушылды.

Озын Хөсәен башын салып уйлап торды-торды да:

– Безгә хайванкайларны үз яныбызга алып бару хәерлерәк булыр, анда аларның сөтләреннән дә файдаланып булыр, – диде.

Озын Хөсәеннең сүзенә барысы да кушылдылар. Әйдүкнең атасы «яшьләр»нең сыерларын күрсәтеп чыкты. Ә бераздан егермеләп сыерны көтүдән аерырга маташа башладылар.

**Гайнү әбинең кәҗәсе**

Аклар отряды авылга, «мактаулы» гаскәргә ашатыр өчен крәстияннәрнең соңгы сыерларын алырга килделәр. Гайнү әби, авылның бер очыннан башлап йорт саен туктый-туктый:

– Алланың каһәре төште, әһем-м-м, соңгы кәҗәмне алырга килделәр, инде нишләрбез, майкушларым, әһем-м... – дип, яшьләрен җиң очына сөртә-сөртә сөйләнеп китте.

Кәҗәсе, аның юклыгыннан файдаланып, күптән кызыгып йөргән яшь кәбестәләргә кунакка китте.

Аклар җыен җыеп маташмадылар. Староста белән эшне бетерделәр. Көтүне эзләп, тирә-якка чапкыннар чапты.

**Яхшы кешеләр түгел икән**

Хәйрулла агай урамда җыелып торган бер төркем ак офицерларны читтән генә карап торды да үз эченнән генә:

– Яхшы кешеләргә охшамыйлар, – дип уйлады. Бу болай гына йөри дип уйласыннар өчен, кулларын артка куйган булып, әкрен генә йортына китте. Ә аннан, көтүне эзләп, урманга чапты.

**Караборын ошатмады**

Урманда көтүне эзләп йөрүчеләр күбәйде. Теге егерме сыерны алып киткәч, Әйдүк тагын ялгыз калды. Аны атасының аякларын төзәткән чакта ыштырлары арасыннан ялтырап килеп чыккан револьвер гаҗәпләндерде. Ул Караборынга бу хакта:

– Ә беләсең, Караборын, минем әти комиссар булган, – дип мактанып куйды.

Ә Караборын аның сүзен аңламады. Ул, тагын да колак йоннарын үрә торгызып, өреп җибәрде. Бу юлы урманнан, карана-карана, Вәли бай улы Габдулла килеп чыкты. Ул, Әйдүк янына килеп туктавы белән, тәмәке төрә башлады. Караборын бу кунакны нигәдер ошатмады. Ул аның ботыннан кабып карарга уйласа да, соңыннан ул уеннан кайтты. «Моңа кемлекне күрсәтәсе иде дә, ярый инде» дип капмаска булды. Габдулла агачлар арасына кереп югалды. Ә бераздан, Вәли бай улы Габдулла белән ике атлы килеп, көтүне авылга алып барырга куштылар.

**Эт баласы**

Авылга җитү белән, көтүне Вәли байның ишегалдына яптылар. Ә Әйдүкне өйгә өстерәп алып керделәр. Өйдә бишләп офицер, Вәли бай, староста, тагын кемнәрдер чәйләп утыралар иде. Әйдүк килеп керү белән, староста:

– Әйт, кемнәр сыерларын алып киттеләр, кайда алып киттеләр? – дип сорады.

Әйдүк әйтергә теләмәде, аңарга шулай кушканнар иде.

Ул:

– Белмим, – диде.

Староста, аның ике колагынаябышып:

– Әйт, эт баласы! – диде.

Әйдүк җавап бирмәде. Аны, эт урынына кыйнап, урамга ташладылар. Ул өстерәлә-өстерәлә өенә кайтты. Караборын аны койрыгын селкеп шатланып каршы алса да, соңыннан хуҗасының газапланганын күреп, бер-ике шыңшып алды. Әйдүкнең күңелен табу өчен уң аягын күтәреп, Әйдүккә сузып карады. Алай да булмагач, Әйдүкнең кулларын ялый башлады.

**Озын Хөсәен**

Төн.

Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән дә, саламга баткан йортлар караңгыда калганнар.

Әйдүк, Караборынны кочаклап, авып килә торган йортларының эргәләренә утырды. Башында чуалып йөргән уйлары берәм-берәм бутала башлады. Бүген аны кыйнаучы авыл старостасы, теге офицерлар аның күз алдына килеп басты. Аннан соң... ул уйларын икенче нәрсәгә борырга уйлады. Ничектер үзен кыйнатуы оят кебек тоелды. Үзе дә сизми йодрыкларын йомарлады.

Тик:

– Барыбер бернәрсә дә әйтмәдем, – дип юанды.

Атасы белән Озын Хөсәеннең бернәрсә дә әйтмәве өчен мактаулары күз алдына килде. Ул әкрен генә елмайды. Ә соңыннан аның күз алдында Озын Хөсәен йөри башлады.

Ул Озын Хөсәенне беренче мәртәбә урманда очраткан иде. Күптән инде бугай... Ул ничектер агачлар арасыннан чыкты да алар янына килеп утырды. Шул вакытта Караборын әз генә аның ботыннан эләктермәгән иде. Алар атасы белән әллә нәрсә сөйләштеләр. Икенче көнне ул тагын шулай килде. Бу килүендә авыл хәлләрен, авылдагы Әйдүкләр кебек ярлы кешеләрнең тормышларын, көнкүрешләрен сорашты бугай... Соңыннан... Әйдүкнең атасы белән алар нәрсәгәдер бик дуслашып киттеләр. Нәрсәдер Әйдүктән качып озак-озак сөйләшә башладылар. Әйдүкнең «Ходай тәкъдире, Алла кушканга без шулай» дип, бөтен кеше алдында бик юаш булып йөргән атасы үзгәрә башлады... Нигәдер уйчанланды, усаллана төште... Ара-тирә кемнәрнедер сүгә башлады. Соңыннан Әйдүк атасының Озын Хөсәен турында күрше Гыймадига сөйләп торганын ишетте:

– Гаҗәп кеше инде ул Хөсәен. Көне-төне урманда ач-ялангач йөрсә дә, үзенең эшен эшли. Безнең ишеләргә дус кеше инде ул Хөсәен. Син, Гыймади, аның сөйләгән сүзләрен ишетсәң иде, менә инде безнең кирәкләрне әйтә дә бирә.

– Җамали, ул үзе кем соң?

– ...Ул... Сиңа, Гыймади, ышанам инде... Без синең белән утыз ел күрше булып тордык. Алай-болай бернәрсә дә булмады, үзара сүз булсын, ул кызыллардан берәү икән... Кызыллар безнең авыллардан чигенгән чакларда, Озын Хөсәенне авылларда яшерен эшләргә калдырганнар. Ул, мондагы безнең ише ярлылардан Кызыл гвардия оештырып, акларның артына төшәргә тиешле икән. Безнең урманнарның берендә сугышка кирәкле төрле әйберләр дә күп калдырганнар, ди...

Икенче көнне күрше Гыймади да Озын Хөсәен белән дуслашты. Шулай итеп, авылда күп кенә егетләр берәм-берәм Озын Хөсәен белән дуслаша башладылар. Озын Хөсәен кичләрдә авылга да килеп киткәли башлады. Әйдүк белән дә бик дуслашып киттеләр. Ул старостадан үзенең үчен Озын Хөсәен белән икәүләп алырга мөмкин булачагын уйлады да:

– Шулай бит, Караборын! – дип, Караборынны кочаклады.

Караборын, үзенең ризалыгын белдереп һәм караңгыдан файдаланып, Әйдүкнең борынын ялап алды. Әйдүк аның борынына төкерде дә урыныннан торып кереп китте.

**Алып киттеләр**

Төн. Ае юк төннең.

Әйдүк, әллә кайда мич арасына кереп, бертуктаусыз җырлап утырган чикерткәгә эче пошып, аны эзләп маташтьы. Таба алмагач, бер-ике кычкырып карады, алай да булмагач, чикерткә кычкырган җиргә үзенең

чабаталарын ыргытты. Чикерткә бераз туктап торса да, күп тә үтми, тагын җырлый башлады. Әйдүк инде эзләп маташмады. Идәнгә салам түшәгән җәйде дә йокларга ятты.

Әйдүк әле төш тә күреп өлгермәгән иде, кинәт уянып китте. Аның баш очында Озын Хөсәен белән атасы Җамали торалар иде. Ул, Әйдүкнең башыннан сыйпап, нәрсә булганны сораштыра башлады. Әйдүк йокы аралаш сүзен кайдан башларга белми торганда, урамда Караборын ачы-ачы өрә башлады, һәм тәрәзә алдында ике күләгә күренде. Озын Хөсәен балтырыннан нәрсәдер алды да әкрен генә тәрәзә янына килеп карый башлады. Ә бераздан бик каты ишек кагуы ишетелде.

– Ачыгыз!

Җавап бирүче булмады. Озын Хөсәен Җамалига, шыпырт кына:

– Әйдә, сул як тәрәзәдән, – диде һәм тәрәзә янына ашыгып кына килде дә, штыгын алга очлап, тәрәзәгә якынаеп килгән солдатка атып җибәрде. Үзе, тиз генә тәрәзә рамын ватып, урамга атылды. Җамали Әйдүкне кочаклап нәрсәдер эшләргә теләгән иде. Ишек ачылып, ишектән кул фонаре тотып бер офицер, дүрт солдат килеп керделәр дә, офицер револьвер тоткасы белән Җамалиның башына сугып җибәрде. Җамалиның башыннан кан елгалары йөзенә агып төштеләр. Усал солдатлар аны тирги-тирги бәйли башладылар. Әйдүк, нишләргә белми, күзләрен зур итеп ачып карап торды-торды да, тиз генә атасына ташланып, аны кочаклап кычкырып елый башлады:

– Әти, сине кая илтәләр, нигә кулларыңны бәйләделәр? – диде. Аякларын кочаклады.

Җамали:

– Елама, улым, безне кызыллар килеп коткарырлар, – диде.

Артык ирек бирмәделәр, усал солдатлар Әйдүкне алып идәнгә ыргыттылар да атасын алып киттеләр. Әйдүк җиргә капланып үкси калды...

**Кызыл йолдызлар**

Бөтен кырларны тутырып, штыкларын кояшта ялтыратып, кызыллар киләләр. Аларның очлы башлы бүрекләрендә кызыл йолдызлар ялтырый. Аларның ат тояклары утлар чыгара. Алар Әйдүкнең атасын коткарырга киләләр. Әйдүкнең карт атасын аклар алып киткәнне беләләрдер алар...

Әйдүккә алар менә хәзер килерләр дә аның атасын аклар кулыннан коткарып алырлар төсле тоелды... Ләкин аның күз алдына атасының башыннан агып төшкән кан елгалары килеп төшү белән, ул, кинәт йокыдан уянган кебек, үксүеннән туктады да тиз генә Вәли бай йортына табан чапты...

**Келәттән тавышлар**

Әйдүк урам буйлап йөгереп барганда, аның артыннан кинәт берәү йөгереп килә кебек тоелды. Ул артына әйләнеп караган иде, аның күзенә Караборын чалынды. Караборын башын түбән иеп, гүя Әйдүкнең кайгысын белгән кебек, әкрен генә атлап килә иде.

Әйдүк Караборынны авылда үзенең бердәнбер дусы итеп хис итте. Шуның өчен дә аны ул кочаклап алды. Караборынның инде рухы күтәрелде. Ул, койрыгын югары күтәреп, Әйдүктән алда бара башлады. Әйдүк башта, атасын Вәли байның йортында кыйный торганнардыр дип уйлап, Вәли бай йортына таба китте. Ул, Вәли бай йорты алдында солдатлар күрү белән, якын барырга кыймады. Туктап тыңлый башлады. Вәли бай йортында тавыш, шау-шу ишетелмәгәч, нәрсә уйларга да белмәде. Ерак түгел бер йорт янында өч-дүрт хатынның мыштым гына сөйләшеп утыруларын ишетте. Әкрен генә алар янына үтеп, бер чатка сөялде дә тыңлый башлады. Сүз Әйдүкнең аталары турында бара иде. Ләкин ул аларның сүзеннән атасының кайда булуын озак аңлый алмады. Соңыннан бер хатын:

– Әй Ходаем, нишләтерләр икән үзләрен, бик каты кыйнаганнар, ахры, ыңгырашу тавышлары бирегә кадәр ишетелә, – диде.

Икенче берсе:

– Мин, тавышларын ишетеп, якынрак барып тыңларга уйлаган идем, келәт янына сакчы куйганнар икән. Бара башлагач, кем ул, атам, дип әйтте дә, буыннарым коелып китте. Тиз генә борылдым да өйгә кереп яшерендем, – дип авыр сулап куйды.

Әйдүк аталарының Вәли бай келәтендә икәнлекләрен аңлап алды. Ләкин нишләргә?

Ул нишләргә белмәде. Аның күз алдына Озын Хөсәен килеп басты. Ул, бәлки, качкандыр дип уйлады. Ләкин кайда хәзер ул?.. Әйдүкне дә, атасын да бердәнбер сөюче Озын Хөсәен кайда ул?.. Бәлки, урмандадыр?.. Ул тиз генә әйләнде дә урманга таба чапты.

**Таң шәүләләре арасында**

Таң атып килә. Авыл тынычсыз йоклый. Крәстияннәр, кояш чыгу белән, соңгы сыерларыннан аерыласыларын уйлыйлар да кире яклары белән әйләнеп яталар. Тагын, тагын шулай итәләр. Куркыныч төшләр белән саташалар.

Вәли бай йортындагы кысык ут шәүләсеннән башка авылда бер яктылык та күренми. Офицерлар күптән инде йоклыйлар. Тик аякларын чишенми яткан кайберәүләр генә төннең караңгылыгы эченнән түземсезлек белән нәрсәдер көтәләр. Кояш чыгарга якынлый. Шәүләләре, көнбагыш чәчәкләренең телләре кебек, күк читенә сузылалар.

Келәт янына куелган акларның сакчысы ары-бире авыл читенә карангалады да бүрәнәләр өстенә утырды.

Кинәт ерак та түгел мылтык аткан тавыш һаваны яңгыратып җибәрде. Тагын, тагын мылтык тавышлары ишетелде. Акларның полковнигы эчке күлмәкләреннән, шинеленең бер җиңен генә киеп келәт янына чабып килде дә сакчы солдатка ашыгып кына келәткә ут җибәрергә кушты.

Солдат, кесәсеннән шырпысын чыгарып, келәткә сөяп куйган киндер көлтәләренә ут төртте. Ут Вәли байның келәте янында буш керосин мичкәсенә күчте. Аннан югары үрмәли башлады.

Кызыл ут шәүләсе таң шәүләләренә кушылды...

**Янган гәүдәләр янында**

Көтелмәгән мылтык тавышларына уянган крәстияннәр нәрсә дияргә белмәделәр. Аларның күбесе кызыллар килеп басты дип уйлады. Бала-чагаларның уянганнары мич астына качып өлгерделәр. Крәстияннәр, мылтык тавышлары басылгач кына, ярык-йорыклардан урамга карый башладылар. Анда үз егетләренең мылтыклар тотып йөрүләрен күргәч кенә урамга чыктылар.

Кызыл отрядның башында Озын Хөсәен иде. Ул Вәли байның йорты алдында куллары, аяклары бәйләнгән Вәли байдагы теге дүрт офицердан һәм егермеләп солдаттан нәрсәдер сорашып маташты. Соңыннан бөтен халыкны ияртеп, янып, пыскып яткан келәт янына китте.

Келәт янында, кара җирне тырный-тырный, кечкенә Әйдүк үкси иде. Аның йөзе тузанга баткан, күлмәкләре өзгәләнгән.

Озын Хөсәен аны күтәреп алды да, шунда җыелган крәстияннәргә карап:

– Менә, кечкенә Әйдүкнең атасы, көтүче Җамали карт, хәзер инде янып көлгә әверелеп килә. Аны ни өчен шулай утка яктылар? Чөнки Җамали карт җирләре ярлы халык кулына күчкән бөтен байларга, зур корсакларга каршы көрәшүчеләрнең берсе иде... – дип, крәстияннәргә карап озак сөйләде. Соңыннан, солдатларга карап: – Менә бу солдатларның күбесе алданып, кайберләре аклар тарафыннан көчләнеп гаскәргә алынган үз туганнарыбыз. Телиләр икән, хәзер үк үзләре теләгән җиргә китә алалар. Китәргә теләмиләр икән, безгә кушылалар. Кулларын чишегез! – диде.

Солдатларның кулларын чиштеләр. Араларыннан берәү, алга чыгып:

– Мин сезнең сафыгызга, үз туганнарым ягына чыгам һәм соңгы тамчы каныма кадәр көрәшергә вәгъдә бирәм, – диде.

Башкалары да шулай ук әйттеләр. Озын Хөсәен, офицерларны күрсәтеп:

– Инде бу зур корсаклар, бу алтын погоннар, ут эчендә янып ята торган иптәшләребез өчен хисап бирергә тиешләр, аларны хәзер үк ут янына тезеп куегыз! – диде.

Вәли бай, тезләнеп, халыкка кулын сузды.

– Җәмәгать, яхшы кешеләр, минем ни гөнаһым бар, намазымны калдырмыйм, нигә мине һәлак итәсез! – дип ялына башлады.

Ләкин Озын Хөсәен тагын үзенең сүзен әйтте:

– Хәзер үк ут янына тезеп куегыз! – диде.

Егетләр аларны утка якын бер җиргә тезеп куйдылар.

Озын Хөсәен:

– Кемнәр болардан үч алырга тели? – диюгә, унбишләп крәстиян егете чыгып аларга каршы тезелделәр.

Кояш инде күптән җир өстенә карап торадыр иде.

**Кызыллар**

Кызылларның алдынгы күзәтчеләре бер татар малае белән зур гына кара борынлы этне тотып китерделәр. Бу Әйдүк белән Караборын иде. Штабта татарча белүче булмагач, аның белән сөйләшер өчен полктагы бер татар командирын эзләп таптылар.

Әйдүк авылларында булган вакыйганы командирга сөйләп бирүгә, Караборынның муенындагы муенсасын алды да муенса эченә тегелгән берничә кәгазь чыгарды. Моны Озын Хөсәен җибәргән иде. Язуларны полкның комиссары карап чыгу белән Әйдүкне килеп кочаклап алды. Әйдүк нигәдер түзә алмады. Әкрен генә елап җибәрде. Ул комиссарны да, тирә-ягын чорнап алган командирларны да үзенең иң якын кешеләре итеп хис итте. Ә кичкә таба Әйдүк китергән планнар буенча кызыл гаскәрләр акларга таба һөҗүм итә башладылар. Һәм акларны ике яктан кысрыклап фронтны төзеделәр...

**Соңгы саубуллашу**

– Хуш, Караборын, без синең белән тагын тиз күрешмәбез инде. Ибрайны яхшы тыңла, ул синең Әйдүгең булыр. Аны мине яраткан кебек ярат, – диде дә Әйдүк Караборынны Ибрай кулына бәйләп бирде. Үзенең күзләреннән ике бөртек күз яше агып төште. Караборын да, Әйдүк белән бик озакка аерыласын сизгән кебек, җиргә ятып ауный башлады. Аяклары белән Әйдүкне кочаклаган кебек итәргә тырышты. Әйдүк аны соңгы мәртәбә кочаклап башыннан сыйпады да, Озын Хөсәен аны ике тәгәрмәчле арбага утыртты. Атлар кузгала башлады. Караборын Әйдүкнең арбага утырып китәсен күргәч, аңарга табан тартыла башлады. Ибрай, Караборынны никадәр җибәрмәскә теләсә дә, булдыра алмады. Караборын аны өстерәп китте. Ләкин шунда карап торучы Ибрайның абзыйсы, җепне үз кулына алып, Караборынны җибәрмәде. Атлар ераклашкан саен, Караборын үзенең шыңшуын көчәйтте. Иң соңыннан бәргәләнә-бәргәләнә улый башлады...

**Караборын аны хәтерләмәде**

Совет кырларында туп ядрәләре соңгы мәртәбә яңгырадылар да, еллар артыннан еллар үтте. Кышлар артыннан кышлар килде. Табигатьнең оста бакчачысы кояш үзенең киң кырларында гөлләр үстерде.

Зәңгәр аксыл болытлар һәр җәйне киң кырларга яңгырлар ташыдылар. Тагын көз килде. Тагын яфраклар саргайды. Тагын салкын карлар кырлардан кырларга очтылар... Тагын карлар эреде дә, чәчәкләр уянды. Чәчәкләр һәр иртән кояшка табан әйләнделәр. Алар көн буе күзләрен кояштан алмый карап тордылар. Кояш иңгәндә аның белән саубуллашып караңгыга күмелеп калдылар... Авылларда Гражданнар сугышы хакында озак еллар әкиятләр сөйләделәр.

Кояш иңеп килә иде. Төнәк авылының кояш батышы ягыннан берсе бик озын, берсе бик кечкенә ике кеше килеп йорт алдына тукталдылар.

Йортның эргәсе янына ятып торган Караборын, бу көтелмәгән шәһәр киемендәге кунакларны куркытырга теләп, урыныннан сикереп торды, да арка йоннарын торгызып, аларга ташланды. Ләкин, көтелмәгәндә, шәһәр кунакларының кечкенәсе аңарга:

– Караборын! – дип эндәште.

Караборын өрүеннән туктады. Аңар бу тавыш ничектер таныш иде. Әллә кайчан аңа кемдер шулай эндәшәдер иде. Кайчандыр шушындый бер кешене ул бик яратадыр иде. Ләкин ул инде үзенең Әйдүген оныткан иде.

Әйдүк, аңарга якынлашып, аның башыннан сыйпады. Әйдүкнең исе дә аңарга бик таныш иде. Ул нигәдер бу кешегә өрүе өчен оялды. Ул, җиргә ятып, корсагы өстендә Әйдүккә табан шуышып килә башлады. Ул да булмады, торып читкә чабып китте, кинәт борылды да Әйдүкне аяклары белән кочаклап алды. Ләкин ул аның бергә куйлар көтеп йөргән дусты, иң сөекле дусты Әйдүк икәнен исенә төшерә алмады... Ул Әйдүкне оныткан иде. Бу, Әйдүк, аның өчен ниндидер онытылган, ләкин кайчандыр бик якын булган бер кешесе кебек кенә тоелды.

Авыл шаулады. Авыл председателе, Озын Хөсәен белән Әйдүк килүне ишеткәч, җыен җыйдырды. Җыенда авыл халкы үзләрен аклар кулыннан коткаручы Озын Хөсәенне күреп шатланды. Бәйрәм иттеләр.

Әйдүк үзенең иптәшләренә фронтларда йөрүен, хәзерге вакытта пионер булуын, тиздән комсомолга күчәчәген һәм коммуна мәктәбендә укуын берәм-берәм сөйләп бирде.

Тыңдәшләре аның батырлыгына гаҗәпләнделәр. Аларны бигрәк тә кызыл галстугы белән киемнәре кызыктырды.

**Әйдүк отряды**

Озын Хөсәен белән Әйдүк, авылда берәр атна торгач, кире шәһәргә китәргә җыена башладылар... Иртә белән үк авылның Озын Хөсәен отрядында катнашкан егетләре, авыл советы членнары, алар белән соңгы мәртәбә күрешергә килеп, саубуллашу мәҗлесен уздырдылар... Комсомол ячейкасының секретаре Гыймад, берничә комсомол белән

килеп, авыл мәктәбен «Хөсәен мәктәбе» дип атарга, авылда төзеләчәк пионер отрядын яшь көтүче, революция батыры «Әйдүк отряды» дип атарга карар бирүләрен белдерде һәм аларны тәбрик иттеләр.

### Караборын шәһәргә бармады

Алар өйдән кузгалу белән, өйне сырып алган авыл балалары, хатын-кызлар, крәстияннәр һәммәсе авылны чыкканга кадәр озата бардылар. Караборын да Әйдүк янына барды. Ләкин авылны чыгып бераз бару белән, Караборын туктады, әйләнеп авылга карады. Әйдүк аны:

– Караборын, бире кил! – дип күпме чакырса да, Караборын урыныннан кузгалмады. Җиргә ятып, аларның артыннан күздән югалганчы карап барды. Әйдүк, артына әйләнеп карый-карый, һаман Караборынны чакырды. Ләкин Караборын аның артыннан шәһәргә барасы килмәде.

### Әйдүкнең эзе буенча

Әйдүкләр күздән югалгач, Караборын нәрсәсендер югалткан кебек хис итте. Әллә ничек бу күздән югалган кешесе якын кебек тоелды. Минут үткән саен, аның йөрәге тибә башлады...

– Кем иде соң ул кечкенә сөекле кунак?

...Киң, зәңгәр чәчәкләр сибелгән урман буйларында көтүләр йөри... Әнә кемдер ерактан:

– Караборын, Караборын! – дип эндәшә.

Чү!

Ул бит күптән, әллә кайчан үзенең көтү көтеп йөрүен, аннан соң... бик кечкенә, бик сөйкемле Әйдүкне исенә төшерә алды. Бу күздән югалган кеше Әйдүк булмасын дип уйлады. Ләкин Әйдүк ул бик кечкенә иде...

Аннан соң аның киемнәре дә мондый түгел иде...

Ул, торып, юлны иснәде. Юлдан үзенең сөекле дусты Әйдүкнең исен тапты. Аннан соң, юлны исни-исни, Әйдүкнең эзе буенча чабып китте.

## ИРКӘ СОЛДАТ

Гали сборга җыелырга бер ай калу белән үк хатынына үзенең солдатка баруы турында сөйләнә башлады. Аның яңа гына өйләнгән хатыны Сәрби атасыннан ишетеп солдат хезмәтенең авыр булуын белә һәм Галине чын күңеленнән кызгана башлый. Гали Кызыл Армиядә борынгы солдат хезмәте юклыкны белсә дә, хатыны алдында ир булып, батыр булып күренергә теләп:

– Их, безнең башлар күпне күрә инде, – ди. Хатынының Кызыл Армия тормышын белмәвеннән файдаланып, хатыныннан үзен кызгандырасы килә. Хатыны да үзенчә мәче баласын ялаган кебек иркәли.

Сборлар башланды. Терармеецлар[1], чакырган көндә үзләренең частьларына килеп, өсләренә кигән киемнәрне сайлап киделәр, үзләренә билгеләнгән урыннарга урнаштылар. Ә безнең теге иркә солдатыбыз юк иде әле. Үткән ел аның белән янәшә караватта яткан Тимофей гына «чудак Гали»не ни өчендер исенә төшереп көлеп җибәрде.

———

Сбор җыелган көннең иртәсендә кызылармеецларны исемнәре белән кычкырып чыктылар. Иркә солдатыбызның исемен кычкырсалар да, «монда» дип җавап бирүче булмады. Ул бары шул көнне кичен генә мышный-мышный үзенең отделкомына килеп «явиться» итте. Отделкомы аны бераз шелтәләп каптенарга[2] җибәрде. Элек килүчеләр өсләренә яткан киемнәрне сайлап алып беткәнгә, безнең иркә солдатыбыз өлешенә калган шинель, ботинкаларны эләктереп үлчәми-нитми генә чыгып китте.

Икенче көнне проверка вакытында:

– Гали... мондамы? – дип кычкыруга:

– Монда! – дип кычкырып җибәрде.

Сагынып беткән иптәшләре аңар карадылар. Алар аны ярты аршынлы ботинкалар, җиргә тигән озын шинель эчендә күреп кычкырып көлеп җибәрделәр.

———

Маневрларга җыену башланды. Маневрларга китү алдыннан Гали хатынына язган хатын болай бетерде: «Сау бул, Сәрби, догада бул! Сугышка барабыз. Алла насыйп итеп, исән кайтсам, үзең теләгән бер ситса күлмәк

алырмын», – дип ялганлап язып куюга, Сәрбинең аны кызганып елавын күз алдына китереп елмайды. Соңыннан: «Кайгырма, Сәрби, командирлар мине бик яраталар. Полкта беренче солдат диләр мине», – дип өстәп куйды.

---

Маневрга чакыру сигналы бирелде. Отделком армеецларны чыгарга ашыктырды. Ә безнең иркә солдатыбыз әле боткасын ашап бетермәгән иде. Ул котелогын юмый-нитми генә китереп куйды да иртән ашыгып-пошыгып киенгән обмоткаларын да төзәтергә өлгермәде, винтовкасын сул ягына алып, газ маскасын кесәсенә тыгып, урамга чапты.

---

Колонналар революция җырлары җырлап баралар. Үткән-барганнар кызыл гаскәрләрнең дәртле җырларын эшләреннән туктап тыңлыйлар. Гали дә: «Мине карыйлар!» – дип, башын югары күтәреп, зур ботинкаларын өстери-өстери атлап бара.

...Менә ул үзен сугышка барган итеп хыял итә. Батыр Гали сугышка бара, үзен кызганып күзләреннән яшьләре килә. Чү, тигез барган колонна бозылды. Гали алга таба сөрлегеп китте. Кемдер артыннан:

– Обмотканы бәйлә, бозау! – дип кычкырды.

Батыр Галинең уйлары таралды. Пычракка баткан обмоткасын тотып, аксый-аксый сафтан чыкты.

---

Маневр ул – зур җиңүләргә алып барган көрәш юлы. Ә җиңү өчен булган көрәш авыр, сугыш белемен күп белүне сорый, түземне сорый. Кызылармеецлар, утыз чакрым үтүләренә карамый, батырларча алга атлыйлар. Аларның колонналары әле бозылмаган. Ара-тирә батыр җырлар җырлыйлар. Юлда өченче отделениенең командиры кызылармеецларның рухларын күтәрерлек көлке сүзләр сөйләп ала. Колонналардан шат яңгыравыклы көлү тавышлары ишетелә. Тик тигез колонналардан илле адымнар артта ике обмоткасын да җилкәсенә салган, фуражкасын кулына тотып, зур ботинкалары белән пычракның күзенә басып, аксый-туксый килгән иркә солдат кына көлми.

Аның рәтсез, ашыга-пошыга киенгән аяклары кабарып беткән. Ике көн юылмаган битләре буйлап тирдән кап-кара юллар сызылган. Аның күз алдында политзанятиеләр вакытында йоклап утырган бәхетле минутлары елмая...

Иркә солдат, уйлый-уйлый, үзе дә сизми базга килеп төште.

– Сөбханалла!

Базга төшү белән, ул «сөбханалла» сүзе артыннан ук бик тозлап сүгенеп алды. Ләкин ул ботинкаларын су белән тутырган базнымы, караңгылыкнымы йә үзен базлардан саклый алмый йөргән күзләренме сүкте? Анысын үзе дә белмәде.

Еракта: «Кызыл гаскәргә штыклар булыр әле, большевиклар синсез дә торыр әле», – дип җырлап барган иптәшләре аның ачуын китерде. Гүя алар аны үртәп шулай: «Синсез дә торырбыз әле», – дип җырлап барган кебек булдылар.

---

Авыл иртә йоклый. Тигез колонналар белән җырлап кергән гаскәр көзге яңгыр астында йоклап яткан авылны уятты. Берәм-берәм йортларга утлар алынды. Крәстиян агайлар, яңгырга чыланган гаскәрләргә үзләренең ишекләрен ачтылар. Галине югалткан командиры урам буенча аны эзләп йөрсә дә озак таба алмады.

– Шундый кызылармеецларың булса, сугышта пропадешь, – дип сөйләнеп йөргәндә, караңгылык эчендә берәү:

– Солдаты чдесь? – дип сорады.

Командир аны тавышыннан таныды.

Гали квартирга керү белән йоклый-йоклый чәй эчте дә аякларын, өстен чишенми генә идәнгә ауды. Аякчуларын киптерми, аяклары су эчендә йоклады. Юеш аяклар белән тагын юлга чыгуның әйбәт булмавы бары иртән уянгач кына исенә төште. Авылны яңгыраткан сигналга кызылармеецлар берәм-берәм әйбәтләп юынган, шәпләп киенгән килеш йортлардан чыгып җыела башладылар.

– Синең обмоткаң кая?

– Моя пропал, – диде Гали.

Иптәшләре аның аягына карадылар. Тездән пычракка баткан Галинең бер аягы обмоткасыз гына, оялган кебек шинель астында кәкрәеп торадыр иде.

«Сугыш» дәвам итә. Каршы яктан ара-тирә пушка, мылтык тавышы ишетелеп ала. Галине пушкага куйган командир:

– Кара, йоклама! – дип, ике-өч мәртәбә тәкрар итте.

Гали чын күңелдән йокламаска сүз бирде.

---

Таң ерак. Болытлар нәкъ Гали турысына килгәннәр дә җилкәсенә тиеп торалар... Галинең башы авыр болытларны күтәрә алмый түбән бөгелә...

Ә аз гына черем итеп алсаң, ничек булыр икән?

Чү! Трещотка[3] тавышы... Чын пулемет түгел ул... трещоткасы! Авыр болытлар Галинең җилкәсенә үк төшеп утырдылар. Ә нindидер шайтан килде дә озын бармаклары белән Галинең күз кабакларын басып тора башлады...

– Торыгыз!!

Гали күзен ачып җибәрүгә, аның алдында командир тора иде.

– Синең мылтыгың кая?

– Мылтыгым?!

Ул үзенең янында мылтыгын табалмады. Командир, артык сөйләшми, постка икенче кешене куеп, аны алып китте...

---

Маневрлар бетте. Переминниклар шатланышып авылга кайтырга җыена башладылар. Ә безнең иркә солдатыбыз Сәрбиенә үзе кайту урынына хат кына язып җибәрде.

«Сау бул, Сәрби! Постта торганда мылтыгымны алдырдым. Газиз башым ристан булды. Догада бул...»

## УЛ КӨННӘРДӘ

Габдулла авылындагы кызыл отрядларның командиры Газиз штабтан гаскәрләрен, акларны кысрыклап, Олы Ширмә авылына күчерергә әмер алды.

– Ничек кенә булса да, Олы Ширмә авылын аклардан әрчергә! Әйе, штабның әмере кимчелексез җиренә җиткерелергә тиешле.

Беренче башына килгән фикер шушы иде аның. Ул үзенең ярдәмчесенә тиешле әмерләрне бирде дә җитез адымнар белән Сәгыйдәләр йортына атлады. Юлда аның башы бу зур бурычны кимчелексез үтәү, ничек тә җиренә җиткерү уйлары белән тулды. Олы Ширмә авылында акларның җәяүле бер бөтен бүлеге ята.

Ә Газизнең отрядында барысы өч йөз җитмеш кенә кеше. Ләкин ничек тә, ничек тә Олы Ширмә авылы иртә таң белән кызыллар кулында булырга тиешле. Ул, бары Сәгыйдәләрнең капкаларын ачканда гына, Сәгыйдә турында уйлап алды. Аның башына кичә Сәгыйдәнең елап, муенына сарылып әйткән сүзләре исенә төште:

– Ә бала булса нишләрмен?..

Газиз кичә бу сорауга җавап бирмәгән иде. Бүген дә әле ул Сәгыйдә өчен шатланырлык җавап таба алмаган иде әле.

Ишектән керүгә, Газизне каршылаган Сәгыйдәнең күзләрендә ул тагын да шул ук сорауны күргән кебек булды.

– Газиз! Ә бала булса нишләрмен?

Газизнең ничектер тиз генә, тиз генә менә хәзер бу сорауга җавап бирәсе килде. Ләкин ничек?..

Ул Сәгыйдәгә таба атлады. Сәгыйдә аның күзенә акыллы гына карады да гүя:

– Син минем сорауга мине шатландырырлык җавап бирергә телисең, әйе бит? – дигәндәй, моң аралаш елмайды.

Газиз Сәгыйдәнең кулыннан алды да:

– Бар, әтиләреңне чакыр! – диде.

Сәгыйдә аңар шөбһә белән карады:

– Ни өчен?

– Соң әйтермен, – диде Газиз.

Сәгыйдә ашыгып бүлмәдән чыгып китүгә, ул китәргә хәзерләнә башлады.

---

Җамали агай белән Галимә абыстай, бүлмәгә керү белән, «Ни өчен безне чакырдың?» дигәндәй, аңарга сорау төсе белән карадылар.

Сәгыйдә, эшне сизенгән кебек, килеп түр тәрәзәсеннән урамга карады. Газиз карт белән карчыкка озак кына карап торды да күзләрен түбән иде:

– Җамали агай, Галимә абыстай... Сез картлар... Сез, бәлки, ачуланырсыз да, гаепләрсез дә... Ләкин... – ул сүзен бүлде. Кинәт авыр гына сулады да аякларын алмаштыра-алмаштыра, күзләрен күтәрми генә сүзендә дәвам итте: – Мин, штабның кушуы буенча, бу авылдан бүген китәргә тиешле... Ләкин сез Сәгыйдәне рәнҗетмәгез, ул балага калган булса... аның атасы мин булырмын... Тагын сорыйм, аны ирсез бала тапкансың дип рәнҗетмәгез... Мин аны өзелеп яраттым... һәм, сугышлар беткәч, без аның белән бергә булырбыз, – диде.

Сәгыйдә, йөзен куллары белән каплап, диварга сөялде. Җамали агай ни дияргә белми аптырап калды, аның күзләре зур итеп ачылды. Ул нидер әйтергә, ачуланып, бер бик каты сүз әйтергә теләде. Ләкин Газизнең, әкрен генә атлап килеп, Галимә абыстайның маңгаеннан үбүе һәм: «Мин – сезнең киявегез, ә сез ата-анам булырсыз», – диюе генә аны туктатты... Кинәт ул үзе дә белми әллә нишләде. Күзләренә яшьләр тәрелде. Сәгыйдәнең үксүе аның карт йөрәген кан белән тутырды. Ул Сәгыйдә янына килеп тукталды да, калтыранган куллары белән Сәгыйдәнең башын сыйпап:

– Аны элегрәк әйтергә кирәк иде, кызым, – диде... һәм җылы яшьләре сакалына агып төште.

---

Авылдан чыгып киткән отрядның соңгы арбалары кузгалды. Карчыклар үзләренә төшкән кызылармеецларны улларын озаткан кебек, иркәләп озаталар, кызылармеецларның куеннарына пешкән йомырка тутыралар.

– Сау бул, балам, җиңеп кайтыгыз инде... – диләр.

Яшькә йомшаклары җиң очларына яшьләрен дә сөртеп-сөртеп алалар.

Галимә абыстай саламлыкта Җамали агайның янына утырып үкси.

– Кияү икәнен белсәм, сыйлаган булыр идем үзен, маемны да, юачамны да ясаган булыр идем... Күзенә дә карап өлгермәдем. Очар кош кебек килеп кунды да тагын очып китте... – ди.

Ә Сәгыйдә, күзләрен бер ноктага теккән килеш, урамга карый, аның Газизе инде, атын уйната-уйната, Сәгыйдә арыш урган кырларны үтеп бара torгандыр...

---

Ерактан ыңгырашып килгән туп тавышлары Сәгыйдәнең йөрәк тамырларына килеп тоташа, бәлки, шул хәзер генә шартлаган туп Газиз өстенә төшкәндер дә... Төшкәндер дә... Юк!..

Сәгыйдә күзләрен ачып, Газиздән калган китапка тегәп, андагы юлларны ул танып бетермәсә дә, йотылып укый башлый. Китап эчендәге фикерләр, бутала-бутала, аның миендәге бушлыкларга йөгерәләр. Аннан, йөрәк тибүләренә кушылып, Сәгыйдәнең кан тамырлары буенча ага башлыйлар.

– Кызыл отрядлар эшче, ярлы крәстияннәр өчен сугышалар. Шул отрядларның берсенең башында аның сөекле дусты Газиз...

---

Төнлә туп тавышлары якынайды. Таң алдыннан авыл ядрә яңгыры астында калды. Урамнан атыша-атыша атлар чабып үттеләр. Авылның ерак очында янгын чыкты. Авыл төннең караңгылыгы эчендә, мылтык тавышлары уртасында, янгын яктысы белән күмелде.

Тик таң булуга гына атышу басылды. Кояш урман битеннән күтәрелгәндә инде, погонлы атлылар йорттан йортка күчеп нәрсәдер эзли, әллә кемнәрдән әллә нәрсәләр алып йөри башладылар.

Йокысыз курку белән төнне уздырган Сәгыйдә, яшеренеп кенә урамга чыгып кергәч, атасыннан кызылларның чигенүләрен, авылның аклар кулына күчүен ишетте.

Димәк, Газизнең отрядлары җиңелгән. Газиз, бәлки, үзе дә Сәгыйдә арыш урган кырларның уртасында җансыз килеш йөзен күккә каратып мәңгелеккә тын калгандыр...

---

Тәрәзә шакуга, Җамали агай урамга чыкты. Сәгыйдәгә тәрәзә ышыгыннан атасы белән кемнәрнеңдер сөйләве ишетелә башлады.

– Твоя лошадь есть?

– Моя бедный, моя лошадь нет!

– Врешь, подлец! Хәзер алыгыз үзен! – дигән тавышны ишетеп, Сәгыйдә урамга йөгерде. Ике солдат Сәгыйдәнең атасының кулларын тотып маташалар иде. Сәгыйдә чыгу белән, офицерның күзләре Сәгыйдәгә төште. Ул аңарга бераз карап торды да солдатларга Сәгыйдәнең атасын җибәрергә кушты. Үзе, янындагы икенче офицерга күзен кысып, нидер әйтте һәм, рус телен татарча бозып:

– Әй, бабай, моя у тебя будет жить, – диде һәм ишеккә атлады.

Өйгә кергән офицерлар Сәгыйдәгә ашарга хәзерләргә куштылар.

---

Инде караңгылык төшеп килә. Сәгыйдәләргә төшкән офицер, Җамали агайдан соңгы тавыгын суйдырып, аш хәзерләргә кушты. Үзе сумкасыннан ниндидер эчемлек алып, бер-ике стакан эчеп җибәрде. Сәгыйдә, берни булмаган кебек, аш хәзерләргә тотынды. Ул утын алырга дип йортка чыккач, аның артыннан офицерның да шпоралары шалтырады.

Менә шпора тавышы якыная. Сәгыйдә, бернәрсә сизмәгән кебек, җирдән бөгелеп утын күтәрә... калтыраган куллар, аны арттан кочаклап алып, саламга табан өстери башлый. Сәгыйдәнең утыннары җиргә коелып китә. Кинәт ул офицерның кулыннан яшен тизлеге белән ычкынып китә дә кулында ялтыраган авыр балтасын офицерның маңгаена төшерә. Офицер, төбеннән киселгән агач кебек, ыңгырашып утыннар өстенә ава.

Төнге караңгы җил, агач башларын дулкынлата-дулкынлата, урман өстеннән әллә кая ашыга. Төнге агач ботакларына битләрен тырный-тырный йөгергән Сәгыйдә үзе дә сизми ярга килеп егылды. Аның тыны кыса, озак йөгерүдән сулышы күкрәгенә сыймый. Ул, үзе үтергән офицерның сумкасын күкрәгенә кыскан килеш, урыныннан авыр гына торды да тагын агачлар арасына кереп югалды. Менә шул кисмә урманны үтү белән, кыр башлана... Аннан Яубаш авылы, анда кызыл отрядлар... Ә аларның башлыгы – Сәгыйдәнең сөекле дусты Газиз...

Сәгыйдәнең уйлары яшен тизлеге белән алмашына, аның адымнары тизләгән саен, йөрәк тибүе көчәя. Урманны чыгу белән, Сәгыйдә кинәт туктады. Алдан кемдер бик каты:

– Кем ул? – дип кычкырды.

Сәгыйдә калтыраган тавыш белән:

– Миңа кызыл отрядларның командиры кирәк, – дип кычкырды.

Ике атлы, аның янына килеп, аны тикшерделәр һәм, ияртеп, Яубаш авылына алып киттеләр. Тик Яубаш авылында Сәгыйдәне Газиз каршыламады. Аны Газизнең ярдәмчесе авыр гына караш белән сөзеп алды да:

– Сез Газизгә килдегезме? – диде.

Сәгыйдә түземсезлек белән:

– Әйе, мин аңарга акларның кирәкле кәгазьләрен алып килгән идем, – диде. Кулындагы сумкасын сузды.

Яшь командир ашыгып кәгазьләр өстендә күзен йөртте дә берәүгә ашыгып әллә кемне чакырырга кушты. Үзе Сәгыйдәнең килеп кулларын кысты. Аның йөзе яктырып китте, тик Сәгыйдәнең:

– Ә Газиз кая? – дигән соравы гына аның йөзен караңгылатты.

Ул авыр гына:

– Газиз кичә безнең арабыздан югалды... – диде.

Сәгыйдәнең башы әйләнде, ул кинәт кычкырып еларга теләде... Ләкин яшьләре, тын юлларына тыгылып, аны будылар. Сәгыйдәнең йөрәгендә беренче мәртәбә көрәш ялкыннары йөгерде, беренче мәртәбә, шул көнне булган сугышта кызыл отрядларны көрәшкә өндәп, үлем кырларында хатын-кыз тавышы яңгырады.

Туп тавышлары Габдулла авылыннан ерагайган саен, дошманнарны куып барган отрядлар белән Сәгыйдә дә ерагая барды... Тик ил телендә аның турында мактау җырлары гына калды.

**КИЯҮ**

Галиянең Сәгыйть җибәргән башкодага:

– Син Сәгыйтькә әйт, мин аңарга иргә чыкмыйм, – дип әйттереп җибәрүе Сәгыйть өчен көтелмәгән бер эш булып чыкты.

Менә сиңа кирәк булса, үзе бит, Сәгыйть, мин сине яратам, фәлән-төгән дип йөрде ләбаса... Очрашуларына озак вакытлар үткән булса, бер хәл булыр иде. Әле бит беркөнне генә әрәмәлектә, бозау эзләп йөргәндә очрап, Сәгыйтьнең бүреген урлап качкан иде. Сәгыйть аны куып җитеп, кочаклап үпкәч тә, кызый авызын гына сөрткән иде, артык бер сүз дә әйтмәгән иде. Менә ышан кызларга...

Сәгыйть башкодага: «Кыз белән сүз куешкан инде, эш ата-аналарыннан гына тора», – дигән иде. Ә эш бөтенләй койрыгы белән килеп чыкты. Галиянең ата-аналары, кызларын Сәгыйтькә ике куллап бирергә риза булсалар да, Галия риза булмаган. Бу ни, бу инде әллә Сәгыйть артык үзенә ышанып ялгышканмы, әллә Галия шаярамы.

Менә оят. Бит белмәгән кызга булса, тагын бер хәл булыр иде. Яратышып йөргән, тиздән хатын булып килүенә һичбер шиге булмаган кыздан шул җавапны алгач, таныш түгел кызларга ничек башкода җибәрергә?..

Әнкәсе дә Сәгыйтькә, кәефен җибәрмәс өчен бугай, карамаска тырыша. Атасы да сүзне гел икенче якка борырга тырыша... Бу ни бу? Их, егет булып йөр дә шулай алдан, имеш... Берәр рәтлерәк кешегә сүз куеп өлгергәндер, ахры. Чорт с ней! Соң Сәгыйть тә тиле инде. Галиягә элек шул турыда белдереп куйган булса, нәрсә булыр иде?.. Бәлки, болай кызарырга да туры килмәс иде.

Сәгыйть ары-бире генә капкалады да урамга ашыкты. Аны аңлашылмаган бу вакыйга ялгызлыкка тартты. Ул ашыгып бакчага чыкты да, шомырт агачлары белән күмелгән салам башлы каралтыга кереп, печән өстенә йөзе белән капланып ятты.

Шулай булсын... чыкмасын... ярый... Әле әллә кемгә чыкмас... Бәхетсез булса, сагыныр әле Сәгыйтьне... Ә Сәгыйтькә чыккан булса... Сәгыйть аны үлеп яратыр, авыр эшкә кушмас иде. Авырган вакытларында, аның баш төбенә утырып, гел күзенә карап торыр иде... Теләсә, җанын да аның өчен фида итәр иде... барыбер үкенер, чыкмасын, чорт с ней. Әй, кыз беткәнмени...

Сәгыйть уйлаган саен уйлаган уйларыннан качарга тырышты. Бер уйдан тизрәк икенче уйга күчәргә, шулай итеп үзенең хурлануын онытырга тырышты. Ул авылның икенче кызларын күз алдына китереп, аларга өйләнгәч бергә тора башлауны күз алдына китерергә уйлады. Ләкин җанга яткан бер матур тормыш та күз алдына китерә алмады. Ул Сәгыйтьләрдән ерак та түгел күрше кызы Фәхриягә уе белән өйләнеп карады. Фәхрия ул үзе матур гына кыз. Ләкин Фәхриянең бертуктаусыз чыкчып-чәпчеп йөргән капчык күзле анасы килеп басты. Картая төшкәч, Фәхрия дә шуның кебек булыр төсле тоелды.

Ул бу уеннан тизрәк качарга тырышты. Юк шул, Сәгыйть үзенең киләчәген бары Галия белән генә матур итеп уйларга өйрәнгән, киләчәген гел Галия белән генә күз алдына китерә алган Сәгыйть бүген менә шул киләчәген югалткан, бөтенләйгә җимерелгән итеп хис итте. Аның әллә елыйсы да килә башлады бугай, эченнән генә: «Барыбер... чыкмасын... миннән матурракка чыгар... ләкин мин биргән бәхетне таба алмас... минем әни кебек йомшак телле каенана да табалмас...» – дип уйлады.

Соңыннан ул уйлары белән шәһәргә китте. Ул үзе, шәһәрне күрмәгән булса да, төрле кешеләр сөйләве аркылы башында зур бер шәһәрне җанландырды.

Менә Сәгыйть, имеш, шул шәһәргә бара. Анда эшкә керә. Тырышып эшләве сәбәпле дәрәҗәсе үсә. Ул ничектер комиссар да була. Ә көннәрнең берендә пар атта нәкъ комиссарларча авылга килеп төшә. Авыл халкы:

– Менә яхшы кешенең баласы һәрвакыт яхшы була ул, – диешәләр, имеш.

Сәгыйть, эре генә, зур күн бумажник тотып, авыл советына бара, имеш. Шунда авыл советына Галия килеп керә, имеш, ул арыкланган, күз төпләре күгәргән. Аны Сәгыйтьне ташлап чыккан ире кыйнаган, имеш. Галия аны күрә дә...

Сәгыйть кинәт сискәнеп китте. Кулына әллә нинди йомшак бер нәрсә тиеп киткән кебек булды. Ул, башын күтәрүгә, яңа гына калдык-постык ашлар белән тамагын туйдырып, кәефе күтәрелеп, Сәгыйтьне эзләп килгән Барбусны күрде. Ә Барбус печән өстенә менеп аның янына ук сузылып ятты, Сәгыйтьнең уйлары таралды. Ул үзенең хәзер генә Барбус түшәгенә килеп ятуын аңлады. Тирә-яктан, борын ярып, эт исе килә башлады.

________

– Балам, атаң таңнан торып эшләп йөри. Тырмаларга барырга кирәк. Тор инде, – диде Сәгыйтьнең анасы.

Сәгыйть, төн буе уйланып йөрүе аркасында бик соң ятканга, бары ике генә сәгать йоклап өлгергән иде. Ул бер күзен генә ачты, яктылык күзен кисеп китте.

– Хәзер торам, әни, – диде, башын күтәрде.

Анасы чыгып китүгә, Сәгыйть тормады. Торасы килмәде. Буыннар шундый рәхәт таралганнар... шундый рәхәт. Буыннарны җыясы килми. Менә тагын бер генә минут күземне йомып алам да аннан торырмын дип уйлады ул. Күзен йомуга, тагын Галия килеп басты. Ул Сәгыйтькә әллә кайдан, томаннар эченнән елмайган кебек булды. Ләкин ишеккә якынайган аяк тавышларын ишетү белән, ул югалды. Сәгыйть, энкәйнең кәефе китмәсен дип, ул кергәнче башын күтәреп, анасы хәзерләп куйган чалбарларын алды да киенә башлады. Анасы, аның киенүен күреп, ишектән башын сузып карады да тагын чыгып китте.

Сәгыйть бер аягын киенеп бетерә алмады, кулларын киң итеп ачып киереләсе, үсәсе килеп китте. Ул башын баскычка куйды да яткан килеш кенә чабата бауларын бәйли башлады, соңыннан иркенләп бер киерелеп алды. Ул икенче чабатасын алып киенергә дип башын күтәрергә теләсә дә, башы күтәрелергә теләмәде. Күзләр бик тәмле, бик рәхәт итеп йомылдылар. Башына: «Бер генә минут күземне йомам да соңыннан торырмын», – дигән уй тагын килеп утырды.

Бу юлы инде Сәгыйтьнең анасы түгел, атасының:

– Тор инде! Тырмага барырга вакыт, – дигән ачулы тавышы ишетелде.

Сәгыйть тиз генә сикереп торды да, калган чабатасын да киенеп, печәнгә китте.

Сәгыйтьнең артыннан карап калган анасы:

– Баламның теләгәне булмагач, бөтенләй йолкынган тавык кебек йөри башлады. Кызы да инде кемгә бармакчы була тагын... Әй Ходаем, алтын алма кебек баламны яратмаган була бит...

Ул эченнән Галиягә бик нык ачуланды. Киленем булыр дип йөргән Галия кинәт аңар бик ерак, бик ят кебек тоелды. Аның йөрәгендә һәрвакыт җылы урын алып килгән Галия югалды. Югалды да йөрәгендә караңгы буш урын гына калды ананың.

---

Канатлары чыкларга чыланган кыр чәчәкләре язгы кояшка елмаерга тырышып карыйлар. Аларны таң җиле туңдырган. Кояш инде офыктагы зәңгәр болытлар өстенә чыгып, елмаюлы җылы якынлык белән җиргә карый.

Көн кояшлы, яңгырсыз, озын булыр төсле.

Галия, ал яулыгын артка бәйләп, очы парга чыккан яктан тапталган арышларны чүпли-чүпли, урак ура. Кояш аның яңакларына аллык керткән. Ул, җирнең чәчәкләрен кызарткан, матурлаган кебек, аны да кызыл чәчәкләргә охшатырга тырышып елмая бугай.

Галиянең җитез кулы белән киселеп салынган учмалар кояш нурларында алтынланалар. Алар таң җилләре белән тирбәлмәсләр тагын.

Якында гына кемнәрдер «Ай урагым»ны җырлыйлар, Галия авыз эченнән генә алар белән кушылып җырлый.

Үзенең җырлыйсы килсә дә кыймый. Кыз башы белән ялгыз кырда җырлап урак уруны килештерми. Күрше Хәдичә апай да бүген урагы бетәсе булганга ашыкмый. Ары-бире кискәләде дә, кыр очы күренә башлау белән, баш астына зур гына көлтә салып йокларга ятты. Әле төнге тәмле йокы белән таралган сөякләр яңа ныгып киләләр. Эшләгән саен, алар ныгый бара төсле.

Әллә кая еракта, озын, моңлы, әллә кемен сагынган, югалткан төсле итеп, ат кешнәп алды. Галия башын күтәреп юл башыннан кемнәр уза икән дип каранса да, басу эчендә беркем дә күренмәде. Бары пар кырында гына соңга калган кайбер сукачыларның ялкау гына атлап йөргән атлары күзенә чагылды. Әнә берсе ялкау гына башын салып артыннан калмый йөргән таен ияртеп тырмалап ята...

«Бичара тай, ятып калсам, анам китеп югалыр, дип уйлый торгандыр. Иярә дә йөри, иярә дә йөри, мескенем», – дип уйлады Галия. Ул урагын тотып, арышка дип бөгелим дигәндә генә, якында нәкъ Галия турысында кояшка аркасын терәп, йокымсырап туктап торган ак маңгайлы атны күреп, карый башлады.

«Хуҗасы ялкау кешегә охшый. Әле кояш күтәрелеп тә өлгермәгән, ә ул йоклап ята», – дип уйлады.

---

Сәгыйть кырга җитү белән бер-ике әйләнде дә, бераз тәмәке тартып алыйм дип, җиргә ятты. Аяклар шундый рәхәт, шундый рәхәт итеп сузылдылар. Ул аякларын бик еракка, бик еракка сузасы килде. Йөрәгендәге суык бушлыкны тутырырга, җылытырга теләгән кебек, кояш нурлары аның аркасын кыздыра башладылар. Ул тагын да Галия турында уйлый иде. Аның уйлары кинәт җанлана башлады. Күз алдына, азапланып, китәргә теләгән Галиянең рәсеме, үзеннән-үзе җанланып, аның алдында йөри башлады. Аның уйлары тәмле төшкә әйләнеп, кояшның якты нурлары арасында рәхәтләнеп йоклап китте. Ә баһбай, үзенең тырмасын өстерәп, арышларга табан атлады. Бер-берсенә бәйләнеп киткән төш Сәгыйтьне әллә нинди урманнарда, суларда йөртте... Менә ул караңгы бер урманда, имеш, тирә-якта шундый чәчәкләр күп, имеш. Ул әллә ничек чәчәкләр өстенә басмый гына атлап бара, менә ул кулларын селти дә, тәне үзеннән-үзе җирдән күтәрелеп китә, имеш... Сәгыйть ничек соң элек шулай оча алмаган... Чү! Әллә каян бик ерактан, томаннар эченнән Галиянең тавышы ишетелә:

– А-а-у-у-у.

Сәгыйть, аңарга очып барырга уйласа да, кинәт авырая да җиргә егылып төшә, имеш...

Сәгыйть уянып китүгә күзләрен ачты. Ерактан ишетелгән хатын тавышына баш күтәргән иде, баш очында сөялеп торган баһбай күзенә күренмәде. Ул тиз генә сикереп торды да, тирә-якка каранып, баһбайны эзли башлады.

Ә баһбай, рәхәтләнеп, нindидер хатынның көлтәләрен ашап ята иде. Сәгыйть тиз генә шунда таба йөгерде.

Тиз барып җитүгә, ул кинәт күзләренә ышанмады. Көлтә өстенә утырып баһбайга арыш ашатып яткан кыз беркөн генә аның бик якын, бик кыйммәтле булган Галиясе иде. Ул туктап нишләргә белмәде. Ә Галия шат, яңгыравыклы көлү белән кычкырып көлеп җибәрде:

– Менә кияү... менә моңар иргә чык... – диде. Үзе кулындагы арышка сузылган баһбайның башын кочаклады.

– Ничек, баһбай, шундый йокы патшасына иргә чыгарга ярамый бит, – диде дә тагын көлеп җибәрде.

Сәгыйть күзләрен Галиягә күтәреп карый алмады. Ул ашыгып килде дә, баһбайның йөгәненнән тотып, әйдә, баһбай, дип өстери башлады.

Галия баһбайның башын җибәрмәде.

– Китмә, баһбай, син миңа кунакка килдең, ялкау кешең китсә китсен, – диде.

Сәгыйть кинәт Галиягә карады, Галиянең елмайган йөзе ниндидер якынлык, тагын да борынгы дуслыкны вәгъдә иткән кебек булды. Йөрәге тагын тулып киткән кебек булды. Галиянең елмаюы йөрәгенең авырткан урыннарындагы ярсулы хисләрен алып ташлаган кебек булды. Ул кинәт җиргә утырды да, Галиягә карамыйча гына, камылларны йолка-йолка:

– Нигә миңа иргә чыкмыйсың? – диде.

Галия тагын кычкырып көлеп җибәрде:

– Син сыер кебек ялкау, аю кебек йокыны сөясең, синең белән ачка үләрсең, – диде.

Сәгыйть үзе дә белми кызара башлады.

– Йоклавыма үзең гаепле. Кичә мин төн буе йокламый сине уйлап уздырдым, – диде.

Галия, урыныннан торып, тирә-якка каранды да, карап торучы кеше юклыкны күреп, якыннан бер уч арыш алып, тагын баһбай янына утырды. Сәгыйть тагын сүзне ничек башларга белмәде.

– Син мине кимсеттең... Ярый... Байга кияүгә чыгарсың, без ярлылар шул... – диде.

Галия тагын көлеп җибәрде.

– Шулай шул, ашың түгелгәч, кашыгыңны сузасың... Сиңа үзең кебек ямьсезрәк кешегә башкода җибәрергә кирәк иде, – диде.

Сәгыйть тагын кызарды. Галиянең сөйләвен ул шаяру катыш икәнен белсә дә, соңгы сүзләре аның кинәт йөрәгенә кадалды.

Ул торып китәргә уйлаган иде, ләкин Галия кинәт аның борыныннан тотып башын күтәрде. Сәгыйть, йөрәгендәге авыр хисләрен тарату өчен, көлеп җибәрде.

Галия аның күзеннән күзен алмады. Сәгыйть бала кебек көлгәннән-көлә бирде. Соңыннан урыныннан торды да баһбайның башыннан тотып китә башлады. Ул, тавышын яшерә төшеп, үзеннән чыгарган җырын җырлап җибәрде.

Яшьлегемнән кырда үстем,
Кыр чәчәген күрмәдем,
Кече яшьтән сөеп йөрдем,
    Галия бәгърем, алдаучы кыз,
    Алдарсың дип белмәдем...

Галиянең йөзендә кинәт борынгы көлү эзләре югалды. Ул, Сәгыйтьне бик яраткан вакытларындагы кебек керфекләрен очлап, моң аралаш Сәгыйтькә карады. Сәгыйтьнең инде йөзендә борынгы оялу эзләре югалып, әллә нинди үкенүле кайгы моңнары белән уралган иде. Галия аның йөзендә элек ничек моңаеп җырлаган вакытларында да мондый төс күрмидер иде. Сәгыйть тагын җырлап җибәрде. Тик ул бу юлы тавышын тагын да әкренәйтте. Тавышы әкренәю белән, аның тавышына тагын да моңлырак яңгыраулар катнашты.

Йөгереп чыктым бакчага ла,
Чәчәк аткан алмагач,
Инде кемгә күңлем бирим,
    Галиям, бәгърем, җанкисәгем,
    Син дә мине алдагач.

Галия аңар табан атлады да, кулыннан тотып:

– Утыр әле! – диде.

Сәгыйть әкрен генә Галия янына утырды. Галия сүзсез генә аның башын кочаклап алды. Сәгыйть нишләргә белмәде. Ул Галиянең сөякләрен сындырыр дәрәҗәдә кысып кочаклады. Тик бернәрсә дә әйтә алмады. Галия:

– Беләсең син, үпкәләмә, үпкәләмә, акыллым... Мин сине шулай ук яратам, – диде.

Сәгыйть шатланып аңарга күзен күтәрде, тик Галия:

– Мин бары хәзер сиңа иргә генә чыга алмыйм, чөнки мин быел көз укырга китәм. Абый мине авылга килеп алып китәчәк, – диде.

Сәгыйть үзен кинәт әллә кая түбәнгә төшеп киткәндәй хис итте. Ул, ашыгып:

– Ә аннан?

– Аннан, укып бетергәч, бергә булырбыз! – диде Галия.

Ләкин Сәгыйтьне бу юлы Галиянең җылы кочагы да, йөрәгеннән чыккан сүзләре дә юата алмады. Ул Галияне бөтенләйгә югалтуын аңлады. Газизнең Хәдичәсе дә шулай укудан кайткач бергә булырбыз дип китеп, авылга кайта алмавын исенә төшерде. Галия яңадан бик еракта кебек тоелды.

Кояш иңгәнче Галия анның үпкә җырларын гына ерактан ишетеп торды.

Күкрәгемә ут кабыздың,
Әрәмәдә үпкәчтән,
Вәгъдә белән алдалыйсың,
Галия җаным, алтын алмам,
Кайтмассың бер киткәчтән.

## СОҢГЫ ЕЛМАЮ

Галия авылга кайтып ике ай да эшләргә өлгермәде, тирә-яктан анның өстенә төрле сүзләр ява башлады. Әллә кемнәр анның шәһәрдә егетләр белән «өстерәлеп» йөреп бала төшерткән, имеш, рус егете белән торып, әллә ниләр булып беткән, имеш, кебек авыл өстенә төрле хәбәрләр таратып өлгерделәр. Галиянең карт анасы кызының алай булуына ышанмаса да, авыл халкының кызы турында шундый сүзләр сөйләүләре анның карт йөрәген рәнҗетте. Ул, элек дус-ишләре арасында шул турыда сүз чыкканда кызын яклап маташса да, тора-бара, кызы турында сүз кузгатмасыннар өчен, якын дусларыннан да очраганда тизрәк-тизрәк аерылырга тырыша башлады. Соңыннан бөтенләй беркем белән дә аралашмый башлады. Ул һәр очрап анның белән исәнләшкән кешенең күзләреннән ниндидер мыскыллау, көлү сызыклары күрде. Ул, Галиянең дә кем белән дә санашмый үз эшен эшләп, үз сүзен сөйләп йөрүенә гаҗәпләнсә дә, бер яктан, анның шулай булуына шатлана иде. Дошманнарга сер бирми, аларның сүзләренә колак салмый йөрү ул үзе яхшы эш.

Ләкин кыз вакытында анның үзе турында шундый сүзләр ил өстенә таралса, билгеле, ул керфеген күтәреп кеше өстенә карый алмаган булыр иде. Яки бөтенләй үзен-үзе үтерер иде. Ә Галия гүя белми дә, гүя ишетми дә. Бәлки, ул дөрестән дә шәһәрдә шулай булгандыр. Булмаса, яла ягуга ул үзе дә түзмәс иде. Бит ул шул сөйләүчеләрне судка биреп яптыра да алыр иде. Шәһәрдә комиссарлар да аны якларлар иде.

Гөлҗамал абыстай күп вакытта шундый шөбһәләр эчендә кала иде. Ә бүген ул түзмәде, яңа гына волостьтан[1] кайткан Галиягә:

– Кызым, минем чыдарлыгымны калдырмадылар. Синең турыда төрлесе төрле начар хәбәрләр сөйлиләр. Синең андый булуыңа ышанмыйм. Ә шулай да күңелгә авыр. Дошманнар күп, ичмаса, берәрсен судка биреп, бераз авызларын каплар идек, – диде.

Галия, гүя йокысыннан уянган кебек, аңар гаҗәпләнеп карады, соңыннан, бик әһәмиятсез нәрсә турында сөйләгән кебек, әкрен генә җавап бирде:

– Сөйләүчеләрнең авызын тыгып булмый, әни. Алар бары наданлыкларыннан, мине күрә алмауларыннан гына сөйлиләр. Аларны судка биреп тә аларның авызларын каплап булмас, сүз куеруга гына сәбәп булыр, – диде. Соңыннан: – Сөйләрләр дә арырлар әле, – дип өстәп куйды. Ул анасына үзенең саф булуы, андый вак-төяк сүзләр өчен үч алуның кирәксез нәрсә булуын сөйләргә теләсә дә сөйләмәде. Эчендә генә анның йөрәгендә авыр, әрнүле ачыну тойгылары уянды. Ул анның өстенә яла сөйләүчеләрнең, начар хәбәрләр таратучыларның кемлекләрен яхшы белә. Һәм алардан бик каты итеп үч ала алуына да ышана. Аларның берсе – авыл советы председателе Гыймади, икенчесе – әгъза булып йөри торган[2] Кара Хәмит һәм өченчесе – кооперативның приказчигы Габдулла - Хәбибуллиннар.

Галия авылга килеп эшкә башлаганнан алып, алар яшертен генә аңарга баз казый башладылар. Дөрес, элек алар Галия белән яхшы булырга тырыштылар. Хәзер дә әле Галия белән очраганда йомшак тел белән сөйләшәләр. Ләкин эчләрендәге ачуларын яшерә алмыйлар. Галиягә елмайганда, йөзләре елмаюдан бигрәк ырҗаюга охшап китә.

Галия кантоннан[3] үз волостена эшләргә җибәрелгән чакта кантком секретаре:

– Анда совет, кооператив тирәләренә үрмәкүчләр оя корганга охшый. Син уяурак бул. Без анда берничә яхшы гына эшче җибәрсәк тә, алар анда кереп, үзләре баткакка баттылар, – дип сөйләгән иде.

Галия, волостька эшләргә килгәндә үк, ул үрмәкүч оясын күреп, белеп килде. Шуның өчен килгән атналарында ук ул яшерен, кеше күзе төшмәгәнрәк караңгы якларга карарга тырышты.

Ә Гыймадилар, Хәбибуллиннар үзләренең хәйләкәр елмаюлары, йомшак телләре белән күзләрен капларга тырыштылар. Хәтта аны үз алдында крәстияннәргә мактаган булдылар.

– Менә үз авылыбыздан да зур кешеләр чыкты. Фәлән-төгән, – дип, аны күтәреп сөйләргә маташтылар.

Ә Галия, аларның мактауларының кая юнәлгәнен яхшы белеп, аларга усаллык та, дуслык та күргәзмәде. Ул әкрен генә үз эшендә дәвам итте.

Гыймадилар аңарга эшләгән эшләрендә булышлык иткән булып та маташтылар. Әле авылда Галия ячейка[4] төзергә җыенгач, алар беркемнән сорамый җыенда халыкка:

– Җәмәгать, Галия туташ авылда комсомол ячейкасы төзергә йөри. Хәзер инде заманалар үзгәрде. Аңарга булышырга кирәк. Балаларыгызны комсомолга язылудан тыймагыз! – дип, Галия булмаганда агитация дә ясаганнар.

Ячейка оештыру собраниесендә дә Гыймадиның шадра малае белән приказчик Хәбибуллинның улы беренче булып комсомолга керү өчен гариза бирделәр.

Соңга табан приказчик Хәбибуллин Галиянең анасы Гөлҗамал абыстайга кооперативтан акчасы булмаганда акчасыз нәрсә җибәрергә мөмкин булуы турында да әйтте.

Галия, билгеле, аларның бу тәкъдимнәренә карышмады. Дуслык та күргәзмәде. Ул, һаман эшнең төбенәрәк төшәргә тырышып, тикшерүендә дәвам итте.

Галиянең яшерен якларга күз төшерергә тырышуы Гыймади белән Хәбибуллинда курку катыш ачу кабартты. Алар артларын мөмкин кадәр арурак тотарга тырыштылар. Кооператив кенәгәләрен тагын бер кат тикшереп чыктылар. Сизелерлек нәрсә тапмагач, тынычландылар. Галия турында яшерен генә тагын төрле кабахәт хәбәрләр таратырга тотындылар:

– Галия волостьта эшләүче бер урыс белән тора икән, кай төннәрне аның янында кунып та кайта икән, – дигән хәбәрне колактан колакка тараттылар.

---

Тик көннәрнең берендә председательгә йомыш белән килгән солдат хатыны Нурҗиһанның күршесе сөйләгән сүзләр генә Гыймадиның чәчләрен үрә торгызды. Нурҗиһанга ул председатель булганнан бирле күз төшереп йөри иде. Ә бервакытны түли алмаслык налог салып:

– Түлисең килмәсә, миңа йомшаграк күңелле бул, – дип, аны үзенең теләген үтәргә мәҗбүр иткән иде.

Ә Нурҗиһан менә бу вакыйганы эчендә саклый алмый Галиягә сөйләгән, Галия аны ни өчендер язып алган.

Гыймади, бу хәбәрне ишетү белән, тешләрен кысып, эчтән генә сүгенде.

– Телен тота алмаган икән, ярый. Гыймадины танырсың әле, – дип янап куйды. Ә үзе ул төнне, Галиянең аның эшләгән эшләрен төпләп тикшереп йөрүенең соңы ни буласын аңлап, кроватында ишелеп-ишелеп йоклый алмый ятты.

Шуның өстенә көтелмәгәндә кантоннан килеп төшкән инструктор аны тагын да какшатты. Инструкторның авылга төшүе белән председательне эзләп килмәве үк, аның торырга да Галияләрнең күршеләренә төшүе Гыймадиларны, Хәбибуллиннарны куркуга төшерде.

Аптыраган үрдәк арты белән суга чума дигәндәй, Гыймадилар нишләргә белмәделәр. Инструкторның һәр биргән соравына бутала-бутала җавап бирделәр. Ә Галия тыныч кына аларның йөзләренә карап торды.

---

Галия бер үзгәреш тә юк кебек элеккедәй тыныч, аның йөзеннән, бик җентекләп карамасаң, ачу эзләрен дә күрерлек түгел. Тик ниндидер авыр салкынлык шәүләсе генә бүген аның йөзендә артык өскә чыккан кебек сизелә.

Ул, инструктор, Хәбибуллин, тагын берничә крәстияннәр белән бергә бер бүлмәдә кооператив кенәгәләрен тикшереп яталар.

Галия, кәгазьләргә карап утырган чагында, үзенә дүрт-биш боз кебек салкын күзләр тегәлүне сизеп тора. Кенәгәнең кай җирләрендә алар тукталалар да инструктор белән күзгә-күз карашып алалар. Галия үзенең дәфтәренә ниндидер билгеләр куеп бара.

Ә председатель белән Хәбибуллиның, Галия һәр билге ясаган саен, йөзләренә салкын тир чыга бара...

Алар кичкә кадәр ара-тирә сораулар, билгеләр ясау белән кузгалмый эшләп утырдылар. Кичен инструктор шәһәргә китте...

Инструктор киткәннән соң, председатель белән Хәбибуллинның башларын түбән салып йөрүләреннән крәстияннәр аларның эшләренең чуалганлыгын аңладылар.

Кайбер мактанчыграк крәстияннәр: «Мин күптән аларның эшләрен сизеп йөрим. Әле беркөнне дә бу малайлар безнең җилкәне ашап йөриләр», – дип, гомердә беркемгә дә сөйләмәгән булса да, сөйләдем дип, йөрделәр.

Ә Гыймади белән Хәбибуллин, йөзләренә кара сөрем суккан кебек, крәстияннәргә очраудан качтылар. Көзге көндә аларның нәрсәдер киңәшеп, председательдә эчеп утыруларын да күрүчеләр булган...

---

Көзге салкын җилләр, яңгыр тамчыларыннан буран уйнатып, үләннәрне саргайткан чирәмнәр өстеннән урманга табан исәләр. Кибән башларыннан озын саламнар буенча авыр, салмак кына тамган тамчылар, көзнең күңелсез җырын җырлагандай:

– Тып-тып, – итеп симез җиргә тамалар.

Уҗымда йөргән атлар яңгырга артлары белән торып ашыгып-ашыгып ашарга тырышалар.

Галия, волбашкарма йортыннан чыгып, волостьтан бер генә чакрым ераклыкта торган авылына табан атлады. Ячейканың секретаре Василий аны озатып килергә теләсә дә, Галия риза булмады:

– Берәрсе күрсә, әллә нәрсәләр сөйләрләр тагын, – диде дә, кулын биреп, җылы гына итеп Василийга елмайды.

Аерылгач, Василий нәрсәдер сизенгән кебек, озак кына аның артыннан карап калды.

Галия ул башта бернәрсә дә уйламады. Соңга табан йөзен пальтосының якасы белән каплады да, пычракка баса-баса, алга атлады. Пальтосы аркылы үткән вак яңгыр тамчылары аның тәнен рәхәтләндереп чиркандыралар иде. Ул:

– Барыбер аякларны батырмый кайтып булмас, ахры, – дип, җиргә карамый гына атлый башлады. Аның башыннан берәм-берәм шәһәр күренешләре, анда укулары, андагы иптәшләре, Газизәләр, Хәмитләр үттеләр... Ул аларга күптән инде хат язганы юк. Кайту белән берәрсенә хат язып ташларга кирәк булыр дип уйлады. Соңыннан аның башына бүген собраниедә сөйләнгән сүзләр, Василийның Галиянең докладды буенча кызу-кызу сөйләү күренешләре үттеләр.

Вак яңгырлар аның пальтосы аркылы үткәннән-үтә баралар.

Кырда урылмый калган яшь әрем сабаклары җил белән әкрен генә иеләләр.

Галия ике авыл уртасындагы зиратларга якынлый.

Зиратлар эчендәге сирәк-мирәк агачлар шомлы тавыш белән уылдыйлар.

Зиратлар алар һәрвакыт кешегә ниндидер кайгылы, авыр тойгылар бирәләр. Галия гомумән зиратлар тирәсеннән үтәргә яратмый. Ул үлекләр турында аз уйлый. Ә алар турында уйласа, уйлаган саен аның яшисе, эшлисе килә. Бу юлы да зиратлар аңарда шундый хисләр уятты. Кинәт аның моннан ун еллар элек булган хисләре тәкрарландылар. Күз алдына яшь чагында шул зиратлар яныннан үткәндә «Әлхәм» сүрәсе[5] укып үтүләре килеп басты. Авылда аның танышы булып та, хәзер үлек булып яткан кайберәүләрнең төсләрен күз алдына китерергә тырышты. Озак уйлагач, ул, кара уйларыннан котылырга теләп, кинәт уйларын тормышның якты якларына борырга керешә. Күз алдына Хәмитләр, Зәйнәпләр килеп басты. Ул үзе дә белми елмайды.

Соңыннан...

– Чү!..

Ниндидер өч күләгә каберлек тирәсенә казылган канаудан күтәрелделәр дә Галиягә табан атладылар. Галия сискәнеп китте. Йөрәк тибүе тоталмаслык дәрәҗәдә кызуланды. Кычкырырга теләсә дә, нигәдер кычкыра алмады. Чабып китәргә теләсә дә, аяклары тыңламадылар. Ул үзенең нишләргә тиешлеген дә уйлап өлгермәде, өч күләгә аны тыгызлап урап алды. Соңыннан... ул үзенең былчыракка егылганын сизде. Ниндидер авыр бер нәрсә албасты кебек аны басты... Үлем ачысы белән чыккан йөрәк тавышын авызын каплаган чүпрәк тышка чыгармады.

Көзге таң авыр яңгырлар белән килә. Җиргә тиеп йөргән соры болытлар туктаусыз еракларга, бик еракларга агылалар. Алар таңны да, кояшны да көн буена кешеләрнең күзләренә күрсәтми каплап, вак тамчылар белән тамчылыйлар.

Көзге җил морҗалардан чыккан төтеннәргә югары күтәрелергә ирек бирми, җиргә табан сибә. Авыр, юеш яңгырлы килгән таң карт сөякләрне сызлата.

Гөлҗамал апа авыр, сызланулы йокысыннан уянган чакта, аның сөекле кызы Галия әле волостьтан кайтмаган иде. Ул, шомланып, төннең кайчак икәнен белер өчен, килеп тәрәзәгә капланды. Ул, әллә кызым миңа сиздерми генә кереп мич башына менеп яттымы икән дип, килеп, мич башына сузылып карады. Ләкин Галия анда юк иде. Галия зиратлар янында, зур кара күзләрен ярым ачык калдырып, җиргә тиеп үткән соры болытларга карап, таң атканны көтә иде. Аның кара чәчләрен соры болытлар чылатканнар. Авызына тыгылган пычрак чүпрәк аңарга елмаерга уңайсызлый төсле. Ул чүпрәк гүя аңар «Киләчәк барыбер андый совет дошманнарыннан үч алыр!» дигән сүзен әйтергә уңайсызлый төсле иде.

**СЕЗ ИКЕГЕЗ ДӘ ГАЕПЛЕ...**

Әле яңа гына башланган кар бураны. Кар очкыннары шимал ягыннан искән җилләр белән урыннан урынга күчә, дулый, котыра башлады. Буран буласын уйламый гына юлга чыккан Габдулла белән Хөсни карт, буран арасыннан күренеп торган авылны югалтмаска теләп, атларын тизрәк куарга, ашыгырга тотындылар.

Хөсни карт башын сузып алгы юлны карады да, алар авылга барып җиткәнче буранның юлны күмеп өлгермәвенә ышанып, тынычланган кебек булды. Буран башлангандагы куркуы әкрен генә басыла төште. Ул, үзенең тынычлануын белдерергә теләп, Габдуллага сүз юктан сүз итеп:

– Энем, ерак калмый инде. Бераз салкын салкынын да, түз инде... Солдат киеме җылы булмый ул, – диде.

Бераздан алда күренеп торган якын гына авыл да буран эчендә югалды. Габдулла башындагы шлемын төзәтә төште дә, җылы толып кигән Хөсни картка ышыклана төшеп, күзләрен йомды.

Аның күз алдыннан берәм-берәм төрле күренешләр үтә башлады. Иң элек аның башына тәртипсез рәвештә казарма тормышы, андагы иптәшләре, соңыннан үзенең отпускага китәр алдыннан взводный командиры белән сөйләшүе, юлга чыгу вакытлары чагылып үттеләр.

Искән ачы җил белән аркалары туңуга карамый, Габдулланың уйлары алга йөгерделәр... Менә ул үзенең авылына кайта. Аны анда Зәйнәбе көтми дә. Аның кайтуы турында, билгеле, уйламый да... Алар Зәйнәп белән, Кызыл Армиягә китәргә биш ай калганда гына, яратышып өйләнешкәннәр иде. Зәйнәп Габдуллага язган соңгы хатларында нигәдер артык өмитсез сүзләр язды. Аны нигәдер елап-елап кайтырга димләде. Сагынгандыр, бәлки. Габдулла да аны бик сагынды... Тик... казармада торганда, үткәннәреннән булган кайбер вакыйгалар гына аны тынычсызладылар. Ул алар турында уйламаска, уйламаска теләде. Уйларын яктырак якка, Зәйнәбенең аны ничек сагынып көтүенә табан юнәлтте. Әйе, ул аны көтә торгандыр. Кышкы озын төннәрдә Габдулланың казармадан җибәргән рәсеменә карый торгандыр да көтә торгандыр...

Кинәт җил туктаган кебек булды. Буран да басылган кебек сизелде. Габдулла күзен ачты. Аның күзенә таныш йортлар күренде. Ул төзәтенеп утырды да Хөсни картка, мөмкин кадәр йомшаграк итеп:

– Йә, Хөсни абый, килеп тә җиткәнбез икән, – диде. Соңыннан, аның күңелен күтәрергә теләп: – Малкай буранны сиздермәде дә, канаткай, – диде.

Хөсни картка үзенең атын мактау җитә калды:

– Хайван яшь. Шулай да буранга, җилгә бирешми, – диде. Үзе Габдуллага карап елмайды: – Ә Зәйнәбең көтми дә торгандыр, – диде.

Габдулла:

– Шулай көтмәгәндә кайту яхшырак ул, – диде.

Ат килеп Габдуллаларның йортларына туктады. Габдулла ашыгып кына Хөсни картка рәхмәт укыды.

– Хөсни абый, син кичкә чәйгә кил, бераз сөйләшеп утырырбыз, – диде.

Хөсни карт та үзенең киләсен әйтте:

– Салкыннан, энем, сөйләшеп килә алмадык. Бераз шәһәр хәлләрен сөйләшү өчен килермен, – диде.

Алар аерылыштылар. Габдулла кечкенә генә кәрзинен күтәрде дә ашыгып кына йортка атлады...

---

Зәйнәп малларын ашыгып-ашыгып эчерде дә, сарыкларга солы саламы алыр өчен кечкенә чанасын ияртеп, ындырга китте. Ул юл буена күзен күккә күтәрми уйлап барды: «Нишләрмен?.. Кайткач ни дип әйтермен?.. Ни дип әйтермен үзенә?»

Аның уйлары караңгылана барды. Сүзләренә җавап эзләргә комачауламаска теләгән кебек, аяклары әкрен атладылар.

Ул, ындырга җиткәч, чанасына төяр өчен бөгелеп салам алды да бөгелгән җиреннән тормады. Саламны кочаклаган килеш капланып елый башлады.

Ләкин күз яшьләре аның кайгыларын киметмәделәр. Киресенчә, үксегән саен, уйлары караңгылана барды. «Әле кем дә белми... Шул килеш югалырга, юк булырга кирәк» дип уйлады. Ул үзен үле килеш күз алдына китерергә тырышты. Салкын боз астында чәчләре тузылып яткан үле гәүдәсен күз алдына китерү белән, чәчләре үрә торды. Тыннары кысылды. Нишләргә белмәде.

Ындырдан кайтканда инде ул үзен югалтырга, Габдулла гаскәрдән кайтканчы югалтырга карар биреп куйды. «Ә Габдулла әле бер елсыз кайтмас» дип уйлады. Аның ындырдан кайтканын саклап карап торган сарыкларның, куйларның, аны күрү белән:

«Бәәә...»

«Мууу...»

дип кычкыра башлаулары гына аны ул уйларыннан аерды. Алар, ишегалдына керү белән, Зәйнәпне урап алдылар да, селкенергә дә ирек бирми, тирә-яктан аның чанасына ябыштылар. Ул, элек алар белән талашып маташса да, соңыннан җиңелде. Чанасы тирәсенә генә саламны алып сипкәләде дә, ишегалдында бераз әйләнгәләп, өйгә табан атлады.

Ләкин күз яшьләренең йөзеннән әле кибеп бетмәве искә төшү белән, ул, каенанасы Хөбби әбигә яшьләрен күрсәтмәскә теләп, бераз чоланда утырырга булды. Тик ул кара уйларын туктата алмады. Ә аның кайгылы уйлары тагын да яшьләрен күзләренә китереп тērәделәр.

Бүлмәдә түземсезлек белән Зәйнәпне көткән Габдулла, ишегалдында аяк тавышларын ишетү белән, тиз генә Зәйнәпне күрергә ашкынып ишекне ачты. Ул, ачык калган ишектән Зәйнәпнең үксеп елавын күреп, аңарга таба атлады. Зәйнәп, аяк тавышларына башын күтәрү белән, кинәт күзләрен зур итеп ачты да үзен-үзе белми кычкырып җибәрде. Аны ашыгып килеп кочаклап алган Габдулланың күзләренә карый алмады. Күкрәгенә капланып бик озак үкседе. Габдулланың өзеп-өзеп биргән сорауларына ул бары күз яшьләре белән генә җавап бирә алды...

---

Кичен Хөсни агай, башка күрше-ярылар килеп, озак кына чәй эчеп утырдылар. Сүз күп булды. Габдулланы алар танымаслык үзгәргән итеп таптылар. Ул аларга газеталар укып күрсәтте, сораган сорауларына ачык итеп җаваплар кайтарып торды. Хөсни агайлар, урамга чыккач, үзара:

– Габдулла бөтенләй танымаслык булган. Вәт Крәсни Әрми нишләтә! Белеклеге белән Казаннан укып кайткан хәзрәтнең улыннан да ким булмаган, – диештеләр.

Зәйнәп бөтен чәй буена яшерен генә Габдулланы күзәтеп барды. Ул танымаслык яхшырган, киемнәре шулай килешеп торалар. Шундый матурайган ул. Ә Зәйнәп? Зәйнәп нишләгән? Нишләдең син, Зәйнәп?..

Кунаклар таралды. Менә Зәйнәпнең иң курыккан минутлары, Габдулла белән ялгыз калу минутлары җитте. Ул бу минутлар килүдән үлемнән курыккан кебек куркып торды, ул, минутлар якынайган саен, хәлсезләнә барды. Ул, бөтен көче белән үзен югалтмаска теләп, урыннарын җәйде. Урын-җирләрен җәйгәндә, күзенә карарга тырышкан Габдуллага туры караудан качарга, күзләрен аның күзләре белән очраштырмаска тырышты. Менә Габдулла аның кулларыннан алып үзенә тартты.

– Зәйнәп, нигә син күңелсез?.. – диде.

Зәйнәп яшен суккан кебек калтырап китте. Бер минут тик тору вакыт эчендә аның башыннан бик күп сораулар үтте: «Нишләргә? Әллә барысын да туры әйтергәме... Әллә бүген яшереп, иртәгә үземне үзем бәкегә ташларгамы?.. Юк, әйтергә... әйтергә дә, аннан соң ул теләсә нишләсен, үтерсен, кыйнасын, ялан аяк урамга чыгарып ташласын. Барыбер үләргә... Барыбер белдерми калдырып булмый...» Ул, башын күтәреп, Габдулланың күзләренә карады. Күз яшьләре ачык күзләреннән битләре буенча тәгәрәделәр.

– Габдулла, мин... мин... Син ку мине... Үтер мине, – диде.

Габдулланың башыннан яшен яктылыгы – йөрәген уртага ярып бер уй китте... Ул аңлады. Иреннәре калтырады аның... Кулына ятып үксегән Зәйнәпне читкә этте. Соңыннан Зәйнәпне кыйныйсы, үтерәсе урынына аның үзенең күзләренә яшьләр килде.

– Кем белән? – диде.

Зәйнәп бу юлы нигәдер ашыкты. Ул йөрәген җәһәннәмгә әйләндергән бөтен авыр серләрен күңеленнән тизрәк чыгарып ташларга ашкынды. Тиз сөйләде. Ул авылның хәзерге председателе Исмәгыйльнең ул киткәч аңа бәйләнеп йөрүен, соңыннан көтмәгәндә кырда очрашуларын һәм аңарга бирелүен, соңыннан тагын бер кат очрашуларын... Аннан соң аңардан балага калуын... Ниндидер ят, авыртулы бер тавыш белән сөйләде дә ава-түнә ишеккә таба атлады. Аның йөзләренә үлем аклыгы, авыртулы, авыру караңгылык сызыклары чыккан иде. Ул, гүя кабердән чыгып, ире янына күрешергә генә килгән дә, әйтер сүзләрен әйткәч, тагын кире үзенең каберенә китәргә җыенган кеше кебек, хәлсез ишеккә атлап бара. Аның өчен хәзер барыбер. Ул вакытлы гаебе белән үзенең өзелеп яраткан ирен югалткан да, аны табуына, аны кире үзенә кайтаруына һичбер юл тапмый, нишләрен, кая баруын белми, ул бары китәргә генә тели иде.

Зәйнәп башыннан үткәннәрен сөйләгәндә, көнләвеннән үзенең кулын чәйнәп нишләргә белмәгән Габдулла аны шул ук минутта буып үтерергә, юк итәргә теләде. Соңыннан үзенең шәһәрдә вакытта Зәйнәпне бер урам кызына алмаштыруын хәтеренә китереп, үзен дә, Зәйнәпне дә юк итәсе килде. Тик Зәйнәп ишеккә табан атлагач кына, Зәйнәпнең үзенең эше өчен никадәр газаплануын, аны җибәрсәң, бу китүдән кире кайтмавын аңлап, урыныннан кузгалды, аның башында яшен тизлеге белән авыртулы кызгану уйлары үтте. Ул, ашыгып торып, Зәйнәпне килеп тотып алды. Зәйнәп, башын артка ташлап, гүя Габдулланың сугуын көткән кебек, күзләрен йомды да хәлсез килеш җиргә ауды...

Габдулла Зәйнәпнең авыр ыңгырашулары эчендә төнне йокысызлык, төрле газап эчендә уздырды. Яктыру белән, ул урыныннан торды да Зәйнәпне уятмый гына киенеп ишегалдына чыкты.

Төн буе ачыккан хайваннар аны мөңгерәп каршы алдылар. Ул аның каршына башын сузып килгән сыерның мөгез астын кашыды. Каршына туктап гаҗәпләнеп карап торган сарыклар арасыннан сөйкемле чуар тананың килеп җилкәсен кашыды. Соңыннан авыр, салмак адымнар белән ындырга китте.

Көн тымызык. Кичә яуган карлар әле катып өлгермәгәннәр.

Ындыр-болында кайбер урында чана, аяк эзләре күмелми калган. Габдулла аяк эзләренә карап Зәйнәпне исенә төшерде. Зәйнәп белән беренче кушылган минутлары күз алдына килде. Соңыннан Зәйнәп сөйләве буенча кырда авылның хәзерге председателе Исмәгыйль белән Зәйнәпнең очрашулары, Исмәгыйльнең Зәйнәпне кочаклап үбүләрен күз алдына китерергә тырышты, аның йөрәге ут кебек янды. Башына кан йөгерде. Түзалмады. Ындыр-болындагы талга сөялеп, күзләрен йомды. Тешләре бер-берсенә тиеп шыгырдады. Кычкырасы, үзен-үзе белми тилереп кычкырасы килде. Ул, үзенең сулышлары кысылуны сизү белән, уйламаска, ул турыда бернәрсә дә уйламаска теләп күзләрен ачты. Ләкин уйлар һаман аны ташламадылар. Бит ул да, Исмәгыйль нәкъ Зәйнәпне кочаклаган кебек, шәһәрдә бер хатынны кочаклаган иде. Аның белән кунган иде... Соң шулай булгач?

Ул юанган кебек тә булды. Зәйнәптән үчен алган кебек тә булды. Ләкин Исмәгыйль белән Зәйнәпнең үбешү күренеше аны һаман ташламады. Ташламады.

Кызык, ул шәһәрдәге кыз белән кунуы өчен һичбер газапланмый, ә Зәйнәпнең Исмәгыйль белән якын мөнәсәбәттә булуы аның шулкадәр ачуын китерә... Соң бит мин кундым... Шуның белән бетте дә. Ә Зәйнәп? Оят... оят... Ул Исмәгыйльдән, кабахәт бер эчкечедән балага калган. Ничек кеше күзенә күренермен... Әле, җитмәсә, ул әллә кемнәргә Габдулланың хатыны белән якынлыкта булуы белән мактангандыр...

Габдулла кинәт борылды да ашыгыч адымнар белән кире өйгә атлады. Ул ни өчен ашыгуын үзе дә белми, тик башында коточкыч ике фикер талашуын гына сизә ул. Кан белән капланган ике күренеш аның алдында гәүдәләнә. Менә шул. Менә шул күренешләрнең берсе – кайсысы булса да бу авыр уйларны җиңәргә тиеш дип уйлады.

Ул, ишегалдына керү белән, юлына очраган сарыкларны таптый-таптый нидер эзләргә тотынды. Соңыннан чөйгә эленеп куйган җепне алды да, баскыч алып, ашыгып, ат абзарының түбәсенә үрмәли башлады.

---

Зәйнәп саташулы йокысыннан бөтенләй җимерелеп уянды. Ул уйларын башына тиз генә җыеп өлгерә алмады. Тик бераздан гына кичә нәрсәләр булуын, бүген аны нинди коточкыч күренешләр көтүен исенә китерә алды. Тик иң авыры, иң зурысы үткән иде аның... Хәзер инде барыбер, ни булса да барыбер.

Ул, урында берьялгызы гына калуын белгәч, әкрен генә урыныннан күтәрелде.

– Ә Габдулла кая?.. Әллә бу саташу гына, әллә ул бөтенләй кайтмады дамы?..

Өстәл янында хәзергә кадәр өйдә булмаган кечкенә кәрзин генә аны тагы аңына китерде.

– Ул кайткан... Кичә булган нәрсәләр берсе дә төш түгел.

Ул, урыныннан торып, күрше бүлмәгә чыкты. Габдулланың анасы, кичәге хәлләрнең бөтенесен ишетеп торганга, йоклый алмый чыккан иде. Ул, Зәйнәп керү белән, аңар арты белән әйләнде. Зәйнәп, Габдулланың аның янында булмавын күреп, кире үз бүлмәләренә керде. Аның бик, бик тиз Габдулланы күрәсе, аның белән сөйләшәсе, кыйнаса – кыйналасы килде. Тик тизрәк булсын гына иде.

Көтеп-көтеп тә Габдулла кермәгәч, Зәйнәп нидер сизенгән кебек булды...

«Әллә кире киттеме?» дип уйлады. Нәрсәдер аны буа башлады. Ул аягына ашыгып-ашыгып кына киде дә, шәлен ябынып, ашыгып ишегалдына чыкты. Яңа кар өстендәге эзләр буенча ул, ындыр капкасын ачып, Габдулланың эзе буенча ындырга йөгерде. Ләкин эзнең ындырга җитми кире йортка кайтуын күргәч, ул тиз генә кире йөгерде. Алгы капкага чапты. Анда чыгып киткән эзләрне күрмәгәч, кинәт бөтен тәне калтырап китте. Тилергән кеше кебек йорт эченнән Габдулланы эзләргә тотынды. Ни өчен? Ул аны үзе дә белмәде. Тик эзләгән саен, аны тизрәк табасы, тизрәк, тизрәк табасы килде.

Ат абзары янына килү белән, ул терәлеп куелган баскычка, соңыннан бик тиз югары карады. Кемдер күзенә чагылды. Кемнеңдер боз кебек күзләре аның йөрәгенә туры карадылар.

Ул баскычка да тотынып өлгерә алмады...

Аяклары көчсезләнделәр, сынын тота алмый, җиргә бөгелделәр... Ачуыннан, оятыннан үз-үзен җепкә асарга уйлаган Габдулланың куллары катып калды. Аның, күз ачып йомганчы, башыннан мең төрле уйлар үтте:

«...Ул гаеплеме?.. Әйе, әйе, ул гаепле! Ул кабахәт, ул минем йөземне җиргә сукты... Ул... ул гаепле... Ә соң мин... мин үзем? Соң бит, соң бит мин ир... Мин ир... Ә ул, ул?..» Ул, үзен аклап, Зәйнәпне генә гаепләргә теләде... Аның ачуы кабарганнан-кабарды. Ул үзен үтерүдән элек аны, Зәйнәпне юк итәсе килде. Тик Зәйнәпнең кинәт җиргә егылуы аның йөрәген нининдидер баш әйләндергеч томан белән тутырды. Ул томан әкрен генә күз алдын

томалый башлады. Ул томан, йомшак күз яшьләренә әйләнеп, күзләрен тутырдылар. Габдулла, кулындагы җебен җиргә ташлады да әкрен генә баскычтан түбәнгә атлады.

Күлмәкчән генә салкын карда исен югалтып яткан Зәйнәпне ул тиз генә күтәреп кулына алды. Аның ак киндергә әйләнгән йөзенә карады.

Кайчандыр беренче өйләнгән көннәрендәге Зәйнәп күз алдына килде.

Ул бервакытны таң вакытында уянган иде... Ә Зәйнәп тыныч кына, иркәләнеп кенә йоклап ятадыр иде. Ул вакытта аның күзләре шулай итеп йомылган, озын керфекләре менә шулай итеп йөзен каплаган иде... Нинди якын иде ул... Габдулла яшьләрен тыя алмады...

---

Габдулланың башыннан бик күп төрле уйлар, күз алдыннан төрле кешеләрнең хатыннары турында ишеткән төрле вакыйгалар үтеп китте. Ул... Тукта! Ул бервакытны шәһәрдә вакытта иптәшләре белән кинокартина карарга барган иде... Анда да нәкъ Габдулла кебек бер эшченең хатыны ире командировкада булган вакытта икенче бер ирдән балага калуын, соңыннан ул баланы үз баласы итеп белеп, асрарга хәзерләнүен... хатынының яшерә алмый баланың икенче ирдән булуын әйтүен... соңыннан вакыйганың кызганычлы рәвештә бетүен күрсәткән картинаны исенә төшерде. Күзләре йомылды. Ачу белән тешләре бер-берсенә каты итеп кысылдылар. Авылда кемнәрдер аның хатынының аны алдавы турында яшерен генә сөйләп көләләр кебек тоелды.

Бөтен авыл аның мәсхәрә булуын белә торгандыр. Габдулланың авылга кайтуын ишеткән һәркем:

– Ә хатыны монда типтерде... – дия торгандыр кебек булды.

Аның башына тагын кан йөгерде...

Габдулла авылдан гаскәргә киткән чакта да яхшы ук аңлы комсомол иде. Аз гына укый-яза белүе өстенә гаскәрдә аңа тагы күп кенә укырга, төрле темаларда лекцияләр тыңларга, китаплар укырга туры килгән иде.

Шуның өчен ул үзен авыл егетләре кебек тотарга, алар кебек Зәйнәпне үтергәнче кыйнарга, «гакыл бирергә» кыя алмады.

Юк, ул томанлы гына булса да үзенең ул нәрсәне эшләргә хакы юклыгын, үзендә дә шуңар каршы Зәйнәпкә гаебе булуын сизә иде. Тик күңелендә тәрбиясеннән килгән иске калдык, «ир хакы» дигән әйбер һаман әйләнә, һаман аның йөрәген кискәли иде.

Ул ике каршылык уртасын таба алмый, үзен бу «хурлыклы» вакыйга белән килештерә алмый озак газапланды. Соңыннан үзенең якын күргән, гаскәрдә вакытта һәрвакыт аңар акыллы киңәшләр биргән үзенең сөекле командирына бөтен нәрсәне ачык итеп язарга, аңардан абыйларча киңәш сорарга булды. Һәм, өч-дүрт мәртәбә су өстәлеп сыекланып беткән зәңгәр караны алып, чырага бәйләнгән каләм белән хат язарга тотынды.

Зәйнәп аңына килсә дә, Габдулланың өстәл өстендә нидер эшләп утыруын сизгәч, күзен ачарга кыймады. Тик бугазына килеп терәлгән ютәлен генә тыя алмый, буылып ютәлли башлады. Габдулла әкрен генә аның янына килде.

Нәрсә әйтергә?.. Ул белмәде. Аның Зәйнәпкә сагынып килүен, шуның белән бергә авыртулы рәнҗү катыш булган үпкәсен әйтәсе килде. Ләкин ул үзен тотып калды. Аның күңеле яхшы ук йомшарган булса да, ул әле җылы сүз әйтер дәрәҗәгә килмәгән иде. Бу уйлар да кинәт көтелмәгәндә генә килделәр дә, аларның урынын тагын боз кебек салкын усал уйлар алдылар.

Зәйнәп яшь тулы күзләрен әкрен генә ачты да диварга карады. Аның күзләре чиксез арыганлык, тирән өмитсезлек караңгылыгы белән кабынган иде.

Габдулла, стаканга су салып, аның авызына китерде. Зәйнәп эчмәде. Эчә алмады. Күзләренә тыгылып торган яшьләре йөзе буйлап түбәнгә тәгәрәделәр. Ул аларны сөртергә теләмәде. Аларның йөзен кытыклап агулары аңар бертөрле рәхәтлек биргән кебек булды. Ул күз яшьләре аның йөрәгеннән ниндидер авыр уйларны үзләре белән агызган кебек тоелдылар.

Габдулла күрше бүлмәгә бөтен вакыйганы белеп, сизеп торган анасы янына керде:

– Әни, Зәйнәп авырый, син караштыргала, мин ячәйкәгә барып киләм, – диде һәм чыгып китте.

---

Ячейкадагы иптәшләре аны шау килеп каршы алдылар. Сораштырып, Габдулланың бөтенләйгә кайтуын белгәч, шатландылар. Авылның хәзерге председателе Исмәгыйльнең эчеп, тузып йөрүе, төрле начарлыкларны эшләве турында сөйләгәч:

– Председательлеккә сине үткәрәбез, – диештеләр.

Бу нәрсә Габдулланың башына яшен суккан кебек тәэсир итте. Хатыны белән якынлыкта булган Исмәгыйльнең җыерчыклы йөзе күз алдына килде. Ул гүя: «Миннән хатыныңның үчен алыр өчен председатель булырга йөрисең», – дип, мәсхәрәле елмаю белән елмайган кебек булды.

Габдулланың йөрәге кысылды. Ул иптәшләренә, көчкә-көчкә: «Мин, иптәшләр, күп эшләр белән таныш түгел. Сез авылдан аерылмый торган берәр иптәшне үткәрергә карагыз инде», – диде.

Ләкин иптәшләре аның сүзен кырт кисеп куйдылар. Габдулла шулай да карышты. Ләкин комсомоллар аның карышуына әһәмият бирмәделәр.

Сүз председатель турында тукталгач, төрлесе төрле нәрсә турында сөйләп киттеләр. Габдулла бөтен сүз буена иптәшләренең һәрберeннән хатынының «серен» белү-белмәүләрен тикшереп утырды. Тик аларның берсе дә бу хакта бертөрле дә нәрсә күргәзмәделәр.

Габдулла әз генә тынычланган кебек булып кайтып китте.

Көннәр үттеләр. Зәйнәп егылган урыныннан тормады. Озын кышкы төннәр тынычсыз ютәл, авыр саташулар белән үтте. Аның күз төпләре күгәрде, йөзләре шиңде. Күзләреннән үлем карый башлады.

Бүген Габдулла доктор алып килде. Зәйнәп доктор караган вакытта күзләрен ачмады. Кипкән иреннәре доктор биргән сорауларга каршы тибрәнмәде. Доктор, аның күкрәген тыңлагач, озак кына Габдулланың күзенә карап торды. Соңыннан, башын селкеп:

– Терелә алмас, үпкә шешүе белән авырый, хәле бик начар, – диде.

Габдулланың күз аллары караңгыланды. Ул докторның сөйләгәннәрен рәтләп ишетә алмады, аның башында бер генә, тик бер генә фикер әйләнә иде:

– Ул терелә алмас... Ул үләр, ул үләр...

---

Зәйнәп өстендә йөргән үлем күләгәсе аның бөтен уен чорнап алды.

Ә бәлки, Зәйнәпнең үлеме аның өчен яхшырак та булыр. Шулай шул, шулай шул! Ул вакытта аның йөзенә беркем дә:

– Хатының уйнаштан бала тудырды, – дип әйтә алмас, Зәйнәпнең гаебе аның үзе белән күмелер...

Ул күзләрен Зәйнәпкә терәде. Зәйнәп буылып ютәлли башлады. Кинәт ул бөтен тәне белән селкенеп куйды. Аяклары тартышты. Күзләре зур итеп ачылды. Ул, бөтен көчен җыеп, үлем белән тартыша башлады. Аның маңлаеннан тирләр чыкты. Өстен каплаган юрган идәнгә төште. Габдулла, Зәйнәпнең күлмәгендә кызыл кан күреп, үзен-үзе белми үксеп, Зәйнәпкә ташланды...

---

Көннәр үттеләр. Зәйнәп терелә башлады. Ә ике атнадан Габдулла үзенең командирыннан хат алды.

*«Нәрсә язарга да белмим. Бу бик авыр мәсьәлә. Ләкин син аны комсомолларча хәл итәргә тиешсең. Бит Зәйнәпнең гаебе синең Зәйнәпкә эшләгән гаебеңнән артык түгел. Сез икегез дә гаепле. Бала мәсьәләсе турында нәрсә әйтергә дә белмим...»*

Габдулла хатны Зәйнәпкә күрсәтмәде. Ике арада кара тап булып торган баласын Зәйнәп авырган вакытында ташлаган иде инде...

**«ТАҢ ҖИЛЕ» РОМАНЫНЫҢ ВАРИАНТЛАРЫ**

**Аючылар**

Рөстәм урманнан Габбас агайның атына утырып кайтты. Ул, авылга җитү белән, болынлыкта Габбас агайдан төште дә Шуарләйдә кармак белән балык тотып ятучы малайлар янына туктады. Кинәт аның күз алдыннан яшьлеге, әбиләр әкияте тыңлап үткән, балык тотып үткән яшьлеге җанланды. Ул, ярга утырып, Шуарләй буена таралып утырган Тулпан авылына күзен төшерде. Бүгенгегә бөтенләй охшамаган, матур да, караңгы да, белемсез дә, ниндидер хыялдагы кебек ерак үткәннәр турында карчыклар теле әкият сөйли. Алар сөйләгән нәрсәләренең әкият булмый дөрес булуына үзләре дә ышанмаган төсле уйланып, онытылган, ләкин бик матур төшләрен хәтерләгәндәй итеп, әкрен тавыш белән, озайтып-озайтып сөйлиләр.

Һәм, дөрестән дә, алар сөйләгән Тулпан авылының үткәне бүгенгегә бөтенләй башка төш кебек томанлы, хыял күзе үтә алмаслык зәңгәр томан эчендә башы белемсез матур әкият кебек тоела.

Кайчандыр Тулпан авылын очсыз-кырыйсыз киң урманнар урап алган булган. Алача ыштаннан, кизеле күлмәктән, киң күкрәкле таза Тулпан егетләре урманнарны яндырып, чирәмнәрне ертып иген чәчә, алма кебек матур Тулпан кызлары чыра яктысында төннәр буе киндер тугый, җеп җерли, җырлар җырлый булганнар.

Авылдан авылга тимер чылбырларга аюлар тагып аючылар йөргәннәр. Аючылар килү Тулпан авылы өчен зур бәйрәм, зур вакыйга булган. Карт аючылар авыл картлары белән төннәр буе утырып ил хәбәрләрен сөйләгәннәр. Яшь аючылар Тулпан авылына яңа җырлар алып килгәннәр. Бөтен авыл җыелып аю биеткән, кызлар белән егетләр парлап биегәннәр. Яшь киленнәр елак балалары өстендә аю атлатып уздырганнар. Хәзер әбиләр сөйләгән авылны ураган аюлар тулы шомлы кара урманнар да киселеп беткәннәр. Авылның артыннан уймакланып аккан Шуарләй суының ярларындагы кеше керә алмаслык баткаклыклар да кипкәннәр. Май айларында бөтен Шуарләй буен ап-ак чәчәккә күмгән шомырт агачлары, каенсарлыклар, еламсыр таллар, баланнар киселгәннәр. Әбиләр җырлап җыеп йөргән кура җиләкләре, карлыганнарның эзләре дә калмаган. Еламсыр талларга уралып үскән комалаклар корыган.

Алар бары, карчыкларның томанлы хыялларына үрелеп, Тулпан авылының борынгы җырларында ышанмаслык матур үткәннәр әкияте булып калганнар.

Урманнары киселгәч, кибәргә якынайган Шуарләй суының төпләрендә чери алмый яткан ак каеннар, аючылар йөргән чакларны хәтерләтергә теләгәндәй, балык тотучыларның җәтмәләренә асылып ерталар, кармакларын эләктереп үзләрендә калдыралар...

---

Рөстәм күзләрен Шуарләй суының уң як тау битендәге иске зиратларга терәде. Бу зиратларга инде үлекләрне күммиләр. Бары Шуарләй суы ташыган вакытларда яңа каберлекләргә чыгарга мөмкин булмаганда гына, үлүче булса, иске каберлекләргә илтеп күмәләр.

Ташландык, чирәмнәр үсеп беткән каберлекләр яныннан эшкә үткәндә картлар моңаеп Коръән укып үтәләр.

Ел саен майның унбишендә Тулпан авылында картлар бәйрәме була. Авыл карчыклары, укадан үргән тастарларын тагып, бергәләшеп, шул каберләр янына барып, каберлекләр тирәсеннән, болыннан үләннәр җыеп кайталар. Чәй кайнатып, намазлар укыйлар. Үзләре белән барган бала-чагаларга бүгенгегә бөтенләй башка, ниндидер белемсез үткәннәр турында сөйлиләр. Бармаклары белән төрле урыннарга күрсәтеп, элек шул урыннарда нәрсәләр булуын, нинди вакыйга булып үтүен искә төшерәләр.

Ә алар белән килгән балалар алар сөйләгән сүзләрне әкият итеп кенә тыңлыйлар.

Чөнки алар әбиләре сөйләгән урманнарны да, бүреләрне дә, аюларны да күрмиләр.

Әнә теге тау битендә әбиләр сөйләгән алача ыштаннан, киҗеле күлмәктән, кулларын артка куеп умарталыклары уртасында йөргән Бикмәй бабай да күренми. Бикмәй бабай умарталыгы дип күргәзгән урыннарда әбиләр сөйләгәннең бөтенләй киресе, агачсыз бер болынлык кына җәелеп ята. Ә болында башларына абыйлары, әтиләре шәлдән алып кайткан иске шляпалар кигән авыл малайлары атлар көтеп шаярып яталар. Тулпан урманнарын кисеп тимер юл сызыгы үткәч, аз җирле Тулпан авылы егетләре чит җирләргә, ерак шәһәрләргә таралып беткәннәр.

Тулпан авылы кызлары элек алача ыштаннан булуына карамый тазалыгы, матурлыгы белән дан тоткан егетләрне сайласалар, хәзер алар шәлдә йөргән шәлче, буфетчы егетләрне сайлыйлар. Авылдан читкә чыгып йөрмәгән егетләрне кешегә дә санамыйлар. Тулпанның үткәннәрен искә төшерә торган җырлар да хәзер җырланмый.

Авылга өйләнергә дип кайткан буфетчылар, шәлчеләр үзләре белән туйларына шәлчеләр, буфетчылар җырлый торган җырлар алып кайталар. Зур шау-шулы Тулпан туйларында шәлчеләр белән буфетчылар берсеннән-берсе көлеп, берсен-берсе үртәшеп җырлашалар.

Кара-каршы җырлашулар күп вакытта канга батышып сугышулар белән бетә.

Тик картлар гына кайчакта буза артында яшьләргә бөтенләй чит, әллә нинди ерак та, матур да, белемсез дә, авылның үткәне белән бәйләнгән вакыйгалар, урманнар, аючылар турында җырлыйлар.

Аючылар, баючылар,
Кайтыгыз үз ил генәмә,
Үз илемә, үз җиремә
Карыйм күзем талганчы,
Елыйм яшем беткәнче...
Пырагонда йөгреп җиттем,
Аючыны саурып үптем...
...............
...............

...«Аючылар» көе – Рөстәмнең әбисе белән бабасы турында чыгарылган көй. Кайчандыр Тулпан авылына ел саен аючылар килә булган. Авылга аючылар килү зур бәйрәм булып саналган. Бөтен авыл җыелып аю биеткәннәр. Төрле уеннар уйнаганнар. Яшь киленнәр елак балаларын җиргә куеп, өстендә аюны атлата булганнар.

Ә бер елны аючылар белән Галим исемле яшь бер аючы килгән. Зур матур кара күзләре, яңа гына чыгып килгән кара мыеклары, батыр гәүдәсе белән ул авыл кызларын үзенә караткан. Авылга Тулпан авылы ишетмәгән яңа җырлар, яңа көйләр алып килгән. Авылда матурлыгы белән дан тоткан Хәмдия аю биеткәндә халыкка белдерми генә Галимгә үз кулы белән чиккән яулыгын ыргыткан. Аючы Галим шул ук көнне бөтен халык алдында Хәмдиянең исемен кушып җырлар чыгарган. Ә төн белән алар, беркемгә белдерми, Шуарләй суының өстенә аркылы ауган каен өстенә утырып төн уздырганнар.

Аючылар авылдан китү белән, Хәмдия дә югалган.

Бер елдан ераклардан килүче кырыктартмачы Галимнең ауга барганда аюлар авызына эләгеп үлү хәбәрен, Хәмдиянең Тулпанга кайта алмый сагынып җырлаган җырларын китергән:

Аючылар, баючылар,
Кайтыгыз үз ил генәмә,
Үз илемә, үз җиремә
Карыйм күзем туйганчы,
Елыйм яшем беткәнче...
Үз илемә, үз җиремә
Карыйм күзем туйганчы,
Елыйм яшем беткәнче...
Мөхәммәдҗан абзыкаем,
Утырып син туры атыңа,
Илебездән үтәр булсаң,
Үтәр булсаң,
Китәр булсаң,
Хәбәр иткел братыма...

Хәмдиянең энесе аны эзләргә чыгып киткән булса да, таба алмый кайткән. Тулпан авылында Хәмдиянең җырлары туктаусыз яңгыраган. Еллар үтү белән генә аның җырлары әкрен-әкрен онытылган, җырчылар телендә генә калган.

---

Тик унбиш елдан Тулпан авылына бер карчык белән унбиш яшьләр чамасында яшь кенә бер егет килеп кергән...

**Морат**

Рөстәм Толстойның «Воскресение»сенең[1] соңгы битен укып бетерде дә чирәмгә аркасы белән яткан килеш уйлана башлады. Ул укучыларда була торган ниндидер томанлы ризасызлык тойгылары белән калды. Ул, бу роман Нехлюдов белән Катюшаның бергә кушылулары белән бетәргә тиешле дип, соңгы главасына кадәр теләп килгән иде. Ул көткәнчә бетмәде. Нехлюдов белән Катюша икесе ике якка киттеләр... Рөстәмдә туган ризасызлык тойгылары романны үзләре теләгәнчә бетерергә теләделәр. Рөстәм Нехлюдов белән Катюшаны бер өйләнгән килеш күз алдына китерергә маташты. Ләкин роман буена сузылып килгән каршылыклар эчендә үскән ике йөрәк тибүен бергә кушарга ул бер генә бәхетле юл да тапмады. Романның каһарманнары аның йөрәгендә Толстой биргәнчә бәхетсез, кызганыч булып калдылар.

Соңыннан ул берәм-берәм романдагы башка каһарманнарны хыялында җанландыра башлады. Алар бер-беренә бөтенләй охшамаган килеш аерым төс, аерым хәрәкәтләр белән күз алдыннан үттеләр. Ул: «Толстой үзенең классын, кешеләрне яхшы белгән», – дип уйлады.

Кинәт ул, үзенең кешеләрне белү-белмәвен сынарга теләгәндәй, күргән кешеләренең йөзләрен, аларның нәрсә уйлауларын, гадәтләрен, хәрәкәтләрен тулы бер типлар килеш хыялында җанландырырга теләде. Ул уйлары белән шул күргән кешеләре арасында үзенең характеры белән башкалардан үзен аерган бөтен аермалыклары белән аерып

алып була торган типларны эзләде. Башыннан яшен тизлеге белән тирә-як күршеләре үтеп киттеләр. Алар гүя барысы да берсе-берсенә охшаган, аерып ала алмаслык якыннар кебек тоелдылар. Тик аларның һәрберсендә үзең яңгалардан аера торган ниндидер күренмәслек, тиз генә тел әйтә алмый торган нечкә үзенчәлекләр барлыгын сизде.

Аның уйларын бүлеп, кемдер ерактан:

– Мора-а-а-т!.. Морат, ашарга кил! – дип кычкырды.

Рөстәм башын күтәрми генә тавышыннан Моратның анасымы яки апасымы кычкыруны белергә теләде. Яшен тизлеге белән Моратның апасының һәм сеңлесенең нинди тавышлар белән сөйләшүләрен хәтерләргә теләде. Кычкыручы Моратның анасы булырга кирәк дип, башын күтәреп кычкырган якка карады. Ерактан маңлаена кулын куеп бакчага карап торган бер хатынны күрде. Моратның анасының күзләре начар булганга, кояшка карый алмавын искә төшереп, Рөстәм кычкыручының Хәмдия карчык икәнен белде. Соңыннан бакчадан күзләре белән Моратны эзли башлады. Морат, анасының кычкыруына карамый, бакчасына тирес сибүендә дәвам итә.

Рөстәм Моратның анасының кычкыруына җавап бирми тирес сибүендә дәвам итүен Моратның үз эшен белгән, бер-ике кычкыруга гына ачулы рәвештә җавап бирүче картлар кебек юри итенергә теләве дип аңлады. Һәм анасының икенче кычкыруына гына эшеннән туктамый кулын селтәп кенә җавап бирүе аның бу фикерен - дөресләде.

Ул Моратның үзендәге нинди яклары белән башка күршеләреннән аерылуын эзли башлады. Моратның тавышы Шәрү агайның тавышына бер дә охшамый. Аларның тавышлары арасында ниндидер тел белән әйтеп булмый торган бер аерымлык бар. Ул аерымлыкны бары тавышларны ишетү әгъзалары гына сизә. Ул төсе, күзе, башка әгъзалары белән дә күршеләреннән генә түгел, сеңелләреннән дә, кардәшләреннән дә нык аерыла. Бары атасы белән генә бертөрле охшау бар кебек. Зур, көн ашаудан яргаланган, кызарып беткән борыны, сары чәчләре, кеше өстенә капланырга торгандай ике зур колагы аны ак йонлы куйларга охшата. Аңарга караган кеше иң беренче аның башын-күзен күрми, колакларын, борынын күрә. Морат көлгән вакытта да авызы белән көлми, гүя колаклары, борыны белән көлә төсле.

Рөстәм аның бөтен гомерен күз алдыннан үткәрде. Ләкин аның табигый, үзенеке дип әйтерлек бер генә хәрәкәте дә күз алдына килеп баса алмады. Аның һәрбер хәрәкәте үз хәрәкәте түгеллеген, кемгәдер ияргәнлеген кычкырып торалар төсле. Йә ул үз яшенә туры килмәгән картларча итенә, яки аның хәрәкәтләре үзеннән яшь балаларныкына охшый. Әллә балалык итенешләре дә аңар килешеп бетмәгәнгәме, әллә буыннары үзләре табигый хәрәкәтләр ясый белмәгәнгәме, ул бик яшьтән үзе ошаткан кешеләрнең хәрәкәтләренә иярә башлады. Ул, Бәкер агай кебек, кулларын артка куеп йөри. Атын болынга озата барганда, ат өстенә утырмый, картлар кебек башыннан гына тотып бара. Сөйләгәндә зурларча сөйли. Балалардан бигрәк картлар белән сөйләшә. Кырда эшләп ятучы таныш, таныш булмаган кешеләргә, унике яшендә булуга карамый:

– Алла хуат бирсен! Бак, Ходай ницек яңгырны бирде, – дип, зурларча сөйләнеп үтә. Аны таныган кеше дә, танымаган кеше дә бу сүзнең Моратның үз сүзе түгеллеген, картларга ияреп әйтүен аңлап елмайды. Ул нәрсә әйтсә дә, картлар теле белән картларча әйтә. Тыңлаучылар да аның үз фикере, үз сүзе дип тыңламыйлар. Морат турында берәр нәрсә сөйләсәләр, ниндидер бер пешмәгән кеше, көлке уята торган хәрәкәте турында сөйлиләр.

Буе үсү белән дә ул бу бәлаләрдән котыла алмады. Аңар егетлек тә килешмәде. Егет булып итенгәндә, аның хәрәкәтләре, егет булуына ышандырудан бигрәк, егетләрне үртәргә теләгән кебек табигый чыкмадылар. Ләкин ул бар көче белән җитди булырга, үзенә егет иттереп каратырга тырышты. Ул бөтен нәрсәләрне шул юлга файдаланды.

Берәр туйда яки өмәдә әз генә эчәргә туры килсә, авыл буе тыныч кына кайта. Ә үз өенә җитәргә бер ун йорт калгач, күршесе Җамали кебек башын селкеп-селкеп җырлап, сүгенеп, кычкырынып, ава-түнә кайта башлый. Шулай итеп күрше хатын-кызларына зур эчүчеләр кебек булуын күрсәтергә тырыша. Ә аның итенешләрен карап торган күрше хатын-кызлары:

– Бак, бак, тилегә. Хәзер генә теп-тере иде, үенә йетә башлагач, котыра башлады. Бак Эләмшә Ксугына, – дип, башларын селкеп көлке катыш карап торалар. Беркем дә аның дөрестән дә шулай исерек булуына, исергәннән шулай ава-түнә, сүгенә-сүгенә килүенә ышанмыйлар.

Морат өйләнә дигән хәбәр таралгач, ун яшьлек бала өйләнергә җыенган кебек, көлке катыш каршы алдылар. Аның туена курчак туе кебек кызыгып карадылар. Кияү булып йөргән вакытындагы итенешләре күршеләре өчен айлар буенча рәхәтләнеп көлеп сөйләрлек вакыйгага булып калды.

Өйләнүгә бер атна үтәргә өлгерми, бер сәбәпсез хатынын кыйнап ташлады. Моны да ул хатынына үзен усал ир итеп күрсәтер өчен, тирә-күршеләренә үзен хатынлы кеше кебек була алуына ышандырыр өчен эшләде дип сөйлиләр.

________

Рөстәм үзенең уенда башына килгән бик күп кешеләрнең, меңнәргә бер тел белән бер үк урында яшәгән кешеләрнең бер-берсеннән нәрсәләр белән аерылуларын, аларның йөрәк тибүләренең, уйларының агышларының бер-берсенә башкалыкларын аерырга теләде.

Ул Моратлар, Шәрүләр арасында туды. Алардан сөйләргә, эшләргә өйрәнде. Аны шул ук авыл кешеләре сукаларга, тырмаларга, ат җигәргә өйрәттеләр. Ул кинәт үзен Мораттан аермасыз, Морат кебек үк, башкаларга ияреп сөйләргә өйрәнүен, аның кебек үк, аларга ияреп меңнәр эшләгән эшләрне эшләвен аңлады.

Соңыннан ул үзенең укуы, белеме белән авыл халкыннан аерылуын исенә китерде. Кинәт ул үзенең алган белеменең дә, китаплардан алган фикерләренең дә үз фикерләре булмавын, крәстияннәргә сөйләгәндә дә үз фикерләрен сөйләмәвен, артистлар суфлерга ияреп сөйләгән кебек әллә кемнәргә ияреп сөйләвен, хәрәкәтләрендә үзенең укыган романнарындагы каһарманнарга охшарга тырышып йөрүен аңлады.

Аның башы әйләнде. Ул миллионнарча укыган, укымаган, гакыллы, гакылсыз кешеләр эчендә үзенең беркемдә булмаган кечкенә генә бер нәрсәсен, аерымлык табарга тырышты. Тик ул үзенең бер генә фикерен дә, бер генә хәрәкәтен дә башкалардан аерып ала алмады. Ул миллионнарча кешеләр эчендә үзенә охшаган меңнәрчә кешеләр барын уйлап, үзен шуларга кушылган нокта икәнен генә аңлады.

**Юкәчеләр**

Рөстәм Дашкова белән очрашуының өченче көнендә Иван Сәдрүләре, Кунышлар, Шәрүләр, Габбаслар юкә кисәргә барырга җыена башладылар. Сиражи агай да аларга пайга керде. Ләкин Рөстәмнәрнең тарыларын әйләндерәсе булганга, ул баралмады, аның урынына Рөстәм барырга булды.

Алар иртән таң белән җыелып юлга җыендылар. Рөстәмнең анасы урманда пешерергә дип тавыгын суйдырды. Бер атнага җитәрлек ярма, икмәк, бәрәңге кебек әйберләр куйды.

Габбас агай, Рөстәмнәрнең йортлары каршына атын туктатып, Рөстәмне үз арбасына утыртып китте.

Авыл кырларын үткәнче Габбас агай яшь вакытларын, Рөстәмнең атасы белән атлар көтеп йөргән чакларын исенә төшереп сөйләп барды. Соңыннан Рөстәмнән берәм-берәм сугыш хәбәрләрен, «вәлшәвиклар», «каммун» турында сораштыра башлады.

– Ницек инде ул алай, ә? Бар да тигез булсын! Примир, кулдагы бармаклар ды ун, бертигез түгел. Нитумшты кешеләр. Мокун улы Мокун улы булып калыр ды. Выт сине аның белән ницек итеп тигезләргә?..

Рөстәм аңарга тигезлек дигән сүзне ничек аңларга кирәклеген төшендерергә тырышып карады.

Башта ул Габбас агайның сорауларына кыска-кыска җавап биреп калды. Аның йоклап туймаган тәне арбаның әкрен генә тирбәлеп баруы белән рәхәтләнә, сызлый, матур төшкә охшаган матур хыяллар йөрәген белемсез бер җиңеллек белән ашкындыра иде. Ул әкрен генә хыялында Дашкованың төсен, аның күз карашларын җанландырырга кереште. Зәңгәр хыял томаны эчендә әкрен генә бер күләгә әйләнә башлады. Тик ул күләгә Рөстәмнең моннан элек күргән бик күп кызларының төсләре белән аерып алмаслык рәвештә бутала иде. Рөстәм, күзләрен йомып, Дашкованың чын төсен күз алдына китерергә теләде.

Аның башыннан нинди уйлар үтүен белмәгән Габбас агай Рөстәмгә төрле сораулар бирүендә дәвам итте:

– Патшаны хурлыйбыз, хурлыйбыз ды, ә выт аның вакытында яхшырак иде. Икмәкне де килеп әтрәд белән алып китмиләр иде...

Рөстәм элек Габбас агайга уйларга комачаулавы өчен ачуланды. Тешләрен кысып, ишетмәгәнгә салышты. Соңыннан әкрен генә җавап бирә башлады.

– Бу авыр вакытлар үтәр, Әббас агай! Алпавытларны җиңеп беткәнебез юк. Бөтен җирдә алар белән сугышлар бара. Ә сугышны алып бару өчен гаскәр тотарга кирәк. Гаскәрне ашатырга икмәк кирәк...

– Суң выт, Рөстәм, Николай ды сугышты. Ә икмәкне болай талап алмады. Алганда ды акца түләп алды.

Рөстәм аңарга Николай вакытындагы сугыш белән хәзерге сугышның аермасын аңлатырга тырышты. Ул үзе дә белми Габбас агай белән сүзгә керешеп китте. Үзенең сөйләгән сүзләренең Габбас агайга ничек тәэсир итүен тикшереп бара башлады. Габбас агайның үзенең сүзләренә кушылмавын аңлагач, тагын да ачыграк мисаллар белән аңлатырга кереште. Аның башында Дашкова күләгәсен әкрен-әкрен бүгенге баш әйләндергеч сәяси вакыйгалар алмаштыра башлады.

Рөстәм кинәт үзенең сәяси вакыйгалардан бик нык артта калуын, аклар белән кызылларның, фронтларның да кай тирәдә булуларын белмәвен, ул гына түгел, үзенең хәзергә кадәр кемнәр яклы булуын да ачык итеп уйлый алмавын бик ялангач рәвештә күз алдына китерде.

Ул крәстияннәр советлар властен сүгеп торган җирдә туры килсә, советларны яклап сөйли, сораучылар булса, бүгенге мәсьәләләрне большевикларча аңлатып бирә. Хәтта сөйләгән вакытта ачыктан-ачык:

– Без әле алпавытларны җиңгәнебез юк, – дип, үзен большевик итеп, «без» дип сөйли. Ә ни өчен соң ул авылда коммунист булып язылган крәстияннәр белән бергә эшләми? Нигә башка крәстияннәр белән бергә аларга нәфрәт күзе белән карый? Ул үзен акларга юллар эзләде.

– Чөнки ул коммунистлар коммунистлар түгел. Алардан Мокунны алсаң, ул үзенең караклыгы белән авылда дан алган кеше. Нуркәй булса, авылның большевикларга кадәр үк иң ялкау кешесе саналадыр иде. Башкалар да шулай ук. Алар арасына керү, алар белән үзеңне рәткә кую?.. Юк, бу нәрсәләр генә аның большевик булуына киртә була алмыйлар. Нәрсәдер башка, Рөстәм үзе аңламаган хисләр киртә булып торалар. Бит ул, шул ук Габбаслар кебек үк, авылга икмәк алырга килгән отрядларга дуслык күзе белән карый алмый. Ул гаскәр өчен икмәк кирәклекне аңласа да, йөрәге нигәдер акылы белән карыша, килешми. Нәрсәдер, нидер кулларын бәйли. Нәрсә? Ул үзе дә белми...

Садрый арбасыннан төшеп, чыбыркысы белән атын сукты да, туктап, үзеннән артта килгән Рөстәмнәрне көтә башлады. Рөстәмнәрнең аты аның турысына җиткәч, ул, Габбас агайга карап:

– Суат, ике хатын интектергән үзеңне, трсидильнигыңны ды күтәреп бәли алмагансың, – диде. Үзе, атны туктатмый гына, Габбас агайның атының аркалыгын күтәреп бәйләде һәм сикереп арбага утырды.

Габбас агай:

– Иртәрәк ятарга кирәк. Адәгез киттек. Ату гаеткә уяна алмабыз.

– Ә киемнәр янында кем кала?

– Киемнәргә ни булыр! Монда урманда чурт ты юк. Адә, тизрәк барабыз ды кайтабыз.

Иван Сәдрүе, күмердән тәмәкесенә ут кабыза-кабыза:

– Суат, сез барып юынып кайтыгыз. Ә мин киемнәр саклап калам. Сез кайткач, мин барам.

– Адә, адә, мукшы, кацып калмакчы буласың. Алладан курык бераз.

– Валлай, суат, кацмыйм. Ату киемнәрне алып китәрләр...

Габбас кулын селтәп елгага табан юнәлде. Аларга Шәрү, Рөстәм, Нәҗми, Фәтхулла, Галүк, Ибрук һәм башкалар ияреп киттеләр...

---

Шуарләй суы зур кара урманны икегә ярып әкрен генә түбәнгә табан ага. Ике як ярлары да кеше кералмаслык баткак, камышлыклар. Балан, усак агачлары, җыламсыр таллар арасында тирән-тирән балыклы күлләр җәелеп ята. Ул күлләр камышлык белән капланган. Тар гына җир кырлар аркылы Шуарләй суына тоташа. Баткаклыктан күтәрелеп өскә, камыш төпләренә баса-баса илле адымнар баргач кына, Шуарләй суының агымлы җиренә җитеп була. Ә камыш аралары сулы баткаклык, Чирәмле җирләр дә аяк басу белән түбәнгә уелып киләләр.

Аның ерак урманнар эчендә бик тирән балыклы җирләре бар. Җәй көннәре эссе вакытларда камышлары эчендә бүреләр яшеренеп ята. Юкәчеләр, Габбас агайга ияреп, камыш төпләренә баса-баса, Шуарләй суына табан китә башладылар. Якын камышлыклар эчендә ниндидер шыпырдау ишетелде һәм канатлары белән һаваны дулкынлатып кыр үрдәкләре очып китте.

Шәрү агай:

– Гу-гу-гу-гу! – дип кычкырды.

Аңарга ияреп башкалар да төрле тавыш белән кычкыра башладылар. Тавышлар, тын урманны яңгыратып, агач яфракларына бәрелә-бәрелә, еракларга китеп югалды. Морат, бер камыш төбеннән икенчесенә сикергәндә, аягы таеп баткакка төшеп китте.

Аның артыннан килгән Галүк:

– Агайлар, Морат батты! – дип кычкырды.

Әйләнеп караучылар шаркылдап көлеп җибәрделәр. Морат, тездән пычракка батып, көчкә өстерәлеп, усакларга асылып, камыш төбенә басты.

Шуарләйнең агымлы җиренә җиткәндә генә, тагын камышлар шалтырап китте. Юкәчеләр камыш төпләренә баскан килеш туктап калдылар.

Габбас агай:

– Егетләр, туктагыз! Камышлар арасында бүре йөри, ахры, – диде.

Башкалар, ашыгып-ашыгып, аның тирәсенә җыелып, тыннарын алмый тора башладылар. Ләкин камышлар арасыннан тагын тавыш ишетелде.

Шәрү:

– Бу үрдәкләрдер, канальяларны, адәгез, курыкмагыз! – диде.

Башкаларга җан кергән кебек булды. Габбас тагын да догалар укый-укый алга табан атлый башлады. Ләкин элекке батырлыгын ул яхшук югалтты. Бер камыш төбеннән икенчесенә сикерү белән, ул туктап тыңлый башлады. Баткаклыктан чыккач, аякларын юар өчен су алып кайтырга дип алган кулындагы чиләк шалтырау тавышлары да аны өркетә башлады. Шуарләйгә якынаю белән, кинәт читтәге күл дулкынланып китте. Камышлар арасыннан хатыннар тавышы ишетелде:

– Әббәс җаным! Әббәс!

Юкәчеләр туктап калдылар. Габбасның кулыннан чиләкләре төшеп китте. Чиләк тавышына аның артыннан ук басып килгән Морат бик каты кычкырып җибәрде. Үзе баткакка егылды. Моратның тавышыннан Габбасның күз аллары караңгыланды. Ул, үзен-үзе белми, Моратның өстенә басып, кырыйга сикерде. Морат, шашкан кеше кебек кычкыра-кычкыра, Габбасның аякларына асылды. Алар икесе дә баткакка баттылар.

– Караул, караул, шайтан! – дигән тавыш урманны яңгыратып җибәрде.

Алардан артта килүчеләр, бер-берсен батыра-батыра, котлары очып артка ташландылар. Рөстәм, җеннәргә, шайтаннарга ышанмаса да, чәчләре үрә торды. Башта ул нәрсә эшләргә белмәде. Канында аккан инстинкт белән куркудан күз аллары караңгыланды. Соңыннан кинәт башкалар белән бергә кача башлады. Габбас белән Морат, үзләрен-үзләре белми кычкыра-кычкыра, ярдәмгә чакыра башладылар. Рөстәм качучыларга карап бик каты:

– Туктагыз, качмагыз! – дип кычкырды.

Ләкин туктаучы булмады. Камышлар арасында кемдер гакылсыз рәвештә кычкыра, ниндидер ят һәм ярык, шалтыравыклы тавыш белән тотына алмый көлә башлады:

– Ха-ха-ха-ха! Хи-хи-хи-хи! Ху-ху-ху-ху!

Күлдән качып китүчеләр урман эчендә тавыш, шау-шу күтәрделәр. Камышлар эчендә ыңгыраша-ыңгыраша, дүрт аякланып, бер-берсенең чабуларына ябыша-ябыша, Габбас белән Морат Рөстәм янына үрмәләделәр. Рөстәм, үз тавышыннан үзе куркып:

– Курыкма, Әббәс абзый, курыкма! – дип кычкырды.

Габбас ыңгыраша-ыңгыраша, ашыга-ашыга ярга табан үрмәли бирде.

– Ух, ух... Караул, караул!.. – Рөстәм, камыш төпләренә сикерә-сикерә, алар белән ярга чапты.

Ә камышлар эчендә кемдер туктаусыз көлә һәм, баткакка бата-бата, алар артыннан чаба.

– Ха-ха-ха-ха! Хи-хи-хи-хи! Ху-ху-ху-ху!

Рөстәм, камышлар эченнән чыгу белән, Габбасны куып җитте. Аның күзләре зур итеп ачылган, йөзе, сакаллары пычракка баткан. Куллары, аяклары туктаусыз калтырый. Алар киемнәр янына җиткәндә, Нәҗми наратка элгән герман сугышыннан алып кайткан винтовкасын, яраштырып, һавага атып җибәрде. Әббәс агай ут янына җитү белән үк җиргә егылды. Мылтык тавышы кешеләрне бераз кыюлатты. Ләкин, күл ягыннан туктаусыз ишетелеп торган көлү тавышы ишетелү белән, алар тагын чигенә башладылар. Нәҗми, винтовкасын яраштырып, көлү тавышы ишетелгән якка атып җибәрде. Көлү тавышы беразга тынды. Биш минуттан тагын ишетелә башлады:

– Ха-ха-ха-ха! Хи-хи-хи-хи! Ху-ху-ху-ху! Туктагыз, мин шайтан түгел! Ха-ха-ха-ха!.. Мин Иван Сәдрүе, хи-хи-хи-хи...

Юкәчеләр, ышаныр-ышанмас, көлгән якка карый башладылар. Төнге караңгылыктан пычракка батып, аяк өстендә тотына алмый көлә-көлә килгән Сәдрү күренде. Шәрү агай:

– Ах, башың сынгыры! Ах, каналья! Уф, янны алды! Ах, анаңны шайтан алгыры!

Галүк, җиргә ятып, гакылсыз кеше кебек көлә башлады.

– Ха-ха-ха-ха!

Нәҗмулла башындагы бүреген ыргытты да көлү катыш Сәдрүгә карап төкерде:

– Тфү! Авызыңны еланнар цаккыры!

Ә Иван Сәдрүе алар янына килеп җитү белән җиргә ятты да тәгәри-тәгәри көлә башлады:

– Ха-ха-ха-ха! Хи-хи-хи-хи! Ху-ху-ху-ху!

Аңарга ябышып, аны Габбас кыйнарга тотынды. Шәрү, сүгенә-сүгенә, Сәдрүнең башына бер чиләк салкын су койды. Ә Сәдрү тәгәри-тәгәри көлүендә дәвам итте:

– Ну, зерә сез. Ух, ха-ха-ха, җибәрегез! Ай, ай, Әббәс агай! Ха-ха-ха-ха!

Куркудан гакылларын югалткан юкәчеләр җирдә аунаган Сәдрүне кайсы кыйный, кайсы кытыклый. Габбас, Сәдрүдән аерылып, җиргә капланды. Ул башкалар белән су керергә дә, күлмәкләрен юарга да бара алмады. Бөгәрләнеп ятты да ыңгыраша-ыңгыраша йокыга китте.

Юынып, күлмәкләрен юып кайтуга, юкәчеләр чикмәннәрен киеп, билләрен юкә белән буып, черкидән качу өчен тәбәнәк кенә, берәр кеше сыярлык итеп ясалган шалашларына кереп яттылар. Шәрү агай, шалашыннан башын чыгарып, шайтаннар, җеннәр турында әкиятләр сөйләргә тотынды.

**ХӘМИТ БЕЛӘН АРЫСЛАН ТУРЫНДАГЫ ӘСӘРНЕҢ ПЛАН-ЭЧТӘЛЕГЕ**

**I**

Язмышлары бөтен яктан бергә бәйләнгән Хәмит белән Арыслан – аерылмаслык дуслар. Алар тирә-як авылларның «иң бай кешеләре». Каралтылары йолдызлы күк белән капланган. Сандугачлы таңнарны, ояныр язның якты кояшлы иртәләрен алар җиде тал уртасында, үләнлектә елмаюлы шатлык белән каршылыйлар.

Кояшның беренче нурлары йорт башларын, мәчет түбәләрен ялтыратканда, йорт морҗаларыннан иртәнге төтеннәр күтәрелгәндә, җиде тал уртасында, куерып-куерып, зәңгәр төтен күтәрелә. Тик анда мич урынында таган ягылган, пулат йорт урынында салам белән ябылган шалаш тора.

**II**

Алар һәр көн, шалашларын көн буена буш калдырып, эшкә китәләр. Ике атна инде Хисами агайга палун[1] салалар. Кичләрен генә җиде тал уртасында тагын зәңгәр төтен күтәрелә. Еракларга җыр тавышы яңгырый.

**III**

Аларны ике нәрсә аерылмаслык дус иткән: беренчесе – артык ярлылыклары, икенчесе – табигать тарафыннан йөрәкләренә салынган чиксез зур җыр байлыгы. Биш-алты ел инде якын-тирә авылларның егетләре, Хәмит белән Арыслан авызыннан ишетеп, тыңлап туялмаслык җырлар җырлыйлар. Кичке караңгылыкта бер төркем яшьләр белән алар урамнан җырлап үтәләр, авыл кызлары, тәрәзәләргә капланып, аларның җырларын отарга тырышалар.

**IV**

Хәмит белән Арыслан чакырылган аулаклар күңелле үтә.

**V**

Авылда Ибраһим дигән бер картның бердәнбер баласы – Сәгыйдә исемле матур бер кызы бар. Өмәләрдә, аулакларда ул матурлыгы, уңганлыгы белән беренче урында.

Арыслан белән Сәгыйдә эчтән генә бер-берсен яратышып йөрсәләр дә, бер-берсенә серләрен бирмиләр. Моңа мөмкинлек тә булмый. Ялгыз-ялгыз очрашырга туры килми.

**VI**

Бары беркөнне Арыслан белән Хәмит икәүләп елга ярында балык тотып утырганда гына моңар мөмкинлек була. Сәгыйдә болынга ат алырга килә. Ләкин аты тоттырмый. Биргән икмәген ашый да чабып китә. Хәмит Арысланны Сәгыйдәгә ярдәмгә җибәрә. Алар, атны тотам дип куа-куа, якында урманга кереп китәләр.

**VII**

Ә бер атнадан урам буйлап җырлап баручы авыл егетләре, Арыслан белән Хәмиткә кушылып, Сәгыйдәнең исемен атап, аның матурлыгы турында җыр җырлыйлар. Чәй эчеп утырган Ибраһим картның шатлыктан сакаллары селкенә. Карчыгы нишләргә белми. Ә Сәгыйдә караңгы бүлмә тәрәзәсеннән онытылып урамга карый.

**VIII**

Арысланның җирсез-йортсыз булуы, аның йорт төзеп гомер итәргә омтылмавы гына бергә кушылып гомер итүләренә комачаулый. Сәгыйдә аулактан Арыслан белән килгәндә, атасының, әгәр Арыслан риза булса, йортына кертергә риза булуын анасына сөйләп торуын ишеткәнен сөйли. Ләкин Арыслан моңар әлегә күнми. Ул ерак шәһәргә барырга җыенуын, аннан бик баеп кайткач, йорт салып, аңа өйләнәчәген сөйли.

**IX**

Иртән кое янында очрашкан хатын-кызлар колактан-колакка Арысланның Сәгыйдәне яратуы турында төрле хәбәрләр сөйлиләр. Авылның атаклы бай Шәмсетдиннең кызы Фатыйма Сәгыйдәнең болай макталуына хурлана. Ул үзен авылның иң матурларыннан саный. Шуның өчен дә иптәш кызларына Сәгыйдә белән Арысланның зина кылып йөрүләре турында хәбәр тарата. Бу хәбәр Сәгыйдә белән Арысланга килеп җитә.

**X**

Ике көннән авыл урамында яңа җыр яңгырый. Тәрәзәдән кызлар карап йөргән егетләр, Шәмсетдин байның йорты турына җиткәч, кызы Фатыйма турында яңа җыр җырлап үтәләр. Кичке намазын укып кайткан Шәмсетдин җырны ишетү белән урыныннан сикереп тора да күсәк күтәреп урамга чыга. Фатыйма мендәренә капланып елый.

**XI**

Шәмсетдин, хурлыкка түзми, кызын кыйный. Соңыннан якын дусты мулла белән киңәшергә тели. Мәчеттә Арыслан белән Хәмиткә бәддога кылдыруны сорый. Ләкин мулла, үзенең асравы белән булган вакыйганы җырга чыгарудан куркып, икенче киңәш бирә. Шәмсетдиннең улы Галидән иптәшләр җыйдырып кыйнатырга куша.

**XII**

Гали Арыслан белән Хәмитне тотып кыйнатырга юллар эзли. Аларны тикшереп йөри башлый. Иптәшләре белән киңәшә.

**XIII**

Язның матур көннәренең берендә Хәмит белән Арыслан бер төркем крәстияннәр белән зур урманга юкә кисәргә чакырылалар. Гает бәйрәме алды була. Крәстияннәрне урманнан гаеткә алырга атлар килергә тиешле булса да, килеп өлгерми. Крәстияннәр гаетне урманда гына укырга булалар. Арысланнан имам торуны сорыйлар. Арыслан, аларның киемнәренең пычрак булуын сылтау итеп, күлмәктән генә калырга куша һәм пычракка батыра-батыра тәһарәт алдыра. Соңыннан дөнья тулы черкиләр уртасында крәстияннәрне биетә-биетә гает укыта. Үзе янып чыгып килә торган кояшка күзен кыса. Алырга килгән кешеләр арасында Сәгыйдә дә була. Ләкин алар урманга коточкыч хәбәр – мобилизация хәбәрен алып киләләр.

**XIV**

Урманнан кайтканда, Арыслан белән Хәмит Сәгыйдәләр арбасына утыралар. Ибраһим карт юл буена башын салып кайта. Ул Хәмит белән арбадан төшеп бара. Арыслан белән кызына серләшергә ирек бирергә теләп, алардан ераграк кайтырга тырыша.

**XV**

Авыл күз яше эчендә. Улларыннан аерыласы карчыклар, ирләреннән аерыласы хатыннарның йөзләрен үлем аклыгы каплаган. Тыела алмый аккан күз яшьләре белән карчыклар китәсе балаларының күлмәк якаларына догалыклар тегәләр. Төн йокысыз, авыр, басынкы үтә.

**XVI**

Туып гомер иткән илдән аерыласы килми. Китүчеләр үзләренең китәселәренә ышанмыйлар. Кемдер килер төсле дә: «Сугыш булмый, мобилизациягә бармагыз!» – дип кычкырып йөрер төсле. Хыялланалар. Тик урамны яңратып чакырып йөргән десятниклар гына авыр ярага тоз салып үтәләр. Ибраһим картның сугышка озатасы улы булмаса да, таңнан торып Сәгыйдәдән самовар куйдыра, үзе Арыслан белән Хәмитне йокыларыннан уятып, саубуллашу чәенә чакырып китә. Чәй эчкәндә, Арыслан белән Хәмит, кайгыларын күрсәтмәскә тырышсалар да, аерылганда түзмиләр. Сәгыйдә Арысланның муенына сарыла. Ә Хәмит карт белән карчыкны күз яшьләре белән үбә.

**XVII**

Җыен йорты тирәсе яулыклары белән күз яшьләрен туктаусыз сөртеп торган хатын-кыз, карчыклар белән уралган. Мобилизациягә китүчеләр яшьләрен күз төпләренә яшергәннәр. Менә атлар кузгала башлый. Мулла

тәкбир әйтә. Солдатка китүчеләр аңарга үтешли садакаларын бирә-бирә исәнләшәләр. Карчыклар улларының муеннарына сарылалар. Арыслан белән Хәмит башлап җибәргән саубуллашу җырына кушылып бөтен авыл үкси.

### XVIII

Ибраһим карт Арыслан белән Хәмитне озатып бара. Кызмачарак башлы никрутлар, авылны чыгу белән арбаларга утырып, кырда узышып, дөнья җимереп барганда, Шәмсетдин бай улы Гали Ибраһимнарның арбасына эләктереп каерып җибәрә. Ике арада тавыш куба.

### XIX

Сугыш башлана. Һәрбер кара конверт килгән йорт күз яшенә күмелә. Авылның мулласы гына кара конверт килгән саен шатлана. Ул кара конверт килгән йортка кереп хатем укый, гүр садакасы ала.

### XX

### XXI

### XXII

Сугыш башлану белән, Газиз мулланың килере артты. Ул сугышта үлүчеләрнең садакаларын җыю өстенә, солдат улларына хат яздырырга, хат укытырга килүчеләрдән дә күп кенә садакалар төшерде. Ләкин бу эштә аның бик зур дошманы аксак мөәзин булып чыкты. Ул хат уку, хат язу килерен бөтене белән үз тирәсенә оештыра башлады. Электән дә дус тормаган мулла белән мөәзин арасы бозылды. Мулла үзеннән элек гүр садакасы алып өлгергән мөәзинне тиргәде. Хәтта корбан тиреләренә дога кылып йөргәндә сугышып та алдылар.

### XXIII

Хәмит, кулы бераз уңайлану белән больницадан чыгып, авылга килде. Ләкин аның йөзендә борынгы көләчлеге югалган иде. Ул, савыгып больницадан чыгу белән, бакчачы Гыйльметдингә бакча караучысы булып керде. Тирә-ягы тау-урман белән уралган карбыз, кыяр бакчасында көннәрен ялгыз үткәрде. Төннәрен бакча янына ат кунарга килгән яшьләр аның Арыслан турындагы һәм сугыш турындагы кайгылы җырларын отып авылларга тараттылар. Әберкөнне ул хуҗасыннан акча алды да, Сәгыйдә белән икәүләшеп Арысланга хат яздылар һәм 4 сум акча җибәрделәр.

### XXIV

Тик аларның акчаларын Арыслан ала алмый. Ул, соңгы сугышларның берсендә бик каты яраланып, сафтан чыга. Бер көн кан эчендә урманда ятканның соңында, аны больницага җибәрәләр.

### XXV

Авыллар инвалидлар белән тула.

## ХӘМИТ БЕЛӘН АРЫСЛАН ТУРЫНДАГЫ ӘСӘРНЕҢ ЯЗЫЛГАН КИСӘКЛӘРЕ

Тротуарда кәрзинәсенә ятып, аякларын югары күтәреп яткан Хәмит белән Арыслан икәү аерылмаслык дуслар иде. Аларны аерылмаслык дус иткән нәрсә, беренче, чиксез ярлылыклары, юклыклары, икенчесе – табигать тарафыннан йөрәкләренә салынган чиксез зур җыр байлыгы. Якын-тирә авылларның егетләре-кызлары кырларны, урманнарны яңгыратып тыңлап туялмаслык җырлар җырлыйлар. Тик шушы матур җырларны беренче мәртәбә җырлаучыларның исемнәрен дә, кемлекләрен дә беркем дә белми. Бары шул авылның егетләре, кызлары гына матур мәгънәле җырларны беренче мәртәбә Арыслан белән Хәмит авызыннан ишетәләр. Ләкин барыбер еллар үтү белән ул җырларның кем тарафыннан җырлануын оныта баралар иде.

Язмышлары һәр яктан бергә бәйләнгән Хәмит белән Арыслан тирә-як байларда эшләп тамакларын туйдыралар. Эш эзләп йөргәндә, бергә йөриләр. Ялланганда, бергә ялланалар. Әгәр икесен бергә эшкә алмасалар, берсе генә эшкә керми. Әлбәттә, икесен дә алуны сорыйлар. Булмый икән, ялланмыйлар. Тик кырларда очраган бер ярлы

крәстиянгә эшләшергә булышалар. Печәнен ялтыратып ябалар. Ярлы крәстияннәр дә хезмәт хакларын соңгы бәрәңгесе белән булса да бүлешеп түли. Алар артыгын сорамыйлар да. Матур язлар – табигать кочагында.

Сәгыйдә авылның матур кызы. Ул каз өмәләрендә, аулакларда матурлыгы, уңганлыгы белән беренче урында. Ул күптән инде Арысланны яратып йөри.

Соңгы вакытларда Арыслан белән Хәмитнең җырларында да Сәгыйдәнең исеме, аның уңганлыгы, матурлыгы макталып җырлана.

*** * ***

Газиз кулындагы китабын ыргытты да, кулларын башы астына куеп, арка өстенә яткан килеш уйлый башлады. Күз алдында берәм-берәм бүген күзенә чагылып үткән күренешләр үтә башладылар. Ләкин ул берсен уйлап өлгерми, уйлары икенче нәрсәгә күчә һәм уйлаган нәрсәләре берәм-берәм онытыла баралар. Аның уе урамда кашыклар сугып җырлаган бер урам баласына килеп туктала. Ул күңеленнән шушы баланың йөзен хәтерләргә тырыша. Уйлары кинәт еллар арасында бутала-бутала артка китә. Ул үзенең моннан унбиш ел элек булган төсен күз алдына китереп бастырырга тырыша башлый. Шул елларда кигән иске бишмәте белән майланып беткән иске чалбар килеп төшә. Ә ул вакыттагы йөзен, никадәр тырышса да, хәтерли алмый. Әллә ничек төрле-төрле булып бутала. Ул сигез-тугыз яшьләрендә кайчандыр бер көзгегә караган, шунда йөзен күргән вакытын искә төшерергә тырыша. Кайчан гына соң ул көзгегә караган?.. Әллә бервакытта дамы?.. Ул беренче мәртәбә көзгене күргәнен искә төшереп карый... Хәтерләми. Аның сигез-тугыз яшьләрендәге йөзе исеннән мәңгегә югалган. Бай тормышта, ата-ана кулында үскән булса, бәлки, аның шул яшьтә дә рәсемен алдырган булырлар иде. Ләкин... ул урамда туып, урамда үскән... бәлки, ул Кызыл Армиягә киткәнче бөтенләй көзге дә күрмәгәндер... Аның уйлары уртасында караңгы бер күләгә әйләнә. Ак бүз белән бәйләгән, күз төпләре шешкән үзенең башын әллә кайчан гына көзгедә күргәне бар бит. Әйе, әйе...

Урам... Коточкыч ялгызлык... Кем ишегенә барып бәрелсә дә, куалар... Салкын... Мыекларын бөтереп, таякларны селкеп-селкеп, тротуардан үткән кешеләр сузган кулны күрми үтәләр. Газиз шул кешеләрне шулкадәр дошман күрә... зур кешеләрне ул барын да яратмый. Зурлар урамда кунар урын тапмый йөргән балаларны ишектән типкәләп куалар. Тротуарда йокларга ятса, баскалап китәләр... Тик балалар гына ничектер... алар кызгану катыш җирәнү белән карыйлар бугай. Сүз кушканда да, куркып-куркып кына булса да җавап бирәләр...

Ун яшьлек Газиз, урамда соранып йөри-йөри, йортның кара ишегеннән югары таба атлый... Йортларның ал ягыннан йортка кертмиләр... Ә арттан асраулар алай усал кыланмыйлар, кыйнасалар кыйныйлар, кайчакта берәр нәрсә ашарга да биреп куялар. Ул, югары менү белән, ачык ишектән эчкә атлый. Юлда очраучы булмагач, ул эчкәрәк кереп, берәр кешене очратса, ашарга сорамакчы була. Кинәт кулына эшләпәсе белән таягын тотып берәү каршы бүлмәдән килеп чыга. Ул Газизне күрү белән Газизгә табан килә. Газиз кулын аңарга табан сузып ашарга сорый. Ул, таягы белән кулга сугып, асрауга кычкыра:

– Карак кергән, Матрена... сволочь! Карамыйсыз...

Бүлмәләрдән йөгереп чыккан ирләр, хатыннар аны урап алалар. Газиз аларга үзенең икмәк сорарга керүен генә әйтергә теләсә дә әйтә алмый. Яңакларына төшкән йодрыклар күз алдында утлар чагылдыра. Менә аяклары җиргә тими, аны ишеккә өстериләр. Һәм... ташка бәрелгән баш сөякләре шытырдап чыңлый да, Газиз аңын югалта...

Соңыннан коточкыч ялгызлык. Йөзендәге каннарын сөртә-сөртә, ул урам буйлап бара. Кешеләр бары да, бары да усаллар...

**«ОҖМАХ КОШЫ»**

Фәтхи Бурнаш пьесасы. Пьеса русларның «Күк кош»[1], «Суга баткан чаң» [2] дигән пьесаларыннан файдаланып язылган.

Кыскача мөндәриҗәсе:

Ни өчендер җәннәттән бер кыз җир өстенә ташлана. Аны бер сукачы карт табып ала да өенә китерә. Җәннәт кызын өенә алып килгәннән соң, бабай байый. Кызның кул астында булган пичуралар көн-төн эшлиләр. Кыз үсә. Көннәрнең берендә бабайның хатыны җәннәт кызына усал сүзләр белән кагыла. Кыз бу сүзләргә түзә алмый, үзенең күптән сагынган урманнарына бабайны ташлап китә. Бабай, кыз китгкәч, ярлылана. Сукырая. Хатыны үлә. Вакыйгалар үтеп, кыз тагын кайта да, бабай байый.

Әсәргә өстән генә күз төшергәндә, тулы, матур телдә, балаларны канәгатьләндерерлек яхшук матур күренешләр бирелгән. Бигрәк тә рухлар, пичуралар картинасы уйнап, хәятлы аерым матур һәм балалар өчен кызыклы.

Алынган рух типларына килгәндә, күбесе татар халкыннан ерак-чит. Шуның белән бергә, татарларның үз хыялындагы мәшһүр Шүрәле нигәдер пьесага кертелми. Вакыйгда русларның урман иясе урынын Шүрәле алып, әсәрдә зур роль уйнарга тиешле иде.

Рухлар арасында аерымлык күренми. Фәрештә тибы белән урман иясе арасында зур аерма бар, моңар игътибар ителмәгән. Әсәрнең тәрбияви җәһәтенә килгәндә, балаларга файдалы җан азыгы бирелү урынында балаларны юкбар нәрсәгә ышандыру, хорафатка таба илтү тотыла. Хәтта Тукайның «Сабыйга» дигән шигыренә дә капма-каршы.

Бурнаш иптәш, материалист, коммунист була торып, нигәдер, җир тормышын тарсынып, күкләргә омтылучы хыялый идеалист шагыйрьләр юлы белән бара. Әллә хәзерге тормыштан җырлар нәрсә табылмыймы? Нигәдер Бурнаш иптәш, материалистларның «Сәнгать – тормыш өчен!» дигән әдәбияттагы шигарьләреннән читтә булып[3], борынгы көчле цензура мәҗбүрияте белән чын тормышны җырлый алмый, икенче бер тормышны җырлауга мәҗбүр булучы шагыйрьләр юлында «Сәнгать – сәнгать өчен!» шигаре астында күренә.

Мин, бу нәрсә хакында язуны икенче бер вакытка калдырып, әсәрнең техникасына күчәм.

Әсәрнең бәгъзе бер урыннарында монологлар балаларны ялыктырыр дәрәҗәдә озын булуы белән бергә балаларга аңлавы читенрәк урыннары очрый.

Мәсәлән, рухлар җыры:

Күләгәләрендә талларның
Бер кыз бала яткан гомергә;
Аппак йөзкәйләре баланың,
Сулар тарткан аны төбенә,
Ак тәннәрен юган чагында.
Тынга калган матур гомергә
Тик ай саклый карап янында...

Бу җирдәге тасвир шулкадәр муаффәкыятьсез, шулкадәр халәте рухия тел агышыннан ерак ки, бу юлларны балалар түгел, зурлар да аңлавы авыр.

Нәтиҗәдә Бурнаш драмалар язудан бигрәк хикәяләр язуга оста күренә. Гомумән, шагыйрьгә бу килешлерәк.

**ОПЕРЕТТА КАҺАРМАННАРЫ**

Шул көннәрдә Татар дәүләт театрында[1] «Сак-Сок» дигән драма уйналып үтте. Әбрар Сәгыйди әсәре.

Тәнкыйтьтән түбән нәрсәләр хакында язып үтү бер түбәнлек булса да, аның хакында сүзсез калу да туып килә торган яңа татар әдәбияты алдында зур җинаять яки түбәнчелек булачак.

Татар дәүләт театрында «Башмак»тан[2] башлап «Пороховой Фатих»[3], «Хәмит»[4], «Талир тәңкә»ләр[5] аркылы «Сак-Сок»ка кадәр килгән бу сәхнәдә тавыклар сугыштыру һөнәре нәфрәтләндерүдән косасын китерер дәрәҗәсенә җиткерде.

Гаҗәп!

Шул пьесаларны язучылар табылган кебек үк, татар гаммәсенең мәркәзендә шуларны рәхәтләнеп караучылар да, шул пьесаларны сәхнәгә куючылар да табыла бит. Татар театрының репертуарын баетам дип, бердәнбер татар театрын балаган дәрәҗәсенә китерү мәсъүлиятен алган Гыйльми мәркәздәге иптәшләргә, белмим, нәрсә генә дияргә?

Бәлки, аларча бу әсәрләр дөрестән дә татар әдәбиятын баета торгандыр, бәлки, шулайдыр да?! Бәлки, Алафузов, Мулланур Вахитов клубы заводына[6] шундый әсәрләрне эшләп чыгару өчен Габитовларга[7] тагын заказлар бирелгәндер?

Анысын көннәрнең үтүе күргәзердер.

Хәзергесе көндә бу эшләнеп чыккан нәрсәләре дә канәгатьләндерерлек.

Монда аерым «оперетта»ларга күчеп язу вакыт әрәм итү булыр. Гомуми рәвештә генә «Галиябану»дан[8], «Яшь йөрәкләр»дән[9] урланып язылган, тәрбияви яктан бер тиенлек әһәмияте булмаган бу әсәрләрне барысын бер капчыкка тутырып, өсләренә мөхәррирләренең исемнәрен язып, алардан сорыйсы килә: «Бу нәрсәләрне язучы иптәшләр шөһрәт алырга телиләрме яки башка афера таба алмауларыннанмы?»

Соңгысы булса, без бер авылга «мулла» булып[10], авыл кулакларына кияү булып ашап ятарга киңәш бирер идек.

---

Татар әдәбияты күчү дәверен үткәрә. Карт язучылар үз дәверләре белән бергә югалдылар. Яшь көчләр әле оешып җиткәне юк. Алар өлгерәчәк. Ләкин шул арада баш күтәргән «хорафат» язучыларының көннән-көн алга баруы туачак татар драма әдәбиятында шомлы эз калдырмавы исеменә үткен, көчле бер тәнкыйтьчене эзләргә мәҗбүр итә. Ләкин, мәгаттәэссеф, ул көч әле күренми. Ләкин ул туарга тиешле. Шиксез, тәнкыйтьчене көчле талант үзе белән тудыра. Инде татар әдәбиятының бу дәрәҗәгә дә килеп җитүе тәнкыйтьче түгел кешенең йөрәгендә шул көчне уятырлык аяныч бер хәл.

«Сак-Сок»ны язучы әфәндегә шуны әйтергә туры килә:

«Иптәш!

«Сак-Сок» дигән нәрсәң – «Галиябану», «Яшь йөрәкләр» дигән әсәрләрдән күренешләре, каһарманнары белән генә түгел, сүзләре, җөмләләре белән үк урланып җыелган бер уйдырма. «Сак-Сок»ны язып сәхнәгә куйдыруга җөрьәт итүеңә гаҗәпләнәбез. Драма язу сез уйлаганча түгел. Аның өчен «Мөхәммәт галәйһиссәлам» күзе урынына хәзерге тормышның иң тирән җирләренә төшәрлек күзләр, үткен күзләр, хәят музыкасының иң нечкә кылларының тавышларын ишетә торган хәссас йөрәк, ниһаять, күп, бик күп нәрсәләр кирәк.

«Сак-Сок»та ул кирәк нәрсәләрнең берсе дә юк. Кирәкмәгән нәрсәләр бик күп. Халыкның рухына хорафат сеңдерү уеңда булсаң, ул нәрсәләрне авылда бик шәп эшләп була.

Синең иптәшләрең «Башмак», «Тәфтиләү»[11], «Талир тәңкә», «Йосыф-Зөләйха»[12], «Хәмит», «Пороховой Фатих»ларга да шул ук сәлам җибәрелә.

Кәефегез китмәсен!

Без хәзер бер дәвердән икенче дәвергә күчү алдында торабыз. Бу иҗтимагый тормышта да, әдәбиятта да һәрнәрсәдә шулай. Сезнең хорафатка таба тартып маташуыгыз ачык бер төс алганга, ачык итеп язарга мәҗбүр итә.

Хәзерге көндә халыкның иҗтимагый язмышын да, тәрбияви язмышын да үз өстенә йөкләгән Советлар хөкүмәтенең кануннары арасында бу сүзләрне күп очратырсыз».

## ИҖАДИЯТЕМ ТУРЫСЫНДА

Кулыгыздагы мәҗмугада[1] басылган бәгъзе бер шигырьләрнең шәкел вә мөндәриҗәләрендә сезнең өчен, мөхтәрәм укучы, байтак кына ят хәлләр очрар. Шигырьне күргәч тә, сез аны такмаклап укырга керешерсез дә анда бик күп кытыршылыклар табарсыз. Вәзенен, кафиясен, басымнарын туры китерә белмәүдә мине, бәлки, гаепләрсез дә. Шулай ук мөндәриҗәләрнең бәгъзе урыннарда өзелә баруы, кинаяләрнең аңларга читенлеге сезгә ят тоелыр.

Ләкин моннан элек такмакларга өйрәнгән шикелле, табигый сөйләү юлы белән укырга да бик тиз өйрәнерсез. Чөнки бу язу юлы – татар теле өчен табигый юл. Кыска сүз белән ике уртада бер-беребезне аңлау хасил булсын өчен, мин тик иҗадиятемнең нигезенә куелган түбәндәге маддәләрне әйтеп үтәм:

1. Бакырганидан[2] алып Тукай аркылы хәзергә кадәр биш йөзләрчә шагыйрьләр тарафыннан сузылып килгән татарның иске шигъри өслүбе җимерелергә тиешле. Ул искерде, ул киң рухлар, ялкынлы йөрәкләр өчен тар.

2. Шигырьдә үгет, нәсыйхәт, сафсата бетәргә тиешле. Яшь күңелләр тасвири әсәрләр сорыйлар.

3. Шигырьдә матур сүзләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде, татар тормышы шулай ди.

4. Халәте рухиянең үзе теләгәнчә агуына киң юл куелып, сонгый иҗат, әлбәттә, «әдәбият кануннары» буенча барырга тиеш түгел.

Халәте рухиянең иркен агуы – үзе әдәбиятның кануны.

5. Иске өслүбтә иң алда тотылган такмаклап язу юлы бетәргә, аның урынына «тон» белән «сөйләп» язу юлы кертелергә тиешле.

6. Шагыйрь композитор булырга тиешле. Ул, яза башлаудан әүвәл үзенең халәте рухиясенең музыкасын табып, шигыренә шул музыканы кушып язарга һәм аның шигыренең нинди халәте рухия вакытында язылганы аңкып торырга тиешле.

**«АДАШКАН КҮҢЕЛ»**

14 гыйнварда Дәүләт татар театрында уйналган бу әсәрнең (Фәйзи әсәре) кыскача мөндәриҗәсе:

Шәһәрдә үскән бер бай кызы, нindидер мәхәббәттән качып, авылга килеп мөгаллимә була. Ләкин сөяргә өйрәнгән яшь йөрәк монда да мәхәббәттән котыла алмый. Үзенә тиң булмаган бер авыл егетенә гашыйк була. Ләкин ул авыл егетен үзенә тиң тормышта бергә торырга яраклы итеп тапмый. Күз яшьләре белән аңардан качып китәргә мәҗбүр була. Ул, авылны ташлап киткәч, Уфага килеп, анда мөгаллимә булып тора башлый. Тик авыл егете Саматтан аерылуга өч ел булса да, оныта алмый, күз яшьләре түгә. Аны хатынлыкка алырга теләүче зыялы журналистка да барырга риза була алмый. Саматны елап, сагынып торган вакытларында килеп Самат керә. Ул инде бер авыл кызына өйләнеп, бер баласы да булган. Мөгаллимә белән Самат тагын аерылалар. Бу аерылудан соң мөгаллимәдә инде бала да була һәм шул мөнәсәбәт белән ул, урыныннан чыгарылып, Златоустка килеп чыга. Ул монда яшь бала белән бик начар хәлдә кала һәм, нишләргә белми торганда, Самат белән тагын очрашалар һәм көн итәләр. Самат инде монда шахтер була.

Әсәрнең мөндәриҗәсе шул. Мондагы моментлардагы халәте рухиягә, табигыйлеккә ят булган гаҗәеп мәхәббәт күренешләре, мәхәббәт сүзләре дә дәрья кадәр. Мәхәббәт күз яшьләре белән мөхәрриребез мәхәббәтнең илаһиятен тасвир итәргә тырышкан.

Ләкин ул тасвирлар, ифратка китү сәбәпле, гаять муаффәкыятьсез, көлке булып чыкканнар. Мондагы фаҗигале мәхәббәт күренешләрен карап утыручы кешеләр тәэсирләнеп утыру урынында «бар икән төшеп калган кешеләр» дип, әсәрне язучы өчен уйларга мәҗбүр булалар.

Кыскасы, идеология һәм халәте рухия ягыннан табигый булмаган кебек, технический яктан да муаффәкыятьсез. Әсәр башыннан актыгына хәтле бер-беренә бәйләнмәгән корама рәвешендәге күренешләр[дән тора].

Әгәр дә моны арзанлы кинематографиядә уйнасалар, кызыграк булыр иде. Мондагы урынсыз җырлар, Фәйзинең һәрбер әсәрендә кабатланып килгән биюләр чүп өстенә чүмәлә булып төшәләр. Әсәрдәге шахтер типларын алсак, алары белән Фәйзи үзеннән көлдерү белән генә калмый, ачуны да китерә. Ул эшче шахтерларны эчүгә сабышкан, сукбайлыкка киткән байбәтчәләргә охшатып тасвир итә.

Без буржуа әдәбиятының иң югарысында торган сәнгать әсәрләрен шул заманның тормышын өйрәнү өчен карасак (билгеле, тәнкыйть күзе белән), икенче яктан, ул әсәрләрнең зур осталык белән эшләнүләре дә бар. Ләкин «Адашкан күңел» киң татар әдәбиятында адашкан. Һәр яктан муаффәкыятьсез эшләнгән бер әсәрне хәзерге татар театрында күрү гаҗәбрәк. Уйнаучыларга килгәндә, әсәрне баштанаяк карап торырга мәҗбүр итүче – талантлы артисткабыз Ильская ханым[1] иде. Шундый муаффәкыятьсез әсәрдәге аның бай уенын әрәм дип карарга кирәк. Татар сәхнәсе репертуарында бу бөек талантка уйнарлык типларны бирүче драматурглар әле күренми.

Халыкның сөекле артисты Вәлишин[2] иптәш соң дәрәҗә оста уйнады. Ул көннән-көн яхшыра һәм күтәрелә бара. Кугушева[3] ханым да, башка әсәрләрдә оста уйнаганы кебек үк, бүген дә матур уйнады. Казан халкы аны яратып кинә. Башка уйнаучылар алай күзгә чалынмады.

**КАРИ КИЧӘСЕ**

31 мартта Татар дәүләт театрында Кари[1] кичәсе булып үтте.

Кичә бик күп бүлемнәрдән гыйбарәт булып, бу кичәне бу елгы сезонда куелган кичәләрнең иң уңышлысы һәм тулысы дияргә мөмкин.

Кичәдә куелган «Чабатаңны кемгә тукыйсың?»[2] (Кави Нәҗми әсәре) дигән нәрсәне уйнаучылардан Уразиков[3] яхшы уйнады. Бу әсәр Кавиның «Киләләр» дигән трагедиясенең бер пәрдәсе булып, көчле булуы белән бергә бераз бәйләнешсезрәк җирләре бар. Кави иптәш, билгеле, ул җирләрен төзәтеп, дөньяга чыгарачак.

Бу кичәдә Тарханов[4], Вәлишиннар яхшы тәэсир калдырдылар.

Концерт бүлегендә Бөдәйли[5], Абруй[6] ханымнарның җырлауларын аерым сызып үтәргә кирәк.

Коллектив декламациядә Маяковскийның «Сул белән» дигән әсәре[7] яхшы булды. Шулай ук «Поезд» картинасы да уңышлы, матур күренде.

«Яңа Печән базары»[8]. Кави Нәҗми әсәре. Бу нәрсә – көчле бер сатира. Сәхнәгә куелышта яхшы булып, халыкта зур тәэсир калдырды. Хәтта пәрдәдән соң Печән базары каһарманнары тарафыннан залда шагыйрьгә бәйләнү кебек нәрсәләр күренде.

Мөхтәрәм Печән базары корольләре!

Кәефегез китмәсен.

Бу әле сезнең оягызның пычракларын ачып күрсәтүнең, бәлки, башы гына. Без, татарның яшь язучылары, сезнең тагын кабахәтрәк якларыгызны тозлап-борычлап күрсәтәчәкбез.

Театрда халык күп булып, билетлар җитешмәде.

## КИНО – «КЫЗЫЛ ПАРТИЗАННАР»

30 ноябрьдән алып «Унион»[1] кинотеатрында «Кызыл партизаннар» дигән кино бара. Бу картина адмирал Колчакның[2] соңгы көннәреннән алынып, шул вакыттагы партизаннарның батырларча көрәшләре, Колчакның кызыл гаскәрдән качып бару вакытлары тасвир ителә. Бу картина революция вакытларыннан алынган картиналарның иң көчлеләреннән дияргә мөмкин. Картина зал тулы караучылар тарафыннан баштан алып ахырга кадәр кул чабулар, туктаусыз көлүләр белән бара. Картинада көлке күренешләр күп булган кебек, куркынычлы күренешләргә дә бай. Агитационный ягы соң дәрәҗәдә көчле. Бу картинаны эшче һәм профсоюз членнарына арзан бәя беләнрәк булса да күрсәтеп үтү, әлбәттә, кирәк.

## «ДАНТОН»

Насыйри иптәшнең «Дантон» дигән нәрсәсен[1] карап чыктым. Әсәр Дантон[2] белән Робеспьер[3] арасындагы разногласиене[4] бертөрле ачарга мөяссәр булса да, аларга икесенә дә каршы һәм соңыннан аларны җиңәчәк лагерьның шул вакыттагы хәле бөтенләй томанлы кала. Бу – бер. Икенче, «Дантон»ның бөтен монологлары лиризм белән сугарылган. Дантонны алай алу аны көчсез күрсәтү дигән сүз. Шуңар башта кайбер тарихи томанлыкларны кушып, әсәрнең технический ягы хакында түбәндәге нәрсәләрне әйтергә туры килә: 1) театральный әсәр итеп алганда, хәрәкәт бик сыек, монологлар озын, трагизм көчсез, типлар җитәрлек дәрәҗәдә эшләнмәгән, психология ягыннан да шул бертонлылык. Шулай да әсәрне язучы иптәштә яхшы ук көч күренә. Язуда дәвам итсә, яхшы гына нәрсәләр бирә алачагы шөбһәсез. «Дантон»ны татар театрына биреп, театральный ягын эшләтеп, куйдырырга кирәк. Артистлар яхшы гына уйнаганда, матур гына чыгар. Бастырырга дигәндә, шигырьдәге техника ягын күп төзәтергә кирәк булачак.

## ЭШЧЕ-КРӘСТИЯН ЯШЬЛӘРЕ ӘДӘБИЯТЫ

Татар әдәбиятының революциягә кадәр булганы милләткә, милли байларга, милли муллаларга, милли миңлеләргә хезмәт итеп килде.

Алган тормышы, язган нәрсәләренең каһарманнары да милли бай, милли миңлеләрдән булып үзләренең милли байларының тормышын матур төсләр белән Европа байларының тормышларына охшатып бизиләр һәм шуның белән милли каһарманнар тудыралар иде[1].

Теле, тормышы белән ят булган бу милли каһарманнар әдәбияты үзендә милли түгел, эшче-крәстияннәргә роль дә бирмәде, һәм эшче-крәстияннәр үзләре дә моңар якын килми, үз тормышлары эчендә туган, беркемгә дә исеме билгесез вә шагыйрьләре тарафыннан чыгарылган үз җырларын гына җырлыйлар иде[2].

Агач башы ак мамык, шунда былбыл оясы;
Рәхәте юк, михнәте күп – утта янсын дөньясы.

Байлар, байлар бал эчә, урта байлар сыра эчә,
Ярлы егет, җанкисәгем, ярга ятып су эчә, –

дип, үзенең сыйнфый, икътисади аерымлыгын, бәхетсезлеген җырлап моңая.

Авылның билгесез шагыйрьләре дүртьюллык җырларында үзләренең тормышларында булган кайгы, шатлыкларны күрсәтәләр һәм шуны күмәкләп җырлыйлар.

Авыл матбугат шагыйрьләренең (авыл мәктәпләре тәэсире белән кергән Тукайдан башка) җырын җырлаганы юк. Ул, тормышның үзгәрүе белән туган каһарманнарны кушып, үз җырын җырлый һәм, авыл җырларында дәверләр үзләренең эзләрен калдыралар.

Солдатка озату, империализм сугышы, унҗиденче ел революциясе – боларның эзләрен авыл җырларында киң күләмдә очратырга мөмкин.

———

Октябрь булды, Октябрьдән соң матбугатта бик күп шагыйрьләрнең исемнәре күренде. Революционный пафос белән күп шигырьләр язылды. Ләкин ул шагыйрьләрнең шигырьләре дә шулай ук эшче-крәстияннәр арасына кереп үзләшә алмады. Ул шигырьләр хакында шуны да әйтергә кирәк, аларның күбесе Европада күптән ташланган бер форма: революция – кораб, без – юлчылар... Без менә утлар тотып диңгез артындагы коммунизмга барабыз, дигән рәвештәрәк интеллигентлар хыялы, эшче-крәстияннең башы сыйдыра алмый торган реальный тормыш воображениеләреннән ерак, шаблонный нәрсәләр.

Эшче-крәстияннәр коммунизмны диңгез артында дип тә уйламый, шулай ук революцияне дә диңгездә корабта йөзеп йөри торган итеп яки гомерендә күрмәгән янартаулар рәвешендә дә башына китерә алмый. Ул революцияне үзенең әйләнәсе тормышында, авылга килгән оратор, комиссар, комсомолда, революциянең чын реальный типларында күрә. Һәм шул тирәдә генә уйлый да ала. Ул революция тудырган аерым типларны, аерым каһарманнарны яхшырак күрә һәм алар хакында үзеннән легендалар тудыра.

Җырларында:

Ак Иделгә яр якын, шуңар күрә су салкын,
Алтын-көмеш чыккан җирдән безгә комсомол якын.
Йөгерә үрдәк баласы, алдан бара анасы,
Яшәсен совет власте, без бит аның баласы, –

дип үзен хис итә.

Быел үләр елым булса,
Каберем тирән казыгыз,
Баш өстемә таш утыртып,
Комсомол дип языгыз! –

дип мәгърур рәвештә шул исемне үзенә кабул итә. Кыскасы:

Татар шагыйрьләре (баштанаяк һәммәсе) быттан ерак. Аларның җансыз шигырьләрендә күренмәгән быт авыл җырларында дөресрәк күренә (бик зәгыйфь булса да) һәм алар хәзерге шагыйрьләрнең массадан ерак бүлмә хыялы белән язган шигырьләреннән яратыла төшеп укыла. Хәзерге көндә революционный быт соң дәрәҗәдә бай.

Революциядән соң Россия типлар галереясына әйләнде. Монда иске тормыштан йолкынып калган йолкыш-көлке типлар күп булган кебек, киләчәкнең хуҗалары яңа (бөтенләй яңа) типлар туып киләләр.

Ул типларны тормыш тудырды инде. Хәзер бары шагыйрьләребезнең югары йөргән күзләрен бераз түбәнгә төшерәселәре генә бар. Шулай итсәләр, алар яңа бытның каһарманнары белән борын борынга бәреләчәкләр.

Шагыйрьләр!

Авылга әдәбият кирәк, тормыш типларына күчәргә вакыт.

## КОМСОМОЛ ҖЫРЛАРЫ

Крыймов[1] иптәш – безнең шагыйрьләр арасында эшче-крәстиянгә якын торган шагыйрьләрнең берсе.

Ул көнлек теләкләр белән бара. Ул бөтен язуларын эшче-крәстиян яшьләренең сорауларына бәйли. Ул шул сораулар буенча «Кызыл Бәдәвам»ны[2] язды. Башка шигырьләре дә шул ук теләкләр белән бара. Соңгы көннәрдә ул күптән эшләнергә тиешле булган «Комсомол җырлары»н язып чыгарган. Бу як бездә әле эшләнмәгән. Ләкин бик эшләнергә тиешле бер эш иде. Бездә комсомоллар һәм пионерлар арасында күмәк йөрүләр, күмәк эшләр вакытында бер көйгә салып җырлана торган җырлар юк иде. Бу хакта сорауларны һәр адымда ишетергә туры килә иде.

Крыймов шул сорауны башка шагыйрьләребездән алдарак үтәде. «Комсомол җырлары»ның эченә кереп укып чыкканда, кайбер кимчелекләрен дә әйтеп үтми булмый.

Билгеле көйләргә салынган кайбер җырлар шул күргәзелгән көйгә туры килмиләр. Яки бездә, татарда, сындырылып-ватылып җырлана торган көйләргә салынган.

Монда саф рус көйләрен алырга иде. Мисал итеп «Кузнецы»[3] көенә салынган җырны алырга мөмкин. Аннан соң «Озату»[4] вә башка шуның кебек җырлар шул көйләргә бөтенләй килеп бетмиләр.

Мондагы кайбер мәшһүр җырлар «русчадан үзгәртеп» алынганнар. Аларны яхшылап тәрҗемә генә итәргә иде. Кыскасы, ашыгып эшләнгәнлеге күзгә бәрелә.

Инде оригинал җырларына килгәндә, бик матур нәрсәләр бар. Шулардан берсе «Коллективный җыр». Мондагы рус бае, татар бае, мулла, милләтче, эшче, крәстиян, кызылармеецлардан сөйләткән көлке гаҗәп матур чыккан. Крыймов иптәш шундый оригиналларны күбрәк бирсә, авыл театрларында, эшче яшьләр клубында җырлау, декламация өчен күп нәрсәләр биргән булыр иде.

Аның шул юлда эшләвен теләп калабыз. «Комсомол җырлары» эшче-крәстиян яшьләре арасында күп таралырга тиешле.

Бәясе дә кыйммәт түгел, бары 15 тиен генә.

## И.РӘМИ ХИКӘЯЛӘРЕ ТУРЫНДА

Исмәгыйль Рәми иптәшнең көлке хикәяләре җыентыгын карап чыктым[1]. Җыентык күләме белән өч табакка якын.

Җыентыкка кергән хикәяләр тематика ягыннан икегә бүленәләр:

1. Печән базары[2] агай-энеләре.

2. Идеологияләре белән Печән базары агай-энеләренә аерып ала алмаслык якын торган кустарьлар.

Автор үзенең хикәяләрендә көлке объекты итеп Печән базары агай-энеләренең рус телен бозып сөйләүләрен, ташбашларын, бүгенгә карата кайбер уңышсыз ләчтит сатып йөрүләрен, ваклыкларын көлке объекты итеп ала.

Элек заманда «Ялт-йолт»[3] журналы, Фатих Әмирханнар Печән базарыннан көлгәндә нинди позициядән торып көлсәләр һәм көлү объекты итеп нәрсәләрне алсалар, Рәми иптәшнең хикәяләрен укып чыгу белән дә аның шул ук позициядән торып диярлек, шул ук әйберләрне көлү объекты итеп алуын ачык күреп була. Аерма бары объектларның икенчерәк шартлар эчендә булуларында һәм совет терминнарында гына. Менә Рәминең «Күңел ачу» дигән хикәясе. Автор бу хикәясендә көлке объекты итеп Уфа Печән базары тибының башы таз булуын, хатыны белән ял итәргә чыгып та көн буе бакчада сүз тапмый, сөйләшми утыруын, хатынының авызына чебен керүен һәм башка шуның кебекләрне ала.

«Дипломат» дигән хикәядә жакт уполномоченные булган бер Печән базары агаеның речь сөйләп, речендә «утильсырье» сүзен аңлата алмавы нәтиҗәсендә килеп чыккан сугышка, бишьеллыкны совет властеның биш елда бетүе дип аңлаулары, Печән базары агайларының рус телен бозып сөйләүләрен көлке объекты итеп ала. Монда авторның позициясе татар милли зыялысының Печән базары татарлары русча белмәүләре, наданлыклары нәтиҗәсендә көлке хәлдә калуларын күрсәтүдән үтә алмый. Печән базары агай-энеләре рус телен өйрәнсәләр, «гыйлемлекләрен» күтәрсәләр, автор тынычланыр төсле иде. Авторның Печән базары типларына коммунизм принцибыннан торып карашы күренми.

Хәтта соңгы елларда язылган һәм сатира ягыннан гаять уңышлы булган «Советский намаз»[4] хикәясендә дә авторның нинди позициядән торып көлүен ачык аңлап булмый.

Ул хикәядә Рәми мөселманнарның Иван имамга ияреп намаз укуларыннан гына көлә төсле. Мөселман имамга ияреп укысалар, акчалы намаз булса да, автор возражать итмәс иде төсле.

Бу хикәядә Рәми Печән базарының, хосусый милек психологиясенең Печән базарына гына хас булган ваклыгыннан, пычраклыгыннан көлеп, Печән базары халыкларының бетәргә мәхкүм һәм яшәргә һичбер хакы булмаган хәшәрәтләр, җирәнгечләр икәнен ачарга тиешле иде. Хикәянең материалында моңар бик күп мөмкинлек бар. Ә автор көлү укларын бары руска ияреп намаз укучыны гына, тагын да положительныйрак алганда, акчага диннәрен сатуларыннан гына көлә төсле. Бит болай чын динле кеше дә көлә ала!

Рәминең «Казан зыярәтенә сәяхәт» дигән хикәясендә: «Тере кешеләр турында язганда була торган кайбер уңайсызлыклардан аз гына булса да котылып тору юлы белән зыярәткә киттем», – дигән җөмләсе бар. Бу җөмлә Рәмиевнең иҗаты турында күп нәрсә сөйли.

Бу хикәяләрне уку белән, дөрестән дә, Рәминең бүгенгегә кирәкле тематиканы алып язу мәсьүлиятеннән качарга тырышуын, үлекләр турында яки тере булып та бүгенге көндә һичбер төрле әһәмияте, актуальлеге булмаган социаль типлар, Печән базары турында язарга тырышуын ачык күреп була.

Рәминең үз сүзе белән әйткәндә, бу типларны биргәндә, мәсьүлият ул кадәр зур булмый дип уйлый. Әсәрләре моның киресен күрсәтә. Әһәмиятсез, мәсьүлиятсез темалар да авторның коммунистлар позициясендә тормавын ачык күрсәтә алалар.

Коммунистлар позициясендә торып тәнкыйть итә белгәндә, көлә белгәндә нинди генә мәсьүлиятле теманы алсаң да, бүгенгегә кирәкле сатира тудырып була.

Бүгенге көндә көлке объекты булып алынырлык, бүгенге социализм көрәше өчен актуальлекләре булган бик күп социаль типлар, социаль вакыйгалар бар. Бу типларны курыкмыйча сатира астына алырга мөмкин һәм алырга кирәк. Коммунистлар позициясеннән торып көләргә, һәм шулай иткәндә алар ул кадәр куркырлык авырлар да түгел. Киресе булса, билгеле, куркыныч. Рәми сатирасында менә бу нәрсә җитми.

Җыентыкка кергән хикәяләренең бик азын сайлап басарга мөмкин, ләкин бүгенге сатира турында сүз кузгату һәм бүгенге сатираның мондый төстә булырга тиешле түгелен матбугатта күрсәтү өчен!

## ШИГЫРЬЛӘР ТУРЫНДА БЕРАЗ ӘҢГӘМӘ

Соңгы елларда бездә рабкорлар хәрәкәте белән бергә редакцияләргә конверт-конверт шигырьләр елгасы ага башлады. Бу шигырьләрне күбрәк селькорлар, рабкорлар кебек эшче-крәстиян арасыннан күтәрелгән яшьләр язалар.

Шул шигырьләр белән беррәттән үк:

– Безнең шигырьләрне басмыйсыз, – дип туктаусыз үпкәләр дә ява. Бу үпкәләр, билгеле, урынсызрак. Чөнки килгән шигырьләр бик яхшы булганда да бит һәммәсен кертеп барырга хәл юк.

Ул язмаларның йөздән туксаны язу ягыннан начар йә идеологически пешеп җитмәгән булалар. Яки берсе язганны икенчесе тәкрарлап кына үтә.

Без монда берәр мисал алыйк. Бикмитов иптәш, әйтик, хатын-кызларны алга чакырып яза. Шигырендә болай ди:

Безнең бурыч: үзебезне һәм балаларны тәрбияләү,
Безнең кызыл байрак гаять югары күтәрелгән,
Көчсезләргә бүген үк ярдәм бирербез...
Иске тормышны үтәли чәнчеп алырбыз,
Алырбыз да яхшы гына җир астына салырбыз...
Сук: күтәреп табагач белән,
Чүлмәк белән! Чуен белән!
Әгәр дә ирең сиңа яхшы карамаса...
Без аңарга әйтербез: син ахмакланма, дип, –

ди. Хатын-кызга, син иректе дип, ирен чуен, табагач белән кыйнап үтерергә киңәш бирә.

Бу шигырь, билгеле, язылу ягыннан да, фикер бирү ягыннан да бик түбән, Советлар хөкүмәте хатын-кызларга «иреңне табагач белән кыйнап үтер» дип ирек биргәне юк. Бәлки, хокукыңны аяк астында таптатма, таптыйлар икән, синең хокукыңны яклаучы советлар суды, женотделлар бар, ди. Алар табагач белән кыйнамый да усал ирләрне җәзалый беләләр.

Язылу ягыннан бу бер дә шигырь түгел. Шигырьдә сүз агымлы булырга, шулай ук җөмлә ахырларының бәрелешләре бер-берсенә охшарга тиешле.

Бу шигырьдә коры лозунглар гына берсе артына берсе бәйләнешсез рәвештә тезелгәннәр.

Инде икенче шигырьләрне алыйк. Монысын селькор Базуков яза:

Дошманнарын партия көрәк белән көриләр,
Бетте дошман тамырысы дип, илдә тыныч яшиләр, –

ди. Монда сәяси хатасы бар.

Дошман әле безгә тыныч яшәргә бирерлек дәрәҗәдә җиңелгәне юк. Безнең тирә-ягыбыз әле дошманнар белән уралган. Һәм алар безгә һөҗүм итәргә генә торалар. Партия дә, дошман җиңелде инде дип, кулларын артка куеп тыныч йөрми. Ул шул дошманга каршы торыр өчен, аның фронтын җимерер өчен көн-төн хәзерләнә.

Безнең бит хуҗалыгыбызны күтәрүебез дә дошманга җиңдермәскә хәзерләнү дигән сүз.

Инде шигырьдәге җөмлә ахырларының бәрелешләре дә уңышсыз: «көриләр» белән «яшиләр» дигән җөмлә ахырлары музыкада төзелеш ягыннан иптәш сүзләр була алмыйлар. Бер фикерне шигырь белән әйтер өчен матуррак сүзләр җыярга һәм аларны тезә белергә кирәк.

Менә мондый мисаллар бик күп китерергә мөмкин. Кайбер иптәшләрнең шигырьләре матур гына була. Ләкин бик күп язылган нәрсәләрне тәкрарлау булуы өчен басылмыйлар. Мәсәлән, яшь язучыларыбыз күбрәк «Без – комсомоллар – алга барабыз!» дигән сүзне яки «Җимерәбез иске дөньяны» кебек бик күп сөйләгән, язылган нәрсәләрне тәкрарлыйлар.

Бер үк шигырьгә буржуйларны да, кулакларны да, сатлык социалистларны да, коммунизмны да, пролетариатны да, бөтен дөньяны кертеп бетерәләр; хәзер инде бу язу юлыннан хезмәт вакытларының аерым күренешләрен бирүгә күчәргә кирәк. Дүртьюллык шигырьдә бөтен дөньяны бутаганчы, кечкенә генә эш картинасын алып, бик матур, мәгънәле шигырьләр биреп була бит.

Аннан соң, шигырь язу ул һәркем каләм алуы белән үк булдыра торган нәрсә түгел. Ул бик күп эшләүне сорый.

Безнең журналга, газеталарга авылларда эшләнгән эшләр турындагы хәбәрләр язудан бигрәк, конверт-конверт шигырьләр җибәрәләр.

Селькор иптәшләрдән без, авылның эчке тормышын җентекләп тикшереп, мәкаләләр, хәбәрләр язуларын сорыйбыз.

Моның белән без шигырь язмагыз дигән нәрсәне әйтергә теләмибез. Шигырь язарга мөмкин, ләкин аны хәзерге төзелеп килә торган тормыштан алып, күп нәрсәләрне бутамый гына, матурлап язарга тырышырга кирәк. Аннан хәбәрләр, мәкаләләр язуны да арткы планга куймаска кирәк.

Менә безнең «Авыл яшьләре» журналында «Авылларда» дигән бүлек ачылды. Ләкин шунда кертергә хәбәрләр юклыктан аптырап бетәсең. Бу кимчелекне селькор иптәшләр тутырырга тиешләр.

**«ӘРӘ ЕГЕТЕ» ҮЛДЕ**

«Әрә егете» – Исмәгыйль Закири[1] иптәш – авыл шагыйрьләренең, авыл җырчыларының киң матбугат дөньясына чыгучыларыннан берсе иде. Мин аның кулъязмаларын беренче кат «Чаян»[2] журналында эшләгән вакытта очраттым. Ул вакытта аның матбугатка чыгарга омтылган вакытлары иде әле. Язган әсәрләре бөтенесе авыл җырлары калыбында. Җырларының мөндәриҗәләре авыл кулакларыннан, авыл муллаларыннан көлү, алар авызыннан аһ-зар әйттерү иде. Соңыннан төрле газета-журналларда аның кызыл гаскәр вә башка шундый көндәлек мәсьәләләр турында җырлары очраштыргалый башлады. 25 нче елны «Авыл яшьләре» журналы чыга башлагач, ул редакциягә шундый бер хат җибәрде[3]:

*«Редактор иптәш!*

*Әүвәле сезгә чын иптәшлек сәламнәре сөйлим.*

*Соңра сезгә үземнең кем икәнлегемне белдерим.*

*Мин үзем авылда чын авыл тормышына үзләшеп, авыл тәрбиясе белән сугарылып, иң фәкыйрь, кечкенә, салам башлы өйдә торган бер семьяда үскән, нечкә табигатьле крәстиян баласымын. Мин кече яшьтән үк бөтен халыкның, ярлы халыкларның аһ-зарларын, фөрьядларын җырларга кушып җырлый торган булдым. Электә мин халыкларның аһ-зарларын җырлаган булсам, хәзер ул зарлануны ташлап, революциядән соң авыл халыкларының, авыл яшьләренең киләчәккә өмет күзләре белән карауларын, шатлануларын җырлый башладым.*

*Мин хәзер яңа тормыш өчен яңа җырларны шатлана-шатлана җырлый башлыйм».*

Һәм безнең журналга[4] түбәндәге җырларны җибәргән:

Аккош кунар күлләргә,
Былбыл куна гөлләргә.
Җырлый-җырлый без барабыз
Алдагы ак көннәргә...
Көнне ямьли кояш нуры,
Төнне ямьли ай нуры,
Уфтанмыйбыз, кайгырмыйбыз,
Ак бәхеткә юл туры.

Шул хаттан соң ул безнең журналга һәрвакыт җырлар җибәрә башлады.

Ул үзенең матур җырларында авылның йөрәгенә менә нәрсәләр сөйләде:

Якты ак тормыш төзербез
Үзебез тапкан табышка,
Никах безгә кирәк түгел,
Әйдә, җаным, загска!

Безнең илләр – сахра җирләр,
Сахра җирләрдә гөлләр,
Гөлләр кебек, ямьле, матур
Безнең алдагы көннәр...

Очрадым таң җилләренә,
Бәрелә җиңнәремә,
Кызыл яулык чигеп бирдем
Комсомол чибәремә.

Бара торгач юл белән,
Юлым китте сул белән,
Ташламый, шулай барырбыз
Ленин кушкан юл белән...

Исмәгыйль иптәш авылча, үзенең җырларында авыл гөлләренә, арыш башакларына урап, кызыл байракны җырлады.

Ул үзенең матур теле, бай образлары белән авылның йөрәгенә яңа уйлар, яңа фикерләр сеңдерде.

---

25 нче елның көзендә мин «Авыл яшьләре» редакциясендә утырадыр идем. Бүлмәгә берәү, аксый-аксый, Такташны эзләп керде.

– Эзли торганыгыз – мин! – дигәч, үзенең фамилиясен әйтте.

Без аның белән тиз дуслашып киттек. Журналга рәсемен басарга сорадым, һәм аның белән Эрмитаж бакчасындагы Комклуб фотографына[5] киттек. Юлда ул үзенең империалистлар сугышында[6] булуын, соңыннан кызыл гаскәрдә йөрүләрен һәм фронтларда бик нык салкын тиереп ревматизм алуын, хәзер аксый-туксый Казан больницасына килүен сөйләде. Шуннан соң аның белән очрашмадык. Больницадан ул бер хат та язмады. Бары бер-ике айдан соң гына аягын ботыннан алып кистерүен һәм авылга кайтып китүен генә белдереп бер хат килде. Аягын кистергәннән соң да, ул, сирәк булса да, безгә җырларын җибәреп торды.

26 нчы елның яз башында бугай, мин аны инде аяксыз килеш очраттым. Бу юлы инде аның яңаклары эчкә баткан, сүзләрендә дә ара-тирә рухсызлык ишетелә иде.

Ул акчасызлыктан, икътисади ягы начарлыктан берничә зарланып алды. Соңыннан үзенең каядыр (хәтерләмим) наборщик булып эшләвен, «хәзер дә керер идем дә, аяксыз эшләп булмас»лыгын сөйләде.

Артык очратмадым. Бары ара-тирә, хәле начарлыгын белдереп, хатлары, җырлары гына килеп торды.

Бүген инде аның туберкулездан үлүен хәбәр иттеләр.

Мин үлеләр турында язарга яратмыйм, ләкин Исмәгыйль иптәш ул үлек түгел.

Авыл комсомоллары аның җырларын җырлыйлар, эшчән авыл кызларының телендә «Әрә егете»нең җырлары.

Исмәгыйль иптәш безнең арабыздан иртә югалды. Үпкәләренә утырган кох палочкалары аны безнең арабыздан иртә алып китте. Эсперантский[7] да туберкулездан үлгән иде. Тагын берничә талантлы язучыларыбыз чиратта тора.

Бүген талантлы авыл шагыйре «Әрә егете»нең кабере өстендә без, авыл шагыйрьләре, кайгы белән башларыбызны иябез.

Һәм аның мактап җырлаган кызыл байрагын каберенә куябыз.

Исмәгыйль иптәшнең байтак кына басылган, күп кенә басылмаган җырлары бар. Акадцентр, аның язуларын җыеп, бер китап итеп бастырса һәм гонорарын хәзерге көндә авылдагы атасы белән анасына җибәрсә, яхшы булыр иде.

## ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАР МАТБУГАТЫ

Татар революция матбугаты «Урал»[1] газетасының беренче номеры чыккан көннән үзенең тарихын башлый. Шушы көннән алып изелгән, хокуксызландырылган татар пролетариаты үзенең корал белән алынырга тиешле теләкләрен матбугатта кычкыра башлады.

Менә шул көнгә 17 гыйнварда егерме ел тулды. Егерме еллык татар матбугаты тарихы үзенең мөндәриҗәсенә күпеллык сыйнфый теләкләре белән капма-каршы булган әллә ничә төрле газета-журналларны да ала.

Бу газеталарның күбесенең теләге буржуа – вак буржуа теләге:

– татар милләтен рәзаләттән коткару;

– милләтебезне-динебезне саклау;

– милләтебезне тәрәккый иттерү һәм башкалар иде.

Бу газеталар татар милләтен коткару юлында үзләренчә төрле юллар күрсәттеләр, үзләренең идеологияләрен сеңдерергә тырыштылар.

Ләкин алар арасында үзенең теләге белән бик нык аерылучы татар эшче-крәстияннәрен караңгылыктан, коллыктан коткару юлында туры юл күрсәтүче бердәнбер большевик газетасы булса, ул да «Урал» газетасы иде.

«Урал» газетасы ул – пролетариат сыйныфы газетасы, ул киләчәктә, әлбәттә, бер җиңәчәк пролетариат сыйныфының теләкләрен таратырга тырышты. Һәм егерме еллык тарихи көрәштә «Урал»ның теләкләре эшкә ашуын күрдек. Егерме ел татар буржуасын үзен дә, матбугатын да җимерде.

Без бу мәкаләдә, башка газета-журналларга артык тукталмый, татар хатын-кызлары турында чыккан матбугатка тукталып үтәбез.

13 нче елга кадәр татар хатын-кызлары өчен аерым газета, журнал чыкмады. Ләкин бишенче елдан алып чыга башлаган буржуа, вак буржуа газеталарында хатын-кызларны хиҗабтан азат итү, хатын-кызларны укыту вә башка шуның кебек мәсьәләләр күп язылды. Күп шау-шулар күтәрде. Уральскида чыгып килгән «Фикер»[2] газетасы хиҗаб мәсьәләләрендә муллаларга карата чын күңелдән сугыш ачты. Шуның аркасында аның тиражы да югары гына күтәрелгән иде. Аңардан башка газеталарда ара-тирә бу хакта мәкаләләр басылгалады. «Урал» газетасы монда да марксизм нигезеннән чыгып хатын-кызларның хокуклары, аларның ирләр белән һәр яктан тигез булулары фикере белән алга чыкты. Ләкин кыска гомере аңарда хатын-кызлар турында күп язарга ирек бирмәде.

Соң елларга таба татар хатын-кызларыннан Европа тәрбиясе күргән татар мадмуазельләре, хатын-кыз зыялылары җитештерү шул вакыттагы кайбер буржуа язучыларының идеалы булып китә язды. Моның тәэсире матур әдәбиятта да күренде. Фатих Әмирхан[3] үзенең романнарында нәфис хәрәкәтле, нәзакәтле, Европа тәрбиясе күргән курсисткалар, сөйләшә, итенә белә торган мәхбүбәләр тудыру идеалы белән янды.

13 нче елда чыга башлаган «Сөембикә»[4] журналы битләрендә сакаллы хатын язучылар[5] чын милләт хатыны, чын милләт анасы, чын йорт хуҗасы тудыру юлында эшләделәр, «озын кара толымлы, сихерле күзле, илаһи фәрештә» кебек милли кызларның милли егетләргә булган гыйшык-мәхәббәтләрен матурлап яздылар.

Хатын-кызны сөяргә, сөелергә, соңыннан шәригатьчә яхшы ана итеп тәрбияләргә тырыштылар.

«Сөембикә» журналы Февраль революциясендә зур бер мәсьәлә итеп «хатын-кызларның мәчеткә йөрү-йөрмәве»н күтәреп чыкты.

Бу журналның ирләрдән башка буржуа идеологиясе белән янган Багъбостан[6], Фәхрелбанат Сөләймания[7], Маһруй Мозаффари[8] кебек хатын-кыз язучылары да җитешкән иде.

18 нче елда чыга башлаган «Шәрекъ кызы»[9] журналы үзенең идеологиясе, теләкләре, хезмәте белән «Сөембикә»дән аерылмады. Бу Русия мөслимәләре мәркәз бюросы тарафыннан чыгарылган әдәби, иҗтимагый, фәнни, икътисади, сәяси журнал: һәрбер хатынга кирәкле булган тышкы матурлыкларына, җыйнаклыкларына хезмәт итте. Революцияне «Илаһым, артык тирәнәймәсә иде!» дип дога белән каршы алды (6 нчы номер).

Моннан башка 17 нче елда Әстерханда «Азат ханым»[10] дигән бер журнал чыкты. «Сөембикә», «Шәрекъ кызы» журналлары кебек бу журнал да хатын-кызларның хокукларын шәригать ягында чишәргә маташты. «Җәнабе Хакның хатыннарны тәне белән ким яратуында мәгънәви бер сер, бөек хикмәтләр бар» дигәндәй көлке фәлсәфәләр бу журналның битендә күп кенә урын алды.

Октябрь революциясеннән соң 26 нчы елга кадәр татар хатын-кызлары өчен аерым газета-журналлар чыкмады.

Октябрь үзе белән хатын-кызларга хәзергә кадәр бер хөкүмәттә дә булмаган ирек алып килде. Бу ирек Коммунистлар партиясенең юлбашчылыгы астында эшкә ашырылып килә.

Советлар хөкүмәтенең матди хәле хәзергә кадәр татар хатын-кызлары өчен аерым газета-журнал чыгарырга ирек бирмәде. Шулай да татар телендәге һәрбер газета хатын-кызлар мәсьәләсенә бик күп урын бирде. Газеталарда аерым «хатын-кыз сәхифәләре» чыгып килде һәм дәвам итә. Ләкин хәзерге көндә күтәрелеп килә торган хатын-кызлар хәрәкәте ташкыны аерым сәхифәләргә генә сыярлык түгел. Менә шушы нәрсәләр татар телендә хатын-кызлар өчен аерым журнал чыгару мәҗбүриятен китереп чыгардылар.

1926 елның августында Татарстан областькомы каршындагы хатын-кызлар бүлеге «Азат хатын»[11] журналын чыгару чарасына кереште. Хәзерге көндә инде без бу журналның бишенче номеры чыкканын күрәбез. «Азат хатын» журналы үзенең алдына «Сөембикә», «Шәрекъ кызы», «Азат ханым» журналлары кебек «милләт аналары» – Европа тәрбиясе күргән татар мадмуазельләре, җанлы шәригать курчаклары җитештерүне куймый.

«Азат хатын»ның алдына куйган бурычлары башка. Ул эшче-крәстиян хатын-кызларын сәяси тәрбияләүне, хатын-кызлардан ирләр белән хокукта бертигез җәмәгать әгъзалары җитештерү юлында юлбашчылык итүне алдына куя.

«Азат хатын» – эшче-крәстиян хатын-кызлары журналы. Аның бурычлары аның көндәлек мәсьәләләренә нигезләнгән. «Азат хатын» журналы «Сөембикә» журналлары кебек хатын-кызлардан оста аш пешерүче аерым гаилә аналары гына җитештерү юлында эшләми. «Азат хатын»ның беренче һәм алдынгы бурычы хатын-кызны иске казан, чуен гаиләсеннән җәмәгать эшенә, производствога, икътисади азатлыкка чыгару, аерым кухняларны бетереп, гомуми ашханәләргә күчерү. Һәм шуның белән [ул] хатын-кызны ирекле җәмәгать тормышына алып чыгу юлында юлбашчылык итә – моны тирәнәйтәсе генә бар.

Хәзерге көндә журналга катнашучы эшче-крәстиян хатын-кыз язучыларының саны көннән-көн үсә, тик аларга тәрбия бирергә, аларны оештырырга гына кала. Журнал бу нәрсәне, билгеле, эшләр. Журналның чыгып таралган номерлары үзенең техникасының матурлыгы белән дә хәзерге көндә чыгып килгән журналлардан бик нык аерыла. Тик рәсемнәрен күбәйтәсе, кайбер бүлекләрне киңәйтәсе генә бар. Моның өчен хатын-кыз язучыларның бик нык катнашы кирәк. Журналның бай, матур чыгуы өчен тагын бер нәрсә кирәк, ул да – журналны тарату, аның басылу санын җиде-сигез меңнәргә җиткерү. Бу эшнең 50 процентын гына эшләгәндә дә тулы, бай бер журнал чыгарып булачак.

**ҮЗЕМ ҺӘМ БАШКАЛАР ТУРЫНДА**

Дыр-дыр дырабан,

Мокамай йомырка урлаган,
Әйшә тәтәй тоткан,
Караулны кычкырткан.

Бу минем беренче шигырь. Җиде яшемдә вакытта минем бөтен гомерем буена тирән бер авыр, сагынулы эз калдырган батрак улы Мөхәммәтҗан – Мокамай исемле бер иптәшем бар иде. Аның белән дус кына торганда, ничектер борынлашырга туры килде. Икенче көнне аның Гайшә тәтәйнең оясына кереп йомырка урлаганда тотылганы мәгълүм булды. Мин, аңардан үч алу нияте белән, шушы беренче шигыремне чыгардым. Хәзер дә әле хәтеремдә: язгы ташкын вакытында ул, муеннан суга кереп, атасының кыйнавыннан куркып, көн буе суда торды. Ә без, авыл малайлары, жыелып, бүрәнәләр өстенә утырып, мин чыгарган шушы такмакны җырлап утырдык.

Соңгы елларда аның тәгәрмәчләр урлап, Сыркыды[1] халкы тарафыннан кыйналып, идән астына ябылгач, кесәсендә калган пычагы белән үзен-үзе үтерүе турында хәбәр иттеләр[2]. Күземә яшьләр килде. Миңа беренче шигыремне илһам итүче минем иң якын дустым Мокамай шулай үлгән.

Соңга табан авыл җырчысы булып киттем. Минем җырларны әле дә Сыркыдыда җырлыйлар бугай. Минем шагыйрьлегемә әниемнең дә зур тәэсире бар[3]. Әнием ике сеңеле, бер абыйсы белән яшьләй ятим калганнар. Алар өчесе дә укый, яза белә булганнар. (Ләкин кайдан өйрәнгәннәр, моны әле һаман белгәнем юк.) Ул вакытта Сыркыдыда укый-яза белүче хатын-кызлар бишәү генә булганнар. Шуның өчен болар язын кешедә ачлы-туклы урак урып, кеше балалары укытып, читтә йөргән кешеләргә хатлар язып, алардан килгән хатларны укып көн күргәннәр. Авылның бөтен серләре аларда булган. Авылда булган фаҗигале вакыйгаларга җырлар чыгаручы өч сеңел булганнар. Әни хәзер дә әле миңа язган хатларын җырлар белән яза. Ләкин ул үзенең җырчы икәнен белми. Унөч-ундүрт яшемдә мәктәпкә эләгеп[4], ниндидер гөнаһ шомлыгы белән, әдәбият белән танышырга туры килде. Шуннан инде чынлап шигырь яза башладым. Элек бик зур, бөтен дөньяга мәшһүр шагыйрь булырмын дип уйлый идем. Тора-бара бөтендөнья әдәбияты белән никадәр якыннан таныша барсам, шулкадәр ул теләгемнең ерагая барганын сиздем. Хәзер инде «булып булмастыр, ахры» дим. Егерме ике яшемә кадәр язган шигырьләремне яндыра бардым. Чөнки мин ул шигырьләрне Тукайдан да яхшы, Сәгыйть Рәми[5] шигырьләреннән дә ким түгел, ләкин оригиналь нәрсәләр дип тә уйлый алмый идем.

Егерме ике яшемнән үз өслүбем, үз аһәңчә үземчәлекне сиздем[6]. Шуннан соң шигырь яндырудан туктадым. Татар әдәбиятын аз укыйм. Татар шагыйрьләреннән яратып укыганнарымның берсе – Кави Нәҗми[7]. Без аның белән «Безнең юл»[8] журналында бергә үстек. Аңарда оста бер җанландыру көче бар. Ул чын художникларча тормышка карый белә. Шагыйрьләр генә күрә ала торган тормыштагы вак бриллиантларны җыя белә. Ләкин аның кайбер әсәрләре күп вакытта даһиларча ясалган декорация эчендә татар артистлары уйнаган пьесага охшыйлар.

Соңгы вакытта Туфан[9] үзенең шигырьләре эчендәге сирәк, ләкин яшь яңа хисләре, күп вакытта гакыллы тирән хисләре белән җанга җылылык кертә башлады. Аңарда зәңгәр яшьлек хисләре бөдрәләнә. Чәчәгеннән бигрәк, җимешле агач булыр ул. Тик техникасы эчне пошыра. Минемчә, шагыйрь үзенең техникасы белән оригиналь талант, көчле талант булып танылмый. Шагыйрь үзенең яңа, хәзергә кадәр әйтелмәгән хисләре, фикере белән укучыларны үзенә карата, сөйдерә ала.

Кутуйны[10] мин башта бик ярата дыр идем. Аңарда шул югарыдагы яңа, яхшы хисләр мине тарткан иде. Ул шул юлы белән барганда, ашыгып, пешереп җитмәгән шигырьләрен матбугатка чыгарырга ашыкмаганда, үсәр, якты бер йолдыз булыр иде. Ләкин ул безне дә бераз алдады, аны футуризм принциплары үтерә язды[11]. Башка язучыларны укымыйм.

Тәнкыйть турында язар идем, бездә яхшы тәнкыйть юк. Бездә тәнкыйтьчеләр шагыйрьләрне надан дип сүгәләр, шагыйрьләр – тәнкыйтьчеләрне. Моның, бәлки, икесе дә дөрестер. Бездә тәнкыйтьчеләр, күп вакытта маңлай тире түгелеп, нечкә кораллар белән эшләнгән матур йортларны тикшереп чыгар өчен кергәндә, күп вакытта балта белән эш итәләр. Ишектән керәсе җирдә диварга тишек тишеп, тишектән керәләр. Кайсы нәрсәне сүгәләр, сүгәргә тиешле нәрсәне мактыйлар. Мин үзем ул халыкны бик үк яратып бетермим. Үзем турында язылган тәнкыйтьләрне, нәрсә язалар икән дип, настроением һәйбәт булганда гына укыйм. Берәр файдасы булыр, төзәттерү нияте белән берәр кимчелекне төзәтер дигән ышану юк әле миндә. Каракны никадәр кыйнап та үтермәсәң, барыбер урлый дигәндәй, шагыйрьне теләсәң күпме кыйнап та үтереп ташламасаң, барыбер яза икән ул.

Минем турыда урынсыз надан тәнкыйтьләр күп булды. Киләчәктә дә үтереп куймасалар, уйлап-уйлап торып та язгалармын, ахры.

Мин ара-тирә тормышта алдалашсам да, җырларымда бер генә булсын ялганламадым. Шул ялганламау өчен миңа күп эләкте. Минем табигый үсүемне аңламаган кешеләр күп сүгенделәр, хәзер дә мактамыйлар. Шагыйрь ул элек шигырьне үзенең тормышында тудырырга тиеш. Тормышы төрле гакыллы-гакылсыз вакыйгаларга ярлы булган кеше шагыйрь була алмый.

Мин үземне шагыйрь итеп кулыма каләм алган чакта гына таныйм. Ул вакытта мин меңнәрчә йөрәкләрнең кылларын үземнең кулымда хис итәм. Ул кылларны теләгәнчә чиртә алуыма ышанам. Шуның өчен дә ялганламыйм. Шуның өчен дә, ул кыллар белән уйнамаска теләп, үземнең шигырьләремне төннәр буе эшлим.

Мин үземне язган вакытта гына иң бәхетле – иң бай кеше итеп хис итәм, чөнки мин атналар буенча укучыларымның йөзләреннән, күзләреннән, йөрәкләреннән урлап җыеп йөргән байлыкны үзләренә кайтарып бирәм.

Ләкин мин бик аз язам. Тормыш, көнкүреш, яшәү өчен көрәш моңа ирек бирми. 75 процент көч шуңарга китә. Ә калган 25 процент белән матур шигырь язу мәсьүлиятен үз өстемә ала алмый йөрим.

«Безнең юл» мине үстерде[12]. «Безнең юл» минем үсү бишегем иде. «Безнең юл»ның бәйрәме – минем һәм күпләрнең яхшы бәйрәме.

## ХАТЫНСЫЗ АЙ, ТОТНАКСЫЗ ТӘНКЫЙТЬ

Матбугат, әдәбият дөньясында сакланып килгән традицияләр буенча мөхәррирнең яки бер шагыйрьнең үзенең әсәрләренә язылган тәнкыйтьләргә каршы чыгу гадәте булмаса да, бу нәрсә гаеп саналса да, гафу итегез, мин ул традицияне җимерергә мәҗбүр булам. Беренчедән, матбугаты киң булган милләтләрдә бер тәнкыйтьче бер шагыйрьнең иҗатын тикшергәндә, тәнкыйтьче ялгышлар ычкындырса, аның ялгышларын күрсәтүче икенче тәнкыйтьчеләре табыла. Бездә аның ялгышларын ычкындыручы «тәнкыйтьчеләр»ебез булса да, тәнкыйтьчеләрнең ялгышларын төзәтүче тәнкыйтьчеләребез юк. Аларның юклыгы бездә әдәбиятның тарлыгыннан, тәнкыйть белән «тамак туйдырып булмау» мәҗбүриятеннән килә.

Шуның өчен дә бездә «тәнкыйть» дип язылган бик күп надан нәрсәләр газета битендә урын алалар – дөрес караш булып калалар. Язучылары гонорар алалар, сүгүче булмагач, тагы язалар. Ләкин алар үзләренең әсәрләрендә мәсьүлият хис итмиләр. Моңа кыска гына мисал китерәм. «Безнең юл»ның ... нчы номерында минем Тамбов урманнары белән саубуллашу шигыре чыкты[1]. Шул шигырьгә тәнкыйть язучы Парсин[2] иптәш «Такташның бу саубуллашуы Есенинның[3] «Баку белән саубуллашуына охшый» ди. Мин, тәнкыйть язучы иптәшне очратып:

– Мин сине ул шигырьне укыгансыңдыр дип уйлый алмыйм. Шулай да әйт әле, кай җире Есенинның «Баку белән саубуллашуы»на охшый? – дип сорадым.

Ул миңа:

– Үзең укып-тикшереп чык, – диде.

Бик сорый торгач:

– Есенин да «Прощай, Баку, прощай!» дип язган. Син дә «Сау булыгыз инде, сау булыгыз!» дип язгансың, – ди.

Соңыннан аның ул шигырьне бөтенләй күрмәвен, бары «берәүнең әйтүе буенча гына» язуын аңладым. Менә бездә тәнкыйть күп вакытта шулай тикшерү, шундый әһәмият белән языла, – теләсәң, шагыйрь өстенә зур-зур гына кара таплар да ташлана.

Парсин иптәш:

– Бу шигырь Есениннан тәрҗемә ителгән дә, Такташ фамилиясен генә куйган, – дип язса да, шулай ук хакыйкать булып китәр иде. Шагыйрь аның ялганын күрсәтеп үзе чыкмаса, чыгучылар булмас иде дип уйлыйм.

Мин моны [...] шагыйрьләрнең яклаучысы булмауларына, «тәнкыйтьчеләребезнең» бик артык тикшереп язмауларына мисал өчен генә китердем.

Матбугатта: «Татар әдәбиятында беркемгә булмаган шау-шуларга мөяссәр булган шагыйрь кеше», «Такташ ул бик күп иркәләүләрне, бик күп мактауларны күргән шагыйрь, күп яктан ул беренче урынны тота торгандыр...» – дип, минем хакта бик күп яздылар. Дөресрәк, бик күп сүктеләр. Миңа язылган чиксез тәнкыйтьнең эченә кереп тикшерә башласаң, кызык бер нәрсә күренә:

– Такташ – талантлы шагыйрь, Такташ – үткен телле, диңгез кебек хыялга бай шагыйрь, – диләр дә, артыннан ук шигырь эчендә булган иң сәләмә җөмләләрне алып сүгә башлыйлар. Мисал сезгә:

Г.Гозәеров иптәш «Давылдан соң»га булган тәнкыйтендә[4] (1925, август, «Эшче» газетасы) шигырьнең башындагы

Минем геройларым кабакларда
Чәнчелгәнче сыра эчәләр,
Эшсез, урам даһилары минем
Геройларым...

дигән җөмләләрне ала да «Такташ хәзерге тормышның темасын, геройларын күрми» дип дөнья җимерә, сүгенә. Ләкин поэма эчендәге ике тормышка параллель бару, кабак типлары бер якта торып, икенче якта байрак илтүче комсомоллар тасвир ителүне күрми, андагы Такташның төп мотивы булган:

Туачак көн якты,
Тарих канаты безне алып бара,
Без туачак тормыш сызыгында,
Бәлки, үләрбез.
Ләкин, бөтендөнья азатлыгы ишеген ачып,
Җир йолдызын азат итәрбез! –

дигән җырны да ишетми.

Мондый тәнкыйтьләрнең чиге юк. Бер җөмләне алалар да, аның төп мотивы – шигырьнең аккордын сызып ташлап, сүгәргә тотыналар.

Менә минем алдымда алты ел буена язылып килгән тәнкыйтьләр ята. Алар, бер-берсеннән уздырышып, минем кимчелекләрне күрсәтергә омтылалар, казыналар, мәгънәләрнең койрыкларын кисеп, эттән куян чыгарырга маташалар, ә иҗаби булган чын мотивлар сүндереләләр. Иң соңыннан минем башка: «Мин, күрәсең, талантлы шагыйрь, ләкин кимчелекләрдән генә гыйбарәт булгач, ничек талантлы да шагыйрь булам инде?» дигән уй килә. Минем иҗаби якларым «талантлы шагыйрь» диюдән башка бернәрсәдә күргәзелгәне юк.

Бу нәрсәләрне мин сүз туры килгәнгә генә яздым. Мине хатны язарга мәҗбүр иткән нәрсә – Галимҗан Нигъмәти[5] иптәшнең 25 июнь, 27 нче елда «Кызыл Татарстан» газетасында язылган «Нәни разбойник, хатынсыз ай һәм бераз гына мужик фәлсәфәсе турында» дигән мәкаләсе. Галимҗан иптәшнең мәкаләләре, гомумән, цитаталардан гыйбарәт була. Кайчакта «Нигъмәтинең үз фикере бармы икән» дигән бер фикергә киләдер идем. Соңгы мәкаләсендә, ниһаять, үз фикерен дә күрергә туры килде... Мәкаләнең башында «бездә бер дә кузгалмаган быт мәсьәләсе турында» сөйләргә вәгъдә биреп, руслардагы есенинчылыкка күчә. Аннан Есенин турында берничә цитатадан соң татарда да шуның эзе барлыгын әйтеп китә һәм язучыларыбызның пессимистлыклары турында сөйләшмәкче булып минем койрыкка килеп ябыша:

–Такташның соңгы көннәрдәге яратып язган мәүзугы нәни хулиганлык, казлар, мәчеләр кыйнау турында булды. Аның яратып тыңлана һәм укыла торган шигырьләренең берсе «Нәни разбойник» булып, анда үзенең әтәч урлау, үрдәк һәм ата казлар кыйнап үскән малай чагын сагына, – ди. Аннары Такташның «Нәни разбойнигы»на[6] ияреп китүчеләр турында сөйли.

Минем «Нәни разбойник» чыгу белән, билгеле, бик нык шауладылар. Ләкин аның шаулавы, берничә иптәш, шулай ук Галимҗан иптәш әйткән кебек, «нәни хулиганлык» турында булуы өчен түгел, бәлки икенче нәрсәдә.

– Син авылда туганмы?

– Авылда.

– Сезнең авыл матур урындамы, су бармы?

– Безнең авылның яныннан ук ... суы ага.

– Алай булгач, сездә казлар да очрый торганнардыр?

– Их, син минем казлар саклап үткән малай чакны искә төшерәсең.

– Ә син ата казларны кыйный идеңме?

– Элек, көч юкта, алар мине үзләре әләктереп, тәнемне күгәрткәнче бирәләр иде, соңыннан үзләренә эләгә иде.

– Казлар үтергәнең бармы?

– Бар.

– Ни өчен?

– Чөнки бакчага һичбер кәбестә, солы, бәрәңге чәчәр хәл юк, җыелып киләләр дә кыркалар да чыгып китәләр. Биздерер өчен бераз биргәләгәндә, берәрсенең башына эләгеп, ялгыш үлгәлиләр иде.

Менә шул анкетаны авылда үскән кемнән генә тутыртсаң да, ул шул җавапны бирер. Бу авылда үскән авыл малаеның биш-алты яшьтән алып ун яшенә кадәр булган тәрҗемәи хәле, «Нәни разбойник» шигыренең бу юллары меңнәрнең башына шул тәрбиясез яшьлеген, кызык яшьлеген искә төшергәндер.

Казлар кыйнап үскән меңнәрчә кешеләр хәзер партия сафында бөек көрәшнең солдатлары. Шуларның берсе Такташ – хәзерге көндә «назлы, мактаулы» шагыйрь. Ул, Галимҗан әйтмешли, нәни хулиганлыгын сагына түгел, бүгенгесе белән чагыштырып кына карый. Элек ул казлар кыйнап үскән, хәзер:

Ерак калмый инде майга да,
Яз ясарбыз салкын тайгада,
Җир безнеке булыр,
Ачулансак,
Шлем киертербез айга да![7] –

дип җырлый. Аны болай җырларга Ленин өйрәтте. Галимҗан иптәш казып чыгарырга тырышкан пессимизм да юк анда. Киресенчә, анда артык оптимистлык. Андагы оптимист айга шлем киертүгә кадәр күтәрелә. Ләкин Галимҗан иптәш моннан күз йома, ни өчендер аңа Такташның койрыгына хулиганлыкны тагу кирәк... Ул мәкаләсенең бер җирендә, югарыда әйтеп киткәнчә: «Такташ соңгы көннәрдә нәни хулиганлык, казлар, мәчеләр кыйнау турында сөеп язды», – ди. Шулай гынамы икән?

Соңгы вакытта язылган «нәни хулиганлык» шигырьләренең төп мотивларын алыйк:

Авылыбызга кайткач,
Шәһәрләрен
Яратмадык, диеп әйтербез,
Ләкин
Шәһәр гудоклары безне чакырып
Көрәш тавышы белән үкерсә,
Очкын атлар безгә ВКПның
Чакыру әмерен тагын китерсә,
Без шәһәргә кире кайтырбыз[8].

(*«Авылга кайту»*)

Шагыйрь булмагыз сез,
Өйрәнегез җирне машинада эшләргә...
.....................
Бүген әле урам буйлап үткән чакта,
Очраттым мин аның бересен!
Ал галстук таккан, янар күзле,
Киләчәкнең тимер кешесен[9].

(*«Казлар турында»*)

Такташның казлар саклап йөргән авылы урамында хәзер янар күзле, киләчәкнең тимер кешесе йөри. Такташ аны күрә, Галимҗан иптәш булса, күрми үтә:

Ташла, мөәзин дустым, манараңны,
Әйдә киттек балык тотарга[10].

Барыбер тормыш башка эздән ага, барыбер киләчәктә сезгә башка эш калмас, халыкның аңы күтәрелер:

Агач сука йөргән яланнарда
Тимер тракторлар юргалар,
Елга буйларында балык эзләп
Чабып йөрер мөәзин, муллалар.

(*«Шәһәр җыры»*)

Гаҗәпләнмә, авыл, синең улың шәһәр җырын җырлый: «Кузгал, уян, ләгънәт ителгән...»[11] – ди.

Син дә шуны җырла.

Бу юллар да, иптәш Галимҗанча, «нәни хулиганлык»мы?

Галимҗан оптимистлык белән хулиганлыкны бутап йөртә. Ул хәтта көлүдә дә хулиганлык күрә. Бу үзе ненормальность.

Халык шаблоннан ялыкты. Бүгенгене ялангач килеш җырлаудан туйды. Шуның өчен дә мин соңгы вакытларда төп мотивларымны матур декорацияләр, күп вакытта көлке элементлар белән урап яза башладым.

Мәчеләр, казларны көлке позаларга куеп, урталарына авылның бәхетле киләчәген җырлаучы тракторны китереп куям. Бу инде, Галимҗан абыйча, нәнилек була.

Урамда авызын ачып елап утырган песи малаена көлке сүзләр сөйләгәннең соңында кешелекнең ахырына балта чабучы, хатын-кызларның бөтен сәламәтлекләрен җимерүче аборт хакында сөйлим икән – бу да нәнилекме? Галимҗан иптәшнең үзенең эшенә артык әһәмиятсез каравын мәкаләсенең соңына табан тагын бер мәртәбә күреп була. Ул «Мәхәббәт тәүбәсе»[12] турында аннан-моннан элеп берничә сүз ала да, «Ана – бөек исем, хатын-кызның бөтен матурлыгы... ана булуда» дигән җөмләләр турында: «Такташ тормышның иҗаби якларына бәя бирү мәсьәләсендә тагын үзенә күрә нәнилек күрсәтә», – ди.

Монысы инде бөтенләй аңлашылмый. Әгәр минем мондагы хатын-кызга карашымны ялгыш дигән булса, ул хакта әле бәхәс ачар идек. Ләкин «нәнилек – хулиганлык» диюе белән Галимҗан иптәш, монда үзенең хулиганлыкны (русның бик гади сүзе булса да) аңламавын күрсәтеп, көлкегә кала.

Галимҗан иптәш, югарыда әйткәнчә, күп вакытта мәгънәне пьесадан эзләми, декорациядән эзләп бутала. Ул бу мәкаләсендә [...] минем пессимистлык турында «Мәхәббәт тәүбәсе»ннән:

Ай ялгыз ул, карт көнендә
Өйләнә алмый калган, шуның өчен

Кайгы нуры күренә йөзендә, –

юлларын китереп, «проблемага өметсез рәвештә кул селти», – ди.

Мин Галимҗан иптәшнең әдәбият белән бик нык таныш булуы турында шөбһәләнмим. Ләкин әдәбиятны тикшереп бәя бирә белүе турында бәхәс ачарга туры килә. Чөнки ул күп вакытта, югарыда әйткәнемчә, көлке элементлар белән драматический элементларны бутый. Төп фикер белән ярдәмче фикерләрне саташтыра.

«Мәхәббәт тәүбәсе»ндә минем төп элемент ай түгел, бәлки Зөбәйдә белән Мәхмүт. Аларның трагедияле мәхәббәтләре килешү белән бетә. Алар өйләнеп тора башлыйлар, ә ай һаман хатынсыз кала. Ай бөтен поэма буена декорация, көлке элемент булып бара. Поэманың соңында да шулай кала. Ә Галимҗан иптәш, бәхетсез айны өйләндереп, поэманы бетерергә теләгән. Аныңча, өйләндереп куйсам, проблемага өметсез рәвештә карамаган булыр идем, күрәсең...

Ашыгып мәкалә язарга ярамый. Миндә пессимистлыкны күрсәтү өчен төплерәк тикшерену кирәк иде. Мондый гына фактларга таянып үлемгә хөкем итмиләр.

## «КЫЗЛАР ҖЫРЫ»

Әле безнең җырлар башлана гына. Ләкин алар матур башланалар: алар сыйнфый аң – таза тойгыларга уралып, безнең әдәбият полотнобызга ефәк хисләр белән чигеләләр.

Әле күптән түгел генә Зәйнәп Бәширова үзенең көрәш җырларын җырлаган иде[1]. Ләкин аның шигырьләрендә без хатын-кызның үзенә хас, үз тормышына бәйләнгән тойгыларны аз күрә идек. Ул күбрәк общий нәрсәләр турында җырлый иде. Аның җырлары татар әдәбиятыннан менә бу җыр Октябрьнең көчле давылы белән иреккә чыгарылган хатынның авызыннан чыккан җыр дип әйтерлек аерымлык күргәзми, Октябрьнең хатын-кызда уяткан хисләрен искәртми иде.

Ә бит Октябрь хатын-кыз йөрәгендә ирләргә башка бик күп хисләр уятты.

Октябрьгә кадәр ярты булып йөргән хатын-кызны Октябрь беренче мәртәбә кеше дип игълан итте. Ирләр меңәр еллар буе файдаланып килгән хокукларны хатын-кыз Октябрьдән соң гына алды. Октябрь хатын-кызда күп яңа хисләр уятырга тиеш иде.

Газета-журнал битләрендә күренгәләп алган күп кенә хатын-кыз имзаларын соңгы вакытта «Азат хатын» журналы үзенең тирәсенә җыя башлады.

Аның инде менә журналга кушымта булып чыккан «Кызлар җыры» да килеп чыкты.

Мондагы җырлар Октябрь үстергән хатын-кызларның тойгылары, таза, ирекле яңа хисләре белән йөрәкне чолгый.

Аитова[2] имзасы «Азат хатын» журналының баштагы номерларыннан ук күренә башлады. Ул үзенең «Сагынып көтмә, әни»се белән күзгә ташланды. Шигырь баласын сагынучы ананың хаты белән башлана:

.................
Өйгә кайта алмыйм дип язасың.
.................
Ник башкалар кайта кыш, язын.
Бер син кайтыр вакыт тапмыйсың,
Минем чакырып язган хатларымны
Илтифатсыз ертып ташлыйсың.

Бичара ана. Октябрь баласыннан ананы шулкадәр ерак аерган. Ул үзенең кызының хисләрен дә, теләкләрен дә аңламый:

....................
«Рабфак» дигән җирдә укыйм, дисең,
Нинди нәрсә соң ул «рабфагы»ң?
Бу елдан соң тагын күпме вакыт
Укыйсың бар әле, аппагым! –
..................

ди. Аны артка чакыра:

Ташла барысын, кызым, кайт авылга,
Дошманнарның теле бәйләнсен.
Элекке күк җырлап, гармун уйнап,
Өй артыннан яшьләр әйләнсен!

Ләкин артка кайту юк. Уку теләге, кеше – яңа бөек теләкләр өчен көрәшүче кеше булу теләге аны артка кайтармый, аны егетләрнең йорт артыннан гармун белән әйләнүләре дә кызыктырмый.

Аитова үзенең җырларын хатын-кыз йөрәгенә, аның тормышына нык бәйли белә. Анасының хатындагы аналык хисләрен ул хатыннарча нечкә бирә. Ана белән кыз арасындагы бүгенге каршылыкларны оста ача. Ул хатын-кызның бүгенгесен җырларга, үсәргә, күбрәк язарга тиеш. Стиле шома, фикерләрен җиңел әйтә белә.

«Кызлар җыры»нда аның ике матур шигыре кергән. Ләкин аның «Сагынып көтмә, әни!» дигән шигырен дә «Кызлар җыры»на кертергә иде.

«Кызлар җыры» җыентыгында Гайфуллинаның[3] шулай ук өйгә чакырып язучы сеңеленә хаты бар. Гайфуллина иптәш тә үзенең җавап хатында:

Чит илләрдә, ерак шәһәрләрдә
Казармалар безгә ят түгел,
..................
Җир шарының һәр почмаклары
Безнең өчен, апам, туган ил, –

ди. Гайфуллина иптәшнең әле берничә генә шигыре күренде. Аның әле шигырьләре өстендә күп кенә эшлисе бар.

Җыентык эчендә күзгә бәрелгән матур шигырьләрдән Идеал Әминованың[4] «Сеңлем башкорт кызы янында», Зәйнәп Зөбәерованың[5] «Капитал төрмәсендә», Мәскәү «Победа» заводында эшләүче Сәлимә Гыймадиеваның[6] «Уку иде теләгем», Гөлсем Рәсүлованың[7] «Ал байрагың» дигән шигырьләре бар.

Әминова иптәш җиңел яза. Аның каләме авырсынмый, шагыйрәнең теләкләренә буйсына. Шуның өчен дә аның каләме очында матур күренешләр җиңел чәчеләләр.

«Кызлар җыры» ул – әле беренче карлыгач, ләкин аның җырлары киләсе матур җәйне искәртәләр.

## НИЧЕК ЯЗАРГА?

«Азат хатын» журналының укучылары күбәйгән саен, аның эш күләме дә, бурычлары да киңәя бара. Шулай ук укучыларның теләкләренә карата материал бирә бару, аларның көндәлек тормышларына юлбашчылык итү эше дә авырлана. Журнал ул күпчелекнең катнашы белән чыгарылса гына, күпчелекнең теләкләренә җавап бирә алырлык журнал була.

Берничә генә кеше тарафыннан чыгарылган газета, журнал меңнәрчә укучыларның теләкләрен үти алмый. Газета, журнал тулы булсын, материалга бай булсын, файдалы булсын өчен анда киң катлау укучыларның катнашулары кирәк.

Менә шуның өчен дә журналны укып баручылар эченнән хәбәрчеләр, язучылар җитештерү – хәзерге көнге газета, журналларның алдынгы бурычларыннан берсе.

Безнең бик күп газета-журналларыбыз, үзләренең хәбәрчеләр армиясен оештырып, бергәләп эшләп киләләр инде.

Хатын-кыз язучылар, хатын-кыз хәбәрчеләр җитештерү мәсьәләсе әле кузгалып кына килә. Бу юлда эшләнгән эш күзгә күренерлек түгел. Бердәнбер хатын-кыз журналы булган «Азат хатын» бу эшкә әле ныклап тотына алганы юк. Шулай да «Азат хатын» журналы тирәсенә җыелырга омтылучы, аңарга катнашырга теләүчеләрнең саны шактый югары. Аларны оештырасы, тәрбиялисе генә бар. Бу ел яз хатын-кыз язучыларының-хәбәрчеләренең конференцияләрен җыю турында да зур хәзерлек бара инде. Без бу мәкаләдә ул якларга кагылмый, аларның бик күбесенең теләкләренә карата «ничек язарга?» дигән сорауга җавап урынында гына шул мәкаләне язып үтәбез.

Бер нәрсә турында язу өчен иң элек хәреф танырга һәм шул хәрефләр аркылы үзеңнең фикерләреңне кәгазь өстенә төшерә белергә кирәк. Сүзне кечкенә хәбәрләр язу турында башлыйк.

### Ничек хәбәр язарга?

«Ничек хәбәр язарга?» дигән сорау белән бергә нәрсә турында язарга дигән сорауны да куярга кирәк.

Безнең хәбәрчеләребез күп вакытта яхшы гына яза да беләләр. Каләмнәре дә шома була, имлясы да, җөмләләре дә дөрес була. Ләкин язган хәбәрләренең әһәмияте бик аз була. Яки бөтенләй юк нәрсәләр турында язалар. Оста гына яза белә торган хәбәрче тота да шундый хәбәр яза.

«Безнең авылда Халик Галиевнең бик усал эте бар. Шул эт тол карчык Минҗамал әбинең күлмәген кабып өзгән. Андый этләрне бәйдә тотарга кирәк иде», – ди. Бу хәбәрнең авыл стена газетасы өчен нәни генә әһәмияте булса да, бишәр мең укучысы булган журнал өчен ниндидер бер авылдагы Хәкимов дигән крәстиян этенең яманлыгының әһәмияте бөтенләй юк. Бу – мисал өчен генә алынган хәбәр. Ләкин моңар охшаган хәбәр яуганнан-явып тора. Шуның өчен алар газета, журнал архивына күмелә баралар. Хәбәр яза башлаудан элек, яза торган хәбәреңнең газета

яки журналда басылганда, журналның бөтен СССРга таралган укучыларына файда итәрлекме-юкмы икәне турында уйларга кирәк.

Сезнең авылда булган яман яклар башка авыл крәстияннәре арасында да булуы мөмкин. Авылларда булган уртак җитешсезлекләр күп. Шуның өчен дә хәбәрне язган вакытта уртак булганрак файданы күзәтергә кирәк.

«Нәрсә турында язарга, нинди хәбәр файдалы?» дигән сорауга кыска гына җавап бирү авыр. Бик күп нәрсәләр турында язарга мөмкин. Шулай да хәзерге көндә әһәмияте булган, авылдагы үсеп килә торган яңа тормышның күп тармакларыннан булган:

– совет кооперация эшен, андагы җитешсезлекләр, уңышлы яклар;

– хатын-кызларның совет эшенә катнашлары, делегаткаларның эшләре, үсеп килә торган хатын-кыз активларының эшләре;

– тормыш, көнкүреш мәсьәләләрендәге җитешсезлекләр, җинаятьләр, хатын-кыз мәсьәләсендәге законсызлыклар, киң күләмдә кайбер кешеләр тарафыннан хосусый законсызлыклар, төрле кампанияләрнең уңышлы һәм уңышсыз үтәлүләре һәм башкалар.

Ләкин шул нәрсәләр турында гына язу кирәк дигән сүз түгел бу. Көндәлек эш ул үзе язуга материал бирә. Бары көндәлек авылның барысын тикшереп барырга гына кирәк. Шуның белән бергә, совет эшләре турында язганда, «безнең совет яхшы эшли» дигән сүз белән дә чикләнү җитми. Ничек яхшы эшли, эш юллары, авылга китергән файдалары турында тәҗрибә юлларын язарга кирәк.

Бу материалны сайлау ягыннан булды. Инде шул материалны сайлагач, ничек язу турында тукталып үтик. Бездә бик күп иптәшләр «Мин язучыларча матур яза алмыйм, барыбер басмаслар» дип уйлыйлар. Билгеле, югарыда әйтелгәнчә, җибәрелгән материалның әһәмияте аз булса, ул басылмый кала. Ә материал кыйммәтле булса, редакцияләр аны үзләре эшләп тә җибәрәләр.

Бер хәбәрне язу өчен бер дә зур язучы булу кирәкми. Аның өчен бары син үзең нәрсә уйласаң, шуны язу гына кирәк. Безнең бик күп иптәшләр күзләре белән күргән вакыйганы сөйләргә тотынсалар, дөньяны онытгырып, матурлап сөйләп бирәләр. Ә язуга килгәндә, шул вакыйганы язып бирә алмыйлар. Монда алар каләм алу белән авырлык хис итәләр. Матурлап «китапчарак» язарга телиләр. Маташа-маташа «китапча» булып чыкмый да – ташлыйлар. Бу – ялгыш юл. Менә шул хәбәрне язарга уйлаганда, тотарга да сөйләгәнчә итеп язарга кирәк. Алай язу авыр да түгел. Укыр өчен дә сөйләгәнне тыңлаган кебек матур була.

## ХИКӘЯНЕ НИЧЕК ЯЗАРГА?

Хикәяне ничек язуга килгән вакытта, инде күбрәк туктарга кирәк була. Хикәяне аңлатудан элек, бераз читкә китәбез. Әдәбиятта роман дигән нәрсә бар. Роман ул үзенең эченә бер бөтен дәверне һәм шул дәвердә яшәгән берничә каһарманны романның төп кисәкләре итеп ала. Аларның тормышларын, эчке табигатьләрен, көрәшләрен, иң соңында җиңү яки җиңелүләрен ачып сала. Романнар күп вакытта бер дәвер тормышның бөтен якларына - кагылалар. Әйтик, роман революциягә кадәр эшчеләр тормышыннан алынган булса, романның эченә шул вакыттагы аерым каһарман итеп алынган эшчеләрнең көнкүрешләре генә түгел, бәлки шул дәвердә каһарман белән замандаш булган бик күп эшчеләрнең көнкүрешләре, байларга каршы көрәшләре, байларның тормышлары, ул көрәшчеләрнең эчке тойгылары һәм башка бик күп нәрсәләрен эченә алалар.

Роман ул төп каһарман булган кешеләрнең тууларыннан алып үлүләренә кадәр булган тормышларыннан каһарманның кемлеген ачу өчен кирәк булган бөтен вакыйгаларны, шул вакыйгага бәйләнешле булган бөтен кешеләрне ала. Шуның өчен дә аларның күләмнәре зур була. Бездә Галимҗан абый Ибраһимовның[1] «Яшь йөрәкләр»е, «Безнең көннәр»е, Шәриф абый Камалның[2] «Таң атканда» дигән әсәрләре – чын романнар.

Безнең «Азат хатын» язучыларыннан романнар язарлык көчләр юк әле. Роман турында туктап үтүебезнең дә бер сәбәбе бар. Безнең яшь язучыларыбыз күп вакытта, хикәя язам дип, дүрт-биш биттә бер романның мәүзугы булырлык нәрсәләр язып җибәрәләр. Алар күп вакытта хикәяләрен болай язалар: Сәлимә туган. Атасы аның ярлы булган. Тамагын чабата тугып уздырган. Сәлимәнең анасы Сәлимә җиде яшьтә чакта үлгән. Сәлимә ятим калган. Тормышлары авырайган. Атасы аны эшкә биргән, шуннан соң ул кыз булып җитешкән. Бай аңарга кулын салган. Актыктан кызны куып чыгарган.

Менә бу унбиш-унсигез еллык тормышны алар биш-алты биттә язып бирәләр. Билгеле, бу хикәя дә, роман да түгел. Бу берәүнең тәрҗемәи хәлен санап чыгу. Монда, каһарманның тормышындагы аның характерын ачарлык вакыйгаларны тасвир итү урынына, ул вакыйгалар саналып кына чыгыла. Соң, хикәя нәрсә? Хикәя ул – романның

кечкенә бер төре. Ләкин ул күләме белән дә, эчке төзелеше белән дә романнан тар. Анда бер бөтен дәвер алынмый. Бәлки каһарманның характерын, идеологиясен ачып салырлык бер яки ике вакыйга гына алынып тасвир ителә.

Хикәянең эчке төзелеше нәрсәләрдән тора? Беренче – хикәянең каһарманы, аның характеры, каһарманның тормышка карашы. Икенче – хикәянең сюжеты. Өченче – төп теләге. Дүртенче – буявы.

Бу саналган нәрсәләрне хикәянең төп материаллары итеп алырга мөмкин.

Инде хикәяне ничек язуга, шушы материалларны ничек файдалануга килик. Әйтик, хикәя язарга теләүченең алдында бер каһарман, гади тел белән әйткәндә, язарга дип күздә тоткан кешесе бар. Ул кешенең үткән тормышы аңарда куркаклык психологиясе ясаган. Менә шул психологияне язучы ачып салырга тиеш. Ләкин ничек? Бездә «батыр сугышта беленә» дигән мәкаль бар. Монда да шулай. Берәү, әйтик, авылда яши. Сука сукалый. Иген игә. Йортын карый. Вакытында ашый, вакытында эчә, кем белән сугышырга да, талашырга да туры килә. Менә мондый гади тыныч аккан тормышта без бер каһарманның характерын тиз генә ача алмыйбыз. Без аның сука сукалаганда яки чәй эчеп утырган вакытына карап, аның батыр табигатьле, куркак табигатьле икәнен белә алмыйбыз. Шуның өчен батырның батырлыгын, куркак табигатьле кешенең куркаклыгын без бары шул табигатьләрен күрсәтерлек бер вакыйга эченә куйсак кына күрә алабыз.

Каһарманнарның эчке тормышларын ачу өчен бирелгән вакыйга сюжет дип атала. Хикәя язуда сюжет зур роль уйный. Каһарманның сюжетка кадәр булган тыныч, гади тормышы, гадәттә, хикәянең эченә төп материал булып керми. Ул тормышы аның ярдәмче материал гына була ала.

Мисал өчен «Азат хатын» журналында басылган «Кем гаепле?»[3] хикәясен алыйк. Анда Саҗидәнең Хәмиткә гашыйк булуга кадәр булган тормышы сюжеттан ... тормый. Шуның өчен хикәядә Саҗидәнең Хәмит белән булган мәхәббәтенә кадәр тормышы күренми. Хәмитнең дә, Саҗидәнең ата-анасының тормышы да шулай ук. Сюжет булырлык башка вакыйгалар да булгандыр. Ләкин хикәяне язучы кеше үзенең каһарманнарының табигатьләрендәге кайбер якларын гына ачу өчен бер сюжет ала. Саҗидәне хатынлы бер кешегә гашыйк итә. Саҗидәне дә, Сәлимәне дә, Саҗидәнең атасын да, анасын да гади бер тормыш халәтеннән чыгара. Аларның тормышларында гадәттән тыш вакыйгалар булып килә. Саҗидә гашыйк була. Бу әле ул кадәр каршылыклы бер эш түгел. Гыйшык Хәмитнең өйләнүе белән дә бетүе мөмкин иде. Ләкин Хәмит өйләнә алмый. Беренче – ул хатынлы, икенче – хатынын ярата. Димәк, мондагы мәхәббәт гади бер мәхәббәттән аерыла. Инде мәхәббәтне корбан итеп, Саҗидә Хәмитне ташлый да алыр иде. Ләкин алар арасындагы мөнәсәбәт гади мәхәббәт мөнәсәбәтеннән үткән. Саҗидә балага узган. Бу нәрсә мәхәббәтнең фаҗигасез сүтелешенә комачаулый. Шәһәр тормышында бу мәсьәлә, бәлки, Саҗидәнең Хәмиттән баласына алимент алу белән генә бетә алыр иде. Ләкин монда – авыл. Хикәягә каһарман булып катнашкан ата белән ананың иске карашлары килеп катнаша. Менә шундый каршылыклар эчендә хикәянең соңы фаҗига белән бетә.

Менә бу – хикәянең сюжеты. Инде хикәягә катнашкан каһарманнарның характерларын, психологияләрен эзлик. Саҗидә ул яшь. Тормыш аңарда кисәк күзгә бәрелеп торган характер эшләп өлгермәгән. Аны әле яшьлек көче идарә итә, Саҗидә тибы монда характерлы каһарман түгел. Сәлимәнең аерата күренеп торган характеры юк. Без Сәлимәдә бары башлангыч хулиганлык характерын гына күрәбез. Ул үзенең нәрсә эшләве турында, эшләгән эшенең икенче берәүләргә бәхетсезлек китерүе турында да уйламый. Аны эгоизм, үзен генә ярату психологиясе идарә итә. Бу хикәядәге каһарманнарның характерлары, язучының яшьлегеннән булырга кирәк, эшләнеп бетмәгән. Икенче яктан, монда хикәянең сюжеты көчле булу белән ул кимчелекләрне каплый.

Хатын-кыз мәсьәләсенә, бер яктан, хулиганнарча каравы, икенче яктан, дини хаклык карашының тупаслыгы нәтиҗәсендә фаҗига килеп чыга. Менә хикәянең төп теләге дә шушы ике карашның кабахәтлеген ачуда.

Хикәяләр тормышта булган вакыйгадан алынып языла ала. Ләкин язучы үзенең теләгенә, osталыгына карата эшли. Әйтик, бер вакыйга тормышта бертөрле була. Ул вакыйгада, тормышта булганынча язылса, матурлык аз була. Ләкин язучы аны шомарта. Икенче, шуңа охшашлы булган вакыйгаларның аерым кисәкләреннән бер бөтен сюжет төзи.

Үзеннән кайбер якларны арттыра, матурлый. Аңар үзенчә декорация төзи. Бу хикәянең буявы дип атала. Инде хикәяне ничек язуга килик.

Хикәяне язудан элек, безнең бик күп язучылар тема, мәүзуг эзлиләр. Көлке хикәя язарга булганда, алар барыннан да элек сюжет төзиләр. Аннан соң каһарманнар эзләп язалар. Бу – ялгыш юл. Иң элек каһарман табарга кирәк. Аннан соң шул каһарманның характерын ачу өчен шарт – обстановка төзергә кирәк. Мәсәлән ....

**НИЧЕК ҮСӘБЕЗ?**

Аерым-аерым шигырьләрендә очкынланган көчле шигъри җөмләләре белән бик күп яшь көчләр кинәт үзләренә дикъкатьне алалар. Ләкин укый башлагач, ул җөмләләр чуалчык, эшләнмәгән, мәгънәләре белән бер-берсенә бәйләнешсез юллар арасында югалып калалар.

Дүрт юл шигырьдә дүрт нәрсә турында җырлыйлар. Бу оригинальлек түгел, тәҗрибәсезлек. Тема таба алмау, сюжетсызлыкта адашып йөрү. Безнең яшь шагыйрьләр бик бертөрле – бер-берсенә артык иярәләр. Берсе җырлаган җөмләне бөтенесе уртак итә, «тапты», «зәңгәр яшьлек», «нәсел кайгырту», «ачуланма, әнкәй», «авылым», шулай ук «шуңаргадыр, ахры» кебек вариантлар шулкадәр тапталды, шул сүзләр кергән шигырьне укыйсы килми хәзер.

Шигырьгә тирән мәгънә бирәм дип, күп вакытта артык ачык әйтелә торган мәгънәне төрле вариантлар белән бутап, аңларга авыр бер хәлгә китерергә тырышу бар – бу да ялгыш юл. Шигырьнең кыйммәте нәни бер идеяне кеше аңламаслык итеп язуда түгел, бәлки бөек идеяләрне җиңел, гади рәвештә өч-дүрт җөмләдә әйтеп бирә алуда.

Яшьләрдәге бүгенге лирика артык эчке «үткен хисләр» тирәсендә әйләнә. Лириканы гомуми тормыш белән бәйләүгә тәҗрибәләр аз. Йөрәк хисләрен «җанкисәгем автобуска» да, яңа салына башлаган йортның беренче кирпеченә бәйләп тә җырлап була. Лирика җепләре, күкрәк төрмәсеннән чыгып, тормыш таллары арасына озайсын! Тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итми. Зур идеяләрне крәстияннәрнең бозаулары арасына кертеп җырларга кирәк. Крәстиян шагыйрьнең шигырендә, койрыгын безләтеп, көтүчедән качып барган бозауны күрү белән, шигырьнең эченә салынган идеяне тизрәк үзләштерә.

Яшьләргә, бертөрлелектән, сюжетсызлыктан чыгу өчен, шигырьләре өстендә бик күп эшләргә, темаларга кырык яктан килеп карарга, ниһаять, бүгенге бирелүсез темаларның оригиналь рәвештә ишекләрен ачарга, укырга, туктаусыз әдәбият укырга кирәк.

**«АМАНТАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕ» ТУРЫНДА**

Амантай шигырьләрен укып чыктым. Җыентык эчендә матур гына шигырьләр бар. Ләкин барлыгы белән басылырлык түгел. Күп шигырьләр техника ягыннан бик нык аксыйлар. Ритмнар агышсыз. Җөмлә бәрелешләре урыны-урыны белән бер-берсенә эхо була алмаслык дәрәҗәдә аерылалар. Яңа җөмлә бәрелешләре дә (рифмалары да) уңышсыз баралар. Бу, билгеле, бөтен шигырьләрендә түгел. Кайбер шигырьләрендә бу нәрсә бик уңышлы бара.

Амантай шигырьләрендә татар матур әдәбиятында очрамаган бик күп ят сүзләр очрый. Мәсәлән, «кылтымаклар», «томалак» «торлакка», «авыл туу», «катмарлана», «килке» вә башка шуның кебек бик күп сүзләр. Бу сүзләр шигырьләрне бик нык тупасландыралар. Шуның өстенә Амантай Туфан кебек яңа сүзләр эзләргә дә омтыла. Ул сүзләре дә Туфандагы кебек уңышлы бармыйлар. Яңа образлар да шытырдавыклы тупаслык белән хискә бәреләләр. Мәсәлән, «ми коробкасы», «томнар битен турап» һәм башкалар. Бу образлар уңышлы образлар түгел. Шуның өстенә Амантайның артык рус сүзләре белән кызыксынуы күренә.

«Төкер укол (?), мышьяк растворына»...

«К. К. Р.дан наказ:

«Даешь индустрия,»

«Ныклы эш, (?!)»

«Глитсина, Зоза...»

Бу сүзләр, бер яктан, кулланыла белмәү сәбәпле, тел агымын җимерсәләр, икенчедән, шигырьләрне тупасландыралар. Кимчелекләр рәтенә табигатьне тасвир итү темпы белән кайбер хисләренең каршылыкларын, үзенең теләкләрен әйтүгә хәзерлексез кинәт күчүләрне, шигырьне моннан ун ел элекке тормышыннан башлап, бәйләнешсез, бүгенге белән бетерүләрне санап китәргә кирәк (мисал: «Авыл малайлары»).

Амантайның мәҗмугасына күп кенә бик яшь вакытында язылган шигырьләре кергән. Ул бу шигырьләрен, аерым бүлем ясап, «Әдәби башлангыч дәверемнең документлары санап, мәҗмугага керттем» ди. Ул документларның бу мәҗмугада чыгулары бөтенләй кирәксез. Алар шагыйрьнең тәрҗемәи хәле өчен генә документ була ала торган, нәфислеге түбән, идеологиясе балалык «гакыллыгы» белән сугарылган нәрсәләр.

Мин кайбер шигырьләрдәге кирәксез яки бәйләнешсез җөмләләрне сызып, кайберләрен төзәтеп чыктым. Шулардан җыеп, минемчә, түбәндәге шигырьләрне мәҗмугага кертеп, калганнарын төшереп калдырырга кирәк.

1. «Үпкәлим әле әнкәмә». – Бу шигырьне беренче шигырь итеп җибәрергә, матур.
2. «Их, КИМ паровоз!» – Бу шигырь Жаровның[1] «Паровоз» дигән шигыреннән турыдан-туры алынган.
3. «Көрәш ярып чыктым дөньяга». – Бу шигырь артык матур түгел, шулай да кертергә ярый.
4. «Яз аккорды». – Төзәткәнчә кертергә.
5. «Өмәчеләр». – Сызганнарын калдырып кертергә.

6. «Су буенда».
7. «Авыл малайлары». – Төзәткәнчә кертергә. Соңгы сызылган җөмләләре башы белән ябышмый.
8. «Кала-кала әлегә далага».
9. «Көннәр алмашканда».
10. «Киләчәгем якты».
11. «Таш кала».
12. «Комсомол».
13. «Җырым».

Бу шигырьләре кертергә ярыйлар. Башкалары басылырлык түгелләр.

Шул санаган шигырьләрне керткәндә, бер табак чамасы шигырь җыела. Минемчә, аңардан соңгы язылган шигырьләрен соратып, шуларны өстәп басарга кирәк.

**«ЗӘКУАН МУЛЛА ШӘҖӘРӘСЕ»**

(*Академия театры, Фатих Сәйфи-Казанлы*[1] *әсәре,*
*Девишев*[2] *постановкасы*)

Бу пьесада иң элек күзгә бәрелгән нәрсә – язучының драмада өч җитди карашы, нәфис дөреслек нигезендә кешенең бөтен эчке каршылыклары белән җанлы психологик типлар тудырырга омтылуы.

Пьесаның сюжеты гади. Хәтта шаблон. Ләкин автор үзенең типларын дөрес җанландыруы һәм драма әйләнешенә дөрес психология салуы, типларны берьяклы итми, аларның эчке каршылыкларын ачарга тырышуы, аларга караучыны ышандырырлык тел бирергә омтылуы белән сюжетны шаблон төстән чыгарып, уйланып карарлык авыр, салмак пьеса тудырган. Мин монда «уйланып карарлык» дигән сүзгә ударение ясыйм. Чөнки типлар берьяклы итеп алынганда, караучы баштан ук аның турында бер фикергә килә дә, соңыннан ул тип белән түгел, бәлки вакыйга белән генә кызыксына башлый.

Гадәттә шаблон пьесалар шулай карала. Начар кеше икән, автор башта ук начар кеше карикатурасы ясап куя да соңыннан аның нинди кабахәтлекләрдә йөрүен күргәзеп кенә үтә. Ә бит зәһәр бер җинаятьчедә кешегә хас булган бик күп якты хисләр барлыгын беләбез. Без бүген кеше үтергән җинаятьченең иртән яраткан кешесе үлгәч күз яшьләре түгүенә ышанабыз. Кеше ул шундый психика каршылыгы эчендә яши. Кешене шул эчке каршылыклар белән көрәш кенә үстерә һәм түбән төшерә ала. Караучыга үз булган эчке һәм тышкы каршылыклар белән каһарманның көрәшүен күрү аны уйларга мәҗбүр итә һәм шул нигезгә корылган драмалар гына нәфис әсәрләр булып саналалар.

«Зәкуан мулла шәҗәрәсе»ндәге каһарман – Гасыйм. Безнең алдыбызга беренче чыгышыннан ук ике каршылык эчендә чыга, һәм без аңарда беренче сүзләреннән үк ике йөрәк тибүе барлыгын сизәбез.

Беренче, ул – коммунист. Үткен телле, пычаклы матур сөйләвеннән аның йөрәк матурлыгы күренә. Аны ярату хисләре уята торган яклары шулар. Шул үзендә булган сыйфатларын ук яхшы якка юнәлдерсә, безгә файдалы яхшы коммунист була алыр иде.

Ләкин ул үзенең «шәҗәрәсе» белән пролетариатка чит булган сыйныфка бәйләнгән. Ул – мулла баласы. Күп кенә мулла балалары да партия сафында яхшы эшче булып киләләр. Ләкин алар үзләренең сыйныфлары белән бөтенләйгә аерылганнар һәм «шәҗәрә»ләренә пролетариатка чит булган бер сыйныф итеп карарга өйрәнгәннәр. Ә Гасыйм алай түгел. Аның бер аягы – коммунистлар партиясендә, икенче аягы – муллалар ягында. Аның бөтен трагедиясе дә үзенең чыгышына, «шәҗәрә»сенә нәфрәт күзе, дошман күзе белән карау дәрәҗәсенә җитмәвендә.

Безнең бик күп коммунистларыбызның әле туганнарына (кем булсалар да) җылы хис белән карау, аларга ярдәм итү, тупас мәгънәсендә агай-энелек итү бәласеннән котыла алганнары юк.

Гасыйм да шулай. Кардәше кулак малае «бедняк» булып укырга керергә килә. Кияү тиешле кешесе аңарга ике бәясе белән үзенең кәгазен сатарга тели. Әгәр Гасыйм аларга чын күңелдән ярдәм итәргә теләп яки аңсыз булу белән үзенең поступокларын дөрес дип алып эшләсә, караучы аңар сәлби тип, шаблон итеп карар иде. Ә бит Гасыйм бу эшләрне ике каршылык көче көрәше эчендә эшли. Ул, үзенең пычраклык эшләрен сизеп, үз теле белән шуны караучыга сиздереп бара.

Ул – вак буржуа стихиясе кулында. Аңарда вак буржуага гына хас булган пассивлык настроениесе бар. Ул хәтта үзенең элекке хатыны белән ике арада булган көрәштә дә үзе актив булып катнашмый. Ничектер ... кемнәр кулы беләндер эшли.

Караучы аның пычраклыклар эшләгән вакытында йөрәгенең тирән бер җирендә шул пычраклыкка катнашырга теләмәгән икенче бер йөрәк көче барлыгын сизеп бара. Ләкин ул көч пассивный. Ул көчкә актив булып катнашырга Гасыймны сарып алган среда да, тәрбиясе дә ирек бирми. Ул төрмәгә кадәр шулай бара. Ләкин төрмәгә ул үзенең хәрәкәтләренең бөтен түбәнлекләрен аңлаган Гасыйм булып китә. Караучы аны кызганып кала. Мин пьесадагы башка типларга тукталмадым. Чөнки алар Гасыймның характерын ачуга ярдәмче типлар гына. Шулай да анда тукталырга тиешле типлар бар. Без анда Октябрь көче белән тормыш төбенә ташланган бай типларны да очратабыз. Элекке бай түрәнең: «Большевиклар, ичмаса, атып та үтермәделәр, мәңге хур булып йөрергә калдырдылар», – дип, үзенең бөтен ничтожествосын аңлап сөйләгән сүзләре бездә «кызгану» хисләре уята. Муллалыгын ташлап, улына ышанып килгән Зәкуан хәзрәт тә, улы төрмәгә киткәндә бик көлке рәвештә килеп керүенә карамый, кызганыч. Аларның яңа тормыш алдындагы зәгыйфьлекләрен күреп кызгана алабыз без.

Мин пьесаның юри яхшы якларына гына тукталдым. Фатих Сәйфи иптәшнең пьесасында, билгеле, җитешсез яклар да бар. Мәсәлән, Гасыймны төрмәгә җибәрү аргументлары зәгыйфь – аның күп алимент түләмәү өчен генә төрмәгә китүе күренә. Бу китүне аның психологически җимерелүенә, «шәҗәрә»се белән арада булган җепләргә бәйләргә кирәк. Шулай ук аның типларының төп нинди хезмәттән булулары томанлы. Язучы, бәлки, караучылар: «Болар Казанда кемнәр тормышыннан алынган?» – дип эзләмәсеннәр өчен шулай томанлы калдыргандыр? Гасыймның хатыны белән арасында булган мөнәсәбәтенең дә Гасыймның психологиясендә бертөрле дә реакция тудырмавы, соңыннан төрмәгә киткәндә дә әле аның белән торырга вәгъдәләшеп калуы – бу пьесаның җитешсез ягы...

Аның хатыны да Гасыймның рухан җимерелүенә, түбән төшүенә сәбәпче элемент булып бара. Драманың сүтелешендә, психологически дөреслек нигезенә куйганда, Гасыймның элекке хатынына мөнәсәбәтен үзгәртү белән, соңгы хатыны артистка белән мөнәсәбәте икенче төскә кереп калырга тиешле иде. Шуның өстенә, пьесадагы кирәксез урыннарны кыскарта төшкәндә, пьесаның динамикасы арта төшәчәк.

Өченче пәрдәдә заговор ясап үтерү, дүртенче пәрдәдә Гасыймның элекке хатынының револьвер белән керүләре пьесаның җитдилегенә зарар китерәләр.

## БҮГЕНГЕ МАТУРЛЫК ҺӘМ АНЫ ҖЫРЛАУЧЫЛАР ТУРЫНДА

**Нәрсәдән аксау**. Безнең язучыларны аксаткан зур фактларның берсе – аларның сәяси теләкләрне бөтен югарылыгы белән, бөтен күләме белән үзләштерә алмауларында; үз-үзләреннән бер теләкне яки фикерне бертөрле рәвешкә кертеп бирә алу баскычына җитә алмауларында; аларның социаль заказны турыдан-туры үзләре ала алмый, башкаларга сукыр рәвештә ияреп баруда яхуд чәйнәп биргән буенча эшләүләрендә.

Бездәге газета-журналлар шаблон, үзенең табигый хисләр булуына ышандыра алмаган шигырьләр белән тулы. Күп шигырьләр үзләрен язучыларның дөрестән дә шулай кызыл кеше, шул фикерләргә үзе ышанып язган булуына ышандыра алмыйлар.

Менә шул, пролетариатка кирәк булган бүгенге идеяләрне бөтен югарылыклары белән үзләштерә алмаудан шагыйрьләребездә, язучыларыбызда тема табуга аптырау туа. Алар турыдан-туры үзләренең темаларын массаның бүгенге теләкләре белән бәйли алмыйлар, алар тормыштан үзләре тема сайлап, үзләре туып килгән теләкләрне күрми, меңнәрчә ораторлар күреп сөйләгән нәрсәләрне генә, мең дә беренче мәртәбә арттырмый-нитми, оратор төсле үк итеп кабатлыйлар. Шуның өчен аларның шигырьләре дә, хикәяләре дә яңа хисләр, яңа күренешләргә бай булмыйлар.

**Икенче трагедия**. Бусы да югарыдагы нәрсәләр белән параллель булып тора. Бик күп язучыларыбыз югарыдагы аксаулары белән бергә икенче аяклары белән дә аксыйлар. Алар тормышны аз беләләр. Яки белгән тормышларыннан алган тәэссоратларын беренче трагедиядәге сәбәпләр белән үзләре бертөрле рәвешкә кертә алмыйлар. Башкалар күзе күргән, башкаларның башыннан үткән материаллар исәбенә торалар. Берәүләре, гомерендә авылда булмаса да, авыл тормышыннан алып хикәяләр яза. Гражданнар сугышы вакытында ыштансыз йөргән егетләр Гражданнар сугышыннан алып хикәяләр, шигырьләр язалар. Алар, билгеле, ул сугышта булган булып, әле унлап яра алган кеше булып алдашалар. Болар, билгеле, кеше исәбенә, кеше башыннан үткән, кеше күзе күргән нәрсәләрне үзебез күрдек дип алдашалар, шуның өчен һәр җөмләләре алдый, һәр сүзләре безгә ышанмагыз дип кычкырып торалар. Әдәбиятта яшәп килгән плагиатлар тиктомалга килеп чыккан әйберләр түгел. Бүгенге шигырьләрнең яратылып укылмауларының да, бер үк темаларның кабатлануларының төп сәбәпләрен дә югарыдагы нәрсәләрдән эзләргә кирәк.

Мин шигырьләрне язучыларны гаепләргә ашыкмыйм. Бүгенге татар пролетариат язучылары алдына шул теләкләрне кую белән бергә аларның тормыш якларына да күз салырга кирәк.

– Нигә сез колхозларны җырламыйсыз? – дип, газеталарда аларны гаепләп язылган җөмләләр астына шагыйрьләрнең җавап урынында куйган сорауларын куеп үтәргә кирәк:

– Ә без колхозларны күрә алганыбыз бармы?

– Ни өчен сез гел Казан тирәсендә әйләнәсез?

– Ә безнең Казаннан башка җирне күргәнебез бармы?

– Волховстройлар[1], Днепростройлар[2] төзелә, шахталар машиналаштырыла, нигә сез шуларны җырламыйсыз?

– Ә безнең аларны күргәнебез бармы?

– Авылда хәзерге көндә сыйнфый көрәш иң кызган вакыт, ә сез шуны җырламый, үткән авылны, борынгы авылны җырлыйсыз!

– Ә безнең бүгенге авылны күргәнебез бармы? Без отпуск вакытында гына ертык үпкәләрне төзәтү нияте белән Казаннан чыга алабыз. Безнең күргән нәрсә – квартира да учреждение, театр да урам...

Шагыйрьләр – оста телле халык. Үзләренә бирелгән сорауларга бик күбесенә дөрес җавап бирә алалар. Ә шагыйрьләр куйган сорауларга ничек һәм кем җавап бирергә тиешле?

Днепростройларга бармый гына язучыларыбызга партийный задание кебек итеп шуларны җырларга кушсак, билгеле, алар дисциплинага буйсынып җырларлар. Ләкин Днепростройда булып язган рус шагыйренең шигырен урлап язарлар, язган шигырьләре яңа да булмас, чын да булмас, матур да булмас. Ильясовны гаепләгән кебек[3], язучыларны берәм-берәм плагиатта гаепләп чыгарбыз, яки һәр язучы үзе Урал сугышларында да, Перекоп сугышларында да булмыйча, «Уралдан Перекопка» дигән роман «язучы» кебек көлкегә калыр. Романның исемен генә диварына язып кадап куйган булса да, кызу канлылык белән ул язучы газетада шул хакта кычкырып өлгерде. Халык романны көтә башлагач, ул газетада Урал, Перекоп сугышларында катнашкан иптәшләрдән материаллар язып җибәрүләрен сорарга мәҗбүр булды. Бу – көлке, ләкин – трагедия.

Бездә язучының хезмәтенә клубта эшләүче клуб эшчесенең эшенә бирелгән әһәмият тә бирелми. Клубта эшләүчегә жалованье биреп торсак, меңнәрчә кешеләрне күп еллар буенча тәрбияләүче, үзенең һәр җөмләсе, һәр сүзе өчен җаваплы булган язучыларыбызның әдәби трагедияләренә көлеп карыйбыз. Аларга тормышны өйрәнергә шартлар тудырмавыбыз өстенә, аларны тын да алырга вакыт калдырмаслык итеп башка эшкә җигеп, башларындагы темаларын бертөрле калыпка салуга вакытларын калдырмыйбыз. Ә чиле-пешле, эшләнергә өлгерми чыккан әйберләре өчен казык белән кыйныйбыз. Шул югарыдагы нәрсәләрне күздән кичергәннең соңында, татар язучыларының оешкан хәлдә СССРны әйләнүләренең никадәр әһәмиятле бернәрсә булуын аңлап була.

Татарстан хөкүмәте ярдәме белән ТАПП[4] һәм Язучылар җәмгыяте оештырган бу сәяхәт – әдәби күтәрелешебезнең соңгы еллардагы иң зур адымы.

**Без нәрсә күрдек?** Бүгенге матур, күтәренке рух белән җырлаучы шагыйрьләр күрергә, белергә тиешле нәрсәләрне күрдек. Без, СССРда яшәп, СССРны белмәвебезне белдек. Без бөек үсешне күрдек. Ләкин, оятыбызга каршы, ул үсешне бик аз җырлавыбызны сиздек.

Идел буенча пароходта барганда, мин делегациядәге иптәшләрнең Идел урманнарыннан алган тәэссоратларын күзәтеп бардым. Аларны Идел ярларының матурлыгы шашырмады да, аларның йөрәкләрен дулкынлатырлык ашкыну да бирмәде. Алар Идел матурлыгыннан тыныч, үзләренең язачак әйберләренә үзләре дә белми буяулар җыю, башларында йөргән каһарманнарын Идел ярларында йөртү, язылачак әйберләренә декорацияләр эзләү белән генә канәгатьләнделәр бугай. Идел өстендә аларда яңа уйлар уянуны да, яңа каһарманнар тууны да ачык рәвештә күреп булмады. Бу, бәлки, бөек елганың ярларында төзелеп яткан социализм балаларын – яңа гигантларны туктап күреп йөрмәүдәндер. Бәлки, пароходның туктаусыз баруы ирек бирмәүдәндер. Бит бүгенгенең яңа хисләре социализм культурасы тудырган гигантлар арасында гына, бүгенгенең яңарып, үзгәреп торган экономикасы эчендә генә туалар.

Бакуның 224 яңа кварталларын караганда, мин янымда йөргән татарның – яшь драматургның йөрәгендә уянган хисләрен укырга теләп йөрдем. Мин аның йөрәгендә яңа, бөтенләй яңа хисләрнең уянуын, шул исемсез бөек шатлыгы уртасында уянган хисләренә ашыга-ашыга исем эзләвен, таба алмый газаплануын карап тордым. Чөнки ул хисләр минем үземнең йөрәк томаным уртасында, иҗат хаосы эчендә туып килгән планета кебек аерым бер рәвешкә кереп өлгермәгән килеш әйләнә, бутала, йөрәкне гакылсыз бер ашкыну белән белемсезлек эчендә очындыра иде.

Язучының йөрәге аркылы үткән хисләрне, аларның туу вакытларын язу бик авыр.

Без машиналар каны – кара алтын аккан диңгез ярларында булдык!

Без – диңгезнең кеше тарафыннан җиңелгән җирләрен карадык!

Без – машиналар туган урында булдык!

Без – яңа кешеләр кулы белән туган яңа экономика балаларын күрдек!

Без – үлеп барган иске техника каберлегендә булдык!

Без – җиде җөмһүрияттә булдык. Йөзләрчә язучылар, ун меңнәрчә эшчеләр безне каршыладылар. Алар, безнең шатланасыбызны белеп, үзләренең уңышлы якларын бернәрсәсен калдырмый күрсәтеп үтәргә ашыктылар.

**Соң без нәрсәләр алып кайттык?** Моңа җавап бирү бик авыр. Без безнең әсәрләребез белән кызыккан унлап милләтнең меңнәрчә эшчеләрен күрдек. Алар безгә милләт, тел аермалыгына карамый, сыйнфый күзлектән карап, интернациональ әдәбият тудырырга социаль заказ бирделәр. Алар үзләрен безнең укучыларыбыз санауларын, әсәрләребезне тудырганда СССРда яшәгән бөтен эшчеләр сыйныфы өчен тудыру юлы белән баруны күрсәттеләр.

Без ун меңнәрчә татар пролетариатын күрдек. Алар үзләренең бөек уңышларының бер генә процентын да әле язучылар тарафыннан күрелеп җырланмавына үпкәләрен әйттеләр. Хаклы сорауларын куйдылар. Пролетариат язучыларына үзләренең эшләренең дә никадәр җаваплы булуларын аңлаттылар.

Без кемлегебезне, кем булырга тиешлегебезне аңладык.

Без нәрсә турында җырларга, нәрсә турында язарга кирәклегебезне белдек.

Ләкин без бу сәяхәттән кайту белән, шул социаль заказларны үтәрлек материаллар алып кайта алдык дип әйтә алмыйбыз. Баш әйләндергеч уңышлыкларны күрү безнең иҗади көчебезгә туры юл сызса, язучылык көчебездә күтәрелеш ясаса да, безнең иҗадиятебезгә аерым, тулы сюжетлар бирә алмады. Аның өчен эшчеләр арасында ике-өч көнгә генә кунак булу җитми. Аның өчен язучыларыбызга уңышлыкларыбызны айлар, еллар буенча өйрәнү һәм шул өйрәнүгә шартлар тудыру кирәк.

Эшчеләр бездән үзләренең тормышларын өйрәнүне, үзләренең тормышларын җырлауны сорыйлар. Без Татарстан хөкүмәтеннән язучыларга эшчеләр тормышын, бүгенге зур уңышлыкларыбызны өйрәнергә мөмкинлек биргән шартлар тудыруны таләп итәбез.

**«ҖАВАП»**

(*Кутуй пьесасы, 4 пәрдәдә*)

Фоны якын, бүгенгенең телендә йөргән вакыйгалар, теләкләр турында язу, аларны нәфис дөреслек нигезендә караучы алдында җанландыра алу – бик авыр бер нәрсә. Үткәннәр фонында калган социаль вакыйгалар, аларның социаль төсләре еллар үтү белән бертөрле калыпка салынып өлгерү сәбәпле, аларны алып язу ул кадәр авыр да, мәсъүлиятле дә булмый. Әле кичә генә караучы алдыннан шаулап үткән вакыйгаларны әдәби калыпка салып күрсәтү, үзе шул вакыйганы күреп үткән укучыны язган нәрсәгә ышандыру, аны әйтергә теләгән уйлары белән чолгау язучыдан күп көч, күп эшләүне сорый.

Безнең театр, әдәбият шул фоны ераклашкан вакыйгалар исәбенәрәк яши. Бүгенге проблемаларны, теләкләрне җанландыруда соңлый яки зур уңышларга ирешә алмый аксап бара. Ә бит әдәбият, театр бүгенге теләкләрне җанландыру, укучының, тыңлаучының фикерен шул теләкләр тирәсенә оештыру нигезендә үсәргә, көндәлек проблемалар белән караучының йөрәген дулкынланып, бүгенгенең туып килгән вакыйгаларына реагировать итәргә тиешле.

6 декабрьдә Татар академия театрында куелган Кутуйның «Җавап» дигән әсәре менә шул бүгенгегә сугуны үзенә нигез итеп ала, һәм аның эчендәге вакыйгалар, кичәге белән башланып, бүгенге аркылы дәвам иткән хәлдә матур рәвештә күз алдыннан үтәләр. Кутуйның пьесасын сәхнәдән карап утырганда, пьеса эчендә барган көрәшләргә үзеңне катнашкандай хис итеп утырасың. Бу – пьесаның караучыга җитүе дигән сүз.

Менә Ханов тибы. Дөрес, ул ничектер без хәзергә кадәр күреп килгән революциягә каршы подпольеда эшләп йөргән кешеләргә охшамый. Без андый кешеләрне икенче маскада күреп килергә өйрәнгән. Алар бит күп әсәрләрдә, хәйләкәр, йомшак телле, ялагайлыгы белән ярарга тырышып, үзенең пычрак эшләрен яшертен эшләп килгән кешеләр булып җанландылар. Хановның артык усал телле булуы, үзен эшчеләр белән тупас тотуы ничектер ят, психологически дөрес түгел кебек. Ләкин без Хановның эчке йөрәк тормышы агымында үзендә бандитлык психологиясе булуны, аның үзенең табигатенә карап, эшчеләрдә булган грубыйлыкны маска итеп аңлы рәвештә сайлап алуны күрәбез. Бу масканы киеп, үзе чит элемент була торып, башкаларны шуңарда гаепләп йөрүчеләрне көрәш безгә күп кенә күргәзеп бирде.

Пьесадагы башка типлар да бүген генә урамда исәнләшеп үткән, иртәгә тагын очраячак җанлы бүгенге кешеләре. Табигате белән йомшак, коммунистлыгы белән каты Гриша (Мәҗитов)[1] әле дә кайдадыр, типографиядә эшли төсле. Йөрәк хисләренә бай Фатиха пьесада аерым бер матурлык булып бара. Фатиха ролендә уйнаган

Булатованың[2] йөрәге аркылы үткән хисләр белән тышкы хәрәкәтләрнең кушыла баруы бүгенгә кадәр иң күренекле артисткаларыбыз бирә алмаган табигыйлекне, осталыкны күрсәтте. Быелгы сезонда Булатова картларга алмашка килгән көчле бер яшь талант булып күренә.

Кутуйның «Җавап» пьесасы, шиксез, бүгенге теләкләрне гәүдәләндерүдәге зур адым. Шулай да әсәрне ашыгыч эшләү күренә. Төзәтеләсе, шомартыласы урыннары бар. Өченче пәрдәдә бүгенге авылның көндәлек көрәшен җанландыру дөрес һәм кирәкле рәвештә алынган булса да, ул пәрдәгә артык күп приключениеләр җыелу, биш минуттан биш минутка трагедияләр өелеп бару пәрдәне куерта, пьесаның агымын читкә алып китә. Авыл пәрдәсе үзе бер сюжет. Авыл кулагының председательгә кереп, куркытып, сүгенеп чыгуы табигый түгел. Сыйнфый көрәш кулакларны үзләренең хәрәкәтләрен бик нык маскировать итәргә өйрәтте инде. (Хисами кулакның беренче пәрдәдә Шәфигә бик тиз чын төс ачуы да шундый ук бер кимчелек.) Кулак Хисамины өченче пәрдәдә бөтенләй кертмәскә кирәк. Аның сатлык ялчысын кертеп чыгу гына да пьеса теләгән нәрсәне әйтүгә җитә.

Пьесада булган башка вак-төяк кытыршылыкларны шомартканда, Кутуйның бу пьесасы көрәшнең икенче ягында торган кешеләргә бик матур бер җавап булып төшәчәк.

## БЕЗНЕ БЕРЛӘШТЕРГӘН НӘРСӘЛӘР

– Көрәш булмаган җирдә әдәбиятның кирәге юк.

– Әдәбият ул – безнең идеалларыбызның омтылышы.

– Язучы ул үзенең сыйнфый идеалларының йә җиңүен, йә һәлакәтен тасвир итә.

– Пролетариат язучысы әле төзелеп өлгермәгән, ләкин җиңелмәслек бер омтылыш белән төзелеп килгән бөек тормыш күренешләрен күрсәтү нигезендә, безнең бүгенге идеалларның җиңүләренең иртәсе белән меңнәрне кызыктыра алырга, аларны шул җиңүләр өчен булган авыр көрәшләргә чакыра белергә тиешле.

Моның өчен ул бүгенге социализм экономикасының иртәсе алып килгән җиңүләрне айнык рәвештә алдан күрергә, меңнәрнең кул хәрәкәтләрен, уй-омтылышларын өйрәнергә, тормыштагы бөтен күтәрелешләрне, бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә, һәрбер тәгәрмәчнең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле.

– Пролетариат язучыларының яңалыклары, аларның кирәклекләре бүгенге социализм экономикасы тудырган яңа хисләрне, яңа уйларны оештыра, бер формага кертә белүләре белән, шул теләкләрне матурлыкка буяп, меңнәрнең йөрәгенә сеңдерә белүләре белән үлчәнергә тиешле.

Бүгенге бөек төзелешнең бөтен милләт пролетариат язучылары алдына куелган бурычы шушы.

Менә шул бурычларны үтәү татар язучылары белән чуваш язучыларын аерылмаслык итеп берләштерә һәм бу берләшү җиңелмәслек пролетариат язучылары армиясен тудыра.

Без бер үк фронтның солдатлары.

Безне аерган нәрсә – телләр аерымлыгы, ләкин бу аерымлык безгә бөек пролетариат культурасын тудыруга комачауламый. Шулай ук аерым милләтләрнең культура эшчеләре тудырган уңышлыклар белән файдаланырга да киртә була алмый.

Чуваш язучылары тудырган, пролетариат өчен кыйммәтле булган әсәрләр, татар пролетариатына рухи азык булганы кебек, татар пролетариат язучылары тудырган әсәрләр дә чуваш пролетариатының социализм өчен булган көрәшендә көчле корал булып хезмәт итә ала.

Пролетариат культурасы – бөтен пролетариат өчен.

Без үзебезнең уңышларыбызның 10 еллыгы бәйрәмен уздырганда, уңышлыклар өчен булган көрәшебездәге тәҗрибәләребез белән уртаклашырга һәм партиянең XVI съездының[1] алдыбызга куйган бурычларын кимчелексез үтәү өчен ҮК боерыгы астында сафларыбызны ныгытырга, сыйнфый дошманнарның агентлары булган татар һәм чуваш милләтчеләренең масса арасында үзләренең йогынтыларын ясарга маташуларына каршы берләшеп сугыш алып барырга тиешбез.

## ТЫҢЛА, ТАПП!

Һавада җилсез генә яңгыр тамчылары оча. Җирдән күтәрелгән төтеннәр, соры болытларга тоташып, домналарның морҗалары яңгырлы төтен атып торган болыт фонтаннарына охшыйлар. Алда Сталин шәһәре.

Фонда:

Шахталардан чыгарылып ташланган порода таулары, рудниклар, яңа төзелеп килгән гигант шахталар.

Башта:

Бүгенге бөек төзелешнең язучы алдына куйган бөек бурычлары:

– Көрәш булмаган җирдә әдәбиятның кирәге юк.

– Әдәбият ул – безнең идеалларыбызның омтылышы.

– Язучы ул үзенең сыйнфый идеалларының йә һәлакәтен, йә җиңүен тасвир итә.

Пролетариат язучысы әле төзелеп өлгермәгән, ләкин җиңелмәслек бер омтылыш белән төзелеп килгән бөек тормыш күренешләрен күрсәтү нигезендә, безнең бүгенге идеалларыбызның җиңүләренең иртәсе белән меңнәрне кызыктыра алырга, аларны шул җиңүләр өчен булган көрәшләргә чакыра белергә тиешле. Моның өчен бүгенге социалистик экономиканың иртәсе алып килгән җиңүләрне айнык рәвештә алдан күрергә, меңнәрнең кул хәрәкәтләрен, уй-омтылышларын өйрәнергә, тормыштагы бөтен күтәрелешләрне, бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә, һәрбер тәгәрмәченең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле.

Пролетариат язучыларының кыйммәте, аларның кирәклеге сыйнфый көрәш һәм бүгенге социализм экономикасын тудырган яңа хисләрне, яңа уйларны оештыра, бер формага кертә белүе белән шул теләкләрне массаның йөрәгенә сеңдерә алуы белән үлчәнергә тиешле.

Бу – бүген үтәлергә, бүген эшкә ашарга тиешле, бүгенге бөек көрәш тарафыннан пролетариат язучылары алдына куелган бурычлар. Без бу бурычлар турында күп язабыз, бик күп сөйләнәбез. Нәтиҗәдә тагын кабатлап чыгабыз. Татар пролетариатының 40 процентын үзенең эченә алган Донбасс шахталарына килү белән бу бурычлар тагын да ачыграк, тагын да ялангачрак күз алдына килеп басалар.

Донбасста хәзерге көндә утыз биш мең татар пролетариаты бар. Алар үзләре өстенә бурыч итеп куелган бишьеллык планны, башка милләт эшчеләре белән беррәттән, өч елда үтәргә омтылалар, һәм кызыл такталарга язылып барган процент цифрлары бу планның өч елда үтәлүенә безне бик нык ышандыралар.

Соң без менә аларның бу көрәшләрендә ярдәм итәрлек әдәбият тудырганыбыз бармы? Уйлар менә шул тирәдә әйләнә.

Донбасс шахтерлары партия тарафыннан үзләре алдына куелган бурычларны үтәүдә хәзерге көндә алдынгы рәттә баралар. Аларның көндәлек көрәшләрендә зур җиңүләр булган кебек, киртә булып төшкән күп кенә комачаулыклар да чыгып тора.

Донбасска ел саен авыллардан ун меңнәрчә сезонниклар бара, аларның төрлесе төрле настроение йогынтысы белән киләләр. Оешкан бер кул көче белән эшләргә дә өйрәнмәгәннәр. Аларның байтагы партия, хөкүмәт тарафыннан куелган бурычларны да аңлап бетермиләр, аңлар дәрәҗәдә белемнәре дә юк. Аларны тәрбияләү, төрле кадрлар тудыру бурычы бар.

Кадровый эшчеләр арасында да тиешсезлекләр юк дип әйтү сукырлык булыр иде. Революциягә кадәр иң кабахәт шартлар эчендә эшләп килгән эшчеләргә, шулар эчендә татар эшчеләренә үзләренең аң-белемнәрен күтәрүгә, үзләрен сәяси үстерүгә, әлбәттә, мөмкинлек булмаган.

Революция еллары гына аларны бу яктан ышанмаслык дәрәҗәдә үстергән. Шулай да бөек төзелеш куйган мәдәни теләкләрне үзләштерүдә, яңа кеше өчен булган көрәштә аларга зур комачаулыклар белән көрәш алып барырга туры килә. Менә бу көрәш пролетариат әдәбияты, пролетариат әдипләре өлешенә зур сыйнфый бурычлар йөкләтә.

Бу бурычларның никадәр зур икәнен шахтерлар массасы белән күзгә-күз очрашкан чакта бигрәк тә нык сизәсең. Аларның бүгенге көрәш әдәбиятына сусаулары, бүгенге әдәбиятның бу сусауны канәгатьләндерер дәрәҗәдә үти алмавы тагын да ныграк күзгә бәрелә. Без үзебезнең унөч еллык көрәшебездә иске буржуа милли әдәбиятының мөндәриҗәсен дә, формасын да җимерү эшендә чиксез зур эшләр эшләдек. Без үзебезнең интернациональ мөндәриҗәле, пролетариатның сыйнфый теләкләре белән сугарылган, матурлык ягыннан татар милли буржуа әдәбияты белән тиңләшмәслек югары пролетариат әдәби стиле тудыруда зур адымнар атладык.

Без әдәбиятны пролетариатның көндәлек көрәшләренә якынайтып, аны бүгенге төзелеш бурычлары белән бәйли алдык. Ләкин ул әдәбиятның күбесе крәстиянгә карата – авылның көндәлек көрәшенә карата бер төстәрәк хәрәкәт итеп килде. Эшчеләр тормышын мөндәриҗә иткән каһарманнары да Донбасс шахтерлары булган күренмәле әсәрне дә, аны тудыручының атаклы исемен дә әле хәтергә төшереп булмый. Кайчандыр укылган вак-төяк шигырьләрдән, сәнгать һәм идея ягыннан түбән торган берничә нәрсәдән башка әйбер искә төшми.

Татар пролетариатының 40 процентын эченә алган Донбасс шахтерларының көрәшләрен татар пролетариат әдәбиятының хәзергә кадәр үз мөндәриҗәсе эченә алмавы бик зур җитешсезлек булып күз алдына килеп баса.

Татар пролетариатының ярым зимагур, ярым ала канат булып, таркау булып яшәгән дәвере Ш.Камал агага «Козгыннар оясында»ны[1] илһам итсә, бүгенге көндә бөек көрәш алып барган, оешкан көчле кадр булган Донбасс татар пролетариаты тормышы хәзергә кадәр үзенә язучыны тапмавы пролетариат әдәби үсешенең зур кимчелеге булып саналырга тиеш. «Атака»ның[2] алдагы санында басылган егерме мең татар пролетариаты исеменнән бирелгән наказда бу нәрсә ачык итеп әйтелеп кителә.

Анда ТАППка бирелгән социаль заказлар – алар бүгенге яңа шахтерларның культурага, белемгә омтылулары тудырган теләкләр. Алар – шахтерлар массасының забой чапканда җырлар өчен яңа җырлар сораулары.

Бу наказ – татар пролетариатының бүгенге әдәбиятка сусаулары нигезендә туган зур документ.

Эшчеләр арасыннан күтәрелгән, Донбасстагы юлбашчылык эшен алып баручы иптәшләрнең ТАПП членының Донбасска килүен бер культура походына, шахтерларны әдәбиятка якынайту кампаниясенә әйләндерүләре, бу шахтерларның пролетариат язучылары алдында үзләренә кирәкле әдәбиятны сорап һәм шуны үтәргә кушып ясалган демонстрацияләре түгелме?

Донбасстагы иптәшләр үзләренең һәрбер хәрәкәтләрендә, һәрбер чыгышларында, көндәлек көрәшләрендә зур корал булган пролетариат әдәбиятына сусауларын аңлатырга тырыштылар.

ТАППның эшче районнарына үзенең членнарын җибәрә башлауны сыйнфый көрәшнең бүгенге пролетариат әдәбияты алдына куйган бурычларын яхшы аңлап хәрәкәт итүе дип таптылар. Алар бу хәрәкәткә үзләренең бик зур әһәмият бирүләрен, ТАПП тарафыннан эшчеләр тормышын өйрәнергә җибәрелгән иптәшләрнең бу юлда кулларыннан килгән ярдәмнәрне күрсәтергә хәзер булулары белән ачык рәвештә күрсәтеп үттеләр.

Оешкан шахтерлар белән ясалган кичәләрдә зал тулы шахтерларның әдәбият турында булган сүзләрне, докладларны тавыш-тынсыз сәгатьләр буенча тыңлаулары – бу аларның әдәбият аркылы сыйнфый тәрбия алыр дәрәҗәгә хәзерләнеп җитүләрен ачык күрсәтә.

Алар шул җыелышларда үзләренең юлбашчылары аркылы ТАППка теләкләрен белдерәләр. Залда тавыш-тынсыз иптәш Шиһабетдинов[3] авызыннан, шатланып, Татарстан пролетариат язучыларына үзләренең уңышлыклары турында бирелгән рапортны тыңлыйлар; шуннан аның авызы белән үзләренең кирәкле теләкләрен тезәләр. Шиһабетдинов иптәшне Абязов[4], Чубаев[5], Яхиннар[6] алмаштыра. Болар бары да забойдан югары урынга күтәрелгән иптәшләр. Алар артыннан буяусыз, ләкин кирәкле теләкләр күтәреп забойщиклар чыга.

Тын рәвештә шигырь тыңларга хәзерләнгән зал алдына килеп чыгу йөрәктә тагын авыртулы, газаплы уйларны кабатлый.

Шахтерларга нинди шигырь укырга соң? Аптырап каласың. Бу укучылар алдында тәүбә итү түгел. Бу – ачы йөрәкне кискәли торган факт белән күзгә-күз очрашу.

Шигырьләр укыганда күз алдында тын һәм һәрбер сүзеңне аңлап калырга омтылган сүзсез залны күрәсең. Бу укылган шигырьләрнең эчке хисләре шахтерларга артык кирәкле булуларыннан түгел, бу – шахтерларның бүгенге әдәбиятка бик нык сусауларыннан, аларның бүгенге әдәбиятны артык кирәксенүләреннән.

Без менә шушы безне кирәксенгән, белемгә, культурага сусаган киң массаның әдипләре, шагыйрьләре булырга, бөтен иҗатларыбызны аларның теләкләре нигезенә корырга тиешлебез.

Донбасс шахтерлары бездән үзләренә кирәкле әдәбиятны сорыйлар. Шәриф аганың «Козгыннар оясында»гы шахтерлар юк хәзер. Алар инде ундүрт ел эчендә партиянең Донбасстагы көчле кадры булып тәрбияләнгәннәр.

Алар хәзерге көндә бишьеллык планны өч елда үтәргә омтылучы яңа шахтерлар кадры, белем, мәдәнияткә сусаган забойщиклар кадры булып җитешкәннәр.

Шахтерларның тимер – йөрәге,
Корычтан каты аның беләге,
Шахтерларның бүген йөрәгендә
Промфинплан тутыру теләге.

1. Бездә ТАПП членнарыннан бригадалар оештырып, шахтерлар арасына җибәрергә, аларның шахтерлар тормышын өйрәнү нәтиҗәсендә тудырган әсәрләрен альманах итеп чыгарып барырга.

2. ТАППның танылган каләм көчләрен шахтерлар арасына озак мөддәткә эшкә җибәрергә.

3. Шахтерларның үз араларыннан үсеп килгән язучыларны ТАПП кулы астына алып, аларга үсүләрендә бөтен ярдәмлекләрне итәргә, «Атака» журналын бу эшкә ныклап файдаланырга.

4. Эшчеләр районнарында яшәп килгән клублар хәзерге көндә репертуар юклыктан аптырап, нәрсә куярга белми йөриләр. ТАПП бу эшне бүгеннән үзенең эш планына кертеп, эшче районнарындагы клубларны репертуар белән тәэмин итү юлында эшләргә тиеш.

Егерме мең шахтерлар исеменнән ТАППка бүләк ителгән шахтерлар лампасы яктысында без шахтерлар тарафыннан безгә бирелгән социаль заказларны үтәргә тиешлебез.

**ҮЗЕМ ТУРЫНДА**

Үзең турында язу – эшең турында сөйләү дигән сүз. Мондый хәлдә инде үз-үзеңне тәнкыйть итмичә булмый. Язучы һәм шагыйрь өчен үз-үзеңне чын мәгънәсендә большевикларча тәнкыйть итү – бу барыннан да элек үз иҗади эшчәнлегеңә тәнкыйть күзе белән карау дигән сүз.

Минем иҗат юлым – хаталарны җыңү һәм үз-үзеңне аяусыз тәнкыйть итү нигезендә әдәби осталыкны камилләштерү юлыннан гыйбарәт.

Хәзер минем сайланма әсәрләремнең зур җыентыгы[1] (25 басма табак) басылып ята, аларда минем вак буржуаз-бунтарьлык чорымнан алып диалектик иҗат методын үзләштерү[2] һәм шушы метод ярдәмендә шигырьләремдә чын-чыннан пролетариат идеологиясен чагылдыру минем өчен төп лозунг булып әверелгән соңгы вакытка кадәрге иҗатымның бөтен процессы гәүдәләнгән. Әгәр иҗатымның беренче, яшьлек чорында миндә пролетариат революциясенең асылы һәм перспективалары турында ачык төшенчә булмаган булса һәм мин шигырьләр белән революциягә ярдәм итеп булуын белмәгән булсам, хәзер исә инде мин каләм безнең кулларда тормышны социалистик нигездә яңартып коруның һәм кешелекне үзгәртүнең куәтле коралы булуын беләм.

Хәзерге вакытта мин «Киләчәккә хатлар»[3] әсәре өстендә эшлим. Аларда мин киләчәк буыннарга безнең яңа тормыш өчен, яңа кеше өчен алып барган героик көрәшебезне тасвирларга тырышам.

Беренче хатта (1930 елда «Кызыл Татарстан»да басылып чыкты) мин сыйнфый көрәшнең гомуми фонын бирдем. Икенче хатта (басылып ята) колхозчы һәм, гомумән, безнең күчү чоры кешесенең психологиясендәге каршылыклар берлеген күрсәттем.

Өченче хатта мин социалистик хезмәтнең кеше психологиясен ничек үзгәртүен сурәтлим. Мин капитализм дөньясындагы колның хезмәте белән бөтендөнья пролетариатының Ватаны булган безнең Союзда үзара ярыша-ярыша социализм төзүче күп миллионлы массаларның азат, иҗади хезмәтләрен бер-берсенә чагыштырып күрсәтәм.

Киләчәк буыннар рухи үсеш ягыннан, һичшиксез, бездән югарырак торырлар, шуның өчен аларга хат язу минем өчен нинди авыр булуы турындагы фикерне мин хат башында басым ясап әйтеп үтәм. Мин Максим Горький белән очрашкан чакта нинди кыюсызлык тойган булсам, аларга хат язганда да шундый ук кыюсызлык тоюымны әйтәм. Мин, аңар ни әйтергә белми, аптырап калдым, бөек кеше алдында «хур булмас өчен», һәрбер сүземне уйлап кына әйтә башладым, ә ул тотты да минем белән шундый гади итеп сөйләп китте, мин шунда ук үземнең кыюсызлыгымны оныттым. Мин киләчәк кешеләренә дә шундый ук мөнәсәбәт ясыйм, һәрбер проблема бөтенләй яңача куела торган безнең эпохабыз турында аларга гади генә итеп сөйләргә тырышам.

Алтмыш яшьлек Мохтар бабай колхоз оештыру эшендә катнашкан, һәм аны шуның өчен карчыгы җылы куенынннан мәхрүм иткән.

Мохтар бабай аңында – каршылыклар көрәше. Бер яктан, ул колхозның өстенлекләрен, акылы белән уйлап, бик яхшы белә, икенче яктан, хосусый милекчелек гадәтләреннән аерыла алмый. Мал-туарлар җәмәгатьләштерелгән, ләкин Мохтар бабай элек үзенеке булган атны бик нык күзәтеп йөри, кеше күрмәгәндә генә аңа яхшырак азык салырга тырыша. Ә бервакыт аның аты үлеп, бу югалту өчен аның белән бергә колхозчы иптәшләре дә кайгыргач, ул бу атның аңа кадерле булган кебек, башкаларга да кадерле булганын аңлый.

Өченче хатның эчтәлеге, чамалап әйткәндә, әнә шундый. Бу хатлар минем иң зур әсәрем булачак. Мин һәрбер хатны аерым проблемага багышларга уйлыйм. Бер үк вакытта мин колхоз тормышыннан пьеса өстендә эшли башладым[4].

**ЯЗУЧЫДАН**

Пролетариат язучысы, әле төзелеп өлгермәгән, ләкин җиңә алмаслык бер омтылыш белән төзелеп килгән бөек тормыш күренешләрен күрсәтү нигезендә, безнең бүгенге идеалларыбыз алып килгән җиңүләрнең иртәсе белән меңнәрне кызыктыра алырга, аларны шул җиңүләр өчен булган көрәшләргә чакыра һәм оештыра белергә тиешле.

Моның өчен ул бүгенге социалистик экономиканың иртәсе алып килгән җиңүләрне айнык рәвештә алдан күрергә, миллионнарның кул хәрәкәтләре, уй-омтылышларын өйрәнергә, тормыштагы бөтен күтәрелешләрне, бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә, һәрбер тәгәрмәчнең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле.

Пролетариат язучыларының кыйммәте, аларның кирәклеге сыйнфый көрәш һәм социализм экономикасы тудырган яңа хисләрне, яңа уйларны оештыра, ул уйларның, ул теләкләрнең формаларын таба белүе белән, шул теләкләрне массаның йөрәгенә сеңдерә белүе белән үлчәнергә тиешле.

Бөек төзелеш, зур көрәш белән юлбашчылык иткән Коммунистлар партиясе тарафыннан пролетариат язучысы алдына куелган бурычлар – шулар.

Бу томга кергән әсәрләр шушы куелган сорауларга җавап бирә алалармы?

Пролетариат язучысы алдына менә шушындый зур һәм кирәкле сораулар, социаль заказлар куелган бер чорда, бу минем беренче томга кергән шигырьләрне бастырып, масса арасына тарату ялгыш бер адым түгелме?

Татар пролетариат язучылары ассоциациясе члены була торып миңа бу шигырьләрне бастырып чыгару җинаять түгелме?

Беренче томым басылганда, мин менә бу сорауларга җавап бирергә тиешле һәм мин «басылырга тиешле» дип җавап бирәм.

Чөнки бу томга кергән әсәрләр – пролетариат революциясе үзенең дәвамында кешене ничек үзгәртә баруын күргәзә торган тарихи документлар.

Бу әсәрләр минем вак буржуа арасыннан чыгып, Коммунистлар партиясенең еллар буена мине ничек үзгәртә баруын һәм шул нигездә миннән яңа, бүгенге, кирәкле кешене тәрбияләп килүен ачык күрсәтәләр.

Яңа кешеләр, революциянең билгеле бер чорында билгеле бер бурычларны үтәүче көчләр алар күктән төшмиләр, шулай ук шул бурычларны үтәргә яраклы булып анадан да тумыйлар. Алар бүгенге яңа тормыш өчен булган бөек көрәшнең эчендә тәрбияләнәләр, ныгыйлар, һәр көн булып үткән дифференциацияләр аркылы үтеп, бөек көрәшкә кирәкле кеше булып җитешәләр.

Менә шул тәрбияләү юлы белән пролетариатның бөек авангарды үзенә кирәкле көрәшче көчләр җыйный һәм бүгенге көндә дә һичбер көч тарафыннан җиңелмәслек бөек көрәшчеләр армиясен тудыруда дәвам итә.

Минем иҗатым, минем кебек вак буржуа арасыннан чыгып, Коммунистлар партиясенең юлбашчылыгы астында тәрбияләнеп, пролетариат идеологиясен үзләштерүдә зур эволюция ясаучы бик күп кешеләрнең йөрәкләре аркылы үткән хисләрен чагылдыралар.

Шуның өчен дә минем үсүемә характерлы булган бу әсәрләр басылырга тиешлеләр дип уйлыйм. Һәм алар бер-берсеннән аерылмаслык бербөтен документ булып саналырга, укыган, тикшергән вакытта югарыда әйтелгән нәрсәләр күздә тотылып, тәнкыйть карашы белән укылырга тиешлеләр...

Үсү чорындагы пролетарит идеологиясенә чит булган идеология кытыршылыкларын эченә алган бу томны җыеп бастыру миңа, киләсе шигырьләремне пролетариат идеологиясе нигезенә корып, бүгенге сорауларга җавап бирерлек итеп яза башлавымны җиңелләштерәчәк.

Шулай итеп, бу том белән үткәннәргә ишекләрне ябып, социализм экономикасы ачып килгән яңа ишекләр алдына миллионнар белән бергә яңа, бөек теләкләр белән килеп басам.

## ТӘНКЫЙТЬ ТУРЫНДА

Күптән түгел генә «Литературная газета»да тәнкыйть турында дискуссия[1] булып үтте. Дискуссиягә катнашкан күп кенә язучылар рус әдәбиятында тәнкыйтьнең бик нык аксавын, үз өстенә төшкән бурычларны үти алмавын яздылар. Алар арасында тәнкыйтьчеләрнең, гомумән, кирәклеге бармы, дигән вопросны куючылар, хәтта язучы өчен дә, укучы өчен дә бернәрсә дә бирмәвен әйтүчеләр булды.

Яшь татар әдәби тәнкыйтенә карата мәсьәләне алар куйган рәвештәрәк куярга мөмкин булса да, интернациональ әдәбиятка карата мәсьәләне алай кую дөрес түгел. Рус әдәбиятында зур әдәби белемле, хәзерлекле марксист тәнкыйтьчеләр бар. Алар рус пролетариат әдәбиятының барышына гына түгел, бүгенге көндә бөтендөнья пролетариат әдәбиятына зур-зур йогынтылар ясап баралар.

Пролетариат әдәби көндәлеге китереп чыгарган бик кирәкле әдәби проблемаларны хәл итү юлында кызу-кызу фикер алышулар алып барыла. Нәтиҗәдә пролетариат әдәбиятының үсеп алга китүенә кирәкле булган юлларны билгелиләр.

Без татар пролетариат әдәбияты өстенә төшкән бик күп бурычларны яшьлегебезгә, көчебез азга сылтап, мәсьүлияттән котылырга тырышабыз. Ләкин татар пролетариат әдәбияты, татар пролетариат тәнкыйте алдында да шул ук гомуми бурычлар тора. Шул ук көндәлек проблемалар дөрес рәвештә хәл ителүне, күбесе татар пролетариат әдәбиятына хас рәвештә хәл ителүне сорыйлар.

Бездә бу юлда нәрсәләр эшләнгәне бар?

Нинди проблемалар күтәрелгәне бар?

Иҗат методы турында тәнкыйтьнең нәрсә эшләгәне бар?

Тематика, стиль мәсьәләләре турында нинди төпле чыгышлар булды?

Әдәбияттагы идеология талпынышларына карата нинди төпле анализлар булганы бар?

Гомумән, бездә тәнкыйть бармы? Ул ни дәрәҗәдә, бүгенге теләкләрне үти аламы, яшь язучыларны тәрбияләүдә нинди урын тота? Аның дөрес, марксизмча булуы ни дәрәҗәдә?

Бездәге тәнкыйть – тәнкыйтьме, рецензияме?

Бу сораулар, билгеле, куелырга һәм дөрес рәвештә җавап алырга тиешләр.

Бу мәкаләдә мин татар пролетариат әдәбиятындагы тәнкыйтьтәге җитешсез якларның кайберләренә генә тукталырга уйлыйм.

Бездә танылган, исем бирелгән марксист тәнкыйтьчеләр булган кебек... марксизмны үзләштерүдә, аны әдәбиятка яраштыруда ныгып бетмәгән яшь тәнкыйтьчеләр дә бар...

Тәнкыйтьчеләребез арасында әдәби багажы күп булган кешеләр булган кебек, әдәбияттан элементар белемле кешеләр дә юк түгел...

Менә бу нәрсәне сызып үтеп, түбәндәге нәрсәләрне әйтергә кирәк. Бездә шагыйрьләрне тәнкыйть итүчеләр булса да, марксизмны әдәбиятка яраштыруда ныгып бетмәгән, әдәбиятны белү дәрәҗәләре түбән булган иптәшләр тарафыннан ясалган ялгышларны күргәзүче, тәнкыйть итеп баручы иптәшләр юк. Яки аларның ялгышларын күрсәтеп чыгу сирәк була. Күп ялгыш фикерләр матбугатка ташланган килеш төзәтелми калалар. Бу – бер.

Икенче, бездәге тәнкыйтьтәге чыгышларда (кайберәүләре исключениегә алына) бик зур схематизм, сайлык хөкем сөрә. Алынган әсәрләр турында язылган фикерләр өстән, язучы өстенә ташланган гаепләр ышандырырлык булмыйлар. Алар күп вакытта:

– шигырь вак буржуа идеологиясендә язылган;

– фәлән иптәшнең бу шигыреннән мещан идеологиясе исе аңкый дигәнрәк төстә ташланган гаепләр булалар.

Вак буржуа идеологиясе ул шигырьнең кай җирендә, нәрсәсендә, бу нәрсәгә пролетариат идеологиясе белән ничек карарга?

Менә бу нәрсәләргә ул тәнкыйтьләрдән җавап табу авыр. Мондый тәнкыйтьләрнең язучыга файдасы булмаган кебек, хәзерлексез укучыны да саташтыру гына була. Инде шагыйрьнең уңышлы якларын күргәзү дә шул ук схематизм белән чикләнелә.

Шигырьнең идеологиясенең дөреслеге нәрсәдә, образларның байлыгы нәрсәдә, фәлсәфәсе кайда? Бу сорауларга тәки җавап биреп булмый. Мондый мисаллар... тулып ята.

Бу схематизм бик нечкә юллар белән формализмга, переверзевщинага[2] барып тоташа.

Мисал итеп төрле кешеләр тарафыннан минем әсәрләргә язылган тәнкыйтьләр эченә кереп карыйк.

Минем ике-өч ел язган шигырьләремә тәнкыйтьләргә күз төшерсәк, иң күп чәйнәлгән нәрсә «Такташ ата казлар турында гына яза, Такташ тавыклар, мәчеләр турында гына яза» дигән сүзләр.

Дөрестән дәме шулай? Минем шул өч ел эчендә язган шигырьләрем эчендә ата казлар, тавыклар турында язган шигырьләр, өч-дүрт мең юл эченнән чүпләп алганда, йөз юлга тулар микән? (Җитмеш юллар чамасы.)

Соң бу иптәшләрнең, соң бу чәйнәлүнең секреты нәрсәдә?

Бу иптәшләр шигырьдәге төп мотивлар белән иярчен настроениеләрне яки әсәрдәге декорацияне бутыйлар. Алар минем шигырьләрдәге декорацияләргә шулкадәр әһәмият бирәләр ки, хәтта үзләре дә сизми формализмга, схематизмга биреләләр...

Мондый вак нәрсәләрне зур бер нәрсә итеп еллар буе язу XVII гасырда Европадагы бөтен университетларның еланның Адәмне тыелган җимешне ашарга нинди телдә котыртуы турында еллар буе дәвам иткән бер бәхәсне искә төшермиме?

Атлар, сыерлар, казлар – болар әдәби әсәрләрнең һәрберсендә бар. Ат, сыер, тавык керми крәстиян тормышыннан алынып язылган бер хикәя яки бер роман да таба алмабыз.

Ни өчен миңа аларны декорация итеп кулланырга ярамый? Ни өчен җитмеш юл өчен еллар буе бу кадәр скандал алып барырга? Тавыклар контрреволюционерлар түгел ләбаса.

Шул ук мәсьәлә турында тагын бер көлке мисал: «Коммуна» газетасында (85 нче номер, 30 нчы ел) Г.Г. дигән бер егет яза[3]. Бу егет яшь әле. Үз фикерен әйтер дәрәҗәдә сәяси белем югарылыгында тормый торган егет, ул шул югарыдагы иптәшләргә койрык булып, уйламый яза.

«Такташның әсәрләрендә ата казлар яки шыр тилеләр,

Көтүендә хәзер кем кәҗәсе
Алдан чабып йөри торгандыр...

Малайларың синең безнең кебек
Кыяр-шалкан эзләп йөрмәсләр...
Әтәч пешергән учаклар...

дан башканы күрә алмыйбыз. Нинди генә шигырен кайдан гына укып карама, аннан шыгырдап торган ата казлар... күрәбез», – ди. Шулай гынамы икән? Шул юлларны мисалга алып, ул Такташны контрреволюционерлыкта гаепли. Бу тәнкыйтькә җитди акыл белән язылган нәрсә итеп карап булмый. Монда гади булмаган абсолютизмга китү бар. Ләкин бу миңа язылган тәнкыйтьләрнең ачы бер рәвеше. Әйтегез, зинһар, Г.Г. тарафыннан бу алынган мисаллар укучыларны минем контрреволюционерлыкка ышандыра алалармы? Бу, шигырьдәге декорацияләрне җыеп, шуларны төп вакыйга итеп күрсәтергә тырышу түгелме? Соң шул мисаллар алынган шигырьләр эчендә төп мотивлар кая?..

Мине аклап шул ук алган шигырьләрдән башка мисал китерергә кирәкми.

Үземне аклау өчен аларны монда күргәзеп китү кирәкми.

Бу, тәнкыйтьчеләр тарафыннан төп мотивларны сүндереп, йөз юллык шигырьдән ике юл алып, җөмләләрнең койрыкларын кисеп, эттән куян ясарга тырышу түгелме?

Бу нормаль, объективный тәнкыйтьме? Һәм бу методны куллану «тәнкыйтьчеләр»гә нәрсәгә кирәк? Моңа җавап бирмим. Минем шигырьләрне укучылар бу нәрсәгә үзләре җавап табарлар.

Инде шул ук Г.Г-ов минем «Казан» шигырен мисалга алуына килим. Бу шигырь вакытында зур шау-шулар белән үтте. Бу шигырь солтангалиевчеләрнең[4] Казанда оялаган чорында «Дон-Кихотлар, милләтчеләргә» ... каршы язылган иде. Ул вакытта солтангалиевчеләр, бу шигырьнең кемгә язылуын яхшы аңлап... русчага тәрҗемә иттереп, ЦКга кадәр барып җиткәннәр иде. Ул шигырьне сәхнәдә укыгач, Борондоков[5] кебек егетләр, сәхнә артына кереп, «күрмәгәнне күргәзергә» дип тә вәгъдә биргәннәр иде...

## «ПАРТИЯСЕЗ» ҺӘМ ПАРТИЯЛЕ ШИГЫРЬЛӘР ТУРЫНДА

(*Иҗат хатлары*)

Бүгенге пролетариат әдәбияты ул безнең уйларыбызның хәрәкәте, идеяләребезнең омтылышы булырга тиешле.

Без шагыйрьләрдән менә шул идеяләребез өчен булган көрәштә аерым бер хезмәтне үти ала торган җанлы шигырьләр сорыйбыз.

Без язучылардан яши һәм хәрәкәт итә ала торган һәм укучыларның уй юнәлешләрен хәрәкәт иттерә торган әсәрләр таләп итәбез!..

Буржуа идеалист, формалист теоретиклары (бүгенге көндәге Кант шәкертләре[1]) сәнгатьтән партиячелекне куып, форманы гына нигез итеп алырга маташалар һәм форманы гына алга сөреп, сәнгатьне, әдәбиятны сыйнфый көрәштән аерып алырга теләсәләр, без сәнгатьтә беренче урынга партиячелекне куябыз. Форманы без билгеле (конкрет) бер идеяне җанландыруга, хәрәкәт иттерүгә ярдәмче бер элемент, икенче төрле әйткәндә, идея белән аерып ала алмаслык бәйләнешле бер нәрсә итеп алабыз.

Тарих тарафыннан бетәргә хөкем ителгән бөтен дөнья буржуазиясе, пычраклыгы һәм канлылыгы белән мәшһүр нажива, хосусый милек идеясеннән башка һәрбер идеягә каршы булса, без әдәбиятта, сәнгатьтә пролетариат сыйныфы торган һәм кешелек дөньясын хурлыклы түбәнлектән чыгаруга алып барган иң бөек идеаллар өчен көрәш алып барабыз.

Без әдәбият, сәнгать коралы аркылы шул идеалларны чагылдыруны, массаның фикерен шул идеаллар тирәсенә оештыруны иң беренче урынга куябыз. Әдәбият шул безнең бөек идеалларыбыз өчен булган көрәшебезгә ярдәм итә алса гына, җанлы, безгә кирәкле әдәбият итеп таныйбыз. Киресе булса, без ул әдәбиятны үле бер форма, тормышта яшәү, хәрәкәт итү функцияләре булмау сәбәпле, үләргә мәхкүм булган зәгыйфь бер әйбер яки турыдан-туры буржуа сыйныфының көрәшенә ярдәм итүче бер әдәбият итеп карыйбыз.

---

Илебездә һәм бөтен дөнья күләмендә сыйнфый көрәшнең кискенләшүе шулай ук көндәлек социализм төзелешенең тирәнәя, тармаклана баруы безнең алдыбызга яңадан-яңа сораулар, яңадан-яңа мәсьәләләр тудырып тора.

Социализм төзелеше эчендә кайнап чыккан яшь иҗат көчләре әдәбиятка килә.

Бездә хәзерге көндә массаның иҗатына капитализм илләренең һичберсендә булмаган һәм була алмаган рәвештә киң күләмдә урын бирелә, ярдәм ителә. Менә шундый мәсьүлиятле бер моментта пролетариат әдәбиятының барышына маяклар билгели бару, әдәбиятыбызда киң күләмдә таралган кайбер авыруларга каршы рәхимсез көрәш ачу бүгенге көндә иң зур бер мәсьәлә булып безнең алдыбызга килеп баса.

Минем өстәлемдә өем-өем булып әдәби әсәрләр, шигырьләр ята. Бу әсәрләрне язучылар арасында үзенең иҗатында башлангыч бер чор уздыручылар булган кебек, фамилияләрен монда язып китсәң, зур җәнҗал чыгарырдай «стажлы» булган, үзенең зур пролетариат шагыйре булуына ышанган, шуны дәгъва итеп йөргән иптәшләр дә күп.

Югарыда куелган сораулардан чыгып, бу иптәшләрнең әсәрләрен тикшереп чыкканда, безнең әдәбиятыбызда булган бик күп авыру һәм җитешсез якларны күреп була:

1. Шигырьне рифма төзү итеп кенә аңлау.

Шигырьдәге оригинальлекне шигырьнең юлларын «кызыклы» итеп бүлгәләп, төрле фигуралар ясап төзүдә дип белү (Теләш), яңа рифмалар белән генә бизәүне яңа форма, оригиналь шигырь дип аңлау. Фикерне шигырьләштерүнең үзенчәлекләрен тирәнтен аңлап җитмәү.

2. Хикәяләрне, драмаларны язган вакытта схема рәвешендә язу, типларны начар типлар, яхшы типлар итеп икегә генә бүлеп йөртү. Начарларның һәммәсен 100 процент (яки бер-берсеннән аерылмаслык) начар, яхшыларның да һәммәсен бер дәрәҗәдә яхшы итеп, типларны бирүдә диалектика методы кулланмау. Әсәрнең бөтен әһәмиятен сюжетның баш әйләндергеч булуына гына юнәлдерү яки:

3.Турыдан-туры формализм.

Ниһаять, иң әһәмиятлесе –

4. Әсәрне конкрет бер идея нигезенә кормау яки фикер, идея ягы бик түбән булуы.

Бу «идеясезлек» бүгенге тормыш куйган тематикадан читкә китүдә генә түгел, бәлки бүгенге тематиканы алып та, аны тирәнәйтми бирүдә, «пафослы» терминнар белән генә канәгатьләнеп, өстән йөзүдә, укучы массага бер яңа фикер дә бирмәүдә.

Бездә кайбер иптәшләр бар, аларның шигырьләренең исемнәре дә «кызыл» була, шигырьләренең эчләрендә дә бик күп ясалма пафослы сүзләр була. Ләкин ул пафослы сүзләр, билгеле бер фикерне, идеяне җанландыруга хезмәт итмәүләре сәбәпле, буш, җансыз, нәфрәтләндерерлек дәрәҗәдә эшсез – «безработный» сүзләр генә булып калалар.

Безнең социализм өчен булган көрәшебездә бер функцияне дә үти алмаган, конкрет бер идеясе булмаган «безработный» шигырьләргә Теләшевтә[2] бик күп мисаллар табып була.

Менә аның «Җиңү чорында» дигән шигыре:

Көнгә карап
Көлгән гигант завод
Эшчеләрне коча эш белән;
Ил батыры кебек (?)
Җиңеп бара
Мактанырлык бөек көч белән.
Станокны сөйгән токарьларның
Сталь йоткан төсле күкрәге.
Җиде сәгать, диеп, сменабыз,
Мастер Гәрәй ямьле күкрәде.
Стеналар йотты Гәрәй тавышын,
Чуен йөзләр ачык елмайды,
Партиялеләр сөйгәч безнең уйны,
Эшче өчен шунысы уңайлы...
Завод,
Җырларымның иң батырын,
Иң матурын сиңа багышлыйм;
Синдә күрәм көрәш чәчәкләрен,
Күргәнем юк моңны-сагышны...
Җырларым да минем синдә туды,
Синнән чыкты байтак уйларым;
Менә бүген янып, ялкынланып
Каршы алдым җиңү елларын.

Бу шигырьдә «кызыл», «пафослы» сүзләр дә бар. Вак буржуача заводка мәхәббәт игълан итү кебек нәрсә дә бар. Ләкин...

Бу шигырь белән Теләшев нәрсә әйтергә тели?

Бу шигырьнең төп идеясе нәрсә?

Бу шигырьдән укучы нинди яңа фикер ала?

Шигырьнең исеме булган «Җиңү чоры»ның бу шигырьдән нәрсәсен күреп була?

Билгеле, бу шигырьдән боларның берсенә дә җавап табып булмый.

Тик

Партиялеләр сөйгәч безнең уйны,
Эшче өчен шунысы уңайлы, –

дигән җөмләсеннән Теләшевнең сәяси наданлыгын, Коммунистлар партиясен эшчеләрдән аерып кую кебек зур сәяси ялгышын гына аңлап була.

Бу шигырь, иң җиңел рәвештә әйткәндә, беспартийный, бүгенге социализм көрәшенә бертөрле дә файда китерми торган, яшәү функцияләре булмау сәбәпле, үзен-үзе үтерергә мәҗбүр булган халтура шигыре.

Фикер, идея теләнчелегенә яки беркемгә кирәксез арзанлы фикерләргә мисал итеп шул ук Теләшнең «Большевиклар язы», «Таң яна» һәм башка бик күп шигырьләрен алырга мөмкин. «Кызыл казарма» дигән шигырендәге:

Таң ул шулай
Кайбер көнне
Тирбәлдереп зәңгәр томанны
Җиргә ия.
Ал байраклы башын
Нурга манчый
Яшел урманны... –

кебек юллары фикерсезлеккә, сүзләрнең, образларның «безработный» булуына классический пример була алалар...

Минем яшь язучыларның бик күпләреннән:

– Синең язарга утырганда башыңда эшләнеп беткән әйтер бер фикерең буламы? – дип сораганым бар.

Аларның бик күбесе, бу сорауны беренче мәртәбә ишеткән шикелле, аптырап калгаладылар.

Ә бит язучының укучы массага әйтергә теләгән конкрет идеясе булу, әлбәттә, кирәк. Монсыз бүгенгегә кирәкле әдәби әсәр тудыру мөмкин түгел.

Менә шул, язарга утырганда, бик күп язучыларыбызның, башларында әйтәчәк фикерләре, конкрет идеяләре булмау сәбәпле, утыз юллык шигырьләрендә үзләре белгән бөтен нәрсәне кертеп бетерәләр. Аларның бер үк шигырьләрендә колхоз да була, ялган буяулар белән кеше ышанмаслык итеп буялган мартен күзле, домна йөрәкле «эшчеләр» дә була, бөтендөнья революциясе дә була, коммуна да, Чан Кай-ши[3] да – бөтен нәрсә җыйналган була. Бер юлы бер нәрсә турында сөйләсә, икенче юлы – икенче нәрсә, өченче юлы өченче нәрсә турында сөйли. Менә шуннан шаблон туа. Шагыйрь бернәрсә турында да укучының башында калырлык links бербөтен фикер бирми. Бернәрсә турында да төпле тукталмый, һәммә нәрсәне өстән, гади күренеше һәркемгә билгеле бер төсендә кабатлый.

Менә мондый шигырьләр конкрет бер идеяне җанландыруга хезмәт итмәгән кебек, шигырьнең эчендә телгә алынып киткән «колхозның» көндәлек көрәшенә дә бертөрле дә хезмәт итә алмыйлар. Бу иптәшләрнең ниятләре яхшы булуга карамастан, аларның шигырьләре безнең көрәшебездә бер функцияне дә үти алмаган, безнең арабызда яши алыр өчен кирәкле булган әгъзалары булмаган беспартийный, үле шигырьләр булалар.

Соң безнең бүгенге көрәшебезгә кирәкле әсәрләр тудыру өчен нәрсә кирәк?

– Әдәби әсәрне, шигырьне яшәтүче «җаны», конкрет бер төп идеясе булу кирәк!

Язучы язарга утырганда аның башында массага әйтергә теләгән фикере булсын!

Бу – иң беренче һәм иң төп шарт. Ләкин бу шартны үтәү өчен пролетариат шагыйре пролетариат сыйныфының иң югары идеяләре белән сугарылган, пролетариат сыйныфының авангарды торган идея югарылыгында торырга, диалектический материализм белән нык коралланган булырга тиешле. Шулай булганда гына ул бүгенге бөек төзелешнең иртәсе алып килгән җиңүләрне күрә ала һәм шул җиңүләр өчен булган көрәштә туган актуаль мәсьәләләрне вакытында күреп, массага юнәлеш бирерлек бер фикер-теләк белән чыга ала.

Бүгенге көндә төзелеп яткан социализм экономикасы безнең тормышыбызны төбеннән үзгәртә. Без яңа тормыш төзү белән бергә үзебезне дә яңарта барабыз.

Пролетариат шагыйре менә шул үзгәртүләрне тирәнтен сизә барырга, бүгенге экономика тудырган бүгенге яңа кешеләр (пролетариатның авангарды булып барган яңа кешеләр) башында туган яңа уйларны, яңа хисләрне күрә белергә тиешле. Ул шул уйларны, шул хисләрне үзенең йөрәгенә сеңдереп, аларны үзенең йөрәк җылылыгы белән тәрбияләргә, үстерергә, үзендә булган шигъри буяулар белән буяп, бертөрле формага кертеп, пролетариатның авангарды җитәкчелегендә барган массаның йөрәгенә сеңдерергә тиешле.

Безнең кайбер язучыларыбыз үзләрендәге идея түбәнлеген яки идеясезлекне «матур форма», «матур сүзләр» белән капларга тырышалар. Алар үзләренең эчке хисләренә күмелеп, форма «нечкәлекләренә» бирелеп, үзләре дә белми формализмга табан баралар.

Шагыйрьнең яңалыгы «яңа форма уйлап чыгарырга» маташуында түгел, шагыйрьнең яңалыгы – аның яңа хисләрендә, яңа уйларында. Шагыйрьнең яки язучының бүгенге яңа хисләрне, яңа уйларны формалаштыруы өстендә эшләве, шул идеяләрнең формаларын таба белүе – бу аның форма яңалыгы, форма яңалыгын тудыру өстендә эшләве дигән сүз.

Чөнки:

Яңа форманы яңа мөндәриҗә, яңа идея белән генә тудырып була.

Безнең идеалларыбыз күктә яшәмиләр.

Алар безнең конкрет тормышларыбызда, безнең көрәшебез эчендә, бүгенге бай көрәш вакыйгалары эчендә туалар, яшиләр һәм хәрәкәт итәләр.

Димәк:

Пролетариат шагыйре шул хәрәкәтләрнең эчендә торып, бүгенге көрәш тәҗрибәсе белән якыннан таныш булса гына һәм шул көрәштә шул теләкләр өчен көрәшүче булып катнашса гына, үзенең әсәрләрендә бүгенге көрәшкә кирәкле булган актуаль идеяләрне вакытында күреп җанландыра ала һәм аларны, үзенең иҗат аппаратында формалаштырып, массага бирә ала. Киресе булса, ул бүгенге конкрет көрәшебезгә кирәкле булган бер фикерне дә үз башыннан уйлап чыгара алмый. Ул фикер аның башында тора алмый.

Шуның белән бергә, бүгенгегә кирәкле бер идеяне бары көндәлек конкрет бер тормыш күренешләренә бәйләү аркылы гына шигъри рәвештә җанландырып, формалаштырып була. (Үткән тормышны, тарихи вакыйгаларны язганда да бүгенге безнең көрәшебезгә яраклы итеп язганда гына файдалы була ала.)

Ә язучының иҗат складында үзенең фикерләрен шигъри җанландыруга, формалаштыруга хезмәт итә алырлык бик күп, бик бай конкрет тормыш материаллары булу кирәк.

Иҗат складында мондый материалы аз булган язучы бервакытта да үзенең әйтергә теләгән фикерен тулы һәм шигъри бер форма белән бирә алмый. Кирәкле материалы җитми.

---

Инде язучының башында булган билгеле бер идеяне ничек итеп шигъри рәвештә җанландыру, формалаштыру мәсьәләсенә килик. Билгеле, бер язучыга да бу хакта тулы бер рецепт биреп булмый. Һәрбер язучының теге йә бу идеяне формалаштыруда аның субъектив аерымлыклары, шиксез, зур роль уйный. Аның психологик аерымлыклары теге йә бу идеяне формалаштыруда бик күп үзенчәлекләрен катнаштыра. Һәм язучының үзенә характерлы иҗат буяулары, конкрет бер идеяне җанландыруга кирәк булган материалларны сайлый һәм аларны урнаштыра белүе нык үзенчә булуы мөмкин. Бу һәр язучының специфик моментларына бәйләнгән.

Ләкин иҗат методының пролетариат язучыларының бөтенесенә уртак булган төп моментлары турында әйтеп китәргә мөмкин.

Беренче:

Югарыда әйткәнчә, әсәр үзенең эченә безнең бүгенге көрәшебез тудырган конкрет бер теләкне, идеяне алсын.

Ул идея актуаль булсын.

(Бер үк әсәр үзенең эченә күп кенә проблемалар, конкрет идеяләр алуы мөмкин. Ләкин ул конкрет идеяләр әсәрнең төп идеясен ачуга хезмәт итсеннәр.)

Икенче:

Әсәрнең сюжеты, шиксез, шушы әсәр эченә салынган идеяне җанландыруга ярдәм булып төзелсен.

Өченче:

Әсәрнең эчендәге сюжет җебенә тезелгән конкрет материаллар шул әсәрнең идеясен җанландыруга яраклы материаллар булсыннар. Алар әсәрнең идеясен мөмкин кадәр көчәйтеп, тирәнәйтеп бирүгә карата сайлансыннар.

Батырның батырлыгын чәй эчеп утырган чагында күргәзеп булмый. Аның батырлыгын батырлык кирәк булган вакыйгалар эчендә генә күреп һәм күргәзеп була. Шулай ук язучы үзенең әсәрендә ударникны күргәзүне теләк итеп алса, ул ударникның ударниклыгын күргәзә алган эш процессларын, аның эш вакытында туган теге йә бу вакыйгага ничек реагировать итүләрен, хезмәткә булган мөнәсәбәтләрен алырга һәм һәрбер алынган вакыйга эчендә ул ударникны күргәзергә, һәрбер сайланган вакыйга ударникны күргәзү идеясенә ярдәм итәргә тиешле.

Монсыз ударникны укучыны ышандырырлык итеп биреп булмый.

Мисал итеп «Атака» журналында басылган С.Рәфыйков[4] иптәшнең «Сыйныф ордены» дигән шигырен алырга мөмкин. Ул шигырендә иптәш Рәфыйков вагонда күрше бүлмәдә барган бер кешенең ударник булуына укучыны менә ничек итеп ышандырмакчы була:

Миңа күрше генә бер бүлмәдә
Нидер уйлап бара бер кеше;
– Ул – ударник.

(Кайдан автор аның ударниклыгын белгән? – *Һ.Т.*)

Тырыш көрәшче
Кызыл ил өчен...
Ил төзүнең шатлык нурлары
Балкып яна алсу йөзендә,
Ул – тимер бригадир,
Флаг тоткан
Коммун эзеннән...

Ул – ударник, актив...

һәм башкалар, һ.б. ...

Бу ударникны күргәзү түгел, бу – ударник турында кеше ышанмаслык рәвештә сөйләү.

Иптәш Рәфыйков бу шигырендә күршесенең ударник булуына безне никадәр ышандырырга теләсә дә, югарыда әйткәнчә, аның герое ударникны күргәзә торган вакыйгалар, образлар эчендә алынып күргәзелмәгәнгә, укучыны геройның ударник булуына һич ышандыра алмый.

Шигырьнең эчендә шигырьнең төп теләгенә хезмәт итмәгән кайбер образлар булса да, геройның ударник булуын күргәзә торган бер генә вакыйга да, бер генә образ да юк.

Ә бит әсәрнең эченә җыелган материаллар, бер яктан, әсәрнең сюжеты белән нык бәйләнгән булу белән бергә, ул материаллар, һәммәсе бербөтен булып, әсәрнең төп идеясен ачуга ярдәм материаллары булып алынсалар гына, язучы алдына куелган идея җанлана, бертөрле формага керә ала. Шуның өчен әсәрдә бер генә вакыйганы да, бер генә образны да әсәрнең төп идеясен җанландыруга хезмәт итмәгән хәлдә кертмәскә, бер генә образны да «безработный» калдырмаска кирәк. Һәрбер образ конкрет бер вакыйганы җанландыруга хезмәт итүе белән бергә, шул образ аркылы җанланган вакыйга әсәрнең төп идеясен җанландыруга хезмәт итсен. Ниһаять, һәрбер сүз кызылармеец кебек үзенең постында булсын, үзенең ни өчен бу постка куелуын яхшы белсен.

Менә шулай булганда гына конкрет бер идея үзенең формасын таба ала. Киресе булса, менә мондый бер кызыксыз мисал килеп чыгуы мөмкин. Бәдрүш Мокамай[5] иптәш үзенең «Игенчеләр»дә басылган «Кырдан бүләк» дигән шигырендә укучыларга бик ялгыш фикерләр бүләк итә. Ул бу шигырендә кулакларның бетүен, колхозлардагы социализм ярышын күрсәтмәкче була. Һәм:

Кулак оппортунист
Канлы куллар бар.
Ул дошманнар, колхоз үскән саен,
Кислородтан мәхрүм калалар...
Киң кырларда носилкалар тавышы
Яңгырап үтә колак яныннан,
Колхозчылар үлә-үлә эшли,
Җилкәләрен кашый ялгызлар...

Билгеле, кырдан носилкалар белән эшләп үлгән колхозникларны ташый башласалар, ялгызлар башларын кашу гына түгел, колхозга гомергә керәселәре юк.

Мондый ялгыш фикерләр Мокамай иптәшнең әсәренә салынган төп фикерне җанландыруга яраклы булган образларны куллана белмәвеннән килеп чыккан. Үлә-үлә эшләү, кырдан носилкалар белән колхозчыларны ташу образы, бу колхоздагы социализм ярышын, иректә хезмәтне күргәзүгә ярдәм итә торган образлар түгел, киресенчә, бу капитализм илләрендәге, колонияләрдәге коллык хезмәтен җанландыра торган образ һәм сүзләр.

Эшче батраклар телендә коллык хезмәте чорыннан калган «үлә-үлә эшләдем» дигән сүзләр иректә социализм ярышындагы хезмәт процессын җанландыруга ярамый. Димәк, югарыда әйткәнчә, яңа хезмәт, социализм хезмәтен җанландыру өчен яңа образлар, яңа аңлатмалар табарга кирәк. Иске форма, иске образлар яңа идеяне формалаштырырга хезмәт итә алмыйлар.

Монда идея һәм форма мәсьәләсенә тагын бер ачыклык кертеп үтәргә кирәк. Югарыда сөйләнгән «һәрбер идеянең формасын табарга кирәк» дигән сүзләрдән һәрбер идеянең бер генә формасы була икән дигән сүз аңлашылмасын. Без әдәбияттагы форманы, шигырьләштерелгән конкрет бер идея массага аңлаешлы булса, укучының эмоциясен уята алырлык җанлы булса, без бу идеяне формалашкан дип әйтәбез. Ә бер үк идеяне, югарыда әйткәнебезчә, төрле язучы үзендә булган үзенчәлекләр белән төрлечә формалаштыра ала.

Инде тагын бер мәсьәләгә килик.

Безнең кайбер язучыларда тагын бер авыру як бар, алар үзләренең әсәрләрендәге кечкенә генә әһәмияте булган бер фикерне гаҗәеп зур сүзләр белән, төрле фигуралар ясаган булып, кеше аңламаслык хәлгә китерәләр. Шигырьдә фикер никадәр аңлаешсыз – «сложный» итеп әйтелсә, шулкадәр матур һәм көчле әйтелгән дип уйлыйлар. Хәтта андый аңлаешсыз шигырьләрне «фәлсәфи» шигырьләр дип йөртәләр.

Бу нәрсә, шиксез, пролетариат шагыйрьләрендә булмаска тиешле бер нәрсә.

Бу – бүгенге коммунизм идеяләрен массаның йөрәгенә сеңдерү теләгенә каршы һәм буржуа язучыларына хас булган бер як.

Пролетариат шагыйренең «фәлсәфи» булуы аның кечкенә генә бер фикерне дә кеше аңламаслык итеп язуда түгел, бәлки пролетариатның зур идеяләрен, аларның зурлыкларына зарар итми, киң массага аңларлык итеп гади рәвештә җанлы, матур бер форма белән бирә һәм массаның йөрәгенә сеңдерә белүдә. Бездә моңа начар бер күз белән «упрощенчество» итеп карауучылар бар. Бу бик ялгыш караш, упрощенчество ул шул зур фикерләрнең

зурлыкларына зарар китерер дәрәҗәдә шаблонный язуда. Зур бер фикерне аның зурлыгын югалтмый, җиңел рәвештә әйтә алу бу шагыйрьнең талантлы булуын, әйтергә теләгән фикерен әтрафлы рәвештә белүен һәм ялангач формага түгел, бүгенге теләкләргә хезмәт итәргә теләвен күрсәтә.

Кечкенә генә бер фикерне кеше аңларлык итеп әйтә алмау йә шагыйрьнең үзенең каләмен массага хезмәт иттерергә теләмәвеннән, пролетариатка дошман булган идеяләрне яшерергә теләвеннән [...] яки фикерләрен җанлы иттереп бирү өстендә эшләмәвеннән килә.

Чөнки зур идеяләрне җиңел итеп әйтә белү бу шагыйрьнең әсәре өстендә бик нык эшләвен сорый. Чөнки зур бер фикерне массага аңларлык бер телдә әйтә алу ул бик җиңел әйбер түгел.

Пролетариат шагыйре, пролетариат язучысы бу авырлыктан качмаска, үзенең әсәрләре өстендә бик нык эшләргә тиешле.

Шулай иткәндә генә яши, хәрәкәт итә алган, безнең бүгенге көрәшебездәге кирәкле бер идеягә хезмәт итә алган бербөтен әсәр тудырырга мөмкин.

## САНДУГАЧЛАРНЫҢ САЙРАУЛАРЫНА РЕЦЕНЗИЯ

Без шагыйрьләрне начар җырлары өчен эт итеп сүгәбез, моның өчен диалектика материализмы белән яки турыдан-туры күсәк белән коралланган тәнкыйтьчеләребез бар.

Алар шагыйрьләрнең ишек төпләрендә шигырь язуларын көтеп кенә торалар.

Яздымы, «мөкяфәтен» бирәләр.

Һәрбер җырчының җырын басучы редакторлар табылган кебек, һәр җырга тәнкыйть язучы табыла.

Ләкин җыр фронтында дөньяда хәзергә кадәр һичбер кузгатылмаган, һичбер кул тимәгән урын бар.

Татарстанда зур-зур урманнар, матур-матур елгалар бар. Шул урманнарда, елга буйларында сайраучы меңнәрчә сандугачлар бар.

Алар җәй буена су буйларындагы әрәмәлекләрдә, урманнарда җырлар сочинять итеп яталар һәм, редактордан һичбер рөхсәт алмый торып, шул сочинять иткән җырларын җырлый бирәләр.

Әле бер генә тәнкыйтьчебез дә аларның җырларына тәнкыйть, рецензия биргәне юк. Ул җырларның идеология яклары һичбер тикшерелгәне юк.

Бу йонлы колак, канатлы урман шагыйрьләре, бәлки, буржуа җырын җырлый торганнардыр. Алар, бәлки, төрек, гарәп илләреннән Татарстанга кайтып пантюркизм[1] җырларын җырлап, үзләренең идеяләре белән массаны сугарырга маташа торганнардыр...

Кайберәүләр, бәлки, мине кеше психологиясенә хас булган әйберне кошларга механик рәвештә күчерүдә гаепләр. Сандугачларның җырларында нинди идеология булсын, дияр.

– Юк, иптәшкәй, ашыкма!

Быел Татарстанның ашын ашап, суын эчеп, матур урманнарында, дачаларында рәхәтләнеп җәйләп киткән сандугачларның кайберәүләргә бик тирән йогынты ясап киткәннәрен күрәбез.

Берничә факт алыйк.

Борнаев кебек кайбер кешеләр, партия директиваларын үтәргә дип авылларга, сыйнфый көрәшнең кызган бер урынына җибәреләләр. Ләкин алар урман араларында, күл буйларында йөреп, сандугачларның җырларын тыңлап, шуңа исереп, сыйнфый көрәшне бөтенләй онытып кайталар.

Специально сандугачлар тавышын тыңларга дачага чыгучы Тарпищев[2] кебек кешеләргә сандугачларның тәэсире тагын да зуррак була.

Алар, шул әрәмәлекләрдә сайраучы сандугачларның тавышларын тыңлый-тыңлый, теория чыгаралар.

– Татарстанда матур елгалар бар.

– Татарстанда гөлгә күмелгән урманнар үсә.

Ул матур урманнарда моңлы итеп сандугачлар сайрый, аларның тынычлыкларын бозучы якын тирәдә сыйнфый көрәш тә юк.

Шундый матур илдән аерып, Татарстан колхозчыларын социализм төзим дип ничек итеп Донбасс кебек ерак илләргә җибәрәсең?

Татарларны үзләренең җәннәт кебек матур илләреннән ничек итеп урыс-улак арасына олактырасың?

Сандугачлар йогынтысының никадәр тирән булуын бу теорияләрдән бик яхшы аңлап була.

Бигрәк тә Тарпищевның кайчандыр «сул» булып йөрүләрен, аның 22 нче елларда шул ук Донбасс эшчеләре арасында «суллар» сүзләре астында русификация теориясен таратып йөрүләрен искә алганда, бу бигрәк тә ачык булып күз алдына килеп баса.

Шулай булгач, бу «сандугачларның» Гаяз Исхаковлар[3] заказы буенча, солтангалиевчеләр идеологиясен җырлаулары турында башта нинди шөбһә калырга мөмкин.

Дөрес, Татарстанда матур урманнар да бар.

Гөлгә күмелгән әрәмәлекләр дә бар.

Сандугачлар да сайрый.

Татарстан сандугачлары, бәлки, андый начар идеологияле җырлар да җырламый торганнардыр. Бәлки, алар бер сыйныфның да файдасын күзәтми торган «беспартийный» җырлар җырлый торганнардыр.

Эш урманнарда да, сандугачларда да түгел.

Эш социализм төзүче партияле кешеләрнең, сандугачларның «партиясез» җырларын тыңлаганда да, партияне, аның социализм өчен булган бөек көрәшен онытмаска тиешле булуларында гына.

Эш партияле «сандугачларның»[4] җырларына да вакытында отпор бирә белүендә.

Татарстан эшче-колхозчылары, партиянең социализм төзелеше өчен көрәшкә чакыру тавышын ишетү белән:

– Матур урманнарны да,

– Сандугачлар тавышын да онытып, Донбасска, күмер фронтына унбер мең эшче бирделәр.

Вокзалда социализм төзү фронтына ирекле рәвештә Донбасска баручы дүрт йөз егерме кешелек яңа бер эшелон туктаган.

Оркестр, вокзалны яңгыратып, пролетариатның бөек маршын уйный.

Бу марш «сандугачлар» җырын күмә.

Бу марш бөек көрәшкә, соңгы җиңүләргә чакыра.

Бу марш социализм төзелешен тизләтергә, бишьеллыкны дүрттә үтәргә өнди.

Бу – «Интернационал» маршы[5].

Эшелондагы шахтерларның йөрәкләре бу чакыруга җавап бирәләр:

Без – ударниклар, тауны тишәрбез,
Күмер пластларын без ишәрбез.
Күмердә булган бишьеллык планны
Дүрт елда арттырып без үтәрбез.

**БОХАРАДА УКУ ҺӘМ УКЫТУ ЭШЛӘРЕ**

Быел Яңа Бохарада ир балалар өчен – реальный училище, кыз балалар өчен гимназия ачылып, 16 августта кабул итү имтиханнары башланды. Бу мәктәпләргә мөселманнардан да егерме бишкә кадәр бала кереп калды.

Милли мәктәпләребез дә юлга салынды диярлек. Җәнабе гали Бохара әмире[1] Яңа Бохарадагы мәктәп өчен шәһәрнең уртасында олуг бер бина вә 20000 сум акча вакыф итте. Бинасы зур, унике бүлмәдән гыйбарәт, ашханәле, зур амбарлы.

Иске Бохарада исә мәктәп өчен бина табылганы юк. Бина табып бирер өчен өч кешедән гыйбарәт бер һәйәт төзелде. 24 май җыелышында мәктәпләрне идарә өчен биш кешедән бер һәйәт төзелгән вә мәгариф юлына 8000 акча тәгаен ителгән иде. Нәшре мәгариф һәйәтенең карары буенча иске мөгаллимнәрне урыннарыннан чыгарып, алар урынына эшлекле мөгаллимнәр чакыртылды. Бер мөгаллим вә мөгаллимә – Яңа Бохарага, вә бер мөгаллим – реальный школага.

Мәктәпләрне җылытыр өчен бер вагон утын алынырга карар кылынды. Әгәр дә мөгаллимнәр килеп җитә алса, 1 сентябрьдә укулар башланачак.

Шәһәр думасына сайлаулар мөнәсәбәте илә мондагы татарларда ярыйсы гына хәзерлекләр күрелә. Барлык татар вә кавказлылар аз булганга, аерым бер партия ясалмый, бөтен төрек-татар халкы бер байрак астында с. революционерлар партиясенә кушылырга булдылар. Ике яки өч гласный[2] үтәр дип өмет ителә.

1 августта Бохара яшьләре тарафыннан кружка илә сбор ясалды[3]. Яңа Бохарадан 556 сум 79 тиен, Иске Бохарадан 1610 сум, җәмгысы 6171 сум 79 тиен җыелып, саф файдадан килгән 900 сумны Анатоли[4] мөселманнары файдасына, 900 сумны Җидесуда[5] ач-ялангач калган кыргыз кардәшләремез файдасына, 350 сумны төрек әсирләре [6] файдасына бүленеп, урыннарына перевод кылынды.

Җәмгыятькә ошбу һиммәт ияләреннән иганәләр тапшырылды: Кушбиге[7] җәнапларыннан 1000 сум, җәнабы казый Кәланнан[8] 2000 сум, Кушбиге Бәян җәнапларыннан 100 сум, гаскәр башыннан 25 сум, рәис әфәндедән 90 сум, сәүдәгәрдән мирза Мөхеддинов 1000 сум, Хәмитхан Дәүликамов 25 сум, Гали Дәүликамов 15 сум, ваклап 55 сум. Һиммәт ияләренә җәмгыяте хәйрия самими калебтән тәшәккер кыйлып, киләчәктә һәм шундый һиммәт ителүен өмет итәдер.

**БОХАРА ХӘБӘРЛӘРЕ**

16 сентябрьдә Яңа Бохарада татар яшьләре тарафыннан җәмгыяте хәйрия файдасына әдәбият кичәсе ясалды. «Кызлар шулай кызык иттеләр» һәм «Татар солдатының үлүе», «Паша-паша» уены, декламацияләр вә башкалар куелды. Уйнаучылар яхшы уйнадылар. Халык Яңа Бохарада икенче кат куелган бу ирекле кичәдән бик мәмнүн булып калды. Бохарада электән театрларда мөселманнар бик аз катнашалар иде. Бу кичәдә күбесе катнашып, театрның тулы чыгуына сәбәп булдылар. Бу кичәне булдыруда иң күп авырлыклар күргән берничә һиммәтле яшьләр бар иде. Шул берничә яшь фикерлеләр, үзләренә булган зарарга карамастан, булдырырга тырышканлыклары өчен җәмгыяте хәйрия анларга матбугат аркылы чын күңелдән тәшәккер итәдер. Театрның бөтен сборы 2000 нән артыграк булды. Саф файда 1300 сумнан ашты.

15 сентябрьдә җәмгыяте хәйриянең гомуми җыелышы булды. Мәҗлестә Милли Шурага[1], Мәскәү Мөселман хәрби комитетына[2], Ташкент комитетына акча җыйдылар.

Җыелган акчадан Ташкент комитетына 200 сум, Милли Шурага 300 сум, Мәскәү комитетына 300 дән артыграк җибәрделәр.

Мәскәү хәрби комитетына булганы Мәскәү вәкиле Сафа әфәнде Гыйбадуллинга тапшырылды.

Моңардан башка Мәскәү хәрби комитетына әмир хәзрәтләренең 2000 сум иганә кыйлганлыгы мәгълүм булды.

**БОХАРА ФАҖИГАЛӘРЕ**

10 декабрьдә Бохараның һиммәтле яшьләреннән Хөсәен Хуҗа Караул биге[1] һәм Хәлил әфәнделәр төнлә йокыларында вакытта Кушбиге адәмнәре тарафыннан үтерелделәр. Җәсәдләре былчырак бөһтаннар илә тәхкыйрь ителде. Бохарада «Бу кяферләр кичә фахешханәдә булганнар, сәрхуш булган соң, берсен берсе кыйнап үтергәннәр» дигән ялган хәбәр тараттылар.

Күптән түгел Яңа Бохарада идарәи хакимият солдат вә эшчеләр кулына күчкән иде. Шул вакыт кәнҗ бохарлылар[2], үзләренә ярдәм итмәсләрме дип, исполнительный комитетка берничә нугай керткәннәр иде. Бу өметләр бар да бушка чыктылар. Исполнительный комитетка кергән кешеләр бер тарафтан – рабочийларга, икенче тарафтан әмиргә тәрилкә тотып, кәнҗ бохарлыларны ачыкта калдырдылар. Бунларның мәнфәгатьсезлекләре

аркасында солдат вә эшчеләр советы әмиргә «үз мәсләгегездә үзеңез хакиме мотлаксыз, яшьләр илә безнең мөнәсәбәтемез юк, теләсәңез нишләңез» дигән карар чыгарып бирде. Менә шуннан соң сарай тарафындагы тәрәккыят дошманнары, көчәеп, яшьләргә каршы хәрәкәт башладылар. Безнеңчә, исполнительный комитетка кергән кешеләр бөтен көч вә куәтләре илә яшьләрне химая кыйлырга тиеш иделәр. Бохарадагы Русия вәкиле Введенский солдат вә эшчеләр советы тарафыннан төшерелде. Урынына икенче кеше куелды.

**ЯҢА БОХАРАДА МОХТАРИЯТ КИЧӘСЕ**

Һиммәтле яшьләр, җәмгыятьләремезнең мохтарият көненә әһәмият бирмәүләрен күреп, 13 декабрьдә мәүледеннәби шәрәфенә мохтарият кичәсе ясадылар. Кичә өч кыйсемнән гыйбарәт булып, «Имчеләр корбаны» исемле драма илә «Ахмак» исемендә комедия уйналды. Соңыннан, туташларыбызның иштиряке берлә хор төзелеп, милли көйләр җырланды. Декламацияләр сөйләнде. Соңыннан лезгин кардәшләремез тарафыннан кавказ биюләре күрсәтелде. Кичә гаять рухан үтеп, халык мәмнүн булып таралды. Расходтан башка саф файда 1888 сумнар тирәсендә. Шуның өстенә Һади Такташев аркылы подписной лист берлә төрле кешеләрдән 172 сум һәм Мифтахетдин вә Низаметдин Арслановлар[1] илә Галимҗан Акчурин[2] тарафыннан җыйналган акчалар бергә кушылып, җәмгысы 2000 сумнан артык сума мохтарият исеменә җибәрер өчен «Тәрәккый» җәмгыятенә тапшырылды. Һиммәтле яшьләремезгә вә шулай ук Яңа Бохарада беренче мәртәбә сәхнәгә чыгучы вә кичәдә армый-талмый хезмәт итүче туташ вә ханымнарымызга, Бохара кызлары арасында фикри инкыйлаб ясауга сәбәп булулары вә яшьләрнең сәхнәдәге кимчелекләре тутырылуы өчен күпме тәшәккер ителсә дә ярыйдыр.

**ХИВА ВӘКИЛЛӘРЕ**

10 гыйнварда шуралар хөкүмәте белән даими мөнәсәбәт ясау өчен Хивадан Мәскәүгә таба унике кешедән гыйбарәт бер һәйәт үтте. Һәйәтнең башында Төркия дарелфөнүнен бетергән яхшы мәгълүматлы Бикҗан иптәш Рахман углы булып, аның белән мөсахәбәбездә Хивада эшләрлек кешеләрнең азлыгы, мәгариф эшчеләренең бөтенләй юклыгы аңлашылды. Алар Татарстаннан Хивага яхшы эшчеләр алып китү ниятендәләр.

Һәйәт белән бергә Мәскәүгә уку нияте белән баручы шәкерт тә бар. Без бу иптәшләребезнең алган юлларында муаффәкыять телибез.

**ПОЖАЛУЙСТА**

Иркәләнүне кем яратмый.

Ә менә мине дөньяда берәү дә иркәләмәгән. Кирәксенүче дә булмаган. Бишектә вакытта иркәләнүче малайлар кебек без фәкыйрегезнең дә иркәләнәсе килеп, авызын зур итеп ачып елакласам да, әһәмият бирүче булмагач, ул эшне дә калдырганмын – еламаска булганмын.

Әткәйгә сукалашырга кеше кирәк булгач, колагымнан тартып үстерергә тырышкан. Әнкәй дә, каз бәбкәләрен сакларга тизрәк үссен дип, чәчтән тартып үстерү юлын тоткан да, без үскәнбез.

Ләкин иркәләнү уе һаман йөргән, юри кайчакта шулай иркәләнәсе килә...

Һәркемне иркәләүчеләр табылган кебек, сакал-мыеклар үсә башлагач, без гарипне дә баштан сыйпаучылар табылды:

– Пудра ягынган, һәрбер яшь егетне атып йөрүче ханымнардан түгел.

– Казанның кәкре аяклы кызларыннан да түгел.

– Кем дисезме?

– Парикмахерлар!

Каһәр сукканнар, минем иркәләнергә теләгән яшерен уйны кайдан белеп өлгергәннәр әле, барып керүең белән:

– Пожалуйста! – диләр дә, килеп, пальтоңны салдырырга өлгерә алмыйлар, тагын:

– Пожалуйста, – дип урындыкка утыртып, чәчләрне, сакалларны пожалуйсталый бирәләр.

Әле ул халыкны бик яратып киттем. Сакал-мыеклар борын астыннан башларын сузарга өлгерә алмыйлар, мескеннәр, хәзер шул парикмахерга юнәләбез дә китәбез.

Казан парикмахерларын һәммәсен диярлек йөреп, иркәләнеп чыктым инде.

Әле көннәрнең берендә урам буйлап йөргән чакта, нигәдер бик иркәләнәсе килеп киткән, малай, яңа гына ачылган бер парикмахерга эре генә кереп киткән идем.

Каһәрләр!

Болар минем бу йомшак якны каян белгәннәр?

– Пожалуйста, гражданин! – дип сөеп каршы алдылар.

Иркәләнү хисләре тагын уянды.

«Пожалуйста!» белән урындыкка утыргач, парикмахер:

– Бриться прикажете? – ди.

Мин монда, үзем өлгерергә тырышып:

– Пожалуйста! – дип куйдым.

Сакалны кырганда борыла-сырыла бөтәрләнеп йөргән парикмахерның итенешләре безгә бик ошады.

Парикмахер борын эченнән генә:

– ...Прикажете... – диде.

Мин, аның сүзен аңлап бетермәсәм дә:

– Пожалуйста! – дип куйдым.

Чәчләрне төзәтеп бетерергә өлгермәде, тагын авыз эченнән нәрсәдер мыгырдады.

– Пожалуйста! – дидек. Йөзебезгә әллә нәмәрсәкәйләр сөртеп бер-ике минут ышкыгач:

– ?.. – диде.

Без әйдә тагын бер:

– Пожалуйста, китсен, – дидек.

Яхшы парикмахер икән, йөзебезгә әгъла хушбуйлар сөртеп, тагын бер-ике «пожалуйста»лардан соң канәгатьләнеп чыгарга булдык. Парикмахер, әүвәлгедән дә килешле итеп:

– Извольте с Вас получить! – дип, безгә мөрәҗәгать итте.

Без иркәләнү аркасында кесәбездә бик аз акча булуын да истән чыгарып җибәргәнбез.

– Сколько? – дидек.

– 2 сум 50 тиен.

Менә сиңа «пожалуйста»?!

Минем кесәдә бары 1 сум гына акча барын парикмахерга белдергәч, безнең арада озак диалог-монологлар булып алды.

Парикмахер үзенең соңгы монологын:

– Болван! – дип бетерде.

## СИРАТ АЮЛАРЫ

(*«Аллан»ның күңел дәфтәреннән*)

Миндә аяклар да бар, куллар да бар, зур гына баш та бар. Аяклар кәкрерәк, баш гакылсызрак. Куллар белән аяклар анархистлар иде. Теләсәләр нәрсә эшләп йөриләр. Дурак баш дигән нәрсәң, тегеләр нәрсә эшләсә, шуңарга риза була да тора инде – соглашательский политика тота.

Борын дигәнең буржуарак, югары гына менеп утырган да йөри бирә.

---

Әле менә бүген куллар бүрекне киде. Аяклар, шул, мин сиңа әйтим, син миңа әйт, юнәлделәр дә киттеләр. Кая? Анысын үзләреннән барып сора. Алар мине һәрвакыт галушка утырталар. Эшсезрәк вакытта урамнарда вывескалар каратып йөртә-йөртә җанны алалар, каһәрләр!

Салкынрак көннәрдә үзләренә дә жарны бирәм инде. Урамга чыгып китү ниятләрен сизү белән, шул, бик шәпләп кенә киез итекләрне алмаштырып, салкын ботинкалар, бүрек урынына фуражка киям дә мин, баш, аяк, борын, кул – бишәүләп чыгып китәбез (калган вак-төякләре дә шунда иярә). Мороз бабай, бу җүләрләрнең йомшак якларын сизү белән, перчаткасыз колакларны, бүрексез кулларны, аякларны менә пешерә башлый. Борынны әйтмә дә, елап кына йөри.

Бу юлы миндә власть, мин юри вывескалар караган булам, алай итәм, болай итәм, тегеләй итәм, тегеләр әй пешәләр, әй кайтырга газапланалар.

Каһәрләр өчен берничә авырып та алдым әле.

---

Бүген бу җүләрләр нигәдер мине Печән базарына алып барырга уйлаганнар. Мин инде бу юлы эшсез йөрергә уйламадым, моменттан файдаланып, рамазан шәриф мөнәсәбәте белән Печән базары агай-энеләренә смотр

башларга булдым. Рамазан шәриф дигәч әле, минем башка утыз көн ураза дигән нәрсә килеп төште, кайдан уйлап чыгарганнар андый юк-бар нәрсә. Ураза, имеш, анаң башы! Минем кебек пролетарлар гомер буена ураза тотып йөриләр.

Ярый. Эшкә кайтыйк. Мин бу юлы сират аюларының генералы. Парад башланды, рәхим итегез.

– Смирно!

– Червонецчылар, направо!

Ай-яй, малай, ну корсаклар!

– Итчеләр, налево!

Ай-яй, егет, корсаклар, вәт корсаклар!.. Чыдайть нельзя, Мөхәммәтша!

Алаша кадәр берәүсе милләтебезнең яшүсмер бер папиросчысын аз гына басып үтермәде.

Парад миндә бик яхшы тәэсир калдырды. Бу елгы ураза кампаниясе салымы безнең Казан шәһәренең Печән базарында, иншалла, яхшы үтәчәк.

Магазинчы корсаклы агайларыбызның һәрберсе берүзе алтмыш уразаның койрыгыннан «сразу» тота алырлык корсакка маликлар. Кибетчеләр утызар ураза и так далее.

Димәк, ураза салымының 90 проценты выполнено. Инде 10 проценты безнең кебек акчасызларга урамда хуруруй сыбызгысы сызгыртып йөргәндә тотарга кала.

**КОЯШ БЕЛӘН АЙ СӨЙЛӘШӘ**

(*Күктә бер яшерен урында качканнар*)

Ай. Кояш әфәнде!

Кояш. Атаң башы, күп шаулама!

Ай. Нигә?

Кояш. Кави дигән теге җүләр шагыйрь монда икәнне белмәсен!

Ай. Бәла инде, егет, чыдайть нельзя! Аңардан качып йөри-йөри чалбар төбе тәрәзә булды.

Кояш. Тик тор! Минем аркадан да борау эзләре төшкәне юк әле.

Ай (*шыпырт кына*). Эһем... тсс! Кави...

Йолдызларга рәт тә юк. Алары себерттереп кенә качып йөриләр.

«Аллан».

Чаян. Кави иптәш, Ай белән Кояшны үбештереп, сөннәтләгәч, өйләндерү чараларын да күрсен иде.

**МЕНӘ НИШЛӘДЕ**

«Чаян» абый!

Минем хәл еларлык та, көләрлек тә.

Эш болай.

Мин үзем 23 нче елларда бик тәти, бик матур, каһәр суккан бер кызны очратып, шуңарга өйләнгән идем. Ялгыш әйтәм, никахсыз, загссыз гына яңача тора башлаган идем. Ул вакытларда мин (исемен әйтмим) бер учреждениедә завхоз булып торадыр идем. Жалуниям аз булса да, арткы килерем күп булганга, тормышым чибәр иде. Ә ул кыз, нәгълэт төшкән, ул вакытларда контрлар оясыннан чыккан бер бывший миллионер кызы булганга, урынга керә алмый ач йөридер иде.

Нәләт төшсен минем туган көннәремә! Нәләт төшсен минем атамның өйләнгән көннәренә! Без аның белән тора башладык. Биш-алты ай ничава тордык. Аннан соң... мине завхозлыктан чыгардылар. Шулай да яхшы иптәшләрнең ярдәме белән төрмәгә керергә туры килмәде. Ләкин көнкүреш авырайды. Тормыш җәһәннәмгә әйләнде.

Шуның өстенә урамнарда көннән-көн тәти киенгән мещан хатыннарының, нэпман егетләренең арта баруы чүп өстенә чүмәлә булып төште. «Бүрене никадәр асрап торсаң да, уңае белән урманга кача» дип белми әйтмәгәннәр. Ул да үз халкы – нэпман хатыннары, нэпман егетләре артыннан чаба башлады.

Соңыннан бик тәти нэпман егете белән танышкан... Йөри башлады. Әүвәл яшерен, соңыннан ачык.

Без аның белән тора башлаганда загска бармаганга икебез ике фамилиядә йөридер идек. Көннәрнең берендә урамда йөргәндә, теге тәти егете очрап, аның белән гуляйть итәргә китә башлады. Скандал китте. Тавышка килгән милиционерга минем хатын:

– Иптәш милиционер! Менә бу ниндидер хулиган, узып барганда, миңа бәйләнеп тора. Аралап җибәрегез, зинһар! – диде.

Милиционер безне өчебезне дә частька алып китте. Частьта мин үземне никадәр аның ире дип күрсәтергә тырышсам да, хатынымның киемнәре яхшы булып, минем начар булганга, ышанмадылар, көлделәр.

– Хатының булса, синең өйләнүең турында язуың булыр иде, – диделәр.

Теге егет тә:

– Мин бу кызны яхшы беләм. Бу кеше белән һичбер танышлыгы юк,– дип өскә ут өрде.

Мине ябып куйдылар. Инде нишләргә белми төрмәдә ятам.

«Чаян» абый, менә нишләде бит! Инде миңа нишләргә?

Чаян. Буржуйкага өйләнгәндә безгә килеп киңәш сорамадың, хәзер инде тю-тю-тю-ю-ю, брат!

## АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТҮГӘРӘКЛӘРЕНӘ ҖӘЙДӘ ЭШ

Үткән номер «Октябрь яшьләре» журналында без авыл хуҗалыгы түгәрәкләренең язгы эшкә әзерләнүдәге берничә бурычларын санап үткән идек инде. Хәзер яз айларында авыл хуҗалыгы түгәрәкләренең кайбер эшләре турында тукталабыз.

Бу айларда безгә кыш көне түгәрәкләрдә эшләнгән планны эшкә ашыру эше тора.

Безнең татар авылларында яшелчә үстерү дигән бернәрсә бөтенләй юк диярлек. Булса да, кайбер авылларда гына. Безнең татар крәстияннәре яшелчә утыртуга рус эше дип карап килделәр. Хәзер дә шулай караулар бар. Үзләре булса, шул яшелчәне әллә никадәр бәя түләп сатып алалар. Сатып алмаганнары яшелчәдән файдаланмыйлар. Авыл хуҗалыгы түгәрәкләре инде бу эштә крәстияннәргә яшелчә утыртуның файдасы зурлыгын бик нык аңлатырга тиешләр, һәм безнең татар авылларындагы авыл хуҗалыгы түгәрәкләренең күбесе башлап бу эшне үзләре эшләргә тиешләр.

Түгәрәкләр монда беренче эш итеп җирне билгеләнгән планнары буенча участокларга (кисәкләргә) бүләләр. Шуннан соң туфракны яхшылап ашлыйлар да чәчәрлек итеп хәзерлиләр. Бу эшне эшләгәндә якында агроном булса, шул агрономны чакырып, аның күргәзүе буенча эшләү күбрәк файда китерер. Шуннан соң нинди нәрсәне кай җиргә чәчәргә икәнлекне сайлап түтәлләр хәзерлиләр. Кәбестә вә башка шуңарга охшаулы әйберләрне утырту өчен урыннар хәзерлиләр дә чәчеп куялар вә башкалар. Бу нәрсәләрне эшләп барганда, хәзерләнгән бланк кәгазьләре буенча кайсы вакытта нәрсә эшләнгәнен һәм ничек эшләнгәнен аермачык рәвештә язып барырга кирәк. Шулай ук чәчелгән түтәлләргә җыелып барып һаман тикшереп торырга, тикшергән нәрсәләрне тагын да язып барырга кирәк. Әгәр кайбер яшелчәләрнең чыгышлары начар булса, барып, агрономнан сорап белешергә кирәк.

Шушы яз айларында ук авыл хуҗалыгы түгәрәкләре үрнәк кырларына, совхозларга, аерым кайбер хуҗалыкларга экскурсияләр ясап, уҗымнарның хәлләре белән таныша барулары тиешле.

Шулай ук язгы игеннәрнең чыгышларын карап кайтырга төрле бакчаларга экскурсияләр ясарга тиешләр. Һәрбер экскурсиядән соң күреп кайткан хуҗалыкларның яхшы-яман яклары турында фикер алышулар, хәтта шул хакта берәр иптәшкә доклад укырга биреп, озын беседалар ясарга мөмкин.

Буш вакытлар булганда яки сабан туйларында, кайбер начар эшләнгән хуҗалыкларны алып, крәстиян агайларның катнашы белән судлар ясарга кирәк.

Судта ул хуҗалыкның ни өчен начар булуын һәм аны ничек төзәтергә мөмкин булуы турында крәстиян агайлар белән фикер алышулар зарар итмәс.

Ләкин судларны агрономның ярдәмнәре белән генә эшләргә кирәк.

Бу айларда түгәрәкләр, авылның җитешсез якларын тикшереп, эш планнары төзергә тиешлеләр.

Мәсәлән, урамнарны чистарту, җимерелгән күперләрне төзәтү вә башкалар.

Бу эшләрне крәстиян агайлар белән нык аңлашып, бергәләп төзәтү чараларына керешергә кирәк.

## ТӘН ЧИСТАЛЫГЫ

Безнең хәзерге көндә авыллар бик караңгы, артта калган. Шуның өстенә бик ярлы. Бу сугыш елларында бигрәк тә халык ярлыланды. Тора торган йортлар, кия торган киемнәр эштән чыкты. Шуның өстенә безнең авылларда халык чиста торырга өйрәнмәгән. Безнең крәстияннәрнең көнкүрешләре дә чиста торырлык хәлдә түгел.

Кыш көннәрендә кешеләр белән бер үк йортта куй бәтиләре дә, кәҗә малайлары да – һәммәсе бергә кайныйлар. Өйдә ис начар, һава авыр була. Шуның өстенә өйдәге сөрем белән дә башлар әйләнеп бетә.

Мондый нәрсәләр кешенең башы эшләвенә бик күп зарар итә. Кешенең сәламәтлеген югалта. Ләкин бит крәстияннең хәзерге тормышы башкача мөмкин дә түгел. Без шулай уйлап киләдер идек. Һәм шулай тора бирәдер идек. Инде безгә үзебезнең тормышыбызны сәламәтлек өчен яхшы куярга тырышырга кирәк. Бу нәрсәдән авылда дворецлар төзеп булмый диярсез. Дөрес, авылда әле дворецлар төзеп булмый. Ләкин булган кадәресен төзәтеп була.

Комсомол бу эштә беренче булырга тиешле. «Сәламәт тәндә генә сәламәт гакыл» булырга мөмкин дигән сүз бик дөрес. Безнең авылларга берәр йогышлы авыру килеп чыга, ул бөтен йортларда кунак булып йөри. Кайвакытларда үзе белән кабергә авылның өчтән бер өлешен дә алып киткәли. Крәстиян агайлар бу нәрсәне Алла тәкъдире итеп карарга өйрәнгәннәр. Бу бер дә алай түгел. Ә бәлки, крәстиян агайларның саклана белмәү, чиста тормауларының китереп чыгарган тәкъдире.

Комсомоллар авылларда һәр эштә алда баралар. Алар чисталык эшендә дә шулай итәргә тиешләр. Без бу җирдә сәламәтлекне саклау өчен иң кирәк нәрсәләрне генә язып үтәбез.

**Тән чисталыгы**

Бездә крәстиян агайлар тәннәрендәге пычрак шалкан чәчәрлек дәрәҗәгә җиткәч кенә мунчага баралар. Авылларда әле мунчалар да уртача хәлле крәстияннәрдә генә була. «Ярлы егет җанкисәгем»ә зур бәйрәмнәрдә генә мунчага барырга туры килә.

Мунчаның файдасын сөйләп тә торасы юк. Аны крәстиян агайлар үзләре дә беләләр.

Авылларда общественный келәтләр, мәктәпләр салган кебек, суга якынрак җиргә бөтен авылга файдаланырга яраклы мунчалар салу авыл өчен бер дә авыр түгел. Ә аның файдасы әллә никадәр.

**Тәннең сулышы**

Без сулышны авыз белән генә алмыйбыз. Безнең бөтен җиребез вак кына тишекләр белән капланган. Безнең каныбыз шул тишекләр аркылы һава һәм һавадан кирәкле азыкны алып тора. Инде тәнгә кер утырса, шул кечкенә тишекләрне каплый да, тиребез аркылы һава керми башлый. Шуннан соң кешенең сәламәтлеге начарлана.

Әгәр дә безнең тәнебез үзенә кирәк кадәр һава, кислород дигән нәрсәләрне ала алмаса, кан азая башлый. Сәламәтлек начарлаша. Шулай итеп, канда булган төрле авырулар белән көрәшә торган нәрсәкәйләребез көчсезләнә, йогышлы авырулар аларны җиңә дә, кеше авырый башлый.

Аннан соң тәнебездәге кергә безнең күзгә зур трубалар аркылы гына күренә торган кортлар (микроблар) ояларга бик яраталар. Чөнки пычракта аларга азык күп була. Шулай итеп, тәнебездәге кер микробларны үрчетү җире булып хезмәт итә. Йогышлы авырулар белән тәннәре керле кешеләр ару тәнле кешеләрдән тизрәк авырыйлар.

**Тир**

Авыр эш вакытында без тирлибез. Тирне тәндә тотарга ярамый. Тир безнең тәнебездән үзе белән яраксыз нәрсәләрне чыгарып ташлый. Аны шул ук вакытта юып ташларга кирәк. Булмаса, ул тиренең азык алуына күп зарар итә. Шуның өстенә төрле угорьлар, сыткылар чыгып, йөзне бозалар. Ул сыткылар тишелеп, суланып торганда, йогышлы авыруларны тагын җиңелрәк алырга мөмкин. Керле тәндә һәрвакыт төрле корчаңгы вә башка шундый тире авырулары башлана.

Тәнне керле тотарга һичбер ярамый. Кыш көннәрендә айга ике генә булса да мунча керергә кирәк. Яз көннәрендә су керү сәламәтлек өчен бик файдалы.

Аннан соң, аш янына һичбер вакытта кулны юмый торып утырырга ярамый. Юмаган кул белән ашны кулга алып, төрле авыру микробларын йотып җибәрергә мөмкин.

**Авызны, тешләрне ару тотарга кирәк**

Аштан соң авызны яхшылап чайкарга кирәк. Безнең тирә-ягыбыз төрле авыру микроблары белән чормалып алынган. Ул микробларның күбесе авыз аркылы безнең тәнебезгә керәләр, әгәр без авызыбызны чайкап торсак, ул вакытта тешләребез сәламәт саклана, черемиләр. Тешләр черемәсә, микробларга анда ашарга бернәрсә дә булмый. Тешләребезнең сәламәт булуы безгә икенче яктан да кирәк. Безнең тешләребез сәламәт булмаса, ашый торган

ашыбызны кирәк кадәр чәйни алмыйбыз. Чәйнәлми йоткан ашны ашказаныбыз бик авыр эшли. Ашказаны начар эшләсә, безнең сәламәтлек тагын начарлаша.

Шулай ук, йөзне юганда, борын эчләрен дә юарга онытмаска кирәк.

Күзләрне бик сакларга кирәк. Күзгә берәр чүп төшү белән, ничек кирәк алай пычрак куллар белән казымаска кирәк. Аякларны ару йөртергә кирәк.

Комсомоллар, эштә алда барган кебек, бу эштә дә алда барырга тиешләр.

Авыл комсомоллары! Синең кулыңа авылның киләчәге бирелгән, син үзең ару йөргән кебек, башкаларны да шулай итәргә өйрәт.

*** * ***

Үткән номер «Октябрь яшьләре» журналында тәнне, тешләрне, авызны ару тоту турында язып үткән идек инде. Хәзер без тагын да кайбер сәламәтлек өчен кирәк нәрсәләр хакында язып үтәбез.

**Эчке киемнәрнең чисталыгы**

Тәнне чиста тоткан кебек, эчке киемнәрне дә чиста тотарга тырышырга кирәк. Авыл халкы киемгә бай түгел. Шулай да ике пар күлмәк-ыштан һәммәбездә дә бар диярлек. Каралган киемнәр тәнне бик тиз каралталар. Кара киемнәргә бет дигән хәшәрәт ояларга бик ярата. Бетнең бер кешедән икенче кешегә күчеп йөри торган гадәте бар. Ул, берәүдә булган тиф, холера вә башка шундый авыру микробларын үзе белән икенче кешегә күчереп, авыру таратып йөри.

Инде эчке күлмәк-ыштаннарны чиста йөрткәндә, юып, һәрвакыт алмаштырып торганда, үрчеп өлгерә алмыйлар.

**Ашның, эчемлекнең, һаваның чисталыгы**

Ашау, эчү, һавасыз яши алмыйбыз. Шуның өчен без бу нәрсәләрнең чиста-ару булуына тагын күбрәк әһәмият бирергә тиешлебез. Азыкның үзеннән-үзе чиста булуы гына җитми. Әле аны тузан-кер, былчырак кунудан да нык сакларга кирәк. Бездә бу нәрсәне бик тикшермиләр. Сөтләрне вә башка шуның кебек нәрсәләрнең өсләрен ачык калдыралар. Икмәкне төрми генә тоталар. Менә инде бу бер дә ярамый. Чөнки өсте ачык калган сөтләрнең вә башка шуның кебек нәрсәләрнең өсләренә һавадагы тузан куна. Ә тузан эчендә төрле авыру микроблары булуы мөмкин. Ул микробларның күбесен бик нык кайнатканда да үтереп булмый. Ә салкын ашта инде ул хәшәрәтләр рәхәтләнеп яшиләр, үрчиләр.

Шуның өстенә бездә чебен кебек хәшәрәтләргә бер дә әһәмият биреп карамыйлар. Чебеннәр булса, төрле җирдә, төрле нәрсәләргә, яман авыру белән авыручының ашына да, урамдагы бөтен әшәке нәрсәләргә, кыскасы, бөтен нәрсәләргә кунып йөриләр һәм холера, дизентерия, тиф кебек авыруларны ташып кына торалар. Чебеннәр белән нык көрәшергә кирәк. Аларны үтерү өчен һәрбер аптекада кирәкле даруны табарга мөмкин.

Шулай ук безнең арадагы кайберәүләрнең чәй эчкәндә бармакларының яртысы стаканнарында йөзә, шул кешенең тырнак араларында әллә нинди микроблар булуы мөмкин.

Кеше стаканыннан эчү, кеше авызыннан тәмәке алып тарту вә башка шуның кебек нәрсәләрне санга да санамыйлар.

Безнең арабызда төрле авырулар белән авыручы кешеләр булуы мөмкин. Бу нәрсәләр белән сифилис вә башка шуңарга охшаулы иң куркыныч авыруларны эләктереп була.

**Һава**

Без һаваның сафлыгын бер дә тикшермибез. Күп кешеләр һаваның авырлыгыннан башлары әйләнеп егылганга кадәр өйнең һавасын яхшыртуны исләренә китермиләр. Кечкенә генә бүлмә эчендәге һава күп кешегә җитми. Шуның өчен бүлмәдәге яхшы һаваның безнең тәнебезгә иң кирәкле булган «кислород» дигән нәрсәсен сулап бетерәбез дә, һава начарлаша. Сулыш алырга авырая. Андый һава кан азаюга сәбәп була, ялкаулата. Шундый һавалы җирдә кеше тыныч йоклый алмый. Тәндәге начар авырулар белән көрәшә торган нәрсәләр көчсезләнә, шуннан соң кешене авыру бик тиз җиңә.

Яшьләр бу эштә «революция» ясарга тиешләр. Моның өчен бүлмәдәге һаваны һәрвакыт яңартып торырга кирәк. Безнең авылларда һаваны яхшырту өчен тәрәзәләрдә форточкалар юк. Авыллардагы агайлар да: «Безнең ата-бабайлар бу нәрсәләрне белми дә аю кебек таза булганнар», – диләр.

Ләкин бит ата-бабайлар заманында тормыш та башкарак булган шул. Хәзерге көндә безнең баштан үткән ачлык, революция көннәре, төрле йогышлы авырулар тәннәребезне яхшы ук көчсезләттеләр. Безгә үзебезнең сәламәтлек

өчен һәрвакыт кайгыртып торырга туры килә. Яз көннәрендә авылларда һава ягыннан куркыныч күп булмаса да, кыш көннәрендә бездә бу хәл бик начар, яшьләр бу якларны төзәтергә тырышсыннар.

Яшьләрнең сәламәт булуы безнең өчен иң кирәк нәрсә.

### «АВЫЛГА ЙӨЗ БЕЛӘН» НИ ДИГӘН СҮЗ УЛ?

«Авылга йөз белән» нәрсә ул?» дип сорау хәзер бик соң кебек инде. Ләкин әле авыл яшьләренең күбесе (күп кенә авыл комсомоллары да) «Авылга йөз белән»нең нәрсә икәнен яхшылап белмиләр. Шуның өстенә татар телендә бу хакта бер брошюра да басылганы юк диярлек. «Авылга йөз белән» лозунгысы эшкә ашырыла башлауга күп кенә вакыт үтте. Ләкин ул эш эшләнде инде дип әйтү хата. Ул лозунгыны кирәгенчә эшкә ашырыр өчен бик күп еллар кирәк булачак. Без бу җирдә кыска гына рәвештә «Авылга йөз белән» лозунгысының нәрсә әйткәне һәм бу юлда хәзерге көндә нәрсә эшләнгәне турында язып үтәбез.

Соң нәрсә ул «Авылга йөз белән»? Кыска гына болай җавап бирергә мөмкин:

1) эшчеләр белән крәстияннәр арасында бик нык бәйләнеш ясау;

2) авылның хуҗалык ягыннан күтәрелүенә ярдәм итү;

3) авыл советларын җанландыру;

4) артта калган авылны белем ягыннан күтәрү.

#### Эшчеләр белән крәстияннәр арасында бәйләнеш ясау

Әле 1917 елда Ленин иптәш үзенең бер мәкаләсендә[1] бу хакта болай яза: «Без бу революциядә пролетариатның союзниклары кемнәр?» сөалeн тагын бер мәртәбә куярга тиешлебез. Аларның ике союзнигы бар. Беренче, Россиядә күп миллионнар белән саналган ярым пролетариат һәм бер кисәк урта хәлле крәстиян массасы, бу массага килешү, икмәк, ирек, җир кирәк. Безгә яңа тәртипнең иркеннән һәм Эшче-солдат депутатлары советыннан файдаланып, аларны барыннан да элек, барыннан да бигрәк агартырга һәм оештырырга кирәк».

Бөтен дөнья күләмендә революция көрәше көчле рәвештә барса да, Советлар хөкүмәте әле бездә генә. Ә бөтен дөньяда әле безнең дошманнарыбыз – буржуалар патшалык сөрәләр. Безгә үзебезне бөтендөнья революциясе булганга кадәр саклану өчен көчле союзнигыбыз крәстияннәр белән нык бәйләнеш башларга кирәк һәм аларның хәлләренә күз салырга, аларның хуҗалыкларының күтәрелүенә ярдәм итәргә тиешбез.

#### Авыл хуҗалыгының күтәрелүенә ярдәм итү

Бөтендөнья сугышы, Гражданнар сугышы вакытларында авыл хуҗалыгы һәм завод-фабрикалар бөтенләй эштән чыкты. Икмәк аз чәчелде, нәрсә эшләү кимеде. 1913 елда крәстиянгә иң кирәкле мануфактура 18 миллион пот эшләнгән булса, 1921 елда бары 1 миллион пот кына эшләнде. Шуның өчен мал кыйммәт иде. Икмәге үзенә җитәрлек булмаган крәстиянгә бөтенләй алу мөмкин түгел иде. Инде соңгы елларда завод-фабрикалар яхшы ук юлга салынды. Ләкин авыл хуҗалыгы ул кадәр күтәрелә алмады. Крәстияннәрнең хуҗалыкларын күтәрү, яхшырту кичектерми эшләнергә тиешле булды. Шәһәр монда авылга йөзе белән борылды.

#### Бу юлда ниләр эшләнә?

Хәзер крәстияннәрнең икмәк бәяләрен мөмкин кадәр күтәреп, крәстиянгә кирәк булган завод-фабрика малларын арзанайту юлы тотыла.

Авылларның хәлен яхшырту өчен авылларда кооперативлар үрчетелә. Шул кооперативлар аркылы завод маллары турыдан-туры арзан бәя белән авылларга таратыла. Кооперативларга крәстиянгә кирәкле маллар бурычка (кредитка) бирелә.

Крәстияннәрнең хуҗалыкларын күтәрү өчен быел налогларда бик күп җиңеллекләр ясалды. Шуның өстенә безнең авыллардагы хуҗалыклар Нух заманындагы кораллар[2] белән көн итәләр. Авылның көнкүрешен яхшырту өчен аны баштанаяк яңартырга кирәк. Монда крәстияннәр өчен зур җиңеллекләр эшләнә. Авыл хуҗалыгына кирәкле яхшы кораллар арзан бәя белән кетәргә җибәрелә. Хәтта берләшеп тракторлар алырга да киң юллар бар. Алпавыт җирләре крәстияннәр кулында. «Авылга йөз белән» лозунгысы астында моңардан башка әллә никадәр эшләр эшләнә. Ләкин крәстияннәрнең хуҗалыкларын күтәрү аларның аң-белемнәрен күтәрү белән нык бәйләнгән.

**Советларны җанландыру**

Советлар революция көннәрендә бик зур эшләр эшләделәр. Советлар аркылы эшчеләр сыйныфы үзенең артыннан миллионнарча крәстияннәрне ияртеп бардылар. Җимерелгән хуҗалыкларны төзәтү көннәрендә советлар өстенә тагын зуррак эшләр йөкләнә.

Без тышкы дошманнарыбызны җиңдек. Ләкин эчке дошманнарыбыз әле һаман безгә киртәләр ясап киләләр. Авыл кулаклары төрле юллар белән советларга үрмәлиләр. Ә үзләренең якыннарын кертергә тырышалар. Яки советларга әллә нинди эчкече башлар, взятка алучы кошлар кереп утыралар.

Мондый хәлләрне, газета укып барсаң, бик күп җирләрдә очратырга мөмкин. Советларда андый үз кесәләрен кайгыртучы кабахәтләргә урын булмаска тиешле. Бу юлда крәстияннәрнең аңын үстереп, батракларны, урта хәлле крәстияннәрне сайлауларга нык катнаштырырга һәм сайлауларның никадәр әһәмиятле булуын аңлатып, советларга үзләренә файдалы кешеләрне сайлату юлын тотарга кирәк.

Мулла, поп, кулакларның сайлауга катнашырга хаклары юк.

Батрак, урта хәлле крәстияннәрнең советларга яхшы караучыларын яки авторитетлы коммунистларны сайлату юлын тотарга, совет эшләренә аларны бик нык тартырга кирәк.

Соңгы сайлауларда крәстияннәр арасына иң яхшы эшчеләр җибәрелеп, шулай эшләү юлы тотылды. Яхшы нәтиҗәләр дә күрелде. Хәзерге көндә «Авылга йөз белән» лозунгысы астында авыл советлары белән волость, кантон, губисполкомнар арасында бик нык бәйләнеш бара. Югары органнар, авыл советларының эшләрен бик нык тикшереп, аларга юлбашчылык итеп баралар.

**Авылның аңын күтәрү**

Авыллар аң-белем ягыннан бик түбән тора. Ә крәстияннәрнең бер кадәресе, аң ягыннан түбән булу сәбәпле, күп вакытта үзләренә файдалы нәрсәләрне дә аңламыйлар. Кем сөйләсә, шуңар ышанучан булалар. Безгә Советлар хөкүмәтен саклау өчен крәстияннәрнең аңлы булулары кирәк. Шуның өчен дә шәһәр эшчеләре авылларны шефлыкка алалар. Анда үзләренең аңлы эшчеләрен җибәреп, аларга юлбашчылык итәләр.

Авыллар өчен сәяси эшчеләр, төрле агрономнар хәзерләү вә башка шундый кирәкле эшчеләр хәзерләү өчен әллә никадәр курслар ачылып, анда крәстиян балалары тәрбияләнә.

Меңнәрчә крәстияннәр төрле съездлар аркылы үтә. Авыл мәктәпләре китаплар вә башка нәрсәләр белән тәэмин ителә.

Крәстияннәр өчен кирәкле китаплар, газета-журналлар арзан бәя белән таратыла.

Югары мәктәпләр крәстиян балалары өчен киң рәвештә ачык.

Авылларда аң-белем ягыннан югары торган укытучы, агрономнарның тормышлары яхшыртылып, алар өстенә авылларда аң-белем эшендә юлбашчылык итү эше тапшырылды вә башкалар.

Ләкин монда һәрнәрсә бик кыска алынды. Шулай ук бу эш әле башланды гына. Бу юлда әле дөнья кадәр эшлисе бар. Шуның өчен дә авыл комсомоллары «Авылга йөз белән»нең ни икәнен бик яхшы өйрәнергә тиешләр.

**Бу юлда комсомолларның кайбер бурычлары**

Авыл яшьләре хәзерге көндә комсомолга омтылалар. Анда керә алмасалар, үзләре төрле түгәрәкләр төзеп оешалар. Менә монда инде комсомоллар шул оешып килә торган яшьләрне кулак, кулак малайлары тәэсиренә бирми, үз канатлары астына җыеп, үзләре тәрбияләргә тиешләр. Шуның өстенә крәстияннәрнең аңны күтәрү юлында комсомолларның бик күп эшлисе эшләре бар. Алар үзләре яңа чыккан декретлар, законнар белән бик нык танышып барып, крәстиян агайларга җыеннарда шул декретларны аңлатып барулары тиешле.

Ярлыларны кулаклардан издертмәскә, тикшереп торырга, бу эштә профсоюзларга ярдәм итәргә тиешләр.

Изба-читальныйларда комсомоллар дөнья кадәр эш эшли алалар. Аларга бу эштә укытучы, агроном, врач кебек укыган кешеләр күп ярдәм итә алалар.

Крәстиян яшьләрен, батрак малайларын, бигрәк тә кызларын, төрле уку йортларына хәзерләп җибәрү комсомоллар өстендә. Кооперативларны алга җибәрү, аларга һәр эштә ярдәм итү – комсомолларның бурычлары.

Совет законнарының дөрес үтәлүен тикшереп тору, закон бозучылар белән көрәшүдә милиция, суд, совет органнарына ярдәм итү – болар барысы да авыл комсомолларының бурычлары.

**ИКЕ ХАТ ТУРЫНДА**

Мактаулы комсомол армиясенең отрядлары иң караңгы авылларда да үзләренең канатларын җәяләр, үзләренең фронтларын ныгыталар.

Шулай итеп, аларның авылда эш күләмнәре көннән-көн үсә:

1) советны җанландыру;

2) кооператив;

3) крәстиян агайларга көнкүрешләрендә яңа юллар күргәзү;

4) партиясез авыл яшьләрен кулак малайлары тәэсиренә бирми, үзләре тәрбияләү вә башкалар... Көн үткән саен, аларның эшләре яңара, эш күләмнәре зурая бара.

Күп авылларда комсомол ячейкалары үзләрен крәстияннәргә күрсәтеп мактаулы исемне алдылар инде һәм алар алларына куйган бурычларын яхшы үтәп баралар. Ләкин әле кайбер авылларда аяклары ныгып җитмәгән отрядлар да бар.

Менә Саратау губкомына авыл ячейкаларыннан килгән бер-ике хатны алабыз (хатлар идарәгә килгән мәкаләдән алына).

Бер авыл ячейкасының секретаре яза:

*«Без, татар комсомоллары, артта калганбыз. Без ячейканың эчендә кирәкле рәвештә эш алып бара алмыйбыз. Ә безнең өстебезгә тагын комсомолда булмаган крәстиян яшьләре арасында эшләүне йөклисез, бездә ул эшне алып барырлык хәзерлек юк»,* –ди.

Икенче бер иптәш:

*«Комсомолда булмаган крәстиян яшьләре безнең мәҗлесләргә килеп һәрвакыт катнашалар. Безнең эшләрне тәнкыйть итәләр һәм үзләренең аңлы-белемле булулары белән комсомолда булган надан батракларга сөйләргә юл калдырмыйлар, шуның өчен без партиясез яшьләр арасында эш алып барудан кул селкәбез»,* – ди.

Мондый нәрсәләрнең булуы бер дә гаҗәпләнерлек түгел. Чөнки безнең авыл ячейкаларындагы членнарның күбесе батрак, урта хәлле крәстияннәр арасыннан булганга, хәзерлекләре аз. Булганнарының да көндәлек бурычларны тиз генә үзләштерә алмаулары бар. Ләкин бит хәзерлегебез юк дип эштән кул селтәү монысы инде комсомолга килешми.

**Комсомол хәзерләнергә тиешле**

Укыган кешеләр күктән төшми. Шулай ук булдыклы эшчеләр дә яңгыр булып яумыйлар. Алар көн-төн эшләп, хәзерләнеп кеше булалар. Комсомол булгач, укырга, хәзерләнергә кирәк. Комсомолга кереп тә, укымый, хәзерләнми торган комсомол комсомол түгел. Ул комсомоллык эшен алып бара алмый. «Бездә хәзерлек юк» дип язучы авыл секретаре үзенең алдына ячейка әгъзаларын авыл яшьләре арасында эшләрлек итеп хәзерләү бурычын куйсын. Моның өчен ячейка янында үзләренең сәяси, фәнни тәрбияләү кружокларын төзеп, шул кружоклар хәзерлеклерәк членнар кулы астында алынып барылсын.

Шулай итеп ул кружоклар аркылы ячейка членнарына бик күп хәзерлек биреп була. Бергәләп күп кенә сәяси китаплар укып чыгып була. Аңламаганнарга аңлатырга да җиңел була. Килгән газета-журналларны бергәләп уку авыл комсомолларын эшкә хәзерләүгә күп ярдәм итә. Тик ялкауланмаска кирәк. Членнарны да эшкә күнектерергә кирәк. Укый-яза белмәгән членнарны укырга-язарга өйрәтергә, ячейка членнарын кантоннарда ачылган курслар аркылы уздырырга кирәк. Инде авыл комсомоллары крәстияннәргә кирәкле декретлар вә башка шундый крәстиян тормышын яхшырту юлында партиянең, советлар властеның күргәзгән юлларын вакытында укып, тикшереп бармаса, крәстиянгә бер ярдәм дә итә алмый.

**Шуның өчен**

Ячейка кирәкле газета-журналлар алдырып барып, үзенең членнарының бөтен дөнья хәлләре, крәстиянгә кирәкле нәрсәләр белән танышып баруларын алга сөрергә тиешле. Членнарын партшколаларга җибәрү кирәк. Инде ячейка собраниесенә кереп, хәзерлексез батрак яшьләренә «сөйләргә калдырмаучы» белемле авыл яшьләре турында бер-ике сүз әйтеп китик.

Авылдагы белемле яшьләрне икегә бүләргә була. Бертөрле «белемле яшьләр» кулак малайларыннан булуы мөмкин. Алар, собраниеләргә кереп, үзләренең белемнәре белән ячейканың эшләрен бутыйлар икән, андый «белемле» яшьләр арасында эшләү урынсыз, андыйларны бик нык тикшерергә кирәк. Авыл яшьләрен андый «белемле» кулына бирүдән бик нык сакланырга кирәк.

Инде авылның икенче белемле партиясез яшьләре бар (төрле техникумнарда укучы яшьләр вә башкалар). Алар советлар властена яхшы күз белән карыйлар. Шулай ук алар авылны яңарту юлында да эшләргә рәтләре зур.

Менә мондый укымышлы партиясез яшьләрне, билгеле, эшкә тартырга, аларның белемнәре белән авылны яңарту, алга җибәрүдә файдаланырга кирәк. Һәм андый совет яклы булган партиясез яшьләр үзләре дә ячейканың эшен бутау түгел, бәлки алар ячейка белән бергә бара торган яшьләр.

Бу ике төрле белемле яшьләрне аера белгәч, эш җиңеләя һәм советка каршы булган белемле кулак малайларына каршы көрәшергә, советлар яклы булган яшьләрдән файдаланырга гына кала.

**Соң ничек файдаланырга?**

Аларны «авыл хуҗалыгы» түгәрәкләре төзеп эшләтергә, драмкружоклар оештырып, шунда файдаланырга, авыл яшьләренә төрле газеталар, журналлар укыту эшләрендә, декретларны крәстияннәргә аңлатып бирү эшләрендә файдаланырга кирәк. Крәстияннәргә кирәкле нәрсәләр хакында лекцияләр, докладлар укыту эшләренә бәйләргә, шулай итеп алар белән авылны агарту юлында эшләргә кирәк.

## КАЙТАСЫ КИЛМИ

### Приказ

12 сентябрь. Багана саен ак кәгазьдә Хәрби комиссариатның приказы:

– Терармиягә[1]! – дип кычкырып күзгә карый. Кәҗәләнеп торасы юк. Шигырь, редакция, журнал-фәләннәрне бер якка.

### Иптәшләр көләләр

Аерым сапротаның[2] ишегалдына килеп керү белән, үткән ел терармиядә бергә булган иптәшләр дөнья җимереп каршы алдылар.

– А, син дә килдең.

– Исәнме?

Баштанаяк карыйлар. Кайберләре үткән елда булган кызык хәлләрне искә төшерәләр. Ротабызда бердәнбер көлдерүче Беляков мин килү белән иптәшләрчә генә тешләп алды. Ул быел малярия белән авырый икән. Эт булып өреп, этәч булып кычкырып бөтен ротаны көлдерүче Шарык та килгән. Ул мине этчә өреп каршы алды. Җанлылык. Безнең ротадагы терармеецлар күбесе завод эшчеләре. Калганнары да төрле заводлардан. Директор, заведующий булып эшләүчеләр дә бар.

### Чәч трагедиясе

Мин, канцеляриягә кереп, килүемне белдергәч, башка иптәшләр белән чәч алдырырга дип рота парикмахерына киттем. Анда бик күп егетләр, чәчләрен алдырырга кызганып, тавышлап маташалар.

Мин инде үткән елдагы кебек бу мәсьәләдә тавыш күтәрмәдем, утырдым. Рота парикмахеры, теге Проломныйдагы[3] парикмахерлар кебек:

– Что вам угодно-с? – дип конфетланып тормады, кычкыртып чәчне алып ташлады.

Ә бераздан без бөтенебез шоп-шома баш белән казарма эчендә тәгәри башладык.

### Һәммәбез бертөрле

Быел полк командирлары башка кешеләр икән. Безне, бүлекләргә билгеләп бетергәч, мунчага алып киттеләр. Бергә «шагом марш!» белән йөрү сагынылган. Үткән елдан хәтердә калган җырларны әйттерәбез.

Мунчадан чыгуга, өстәге киемнәрне гаскәри киемнәргә алмаштырдык. Шулай итеп, һәммәбез бертөрле булдык.

### Ботка, котелок

Гаскәрдә эшләр минутлар белән йөри.

– Бер минут та әрәм итмәскә!

– Өч атна эчендә яңа сугыш һөнәрләренең барысы белән дә танышырга!

Шул лозунг белән барабыз. Йөгерергә өйрәнмәгән аяклар тиз талалар. Корсактан, азык сорап, туктаусыз радиолар килеп тора. Монда инде котелок белән ботка ярдәмгә ирешә. Шәпләп ашыйсың да, тагын эшләр җайлана.

Кич казарма клубка әйләнә. Терармеецлар, җыелып, бергә газета укыйлар. Үзара беседалар ясыйлар. Җанлылык.

**Газ**

Киләчәк сугышлар ике нәрсә белән булыр, диләр – газ һәм һава флоты белән. Таракан кебек катып үлмәс өчен дә газ белән көрәшкә өйрәнергә кирәк.

Безне Арча кырына[4] газ томаны аркылы үткәрергә алып баралар. Чәчләр үрә тора. Менә Арча кыры. Без тиешле урынга килеп туктадык.

Безгә газны үткәрми торган маскалар бирделәр. Һәм бераздан киң кыр буена зәңгәр газ җибәрделәр. Саубуллашкан булабыз. Тотнаксыз көлүләр, команда. Без агулы газ төтене эченә керәбез...

**Җырлыйбыз**

Иртәнге кояшны без гаскәри җырлар белән урамнарда каршылый торган булдык. Һәр көн. Аннан сәяси белем – устав, химчас, ату сәгатьләре тизләп үтәләр. Без, төрле завод-фабрикалардан, авыл-шәһәрләрдән җыелган кешеләр, үз тормышыбызны төзедек. Ләкин бу тормыш, бу кызык, бу җанлылык гаскәри тормышта гына бар.

**Шах һәм мат**

Дәрес сәгатьләрендә безнең командир үз ролендә: устав буенча хәрәкәт итә, командир була. Бу сәгатьләрдә аны үзеңнең юлбашчы командирың дип беләсең.

Ә дәрестән соң ул иптәш безнең белән клубта бергә укып, сөйләп утыра. Теләсәң:

– Әйдә, шахмат уйныйбыз! – ди.

Мин керешеп китәм. Королен куып йөрим. Ә бераздан командирга:

– Шах, мат! – дим.

**Китәсе килми**

Өч атна безгә бик күп бирде. Өч атнада без аерыла алмаслык иптәшлек, бергәлек тормышы төзедек. Өч атнада күп нәрсә белән таныштык.

Соңгы көн. Казармадан китәсе килми. Иптәшләргә өйрәнелгән. Ләкин һәммәбезне эш фронты көтә.

– Хуш, егерме пуля атып та бер пуля да тидерә алмаган винтовкам! Киләсе елга, бәлки, туры атучыга эләгерсең.

– Хуш, җанкисәгем котелок!

«Икенче чакыруга кадәр» дип язылган пичәтле удостоверениеләребезне алып, заводларга, кырларга, шәһәр эченә таралабыз.

## СОВЕТЛАРГА САЙЛАУЛАР

Хәзерге көндә бөтен СССР күләмендә авыл советларына сайлаулар яки шуңар хәзерлекләр бара.

Монда инде менә комсомоллар да, крәстиян яшьләре дә йоклап калмаска тиешләр. Үткән сайлаулар бездә яхшы үткән иде төсле. Ләкин газета саен «безнең советның председателе дә, членнары да көн-төн эчеп йөрүдән бушамыйлар», «бездә советка кулаклар кереп утырганнар да ярлыларның каннарын эчеп яталар», «безнең председатель взятка ала» вә башка шуның кебек хәбәрләр ел буена өзлексез язылып килделәр. Димәк, үткән елгы сайлауларда да бездә бик күп авылларда яраксыз кешеләр сайланган булганнар. Хәтта кайбер Чүти кебек авылларда авыл советларына гына түгел, волость советларына да караклар кереп утырган булганнар.

Менә бу ел инде безгә күзне тагын да ача төшәргә кирәк.

Сайлау алдыннан комсомол иптәшләр сайлаулар турындагы законнар белән бик нык танышырга, кулай итеп крәстиян агайларга сайлау законнарын бермә-бер аңлатырга тиешләр.

Шулай ук советка сайланган кешеләр яхшы булганда гына, авылны аң-белем ягыннан һәм хуҗалык ягыннан күтәрергә мөмкин булуын крәстияннәргә бик яхшылап аңлатырга кирәк.

Бездә крәстиян агайларның кайберләре сайлауларга бармак аркылы карап килделәр. Сайлау көнендә дә «миннән башка да сайларлар әле» яки «анда миннән гакыллыраклар да күп булыр» дип, сайлауга бөтенләй катнашмыйлар.

Ә анда «гакыллы» кулаклар, оешып, үзләренә кирәк кешеләрен үткәрәләр, аннан соң шул ук крәстиян агай советка үзенең теләген сорап барырга да куркып йөри. Мондый фактлар бик күп була.

Сайлау алдында кулаклар оешып хәрәкәт итәләр. Алар кешеләрен теш-тырнаклары белән кертергә тырышалар.

Комсомоллар сайлаулар алдыннан ярлы һәм урта хәлле крәстияннәрнең, оешып, булдыклы, халык өчен файдалы кешеләрне сайлауларына ярдәм итәргә тиешләр.

«Авыл советларын җанландыру» дигән нәрсәне без күптәннән сөйләп киләбез. Менә бу сайлауларда инде бу нәрсәне эшкә ашырырга кирәк.

Ягъни советларга халык арасында авторитеты бар коммунистларны, советларда эшләргә омтылучы, активный, эшлекле партиясез крәстиян агайларны сайларга кирәк. Үткән елгы сайлауларда үткәрелгән күп кенә партиясез крәстияннәр гөр килеп эшләп чыктылар һәм эшләп яталар.

Бу сайлауларда да шундый булдыклы крәстияннәрне советларга үткәрергә тырышырга кирәк. Моның өчен ярлы, урта хәлле крәстияннәр оешып, сайланырга тиешле кешеләрне алдан тикшереп, үзара киңәшергә тиешләр.

Комсомолларның билгеле бер эштә уртада булулары кирәк. Үткән ел крәстиян агайлар советларга сайлауларда 45 процент катнашканнар иде. Быел моны 100 гә күтәрергә тырышырга кирәк.

Аннан соң, бездә авылларда хатын-кызлар халык эшеннән бөтенләй читтә торалар. Шуның өчен авылларда хатын-кызларның хокуклары да аяк астында тапталып килә. Бу сайлауларда инде советка, әлбәттә, хатын-кызлардан вәкилләр кертергә тырышырга кирәк. Бу эш авыл хатын-кызларын халык эшенә тартуга бик күп ярдәм итәчәк.

Сайлау көнендә иске советның ясаган отчетын (еллык хисап) крәстиян агайлардан бик нык тикшертергә кирәк. Тикшерү вакытында крәстиян агайларның һәммәсе моңар катнашырга тиешле.

Сайлауларга күрсәтелгән кандидатларны да инәсеннән җебенә кадәр тикшереп үтәргә һәм сайланган яңа советка крәстиян агайлар сәяси һәм икътисади наказлар бирергә тиешләр.

**КАРУСЕЛЬ**

– Тфү! Шайтангамы кирәк булгандыр шулай кешеләрне разрядларга бүлеп узыштырулар.

– Нигә алай?

– Нигә алай, нигә алай... Учреждениеләрдә берәүгне дә очратыр хәл юк: иртән шул учреждениеләр ачылырга өлгерми – 10 нчы разряд белән жалованье алучы 11 нчегә китә, 11 нче үз рәтендә «эш» белән 12 нче разрядлы кешегә китә, 12 нче 13 нчегә, 13 нче 14 нчегә, 14 нче 15 нчегә, 15 нче 16 нчыны эзләп китә, 16 нчысы 17 нчегә киткән була. Шулай итеп, учреждениеләрдә буш өстәлләр моңая.

Мин үзем 9 нчы разряд белән жалованье алам.

Бүген иртә белән иртүк торып 10 нчы разряд белән жалованье алучы Хәмитевкә эш белән киттем, ул 12 нче разряд белән жалованье алучы Сәмитевкә киткән, Сәмитев Хәлитевкә киткән, Хәлитев Сабитовка киткән. Тфү!

Мин, боларның эзе белән барсаң, гомердә таба алмассың, дип, «барабыз»га[1] утырдым да:

– Бу халык, «бер-берсен эзләшеп», Совнаркомга[2] кадәр барып җитәрләр әле, – дип, туры ук Совнаркомга барып чыктым.

Барып чыгуыма күп тә үтмәде, аның артыннан ук, портфельләрен өстерәп, аны эзләп, берничә 15 нче разрядлы кешеләр килеп керделәр.

Аларны эзләп, 14 нче разрядлар килеп җиттеләр.

Соңыннан берәм-берәм нәни разрядлар килә башладылар.

Шулай итеп, Совнарком коридорында очередь тезелде, 16 нчы разряд 15 нчеләрне кабул итте, ул китүгә, 15 нчеләр аның урынын алдылар.

Коридор базарга әйләнде.

Мин үзем, очередь җитеп, 10 нчы разряд белән эшне бетереп чыгыйм дигәндә, койрыгыма әйләнеп карасам, 8 нче разряд минем үземне эзләп килгән...

– Ха-ха-ха-ха!..

Нәрсә авызыңны ерасың, уен эш түгел ич, бу һәр көнне шулай. Әле кайбер көннәрне 17 нче разряд заседаниедә булу белән, 16 нчы разряд аны көтми чыгып китә, аны эзләп килүчеләрнең килүчеләре дә шулай итәләр. Автомобильне юрга куа, юрганы – «барабыз», «барабыз»ны – җәяүле, җәяүлене...

Тфү!

Учреждениеләр Ташаяк[3] каруселенә әйләнеп баралар.

## МӨЯССӘР ДИЮ ҺӘМ ЯМАН АВЫРУ МИКРОБЛАРЫ

Алай эшләсәң дә, вай,
Болай эшләсәң дә, вай.
Соңгы тиен Себер китсен –
Салып җибәрик давай! –

дип җырлаган мескен Һибәт бабай. Кайгысы зур булган шул, малай: карт хатынын эчәргә дә бирми дип аерган, яшьне алган, яшь хатын алу белән, ялангач калган. Сез, бәлки, әйтерсез: бу нәрсә ялган, ышанмаслык, карган! диләр мишәр абзыйлар. Сырдан авылы халкы кооперативларында «комчамулка»ларны:

– Эш йөртә белмисез, башларыгыз яшь әле! – дип, алар кулыннан кооперативны алдылар, эш йөртә белүчеләрне куйдылар да кооперативсыз калдылар...

– Их-ма! – мишәр әйтмешли.

Моннан өч ел элек Мамадыш кантоны Өчиле[1] волосте[2] крәстияннәре: «Кооператив юк, шуның өчен сәүдәгәрләр дә юк», – дип, кооператив юклыктан зарланып йөрделәр. Кооператив ачып, кооперативны алып барырга бу ел җәмәгать хәшәрәте Мөяссәр дигән спекулянтка бирделәр.

Бер елдан кооперативлары гына түгел, крәстияннәр үзләре дә бөлделәр.

Мөяссәр абзаң бу ел, кооперативка хисап биргәндә, ары-бире юл расходларына гына да 1300 сум күргәзә. Димәк, айга юл расходларына гына 100 сумга якын акча чыккан. Башка мең сумнарны әйтмә дә, бөтен кооперативларны берүзе йоткан!

Коммунистлар «Алла, җен, дию юк» дип йөрделәр, ә Өчиле волосте халкы Мөяссәр диюне дә күзләре белән күрделәр. Хәзер:

Кооператив ачмасаң да, вай,
Кооператив ачсаң да, вай;
Киткән акча киткән инде,
Пайларны кире давай, –

дип җырлап йөриләр, ди. Алар ише кооперативлар бөтен җирдә чәчәк ата. Әле 19–24 нче елларда оештырылган Тәтеш кантоны Бик Үти[3] авылы кооперативы да үлем түшәгендә ята... Мескен кооператив, «правление әгъзалары» дигән яман авыру микроблары эләктереп, бер ел авырып йөргән, ди. Соңгы хәбәрләргә караганда, бөтенләй череп, эштән чыгып үлгән, ди. Алай да Бик Үти халкы кайгырмый, ди. Җитмәсә, мәрхүм кооператив 1080 сум халык акчасын ашап үлүе өстенә үлгәч тә, авыл халкын мәрхүмнең бурычларын түләтеп аптыратып бетерәләр, ди.

– Их-ма! Бу нәрсәләр әле кулга төшкән материаллардан гына.

Авылларга чыгып йөрсәң,

Үзең тикшереп йөрсәң,

Гакылдан шашарсың.

Сырдан авылы халкы кебек: «Кооператив төзелсен!» – дип түгел, төзелмәсен дип, муллага хәер бирер өчен ярты җиреңне сатарсың.

## БЕЗНЕҢ ХАТ

Безнең журналда «Авыл хуҗалыгы түгәрәкләре» дигән бүлек бар. Без журналның һәр номерында диярлек бу бүлекне алып барабыз. Ләкин урыннардагы авыл хуҗалыгы түгәрәкләреннән үзләренең эшләре турында бер материал гына килми. Әллә инде безнең татар авылларында ул түгәрәкләр туарга өлгерми үлеп беттеләр микәнни?

Урыннардан материаллар, сораулар булмау сәбәпле, безгә дә бу бүлекне алып бару авыр. Ләкин яңалыкка омтылучы крәстиян яшьләре өчен бу бүлек бик кирәк. Бу бүлек безнең бик җанлы барырга тиешле иде. Аңлы крәстиян яшьләре, бу эшкә бик нык әһәмият биреп, түбәндәге сорауларга җавап җибәрергә тиешләр:

1. Сезнең авылда авыл хуҗалыгы түгәрәге төзелдеме һәм кайчан?

2. Төзелмәгән булса, ни өчен төземисез?

3. Төзергә теләк белдерүчеләр бармы? Булса, нәрсә киртә булып тора?

4. Авыл хуҗалыгы түгәрәге төзелгән булса, хәзергә кадәр нәрсәләр эшләде?

5. Күпме әгъзасы?

6. Картрак крәстиян агайлар катнашалармы?

7. Эшне план белән алып барасызмы? (Планыгызны языгыз.)

8. Авылыгызда яки якын бер авылда агроном бармы һәм аның белеменнән файдаланасызмы?

9. Планыгызга кергән нәрсәләрнең кайсы эшкә ашты? Нәрсәне эшкә ашыра алмый торасыз, ни өчен?

10. Журналның «Авыл хуҗалыгы түгәрәге» бүлегендә нәрсәләр турында күбрәк язарга?

Менә шул сорауларга җыйнаулап җаваплар языгыз. Редакциягә төрле сораулар җибәрегез, без сезгә үз вакытында җаваплар биреп торырбыз.

**СИНЕҢЧӘ НИЧЕК?**

Журналыбызның менә инде 12 нче номеры чыга, шул унике номер үзен авыл яшьләре арасында таныттырга тиешле иде дип уйлыйбыз. Ничек булгандыр. Ләкин журнал үзенең беренче номерыннан ук «Авылга йөз белән» лозунгысы астында киткән иде һәм ул шул лозунгыны һәр номерында тулырак үтәргә, авыл яшьләренең эченә керергә тырышты. Ләкин журналыбыз бер ел эчендә авыл яшьләренең йөрәгенә керде, авыл яшьләренең үз журналлары булып әверелде дип әйтеп булмый. Чөнки «Авыл яшьләре» журналының авыл яшьләренә йөз белән китүе генә җитми. Моның өчен авыл яшьләренең үзләренең журналга йөз белән әйләнүләре тиешле. Ләкин авылның алдынгы яшьләре тарафыннан бу нәрсә тулы рәвештә үтәлде дип әйтеп булмый.

Дөрес, авыл яшьләре төрле шигырьләр, җырлар җибәрәләр. «Журналдагы яңа җырларны матурлап җырлап йөриләр, хикәяләр дә бик тәмле була. Журнал бик матур, бик тәмле», – дип тә язалар.

Ләкин мондый мактаулар белән генә эш бетми.

Авыл яшьләренә дә гел шигырь генә кирәк дип әйтеп булмый.

Яшьләрнең көндәлек тормышларында очрый торган бик күп яңа мәсьәләләр бар. Аз белемле авыл яшьләре күп вакытта бу мәсьәләләрне үзләре генә башкара алмыйлар. Бездә әле кирәкле мәсьәләләрдән җитәрлек брошюралар да (китаплар да) юк. Шуның өстенә практика, эш үзе авыр-авыр мәсьәләләр тудыра. Менә аңлы авыл яшьләре бу мәсьәләләрне хәл итү, кирәкле юллар табу өчен журнал белән бәйләнеш ясарга тиешләр иде. Аңламаган нәрсәләрен журнал идарәсеннән сорап язарга, уңышлы, үрнәк булырлык адымнарын журнал аркылы башка иптәшләренә белдерүләре кирәк иде.

Икенче яктан, журналның кимчелекләрен күрсәтү, нинди мәкаләләр язу турында үзләренең фикерләрен белдерү, шуның белән бергә «Авыл яшьләре» журналын яшьләр арасында күбрәк тарату белән дә булышлык күрсәтү – авыл яшьләренең бурычларыннан берсе.

Журнал никадәр күбрәк авыл яшьләре арасында таралса, шулкадәр журнал авылга якынаячак, массаның эченә керәчәк. Журналга катнашучылар күбәячәк, журналның кәгазе дә яхшырачак, рәсемнәргә дә, кирәк материалларга да бай чыгачак. Бу юлда бик күп эшләргә кирәк һәм шул кирәкләрне әз генә җиңеләйтү өчен дә бергәләшеп эшләргә кирәк.

Менә безнең бу номердан алып журнал турында әңгәмә, киңәшү бите ачыла. Без бу дискуссиядә авылның аңлы яшьләре катнашырлар, журналыбызның ким якларын күрсәтерләр, шулай итеп, журнал белән бик нык бәйләнеш ясап, киләчәктә эшләнергә тиешле эшләрне сызып үтәрләр дип уйлыйбыз.

Даешь журнал турында үзегезнең фикерегезне!!

**ҖАНЛЫ КАЗАРМАЛАР**

Шәһәр чите авыл кырларыннан, заводлардан җыелган киң күкрәкле яшь егетләрнең җырларын тыңлый.

Казармалар җырлый.

Йөзләрчә аякларның бергә атланган адымнарыннан чыккан тавышлар җырга кушыла. Бер рәткә тезелгән меңнәрчә егетләр кояшны менә шулай каршылыйлар, шәһәр читенең Октябрь казармаларының[1] иртәсе шулай башлана.

---

Советлар иле капиталистлар белән чормалган. Без сугышны теләмибез. Ләкин Советлар илен дошманнан сакларга мәҗбүрбез! Шуның өчен дә винтовка сөңгеләре кояшта ялтырый. Авыллардан, заводлардан җыелган яшь-яшь егетләр, винтовкаларын алга, артка ташлап, сугыш белемен өйрәнәләр. Авыр тупларның борыннарын кояшка төзиләр.

---

Октябрь казармалары күпне күргән, Каргаполь казармалары[2] күптән салынганнар.

Шушы казармалар эчендә, патшаның әбисе белән бабасының исемнәрен белмәгән өчен, солдатлар яңакка кыйналганнар, кыйналудан соң аларга тагын шул ук исемнәрне бикләткәннәр. Тагын Ватанны, бөек императорны саклау бурычларын өйрәткәннәр. Казармаларда җансыз гәүдәләр йөргәннәр. Казарма тирәләрендә эфисәрләрнең погоннары ялтырагандагы еллар үткән инде.

Менә бу биек кызыл кирпечтән салынган казармалар яшь переменникларның исләренә куркынычлы үткән көннәрнең фаҗигаләрен генә сөйлиләр.

Көләч, үзенең гаскәри бурычын үзе белгән яшь переменниклар карт казармаларны яшәрткәннәр хәзер.

Аларның диварларын үзләренең бөек теләкләре язылган плакатлар белән бизәгәннәр. Бөек җиңүдә даһиларча юлбашчылык иткән Ленин үзенең төзеп калдырган ирекле илен сакларга хәзерләнүче балаларының йөзләренә карый.

Төш вакытында котелоклар шалтыравыннан чыккан тавышларга кемнеңдер: «Ленин уголгына!» дигән тавышы кушыла. Ә бераздан:

– Ать, два!

– Ать, два! –

белән меңнәр аягы тагын кырга атлый.

---

Бүген күп җир йөрелгән. Биш-алты дәрес уздырылган. Хәзер кичке ашны ашарга да арыган аяклар белән клубка атларга. Ә клубта:

– «Кызылармеец»ның соңгы номеры!

– «Кызыл Татарстан»ның бүгенгесе!

– Журналларның яңалары!

Көтәләр.

Казарманың төне шулай башлана. Казармалар әле йокламый.

Тик казармалар каршындагы авыр туп арбалары гына борыннарын йолдызларга терәп йоклыйлар... Алар, бәлки әле, күп еллар шулай йокларлар.

## «ЛОТЕРЕЯ УЕНЫ»НДА КЫЗЫК СОРАУЛАР

Хәзерге көндә гаскәри частьларда «Лотерея уены» таралып бара. Бу уен терармеецлар өчен кызыклы. Шулай ук бу уен белән кызылармеецларга күп кенә белем бирергә, матур гына беседалар үткәрергә мөмкин. Ләкин лотереяга куелган сораулар терармеецларны аптыратырлык аңлаешсыз, шулай ук терармеецларның аңнары сыйдырмаслык зур мәсьәләләрдән булмаска тиешле... Болай булганда, аңнарыннан югары сорауларга җавап бирә алмаган терармеецлар өчен «лотерея уены» кызык булмый.

Безгә, беренче укчы полкның Ленин почмакларын тикшереп йөргәндә, лотереяга куелган шундый сорауларны очратырга туры килде.

Беренче сорау:

1) Башка хөкүмәтләр Милләтләр лигасына[1] СССРның керүен телиләрме, юкмы?

Менә бу сөальгә гади терармеец җавап бирә аламы, иң элек әле ул Милләтләр лигасының нәрсә икәнен беләме?

Икенче сорау:

2) Бөтен дөнья йөзендә ничә лагерь бар?

Моңар ничек җавап бирергә? Нинди лагерь ул? Кызыл Армиянең язгы лагерьларымы, Германия гаскәрләренең лагерьларымы яки ике дошман лагеремы?

Өченче сорау:

3) СССРның авыл хуҗалыгы яки промышленносте?

Моңар ничек җавап бирергә? Җавап бирим дигәндә дә, гади терармеец бу хакта нәрсә әйтә ала?

Дүртенче сорау:

4) СССРның мирный договоры бармы, әллә юкмы?

Ни дигән сүз бу? Кайдан алып бу сорауны чишәргә?

Менә бу сораулар безнең кулга артык эзләнми генә төшкән нәрсәләр. Тикшерә башлаганда, моннан кызыграк сораулар табарга мөмкин булачак.

Лотереяга сораулар язучылар үзләре өчен сораулар язмый, түбән аңлы, караңгы авыллардан җыелган кызылармеецлар өчен аларның аңнарына карап язарга тиешләр.

Шундый ук нәрсәләрне собраниеләрдә, сәяси сәгатьләрдә дә очратырга мөмкин. Бу эшләрне башкаручы иптәшләр кызылармеецларга «колониальный», «консервативный», фәлән-төгән кебек «югары» сүзләр белән артык җәелми, терармеецларга аңлаешлырак тел белән сөйләргә тиешләр. Киресе булганда, терармеец иптәшләр политзанятиеләрдән бернәрсә ала алмый китүләре бар.

**РАДИО**

Газета укып барган кешеләргә һәрвакыт «радио» дигән сүзне очратырга туры килә. Шәһәрләрдә инде ул «радио» дигән сүзне ишетү генә түгел, күзләре белән дә күреп беләләр.

Безнең авылларга килсәк, бу сүзне, билгеле, ишеткән булсалар да, күбесе әле аның нәрсә икәнен белмиләр.

Нәрсә соң ул радио?

Кешеләр бер-бере белән, үзләренең тавышлары күпмегә ишетелсә, шул җирдән генә сөйләшә алалар.

Ләкин күп вакытта бик ерактан берәүгә бер хәбәрне бик тиз ишеттерергә кирәк була. Билгеле, бик борынгы заманнарда ук шулай ерактан сөйләшә алу юлларын эзләүчеләр булган һәм бу эштә төрле юллар табып тәрәккый иткән. Шулай итеп, бик күп көчләр куеп, кешеләр хәзерге көндә без еракта сөйләшә ала торган телеграмма, телефон кебек нәрсәләргә килеп җиттеләр. Инде телефон белән кешеләр бер-берсе белән бик ерак шәһәрләрдән, хәтта чит илләр белән дә сөйләшә алалар.

Инде шулай сөйләшә алгач, артык эзләнү дә кирәкмәс иде кебек. Ләкин кешеләр моның белән генә тукталып калмый һәм эзләнүдә дәвам итәләр. Чөнки шул ук телефонның бик уңайсыз яклары бар.

Алыйк бер ягын: телефонда тимерчыбыклар белән генә сөйләшергә мөмкин. Ә инде тимерчыбыклар бик кыйммәткә төшә, бигрәк тә безнең Россия кебек сирәк һәм бер-берсеннән ерак утырган халыклы бер җирдә.

Шулай итеп, соңгы елларда бу нәрсәләрне җиңеләйтә торган гаҗәп яңа бер юл – радио белән сөйләшү юлын таптылар. Радионың ничек эшләнүе турында бу җирдә тукталмый, шуны гына әйтеп китәбез: радио ул кеше тавышы йә сүз билгеләрен тимерчыбыклар аркылы бирми, бәлки чиксез һава аркылы бирә.

Әгәр дә радио моннан өч йөз еллар элек табылган булса иде, аның табучысын сихерче йә җенле дип, шиксез, тотып утта яндырырлар иде. Дөрестән дә, бик гаҗәпләнерлек эш бит?

Әйтик, син Мәскәүдән ерак бер җирдә утырасың, ә Мәскәүдә үзенә тиешле ясалган бер машинада берәү сөйләшә яки җырлый, шул машина күзгә күренми торган һавадагы дулкыннар аркылы сөйләүче кешенең сүзләрен күз ачып йомганчы зур урманнар, киң сахралар аркылы әкиятләрдәге кебек тирә-якка тарата.

Шулай итеп, син, өеңдә утырганың хәлдә, үзеңнең шул сүзләрне һавадан тота торган аппаратың белән Мәскәүдән торып сөйләгән кешенең сүзләрен тыңлап торасың.

Ләкин бу әкият түгел, бу нәрсәне кешенең гакылы уйлап, кулы эшләп чыгарган. Ләкин әле радио белән файдаланганда, без тыңлап кына тора алабыз, ә инде радио аркылы һәркем үзе сөйләп тә тыңлап тору хәзергә мөмкин түгел, чөнки радионың сөйләргә мөмкин булган машинасы бик кыйммәт, аның сөйләшә торган аппаратын хәзергә һәрбер гражданга сатып алу мөмкин түгел.

Әле тыңлау өчен дә кайбер уңайсызлыклары бар. Ул уңайсызлыклардан берсе – сүзләр тарата торган станция никадәр якын булса, радионы кабул итү аппараты шулкадәр арзанга төшә, инде никадәр ерак булса, шулкадәр кыйммәткә төшә.

Ә андый сүз тарата торган станцияләр әле бик аз. Шулай итеп, без әле тыңлап кына утыра алабыз. Сөйләшергә бераз иртәрәк.

Хәзерге көндә радио безгә нәрсә бирә ала?

1. Радио ул – җанлы газета. Радио аркылы сез иң соң хәбәрләрне ишетә аласыз. Газеталар килеп җиткәндә инде, сез ул хәбәрне ишеткән буласыз.

2. Радио аркылы мәркәздә бөек юлбашчыларыбызның сөйләгән сүзләрен ишетеп була. Алай гына түгел, советлар съездының яки Коминтерн[1] мәҗлесләренең бөтен докладларын, сөйләүләрен, кыскасы, төрле фәннәрдән зур галимнәрнең сөйләгән докладларын тыңлап була. Радио аркылы иң яхшы артист, артисткаларның җырларын ишетеп була. Шулай итеп, радио – белемеңне арттыруга бик зур ярдәмче.

Инде крәстияннәр радио аркылы бик күп файда итә алалар. Хәтта укый-яза белмәгән крәстияннәрнең (бигрәк тә рус крәстияннәренең) аңын күтәрүгә зур ярдәм.

Буш вакытта трубкаларын колакларына куя да тыңлый. Аңарда шул дөньядагы яңа хәбәрләрне сөйләп торалар. Радио крәстияннәргә үз вакытында декретларны, налогларны, башка крәстиянгә кирәкле нәрсәләрне аңлатып тора

ала. Шулай ук крәстиян радио аркылы мәркәздәге иң яхшы агрономнарның крәстиянгә кирәкле нәрсәләр хакында сөйләгән сүзләрен тыңлап, бик күп файда бирә ала.

Ләкин крәстиян йортларына радио кертү иртәрәк һәм бераз кыйммәтрәк. Ләкин радио белән мәктәпләрдә хәзердән үк файдалана башларга мөмкин. Радионы кабул итү аппараты киләчәк еллар 3 сумнан артык тормас.

Еллар үтү белән, радио ышанмаслык дәрәҗәдә тәрәккый итәчәк. Кешеләр бүлмәләрендә генә түгел, бәлки шул аппаратларны кесәләренә куеп тыңлап йөрерләр. Кирәксә, сөйләшә дә алырлар.

**БӘХЕТ БАРАБАНЫ**

Шәһәрдә колактан-колакка хәбәр йөри:

– Ә беләсең, Йосыпов кичә лотода 200 сум акча откан!

– Кит аннан!

– Валлаһи, үзе сөйләде.

– Вот бәхетле кеше!

– Да, малай!

– Бер барып, бәхетне сынап кайтырга кирәк, тунлык отып булмасмы.

– Жалуния алу белән давай барабыз!

– Давай!

Алар, жалованье алу белән, шул көнне хатыннарыннан яшереп кенә акча алып калалар да бәхетләрен сынарга – «тун отарга» – Проломный чатындагы лото залына китәләр. Ә анда инде сәгать сигез тулуга йөзләрчә кеше бәхет залының ачылуын көтеп торалар.

Болар акчасыз кешеләр. Болар инде шул залда икешәр ел бәхетләрен сынап йөргәннәр.

«Бәхет залы» ачылуга, биш уен акчасыз карта өләшәләр. Шуның өчен акчасыз халыкларның әле күңелләре күтәренке.

– Эх, уйнарлык кына, малай, отып булса иде.

– Әллә нәрсә озаклыйлар. Тизрәк ачсыннар иде!

Менә зал ачыла. Сугыша-сугыша, бәхет карталары өләшенә. Һәммәсе өстәлләргә тезелеп утыралар. Йөрәктә бәхетле уйлар:

– Бүген, бәлки, бер 50 сум отып булмасмы?

– Берәр атна оттырам инде. Бүген, бәлки...

Хыял ул кешене биш минутта бәхетле итә.

– 100 сум отсам, кайтуга хатынга белдермим. Тыныч кына кайтып ятам. Ә иртән аңа күлмәк... үземә...

Бәхет цифрлары кычкыручы «ораторлар»дан берсе бәхет колоколы шалтырата:

– Соңгы бәхетле карта!

– Миңа!

– Миңа!

Якында торган берсе картаны эләктерә. Менә бәхет цифрлары кычкыручы шадра йөзле егет, салмак кына «бәхет машина»сыннан бәхет шарлары алып, бәхет цифрлары кычкыра башлый:

– Сорок два!

– Семь!

Һәм кичке сәгать сигездән иртәнге дүрткә кадәр колакларда бәхет шаннары яңгырый. Менә егерме-егерме биш яшьләрендә берәү, картасына күзләрен тегәп, номерларын тикшереп ята. Ул инде ике ел шул залда бәхетен сыный. Ике ел эчендә ул әнә тегендәге кассадан һәрбере 30 ар тиеннән ике меңгә якын карта сатып алган. Ләкин шул карталар арасында бер генә бәхет картасы эләгеп, 96 сум акча откан. Ә шул бәхетле картаны эзләүгә ул ай саен ярты жалованьесен җибәргән. 250 сум хөкүмәт акчасын шул юлга куйган. Аннан, судка эләгеп, урынсыз калган. Бөтен нәрсәсен саткан. Матур гына торган сөйкемле хатыны белән баласыннан аерылган. Хәзерге көндә тормышның иң түбән баскычларына төшеп бара. Иртән сәгать дүрттә лото ябылуга, ул иртәгә кичкә «бәхет карталары» алу өчен акча эзләргә керешә. Төнге йозаклы, бикле ишекләрне каргап йөри башлый.

– Бәлки, иртәгә чыгар... Бер 100 сум отсам, мәңгегә-мәңгегә уйнауны ташлармын. Казаннан китеп, берәр урынга керермен.

**Биш этәч**

Бер зур өстәлнең читендә алты әби утыра. Алар йолкынып беткәннәр. Шулай да киләчәккә өмет зур. Алтау-бишәү тиен кушып алган карта. Аларга бәхет вәгъдә итеп елмаеп ята.

– Отарбыз!

– Минем инде 10 гына тиен акча калды. Иртәгә ашарга да калдырырга онытттым.

– Кайгырма, бик әйбәт карта эләкте. Алла насыйп итсә, отарбыз!

Алар бәхетле, тәмле оту хыялларына чумалар. Берсе авыз эченнән нәрсәдер укына, икенчесе, тирә-яктан тикшереп карап торучы юкмы дип, әйләнеп карангалый да яшерен генә картасын чукындыра.

Менә бәхет цифрлары яңгырый башлый. Әбиләргә кирәкле цифрлар машинадан чыкмыйлар. Берсе чыкса, икенчесе әллә кая кысылып калган була. Менә картадагы дүрт цифр ябыла, берсе генә ябылмый кала. Алты авыз үзләренә кирәкле цифрны тәкрарлый башлый.

– Егерме ике, егерме ике, егерме ике...

Ә бәхет цифрлары кычкыручы егерме икенче цифрны кычкырмый, әбигә үч иткәндәй, егерме өченче цифрны кычкыра. Әллә кайда еракта ниндидер бәхетле кеше:

– Готово! – дип залны яңгырата.

– Уф!

– Бәхетле кеше!

Залда үтүче кеше адресы буенча төрле сүзләр ява.

Тагын яңа карта сатып алырга кирәк. Кесәсендә 10 тиен генә акчасы калган әби сүгенә-сүгенә зарлана:

– Инде биш әтәчемне саттым. Бишәвенең дә акчасын шунда оттырдым. Хәзер нәрсә сатарга да, нәрсә ашарга да юк.

Ул көлеп сөйләми. Ул биш әтәч асраган. Әтәчләренең койрыклары да, төсләре дә матур булган. Ә ул сатып ашарына тоту урынына бишәвен дә бәхет эзләргә корбан иткән.

– Ә иртәгә?..

**Бәхетле тун**

Бер кием тегүче тол хатын алты ай лотога йөргән. Ул һәр көн дүрттә ятып, сигездә торган да кичкә кадәр киемнәр теккән. Тегүдән килгән 2–3 сум акчасының 50–60 тиенен ике баласы белән үзенең ашарына тоткан. Калганын бәхет эзләүгә җибәргән. Алты ай төтенгә күмелгән залда төннәр уздыру, начар ашау сәбәпле туберкулез белән авырый башлаган. Көннәрнең берендә лотога барырга акча кулына төшмәгәч, тегәргә дип китергән берәүнең материясен саткан да, бәлки, шул акча белән бер 50 сум акча ота алмаммы, дигән. Ләкин... бәхетле карта туры килмәгән. Ул күршесенә шул хакта зарланып утыра.

Күршесе аны бу эш өчен гаепләми. Үзе дә шундый ук хәлдә булуын уйлап сүгенә:

– Нигә халыкны харап итәләр? Нигә хөкүмәт шул җәһәннәм базларын яптырмый? – ди.

Хатын тагын нәрсәдер сөйләргә башлаганда, лото патшасы Галимҗан егерме берләрне кычкыра башлый. Ул тына.

Бишенче уенда тегүче хатын кинәт ачы, йөрәк яргыч тавыш белән залны яңгырата:

– Ту-у-ун! Туным! Шуба!!! – дип кычкырып җибәрә.

Аның куллары калтырый. Картасын югары күтәрә. Тикшерәләр. Картасы 15 сум акча откан була.

Зал кычкырып көлә. Ни өчен бу хатын «җитәр», «оттым» дип кычкыру урынына «шуба», «тун» дип кычкыруын беләселәре килеп, аның янына җыелалар. Ул, тегү тегәргә дип китергән материалны сатып, акчасын оттыргач, аңарга сорап килгәннәр. Ул, хәзер түгел әле, дигән. Шуннан, ни булса була, оттырсам, асылынып үләм, отсам, бирермен, дип тәвәккәлләп тунын саткан һәм кеше туны киеп лотога килгән. Бәхетенә каршы, туны аның бәхетле булып чыкты.

Ул:

– Оттырган акчаларымның яртысы кайтты инде. Гомердә дә, гомердә дә килмәм! – дип антлар итә. Ләкин...

Бер атнадан ул хатын тагын да лото залында утырадыр иде.

**Хатыны аны көтә**

Ак йөзле, сары чәчле, күзләре эчкә баткан, залдагы төтеннән арыган егерме биш яшьләрендә яшь бер егет утыра. Ул партияле. Аның кесәсендә 1 сум 50 тиен акчасы калган. Димәк, биш карталык. Аның обедтан соң ашаганы булмаса да, ашыйсы килсә дә, карта алырга акча калмый дип, ашарга саранланып утыра.

Аның ак йөзендә күм-күк арыганлык, кайгы сызыклары сызылган. Ул, алдындагы картасына карап, андагы цифрларны тикшереп утыра. Берле цифрны ул яратмый. Әллә ничә аңарда шул цифр. Менә шул ук картасында егермеле цифр да бар. Бу цифр да аңарга чыкмас төсле тоела. Шуның өчен ул картасын барып алмаштырып килә дә, тәмәкесен кабызып, уйга бата.

Мин аның, теле сөйләмәсә дә, нәрсә уйлавын аңлыйм: аның матур гына, аңлы гына хатыны бар. Бу партиец аңарга бернәрсәдә дә алдаганы да, хыянәт иткәне дә юк. Аны өзелеп яратты. Ләкин лото мәсьәләсендә ул аны көн саен алдый. «Собраниегә» йә башка хәйлә белән китә дә төнен лотода уздыра. Өйдә доклад хәзерлисе бар. Ләкин...

Аның кесәсендәге акчасы сәгать икегә кадәр уйнарга җитәр. Димәк, икесез кайта алмас. Соңыннан ул миңа ышанып, зарланып сөйләгәне бар:

– Алдашып маташмыйм. Сиңа ышанам. Мин көннән-көн үзем сизеп түбән төшә барам. Йөрүдән туктый алмыйм. Үземне-үзем өзгәләр дәрәҗәгә җитәм. Партия эшеннән ераклашам. Эшләгәндә башымда көн буе каһәр суккан цифрлар бутала. Минем хатынны беләсең син. Мин аны өзелеп яратам. Ләкин менә монда дүрткә кадәр утырып кайтып ятам да иртән «ашыгып-пошыгып» йокламаган баш белән эшкә китәм. Хатын кайчак мин торганда базарга киткән була. Шулай итеп, икешәр көн яхшылап күрешеп булмый. Кичен кайтып ашауга, ары-бире үтми, алдалап бире китәм. Ә ул... Бүген дә иртәгә ашарга акча калдырмадым.

Ул кайтуга матур сөекле хатыны аңардан кайда булуын сорар, ә ул аны алдар.

– Иптәшләрдә идем.

– Ялганлыйсың син, кемнәр беләндер йөрисең яки... Ә акчаң кайда?

– Берәүгә биреп тордым.

– Ялган! Ялган!

Ул, сөекле хатынын юатырга теләп, акланырга тырыша. Ләкин... хатынының күз яшьләре аның ятачак мендәрен чылатырлар...

Мин аңарга карыйм да киләчәгенә пәйгамбәрлек итәм:

– Ул, монда йөри-йөри, партия эшеннән аерылыр, бәлки, растратка эләгер. Үзенең иптәшләреннән ераклашыр. Соңгы киемнәрен сатарга җитәр. Сөйгән хатынын һәр көн күз яшьләренә күмәр. Соңыннан эш, бәлки, партиядән чыгуга, хатыны белән аерылуга, бәлки, тагын да югарырак китәр...

**Җинаять капкасы**

Шәһәрдә колактан-колакка хәбәр йөри:

– Ә беләсең, Закиров кичә лотода 100 сум акча откан.

– Кит моннан?

– Дөрес, үзе сөйләде. Әйбәтләп киенгән малаең.

– Вәт бәхетле кеше!

– Барып, бәхетне сынап кайтырга кирәк. Пальтолык отып булмасмы?

Һәр көн, пальтолык отарга дип, шушы җинаять базына кырыгар-иллешәр яңадан-яңа кешеләр кереп тора.

Ләкин кем генә керсә дә, биш айдан ул ялангач кала. Растратщик була, пессимизмга китә, хатыныннан, иптәшләреннән, партиясеннән, ниһаять, шатлыгыннан – бөтен нәрсәләреннән аерыла.

Лото барабаны тишегеннән бәхет көтүчеләрнең 100 проценты совет хезмәткәрләре, кустарьлар, рассыльныйлар, дворниклар, укучылар, итекчеләр, тегүчеләр, эшчеләр, грузчиклар, элек рәтле кеше булып та, лотога тун отарга йөреп, ота алмагач караклыкка киткән кешеләр. Нэпман[1] гына юк. Ул «тунлык» акчаны кайдан табарга бик яхшы белә.

Тиздән асылып үләчәк художник. Мин аны кызганам. Татарның художниклары болай да көчкә тамакларын туйдырып торалар. Ә ул менә тамакка дигән акчасын да көн саен шунда килеп оттыра. Миңа аның турында берәү сөйли:

– Мин аның беренче мәртәбә лотога килгәнен хәтерлим. Ул элек рестораннарга кереп ашап-эчеп утыручыларның рәсемнәрен ясап, акча табып йөридер иде. Көннәрнең берендә лотога килеп чыккан кесәсендәге 60 тиен акчасына саранланып, ошатыр-ошатмас, карта алды. Гөнаһ шомлыгына каршы, шул картасына 3 сум акча отты. Тагын бер-ике уен уйнаган иде, көтмәгәндә тагын 8 сум килеп чыкты. Икенче көнне егетебез хатынын, баласын ияртеп килгән. Ул көнне отканнардырмы, хәтерләмим. Ләкин хәзерге көндә хатынын да ачка үтерә, үзе дә асылып үләргә йөри, ди.

Мин бәхетсез художникка карыйм. Аның акчасы беткән булырга кирәк. Ул башкаларның уйнап торуларын гына карап тора. Соңыннан кемнәндер инәлеп бер карталык акча сорый. Аннан икенчесенә китә. Ә бераздан 16 сум акча откан бер итек тегүче янына барып утырып, аңардан ике карталык акчага рәсемен ясатуын инәлеп сорый башлады. Тегесе риза булды булырга кирәк. Кызыл мыекларын бөтереп, өстәлгә таянып поза алды. Ә тиздән асылып үләчәк художник ике карталык акчага ашыгып-ашыгып аның рәсемен ясый башлады. Ул рәсем ясап алган акчасын, һичшиксез, шунда оттыргандыр. Ә баласы белән хатыны кан-яшь белән аның икмәклек акча алып кайтуын көтә торганнардыр...

———

– Нигә лотосын да, чертын да яптырмыйлар!

Кем генә лотога яки электролотога йөрсә дә шулай ди. Кайберләре сөйләп кенә калмыйлар, сипкелләре йөзенә дары кисәкләре кебек кереп баткан арык, сипкел йөзле, көндезге сәгатьләрдә столовойда эшләүче татар көн дә электролотога килә. Оттыруы белән ул берәүдән 30 тиен акча ала да, күршедәге пивнойга кереп, берне салып чыга. Соңыннан кызмача баштан, уйнаучылар янына кереп, дөнья җимереп, тавыш күтәрә:

– Нигә япмыйсыз, нигә безне талыйсыз? – ди.

Аны һәр көн милициягә алып китәләр.

Әнә берсе, әле яңа гына кереп, электролотода уйнарга кереште. Бүген числоның унбише. Димәк, ул жалованье алган, акчасы күпкә ышанып булырга кирәк, акчасын кызганмый номерларга сала. Бер-ике унар сумга якын акча да алды бугай. Йөзе ачылып китте. Ул тагын да иркенрәк уйный башлады. Кулында акча күбәйде. Кемдер аңар арттан:

– Әйдә, артык ота алмассың. Откан чакта чыгып китик, – ди.

Ләкин уенның кызык бер психологиясе бар. Кеше отса, күбрәк отасы килә. Оттырса, оттырганын кайтарасы килә. Соңыннан ул акчасыз чыгып китәргә тиеш була. Бу егет тә шулай инде.

– Тагын бер генә салып алам да китәрбез, – диде. Ул уң якка 5 сум акча салды, оттырды. 5 сумны кайтарыйм дип, 10 сум салды, анысы да китте. Аның артыннан берәм-берәм кулындагы акчалары ычкына башлады.

Ул әкрен генә кесәсендәге акчаларын чыгара башлады. Мин аның йөзенә карадым. Кергәндә елмаеп торган йөзе тиргә батты. Артыннан «Әйдә инде, әйдә!» дип торган иптәшенә:

– Пошел к черту! – дип кенә җавап бирде.

Соңгы акчасын салды булырга кирәк. Күзләрен аппаратка терәде. Аппаратның стрелкасы икенче якка тукталды. Егетнең йөзләре агарды, ул урыныннан торды да уенны алып баручы кеше янына килде һәм:

– Акчамны кайтарыгыз! Мин яңа гына урынга кергән идем. Агент булып. Бу акча – хөкүмәт акчасы. Мин ышанычымны югалттым, зинһар, кайтарыгыз! – дип инәлә башлады.

Ләкин аңар кайтармадылар. Мин аның иреннәренең калтыравын күрдем. Диварга сөялде. Үкси башлады.

Хәзерге көндә безнең тормыш лирический бер төскә кереп бара. Партия, комсомол юлбашчылыгы астында булган иптәшләрнең күбесе үзләренең тормышларын җәмәгатьчелек белән бәйләп алып бара алалар.

Кайберсе моны эшли алмый, җәмәгатьчелектән аерылып бара. Партия, комсомол кул астына кереп өлгермәгән яшьләрнең күбесе адаштыргыч юлларга кереп баралар.

Кая барырга юк, эч поша... Шуның өчен пивнойлар, лотоларга китәләр.

Казанда инде меңнәрчә кеше, лотоларга йөреп, тормышларын җәһәннәмгә әйләндереп баралар. Аларның «Нигә лотоларны япмыйлар?» дигән сүзләре көләч йөздән әйтелгән сүзләр түгел, болар батып бара торган кешеләрнең җан ачысы белән кычкырган авазлары.

Эчке эшләр халык комиссариаты бу тавышны ишетергә тиешле.

**Соңгы сүз**

Казанда ике-өч лото, берничә икенче төрле уен йортлары бар. Алар балалар комиссиясе файдасына эшлиләр. Димәк, лотолардан, уен йортларыннан килгән акчалар тәрбиячесез калган балалар файдасына китә.

Ләкин, бер яктан, тәрбиячесез калган балаларга лотолар аркылы акча җыйсак, икенче яктан, меңнәрчә балаларны, аналарның күз яшьләрен түктереп, урамнарга ташлыйбыз. Лотога йөрүчеләрнең 90 проценты – хезмәткәрләр, кустарьлар.

Лотодан килгән файда аларның кара икмәккә дигән акчалары. Мәскәүдә бу йортларны күптән япканнар инде.

– Казанда да бөтен лотоларны ябарга!

– Клубларны җанландырырга!

– Халыкның тормышын сәламәтләндерергә кирәк!

**БЕЗНЕҢ БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР**

Татарстан Үзәк башкарма комитетының 4 нче сессиясе[1] әле башланмаган. Сессиягә килгән иптәшләр, төркем-төркем булып җыелып, әллә нәрсәләр турында кызу-кызу фикер алышып йөриләр. Эш залының уртангы рәтләрендә ундүрт-унбиш урындыкта хатын-кызлар утыра. Алар барыннан да элегрәк залга кереп утырганнар да сессиянең ачылуын көтеп утыралар. Татарстанның бу ерак авылларыннан килгән беренче карлыгачлар – хатын-кыз авыл председательләре. Аларның йөзләрендәге тынычлык, эшчәнлек минем башка ике күреп үткән вакыйганы искә төшерә.

Мин әле ул вакытта яшь идем. 14 нче ел сугышы башлануга, Ибрай агай[2] икенче чакыруга эләкте. Иртән, аерылып китәр алдыннан, ул, башын селкеп, (гомергә тәмәке тартмаган кеше) тәмәке тартып утыра һәм ара-тирә авыр гына сулап башын селкеп куя:

– Өч бала белән йортны хатын кешегә ташлап кит... Эх! Балалар да ачтан үләрләр, йорт та таралыр...

Йортыннан аерылып киткәндә дә, ул шул ышанмаучылык белән авыр-авыр атлап үлем кырларына китте.

Тагын бер вакыйга.

Безнең авылда Бәкәр (Абубәкәр)[3] агай бар. Ул хатын-кызларны ничектер кеше дип саный алмый. Хатыны авылда иң булдыклы хатын-кызлардан саналса да, базарга яки урман күтәрергә (утын хәзерләргә) китәргә туры килсә, хатынын ике көн алдан үгетләргә, нәрсәләр эшләү, ничек эшләү турында лекция укырга башлый. Бөтен нәрсәне өйрәнгән, бөтен нәрсәнең ничек эшләргә кирәклеген мең мәртәбә әйтеп киткән булса да, урманда утын күтәргәндә тынмый: өйгә барып карарга кирәк-фәлән дип, авылга кайтып килә.

Аны искә алу белән көләсем килә.

Менә залда хатын-кыз авыл председательләре утыралар. Аларга крәстияннәр, бөтен авылның язмышын ышанып, авылны идарә итү эшен тапшырганнар, һәм алар, ирләрдән бер дә калышмый, авылларны идарә итеп киләләр.

Әгәр агайны шушы залга китереп, аларның авылларында эшләгән эшләре турында доклад бирүләрен тыңлатып утыртсаң, нәрсә дияр иде икән ул? Менә:

Әхмәтҗанова Фатыйма[4] иптәш.

Ул Чаллы кантоны Карамалы волосте Рангазар Тамак җәмгыятендә рәисә булып эшли. Бу җәмгыять үзенең эченә поселоклар белән тугыз авылны ала. Шуның өстенә дүрт рус авылы да керә – Фатыйма иптәш шушы авылларның идарәсе башында тора. Аның үткәне бәхетле түгел.

Яшьли ятим калган. Кукаркин[5] дигән помещикта идән юучы булып эшләгән. Батраклыкта йөреп, кул көчен, маңгай тирен биреп тамагын туйдырган. Сугышның, ачлыкның бөтен авырлыгын татыган. Менә шул ишекләр аркылы революция аны җәмәгать тормышына алып килгән һәм волость башкармаларында, бурыч бирү ширкәтләрендә әгъза булып сайланып килгән. 26 нчы елда Рангазар Тамак җәмгыятенең ярдәмләшү комитетында рәисә булып эшләгән, 27 нче елда аны җәмгыятьнең рәисәсе итеп сайлаганнар. 26 нчы елдан партиядә тора.

Ул сөйләгәндә ашкынып тора. Тормыш аны әйбәтләп русча сөйләргә өйрәткән.

Эш турында сөйләгәндә – дәртләнеп сөйли. Аның идарәсе астында булган авылларда налоглар 100 проценты белән үтәлгән. Ярлы крәстияннәр аның һәр эшендә ярдәмләшәләр.

Бары частный сепаратор тотучы кайбер бай крәстияннәр генә аны яратмый. Аның сәбәбе бар. Әхмәтҗанова иптәштән элек авылда председатель булган кеше байлар яклырак булган. Ул ярлылардан, тол хатыннардан налогларның авыр якларын күтәрткән. Кайбер һич налог түләмәскә яки бик аз налог түләргә тиешле кешеләрдән 25 сум налог түләткән булган. Әхмәтҗанова иптәш рәисә булган елны налог мәсьәләләре алдан тикшерелгән. Шуның өчен налогларның авыр ягы тол хатыннарга түгел, бәлки баерак крәстияннәр ягына авышкан. Шуның өчен алар аны яратмыйлар.

Черкас волосте Атияз авылы рәисәсе Залипская иптәш[6] үзенең эшләгән эшләре турында болай сөйли: «25 нче елны – делегатка, 26 нчы елны – авыл советы члены, 27 нче елдан авыл советы рәисәсе булып эшлим. Минем белән хәзерге көндә өч хатын авыл советында член булып эшлиләр. Миңа совет эшенә өйрәнү авыр булмады. Чөнки делегатка, совет члены булып эшләгәндә үк мин совет эшләренә өйрәнеп килдем».

Ул налоглар мәсьәләсендә бик нык тикшереп эшләгән. Ярлыларга мөмкин кадәр льготалар бирдерү ягын караган. Хәзерге көндә крәстиян агайларны күп басуга күчерү юлында эшләп килә. Крәстиян агайлар үзләре бу хакта яхшы фикердәләр.

Минзәлә кантоны Түбән Батыш авылы рәисәсе Рәхилә иптәш Мансурова[7] кызык бер нәрсә сөйли.

Аны авыл советына рәисә итеп сайлагач, крәстиян агайларның күбесе: «Инде хатын-кызлар болай да баш бирмиләр иде. Хәзер инде үз башлыклары да булгач, азып бетәрләр», – дип уйлаганнар. Ләкин Рәхилә апай аларны

«аздырмаган», укуга, аң-белемгә, җәмәгать эшенә тарту юлында гына эшләгән. Крәстиян агайлар, үзләренең ялгышларын аңлап, алай сөйләмиләр икән хәзер.

Рәхилә абыстай җәмәгать эшендә эшли башлау белән уку-язу кирәклекне бик тиз төшенгән. Шуның өстенә, киңәш сорап килгән крәстиян агайларга туры киңәшләр бирү кирәклектән, ул укырга-язарга омтыла башлаган. Хәзерге көндә укый-яза белерлек хәлгә килгән. 26 нчы елда партиягә кандидат булып кергән. «Хатын-кыз башлыгың булса, корыда батып үләрсең» дип йөргән крәстиян агайларны ул әйбәтләп эшкә җигә икән.

Яз башы. Карлар эрү белән, крәстиян агайлар мәңгелек баткаклыклардан бата-чума сукаларга чыга башлыйлар. Рәхилә апай, аларны җыеп, күперләр салу турында киңәшергә булса да, аны тыңламыйлар.

Соңыннан Рәхилә апай иртән таң белән юлларга сакчылар куйдыра һәм:

– Бүген җыенга бармасаң, иртәгә дә, берсекөнгә дә сукаларга чыгармыйбыз, – дип әйттерә.

Крәстиян агайлар, авырсынып булса да, җыенга җыелалар. Ә җыеннан Рәхилә абыстай аларны, көрәкләр, балталар тоттырып, күперләрне төзәтергә алып китә. Соңыннан крәстиян агайлар үзләре дә күперләрдән җырлап йөри башлаганнар.

– Менә хатын башы белән нишләтә! Ир председательләр салдырмаган күперләрне салдыра бит! – диләр.

Болар әле беренче карлыгачлар гына, киләсе сайлауларда аларның саны йөзгә җитәргә тиешле.

## СӨЙЛӘШМИ ТОРГАН ВАГОН ЙӨРТҮЧЕ ҺӘМ ӨЧ ХУЛИГАН БЕЛӘН МИЛЛИ СУДЬЯ ТУРЫНДА

Кояшка бит аңа инструкция биреп булмый. Үзең теләгәнчә эшкә дә кушып булмый. Ул үзенчә. Телисең икән, комга ятып тәнеңне кыздырасың, эссесенә түзә алмыйсың икән, тәнеңне Иделнең йомшак дулкыннары иркенә ташлыйсың. Идел чыгарга теләсәң, йөз әйдә, батырмый. Чыгарга теләмисең икән, рәхәтләнеп бат. Идел өчен барыбер, ул үз эшендә. Сал саласың икән, авырсынмый Әстерханга кадәр алып китә. Сал салмасаң да, барыбер ага, ә ярлары аның кызу ком белән капланган.

Төркстан сахраларында койрыгын күккә күтәреп, берәрсе эләкмәсме дип, үзенә корбан эзләп йөргән чаяннарга охшаган Казан трамвайлары, койрыкларын күтәреп, үзләренең «корбаннарын» Идел ярындагы кызу комга өстериләр.

Алар да эшче Идел кебек үк – теләсәң, ике сәгать трамвай көтәсең дә, утыра алмый, икенче килгәненә сугышып кереп утырып китәсең, теләмисең икән, атаң-бабаң бүләк иткән аякларыңнан ботинкаларыңны саласың да җәяүлисең. Үзеңне бай дип беләсең икән, извозчик яллап, байларча Иделгә китәсең. Казан трамвайлары өчен барыбер. Алар иң элек бер-бер артлы бер кешесез пристаньга тезелеп баралар, тәгәриләр. Анда берәр сәгать утыручылар көтеп, бер-бер артлы бер кешесез эре генә тагын шәһәргә агылалар. Шәһәргә агылганда туры килсәң, бояр булып кайтасың инде. Шул вакытта пристаньга барам дип чыгасың икән, иң элек аларның җырлый-җырлый бер-бер артлы алдыңнан үтүләрен карап каласың. Соңыннан Суконныйдан[1] кайтып килүләрен көтә башлыйсың. Ә трамвайның нәкъ вагон йөртүчесе каршында лозунг эленеп тора: «Вагон йөртүче белән сөйләшергә ярамый».

– Алай икән, – дип, ничек тә туры килсә дә, сөйләшмәскә булып уйлап барасың.

Шулай шул, вагон йөртүче белән сөйләшергә ярамый. Сөйләшеп аның дикъкатен үзеңә алгач, аның юл аркылы үтүче бөтен ачык авыз кешеләрне басып китү ихтималы бар. Зур эш бу вагон йөртүче булу... Әйе, авыр хезмәт.

Бөтен җирдә яз чәчәк ата. Вагонга утырган кешеләрнең рухлары күтәренке, рәхәтләнеп сөйләшеп ял итәргә баралар... Бәхетле халык... Ә вагон йөртүчегә менә сөйләшергә ярамый... Менә аз гына трамвай туктап торган урында вагонның алгы ягыннан эре генә милиционер кереп, вагон йөртүче янына баса. Милиционерга аның белән сөйләшергә ярый торгандыр. Ни булса да, тәртип саклаучы – хөкүмәт кешесе. Ул, вагон йөртүченең ялгызлыгын бүлешер өчен булырга кирәк, сүзгә башлый:

– Көн әйбәт, – ди.

Вагон йөртүче рәхәтләнеп китә һәм шагыйранә табигатьнең матурлыгын сөйләп китә... Ә юлда ялгыш трамвайга арты белән баручы аксаклар, чукраклар звонок бирми барган трамвайдан сыпырттыралар гына... Иртән бары газетаның соңгы битендә трамвай таптаган кешенең исемен-фамилиясен генә басып чыгаралар. Минем, шул хәбәрләрне укыган саен, күз алдыма теге асылып торган язу килеп баса: «Вагон йөртүче белән сөйләшергә ярамый». Артыннан ук башка икенче фикер килә: «Казанда иң күп сөйләшүчеләрнең берсе вагон йөртүчеләрдер, ахры...»

Пристаньга төшкән саен, Иделнең аръягындагы матур агачлыкларга күмелгән комлы урман күренә. Аңар караган саен: «Барса идең дә, шунда, комында кызынып, Иделендә юынып, бәрәңге пешереп, балык тотса идең», – дигән уй йөрәкне кытыклый...

Бары вакыт табарга да Идел аркылы чыгарга гына кирәк. Ә Идел өчен барыбер, чыксаң, көймә белән чыгасың, чыкмасың, карап торасың. Әле урманлык белән быел гына файдалана башланыла. «Динамо»[2] Идел яры урманга чыгып палаткаларын корган. Матур зәңгәр буяуга буяп беседкалар ясаткан. Идел ярына матур капка ясап, ал байракны элеп куйган да – җилферди ал байрак. Ярга, кояш нурларына, кызу комга, Иделнең йомшак күкрәгенә чакыра.

Матур иткәннәр!

Осланга[3] барып, үлән, яшеллек тапмый исереп кайтырга мәҗбүр булган ял итәсе килүчеләр өчен матур, иркен ял итү урыны төзелгән. Гакыллы кешеләр күптән инде аны белеп өлгергәннәр. Аксак трамвайлар белән Идел ярына көчкә килеп җитәләр дә кызу комга, иркен матур Идел яры урманнарына чыгалар.

Якшәмбе көннәрне дүрт күз белән көтеп алган эшчеләр, хезмәткәрләр тәннәрен кызу комга күмеп бер күзләре белән генә күккә карап яталар. Иркен, рәхәт... Шундый рәхәт... Әнә татар журналисты күлмәген салып ташлаган да, трусиктан гына калып, аркасын кояш нурларына ачып куйган:

– Теләсәгез нишләгез, иптәш кояш нурлары, бары артык әрнерлек итеп кызартмагыз гына!

Күпләр шулай иткәннәр... Су да ком, ком да кояш. Кояшта йөзләрчә рәхәтләнеп кызынып ятучылар. Мәдәни ял итүчеләр.

Никадәр куарга теләсәң дә, хулиган әфәнде әле бездән калмый йөри. Ул, үзенең бутылкасын күтәреп, «Динамо» бакчасына да килгән. Ярда комда кызынып яткан, трусиктан гына калган хатын-кызларга кызарган борыны аркылы карап ыржая. Шешенеп эренләгән күзләрен майлатып, эчүдән тутыккан, кабахәтлеге белән мәшһүр телен чыгара.

– Син ни өчен чит хатыннарга кабахәт сүзләр белән кулыңны сузасың, тибеп китәсең?

– Кем, минме... Кит, ...ләт!

Тавыш күтәрелә. Кәләпүшен кыңгыр салган кызыл борынлы татар хулиганы үзенең гайрәтен йодрыкларына чыгара. Аның канаты астында ава-түнә барган сары чәчле, пешеккән күзле кызурак куллы хулиганы якага кул суза:

– Безме? Ах син...

Өч хулиган Идел урманнарын яңгыраталар.

– Әйдәгез милициягә!

– Пашул к ...!

«Динамо»дан эзләп йөрүчеләр бер милиционер да тапмыйлар. Ләкин ярдәмгә «Динамо»ның комсомоллары киләләр. Аларны протокол язарга чакыралар.

– Китегез! Ми ничава низнам!

Тартыш башлана. Халык җыела. Эчеп-исереп тынычлык бозып йөргән башка Печән базар агай-энеләре килеп кушылалар. Бу хулиганнар ярты русча, ярты татарча сүгенә торгач, аларны яклаучы, русча яхшы сөйли белүче уртага килеп чыга.

Ул комсомоллар кулыннан хулиганнарны тартып алып җибәрә дә, исерек авызыннан төкерекләрен чәчә-чәчә, мөселман агай-энеләргә мәдәни гайрәтен күрсәтә.

– Я сам закунник, пропустите, знаю я их. Бу – Татреспублика. Без – татарлар. Монда чыгып татарларны обижать итәргә бирмәбез!

Егет, теге хулиганнарның рәнҗеткән кешеләренең үзләренең татар булуларын белгәч:

– Руска чукынган татарлар, – ди. Соңыннан хулиганнар тарафыннан рәнҗетелгән хатынга берничә кабахәт сүз ялгый, хулиганлык ыржаюын күрсәтә.

– Кем ул хулиганнарны яклаучы закунник?

Сораша торгач, аның кемлеге беленә.

Ул дүртенче участканың Ф. дигән милләтче судьясы булып чыга. Прокуратура бүлеге, аның милли хисләренә анализ ясап, аңардан үзенең өч дустының фамилиясен әйттерә.

Ә Иделгә барыбер. Су керсәләр дә, кермәсәләр дә, талашсалар да.

Кояш та ерактан, Усия урманнарыннан[4] томанланып күренеп торган Казан шәһәренең биек йортларының түбәләрен ялтырата-ялтырата батарга якынлый.

Ә бит урманлы ярларны тагын да матуррак ял урыны итү өчен, берничә милиционер куеп, мәдәни ялга каршы көрәшүчеләргә көрәш ачасы иде.

**САГЫНЫЛГАН ҖИРЛӘРДӘ**

**Таң чәчәкләре**

Чәчәкләр кояшка карап көләргә тырышалар, таң суыгы туңдырган аларны. Канатларын чыкларга чылаткан.

Каеннар бәхетле алар, алар зур итеп үсә алганнар, аларны бернәрсә дә кояштан каплый алмый. Алар кояшның күзенә туры карый алалар, бәхетле каеннар...

Каен яфракларында көмешләнгән кояш нурлары урман чәчәкләренең канатларына тамган чыкларны киптереп өлгермәгән, бары юл кырыйларындагы чирәмнәрдә үскән ялан чәчәкләре генә җылынып өлгергәннәр. Алар инде кояшка карыйлар да күзләрен кысалар...

Ә кояш киң кырларга, чиксез яланнарга үзенең җылы канатларын җәя.

Поезд Кирсановка урманнарын ярып түбәнгә – җылы якка тәгәри.

Чәчәкләр янында каласы килә... Яшел чирәмнәрдә ауныйсы, сагынылган Тамбов урманнары күкрәгендә үскән зифа каеннарның[1] ботакларына асылып каласы, бик озакка каласы килә.

Минем вагондагы күрше ни уйлый торгандыр. Ул инде йокысыннан торганнан бирле күзләрен тәрәзәдән ала алмый, урманнарга карый. Бәлки, аның моннан бик еракта туган авылы бардыр, каенсарлы урман белән уралгандыр. Нәни чакларны, атларның муеннарына кыңгыраулар тагып, урман яланнарына атлар көтәргә йөргәннәрдер.

Шулай булса, бәхетсез минем күрше. Аны урманнардан аерганнар, күрәсең.

**Алар үскәннәр инде**

– Ни өчен түбән төшмисез?

Җавап бирү урынында дусларча елмаялар.

Аларга төшәргә ярамый шул. Алар вагонның, очында югары нәрсә куя торган бер җиргә менеп, бөгелеп, кара-каршы утырганнар да, үтенеп-нитеп йөргән проводникның түбәсенә карыйлар. Ә проводник аларны күрми.

– Уңайсыздыр анда?

– Бик әйбәт!

– Ләкин син, абый, проводникка әйтмә.

– Һичбер вакытта.

Авыр елларда имәсе сөтләрен имә алмый салкын урамнарга ташланган ике дус елмаеп миңа карый. Алар үскәннәр инде. Соң мин аларның яшеренеп баруларын проводникка әйтә аламмы? Тик кая барасыз сез, нәни юлчылар? Алдагы шәһәрләрдә сезне ана кочагы, җылы түшәк көтә дип уйлыйсызмы сез?

**Матурлык нәрсә?**

Минский мине күптән инде Әстерханда көтә. Аңар юлга чыгуым турында телеграмма да суктым. Әстерханга баргач, без Минский белән зур бер әдәби кичә оештырырга тиешбез. Бу әле бездә яңа эш. Бару белән миңа «Көрәшнең матурлыгы һәм аның җырчылары» турында доклад укырга туры киләчәк.

– Соң нәрсә ул матурлык? – Шул хакта башка җыелган фикерләр чуалалар.

– Һәрбер файдалы нәрсә матур.

Әйе.

Һәрбер маңлай тире, йөрәк каны, мең еллар буенча көрәш нәтиҗәсендә туган һәрбер файдалы нәрсә матур! Мин үземне киң урманнар, яшел басулар аркылы ыргылып алга өстерәгән поездның матурлыгы турында уйларга тырышам. Соң ни өчен хәзергә кадәр кешелекнең тудырган даһи җырчылары шушы бөек хезмәт тудырган матурлыклар турында җырламаганнар? Ни өчен матурлыкны хатын-кыз күзеннән, табигый яратылыштан гына эзләгәннәр алар?.. Экономика матурлыкка булган карашны үзгәртә бара. Кичәге матурлар үлде. Иртән аның яңасы туар.

**Эчмә, җанкисәгем Василий!**

Тамбов урманнары ерак калды. Күреп үткән каеннарның яфраклары бүген дә кояш нурларында көмешләнә торганнардыр.

Мин Саратов станциясенең беренче классында утырам. Әстерхан поезды тиз килмәс, зарыктырыр төсле. Поездда иптәш булып килгән кешеләр Саратовта таралып беттеләр.

Поезддан яңа гына килеп төшкән юлчылар өстәлләрне тутырып чәй эчеп утыралар.

Минем каршымда әллә кем – нindидер матур тойгыларын яшерә алмаган йөрәк – залны яңгыратып җырлап җибәрә:

Ванька-ключник – злой разлучник,
Разлучил князя с женой...

Залның күзе җырлаучыга текәлә.

Ул егерме сигез яшьләрендә, зәңгәр күзле, матур очлы борынлы, йөзе нindидер йөрәккә якын сызыклар белән капланган. Ул исереп өлгермәгән. Аның йөзендә исереклекнең бер сызыгы да юк. Ул гүя бары йөрәгендәге ташкын тойгыларын йөрәк көче белән тота алмаганнан гына шулай җырлап җибәргән. Давыллы йөрәккә охшый ул. Мин аның күзенә карыйм. Ул үзенең сөйкемле зәңгәр күзләре белән карый да елмаеп күзен кыса һәм, әллә кайчангы дус кебек, миңа үзенең стаканын суза.

Аның давыллы йөрәге җырын бүлешер өчен дуслар эзли, күрәсең.

Тавыш ишетеп, янына килгән ГПУ[2] агентлары аны култыклап залдан алып китәләр. Ә Василий, җырлый-җырлый, аны гүя дуслары култыклап алгандай чыгып бара.

«Ванька-ключник»ны ул бөтен станция буенча җырлап бара. Василий шул станциянең данлы грузчигы икән. Ул үзен грузчиклардан гына түгел, бөтен станция кешеләре тарафыннан яраттыра алган.

Аны тагын очратырмынмы?

Йөрәкне авыр уйлар чолгый. Караңгы уйлар күз алдын томаландыра. Мин Казанда «кунучылар йорты»нда булган идем. Анда чәчләре агарган, йөзләре авыр әрнүле уйлар сызыгы белән кискәләнгән өч-дүрт кешене очрата идем. Аларның берсе элек булдыклы эшчеләрдән булган. Үзенә ничектер эчүчеләрне дус иткән. Соңыннан туктый алмаслык эчкече булып киткән. Ул да Василий кебек зәңгәр күзле. Хәзер урамнарда: «Бер шешәгә тулмый», – дип, очраган берәүгә бәйләнеп йөри. Аның йөзендә элекке булдыклы көннәрнең сызыклары бар әле. Нинди киләчәк аны көтә?..

Йөрәгендә табигый шатлыгы булмаган кешеләр генә эчәләр. Алар, үзләрен агулап, сүнгән йөрәкләрендә шатлык уятырга тырышалар.

– Синең кулларың көчле, елмайган йөзләреңдә караңгы йөзләрне яктыртырлык шатлык аңкый.

– Матур җырларыңны эчми җырла. Киләчәгеңне уйлау мине авыр уйларга төшерә.

– Эчмә, җанкисәгем Василий!

**Чәчәк кебек матур дуңгызлар**

Ах, җир! Ах, җир,
Синең матурлыгың
Шундый тигез итеп таралган,
Һәр дуңгызың, һәрбер песи кызың
Чәчәк кебек матур яралган.

Алай ук түгел түгелен дә, мин Казаннан киткәндә шундыйрак бер шигырь язып, «Авыл яшьләре» журналына биреп киткән идем[3].

Хәзер алай түгеллегенә ышанам инде.

Саратовтан Идел аркылы Покровский станциясенә чыктым.

Моннан Әстерхан поезды китәчәк.

Поездны Иделнең ярына ук китереп туктаттылар. Без утыру белән, поезд акрын гына Покровский станциясенә тартылды.

Станциягә җитү белән, вагоннарда шау-шу башланды. Тәрәзәдән Иделне рәхәтләнеп карап килгән минем күршем ашыгып-ашыгып тәрәзәне яба башлады. Мин нәрсә булуын уйлап өлгерә алмадым, вагон тәрәзәсеннән килеп кергән кабахәт исле газдан буыла башладым. Вагоннарда тавыш купты. Кемнәрдер станция начальнигын сүгә башладылар. Мин тәрәзәдән карадым. Безнең вагоннар белән беррәттән чәчәк кебек матур дуңгызлар төягән иллеләп вагон туктаган. Алардан чыккан ис бөтен станцияне каплап алган. Булдыксыз станция начальнигы, аларны станциядән ераграк бер җиргә туктату турында уйлый алмаган, күрәсең.

Поезд кузгалды, караңгылыкны ярып, Әстерхан кырларына тәгәрәде. Идел безне тыныч килеш озатып калды.

Бәхетле Идел!

Синең өстең давыллы көннәрдә генә дулкынлана, давыл үтү белән, ул тагын да тын кала. Ә безнең йөрәкләрдән давыл үтсә, йөздә югалмаслык булып сызылып эз кала.

.....................................

Кичә Әстерханда язучыларны каршылау кичәсе булды. Анда безгә доклад белән һәм хикәяләр, шигырьләр белән чыгарга туры килде... Безне каршыларга килүче Әстерхан зыялылары аз иде.

.....................................

Әстерхан зыялылары безне каршыламады. Әстерханның укытучылары әдәбият белән кызыксыныр дип уйлаган идек. Булмады. Бүген Тияк районында эшчеләр өчен безнең зур әдәби кичә[4] булачак. Иртәдән кичкә кадәр кассага билетка киләләр. Билетлар җитмәс, кеше күп булыр, диләр. Эшче районының безне кызыксынып каршылавы күңелне күтәрә. Эшчеләр алар инде бөтен мәдәни байлыкны (шигырьне дә, әдәбиятны да) үзенеке итеп хис итү дәрәҗәсенә үсте. Бу безнең өчен зур җиңү.

Без Әстерхан эшчеләренә үзебезнең җырларыбызны җырларга, аларга үз булган әдәбият белән таныштырырга килгән идек.

Эшчеләрнең алдынгы активларыннан иптәш Ишираев, Рәхмәтуллин, Вальшин, Измайлов[5] иптәшләр безне урап алганнар. Аларның күз карашлары йөрәккә җылылык бирә.

**Балыксыз Идел**

Кичә дуслык төсендә үтте. Безнең кичәгә катнашкан иптәшләргә зур рәхмәтләр булсын. Кичә үтү белән, төнге сәгать өчләрдә моторлы көймәдә эшче активлар безне сазан тотарга алып киттеләр.

Минем янга утырган иптәш Ишираев миңа балыкчылар турында сөйләп бара...

Таң якын.

Идел тармаклары белән кочакланган Әстерхан тынып йоклый. Көндез Идел күкрәгендә тавышланып йөргән мотор көймәләре җансызланганнар. Ярларга килеп борыннары белән терәлгән, җилкәннәре күтәрелгән көймәләр ярда йоклап таңны көтеп калган ак казларга охшыйлар. Менә борынгы Нобель заводы[6]. Ул хәзер Ленин заводы булып исемләнгән. Зур канаулар күтәрелеп, уралып алынган эшчеләрнең йортлары Идел суыннан түбән калганнар, шушы валларны көрәк белән әз генә казып су җибәрсәң, ул йортлар су астында калачаклар.

Идел тын.

Безнең мотор көймәсе ярга килеп туктый. Иптәшләр ярга чыгалар... Мин, кармак алып, Идел ярына йөгерәм.

– Әстерхан ул – балыкка иң бай җир.

– Әстерханга диңгездән көтү-көтү балык керә, – ди иптәш Ишираев.

Мин, ярга утырып, беләк озынлыгы зур сазанның кабуын көтәм...

________

Әстерханда бер сазан да тотып булмады. Юкка Әстерханны балыклы дип мактыйлар.

Шулай да сау бул, Әстерхан! Сау булыгыз, СССРның төрле җиреннән җыелган Идел балалары – дәртле балыкчылар!

**Мәхәббәт һәм катык, иркәләнәсе килгән инженер**

«Ермак» пароходы[7] безне Казанга алып кайта. Безнең белән пароходта кайтучы иптәшләрдән берәү, пароходка утыру белән, шунда баручы бер инженер кызына гашыйк булды.

Ул пристаньга төшеп катык алып менә дә, ашап бетергәннән соң, палубага чыгып, инженер кызы белән мәхәббәт тәсбихы тартып бара[8].

Ә инженер күңелсез. Миңа ул үзенең тойгыларын сөйләп бара. Самокритика мәсьәләсен ул төшенеп бетми.

– Тәнкыйть итәр өчен, иң элек массаны тәнкыйть итәр дәрәҗәдә тәрбияләү кирәк, – ди.

– Мин – Нобель заводының инженеры. Түбәннән, пароходта идән юучы малай булып йөрүдән башлап, укып, соңыннан инженер булган кеше. Бөтен көчемне куеп эшлим. Минем шәхси тормышым да юк. Илле яшемдә туберкулез алуым моңа шаһит булырлык. Ләкин...

Мин аның йөзенә карыйм. Зәңгәр күзләре алдамый кебек. Алар «Дөрестән дә шулай» дигән кебек моңлы карыйлар.

– Ләкин... кеше ул йомшак бит. Без картлар инде. Борынгы хуҗаларда эшләгән кешеләр. Алар үзләренә кирәк кешенең бөтен көчен суырып ала беләләр иде. Алар кешенең йомшак кылларын тарта беләләр, йомшак телләләр

иде. Мин ул кабахәтләрне сагынмыйм. Көннәр буенча бирелеп эшлим, ләкин кеше йомшак. Аның җылы сүз ишетәсе килә. Минем алган жалованием дә җитәрлек. Бары эшләнгән эшең өчен җылы сүз ишетәсе килә.

– Шулай гына микән?

Мин үзем дә «иркә кеше». Инженерның йөрәген аңлыйм. Аны Советлар Союзы исеменнән иркәләргә тырышам. Дөрестән дә, ул җанланган кебек була. Ашыгып-ашыгып, беренче баркас ясалып беткәч тә, үзенең ничек шатланганын сөйләргә башлый:

– Балаң кебек. Тирәсендә күзем туймый карап йөрим. Әллә ничек, үзеңнең беренче балаң кебек, – ди.

«Көрәшнең матурлыгы, аның җырчылары»[9] – мин шул хакта Әстерханда доклад укыдым.

Күкрәкне авыр бер уй чолгый. Шул матурлыкны без җырлаганыбыз бармы? Әле караңгы.

Үле заводларны СССР эшчеләре җанландырдылар.

Аларның кара төтеннәре күкләрне каплый хәзер. Без шушы авыр көрәшнең тудырган матурлыгын җырлаганыбыз бармы? Аларны тергезүчеләрнең йөрәк тавышлары безнең җырларыбызда ишетеләме?

– Белмим.

Ләкин эшчеләргә барып, үзебезнең җырларыбызны укуга кадәр алар арасына кереп, алар тудырган матурлыкның тойгылары белән йөрәкләребезне тутырырга, тәрбияләргә тиешбез.

## КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ БӘЙРӘМ

Без үзебезнең бәйрәмнәребездә уңышлыкларыбызны күздән кичерәбез. Уңышсыз якларны тикшереп, киләчәккә уңышлы юллар хәзерлибез. Безнең бәйрәмнәр шуның белән дан алган.

Августта «Азат хатын»[1] журналының ике еллык бәйрәме була. «Азат хатын»га ике яшь тула.

Ни өчен без аны бәйрәм итәбез?

### Укучылар турында

Татар эшче-крәстиян хатын-кызларын без газета-журнал укырга өйрәнгән, чыныккан дип әйтә алмыйбыз. Революциягә кадәр эшче-крәстиян хатын-кызлары газета-журналның исемен дә ишеткәннәре юк иде. Хатын-кызлар гына түгел, татар эшче крәстияннәре арасыннан да газета укучыларны очрату авыр иде. Сәбәбе бик ачык. Ул вакыттагы газета-журналларда эшче, крәстиян өчен кызыгырлык әйберләр, аларның файдасын күзәткән нәрсәләр юк иде.

Соң хәзер ни өчен «Крәстиян гәзите»н[2] 18 мең крәстиян укый?

Чөнки һәрбер крәстиян аның битләрендә үзенә иң кирәк булган нәрсәләрне таба.

Совет хөкүмәте бөтен көче белән крәстияннең авыр тормышын яхшыртырга, үзе өчен дә, хөкүмәт өчен дә файдалы булган бер юлга куярга, крәстияннең караңгы тормышын яңа, якты нигезгә корырга тырыша.

Совет хөкүмәтен үз итеп белгән крәстиян газета укый. Газета аңа яңача тормыш корырга булышлык, юлбашчылык итә.

Сәрби апа да «Азат хатын» журналын 5 нче номердан алып укып килә. Ни өчен? Чөнки Сәрби апа үзенә кирәк нәрсәләрне журналдан таба ала.

Ике еллык «Азат хатын» журналының чыккан номерларын тикшереп чыксак, без түбәндәге нәрсәләр турында язылганны күрәбез:

1 – Совет законында хатынның хокукы. Бу хакта журнал 10 зур мәкалә биргән.

2 – Авыл хуҗалыгын яңача кору, яхшылату турында 16 мәкалә.

3 – Аналарда, балаларда була торган авырулар, аналарның һәм балаларның сәламәтлекләрен саклау, балаларны фән кушканча тәрбияләү юллары турында барлыгы 48 зур мәкалә язылган. Монда бала тәрбиясен әбиләрдән генә ишетеп килгән хатын-кызларга әллә күпме белем бирелгән. Әллә никадәр бала тәрбиясендә очрый торган авырлыкларны җиңеләйтү юллары күрсәтелгән.

Хатын-кызларны җәмәгать эшенә тарту, аларның бу эштәге көндәлек бурычлары, хатын-кызны сәяси тәрбияләү юллары турында журналда 49 мәкалә басылган.

Хатын-кызны әртилләргә оештыру һәм оешкан әртилләр турында 5 мәкалә.

Гаиләне яңа нигезгә кору, хатын-кызны икътисади коллыктан, чүлмәк-чиләктән азат итү, гомуми эшкә, ашханәләргә күчү, хатын-кызларны кооперация тирәсенә оештыру турында 11 мәкалә язылган.

Капитал илләрендәге хатын-кызларның тормышларын ачып салган 20 мәкалә, СССРдагы татар хатын-кызларының көнкүрешләре, яңалык өчен көрәшләре турында язылган 53 заметка кергән.

Журналда делегаткаларны эшкә өйрәтү юлы белән 7 мәкалә, җәмәгать эшенә тартылган хатын-кызларның эшләүләре, аларның практикада ирешкән уңышлыклары турында 15 мәкалә, төрле почмаклар, түгәрәкләр турында – 5, хатын-кызның сәяси азатлык юлындагы көрәш тарихыннан 8 мәкалә, хатын-кыз һәм профсоюзлар, МОПР[3] һәм хатын-кыз, дин һәм хатыннар турында җиде-сигез мәкалә журнал битенә кергән. Доктор киңәшләре, крәстияннәрнең сорауларына җаваплар урынында 31 заметка, төрле социальный авырулар турында 3 зур мәкалә кергән.

Татар хатын-кызларын кул һөнәренә өйрәтү юлы белән 6 мәкалә һәм үрнәкләр бирелгән. Өй эшләре, йортны алып бару турында 11 мәкалә, хатын-кызны төрле аш-су пешерергә өйрәткән 23 заметка кергән.

Саклык кассалары, үзара ярдәмләшү комитетлары турында киң мәгълүмат бирелгән берничә мәкалә бар.

Кызыклы фәнни бүлеккә 57 төрле заметка кергән. Хатын-кызны сәяси, хокукый тәрбияләү, аларга юл күрсәтү нигезендә 35 хикәя, 51 шигырь кергән, журналның ике ел эчендә чыккан 30 лап номерында төрле мәгълүматлар белән тулы башка егермегә якын мәкалә кергән.

Өстән генә алганда, журнал үзенең ике еллык гомерендә хатын-кызның тормышын җиңеләйтү, аларга азмы-күпме булышлык итү, аларны сәяси тәрбияләү юлында киң күләмдә эшләп килгәне күренә. Нәтиҗәдә газета-журналның ни икәнен белмәгән авыл хатын-кызлары хәзерге көндә «Азат хатын»ны укып бару гына түгел, аның битләренә язышып киләләр. Журнал битләрендә ике ел эчендә йөздән артык төрле хатын-кыз имзасы кергән. Бу нәрсәне, билгеле, күп дип булмый. Ләкин журналның айлык, соңыннан ике атналык булуын, шулай ук кайбер аерым отделларны специалистлар алып баруны искә алганда, бу сан канәгатьләнерлек.

Шулай да киләчәктә бөтен көч белән журналга язышучылар санын хатын-кыздан күбәйтүне алга сөрергә кирәк.

Кайбер кантоннарда яхшы гына сәяси белемле хатын-кыз эшчеләр бар. Ләкин шул кантондагы хатын-кызлар тормышыннан шундагы ирләр язып торалар.

Бу иптәшләр журналга язышуны үзләренең бурычлары итеп белсеннәр. Кооперация, әртилләр һәм башка төрле нәрсәләр турында язарлык белемле хатын-кызларыбыз да ничектер язудан читтәрәк күренәләр.

Журналның ике еллык номерларын карап чыкканда, түбәндәге бүлекләрне киңәйтергә кирәк дип беләм. Бездә, Татарстанда, күп кенә бергәлек хуҗалыклар бар. Аларның күбесе хәзерге көндә үрнәк булырлык рәвештә эшләп киләләр. Шул хуҗалыкларның эшләү юллары, андагы хатын-кызларның тормышлары турында зур-зур гына материаллар бирү кирәк иде. Журналда әлегә кадәр мондый материаллар күренгәне юк. Бу материалны, билгеле, урыннарда хатын-кыз каләм көчләре бирергә тиешләр.

Безнең күп кенә хатын-кызларыбыз җәмәгать эшендә эшлиләр. Аларның ничек эшләүләре, нинди авырлыклар белән көрәшергә туры килүләре турында практик материаллар журналда бар. Бу иптәшләр үзләренең эшләү юллары белән укучыларны таныштырып барсалар, башка җәмәгать эшенә күтәрелеп килә торган иптәшләренә күп кенә ярдәмнәр иткән булырлар иде. Бюрократизм, түрәлек йә башка кимчелекләр турында урыннардан язучылар күренми. Журнал битләрендәге килгән хәбәрләрне караганда, күбрәк аерым гаилә хәлләренә багланганрак хәбәрләр килә. Шуның өчен ул хәбәрләрнең күбесе басылмый да. Бу бүлек шул югарыда күрсәтелгән бюрократизм, советлардагы, кооперативлардагы кимчелекләр, җәмәгать тормышының яхшы һәм яман якларына юнәлтелгән хәбәрләр белән бизәлергә тиешле.

Яңа тормыш мәсьәләсе турында да журналда материал бик аз бирелә. Бу бүлектә кайбер мәсьәләләрне дискуссия рәвешендә алып бару да яхшы нәтиҗәләр бирер иде. Шуның белән бергә кайбер мәсьәләләрне журнал битендә куеп, шуның эшкә ашырылу тәҗрибәләрен язып бару да зур адымнар атларга сәбәп булыр иде. Мәсәлән, журналны укучы авыл хатыннары арасында күмәк икмәк пешерү яки күмәк кер юу кампаниясен уздырырга. Журналны укучы авыл хатыннары арасында шуны тәҗрибә ясап карарга өндәргә, тәҗрибә юлларын күрсәтеп язарга, соңыннан шуның нәтиҗәсен журналда язып, бу юлда булган каршылыкларны журнал битендә бергәләп хәл итүне куярга кирәк.

Бу мисал өчен генә алына. Журналда бик күп нәрсәләрне тәҗрибә белән бәйләп кампанияләр уздыру мөмкин. Бу, бер яктан, журналның эшен тәҗрибә белән бәйләсә, икенче яктан, журналны җанландырачак. Укучылар белән журнал өзелмәслек булып бәйләнеп барачак. Без хәзер алай эшләргә, болай эшләргә кирәк дигәндәй, мәкалә язудан бигрәк менә бу нәрсәне эшләп карыйк, ничек булыр дигән рәвештә бергәлек тәҗрибәгә күчәргә кирәк. Бу юлда белемле хатын-кызларның көчләреннән файдаланырга кирәк булыр. Авыл хуҗалыгы материалларын биргәндә, «сыерны болай ашату, тегеләй карау файдалы» дигәннән, «сыерларыгызны тәртипле ашату тәҗрибәсен ясап, нәтиҗәсен безгә языгыз» рәвешендә «кем сыерын тәртипле ашатуга күчерде?» дигән кампания уздырырга кирәк.

Журналда вәкиләләр җыелышы турында материал аз бирелә.

Моны да «кайсы вәкиләләр җыелышы уңышлы эш алып бара, кай җирдә вәкиләләр күбрәк җәмәгать эшенә катнаша» рәвешендә куеп, күбрәк материаллар кертергә кирәк.

Дин һәм хатын-кыз турында журналга материаллар бик аз кергән. Бу турыда да язылася әйберләр бар. Монда кайбер хәбәрләрне алып файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, журналда берничә хатын-кыз белән шаяручы муллалар турында хәбәрләр басылды, шул хәбәрләрне алып «дин-мулла һәм хатын-кыз» темасына дискуссия уздырырга мөмкин. Муллалар зинаны, аракыны хәрам диләр. Үзләре эшләп йөриләр. Ни өчен? Менә монда күп кенә сөйлисе сүзләр бар.

Профсоюз һәм хатын-кыз турында да аз язылды. Бу кампанияне дә журналда уздырырга ярый. Журналның башка бүлекләре тулы бара. Ләкин ул бүлекләрдә язылган нәрсәләр урыннарда эшләнеп күреләме, нәтиҗәсе билгесез булып кала бара.

Киләчәктә журналны шул юл белән алып барырга тырышылачак.

Ләкин бу нәрсәне эшләү урыннардан язучы селькоркалар, рабкоркаларның киң ярдәме белән генә мөмкин.

Моның өчен «Азат хатын» журналы үзенең ике еллык бәйрәмендә үзенә язышучыларның киңәшмәсен уздыру белән җанландыра алыр иде.

Журналны җанландыру өчен бу киңәшмәне көзгә җыярга, алар белән күп кенә нәрсәләрне аңлашырга кирәк булыр.

Киләсе номерда журнал турында фикер алышу бүлеге ачыла[4]. Урыннардан иптәшләр, билгеле, монда ныклап катнашырлар.

## СӨЙКЕМЛЕ КЕШЕ

Нинди тавык каргышы төшкән ана тудырганда үземне? Үз башыма үзем бәла булып туганмын. Туган сәгатемдә мунча күселәре, ике ботымнан ләүкә астына өстерәп кереп, борынымны чәйнәп үтергән булсалар иде, мондый бәлаләргә очрамаган булыр идем.

Миннән дә бәхетсез, миннән дә тиле кеше дөньяда юк. Сез минем хәлемнең нинди начар булуын бары үз башыгызга төшкәндә генә белә алыр идегез. Туып, аякка басып йөри башлаганнан алып җәфа чигәм. Бер генә көн тамагым туйганы юк. Бер көн генә булсын үзем өчен торганым, үз эшемне эшләргә вакыт тапканым юк. Эләктереп алалар да:

– Габдулла ул әйбәт, сөйкемле егет! – диләр. Мактарга тотыналар. Аның белән генә калсалар, кулларын үбәр идем. Ләкин алар мактауларының койрыгына икенче нәрсә ялгыйлар:

– Син, Габдулла, уңган егет, печәнең чабылып бетә торгандыр инде. Без менә соңга калдык, бераз безгә булышмассыңмы? – диләр.

Яхшы кеше булгач, ничек булышмассың? Көннәр буенча шул кабахәт мактау сүзе өчен азмы кеше печәне чабарга, азмы йомшак телләргә сукалашырга туры килмәде.

– Тиле, тиле! Нигә син үз эшеңне эшләми кеше эшен эшләп йөрисең? – дип, әткәй мәрхүмнән азмы кыйналу-сүгелүләр башымнан уздылар.

Барына да түздем. Инде түзәрлегем калмады.

Үткәннәрне санап та тормыйм. Казанга килеп, матур гына, йомшак кына күңелле бер кызга өйләнеп, тормыш төзи башлаган идем. Ике кешегә рәхәтләнеп торырга җитәрлек жалуниям дә килеп тора иде. Хатыным да үземне яратып, иркәләп кенә тора башлаган иде.

Тыныч торырга ирек бирмәделәр. Бүрек салып исәнләшеп йөрергә җыен яланаяк шалапай, ач Казан кочыклары тирәмне урадылар да алдылар. Киләләр дә:

– Син, Габдулла абый, әллә ничек күңелгә якын кеше. Беркемгә дә барасы килми. Синең белән утырып сөйләшәсе килә. Гаҗәп күңелле семьяга охшыйсыз сез, – диләр.

Хатын да минем табигатьлерәк кеше булып чыкты. Чәй әзерли, аш пешерә, сыйлый башлый. Жалуния алуга биш-алты көн тулмый, чалбарны чыгарып сатарга туры килә.

Соңга табан торырга мөмкин булмый башлады. Обедка утырырга өлгермисең, бер көтү җыелып киләләр дә, әзерләгән ашны ашап, үзеңне мактый-мактый, төн буе шайтан туе торгызып, мандолин уйнап кичке чәйне көтеп утыра башладылар. Үзләре үзләре әле, соңга таба:

– Габдулла абзый, бу минем якын иптәшем, яңа Казанга килеп төште. Син яхшы кеше бит, зинһар, берәр көн син үзен кунак ит! – дип, бөтенләй миңа таныш булмаган ниндидер үзләренең иптәшләрен дә запискалар белән җибәрә башладылар.

Беркөнне шундый сыбызгының берсен җибәргән идем, өч көн торасы урынга бөтенләй семьяның члены булды да китте. Үзе мине мактый, үзе хатынны ухаживать итә.

– Габдулла абзый яхшы кеше ул, көнләшми, – дип, киендереп хатынны театрларга йөртә башлый... Соңыннан: – Габдулла абзый ул киң күңелле кеше, – дип, хатынны күз алдымда кочаклап та утыргалый башлады. Иң соңыннан ияртеп тә алып китте.

Башта кайда эшләгәнемне белми йөргән жуликлар, минем Казанның бер читендәге кибеттә мөдир булып эшләвемне белгәч, дөньяларын онытып шатландылар.

– Әй, Габдулла абзый, син монда эшлисеңмени? Менә әйбәт, ә без белми дә йөрибез. Бүген әле акчасыз көн, син инде миңа бер биш сумлык әйбер җибәрергә карышмассың бит. Син сөйкемле, вежливый кеше, – дип, рөхсәтемне алырга өлгерми, приказчиклардан әйбер ала башладылар.

Ике ай үтми, алар өчен жалуниямне алмый урынымнан чыгарга туры килде. Әйтегез, зинһар, кай каргалган җиремдә минем сөйкемлелегемне кычкырып торган сызыклар бар. Тавык йомыркасы кадәр зур күзләремдәме, борынымдамы, шадра йөземдәме?.. Ай инде эшсез йөрим. Таныш түгелләргә түгел, танышларга да йөзне күрсәтмәскә тырышам. Ләкин... сәгать бердә миңа бер җирдә урын вәгъдә иттеләр. Шунда барганда, бара торган кибет дип ялгышып, мин керергә тиешле кибетнең күршесенә барып кергәнмен. Ниндидер алаша кадәр сәүдәгәр хатыны эләктерде дә алды бит.

– Сөйкемле кеше, милый человек, мин иремә брюкалык алырга теләгән идем. Син миңа булышлык итмәссеңме икән?– диде.

Мин ихтыярсыз аның янына бардым.

– Бусымы әйбәтрәк икән, бусымы? Минемчә, бусын карыйк. Әнә тегендә полкадагы серый төс, синеңчә, брюкага килешәме? Ой, ямьсез икән. Сез ничек уйлыйсыз?.. – Фәлән-төгән дип сайлый-сайлый сәгать ярым үткән. Мин кибеттән чыкканда инде өченче биш минут киткән иде. Барып керүгә, кичегүем сәбәпле, урыннан колак кактым.

Нинди тавык каргышы төшкән ана тудырганда үземне? Бөтен шалапайга мине сөйкемле итеп күргәзүче күзләремдер, ахры, дип сүгенеп, ике күземне икесен дә чыгарырдай булып ачуланып чыгып барадыр идем, кемдер кулымнан тартты.

– Сөйкемле гражданин, мине урам аркылы чыгарып җибәр, зинһар, – диде.

Әйләнеп карасам, ике күзе дә сукыр кеше булып чыкты. Димәк, минем сөйкемлелегемне белдереп торучы күзләрем дә түгел. Соң нәрсә? Соң нинди каһәр суккан нәрсә? Сукырны чыгару белән, зур-зур атлап, инде моннан соң берәүнең сүзен дә тыңламыйм дип ачуланып барадыр идем, берәү йөгереп килде дә:

– Сөйкемле иптәш, минем тәгәрмәчем төште бит, ашыгам, йөкне бушатмый гына күтәреп тәгәрмәчне кидерергә ярдәм итмәссеңме? – диде.

Минем күзләр шартлар дәрәҗәгә җитте. Үземне-үзем белми, бөтен урамны яңгыратып:

– Мин сөйкемле кеше түгел, мин – жулик, мин – карак, мин – кеше үтерүче, мин – разбойник, мин сөйкемле кеше түгел! – дип кычкыра башладым.

Ике милиционер мине җитәкләп участокка алып киттеләр. Хәзер следовательләр көн дә килеп: «Син кем?» – дип сорыйлар.

– Мин – карак, мин – жулик. Мин әтәч үтердем. Мин тавыкларны таладым. Бер сәгатьтә йөз егерме кеше суйдым, – дип җавап бирдем.

Следовательләр:

– Ялганлыйсың, син һич кеше үтерүчегә охшамагансың. Син болай ни өчендер... син бик сөйкемле кеше, – дип, мине төрмәдән чыгарырга телиләр.

Юк, хәзер, үтерсәләр дә, төрмәдән чыкмыйм.

## ЯЗЫШУЧЫЛАРЫБЫЗ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Без журналыбызның ике еллык бәйрәмен уздырабыз. Үткән номер журналда журналның ике еллыгына карата мәкаләләр[1] булган иде. Без бу номерыбызда журналга язышучыларыбыз белән кайбер мәсьәләләр турында сөйләшеп үтәргә уйлыйбыз.

Безнең журналга язышучыларыбызның бик күбесе журналның эше ничек алынып барылуы белән таныш түгелләр. Язышучыларыбызны кыска гына рәвештә редакциянең эчке эше белән таныштырып үтү зарар итмәс.

Журнал ничек эшләнә?

Бер номер журнал чыгу белән, икенче номерга хәзерлек башлаганда, иң беренче, редакциядә эшләүчеләр чыгачак журналның алдан планын төзиләр. План үзенең эченә шул айда эшләнә торган эшләргә каратыла.

Әйтик, редакциягә апрель яки май ае журналын чыгарырга кирәк.

Ул үзенең алдына иң беренче «Бу айларда нинди эшләр эшләнә, нинди кампанияләр бар?» дигән сорауны куя. Шуннан соң кирәк мәкаләләрне язуны билгели.

Әйтик, апрельнең азагында язгы чәчүгә, бакчачылык эшләренә хәзерлек башлана. Димәк, шул турыларда хатын-кызга юлбашчы булырлык мәкаләләр бирергә кирәк. Редакция, шуны планына кертеп, белгечләргә мәкалә язарга бирә.

Сәяси мәкаләләр дә шул айда була торган революция бәйрәмнәренә каратылып планга кертелә. Язын балаларны ничек тәрбияләргә кирәклек турында докторларга мәкаләләр язарга куша. Аннан соң, апрель аенда делегаткалар кышкы эшләрен бетереп, язгы эшләү шартына күчәләр. Язын делегаткаларның нәрсәләр эшләргә тиешлекләре турында юлбашчы булырлык мәкалә бирү кирәк.

Редакция шул кампанияләргә каратып журналның мәкаләләр бүлеген билгели. Соңыннан, урыннардан килгән хатларны ачып, алар эчендә булган материалларны тикшерә башлый.

**Көтелгән хатлар**

Урыннардан селькоркалар, рабкоркалар язган хатларны ачу белән, аның кем һәм кайдан язганлыгын карап, аерым кенәгәгә теркәп куеп барыла. Язучының адресы булмаса, андый хәбәрләр керми. Кергән вакытта да язучыга каләм хакы җибәрелә алмый.

Хәбәрләр теркәлү белән, журналның секретаре аларны тикшерә башлый. Ул хатлар эчендә бер биш-алты хат бер үк кимчелекләр турында булса, шул язуларны ачып, кимчелекләрдән чыгу юллары күрсәтелеп мәкалә язарга тырышыла. Шулай ук килгән хатлар арасыннан югарыдагы план буенча шундыйрак хәбәрләр эзләнә:

– Кайсы авылда язгы чәчүгә хәзерлек ничек барган? Бу хәзерлеккә делегаткалар ничек катнашканнар? Кышын делегаткалар ничек эшләгәннәр. Язгы эшкә ничек хәзерләнәләр? Авыл хуҗалыгы түгәрәкләре язгы эшкә ничек хәзерләнгән? Уртак бакчалар чәчүгә хәзерлек булганмы, кайда нинди бакчачылык артеле төзелгән?

Менә шундыйрак хәбәрләр эзләнә. Андый хәбәрләр булса, редакция шатланып шул номерга кертеп тә җибәрә. Әгәр вакытына яраксыз яки әһәмиятсез хәбәрләр булса, алар журналга кертелми.

Бу айда гына чыга торган журналга кертелгән хикәяләр дә, шигырьләр дә шуңар каратыла төшә. Журналга керәчәк рәсемнәр дә шул айга каратып урнаштырыла. Тик безгә урыннардан рәсемнәр җибәрүчеләр бик аз әле.

Хатлар арасында килгән төрле сорауларга җавап бирү өчен журнал каршында хокукый киңәшләр бирү бүлеге бар. Сораулар хокук турында булса, хокук бүлеге аларга киңәшләр язып бирә.

Сорау төрле авырулар турында булса, докторлар журналга җавап язып бирәләр. План буенча материаллар җыелу белән, секретарь материалларны төзәтеп матбагага хәзерли башлый.

**Хәбәр язарга уйлаганда**

Журнал ул бары читтән язышучыларның катнашы белән генә чыга ала. Журналда эшләүчеләр журналның чыгуына юлбашчылык кына итәләр. Ә журналның битләрен аның язышучылары тудыралар. Хәбәр язарга уйлаганда, һәрвакыт югарыда күрсәтелеп үткән журналның эчке төзелешенә бик нык әһәмият бирергә кирәк.

Хәбәрче урыннардагы эшнең барышын бик нык күзәтеп барырга һәм журналга вакытында материаллар биреп торырга тиешле.

Киләсе номер журналларыбызда кайбер әһәмиятлерәк нәрсәләр турында дискуссияләр уздырыла. Журналыбызның язышучылары шул дискуссияләргә катнашулары белән бергә урыннарда да ул мәсьәләләр турында хатын-кыз арасында фикер алышулар үткәрергә тиешләр һәм гомуми фикерләрдән чыккан нәтиҗәләрне безгә язып торырга бурычлылар. Журналның ике еллыгы аның киләчәктә эчке мөндәриҗәсен яхшылату теләге белән уздырыла.

Журналны яхшылату язышучылар өстенә йөкләтелә.

**КАРА КҮЛӘГӘ АСТЫНДА**

Хатыны бала табу йортына киткәч, минем бер иптәшем үлә язды. Ул, хатынының газаплануларын күз алдына китергән саен, аның газабын җиңеләйтергә, бүлешергә теләгән төсле, чын күңелдән ыңгырашып, караваттан бала

тапкандай итеп газапланып ятты. Аның йөзен иптәшен чиксез кызгану белән аталык йөрәгенең авыртулы хисләре каплаган иде.

Ул мине, тиле кеше кебек, биш-алты мәртәбә консультациягә өстерәп барды. Кулларын юарга өлгерми хатынының ул тапканын белдерергә чыккан акушерканың ул, тиле кебек, кулларын ялады.

Мин аның беренче мәртәбә баласының йөзен күрүен, беренче мәртәбә аталык хисләре уянган минутларын карап тордым.

Аның йөзендә кыргый оялулы үзлек мәхәббәте тулган иде. Ул, бер елдан соң үлгән шушы улын күмгәндә, кайгысына түзми үксегән анага авыр сүзләр әйтте. Баласын карый алмавы өчен йөрәкне кискәләрдәй ачы тиргәде.

Каныннан аккан томанлы кешелек нәселен саклау куркуы йөзен күләгәләгән иде аның.

Бала табу йортлары алдыннан үткәндә, һаман бер нәрсә күз алдына килә. Анда күз төпләре кара, иреннәре күмер булып янган ап-пак йөзле аналар, ак мендәрләргә күмелеп, бала табудан соң хәл җыеп яталар. Ә күбесе әле үлем тартышында, баланың тәненә кан, сөт агызган тамырлар өзелергә теләми, аның үлеме белән яшәве уртасында туарга тиешле бала ашыкмый. Анасының газабын белмәгәндәй озак. Бала тапкан хатыннар ирләрен тиргиләр, ди:

– Кабахәтләр, алар белмиләр... аларга җиңел... Мин гомеремдә дә тагын якын җибәрмәм үзен, – диләр икән.

Үзләре бала тапкач хәлен белергә килгән ирләренә елмаялар, ирләренең йөзләреннән шатлык сызыклары эзләргә тырышалар. Иренең йөзендә шатлану эзләрен тапсалар, масайгандай, менә нинди матур бала тудырдым, дигәндәй, елмаюлы шатлыклары белән үткән авырлыкларын онытала...

Ләкин бары да бәхетле түгел аларның.

Күпләре, канлы яшьләрен балаларының чүпрәкләренә сөртә-сөртә, сөрелгән килеш, хәлсез аяклары белән урамга, елмаюсыз тормышка атлыйлар.

Ул тудыруына шатлану хисе юк аның. Торыр урыны да юк. Аның аналык күкрәге генә баласын туңудан саклый ала. Шуның өчен дә аналарга җылы хисләр бирәсе килә.

Балаларын көчсез аналар кулына ташлап киткән кыргый аталарга нәфрәт хисләре уяна. Хатын-кызлар белән шаярып та бала тәрбиясеннән төрле юллар белән качып йөрүчеләргә каты хөкемнәр, авыр җәзалар бирдерәсе килә.

Ләкин...

---

Мин бер иптәшнең кабинетына кердем. Ул – мәсьүл бер эшче. Йоклыйсы йокыларын, ял итәсе минутларын, ниһаять, үзен совет, партия иркенә биргән кеше.

Ул, кайчандыр өйләнеп, соңыннан шул хатыннан баласы булып, аерылган иде. Мин аны шул эше өчен эчтән генә тиргәгән, сүккән идем.

Аның: «Спекулянт кызы. Тәрбияләргә тырышсам да, булмады. Үзенең мещанлыгын, минем артта маңлай тире белән тапкан акчама типтерүләрен ташламады», – дигәненә ышанмыйчарак караган идем. Бит шундый ук сүзләр белән бик күп ирләр файдаланып, элекке хатыннарын ташлап, яңаларга өйләнделәр. Бу да гомуми аклану гына дип уйлаган идем.

Мәскәүдә суд булып, судьялар да шулай караганнар, ахры. Аның ала торган жалованьесеннән 30 процент бала тәрбиясенә бирергә хөкем иткәннәр һәм, суд кәгазен ярты елдан соң төшереп, бу иптәшнең жалованьесеннән 50 процент тотып кала башлаганнар. Эш аның жалованьесеннән тотылып калган процентында түгел.

Соңга таба ул хатынның дөрестән дә шулай гулять итеп йөрүләрен Мәскәүдән килгән кайберәүләр сөйләделәр.

Ә бүген менә минем кулыма авыр хисләр уятырлык бер хат килеп төште. Аны шушы иптәшнең элекке хатыны Хәлимә Бикчәнтәева торган Омск шәһәренең комсомол әгъзаларыннан ике кеше аның исеменә яза. Менә хатның беренче юллары:

*«Омск шәһәре... комсомол ячейкасы членнары... һәм ...ләр сезнең белән танышу яки дуслашу нияте белән түгел, бәлки киләчәк комсомол оешмасының эшчесе булырга тиеш булган бер баланың хәзерге кызганыч хәлен күреп, аны ул начар тормыштан котылдыру нияте белән сезгә хат язарга уйладылар. Аңлыйсыздыр. Сүз сезнең кызыгыз Рәкыя турында бара.*

*Ул тора торган семьяда искиткеч явыз пычраклык, гаилә пычраклыгы, кара йөрәклек һәм җирәнгеч начарлыклар бар. Анда хулиганнарча сүгенүләр, сездән алимент төсендә алынган акчаны эчүгә, егетләр җыеп кичә ясап, бутылкалар арасында кәеф-сафага түгәләр һәм башкалар бар.*

*Ялгышмасам, бу елның 5 августында тантаналы кичә үткәрделәр. Кичәдә кызыгызның анасы Хәлимә, сеңлесе Хәдичә, калганнары – кызарып пешкән обыватель егетләре. Кичә, аракы бутылкалары бушагач, бик «кызык булган»... Шушындый ук характерда, бәлки, тагы да пычраклыклар белән тулырак төстә, шәһәр читендә күп кенә гуляниелар ясала. Баланың анасы мондый кичәләргә расходның зур өлешен күтәреп катнаша».*

Тагын:

*«Хәлимә көн дә театрда, кинода, кәеф-сафада, көн дә диярлек кызарып, баш әйләндереп йөри. Баланың хакын ашый, ата тарафыннан бирелгән ярдәмне кимерә...*

*Күптән түгел ул син җибәргән 150 сум акчаны алган. Аның мактанып сөйләвенә караганда, ул акчалар күбесе кәеф-сафага, бер өлеше Хәлимәнең яшерен рәвештә ... белән сәүдә итүче анасының сәүдә капиталына бирелгән...*

*Бала менә шундый хәлдә, анасының чын мещанлыгы белән генә түгел, аның бөтен пычраклыклары белән уралган...»*

Әйтегез, кызганып күңел әрнерлек түгелме? Хатта моннан башка бала турында җан әрнетерлек җөмләләр бар.

Алар хатны үзләренең комсомоллык бурычын үтәү өчен, киләчәктә бөек нәселебезнең бер әгъзасын пычраклыктан коткару өчен генә язалар.

Соң бу хатка тагын нәрсә өстәргә?

Бер генә нәрсә:

– Баланы, ана исемен күтәрергә хаксыз мещанка кулыннан, кара күләгә астыннан алып, кешелекнең бүгене, киләчәге өчен көрәшүче коммунист атасына кайтарырга кирәк! Атасы да шул турыда ашыгыч чаралар күрергә тиеш.

## **«ОПРОВЕРЖЕНИЕ»**

– Ну, гәзиттә пешергәннәр, малай, үзеңне, укыдыңмы?.. Ай-яй...

– Ялган, барысы да ялган, валлаһи, ялган! Юк, мин бүген үк опровержение язам! – диләр дә рабкор заметкаларына каршы газетаның үзе кадәр опровержениеләр язалар. Редакциягә һәр көнне йөзләрчә конверт шундый хатлар килә.

Без менә шундый хатлардан берсен алып, һичбер төзәтмәсез генә басып күрсәтәбез. Хатны ...нчы татар полкының взвод командиры Әхмәтҗанов яза: «Кызыл Татарстан»[1] газетасының 204 нче санында хәбәрче Фәхри минем партиядән чыгуымның сәбәбе итеп бөтенләй булмаган нәрсәләр белән буяп ташлый. Мин, имеш, чит элементлар белән аралашканмын, мин, имеш, бер бай поляк кызына өйләнгәнмен! Берәүнең хатынын көчләгәнмен, икенче берәүнең хатынын көчләргә иткәнмен.

Үземнең хосусый эшләремне башкаруда кызыл армияләрдән файдаланганмын! Болар һәммәсе алдау. Дөресе, мине чистка[2] комиссиясе түбәндәге эшләр белән гаепләде:

Берәүнең хатынын көчләргә теләү;

Чит элементлар белән аралашу;

Кызыл армияләр көченнән файдалану;

Сүгенү, эчү, күз буяу.

Ә Фәхри дигән хәбәрче бөтенләй булмаган нәрсәләрне язып мине пычрата. Мин, аның үзем турында «чит элемент» дип сүгенеп язуын укыгач: «Кайдан бу нәрсәләрне уйлап чыгарган», – дип уйга калдым. Бу бит хәбәрчелекне пычрату була.

Мин үземнең өстемә төшкән гаепләрне түбәндәге сәбәпләр белән дөрес түгел дип әйтәм. Хәзерге вакытта да әйтәм, киләчәктә дә әйтәчәкмен: берәүнең хатынын көчләргә теләү дигән нәрсә миндә булмады. Валлаһи булмады. Ә дөресрәге, аның хатыны мине көчләде.

Чит элементлар белән аралашу бөтенләй юк сүз. Минем белән йөргән кыз Польшадан килгән булса да, аның атасы иске вакытта адвокат булса да, Октябрь революциясеннән соң ул чит элементлыктан чыккан.

– Кызыл армияләр көченнән файдалануны, тәкрар әйтәм, дөрес түгел. Кызыл Армияләр миңа столовойдан аш, икмәк, чәй һәм тәмәке алып киләләр икән, аның өчен мине гаепләргә кемнең дә хакы юк!

Сүгенү, хулиганлык... менә бу эштә үземне гаепле саныйм. Ул нәрсәләр миндә действительно бар. Ә инде күз буяу дәхи дөрес түгел. Минем күз буяганым булмаганы белән бәрабәр, мин үзем дә күз буяган кызларга каршы көрәшеп йөрим.

Әхмәтҗановның күз буямаганлыгы бу хатыннан бик ачык күренә. Күз буйый белгән кеше разве үзен буяп болай редакциягә «опровержение» язар иде?

## **ЧЕГӘН КЫЗЫ КОЛХОЗДА**

Идел тын. Идел ярында, талларга басып, ана сандугачлар сайрамый гына Иделдән агып үткән салны карап торалар. Иделнең янында ук «Нәриман» колхозы утырган. Колхозның этләре, урамда чит кешеләр йөремәгәнгә, кемгә өрергә белми эчләре пошып, борыннары кычытканга аптырап йөриләр. Колхозда эш кайнап торганда эшсез йөрүне килештермәгән кебек, ара-тирә танымаган булып, таныш кешеләргә дә өреп-өреп куйгалыйлар. Күңелсез бит, чын күңелдән өрмәгәч булмый булуын да, тик, юкта үпкә дә тансык дигәндәй, кычыткан борынны басу өчен ярап куя ул.

Менә урамның әллә кай җирендә Сарбайның чын күңелдән өрү тавышы ишетелде. Этләр, шатланып, яшь кенә, ялтыр күзле бер сәләмә чегән кызын урап алып талый башладылар. Очтагы йортларның берсеннән бер карчык, чыгып, чегән кызын этләрдән аралады. Этләр, карчыкның болай кеше эшенә килеп борын тыгуыннан бик недовольный булып, өрә-өрә читкә киттеләр. Чегән кызы, этләрдән арыну белән, карчык янына килеп туктады да, карчыкка карап:

– Давай погадаю, бир кулыңны, бәхетеңне әйтим, – дип кулын сузды.

Ул көнне колхозда эш бик иртә тукталды. Тирес ташып йөрүче атлар вакытсыз эштән туктауны аңламадылар. Алар:

– Әллә колхозда берәр бәйрәм-фәлән булдымы икән? – дип гаҗәпләнеп калдылар.

Колхоз урамында җанлылык башланды:

– Син караттыңмы әле?

– Караттым.

– Нәрсә диде?

– Каян белә, каһәр суккыры, прәме өстенә басып әйтә.

– Шулай шул, малай, минем дә исем китте.

– Әллә җеннәре әйтеп торамы икән үзенә?..

– Чынлап та, җеннәре әйтеп тора торгандыр. Юкса каян белсен...

Ул төнне төн буена колхозда чегән кызы турында сүз барды. Рәтле генә көн күрә башлаган колхозның общий йортында торучы кыска сакаллы агай төн буе йокламый чыкты.

– Хатын, чегән кызы ничек диде?.. Сиңа ерак сәфәр торамы, ди? Колхоздан чыгарырлар, ахры, моннан китәргә туры килер, ахры. Их, тамак икмәккә туя башлаган иде... Инде бетте, күрәсең, – дип, төн буе ыңгырашып чыкты.

Икенче көнне колхоз членнары эшкә бик ялкауланып кына чыктылар. Чегән кызы бик телчән булмаган, күрәсең, барысына да:

– Сәфәр тора, сәфәр, – дигән. Күңелләргә шик салган. Борчу арттырган.

Чегән кызы колхоз председателе Шәмси Мөхетдиновның хатынына да зур бәхетләр вәгъдә иткән. Шуның өчен, иртә тору белән, аның кәефе дә гадәттәгедән әйбәтрәк иде. Самовар куеп, иртәнге чәйне эчеп бетерим дигәндә генә, аңа, ашыгып, правление члены Миңнулла агай килеп керде. Ул, керүе белән үк:

– Шәмси агай, теге урланган тәгәрмәчләрне чегән кызыннан каратырга оныткансыз, искә дә килмәде бит. Кем урлаганны әйтеп бирер иде, – диде.

Шәмси агай аның сөйләп бетергәнен көтмәде:

– Бар тизрәк, атка утырып эзләп кайт үзен! Җир астыннан булса да табарга кирәк. Әйтер ул, белер ул, белми булмас, – диде.

Киттеләр, чегән кызын эзләргә киттеләр, колхозда калган членнары Идел ярына утырып чегән кызын көтә башладылар, араларыннан кемдер:

– Чегән кызы тапмаса, Арча кантонында бер багучы бар, ди, күзгесез карый да, ди, чистый әйтә дә бирә, ди. Шуны чакыртып килергә кирәк, сигез тәгәрмәч уен түгел ул, – диде.

Председатель дә сүзсез калмады, ул, Шелангы[1] ягыннан «Нәриман»га таба озаеп килгән юлга карап, үзенең зур сүзен әйтте:

– Ие, шулай итәрбез, – диде.

Правление члены чегән кызын очратмый кайтты. Чегән кызы булмагач, икенче көнне правление членын, багучы карчыкны эзләргә дип, Арча кантонына җибәрделәр. Ул аннан өч көн, өч төн үткәч кенә кире кайтты. Йөргән көннәре эшкә саналды. Юл расходлары түләнде. Ләкин тәгәрмәчләр табылмады.

Беркөнне генә әле мин «Нәриман» колхозы эзләгән чегән кызын Осланда очраттым.

– Погадаю! – ди.

Сорамыйча ук 15 тиен акча суздым үзенә һәм:

– Чегән кызы, менә сиңа 15 тиен акча, зинһар, ялганламыйча гына гомереңдә дөрес сүз әйт: кайчан да булса Теньки районы[2] «Нәриман» колхозына Наркомпросның[3] берәр инструкторы килгәне бармы, юкмы? Килмәсә, килерме? Килеп, наданлыкны бетерү мәктәбе ачып эшкә керешерме? – дип сорадым.

Чегән кызы:

– Нәрсә? Кем ул? – диде.

Мин, аның соравын әллә аңлап, әллә аңламый:

– Наркомпрос, – дидем.

Чегән кызы «Нәриман» колхозы члennары кебек «Наркомпрос» сүзен беренче мәртәбә ишетте булырга кирәк:

– На просо (ягъни ярмага) не гадаю, – диде.

**СӘМИГУЛЛА ХӘЗРӘТ**

Сәмигулла хәзрәт, большевиклар властьны алгач, аларга үзенең фатихасын да, мәхәллә халкына большевик булырга фәтвасын[1] да бирмәде.

– Бер атнага гына... Чәнчелерләр... Озакка бармаслар, – дип йөрде...

Агылчан патшасының сугыш көймәләре Сахраи кәбир[2] аркылы йөзеп үтеп, большевикларны «усмирить итәргә килүе» турында хәбәрләр таратты.

Сәяси вакыйгалар алмашынган саен, ул үзенең пәйгамбәрлеген, большевикларның бетүләренә карата сөйләгән сүзләрен үзгәртә барды.

Большевиклар җирләрен крәстияннәргә алып биргәч, табышына налог белән дә керә башлагач, хәзрәт пәйгамбәрлеген тагын да көчәйтә төште. Үз тирәсендәрәк җыелган кулакларга авылда яңа оешып килгән комсомолларны төннәрдә тотып кыйнау юлларын өйрәтте. Очраганда үзе дә, үгетләп, комсомоллыктан кайтару юлын тотып йөри башлады.

Ә беркөнне хәзрәт өчен көтелмәгән вакыйга булып алды. Кызы Мөршидә налог эшләре белән килеп-китеп йөргән большевик комиссарга, хәзрәтнең иң яратмаган кешесенә, ябышып кияүгә китте дә барды.

Бу вакыйга хәзрәткә яшен кебек тәэсир итте. Күзләреннән яшьләре мөлдер-мөлдер булып сакалы буенча актылар. Намазлыгы өстенә утырып, бик озак зари кылып дога кылды. Ул төннең-төн буе йоклый алмый чыкты.

Икенче көнне иртүк торып атын җикте дә, абыстаен утыртып, үзенең дин дошманына иргә чыккан кызына китте. Хәзрәт юл буе нигәдер моңаеп җырлап барды. Кияү тиешле кешесе эштән кайтып өлгермәгәнгә, аларны кызлары гына каршы алды. Атасының бәддогасыннан куркып ишек ачкан кызын күрү белән, хәзрәт:

– Саумы, балам, бик исәнме, кошчыгым, Аллаһы Тәгалә бәхетеңне киң кылсын, кызым, әйе... Киявеңнең кадерен белеп яшә... Коммунистка кияүгә чыгу, фаразан, хәзерге көндә җиңел эш түгел. Иншалла, иншалла... Соң, кызым, киявең, фаразан, ничек... бик ни түгелме?..

Атасының болай җиңел генә бәхиллек бирүен көтмәгән кызы шатланганнан нишләргә белмәде.

– Киявем, әткәй, бик кул кеше... Бик яхшы кеше... – диде.

Кичен кәләпүшен маңгаена төшереп чәй эчеп утырганда, хәзрәт үзе дә киявенең кул кеше булуын, яхшы большевик булуын аңлады. Кияве:

– Мин, әткәй, дин тоткан кешеләргә каршы түгел, совет җирендә һәркем үз дине белән яшәргә хаклы... – диде.

Киткәндә, хәзрәт кияве белән кызын кунакка чакырып китте.

Бу вакыйгадан соң хәзрәтнең большевиклар турындагы хәбәрләре сирәгәйде. Соңгы вакытларда хәтта борынгы сөйләгән сүзләренә капма-каршы итеп:

– Балшавиннардан да яхшы кешеләр, фаразан, булуы мөмкин. Мәсәлән, минем киявем, әйтик, ягъни... – дип озайтып-озайтып яхшы «балшавиннар» булуы мөмкинлеге турында сөйләкли башлады.

Кияве налогларын да киметкәч, улын комсомолга кертеп укытучы итеп тә урнаштыргач, кече кызын техникумга укырга да җибәрә алгач, хәзрәт бөтенләй суллашты[3]. Суллашуы гүя аңа бәхет китергән кебек булды. Йорт-җир тирәсе дә рәтләнә башлады. Һәйбәт тун да тектереп алды, җигеп йөрер өчен генә тагын да бер һәйбәт айгыр алды. Аның тормышы әйбәтләнгән саен, ул большевикларны мактавын арттыра башлады: хәтта мәчет картлары хәзрәтләренең «балшун» булып китүеннән куркып йөри башладылар. Абыстае да хәзрәтнең иманына көч килүдән шикләнә башлады.

Мәчеткә большевиклар гайбәт сөйләр өчен генә җыелган авыл кулаклары, хәзрәтләреннән өркеп, аның алдында большевикларны сүгүдән тыела яздылар. Ә беркөнне аларның гаҗәпләнүләренә карамый: «Ленинның урынын Ходай җәннәттә итсен!» – дип дога да кылдырды.

Еллар, хәзрәтнең тәсбихы кебек тезелеп, тыныч кына үтә бирделәр. Хәзрәтнең тормышы да һаман һәйбәтләнүгә табан барды.

Бу ел яз көне отпуск вакытында кияве белән кызы, аларга килеп, айга якын кунак булып киттеләр. Алар китү белән генә хәзрәт ничектер алмашынган кебек булды. Нигәдер пошынып йөри башлады. Ара-ирә большевикларга да тел тидерә башлады.

Көзгә таба авылда хәзрәтнең киявенең партиядән чыгарылуы турында хәбәр таралды. Шул хәбәрнең артыннан ук улы комсомолдан да, укытучылыктан да чыгарылу хәбәре килде. Хәзрәт көннән-көн уңлаша[4] башлады. Ул большевиклар турында элекке кебек төрле хәбәрләр тарата башлады. Бер ай да үтми, кәрзиннәрен ияртеп, мәктәптән куылган килеш кече кызы килеп төште. Өстәвенә, ярты ай да үтми, кызы ашап яткан стипендиясен дә түләттеләр.

Бу вакыйгалар хәзрәткә яшен кебек тәэсир иттеләр.

Күзләреннән яшьләре мөлдер-мөлдер булып сакалы буйлап актылар.

Ул инде, мәчет мөнбәреннән торып, Чин мәмләкәтенең җиһад игълан итүе[5], ахырзаман алды, яэҗүҗ-мәэҗүҗ кавемнәренең[6] дөньяда патшалык сөрүләре турында ачыктан-ачык шомлы хәбәрләр сөйли башлады...

## ҺАДИУЛЛАНЫҢ ҺӘЛАКӘТЕ – ОТНОШЕНИЕ БӘЛАСЕ

Совет хезмәткәре Һадиуллага яңа гына өйләнгән хатынынннан бер ел аерылып торырга туры килде. Аерылып торгач инде хатлар язмый торып булмый. Менә шул хатлар язып тору эше дә Һадиулланың һәлак булуына сәбәп булды.

Әллә хатларын ашыгып язганга, әллә хатыны ахмак булганга, аның беренче хатына каршы ук хатынынннан: «Хатыңнан бернәрсә дә аңламадым», – дигән җавап килде. Ул шул җавапны алу белән үк поездга утырды да хатта язылган нәрсәләрне аңлату өчен хатыны янына кайтты һәм, хатыны янында бер көн торып, хатны аңлатып, кире эшли торган шәһәренә кайтып китте. Ике атнадан тагын хат җибәрде. Аңар хатыны тагын шундый ук җавап кайтарды. Бу юлы да Һадиуллага, кайтып, хатын аңлатырга туры килде. Өченче, дүртенче хатларын да кайтып аңлатмый тынычланмады. Шулай итеп, бер ел буена егерме хат язып, егермесен дә хатынына кайтып аңлатып китәргә мәҗбүр булды.

Аның бөтен алган жалованьесе хатыны янына кайтып, хатларын аңлатып кайту расходына китеп бетүе сәбәпле, ашарына-эчәренә дә калмады. Арыкланды, йөрерлек хәле калмады. Киемнәре өзгәләнеп бетте, һәм беркөнне шулай соңгы хатын аңлатып кайтырга дип юлга чыкты. Билет алырга акчасы булмау сәбәпле, качып-посып площадкада кайтканда туңып үлде, һәлак булды.

Һадиулладан да тиле, бу хикәядән дә ахмак хикәя булырга мөмкин түгел, ә менә шундый вакыйга күптән юк кына Казанның борын төбендәге Арча кантонында булып алды.

Арча кантоны ярдәмләшү комитеты волость ярдәмләшү комитетларына менә шушындый кәгазь җибәрә:

«Бөтен волость ярдәм комитетларына!

Арча кантоны ярдәмләшү комитеты шуның белән сезгә үз орлыкларын йөз процент белән чистартып чәчкән ярлыларга язгы һәм көзге чәчү кампаниясендә даими рәвештә ярдәм күрсәткән ярлыларның җирләрен сукалап эшен уңышлы чыгару өчен тарту көче алыштырган авыл ярдәм комитетларының исемен, килерен тиз көн эчендә кантон ярдәм комитетына җибәрергә». Имзалар...

Авылларда бу отношениене алып укысалар да, бернәрсә дә аңламаганнар, соңыннан ярдәмләшү комитеты, авылларга кешеләр җибәреп, отношениене аңлатып йөрткән дип язалар.

Менә бит Һадиулланың тере иптәшләре кая!

## ЭШЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘР

Садыйков, кабинетына килеп керүгә, портфелен өстәлгә куйды да, тәмәкесен кабызып, креслосына утырды. Ишеген гадәттәгечә ачык калдырды. Ул кабинетында ялгыз гына утырырга яратмый, ишеген ачык калдырса, янында сөйләшеп утыручы булмаса да, ачык ишектән учреждениедәге хезмәткәрләрнең мыжылдауларын карап тору күңелле була.

Бүген ул тәмәкесен кабызды да кулына ручкасын алды. Аның өстәлдә өелеп яткан эшләргә күзе төште. Тау булып өелеп торган кәгазьләр аның эчен пошыра башладылар. Ул нервничать итеп бер-бер артлы төтенен суырды

да ачык ишектән күренеп торган делапут белән отдел мөдиренең сөйләшеп торуларын карап тора башлады. Алар күз кырыйлары белән генә Садыйковка карыйлар да, тәмәке төтененнән бożралар ясый-ясый, сөйләшеп утыралар. Садыйковның үзләренә карап торуын күргәч, нәрсәдер язган булып маташалар. Садыйков һәрвакыттагы кебек ике-өч сәгатькә кадәр аларга, эшләгән булып, күз кырые белән генә карап торды. Ул, бәлки, занятие бетүгә кадәр шулай итәр иде. Ишектән посетительләреннән качып килгән үзе кебек бер мөдир генә аны бу эштән туктатып калды. Ул, килеп керүгә, портфелен өстәлгә ташлады да уфылдап креслога утырды һәм эш күплектән зарлана башлады. Садыйков та эш күплектән нервничать итеп утыруын сөйләде. Алар, утыра торгач, чистка турында булган кызыклар турында сөйләп киттеләр. Бу сөйләшү Садыйковка эч пошканнан яраган кебек булды. Ул иптәшенең чистка турындагы модный анекдотлар сөйләвен чын күңелдән тыңлап торса да, күзен һаман делапут белән отдел мөдире өстендә йөртте. Аларның сөйләшеп утыруларына карап тору аның чыдамлыгын җимерә язды. Ул делапут белән отдел мөдиренә таба башы белән ишарә итте дә:

– Ну бюрократлар... Өч сәгать карап торам, һичбер нәрсә эшләмиләр, тәмәке кабызалар да колакка-колак куеп нәрсәдер сөйләшәләр, тәмәке кабызалар да шулай итәләр... Бер ай инде бу учреждениедә эшлим, һаман шулай... Ә бит жалунья ашап яталар, эшлексез разгельдәйләрне ерактан эзлисе юк... менә алар кайда... – дип, башын чайкап куйды.

---

Шул ук вакытта делапут үзенә справка сорап килгән берәүне өстән-өстән генә сөйләп озатты да тәмәкесен кабызып отдел мөдиренә борылды һәм колагына гына:

– Ну безнең яңа зав эш сөймәс кеше дә соң... Өч көн була, кул куярга биргән кәгазьләрне һаман кайтарганы юк. Эшлексезләрне әллә кайдан эзләп йөрибез. Менә кая ул, анекдот сөйли дә утыра... – диде.

Отдел мөдире аның фикеренә кушылды һәм, тәмәкесен кабызып:

– Әле син анекдот дигәч искә төште. Син теге чистка турындагы анекдотны ишеттеңме әле... – дип, тәмләп торып анекдот сөйләргә башлады.

**ТАВЫКБАЕВ**

Вәлиулла Тавыкбаев чистка комиссиясе өстәле янына килеп басу белән, комиссия председателе аның партбилетын сорап алды. Ул тамагын кырды да залга карап тәрҗемәи хәлен сөйли башлады. Кинәт түбә чәчләре аягүрә тордылар. Беренче сүзен әйтергә теләсә дә, теле тыңламады. Партбилеты кесәсендә булган чакта мәһабәт кенә чыккан тавышы тамагында тыгылып калды. Ул тагын бер кат тамагын кырды. Тамак төбеннән көчкә-көчкә чыккан тавышы беспартийный вакыттагы тавышы кебек гайрәтсез чыкты. Суфи тавышына охшады. Кесәсендә партбилеты бар вакытында да айлар буенча сөйләргә хәзерләнгән тәрҗемәи хәле хәзер беспартийный кешенең тәрҗемәи хәленә охшар кебек тоелды. Ул сүзен дәвам иттергәндә:

– Атам крәстиян... – диде. Үзе атасын күз алдына китерергә тырышты.

Ул партиягә кергәннән алып үзенең атасының крәстиян булуына тәмам ышанып йөри башлаган иде. Хәтта өзгәләнгән киемле ниндидер бер ярлы крәстиян аның атасы булып кайчакларда хыялына кереп-чыгып та йөргәли иде. Бу юлы крәстиян атасы аның башына төрле булып гәүдәләнде. Йә ул авылларындагы Гыймади карт булып килеп басты, йә үзләрендә гомер буе ялчы булып торган Нурулла кебек күренде. Уйлары шул җиргә җиткәч, колагына атасы Ибраһим хәзрәтнең Нуруллаaны сүгүе һәм Нурулланың:

– Соң инде, мулла абзый, Вәлиулла синең улың да, минем улым да, – дип, беспартийный тавыш белән сөйләгән сүзләре ишетелгән кебек булды.

Ул, тәрҗемәи хәлен, эшләгән эшләрен сөйләп беткәндә, тирләп беткән иде. Беренче сорауны комиссия рәисе бирде:

– Атаңның исеме ничек?

Вәлиулланың башында үзе өчен сугышып канга баткан хәзрәт белән Нурулла килеп басты. Ул ярлы атасы Нурулланың исемен әйтте.

– Нурулла, – диде.

Комиссия рәисе залга Вәлиулланың анкетасында Ибраһим дип язылуын һәм Вәлиулланың крәстиян баласы булмыйча мулла баласы икәнен белдереп бирелгән документ булуын әйтте. Вәлиулладан җавап бирүен сорады.

Вәлиулланың партияле булып кеше күзенә карарга өйрәнгән күзләре партиясезләрнең күзләре кебек мелт-мелт иттеләр. Соңгы елларда үз кул астында эшләгән хезмәтчеләрне каты тотарга өйрәнгән куллары беспартийный вакыттагы кебек хәлсезләнделәр, ул:

– Мулла атамның (атамның – в кавычках) исеме Ибраһим, чын атам крәстияннең исеме Нурулла, – диде. Ул үзенең хәзрәт атасының улы булуына шөбһәләнүен, аларда ялчы булып торучы Нурулла белән анасы арасында ниндидер серле мөнәсәбәт булуын сөйләп, үзенең, мөгаен, Нурулла улы булуын аңлатырга теләде.

Бер-бер артлы сораулар ява башлады. Ул төрле сораулар эчендә югалып калды. Урын алу, тамагын туйдыруны гына уйлап партиягә кергән башы бу сорауларның берсенә дә җавап таба алмады. Партияле булып кеше күзенә күренергә өйрәнгән йөзе әллә ничек үзгәрде, беспартийныйлар йөзенә охшап киткән кебек булды. Җитмәсә, сүзгә чыгучылар җан әрнеткеч сүзләр сөйләделәр: эшли белмәвен әйттеләр, бюрократлыгын ачтылар, хатын-кызлар белән чуалуын, кемнәрнедер үзе белән мөнәсәбәттә булулары өчен урынга урнаштыруын сөйләделәр.

Вәлиулланың йөрәге моннан биш ел элек беспартийный вакытындагы кебек мескенләнеп тибә башлады. Ул ава-түнә залдан өенә таба атлады. Ишекне ачып урамга бер адым гына атлаган иде, каршына, күзләрен алаландырып, хатыны Хәдичә килеп басты. Ул нәкъ комиссиядәге кешеләр кебек аңарга сораулар бирә башлады:

– Нинди себеркеләрне син урынга урнаштырдың?

– Әйт, кемнәр белән минем өстемнән себерелеп йөрдең?

– Кемнәр белән, ә, кемнәр белән?!

Хәдичә ул чистка комиссиясе кебек әдәп саклап тормады, кулына эләккән нәрсә белән яңакларын, авыз-борыннарын чистарта башлады.

Партбилеты кулында вакытта хатынын шәпләп кыйный торган Вәлиулланың куллары бу юлы беспартийный вакытындагы кебек хәлсезләнеп сәленеп төштеләр, тезләре беспартийный вакытындагы кебек уңга да, сулга да китеп селкенә башладылар. Ул тагы бер кат үзенә көч биргән, кеше арасында кеше иткән кечкенә генә, нәни генә партбилетын сагынып куйды.

## ҖАМАЛИ БЕЛӘН КАМАЛИ

Җамали белән Камали – ике күрше, менә өч ай була инде, сугышканнары юк. Атнага икешәр мәртәбә тәртипле рәвештә сугышып торган күршеләр кинәт сугышмый башладылар. Бу – күршеләре өчен ничектер аңлаешсыз бернәрсә булып калды.

Унбиш ел күрше булып торган елларында Җамали белән Камали бер-берсен кыйнаганда кай җиргә сугарга кирәклекне, кайда сукканда берсен-берсе җиңә алуларына кадәр белеп бетергәннәр иде инде. Хәтта сугышу алар өчен гади бер әйбер кебек булган, артык кычкырынмый:

– Ник син, яньчек борын, кабыргага сугасың, не смей!

– Ә синең кабыргага сугарга ярамыймыни, менә алайса, мә, башың сынсын! – дип, кайда сугарга ярау-ярамау турында киңәшә-киңәшә, тәмләп-тәмләп сугышалар иде.

Еллар буе сугышу нәтиҗәсендә Җамалинең борыны яньчелеп калды. Бер бармагы кәкрәйде, уң аягы сулга карап йөри башлады. Камалинең уң колагының яртысы корбан булды. Дүрт теше коелды.

Аларның соңгы мәртәбә сугышуларына Камали тәкәсенең Җамали ындырына кереп, печәнен ашап чыгуы сәбәп булды.

Аларның элекке сугышларының төбендә дә шундый ук кечкенә нәрсәләр яталар иде.

Мәсәлән, аларның җирләре беррәттән йөргәнгә, кем соңрак чәчсә, шул ызан (межа) куйганда эчкәрәк керә. Әйтик, бакчасын Җамали элек сукаласа, аннан соң сукалаган Камали инде бер ярты гына адым Җамали җиренә керми түзми. Игенне урырга барганда да, кем элек барып урса, шул межаны гына булса да урып китә. Ә нәтиҗә сугыш белән бетә. Ул:

– Минем тавык синең йортка йомырка салырга йөри, син белә торып минем йомыркаларымны урлыйсың, – дип, хатыннары арасында чыккан ызгышлар да сугышсыз бетмиләр иде.

Бакчага тавыклар кереп кыярларын йолку, бозауларының бәрәңгеләрен таптап йөрү вакыйгалары – берсе дә сугышсыз хәл ителмиләр иде.

Соңгы мәртәбә сугышканда, алар бер-берсен:

– Соңгы мәртәбә әйтәм, башыңны сындырмый гүргә кермәм, – дип, берсен-берсе бөтенләй үтерешеп ташларга янашып куйдылар.

Ләкин өч ай була инде сугышканнары юк. Әле, сугышу түгел, урамда очраганда бер-берсенә җылырак сүзләр әйтешергә, авыл җыеннарында берсенең берсе сүзен җөпләшергә тырыша башладылар.

Аларның бу хәлен аңламаган күршеләре, үзләре сугышмагач, араларын боздырып булса да сугыштырырга теләп карадылар. Булмады. Җамали шул котыртучыларның берсенә:

– Шалиш, брат, хәзер инде безгә сугышырга нечево, бүлешер әйбер юк, һәммәсе бергәлек – колхоз әйбере, колхозга күчмәгән булсак, әле дә сугышыр идек, – диде.

## АЛМАШТЫРЫЛМАСЛЫК КЕШЕЛӘР

Хайванчылык ширкәтенең мәсъүл эшчеләре хәзергә кадәр бик дус булып, агай-энеләрчә, очраганда бер-берсенә йомшак тел белән эндәшеп, бер-берсенең күңелен күреп, күгәрченнәр кебек гөрләшеп килделәр. Ә бүген менә алар тыштан дус булып күренсәләр дә, эчләреннән бер-берсен күралмыйлар.

Бүген аларны һәммәсен бер-берсенә дошманлаштырган бер мәсьәлә килеп чыкты. Кантбашкарма хайванчылык ширкәтендәге кайбер урыннарны эшчеләр белән алмаштырырга тәкъдим итте. Шуның өчен бүген алар берсе-берсенә карап эчтән генә:

– Менә сине ни өчен берәр эшче белән алмаштырмаска, бик алмаштырып була. Һәрбер аңлы эшче син алып барган эшне синнән әйбәтрәк алып бара алачак... Аннан соң бюрократ та...

Һәммәсен бер уй борчыды: «Неужели мине эшче белән алмаштырырлар... «Неужели минем урынга берәр эшчене куярлар...» Үзләрен ничек тә алмаштырмау юлларын эзләделәр. Мәҗлес ачылу белән, һәрберсе үзен актив итеп күрсәтергә тырышты. Тире складының завы уйлап торды-торды да әйтте:

– Минемчә, беренче, ветеринария докторын берәр эшче белән алмаштырырга кирәк. Үзе чит элемент та бугай...

Эчәге мастерскоеның завы:

– Шулай ук агрономны да берәр эшче белән алмаштырып була, – диде.

Башкаларның күңелләре күтәрелде. Эчләреннән генә:

– Дошманлашып утырабыз. Менә кемнәрне алмаштырып була бит әле, – дип уйлап тынычлана яздылар.

Правление члены Плижанов:

– Врач белән агрономны станоктан күтәрелгән эшче белән алмаштырып булмый. Агроном, врач булыр өчен университетны бетерергә кирәк, – диде.

Хуҗалык эшләре мөдире:

– Мин дә шуны әйтәм бит. Агроном белән врачны ничек эшче белән алмаштырасың. Булмый ул. Шулай ук, әйтик, күн склады мөдирен дә, эчәге склады мөдирен дә алмаштырып булмый.

Эчәге склады мөдире сүз алып әйтте:

– Дисвительно булмый. Әйтик, хуҗалык мөдирен ничек эшче белән алмаштырасың?

Тире склады мөдире:

– Без инде незаменимый работниклар, – диде.

Бөтенесе :

– Правильно! – дип куйдылар һәм карар кылдылар: – Бөгелмә хайванчылык ширкәте, кантон башкарма комитетына ширкәт тәртибе буенча түбәндәге урыннарны эшче белән алмаштырырга мөмкин таба:

1 – чи тире складындагы бер кара эшчене;

2 – хуҗалык эшендәге бер кучерны, ат дагалаучыны;

3 – мал суя торган урындагы бер кара эшчене, санитарны;

4 – эчәге мастерскоендагы бер кара эшчене;

5 – кантондагы курьерны.

Башка эшчеләрне һичбер алмаштырып булмый.

Правление члены: Плижанов.

Секретарь: Кудряшова.

Ә без Бөгелмә хайванчылык ширкәтендә бу алмаштырылмаслык хайваннарның бик күбесен алмаштырып булыр дип уйлыйбыз.

## УДАРНЫЙ КӨН

Сәгать ун булуга карамастан, больницада әле прием башланмаган. Прием бүлмәләренең берсенең ишек төбендә озын чират койрыгы тора. Кемдер:

– Кайчан ачарлар инде? – ди.

– Аларга нәрсә. Корсаклары авыртмый аларның, – ди корсак авыруы белән килгән кеше.

Башы авырткан кеше:

– Башлары да авыртмый аларның, – дип өстәп куя.

Ә бүлмә эчендә сестралар, докторлар ашыкмыйча гына приемга хәзерләнәләр.

Больницага бүген Казаннан яңа мөдир килергә тиеш. Сүз шул тирәдә бара.

– Кем булыр икән?

– Усал булырмы икән, яхшы булырмы икән, блондин микән, брюнет микән?..

Чиратта торган бер кара чәчле егет, ишекне ачып, аларның сөйләшүләрен бераз тыңлап торды да тагын япты. Чиратта торучылар арасыннан кемдер:

– Уф, – дип ыңгырашып куйды.

– Ай, башым, – дип, башы авырткан кеше үзенең башы авыртуы турында белдереп куйды.

Ә бүлмә эчендә һаман, әкрен генә сөйләнә-сөйләнә, приемга хәзерләнеп тордылар.

Теге кара чәчле егет, чираттан чыгып, тагын ишекне ачып карап, тыңлый башлады. Сүз һаман шул мөдир турында барды:

– Кем булыр икән?

– Яшь микән, карт микән?..

– Зур микән, тәбәнәк микән?..

Теге кара чәчле егет бүлмәнең эченә керде дә:

– Сез көтә торган мөдир ул мин инде, – дип, урындыкка утырды.

Бүлмәдәгеләр бик тиз хәрәкәткә килделәр. Аларның күбесе аның белән исәнләштеләр дә сөйләшергә вакытлары булмаган кешеләр кебек ашыгып-ашыгып эшкә керештеләр. Чиратта торучылар биш минут саен алмашып торды, гаҗәп бер җитезлек белән чиратның койрыгы кыскарды. Бөтен больница яшен тизлеге белән хәрәкәт итә башлады. Теге кара чәчле егет чират беткәнче приемның ничек баруын күзәтеп утырды. Больницаның башка бүлмәләрендә дә бик нык җанлылык башланды. Колактан-колакка:

– Кара чәчле икән...

– Урта буйлы икән...

– Усалга охшамый, – дигән сүзләр китте.

Чират бетү белән, теге кара чәчле егет, докторга карап:

– Менә нәрсә, егетләр, мин юлда бераз авырый төштем, сез инде мине дә карап җибәрегез, булмаса, авыру килеш эшләргә уңайсызрак, – диде.

Аны бүлмәдәге доктор бик җентекләп карады да, икенче бүлмәдәге докторны чакырып, аңарга карарга кушты. Теге кара чәчле егетне больницаның бөтен докторлары карап чыктылар һәм диагноз куйдылар. Эш бетү белән, кара чәчле егет, докторга карап:

– Бик рәхмәт сезгә, иптәшләр, ну ләкин мине кичерегез, мин сез көткән мөдир түгел. Мин – шәһәр кооператив склады мөдире, шулай да сез ачуланмагыз, хәзер ударный вакыт, сез дә бүген кызыл тактага язарлык ударный эшләдегез, – диде.

**ЭКОНОМИСТЛАР**

Бишенче тегү фабригының директоры белән ячейка секретаре, Идел ярында утырган килеш, сүзсез, тәмләп тәмәке тартып утыралар. Иделгә салган кармакларының калкавычлары сәгатьләрчә бер урында селкенми тору директорга сөйләргә илһам бирә:

– Болай булса, көн буе утырсаң да, бернәрсә дә тотып булмас.

Ул һәрбер вакыйганы сәясәт белән бәйләргә өйрәнгәнгә, бу кечкенә генә балык чиертмәү вакыйгасы да аның башында зур сәяси вакыйгаларга барып тоташа.

– Әстерханда да шулай чиертми торган булса, балык тотудагы промфинплан ерак бара алмас, – ди ул.

Сүз тагын киселә. Алар тагын, тәмәкеләрен тәмләп тарта-тарта, калкавычларына карап тора башлыйлар. Ә су өстенә салган калкавычлары, һаман янәшәләп торып, селкенмичә генә, саф, көмеш төсле су өстендә йөзеп йөриләр.

Иртә таңнан килеп, көндезге уникегә кадәр утырып бер балык та тотмау партия секретареның эчен пошыра башлый. Ул, эченнән генә балык тотарга китү расходын тотылмаган балыкларның каплый алмавын уйлап, халык телендә йөргән бер зур сәяси фикер әйтә:

– Цель не оправдывает средства... – ди.

Директор:

– Икенче төрле әйткәндә, овчинка не стоит выделки, – ди.

Аларның балык тотудан күңелләре тәмам кайта. Икесе дә машинальный гына бу балык тотарга килүгә чыккан чыгымнарны уйлый башлыйлар. Иделгә килү өчен трамвайга 56 тиен, кайтырга тоже 56 тиен кирәк булачак. Ике кармакка берәр сумнан – 2 сум. Азыкларга 4 сумнар чамасы, барлыгы...

Ячейка секретареның кармаклар алганда 2 сум түләве, азыкларга 4 сум түләве исенә төште һәм:

– Кара әле, синнән миңа 3 сум акча тия...

– Син, егет, аз гына ошибка пустил: 2 сум 37 тиен туры килә.

– Ничек алай? Мин 4 сум – азыкларга, 2 сум кармакларга түләдем, барлыгы 6 сум була. Икегә бүлгәндә, 3 сум туры килә.

– Ә минем трамвайга түләгән 56 тиенне санамыйсыңмы?

– А, да, дөрес, шулай шул.

– Алай гына түгел, ә теге вакытта икәү бер кадак чия алган идек. Мин 80 тиен түләгән идем.

– Дөрес, ул вакытта мин 40 тиен бурычка калган идем.

– Шул шул...

Аларның бер-берсенә биргән бурычларын мондый вакыйгаларга кадәр хәтерләүләре гаҗәп түгел. Ләкин бишенче тегү фабригының директор белән ячейка секретареның эш вакытында балык тотарга килеп, промфинплан буенча өченче кварталда дәүләткә күпме бурычлы булуларын исләреннән чыгарулары – менә бу нәрсә действительно гаҗәпләнерлек.

**ПЕРЕГИБЩИК**

Өченче стакан аракыны эчү белән үк Әхмәтсафа И.ның күңеле йомшап китте. Эшләгән гөнаһлары, кеше рәнҗетүләре күз алдына килеп, елыйсылары килде. Каршында утырган шул рәнҗеткән кешеләрнең беренчесе булган хәзрәткә карап:

– Прости мине, хәзрәт, прости мине, сукин сынны, – диде. Һәм дөньядан туйган кеше рәвешендә сүзендә дәвам итте: – Мин кешемени? Мин дуңгыз, хәзрәт, дуңгыз, эх! Дуңгыз түгел диген, ә?

Хәзрәт, үзенең кунагының сүзен җөпләп, күңеле булсын өчен «дуңгыз» дияргә тиеш булса да, кыймады, аны Алла тәбарәкә вә Тәгаләнең ярлыкаячагын, яңадан тәүфыйкланасын сөйләп юата башлады. Хәзрәтнең иркәләве Әхмәтсафага җитә калды. Ул картаюы сәбәпле еларга оныткан авызын килешсез итеп җәйде дә, еламсырап:

– Перегибщик мин, сукин сын, хәзрәт, перегибщик, синең мәчетне алдым, хур итеп тавыштан төшердем, раскулачит иттем, рәнҗеттем мин сине, авылда менә дигән кешеләрне раскулачит итеп, башларына җиттем. Әйт, сукин сын түгел диген мине, ә?

Хәзрәт, аның сүзен җөпләргә теләсә дә, бу юлы да аны сукин сын дияргә кыймады.

Әхмәтсафа селәгәйләнеп беткән авызын җыя алмый тагы еларга җыенды. Ләкин еллар үтүе белән, еларга оныткан булып чыкты. Һәм артык елап та маташмады.

Дүртенче стаканны эчкәннән соң, үзенең секретарен кочаклап еларга теләде:

Байлар байлар бал эчә,
Урта байлар сыра эчә,
Минем кебек сукин сыннар...

Әхмәтсафа җырын бетерми туктады һәм кинәт тагын еласы килде. Каршында утырган, эчеп мәлҗегән хәзрәткә карап-карап торды да, аны кочакларга теләп, кулларын сузды:

– Җанкисәгем хәзрәт, рәнҗеттем мин сине... Перегибщик мин, сукин тәре! Мин менә дигән тормышлы кешеләрне раскулачит иттем... Юк! Мин үземнең перегибымны төзәтермен, восстановлю мин сезне! Мин барыгызның да тавышларын кайтарып бирермен...

Ул каты итеп өстәлгә сугып җибәрде.

Буа кантоны Чүпрәле волосте Шланка авылы председателе Әхмәтсафа И. сүзендә торды, ул хәзерге көндә секретаре белән раскулачит ителгән мулла, кулакларда көне-төне эчеп йөри һәм аларның тавышларын кайтару юлында эшли.

## ГАЕПЛЕЛӘР

Габдулла агай белән Вәлиулла абзый хәзер терсәкләрен тешләр иделәр дә, җитми.

– Теге егетләрнең башлары әйләнгән вакытта, мәйтәм, колхозга кереп калган булсак, Вәлиулла, хәзер, значит, инде колхозчылар булган булыр идек. Син шул, карга борын, башны әйләндердең. «Тукта, Габдулла агай, көтик бераз... Колхозның ни икәнен аңлый төшик...» Аңладык атаң башы менә... Хәзер бик аңладың да, колхозга гына алмыйлар...

Һәм, дөрестән дә, алар никадәр генә колхозга керергә теләсәләр дә, гаризалар бирсәләр дә, аларны колхозга алмадылар.

Колхоз правлениесенең председателе:

– Һе, хәзер инде үзегез колхозга керергә телисезмени, керми торыгыз... Без, колхозга керегез, дип көчләп йөргәндә, көчләп кертәләр, дип, волостька жалоба белән йөрдегез... Значит, ул вакытта без кирәкми идек. Дескать, без перегибщиклар, дескать, без усаллар... Хәзер килдегезмени, кошчыкларым...

Габдулла агай:

– Без, энем, шул, ул вакытта аңламадык... Аннан, Вәлиулла белән без волостька жалоба белән дә барып йөрмәдек...

– Ә соң ник ул вакытта колхозга кермәдегез?.. Значит?

– Ул вакытта без, энем, колхозның ни икәнен аңламаган идек шул. Мин Вәлиуллага, керик-керик, дисәм дә, Вәлиулла, тукта, көтик бераз... колхозның ни икәнен аңлый төшик, дигән булды.

Вәлиулла көтмәгәндә Габдулла агайның болай гаепне үз өстенә генә аударуына нишләргә белми бөтенләй коелып төште. Ул, күзләрен мөлдерәтеп, колхоз председателенә карады да... күзләрен чыт-чыт йома-йома, тонык тавыш белән:

– Мин гаепле шул, гаеп миндә, энем... Без кара, надан кешеләр инде шул... – диде. Ул колхоз председателе алдына ук тезләнергә хәзерләнде.

Ә колхоз председателе тәмәкесен кабызды да:

– Единоличник булып җаныгыз чыксын хәзер... Алдыма тезләнегез, көне-төне ялгыз башыгызны ташка бәрегез, но ләкин сез хәзер гомергә дә колхоз йөзен күрмәссез, – дип, тәмәкесен кабызып, урамга ук чыгып китте...

Габдулла белән Вәлиулла, урыннарында баскан килеш, колхоз председателенең кайтуын көтеп калдылар... Алар инде аның килүе белән аягына егылып, колхозга алу турында сорарга булып хәзерләнделәр.

Габдулла агай белән Вәлиулла абзый – болар икесе дә хыялдан алынган исемнәр генә. Бу ике крәстияннең чын исемнәре ничектер, без белмибез. Бер факт кына беләбез.

Арча кантоны Янгул волосте колхозына керергә теләп, ике крәстиян гариза бирәләр, ә колхоз идарәсе аларны, айлар буенча ялындырып, колхозга алмый йөртә. Соңыннан алар волкомга килеп, волком секретареннан резолюция алгач кына колхозга керә алдылар.

Бу Вәлиулла абзыйлар башка авылларда да юклар микән?

## КӨТӘЛӘР

Беренче кар явуны халыкның быелгы кебек бервакытта да көткәне юк. Бик күпләре инде:

– Әллә быел бөтенләй кар яумасмы? – дип тынычсызлана башладылар.

Дөнья яратылганнан бирле халыкның беренче карны болай сагынып көткәннәре юк дисәк, тайпылыш ясамаган булырбыз.

Ләкин сезнең күбегез бу нәрсәгә ышанырга теләмәс.

Җәй көтәләр дисәң: хәер, диярсез, җәен отпускалар башлана, кырларда, урманнарда чәчәкләр үсә, бакчаларда гуляниеләр башлана, дачаларга чыгалар, балык тотарга йөриләр, мәхәббәт сезоны башлана...

Ә кышын нәрсә? Мороз борынны туңдыра, җил теңкәгә тия, һәркемнең башына җылы киемнәр табу заботасы төшә, утын, чорт... нинди җүләр кышны сагынып көтсен, вот чудак! диярсез. Ләкин һәммәгез ялгышасыз.

Беренче кар яву, бу хәзерге көндә бик күп кешеләр алдында актуаль мәсьәлә булып тора.

Мәсәлән, гомердә татар газетасы укымаган ответработник һәр көн «Кызыл Татарстан» газетасыннан обсерватория хәбәрләрен эзләп карый.

Тизме кар явар? Шуны беләсе килә.

Авыл советы председателе юк йомыш табып районга чаба, анда таныш докторы Иван Ивановичка кереп, барометр каравын сорый.

Барометр һава алмашынуны, кар явуны күргәзмиме, шуны беләсе килә.

Кулак өендә утыра алмый, йортына, бакчасына чыга, бүре кебек яшерен генә каранып бакчасын әйләнә. Һавага карый. Тизме кар явасын беләсе килә. Иген хәзерләү өчен районнарга җибәрелгән ответработниклар, сельсоветка килеп төшүләре белән, авылларындагы иң карт кешегә алып баруны сорыйлар:

– Сездә сиксән яшькә җиткән картлар бармы?

– Бар!

– Мине шул сиксән яшьлек карт торган йортка кунарга төшерегез, – ди. Ә кичен шул сиксән яшьлек карттан, сүз уңае китереп: – Ни... син, бабай, картая-картая барометрга әйләнгәнсең инде, ә?

– Нәрсә ул бармител?

– Әйтәм, һава алмашынуын сизә торгансыңдыр. Картлар һава алмашынуны тиз сизәләр бит.

– Әйе, улым, картайгач шулай инде, һава алмашынырга булса, вата, сындыра башлый...

---

Икмәк хәзерләүче авылда ятканда атналар буе картның ыңгыраша башлавын, барометрга әйләнгән чагын көтә башлый.

Райисполком, фабком, завком, месткомнар, колхозсоюз, хлебсоюз, союзсоюзлар – һәммәсе бу мәсьәлә белән баш ваталар:

– Тизме кар явар?

Дөрес, аларның һәммәсе өчен дә кыш үзе белән бик күп забота алып килә.

Хатыннары:

– Утын кирәк, балаларга киемнәр, киез итекләр кирәк, фәлән-төгән, – дип колак итләрен ашыйлар.

Ләкин бу нәрсәләр кыш көтүчеләр алдында чүп булып кына торалар, чөнки... бабайлар «калган эшкә кар явар» дигәннәр.

Ә авыл советларының, райисполкомнарның, завкомнарның, фабкомнарның вә әлхкомнарның әллә күпме эшләнми калган эшләре, кар астында калырга тиешле үтәлми калган кампанияләре бар.

Беренче кар яуса, шул үтәлми калган эшләрне кар каплар, кар күмеп китәр дип көтәләр...

Хәтта сыйнфый дошманнардан булган кулак та, җиргә күмгән икмәген кар күмсен дип, кар явуны көтә...

Тик Казанны утын белән тәэмин итүче учреждение генә (аты корсын!) кышны көтми. Ул хакта уйламый да... Хәтта аның өчен мәңге яз дәвам итәр төсле...

## ЧИРАТЛАР ПАТШАСЫ

*(Обыватель трагедиясе)*

Җәлтәфинов квартирына кереп, портфелен өстәленә куеп өлгермәде, хатыны Җәмилә, йокы бүлмәсеннән чыгып, аның муенына асылынды:

– Уф, арыдым, җаным, көн буе чираттан чиратка йөри-йөри эштән чыгып беттем. Чиратта торып носкилар, оеклар алдым. Водниклар кооперативында алма бирәләр, дигәч, чабып барып, чиратта торып, биш кило алма алдым. Печән базарында беренче магазинда кәтүк җеп бирәләр икән... – дип, көн буе торган чиратларның, алган әйберләрнең отчетын бирә башлады һәм, шуның мөкяфәтен теләгәндәй, иреннән иркәләү сораган тавыш белән: – Базарда носоклар хәзерге көндә 4 сум тора, ә мин 70 тиенгә алдым, – дип, чиратта торуыннан килгән файдаларны саный башлады.

Җәлтәфинов үзенең шундый акыллы хатынга өйләнә алуы өчен һәрвакыттагы кебек эченнән генә шатланып куйды.

Җәмилә, дөрестән дә, уңган хатын... Ул бер тиенне дә әрәм-шәрәм итми. Киресенчә, төрле ялган юллар белән карточкалар, ордерлар табып, хөкүмәт кибетләреннән чират торып төрле товарлар ала һәм аларны өч-дүрт бәя

белән базарга чыгарып сата, шулай итеп, көндәлек расходларын каплап бару өстенә Җәлтәфиновның жалованье, 140 сумнар гына булса да, янга кала бара.

Бүген Җәмилә кырык чиратта торып кырык беренче итеп озын койрыклы бер чиратка килеп баскан иде, уңышсыз булып чыкты. Күршеләреннән сораша торгач, бу чиратта талон белән тәмәке бирелүен белде. Бер чиратны да калдырмый торган Җәмиләне бу чиратка талонсыз торырга ярамау хурландырды, үзен кешеләрдән кай ягы беләндер ким хис итте. Эченнән генә Җәлтәфиновның хәзергә кадәр тәмәке талоны алмавына ачуланды һәм, тәмәкенең киоскадагы бәясе белән базардагы бәясен белеп кайтыр өчен, базарга китте. Анда киоскада 10 тиенгә сатыла торган тәмәкенең бәясе 1 сум 30 тиен булуны белгәч, Җәмиләнең иренә тагын да ачуы кабарды. Җәлтәфинов эштән кайту белән, Җәмилә:

– Нигә син тәмәке талоны алмыйсың? – диде.

– Мин тәмәке тартмыйм ич!

– Халык әнә тартса да, тартмаса да ала... Базарда тәмәкенең бәясе 1 сум 30 тиен, – дип, Җәмилә иренә айга ун кап тәмәке алып, аны базарга чыгарып сатканда, 9 сумнар файда китерәсен сөйләп китте.

Җәлтәфинов эченнән генә үзенең шундый акыллы хатынга хуҗа була алуына тагын бер кат шатланып куйды.

Икенче көнне Җәлтәфинов, месткомга кереп, секретарьдан тәмәке талоны бирүне сорады. Местком секретаре:

– Син тәмәке тартмыйсың ич! – дигәч, Җәлтәфинов:

– Юктан гына тартмыйм, – дип куйды һәм, местком секретареннан сорап, гомерендә беренче кат тәмәке тарта башлады.

Җәмилә Җәлтәфиновның алып кайткан талоны белән рәхәтләнеп тәмәке сата башлады. Аның чират мәсьәләсендәге бер китек ягы да төзәлгән кебек булды. Ул инде үзен чиратларның анасы, бер чираттан да калмый торган чират патшасы итеп хис итә башлады.

Җәмилә, «син тәмәке тартмыйсың» дип әйтмәсеннәр һәм талонны кире алмасыннар дип, Җәлтәфиновка местком секретаре алдында тартыр өчен һәр көн өч тәмәке бирә башлады. Җәлтәфинов башта хатынының тәмәке бирүенә бик игътибарсыз гына булса да, соңга таба Җәмиләнең көндәлек порция тәмәке бирүен түземсезлек белән көтә башлады. Ә соңга таба Җәлтәфиновлар семьясында зур үзгәреш булды. Бер яктан, чиратларда йөри-йөри Җәмилә бик нык үзгәрде. Җәлтәфиновның йомшак кына телле хатыны исерек итекчеләр кебек гаҗәп кабахәт тел белән сүгенүгә өйрәнде. Ялган талоннар белән мал алып йөрүе өчен милициягә эләкте, ябылып чыкты. Җәлтәфиновның үзен дә, хатының сәүдә итә дип, эштән чыгардылар.

Элек местком секретаре алдында гына тәмәке тарта торган Җәлтәфинов, урынсыз калуына карамастан, талонына алган тәмәкеләре өстенә көн саен 1 сум 30 тиенгә базардан талашып-сугышып тәмәке алдыра башлады.

Матур гына яшәп килгән Җәлтәфиновлар гаиләсе бозылды. Җәлтәфиновның хатыны Җәмилә Җәлтәфиновны сүгү өчен көн саен базардан усал сүгенү сүзләре җыеп йөри башлады.

**ТИЗЛЕК НӘРСӘДӘ**

– Рәхмәт сезгә, иптәш Билалов, бик рәхмәт! – дип, Сәйфетдинов, почта начальнигы иптәш Билаловның кабинетына кереп, аның белән таныш булмаса да, кулын кысып сөйләнә башлады.

Билалов: «Бу бәхетсез кешегә нинди яхшылыгым тиде икән», – дип уйлап та өлгермәде, Сәйфетдинов аның кулын үбеп алды һәм:

– Син мине үлемнән коткардың, ничек рәхмәтләр укырга, – дип, күз яшь аралаш сөйли башлады: – Минем хатыным белән балаларым Казанда торсалар да, мин үзем Свердлов шәһәрендә эшли идем. Моннан дүрт ай элек хатыныма, балаларыма дип 50 сум акча җибәрдем...

Почта начальнигы иптәш Билалов:

– Соң син үзең акча җибәргәч, ни өчен миңа рәхмәтләр укыйсың? – дип сорады.

Сәйфетдин сүзендә дәвам итте:

– Син актыгына кадәр тыңла. Шулай. Акча җибәрүемә бер ай үтү белән, бер танышым Свердловка килеп, хатынымның бер егет белән гулять итеп йөрү хәбәрен китерде. Мин тиз генә отпуска алып Казанга кайттым. Хатыным, кабахәт, балаларымны калдырып, егете белән качып киткән иде. Балаларымны үзем белән алып китәргә дип уйлаганда гына, хурлыктан эчәргә сабыштым. Кесәмдә булган акчамны да, нәрсәләремне дә сатып эчтем.

Казан почта начальнигы иптәш Билалов, бернәрсә аңламый, күзләрен зур итеп ачып, Сәйфетдиновка карады. Сәйфетдинов Билалов иптәшнең тагын бер кат кулын үбеп алды.

– Кайтырга юлга бер тиен акчам калмады. Шуннан үлү турында уйлый башладым. Бер көн уйладым, ике көн уйладым, карыйм, балалар кызганыч. Шулай да өченче көнне үземне үтерергә карар бирдем. Бик рәхмәт сиңа!.. Син мине үлемнән коткардың... – дип, Сәйфетдинов сыгылып-сыгылып күз яшьләрен түгә башлады.

Почта начальнигы Билалов иптәш:

– Бу кешенең акылына зәгыйфьлек килгән, күрәсең, хатынын бик ярата булган, ахры, – дип кызганып куйды.

Сәйфетдинов:

– Шуннан соң, балаларым белән исәнләшеп, трамвай астына ташланырга дип чыкканда гына, ишектән синең почтальоннардан берсе минем кулыма 50 сумлык повестка тоттырды. Ул минем моннан өч ай элек сукин сын хатыныма җибәргән акча булып чыкты.

Билалов иптәш кызарып куйды. Акчаның бу кадәр кичегеп тапшырылуына объектив сәбәпләр эзли генә башлаган иде, Сәйфетдинов аның кулын үпте дә шатлыклы тавыш белән:

– Мин хәзер котылдым инде. Син мине дә, акчамны да сукин сын хатынымнан коткарып калдың, – диде. Һәм: – Мин хәзер Казаннан китә алам, – дип, Билаловның кулын кысып, йөзенә дуслык елмаюы чыгарып, көтмәгәндә, ашыгып кабинеттан чыгып китте. Казан почта начальнигы иптәш Билалов үзенең кешегә шундый зур шатлык бирә алуына шатланып эшенә тотынды.

———

Бу хикәяне укучы иптәш Билалов, бәлки:

– Ялган, минем белән гомердә дә мондый вакыйга булганы юк! – дияр.

Җаваплашып маташмыйбыз.

Билалов иптәшне бу нәрсәнең булуына яки булуы мөмкинлеккә ышандыру өчен тагын бер генә факт китереп үтәбез. Бусы әле күптән юк кына булган вакыйга.

Казаннан 60 чакрымдагы Әтнәдән «Кызыл Татарстан» газетасына җыелган 22 данә, «Колхоз гәзите»[1] кергән 44 данә подписка, Әтнәдән 22 сентябрьдә чыгып, Казанга 24 нче сентябрьдә килеп җитсә дә, Казан почта конторасы белән, Татиздатның[2] арасы бары 27 метр гына булуга карамастан, шул подписка салынган заказ бары 21 октябрьдә генә (27 тәүлектән соң) килеп җитә. Анда да аны почта үзе тапшырмый, ә Татиздаттан барган бригада үзе эзләп таба. Билалов иптәш, бәлки, моңа да ышанырга теләмәс. Ләкин инде бусы үтмәс. Бу вакыйганың шаһитлары бик күп. Хәтта Татиздатның экспедиция мөдире иптәш Бәхтияров[3], бу вакыйга мөнәсәбәте белән зур бер демонстрация ясап, үзенең бөтен сотрудникларын ияртеп почта белән Татиздат арасын үлчәп тә чыкты. Соңыннан, әллә кайдан кара таракан табып алып, аның аякларын карага буяп, кәгазь өстенә җибәреп, кара тараканның сәгатенә ничә сантиметр йөри алуын да үлчәп чыгарды.

Бәхтияров иптәш хисабына караганда, кара таракан Татиздат белән почта арасын тәүлегенә 32 мәртәбә, ә 27 көнгә 969 мәртәбә әйләнеп чыга ала икән.

———

Иптәш Бәхтияров, үзенең «иҗатын» «Чаян» идарәсенә биргәндә, Казандагы һәм урыннардагы почта органнарының башка бик күп җитешсезлекләрдән зарланып утырды.

Без тыңлап кына утырдык. Кара таракан белән чакрымнар үлчәп йөрергә вакыт табучы иптәш Бәхтияров үзе өстеннән: «Чаян» килми», – дип зарланып килгән хатларны күргәзмәдек. Ни булса да, Билалов иптәшнең күңеленә авыр булган кебек, аның да күңеленә авыр булыр дип уйладык.

## БЮРОКРАТ

Габдулла агай, совет ишек төбенә килеп җитүгә кадәр, юл буена:

– Менә барырмын да әйтермен, мин – батрак, син миңа налог салырга хаклы түгелсең, диярмен... Садыйк кулакка әнә, гомер-гомергә бай булса да, минем кадәр генә налог салгансың... Миңа...

Ул хәтта, советка баргач, өстәлне сугып:

– Миңа андый зур налог салырга да не имеешь полный право, – дип әйтергә дә җыенган иде, хәтта авыз эченнән юлда шул сүзне әйтеп тә карады. Тик менә совет ишегалдына килеп җиткәч кенә, аның гайрәте чикте. Ул, авыл советы председателе Мөхәммәтшаның үзе белән ничек сөйләшәчәген уйлап, шүрләп тә куйды. Габдулла агай аның белән берничә сөйләшеп караган иде инде.

Сәгать унике булуга карамастан, Мөхәммәтша әле советка килеп өлгермәгән иде, Габдулла агай, совет йортындагы плакатларны карый-карый, аны көтә башлады. Сәгать бер тулып килгәндә генә, иске күн портфелен күтәреп, Мөхәммәтша килеп керде. Ул, килеп керүе белән:

– Моннан чыгып торыгыз, секретарь белән сөйләшәсе чикретный эшләр бар, – дип, үзен көтеп утырган берничә крәстиянгә чыгарга кушты. Соңыннан, өстәленә бик эре генә утырган килеш, коры гына:

– Ни йомышың бар? – дип, килгән кешеләрне кабул итә башлады. Габдулла агайга: – Йомышыңны кыска итеп сөйлә, юк-бар сүзләр белән вакытны әрәм итмә, – диде һәм эшләгән булып өстәле өстендәге кәгазьләрне актара башлады. Йомышын әйтергә аптырап торган Габдулла агайга: – Йомышың булмаса, вакыт әрәм итеп йөрмә, минем эшем муеннан, – дип, портфелен күтәреп чыгып та китте.

Мөхәммәтша үзе белән районга бергә килгән кооператив председателе Нурмөхәммәткә чәй хәзерләргә кушты да, өзгәләнеп беткән портфелен култыгына кыстырып, райбашкармага табан китте. Райбашкармада артык күп эшләре булмаса да, районлашкач кантоннан күчкән яңа район башкарма комитетының председателен күреп китәргә, аның белән танышып чыгарга булды.

Сәгать унбер булуга карамастан, район башкарма комитеты председателе әле эшкә килмәгән иде.

Аның «Рөхсәтсез керергә ярамый!» дип язылган ишеге төбендә Мөхәммәтша кебек берничә авыл советы председательләре аны көтеп яталар иде. Көтүчеләре гади крәстияннәр булмаганга, Мөхәммәтша алар белән бик тиз сөйләшеп китте. Колхозлар турында сөйләштеләр, яңа председатель турында сүз йөрттеләр. Сүз көрәштерә торгач, сәгать уникеләрдә райбашкарма председателе дә килеп керде.

Ул, иң элек секретарен чакырып алып, берәр сәгать нәрсәдер киңәшкәннән соң, көтүчеләрне кабул итә башлады.

Мөхәммәтшага чират җиткәндә, инде сәгать ике булган иде. Ул керү белән ишек төбендә тукталды. Райбашкарма председателе, аны күрмәмешкә салынып, ун минутларга якын нәрсәдер портфеленнән эзләп маташты. Мөхәммәтша тамагын кыргач кына, ул:

– Сезгә нәрсә кирәк? – диде һәм: – Йомышыңны кыска итеп сөйлә! Юк–бар сүзләр белән вакыт әрәм итмә! – диде дә, аның сөйләгәнен тыңламый, үзенең эшендә дәвам итте.

Мөхәммәтша кабинетка керүгә кадәр: «Менә керермен, бик яхшы итеп исәнләшер, хәлемне сорашыр, кайсы авылның председателе булуымны беләсе килер. Мөхәммәтша иң элек үзенең исемен әйтер, Шарман авылы председателе булуын һәм аның белән танышуына бик шат булуын әйтер», – дип хыялланып кергән иде. Райбашкарма председателенең болай каршы алуы бик нык каушатты аны һәм аның кинәт:

– Сезгә нәрсә кирәк? – дип коры гына сорап куюы да аны аптыратты.

Берәр зуррак, кирәклерәк мәсьәлә юк микән дип, яшен тизлеге белән башыннан ниндидер бер мөһим мәсьәлә эзләде. Таба алмагач:

– Мин – Шарман авылы председателе.

– Ни йомыш бар?

– ?..

– Йомышың булмаса, вакыт әрәм итеп йөрмә, минем эшем муеннан... – диде һәм секретаре янына чыгып китте.

Юлда Мөхәммәтша юл буенча Нурмөхәммәткә зарланып килде...

– Бөтен җирдә бюрократлар утыра, малай... Әйе, райисполком председателен әйтәм... Дөрес, мине ул бик яхшы каршы алды, хәлемне сорашты... Ә шулай да бик зур бюрократка охшый... – диде.

**ЧӘЧЛӘР АЯГҮРӘ**

– Сез застрахованныймы, юкмы?

Әгәр дә застрахованный булмасагыз, түбәндә басылачак Әлмәт райбашкармасының авылларга җибәргән документын укып чыгуга кадәр, докторга барып, йөрәгегезне каратып кайтыгыз. Йөрәгегез таза булса гына, бу документны укып чыгарга киңәш бирәбез. Булмый икән, йөрәгегез ярылып үлә икән, мәсьүлиятне үз өстебезгә алмыйбыз.

Шулай итеп, иптәшләр, документны укый башлыйбыз, менә аның беренче җөмләсе: «Согласно постановления рико сполусеинем сего рик предлагает незастрахованных убит...».

– Караул!

– Страховайт ителмәгән кешеләр, җаныгызны коткарыгыз! Ну ләкин алай куркуга төшәргә ярамый, бит РИК страховать ителмәгәннәрне атарга тәкъдим генә итә. Әгәр дә менә приказ бирелсә иде, эш башка булыр иде.

Шулай итеп, тынычлана төшеп, документның икенче җөмләсенә күчик. Беренче җөмләне укып йөрәгегез ярылмый калган булса, икенче җөмләсен уку ул кадәр куркыныч түгел. Чөнки, бер яктан, икенче җөмләдә сүз кешеләр турында бармыйча, котырган этләр турында барса, икенче яктан, ул җөмләдән бернәрсә дә аңлап булмый. Аңламагач инде, билгеле, куркып гакылдан шашу куркынычы да юк. Менә документның икенче җөмләсе: «Собаки бешенных и беглых застрахованных перевезать цепь случай будет таковых т.е. будет убить таковая компания проводить срочно».

Бу чәчләрне аягүрә торгызырлык документны язучыны котырган эт талап гакылына зарар китергән дияр идек, ләкин отношениенең астында мөхтәрәм РИК председателенең имзасы ялтырап ята.

Ул, бәлки, мин документны укымыйча гына кул куйган идем, дип акланырга тырышыр. Ләкин бер сорау:

Әлмәт районында язгы чәчү һәм башка шуның кебек кампанияләрнең артта калуларына РИКта утыручы кешеләрнең котырган эт кампанияләре уздырып йөрүләре сәбәп түгел микән?

## ТӨЗӘЛМӘСЛЕК ЛЕТУН

– Син нәрсә, тагын квартираңны алмаштырасыңмы?

– Әйе!

– Соң бит әле бу квартирга күчүеңә бер атна булганы юк.

– Булганы юк та...

– Соң?

– Өйрәнелгән. Заводтан заводка күчеп йөрергә ярамый, диләр. Производствога зарар килә. Мин шул элекке гадәт буенча квартирдан квартирга күчеп булса да йөрәкне басам.

## АКТАШ[1] БЕЛӘН АКТАНЫШ ТРАГЕДИЯСЕ

Советлар илендә, Башкортстан чигендә, Татарстан илендә Акташ һәм Актаныш районнары бар. Бу ике агай-эне атдаш районнар соңгы вакытта якага-яка ябышыр хәлгә килделәр. Ник дисәк, Актанышка кайтасы газета-журналлар, хатлар – Акташка, Акташка кайтасылары Актанышка кайталар.

Әле берсенә, әле икенчесенә барып йөри-йөри, газета-журналлар бөтен әһәмиятләрен бетереп кайталар. Хатлар хуҗаларын табалмый интегәләр.

Актанышлар:

– Акташлар безнең газеталарны укып рәхәтләнәләр, – дип сүгенеп йөрсәләр, акташлар:

– Актанышлар безнең җилкәдә көн күрәләр, – дип, актанышларга ачулары кабарып йөри.

Киләчәктә бу ике агай-эне арасында җәнҗал чыкмасын өчен, йә берсенең исемен алмаштырырга, яки почтада утыручы фокусникларны рәтлерәк эшчеләр белән алмаштырырга кирәк булачак.

## МӨГЕЗЛЕ ДУҢГЫЗЛАР

– Синең мөгезле атлар күргәнең бармы?

– Юк!

– Ә мөгезле дуңгызлар?

– Син нәрсә, гакылыңнан шаштыңмы әллә?

– Билгеле, кемнең дә гакылыннан шашканы юк, һәм хәзерге көндә аңа вакыт та юк, гакылдан шашу бик үк файдалы эш тә түгел. Әмма ләкин шуңа карамастан мөгезле дуңгызлар бар.

Совет учреждениеләренә кереп урнашкан ике аяклы дуңгызларны әйтә торгансың дип тә уйламагыз. Юк, дүрт аяклы, ярылган тояклы, зур корсаклы, кыска клиндер койрыклы, «хорык-хорык» итеп йөрүче, ак керфекле, сөйкемле, чып-чын мөгезле дуңгызлар бар. Алар Америкада да түгел, Африкада да түгел, хәтта СССРның башка өлкәләрендә дә түгел, ә Татарстанда, Татарстанның да Минзәлә кантонында яшиләр.

– То есть ничек, менә мин Минзәлә кантоныннан һәм һичбер вакытта да мөгезле дуңгызлар күргәнем юк, – диючеләр табылыр.

– Табылса, бигрәк тә начар. Хәзергә кадәр Минзәләдә яшәп тә мөгезле дуңгызларны күрмәү яки шул мөгезле дуңгызларның итеннән ясалган тәмле колбасаны авыз итмәү бәхетеннән мәхрүм булу ояты ул кешенең өстенә төшәчәк...

Минзәләдә мөгезле дуңгызлар барлыгы беленүгә кадәр, фән дөньясында Дарвинның[1] эволюция һәм революцияләр нигезендә иң түбән видтагы хайваннарның тәрәккый итә-итә иң югары формага килеп җитүләре хакыйкать булып саналыр иде. Ә бу вакыйга Дарвинның теориясен җимереп ташлый. Чөнки монда кире эволюция теориясе килеп чыга. Ягъни почтада утыручы кешеләр кирегә китә-китә шул дәрәҗәгә барып җитәләр ки, алар дуңгызга, дуңгызның да мөгезлесенә әйләнәләр.

Без, почта дуңгызлары турындагы сүзне соңга калдырып, чын мөгезле дуңгызларга күчик. Менә Минзәлә РИКына Татарстан Совнаркомы тарафыннан бирелгән телеграммны укыгыз:

«...Зоотехкомесиями должно быть обязательно отобрано с начало этой кампании укомплектованию первую очредь колхозам имени Воровского 150, техникум 20, домзаку рогатого свиней по требованием Вашиго района рогатого свиней 50. Случаех не достатчного наличия дойного укомплектовывайте молодняком. (Танылмый) сдаваете колхозам создание товарищество обобществленных в Вашем районе 680 голов рогатого свиней 62 овец...»

Бу телеграмманың төп нөсхәсендә мөгезле дуңгызлар турында бер сүз дә юк.

Ләкин почта-телеграфтагы фокусникларга ни дә мөгез чыгару кирәк.

РИК бу мәсьүлиятсез халыкларга үзләренә мөгез чыгарып куяр әле дип уйлыйбыз.

## ҮЗЕНӘ ЭЛӘКТЕ

СССР Үзәк башкарма комитеты циркулярларның телләрен җиңеләйтүне, аңлаешлы итеп язуны тикшерү өчен аерым комиссия төзеде.

*Газета хәбәре*

Арман авыл советы председателе үзенең секретарен чакырды да:

– Хәзер үк тирә-як авылларга десятниклар җибәр. Әгәр шул җибәрелгән авылларга районнан берәр инструктор яки начальник килеп төшсә, ничек кенә булса да безгә алып килсеннәр. Кара, йокламасыннар, булмаса, эшләр харап,– диде.

Председательнең приказы җиренә җиткерелде. Ә дүрт сәгатьтән десятникларның берсе күрше авыл аркылы тимер юл станцасына үтеп барышлый туктаган иптәш Шакировны эләктереп, чанасына салып, гөрләтеп китереп тә ташлады.

Председатель шатлыгыннан дөньясын онытты.

– Документны да күрсәтмә, кирәге дә юк, синең болай да район кешесе икәнеңне беләбез,– диде һәм «ничек сине монда җил ташлады» дип, кулларын уа-уа тирәсендә йөри башлады.

Шакиров иптәш үзенең станцага үтешли бер авылда туктаган җиреннән менә бу десятникның, чабуына ябышып, бернәрсә белән санашмый, чанасына салып, үзен монда алып килүен зарланып сөйләп бетерүенә, председатель десятникның барып аркасыннан ук какты.

– Молодец, аны шулай кирәк, – дип куйды. Һәм Шакировка: – Мин үзем аңарга шулай кушкан идем, син аңарга ачуланма инде. Бит сезне шулай алып килмәсәң, гомердә дә килмисез, – диде.

Шакиров:

– Ну, нәрсә йомышыгыз бар? Чәчүгә ничек хәзерләнәсез? – диде.

Председатель:

– Йомышлар бик күп, хәзер сөйләшәбез. Ә чәчүгә әле бүген генә хәзерләнә башладык.

Шакиров:

– Ничек алай? Бит тиздән чәчүгә чыгу вакыты җитә. Сезгә бу хакта гыйнвардан алып көн саен кулланмалар килеп торырга тиешле.

– Әйе, ул кулланмалар көн саен кулыбызга килеп тора, менә сезгә безнең йомышыбыз да шул кулланмалар турында иде, – дип, председатель аның алдына бер папка кәгазьләр китереп куйды.

– Менә, зинһар, безгә аларны аңлатып бир әле, – диде.

Шакиров алдына куелган кәгазьләрнең берсен кулына алып, озак кына әйләндереп-әйләндереп карады. Машинкада танымаслык рәвештә шайтан теле белән язылган бу язуларны укып карарга маташса да, булдыра алмый өстәлгә ыргытып һәм урыннан торып:

– Менә авылларга нинди шайтан аңламаслык кулланмалар җибәрәләр икән! Ярый, районга кайткач, мин ул бозык башларның кирәкләрен бирермен. Мин аларны судка бирермен! Бу вредительство, бу әллә нәрсә бу! – диде, ачуыннан өстәлгә китереп сукты.

Председатель шатлыгыннан сикереп куйды. Шакиров, кесәсеннән блокнотын алып:

– Мин аларга күргәзермен ничек мондый кулланмалар җибәрүне, кем язган бу циркулярны? Мин аларның фамилияләрен язып алыйм әле, – дип, кулланмаларның имзасына күзен төшерде.

Шакиров, кәгазьнең соңгы битендә үзенең имзасы ялтырап ятуны күргәч, колакларына кадәр кызарып икенче кәгазьне алды.

Анда да аның үз имзасы ялтырап ята иде.

**ҮЗСҮЗЛЕ КЕШЕ**

Авыл советы председателе Нуркәев хайваннарны суярга ярамау, суйган кешеләрдән штраф алыну турындагы игъланны совет йортына ябыштырып куйды да, шундагы крәстияннәргә карап:

– Карагыз аны, мин, агай-энеләр, күп сөйләнергә яратмыйм, миндә һәрнәрсә законча булырга тиешле, – диде. Һәм бик коры гына рәвештә өстәп куйды: – Законнан чыгып эш итәсең икән, үзеңә үпкәлә. Мин, агай-эне, фәлән дип тормам, штраф салырга туры килә икән – штраф, ябып куярга туры килә икән – ябып куярга да күп алмыйм, мин бер кат сөйләргә яратам. Мин үзсүзле кеше, миндә һәрнәрсә законча булсын, – диде һәм, өстәленә утырып, махоркасын төрә башлады.

Нуркәйнең дәһшәтле сүзләреннән соң крәстиян агайлар игъланга нәрсә язылганны белсәләр дә, тагын бер кат игълан тирәсенә җыелып, игъланны карый башладылар. Шул вакытта советка ашыгып Ибрай агай кереп килде. Ул крәстиян агайлар укып торган игъланга күз йөртеп чыкты да, урындыкка утырып, тыныч кына:

– Син, Нуркәй, әбъявлиния ябыштырасың да ябыштырасың, ә Садыйк кулак анда караңгыда гына сыер суеп ята, – диде.

Нуркәй урыныннан сикереп торды:

– Ничек? Сыер суя? Кем? Садыйк кулак законнан тыш эш эшли. Штраф аңарга! Сыерын конфисковать, үзен ябарга! Мин күрсәтермен аңарга! – Ул папкасын кулына кыстырды да: – Карап карыйк, аның таш капчыкта утырасы килә... Попрубуем, – дип ашыгып чыгып китте.

Нуркәй Садыйк кулакның йортына барып кергәндә, Садыйк кулак, дөрестән дә, караңгы гына бер урында сыер тунап ятадыр иде. Нуркәй килеп керү белән, ул пычагын карга кадап куйды да, алъяпкычына кулын сөртә-сөртә, Нуркәйгә каршы килә башлады.

Нуркәев:

– Ни... Сыер суеп ятам диген... Штраф түлисең килде? Законга баш иməскә телисең... Карап карыйк, акт язгач нишләрсең икән? – Ул, папкасын ачып, кесәсеннән карандашын эзли башлады.

Садыйк кулак гаепле кешеләрчә:

– Бөтен нәрсә күз алдында инде, Нуркәй, гаепне танар хәл юк. Билгеле, хәзер син минем өстемнән акт та яза аласың, төрмәгә дә утырта аласың, гаеп миндә, үз гаебеңнән беркая да кача алмыйсың инде, – диде.

Нуркәев, карандашын табып, папкасын тезенә куеп, акт язарга хәзерләнде.

Садыйк:

– Нуркәй энем, монда урамда акт язарга уңайсыз, караңгы да, салкын да, акт язарга булгач инде, әйдә, өйгә кер! Анда кара да бар, өстәл дә. Язарга булгач, иркенләп язарсың. Нишлисең, билгеле, болай булгач, акт язмый калмассың инде, – диде.

Нуркәев:

– Ярый, әйдә, карап карыйк ничек совет власена каршы баралар, – диде.

Алар Садыйкның өенә табан атладылар.

Садыйк, кулларын уа-уа энесе Хәнәфигә борылып:

– Син, Хәнәфи, әйдә тирене туный тор, – диде. Үзе Нуркәй артыннан өйгә кереп китте.

Ә бераздан алар икәүләп өйдән чыктылар. Нуркәевнең йөзе яхшы ук кызарган иде. Ул Хәнәфинең тире тунавына карап-карап торды да:

– Ни... алай тире туныйлармыни, өстәнрәк ал, өстәнрәк, – диде.

Садыйк кулак энесенә карады да:

– Нуркәй агаңның өйрәтүен тыңла, аңардан сабак ал! Аның мәрхүм атасы менә дигән оста сугым суючылардан саналадыр иде. Ул, мәрхүм, берүзе бер көн эчендә ике-өч сугым суеп, итен дә сатып өлгерәдер иде, – диде.

Нуркәев атасы мәрхүмне күз алдына китерде.

Ә бераздан соң ул өстендәге киемен салып ташлады да, Хәнәфинең кулыннан пычагын алып, сызганып, Садыйк белән беррәттән торып, сыер туный башлады...

## ИДАРӘГӘ ХАТ

Мөхәррир иптәш!

Хатыбызны басуыгызны үтенәбез.

Без, СССРның бөтен шәһәрләреннән Чаллы почтасына җыелган хатлар, журналлар, посылкалар, безне көтеп ятучы иптәшләргә «Чаян» аркылы үзебезнең сәламәт булуыбызны һәм түбәндәге нәрсәләрне белдерәбез.

Озак вакытлар юлда йөреп, арып-талып, без Чаллы почта бүлегенә килеп кердек.

Чаллы почтасы безне бик яхшы каршы алды. Һәммәбезне уңайлы шкафларга урнаштырды.

Почтада безнең артыбыздан уход бик яхшы. Тынычсызлый торган нәрсә дә юк. Айлар буе тыныч килеш ял итеп ятабыз. Почтаның мөдире Тарасов иптәш безгә ял итүгә кирәкле булган шартларның бөтенесен булдырырга тырыша. Кыскасы, Чаллы почта ял йортларында безгә ял итеп яту бик күңелле.

Арып-талып, эштән чыгып килгән авыру посылкалар рәхәтләнеп ял итеп, тазарып чыгып китәләр.

Посылкаларга, хатларга ял итү вакыты чикләнмәгән. Мәсәлән, Казан финотделы тарафыннан Чаллы финотделына җибәргән Посылка Посылков иптәш, 12 ноябрьдә Чаллы почта ял йортына кереп, 35 көн рәхәтләнеп ял итеп, тазарып чыгып китте. Шулай ук Казаннан Чаллы райбашкармасына килгән посылка, 24 ноябрьдә Чаллы почта ял йортына кереп, 34 тәүлек ятып ял итеп чыгып китте. Казаннан Осоавиахимга[1] җибәрелгән иптәш Посылка Авиахимович – 37 тәүлек, Ык Тамагыннан Союзхлебка җибәрелгән Посылка иптәш Союзхлебович – 29 тәүлек, башка бик күп посылкалар 26, 27, 30 тәүлек рәхәтләнеп ял итеп, рәхмәт әйтеп чыгалар. Дөрес, эчләрендә май күп булган кайбер буржуй посылкалар озак яту сәбәпле авыруга да сабышкалыйлар.

Шулай да кайбер ашыгыч циркулярлар, чыгарга ашыгып, тизрәк җибәрүне сорасалар да, почта ял йорты мөдире Тарасов аларга үзенең киңәшләрен биреп тынычландырып тора:

– Ашыгырга ничу, – ди, – ял итәргә мөмкинлек биргәндә ял итеп калыгыз, – ди.

Һәм дөрестән дә шулай бит. Язгы чәчү кампаниясенә карата җибәрелгән кайбер циркулярлар тынычсызланалар тынычсызлануын да, ләкин бит әле кар эри башлаганы юк. Сукага да чыкканнары юк бит әле. Бүген әле ял йортында бер күңелсезрәк вакыйга булып алды. Безнең арабызга килеп ике ай ял итеп яткан бер Хат иптәш, ял йортыннан чыгып, кулында булган адресы белән барырга тиешле кешесенең йортына барса да, ул кеше Чаллыдан китеп калган. Елап, күз яшьләрен түгеп, безнең яныбызга кире кайтты. Хәзер кая барырга белми, мескен.

Без бу хат белән журнал аркылы Чаллы почта мөдире Тарасовка безгә ял итәргә мөмкинлек бирүе өчен рәхмәтләребезне белдерәбез һәм аның бу хезмәтләре өчен берәр орден белән бүләкләүне сорыйбыз. Шуның белән бергә без барып чыгарга тиешле кешеләрдән, әгәр Чаллыдан китә калсалар, почтага кереп, китүләре турында берәр записка һәм адресларын калдыруларын үтенәбез.

Чаллы почта ял йортында ике ай ял итеп ятучы карт Посылка Посылков.

Чаллы почта ял йортында ятучы Хат Хатов.

Гыйнвар аеннан бирле ял итүче «Яшь ленинчы»[2], «Кызыл Татарстан» газеталары һәм Чаллы почта бүлегендә ял итеп ятучы бу хатны «Чаян»га язучы «Чаян»ның 1 нче ном. Кәрим.

## «ЧАЯН» ХОЛОДИЛЬНИГЫ

Май ае дию белән һәркемнең башына чәчәкләр, гөлләр, урман, су буйлары килеп төшүе мөмкин. Но ләкин һәркемнең башына шул чәчәкләр генә килеп төшү необязательно.

Берәүләрнең башына бөтенләй икенче әйберләр, мәсәлән, холодильник, тоз кебек әйберләр килеп төшәргә мөмкин. Һәм бу бик табигый булачак.

Май ае бик эссе айлардан санала. Бу айда бер өстәл астына озак мөддәткә сакланырга дип куелган кайбер карарларның бозыла башлаулары, тозлауны сораулары мөмкин. Шулай ук кайбер заводларның май ае планнары да, әйтик, май аеның үзендә үтәлеп бетмәсә, июньдә инде тозламый сакларга һичбер мөмкин түгел.

Җәй айлары өчен «Чаян»га да гаҗәп дәрәҗә күп тонна тоз кирәк була.

Чөнки май, июнь планнарын үтәмәгән учреждениеләрнең, завод-фабрикаларның планнарын гына түгел, үзләрен дә бозылудан саклау өчен бозыла башлаган урыннарына тоз сибәргә туры килә.

Җәй аенда йомырка эшендә эшләүчеләргә дә күп кенә тоз тотарга туры килә. Сез үзегез беләсез, йомырканы тозсыз ашап булмый. Ә соң йомырка хәзерләүче кайбер агай-энеләргә законсыз рәвештә урлап калынган йомыркаларын ашарга әз генә тоз кирәк дип уйлыйсызмы? Шулай ук, әйтик, май, июнь айлары керү белән, гаҗәп дәрәҗәдә сасыган ит исе тарала башлады. Сез инде бу иске Казан үзәк кооперативы столовойларыннан гына таралган ис дип уйлыйсыз, билгеле. Ләкин ялгышасыз.

Бу ис, җанкисәкләрем, Татхлебшефсоюз, Союзмясо учреждениеләре ягыннан да бик борынга бәреп тора.

Мәсәлән, Алексеевский районында хәзерләнгән итнең 22 тоннасы кая киткән дип беләсез?

Билгеле, очып китмәгән. Законсыз рәвештә үзләштерелеп яшерелгән дә, эсселәр башлану белән, ул итләр ислənə башлаган. Ә борыны яхшы ук сизгер кешеләр ул итләрне ис буенча эзләп тапканнар.

Бу итләрнең ислəнүе дә тоз җитмәгәнлектән. Аннан соң шул ук Союзмясоның Октябрь, Шөгер, Балык Бистәсе районнарында ит заданиесе ни өчен 50 процент кына үтәлгән?

Чөнки ул учреждениеләрне тозлау, борычлау җитмәгәнлектән.

Шулай ук, әйтик, быел Татарстанда балык тоту планы ни өчен тиешле дәрәҗәдә үтәлми?

Тоже тоз җитмәгәнлектән. Сез тагын балыкларны тозларга тоз җитмәгәнлектән үтәлмәгән дип уйламагыз. Юк, балыкларны түгел, бәлки балык тоту эше белән юлбашчылык итүчеләрне үзләрен тозлау бурычлары җитмәгәнлектән ул план үтәлми.

Быел Татхлебшефсоюзда да, Союзмясода да үз карауларында булган учреждениеләрне тозлау өчен бик күп тоз кирәк булган кебек, аларны үзләрен бөтен инструкторлары белән тозлау өчен дә «Чаян»га бик күп тоз кирәк булыр төсле тоела.

Шулай итеп, иптәшләр, ни өчен май, июнь айларында тозның күп кирәк булуының серен аңлагансыздыр дип уйлыйм.

Быел җәй айлары бик эссе булырга чамалый. Менә шуны күздә тотып, киләсе номерлардан «Чаян» журналы үзенең каршында холодильник ачарга хәзерләнә. Билгеле, холодильник булмый торып, бер тоз белән генә бернәрсә дә эшләп булмый. Шулай итеп, иптәш чаянкорлар, башлары бозыла башлаган тозсыз кешеләрне «Чаян» холодильнигына җибәрә башлагыз.

*Сәлам белән Чаян.*

**«ТАҢ»**

**Картның әле яшисе килә**

Урам уртасыннан чәче көмешләнгән яланаяк бер карт үтеп бара. Карт кулына зур гына кашык тоткан.

– Картның әле яшисе килә, күрәсең, – ди минем иптәш.

Дөрестән дә, ул минем тарафтан бирелгән бөтен сорауларның очын ашау мәсьәләсенә китереп тери, дөрестән дә, картның әле ашыйсы да, яшисе дә килә:

– Мин җитмеш биш яшьлек карт, быел җәй колхозга керүен кердем дә, куркам. Эшләргә хәл юк. Ә колхозда эшләмәгән кеше ашамас та, – ди.

Бичара карт. «Алай түгел, бабай» дигән җылы сүзне ишетергә теләгән кебек, безгә сорау билгесе тулы йөз белән карый.

Кулаклар үзләренә карата чыгарылган бу бөек лозунгны да безнең үзебезгә каршы юнәлдерергә тырышканнар. Чәче көмешләнгән әбиләрне, әле ашыйсы, яшисе килгән картларны алар, «үлем куркынычы» белән куркытып, колхозга кертмәскә маташалар.

**Бердәнбер – «ялгыз»**

– Актаныш районы Такталачык авылында бер генә ялгыз хуҗалык калган, – диләр.

Авылдагы 450 хуҗалык колхозга керүгә карамастан, берүзе генә керми калган нинди кеше ул?

Элек аның исеме дә, фамилиясе дә булган. Ләкин аны хәзер инде «Заядливый единоличник!» дип кенә йөртәләр.

Мулла кушкан исеме дә, паспортында язылган фамилиясе дә онытылып бара.

Аның кемлеге турында сораулар бирә башласаң да, колхозчылар ни өчендер елмаюларын яшерә алмыйлар:

– Берәү инде шунда, – диләр.

Элек алай булмагандыр.

Алтмыш биш-җитмеш яшьләренә җиткән картның колхозга кадәр булган үткәннәре турында «бер начар сүз дә» сөйләмиләр:

– Урта хәлле крәстиян иде, – диләр, ләкин...

– Тавык йомыркаларына кадәр үзе җыя. Хатыны үлгәч, тагын бер хатынга өйләнгән иде... Түзмәде, китте...

Шул гынамы?

Такталачык авылы колхозчы картлары аны берәм-берәм димләп караганнар:

– Бергә яшәдек, бергә аш ашадык, бездән олагып калма, – дигәннәр.

Ләкин ул акыллы картларның сүзен тыңламаган. Хәзер инде колхозчылар аңа ялынмыйлар. Бер карт ярлы колхозчы:

– Аны инде шулай үз көенә кәмит итеп калдырырга кирәк, – ди. – Өстенә карап, борынгы заманны искә төшерербез, – ди.

Һәм ул, дөрестән дә, Такталачык авылында «Таң» колхозы музее өчен бер экспонат булып бара.

Урманга якын кыр читендә берьялгыз урак урып йөргән карт ерактан урманга кереп бара торган карт бүрегә охшый. Колхоз кырындагы урак машиналарының бер күтәрелеп, бер төшеп әйләнгән канатлары, тезелеп урак урып барган колхозчылар гүя ул ялгыз бүрене урманга куып баралар төсле.

Бичара.

Ул бүгенге көндә Такталачыкның туып килгән «Таң»ына үги әле.

– Ник?

Бәлки, кулакларның:

– Колхозда эшли алмаган картларны да, балаларны да ашатмаслар, ачтан үтерерләр, – дигән кабахәт агитацияләре тәэсирендәдер?

Бәлки, йөз еллар буе кешелек дөньясын изеп, иң түбән тормышта яшәргә мәҗбүр иткән «хосусый милек» богаулары картның кибеп барган кан тамырларына ябышып тутыкканнардыр?..

**Коллективның ирке**

Колхоз правлениесенә киң җилкәле, сирәк монгол сакаллы, урта яшьтә бер крәстиян килеп керә. Аның кояшта янган бите тир бөртекләре белән юылган. Ул колхоз председателеннән кәгазь сорарга дип килгән.

– Минем колхоздан чыгуым турында кәгазь бирегез, – ди.

– Нигә кирәк ул?

Билгеле, ул кәгазь аңарга бернәрсәгә кирәкми. Сизгер, үткен күзле колхоз председателе берсүзсез аның сораган кәгазен секретарена язып бирергә куша.

Менә кәгазь дә языла.

Печатьләр дә, куллар да куела.

Тик монгол сакаллы крәстиян колхоз правлениесеннән чыгып китми. Аякларын алмаштыра-алмаштыра өстәл янында тора. Үзенең уңайсыз хәлдә калуын сизеп булса кирәк, ара-тирә сөйләнгән сүзләргә катнашырга тели. Елмайган да була. Ләкин никтер аның сүзләре дә, елмаюы да табигый булып чыкмый. Кулына язылып бирелгән кәгазен дә ни өчендер кесәсенә куймый тора. Эш болай икән: Актаныш районында күптән түгел генә җыеннар булып үткән.

Авыллардан авылларга кунаклашып йөргәннәр.

Менә шул җыеннардан соң кинәт яз башы колхозга кергән унбишләп урта хәлле, «ашлыкны бергә җыюга без каршы» дигән нәрсәне сылтау итеп, «Таң» колхозыннан чыгарга гариза биргәннәр.

«Таң» колхозчылары, билгеле, аларны берсүзсез колхоздан чыгарганнар.

Шуннан? Шул ук крәстияннәр берәм-берәм:

– Ялгыштым, уклон булган, җыенда сөйләнгән кулаклар сүзенә иярелгән, – дип, гаризалар китерә башлаганнар.

Ләкин бу «уклонга эләккән» крәстияннәрнең берничәсен генә кире колхозга алганнар. Ә монгол сакаллы, киң җилкәле крәстиян әле һаман:

– Берәр җылы сүз ишетмәмме, үзләре шул турыда сүз башламасलармы? – дип, колхоз правлениесенә төрле йомышлар табып килә тора.

Минем:

– Әллә яраксыз элементмы? – дип соравыма колхоз активларыннан берәү минем колагыма гына:

– Түгел, урта хәлле крәстиян, аны без барыбер кире колхозга алырбыз, тик бераз акылга утыртыр өчен генә йөртәбез, – ди.

Бичара, акылга утырырга тиешле кешенең өстенә карап көләсе дә, елыйсы да килә. Ул әле тиз генә «акылга утырырмы», юкмы, белмим. Ләкин аларның тагын берсе турында колхоз председателе мондый бер әкият сөйли:

– 12 июльдә без уракка чыктык. Авылның ындыр табагыннан алып 18 нче бригада тезелеп уракка башлады. Менә шул вакытта...

Авыл эченнән бала-чагаларын ияртеп уракка баручы бер крәстиян карты күренгән. Ул «Таң» колхозыннан чыгарылып та колхозга кире алынмаган кешеләрнең берсе икән.

Карт, колхозчылар турысына җитү белән, адымнарын әкренәйткән. Туктап, башын түбән иеп, җиргә карап тора башлаган. Унбиш яшьләрендәге кызы белән малае әкрен генә аталарыннан аерылганнар да уракчылар янына килгәннәр. Алар күз яшьләре белән:

– Әтиләрне алмасагыз алмагыз, чорт с ней, безне алыгыз! Без колхоздан чыкмыйбыз! – дигәннәр.

Башын түбән салып, юлда басып торган карт та әкрен генә балалары рәтенә килеп баскан һәм колхозчыларның елмаюлары астында оялуыннан күзен күтәрмичә генә уракка бөгелгән:

– Колхозга алмасагыз алмагыз! Ләкин сездән олагыр хәл юк. Эшемне бергә эшлим, ашлык бүлгәндә мине колхозчы итеп санамасагыз да, үз өлешемне бирерсез,– дигән.

Күзләрендә яшьләр дә күренгән, диләр...

Киң басуда ялгыз гына урак уру куркытканмы аны? Үз өереннән олагып каласы килмәү инстинкты картны коллектив алдына килеп баш иярга мәҗбүр иткәнме?

Әллә –

Көчле, оешкан коллективның чиксез ирке аны һичбер мәҗбүриятсез үзенең көче алдында баш идергәнме?

Әйе!

Такталачык авылы «Таң» колхозында нык оешкан, зур активы, булдыклы юлбашчылары булган, 450 хуҗалыкны берләштергән зур бер коллектив бар.

Бу коллективның чиксез ирке, бик кыска гомер эчендә тирә-як колхозларга үрнәк булырлык зур эшләре бар.

**Менә аның кыскача тарихы**

1929 елның июль аенда Такталачык авылында колхоз төзелә. 1930 елның гыйнвар аенда бөтен авыл колхозга күчеп бетә. Ләкин бу колхоз, кәгазьдә генә булу сәбәпле, «уңышлардан баш әйләнү» чорында[1] тарала. Колхозда ярлы, батраклардан гыйбарәт 83 хуҗалык кына таралмый кала. Сталин иптәшнең мәкаләсен аңлатулар нигезендә тагын колхозга кайтучылар була. 113 хуҗалык белән алар язгы чәчүгә чыгалар.

Язгы чәчүне уңышлы үтәгәч, колхоз 123 хуҗалыкка күтәрелә. Язгы чәчүне уңышлы уздыру нәтиҗәсендә колхозга Хезмәт ордены бирелә (ул орден колхозның членнарыннан Гыйльметдинов һәм Фәрдиев исемле ике батракка бирелә).

Шул елны 123 хуҗалык белән уңышны бүләләр. Беренче уңышны бүлгәннән соң, көзен, 60 атлык зур һәйбәт ат абзары салалар. 40 бозау сыярлык бозаулар йорты салына. Май заводы, 18 амбарны берләштереп колхоз өчен зур бер амбар ясаталар.

100 сыер алып, ферма төзиләр. Сыер фермасы ачалар.

Нәтиҗәдә 1931 елда язгы чәчүгә 205 хуҗалыкка җиткән хәлдә чыгалар. Язгы чәчүне вакытыннан элек уңышлы чәчеп бетерүләре аркасында, колхоз 450 хуҗалыкка җитә. Менә шулай итеп, Такталачык бөтене белән колхозга күчеп, авылда бер генә аерым хуҗалык калган була.

**«Авыл гигантлары»**

Тормышта менә мондый кешеләр очрыйлар. Аларның тән хәрәкәтләре ни өчендер үз хәрәкәтләре булып тоелмый, ябышсыз булып чыгалар, кемгәдер иярә, кемчәдер итенергә теләгән кебек тоелалар. Ни дә кешенең йөрәк хисләренең кушу мәҗбүрияте буенча эшләнгән хәрәкәтләр булып тоелмыйлар.

Дөрестән дә, бу – кешенең тышкы хәрәкәтләре белән эчке йөрәк тормышының бергә кушылмавыннан килеп чыккан табигыйсезлек.

Без менә шушындый кешеләргә охшаган колхозлар да очраштыргалыйбыз. Алар гүя һәрнәрсәне эшләп баралар. Уңышны җыярга да хәзерлек алып барган кебек булалар. Эш башыннан эшләүне дә уздырган кебек тоелалар. Кыскасы, югарыдан килгән һәрбер директиваны эшкә ашырган төсле тоелалар.

Ләкин бу эшкә ашырулар табигый булып, чын күңелдән эшләнгән эш булып бармыйлар яки колхозның үзе өчен мәҗбүри кирәк, табигый бер мәҗбүрият кушуы буенча эшләнгән эш булып бармыйлар. Болар партия директиваларын үзләштереп эшләгән эш булып та чыкмыйлар.

Директиваны формальный уздыру рәвешендә баралар. Такталачык авылы «Таң» колхозына килгәндә, без бөтенләй башка нәрсә күрәбез. Монда һәр эшләнгән эш гади, колхозның үсүе өчен шиксез кирәк һәм колхозның үзенең эчтәлеге тудырган мәҗбүрият төсендә эшләнә. Бу колхозда иң беренче – формалистлык юк. Монда һәр алга куелган эшнең иң беренче реаль нәтиҗәләре күз алдында тотылырга тырышыла һәм ачык рәвештә һәр колхозчының күз алдында ачып салырга тырышу методы тотыла. Шуның өстенә һәрбер эшләнергә дип протоколга кертелгән теләк реаль фактка әйләндерелә барыла.

Бик күп колхозлардагы начар юлбашчылар колхозларның начар баруын югарыгы органнарның начар юлбашчылык итүләреннән күрәләр. Колхозларның ни өчен уңышсыз баруы турында сораулар бирә башласаң, объектив сәбәпләр күрсәтергә, Колхозсоюзны[2] сүгәргә башлыйлар. Билгеле, Колхозсоюзда да гаеп булуы мөмкин һәм бар да, ләкин эш аңарда гына түгел, бу нәрсә күбрәк ул иптәшләрнең колхозның эчтәлеген бик нык өйрәнеп, һәрбер директиваны реаль фактка әйләндерә барырга күнекмәгәнлекләреннән. Мин «Таң» колхозындагы иптәшләрнең һичберсеннән югары органның начар юлбашчылык итүләреннән зарлануларын, сүгенүләрен ишетмәдем.

«Кирәкле директивалар килә тора», – диләр алар. Алар өчен шул җитә кала. Чөнки, ул директиваларны эшкә ашыруга килгәндә, алар үзләре эшләргә тырышалар, һәм аларның шул директиваларны реаль фактка әйләндерә баруга омтылулары уңышлы адымнарын күбәйтә. Ул уңышлар колхоз членнарының бергәлек көчкә булган ышанычларын ныгайта бара.

———

Без 60 ат сыярлык итеп салынган зур матур ат абзарында йөрибез.

Абзар эчендә ике яклап һәр ат өчен аерым бүлмәләр тезелеп киткән, һәр ат өчен аерым аш «табагы» куелган. Абзар тәртипле, тулай ятакка охшаган. Бер ат та обижаться итәрлек түгел, һәрбер бүлмә, һәрбер ат өчен кирәкле булган нәрсә бертөрле, бер төстә эшләнгән. Тезелеп печән ашап яткан атлар коллективның көчен аңкытып торалар.

– Абзарны күптән салдыгызмы?

– Үткән ел көзен.

– Күпмегә төште?

– Бер тиенгә дә төшмәде!

– Ничек алай?

Җавап бик гади.

– Агачны без сатып алмадык. Колхоз членнарында булган кайбер кирәксез каралтылардан җыйдык.

– Ә балта осталарына күпме түләдегез?

– Балта осталары да колхоз членнары.

Хәтта амбарлар өчен кирәк булган тимерләрне дә, кадакларны да сатып алмаганнар. 18 амбарны берләштереп салынган колхоз амбары да шул ук юл белән салынган. Бозаулар өчен салынган абзар да, бүгенге көндә салынып ята торган 50 мең пот сыярлык яңа ашлык амбары да, тагын бер 60 ат өчен салынып ята торган яңа абзар да шул ук юл белән, колхозның үз көче белән салынып ята. Гаҗәпләнерлек тә, шулай ук бик гади нәрсә дә. Тик шунсы кызык, «Таң» колхозы активлары: «Безгә ярдәм итмәделәр, фәлән-төгән», – дип, югары органнарны сүкмиләр. Югары органнардан үзләренә кирәк материалларны, булмау яки берәр башка сәбәп белән ала алмасалар, сүгенми-нитми үзләре булдырырга тырышалар. Агачларны үзләре табалар, кадаклар, тимерләр булмаса, кустарный булса да, үзләре хәзерлиләр.

Шулай итеп, Такталачык авылының тормышын төбеннән үзгәртеп бара торган авыл гигантлары туалар.

**«Алай рәсемгә төшмиләр»**

Без Такталачыкның фото яратучысы белән уракчылар янына барып чыктык. Трактор артыннан узышып көлтә бәйләп йөргән кешеләрне эшләреннән туктатасы килми. Әллә ничек җинаять булыр төсле. Шулай да тракторны туктатырга туры килә.

Аппаратны трактор алдына кую белән, бригададагы колхозчыларның күбесе, рәсемгә төшәбез дип, трактор алдына килеп бастылар. Йөзләре тузанга баткан булуга карамастан, егетләр ак эшләпәләрен матурлап төзәтеп куйдылар. Кызлар да, яулыкларын рәтләп, матур-матур позалар алдылар. Хәтта йөзе җирдән аерылмаслык

тракторист та, кепкасын артка таба этеп, тешләрен ялтыратып, көлү позасы алды. Читтәрәк көлтә бәйләп торган бер апай гына башын күтәреп кычкырып куйды:

– Их сез, шулай рәсемгә төшәләрме, рәсемегез газетта басылып чыкса, «Таң» колхозын хур итәрсез. Күргән кешеләр, әнә ничек «Таң» колхозында эшлиләр, дип көләрләр, – дип куйды.

Бригададагы иптәшләр, команда ишеткән кебек, үз урыннарына таралдылар.

Тик, кызганычка каршы, фотографыбызның пластинкалары «иске» булганга, абыстай кушуы буенча эш вакытында алынган рәсем дә газетаны күрерлек булып чыкмады. Абыстайның онытылмаслык дөрес сүзләре генә менә бу газета битендә басылып чыгалар:

– Гәзит битенә кергән колхозниклар рәсемен карап, эшләмиләр дип көлмәсеннәр. «Таң» колхозниклары начар як белән үрнәк булырга теләмиләр. «Таң» колхозчыларының Татарстан колхозчылары арасында хур буласылары килми!

**«Ни өчен хатын-кызлар талашмыйлар?»**

«Таң» колхозында эшләүче ирләр бер-берсенә шундый сорауны бирәләр дә, башларын селкеп, гаҗәпләнеп куялар:

– Әй бит, малай, хатын-кызлар талашмый-нитми гөрләтеп эшләп баралар.

Алар хатын-кызлар талашып, ызгышып бетәрләр дип көткәннәр, күрәсең. Шулай булса да хатын-кызларның талашуларын миңа күргәләргә туры килде.

Без колхоз активларыннан бер иптәш белән колхоздагы яслеләрне карап йөрдек. «Таң» колхозында райздравның планы буенча ике ясле ачылырга тиешле булган. Ләкин анда 35 әр бала сыярлык 4 ясле, 1 балалар бакчасы ачканнар. Бу яслеләр колхоз тарафыннан сөт, май, икмәк һәм башка нәрсәләр белән яхшылап тәэмин ителәләр. Яслеләр өчен колхозницалардан, курслар аркылы уздырып, тәрбиячеләр хәзерләгәннәр. Ләкин курслар гына аларга күп нәрсә бирмәгән, билгеле. Яслеләрнең тәрбия ягыннан куелышы бик күп яктан аксый.

Менә шул яслеләрне карап йөргәндә, ике колхозницаның талаш вакытларына очрадык. Ул колхозницаларның берсе – кырда эшләүче ана. Аның яследә яшь кенә баласы бар. Икенче колхозница яследә эшли. Аның да баласы бар. Наркомздрав[3] тарафыннан манный ярмасы, печенье кебек әйберләр, ике генә яслегә җибәргәнлектән, бөтен балаларга җитеп бетми.

Талашларына сәбәп булган нәрсә – яследәге абыстайның башка аналарның балаларына артык әһәмият бирми, үз баласын гына печеньелар белән сыйларга тырышуы.

Без бару белән, талаш үзенең матурлыгын югалта язды. Матур гына талашып килгән абыстайлар, без якынаю белән, тына төштеләр. Тик бер колхозница гына матур бер сүз әйтеп куйды:

– Без кырда эшләгәндә, кеше эше дип тормый, үз эшебез дип эшлибез. Син дә монда, үз балаңны аерып, безнең балаларны чит балалар итеп карама, – диде.

Әйе. Апай бик дөрес сүз әйтте.

– Син колхозда эшлисең икән, үз көчеңне бергәлек ит!

– Син колхоз яслесендә эшлисең икән, аналык хисләреңне, җылы елмаюыңны бөтен балаларга уртак ит!

Авылда туып килә торган бөек коллективның ирке шуны тели, коллектив синең яңа эшче, яңа ана булуыңны сорый!

**«Абыстай, аш тәмлеме?»**

Көтмәгәндә үзеңне шәһәр эшчеләре арасында кебек хис итәсең.

150 кеше сыярлык матур, чиста ашханә. Тәртиплелеге белән Казан үзәк эшчеләр кооперативы ашханәләренә охшамый. Яхшы бер заводта, оста кул белән оештырылган эшчеләр ашханәсенә охшый.

Урактан кайтып өстәл тирәсенә утырган ашаучылар да әллә ничек үзләренең крәстиян икәнлекләрен оныттыралар. Нәрсәләре беләндер оешкан завод эшчеләренә охшыйлар. Аш арасында сөйләгән сүзләр дә, терминнар да ничектер заводны искә төшерәләр:

– Безнең бригада бүген төнге сменага барачак.

– Запас частьлар булмау сәбәпле машиналарга рәтләп эшләргә ирек бирми.

– Яртысына җитеп барабыз. Производство планын иртәрәк үтәрбез күренә.

Мондагы өстәлләр дә, крәстияннәрне бер түгәрәккә оештырырга хезмәт итәргә теләгән кебек, 30–40 лап кешене үз тирәсенә җыеп кунак итә. Ашханәдә хатын-кызларның ашаганнарын карап тору әллә ничек үзе күңелле. Аларның әле ашханәдә беренче ашаулары.

Кеше кулы белән пешерелгән аш әллә бик тәмле тоела, хатын-кызлар, урактан арып кайтуларына карамастан, кунакта утырган кебегрәк ыспайланып утыралар.

Аш бирүче хатын-кызлар да Казан ашханәләрендәге аш бирүчеләр кебек тупас кыланмыйлар, кунак сыйлаган төсле йөриләр.

«Таң» колхозы активлары акыллы иткәннәр. Алар:

– Без менә ашханә ачарбыз, хатын-кызларны чуеннан, чүлмәктән азат итәрбез, яшәсен азат хатыннар! Ура! – дип тә сөйләнеп йөрмәгәннәр. Тотканнар да урак өстенә дип ашханә салдырганнар. Матур, зур итеп салдырганнар. Колхоздагы аерым фондтан кирәкле әйберләрне җибәргәннәр.

Хәзер менә:

– Абыстай, аш тәмлеме? – дип, кайсы гына апайдан сорасаң да, чын күңелдән:

– Бик тәмле, балам, – диләр.

Һәм, дөрестән дә, ашханәнең ашы бик тәмле.

Шулай булгач, агитация дә кирәк түгел. Әгәр дә бу ашханә өчен берәр апайны поварлар курсы аркылы да уздырсаң, аннан инде колхоз агайлары эштән арып кайткан хатыннарын:

– Чумар ашыйсым килә, – дип тә аптыратмаслар.

Абыстайларны кулакларның:

– Мең кешелек самовардан чәй эчертерләр. Җитмеш кеше бер юрган астында йоклар, – дигән кабахәт агитацияләре дә куркытмас.

**Караңгыланып барганда**

Трактор хәзер инде авылны гаҗәпләндерми. Моннан бер генә ел элек авылда булган машина романтикасы бетеп бара. Трактор хәзер гади нәрсә. Хәзер инде колхозчылар тракторны тәнкыйть тә итә башладылар. Сүккәләп тә алалар. Сүгәрлеге дә бар шул.

– Бүген трактор төнге сменада өч сәгать туктап торды. Бәйләүче бригада, төнебез әрәм китте, дип тавыш куптарды.

Билгеле, гаеп тракторда түгел. Яхшы хәзерлекле кадрлар булмауда. Шулай да «Таң» колхозы трактористлары тырышып, уздырышып эшлиләр. Аннан:

– Запас частьлар юк.

Бригадирлар зарланып утыралар.

– Лабогрейка ашлыкны коя.

– Трактористлар, темп дип, тракторны артыграк куалар. Әкренрәк йөртсәләр, алай булмас иде.

Без производство киңәшмәсендә утырабыз.

Бригадирлардан берничә иптәш киңәшмәне үзләренең эшләре белән таныштыралар:

– Минем бригадамда 32 кеше. Числоның 13 ендә 5 бөтен дә йөздән уники гектар урдык.

— Минем бригадам...

Президиумдагы иптәшләр бригадаларның цифрларын процентка әйләндерәләр:

Норма 100, 105, 106, 110 процентка үтәлгән.

Арада аксаучы бригадалар да бар. Производство киңәшмәсе ул бригадаларның аксаган якларын эзли. Докладчы-бригадирларга сораулар бирелә:

– Көндәлек эш көннәрен язып барасыңмы?

– Әйе!

– Бөтенесенә бертөрле үк эш көне язасыңмы?

– Юк. Эшләүчесенә карап өч категориягә бүлеп барам: яхшы эшләүчеләр, уртачалар, начарлар.

– Начар эшләүчеләрне ничек аерасың?

Бригадир аптырый төшебрәк тора:

– Аның эшенә карап.

– Начар эшләүчеләргә үзләренең нормаларын тутырмый баруларын әйтә барасыңмы?

– Юк.

Производство киңәшмәсендә утыручы иптәшләрнең күпчелеге бу нәрсәне ялгыш табалар. Һәр эшләүчегә, эшенә карап, күпме эш көне язылуны аңлата баруны кирәкле табалар. Кемдер бу мәсьәләдә уракчылар белән бригадир арасында көн саен тавыш чыга барудан куркуын әйтә. Тагын берәү аның дөрес түгеллеген күргәзә:

– Һәркем ничек эшләгәнен белеп барсын. Тавыш чыгудан куркырга ярамый. Берәү бүген начар эшләп, начар категориягә элгүен белә икән, икенче көнне яхшы эшләп, югары категориягә элгүен күрсә, ул бригадир белән дә талашмас, ашлыкны бүлгәндә дә тавыш, шау-шу булмас, – ди.

Бу фикер производство киңәшмәсе тарафыннан дөрес табыла.

*** * ***

Караңгыланып бара. Эшләпәләрен җиргә салып куеп, аякларын бөкләп җиргә утырган бригадирлар, колхозның ышанычлы активлары колхоздагы хезмәтне яхшырту, аны дөрес рәвештә оештыру турында киңәш алып баралар.

Киңәшмәдә колхозга элек кергән «карт кадрлар» аеруча активлык күрсәтәләр. Алар яңа кергән колхозчылардан дисциплина ягыннан да, башка яктан да бик нык аерылалар. Дөрес фикерләр әйтәләр. Бу киңәшмәдә алты бригада үзара ярышка чыгалар.

Минем күз алдымнан колхоз эшенә нык бирелгән, үзендә булган бөтен иҗат көчен колхозны яхшыртуга биргән, Актаныш районында хезмәтне дөрес оештыра белүе һәм уңышлыклары белән данлыклы «Таң» колхозы активлары үтә.

«Таң» колхозының ике еллык председателе 25 мең исәбенә килгән[4]. Яшь булуына карамастан, 12 ел эшчелек стажы бар. Аның һәрбер сүзе, колхоз активы тарафыннан сыналган бер кеше тарафыннан сөйләнгән бер сүз итеп, зур игътибар белән тыңлана. Һәр предложениесе урынлы һәм кирәкле булып чыга.

Тагын 25 ләп комсомол, партиясез активлар. Бу иптәшләр, шиксез, газета битендә мактаулы исем алырга хаклы кешеләр.

Актаныш районы «Таң» колхозында укытучылар да бар.

Укытучылар булгач, «Таң» колхозының ирешкән уңышлыкларында аларның күп кенә өлешләре булырга тиеш иде. Ләкин...

Дөрес, алар колхоз правлениесенә ара-тирә, подручка тотынып:

– Безгә фәлән авылга барып кайтырга, – дип, ат, арба сорап килеп чыккалыйлар. Ләкин шуңардан үтми.

Авылда 4 ясле, 1 балалар бакчасы бар. Ул ясләләрдә бер айлык курслар аркылы үтүдән башка белеме булмаган колхозницалар эшлиләр. Аз гына педагогия белеме булган иптәшләрнең ярдәме белән «Таң» колхозы ясләләрен бөтен районда үрнәк итеп куярлык мөмкинлекләр бар. Тик «Таң» колхозы укытучылары әле бу нәрсәне аңлау дәрәҗәсендә түгелләр. Алар әле үзләрендә булган наданлыкны бетереп, колхоз эшенә кирәкле ярдәмне бирерлек белемнәрне алырга да омтылмыйлар. Моңа районлагы иптәшләр күз салсыннар! Инде соңгы сүз:

**Тыңла, «Таң»!**

Бүгенге җиңүләрең белән генә тукталып калу бу синең җиңелүең булачак. Алдагы җиңүләр синнән түбәндәге нәрсәләрне сорыйлар:

Колхозда сәяси аң-белем эшләре кирәк дәрәҗәдә бармаганлыгы күренә.

Киләсе җиңүләр өчен зур сәяси белем белән коралллану кирәк.

Җиңүләр өчен көрәшкәндә, бөек җиңүләргә алып баручы Коммунистлар партиясенең тоткан сәясәтен, алга куйган теләкләрен бик нык өйрәнү кирәк. Моңардан башка алдагы җиңүләргә барырга мөмкин түгел.

Шуның өчен «Таң»да сәяси аң-белем кружоклары төзегез, шул кружокларга колхоз активын тартыгыз!

Быелгы уңышны җыю вакытында очраган комачаулыкларны, хезмәтне авырлаштырган әйберләрне кружокларыгызда өйрәнегез! Хезмәтне җиңелләштерә торган яңадан-яңа юллар эзләгез! Колхозыгызның үсешен иҗат нигезенә корыгыз!

Үз эшен белгән сәяси аңлы кадрлар хәзерләгез!

Шулай ук үз тирәгездә яшәгән колхозларның да ни өчен аксауларын, ни өчен тиешле дәрәҗәгә күтәрелә алмауларын һәм аларның сездә булмаган уңышлы якларын өйрәнеп барыгыз! Үзегездәге тәҗрибәләрне алар белән уртак итегез!

Бу нәрсәләр сезгә тирә-як колхозлар белән берләшүне дә, тирән идән астында эшләп яткан сыйнфый дошманнарны бөтенләйгә җиңүне дә, үзегезнең яхшы тормыш өчен көрәшүегезне дә җиңелләштерәчәк!

Тагын бер теләк: Татарстан гыйльми-тикшерү институты «Таң» колхозының тәҗрибәләрен ныклап өйрәнергә тиешле[5].

**«ТАТАР ТҮРӘ БУЛСА...»**

Татарстан начальникларына хөрмәт юк та юк инде. Менә әле миңа «Камил Якуб» пароходында йөрергә туры килде. Ул пароходта күбрәк дачада тора торган кешеләр йөри. Ара-тирә мәсьүл эшчеләр дә, борынгы тел белән әйткәндә, начальниклар да йөриләр. Ләкин хәзерге начальниклар нәрсә, борынгы начальниклар күргән хөрмәтнең «х»сын да күрмиләр.

Әйтик, кешенең төрле чаклары була. Мәсәлән, мәсьүл эшчеләр көне-төне авыр эшләр эшләп йөриләр. Нагрузкалары зур. Арыйлар. Сөйли-сөйли тамаклары карлыгып бетә. Атнага бер пароходта ял итеп барырга туры килә икән, анда да хөрмәт күрмиләр. Карлыккан тамакны ачу өчен кайчакта шулай тамакны майлап алу гадәте бар. Тамакны майлагач, билгеле, тавыш иркенрәк чыга башлый. Ә пароходның капитаны Рахманкулов, начальник дими, ни дими, килә дә:

– Пароходта кычкырып тәртипне бозарга ярамый, – ди.

«Камил Якуб» Татарстанның үз пароходы лабаса. Татарстанның мәсьүл эшчеләре булсыннар да, үз пароходларының капитаны килеп, аларга, ярамый-фәлән, дип йөрсен, имеш. Рахманкул вообще начальникны болай кешедән аермый.

Әле беркөнне мәсьүл эшчеләрдән Ибраһим Бурнаш беренче класска авырлыгы ике поттан артмый торган этен алып кергән. Рахманкул килгән дә дөнья җимерә:

– Этләрне пароход законы буенча беренче класска алып керергә ярамый. Пароходта этләрне ябып бара торган аерым урын бар, – ди.

Бурнаш – үз дәрәҗәсен белә торган кеше. Имеш, мәсьүл эшче Бурнашның эте пароходта ябылып арестант булып барсын. Бурнаш начальникларча Рахманкуловны бик нык сүгеп ташлады һәм:

– Тукта әле. Без синең белән очрашырбыз, – диде.

Бурнаш кына түгел, без дә Рахманкуловка шундый бер зур кешенең этен кимсетүгә ачуландык. Бәлки, дөрестән тә, пароходта этләрне ябып йөри торган закон да бардыр. Ләкин ул закон бит мәсьүл эшчеләрнең этләре өчен язылмаган. Аннан мәсьүл эшчеләрнең этләре белән мәсьүл түгел кешеләрнең этләрен аера белергә кирәк. Минемчә, мәсьүл кешеләр этләрен генә түгел, беренче класска сыерларын өстерәп кертсәләр дә, Рахманкулов каршы сүз әйтергә тиеш түгел иде. Начальникларга яхшылык итүе югалмас иде. Ә үзе әле сознательный партиец.

## КООПЕРАТИВ СҮЗЛЕГЕ

Очередь – икенче төрле әйткәндә, кооператив койрыгы. Койрык кооперативсыз булуы мөмкин, ләкин кооператив койрыксыз булмый.

Агай-энелек – бу кооперативларга хас яман авыру. Башка яман авыру белән авырган кешеләрдән кешеләр качса да, бу авыру белән авыручылардан качмыйлар. Киресенчә, бу авыру белән авырган приказчиклар завлар белән дус булырга тырышалар. Совет җәмәгатьчелеге алардан бик күп зарар күрсә дә, бу авыру белән авыручылар үзләре бер төрле дә зарар күрмиләр. Киресенчә, файда күрәләр. Шуның өчен совет җәмәгатьчелеге аларны тотып, көчләп дарулау чарасын күрмәсә, үзләре бу авырудан даруланырга да теләмиләр. Аларны, мондый авыру белән авыручыларны, кооперативлардан чыгарып, тагын шундый урынга куймау белән генә дарулап була.

## МИНЕМ БЕРЕНЧЕ КРИТИКЛАРЫМ ҺӘМ БЕРЕНЧЕ УКУЧЫЛАРЫМ

Алты яшьләремдә мин язучы булмаганмын. Ләкин минем башка һөнәрем булган. Мин ул вакытта үземнең авылда алдауларым белән мәшһүр булганмын. Бу нәрсә минем этиләр, әниләр һәм иптәшләрем алдында бик яшьли авторитетым төшүгә сәбәп булган. Башта һәр алдавым артыннан ачуланып кына торган әни, этинең кушуы буенча бу начар гадәтне ташлатырга теләп, аяусыз рәвештә кыйный, тәүбә иттерә башлады. Бу нәрсәне һәр көнне яңартырга яки яңадан тәүбә итәргә туры килә иде. Кыйналуга сәбәп булган бу алдаулар, билгеле, булмаган вакыйгаларны сөйләү өчен түгел. Кайдадыр булып үткән вакыйганы үзгәртә төшеп, матурлап сөйләвем өчен, билгеле. Бу матур итеп сөйләнгән вакыйгаларның һәрберсендә дә мин үзем җиңүче булмыйдыр идем. Ә бәлки, киресе, мин иң күп кыйналган малайларның берсе идем. Ләкин этиләргә, әниләргә килеп сөйләгәндә, ул вакыйгаларда мин һәрвакыт ... батыр булып үземне күрсәтәм. Ә эти-әниләрнең үзләре күргән вакыйгаларда мин гел җиңелүче булып килгәнгә, ышанмыйлар гына түгел, һәр алдавымның соңы таяк тату белән бетә. Алар кыйнаган саен, мин алдаган вакыйгаларның сюжетларын матуррак итәргә, сөйләгән вакыйгаларымны аларны ышандырырлык итеп алдарга тырыша башладым.

Алар минем ул вакытта буяп, матурлап сөйләгән, шулай итеп язучы булырга хәзерләнүемне, бик яшьтән вакыйгаларны бертөрле нәфис рәвешкә кертергә омтылуымны белмәгәннәр.

Мин дә ул вакытта үземне таяк белән кыйнаучы беренче тәнкыйтьчеләремә зур ачу саклап йөридер идем. Ләкин аларның оста итеп алдый алмауларым өчен булган кыйнаулары нәтиҗәсез үтмәде, мине остарак алдарга, кеше ышанмаслык вакыйгаларны ышандырырлык итеп, тормышта булганчарак оформить итәргә өйрәттеләр.

Болар инде – күптән үткән вакыйгалар. Үтелгән юллар, күреп үткән яңалыклар, бөек социаль вакыйгалар йөрәк томаны уртасында туарга омтылган йолдыз кебек кайныйлар.

*10 бит.*

**Таң җиле.** Романның баштагы өлеше беренче тапкыр «Безнең юл» журналының 1929 елгы 12 нче (декабрь) санында «Һади Такташ» имзасы белән басылган. Исем астына «Әле язылып бетмәгән романнан бер кисәк» дип куелган. Соңыннан шул ук текстка авторның архивтагы кулъязмасыннан аерым өлешләр өстәлеп, Такташның 1942 елда Казанда чыккан «Әсәрләр» җыентыгына (төзүчесе – Х.Хәйри) кертелгән. Аннары әдипнең «Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр» китабында (төзүчесе – Х.Госман) бирелгән.

Язылып бетмәгән бу романга тормыш материалы итеп язучы үзенең туган яклары мишәр авылларындагы вакыйгаларны ала. Романның төп герое Рөстәм образында авторның үз тормышы да чагылып үтә. Мәгълүм булганча, 1918 елның язында Такташ, Урта Азиядән туган авылы Сыркыдыга кайткач, укытучы булып эшли, авыл советына әгъза булып сайлана, авылда культура-агарту эшләрендә катнаша. Романдагы Рөстәм тормышы Такташның шул чорда Сыркыдыдагы тормышына якын. Әсәрнең герое Рөстәмнең үсмер вакытлары да Һади балачагына охшаш. Рөстәм мохтаҗлыктан кардәш тиешле Исмәгыйльгә малай булып сәүдәгә китәргә тиеш була. «Ул, бер урыннан бер урынга күчеп йөри-йөри, өч ел эчендә күп кенә җирләрдә эшләде һәм, 17 яшьлек малай булганы хәлдә, революцияне эшсез килеш, яланаяк «Марсельеза» җырлап урамда каршы алды».

Һади да унөч яшендә, әтиләренә матди ярдәмне күздә тотып, үзләренә кардәш тиешле бер байга ияреп Бохарага китә... «Магазин малае буларак, минем өстемә бик күп төрдә булган эшләр йөкләтелгән иде, минем «мөхтәрәм» хуҗаларымның идәннәрен юудан башлап керләр юуга кадәр сузыла иде. 1917 ел Февраль переворотын мин, хуҗаларым тарафыннан эштән урамга чыгарылып ташланган хәлдә, эшсезлектә каршыладым», – дип яза Такташ автобиографиясендә (ТА. 11–8 папка. 1185 саклану берәмлеге). Такташ иҗатын өйрәнүче әдәбият галиме М.Мамин шушы әсәр уңае белән болай ди: «Рөстәм образы аша Такташ Сыркыды шартларында культурага, яңа тормышка омтылучы яшьләрнең психологиясен, аң дәрәҗәсен гәүдәләндерергә тырыша. Такташ, Рөстәм тибын иҗат иткәндә, үзен дә шушы тип яшьләр категориясенә керткән дип уйларга урын кала» (Мамин М. Һади Такташ поэзиясе. Казан : Таткнигоиздат, 1952. 23 б.).

Әсәрдәге персонажларның теле дә Сыркыды авылы сөйләшенә бик якын тора.

Язучының романны кайчан яза башлавы төгәл үк билгеле түгел. Такташ 1929 елның 22 июлендә Чиләбе шәһәрендә яшәүче Габдрахман Теләшкә язган хатында: «Үзем роман язу өстендә эшлим», – дип хәбәр иткән.

Язучының 1929 елның 10 октябреннән соң Михаил Юринга язган хатында мондый юллар бар: «Я пишу роман, название которого вроде «Человек, который потерял себя». Вещи проблематичны, но чертовское экономическое положение не дает возможности серьезно вести работу», – ди. Күрәсең, бу вакытта әле язучы әсәренең исемен ачык ук билгеләмәгән булган. Ә «Үз-үзен югалткан кеше» дип атау фикере романның төп герое Рөстәмнең уй-кичерешләренә, тормышына ишарә рәвешендә туган булырга мөмкин. Рөстәм үзен ике уртадагы кеше кебек хис итә. Беренчедән, авылның гади, надан крестьяннарыннан ул укымышлылыгы, яңача фикер йөртә алуы белән аерылып тора. Ләкин авыл агайлары аны түгел, ә гади крестьянны, хәтта ярым тинтәк Мокунны якынрак күрәләр, ул аларга үз кеше. «Аның [Мокунның] алдында гакыллы булып сөйләргә дә тырышмыйлар. Ул булган җирдә алар үзләрен тыгызланган итеп тә хис итмиләр». Икенчедән, авылдашлары Рөстәмне, «вәлшәви» дип йөртсәләр дә, Рөстәм әле большевикларның платформасын, сәяси вакыйгаларны ачык итеп аңлауга хәзерлексез. Аның алдына төп бер проблема – халык өчен яхшы, рәхәт тормыш табу проблемасы килеп баса. Ә ул проблеманы ничек чишәргә – Рөстәм әле моңа җавап таба алмый.

«Таң җиле» романының Татарстан Республикасы Милли музеенда сакланган кулъязмалары шуны ачыкларга мөмкинлек бирә: роман эшләнү процессында тукталып калган. Язучы тәмамланган бүлекләрнең барысын да акка күчерергә дә яки аларны эзлекле тәртипкә салырга да өлгермәгән. Такташның Х.Хәйри төзегән «Әсәрләр»ендә (1942) «Таң җиле» романының бүлекләрен бирү тәртибен уңышлы дип санарга була.

Такташ романын иҗат итү процессында, киләчәктә әсәр тукымасына кертеп җибәрү өчен, байтак «заготовка» әзерләгән: аерым күренешләрне, кайбер геройларның портретларын, эш-хәрәкәтләрен, психологик кичерешләрен тасвирлаган. Аларны әсәрнең булган кадәр текст тукымасына автордан башка урнаштыруы да кыен. Әмма шагыйрьнең прозаик буларак иҗат итү процессын – лабораториясен – аз гына булса да күзаллау өчен, шундый аерым кисәкләрнең берничәсе «Вариантлар...» бүлегендә бирелә.

Такташның әсәрләрен төрле вариантларда язуы билгеле. «Таң җиле» романы белән дә шундый ук хәл. Эшләү процессында язучы романның планын да үзгәрткән булырга мөмкин. Аның бер үк вакыйганы төрле фонга куеп, алдыннан яки артыннан килгән күренешләрне алмаштырып язуы, геройларның урыннарын, рольләрен үзгәртеп караулары әнә шул турыда сөйли. Романның беренче бүлеге «Безнең юл»да чыгуга ике ел үтсә дә, Такташ әсәрнең калган бүлекләрен, дәвамын журналга тәкъдим итми. Бу хәл, бер яктан, язучының романны ашыкмыйча, җентекләп, төрле вариантлар аша (мәсәлән, «Аючылар» бүлеген ул өч вариантта яза) камиллеккә китерергә тырышуы белән аңлатылса, икенче яктан, редакциядә эшләгәнлектән, язучының романын язарга, төгәлләргә вакыты да җитмәүдән килгән булса кирәк.

Автор телендә «җ»ләштерү сизелә. Мәсәлән: «җылый», «җегет», «җырта» һ.б.

Такташның Татарстан Республикасы Милли музее фондындагы архивында романның 14 кисәк кулъязма-автографы саклана.

ТА. 2–6 п. 335 с.б. 1–53 б. Гарәп графикасында язылган. Акка күчерелгән. 1–41 нче битләр басма текстның икенче бүлегенә тәңгәл килә, язучының 1942 елгы «Әсәрләр» җыентыгына текст шуннан алынган. 44–50 нче битләрдә Рөстәм белән Габбасның атта юкә кисәргә барулары, әңгәмәләре тасвирлана. Басма текстта бу кисәк юк. Шуңа күрә кулъязманың бу өлеше кушымталар бүлегенә тәкъдим ителә. Кулъязма (соңгы ике биттә) Рөстәмнең балачагын искә төшерүе белән тәмамлана.

ТА. 2–7 п. 336 с.б. 43–79 б. Каралама. Төзәтү-сызулар бик күп. Такташның үз кулы белән «II глава» дип куелган бу кисәк басма текстның беренче бүлегенә якын тора.

Тик язучы Садрыйның «эш сүмәс кешеләр», «укымышлылар» турындагы фикерләрен бу кисәктә Габбастан әйттерә. Рөстәмнең бала чагын, этисен искә төшерү моменты басма текстагыга караганда зуррак бирелгән. 63–76 нчы битләр басма текстагы өченче бүлекнең баштагы өлешенә якын. Кульязма Антонинаның Рөстәмнәр өендә тору вакытларын тасвирлау белән тәмамлана.

ТА. 2–10 п. 348 с.б. 1–51 б. Акка күчерелгән автограф. Титул битенә «Такташ. Роман. Беренче кисәк. 1929 ел. Казан» дип куелган. Беренче биткә «Разрешено Главлитом ТАССР 5/XII–1929» дип язылган. Соңгы биткә башка кеше (рецензент) кулы белән латин графикасында язылган мондый юллар бар: «Шул көйгә дә «Безнең юл»га басарга яраклы булуын, тел сөреше һәм язылу рәвешеннән зур бер әсәрдән өзек исеме алырлык булуын әйтү белән бергә шуларны да әйтергә кирәк:

1. Автобиографично.

2. Рөстәм тибы һаман да ачылмый.

3. Вак штрихлар артык күп.

4. Уку барышын освещать иткән отступлениеләр аз.

5. Авыр һәм яңлыш җөмләләр бар».

Кульязманың 1–48 нче битләре «Безнең юл» журналының 1929 елгы 12 нче санында басылган текст белән тәңгәл килә. Соңгы 49–51 нче битләрдә басма текстка кермәгән күренешләр бирелгән: Габбаслар күл буена киткәч, Садрый белән Рөстәм Алла, теге дөнья турында сөйләшәләр. Садрый Рөстәмнән күптән көткән «Мин Алланың барлыгына ышанмыйм. Алла ул борын-борыннан килгән әкият кенә» дигән сүзләрне ишетә һәм, «әллә чын күңелдән ышанып, әллә үзе Алланың булуын теләмәгәнгә, ул бик җиңел рәвештә Рөстәм ягына авыша башлады. Габбаслар кайткач, алар икәүләп госелләрен яңартырга, күлмәк-ыштаннарын юып кайтырга киттеләр... Сәдрү, күл янына җитү белән, Рөстәмнең күзенә карады да, кулын селтәп: «Әйдә... На кой чурт!» – диде. Рөстәм елмайды. Алар, госелсез килеш соңгы гаетләрен укырга дип, кире борылдылар».

ТА. 2–12 п. 350 с.б. 1–5 б. Романның басма текстыннан нык кына аерыла торган вариантының фрагменты. Басма текстагы Рөстәмнең әбисе Маһирә бу автографта Хәмдия исеме белән бирелгән. Өзек кушымталар бүлегенә тәкъдим ителә.

ТА. 2–12 п. 351 с.б. 1–5 б. Төзәтү-сызулар күп. 1 нче биткә язучы кулы белән «Романның О кисәге» дип язылган. Бу кисәк басма текстан шактый аерыла. Шуңа күрә кушымталар бүлегенә тәкъдим ителә.

ТА. 2–12 п. 352 с.б. 1–15 б. Басма текстның өченче бүлегенә тәңгәл килә. Китапка текст шуннан алынган. Кайбер персонажларның исемнәре ике урында ике төрле бирелгән: 3 нче биттә «Ибраһимның энеләре Габдулла белән Газиз», ә 9 нчы биттә «Ибраһимның энеләре Хәмзә белән Сибгат» диелгән.

ТА. 2–12 п. 353 с.б. 1–7 б. Сызулар күп. Романның беренче бүлек басма текстына якын тора торган вариант фрагментлары.

ТА. 2–12 п. 354 с.б. 1 б. Каралама. Романның беренче бүлегенең баш өлеше.

ТА. 2–12 п. 355 с.б. 1 б. Каралама. Романның беренче бүлегеннән бер фрагмент.

ТА. 2–12 п. 356 с.б. 1–28 б. Төзәтү-сызулар күп. Басма текстның икенче бүлеге караламасы. Әмма басма текстта булмаган фрагментлар да бар.

ТА. 2–10 п. 358 с.б. Беренче кисәк – 1–3 б. Басма текстан нык аерылып торган вариантның фрагменты. Рөстәм Габбас арбасына утырып урманга барганда, Габбасның Рөстәмне сынаулары, Рөстәм турындагы начар уйлары чагыла. Икенче кисәк – 1–2 б. Басма текстагы беренче бүлекнең соңгы өлешенә якын тора.

ТА. 2–12 п. 359 с.б. 1–3 б. Басма текстта булмаган фрагмент. Садрыйның хатыны белән тормышлары, мөнәсәбәтләре турында сүз бара.

ТА. 3–3 п. 430 с.б. 1 б. Басма текстта булмаган кечкенә фрагмент. «Кешеләр җирне төрмәгә әйләндерделәр». Ул [Рөстәм] «Савва»ның идеяләрен дә файдалы-файдасыз булуын тикшерми, аның үзе өчен яңа булган көчле сүзләре белән кызыкты. Савваның үзе дә белми бөтен кешелек дөньясына каршы бунт күтәрүе аның үзенең йөрәгендә булган, туып килә торган белемсезлеккә каршы гыйсъян итүгә якын.

ТА. 1–1 п. 1141 с.б. 1–46 б. Сызулар күп. Беренче биткә Такташ кулы белән «Романның N главасы» дип, сул почмакка кыеклап «каралама», ә сул кырыйга «11 июнь, 1929» дип язылган. Баштагы өлеше басма текстагы беренче бүлеккә якын тора. Әмма Габбасның ике хатынга өйләнү тарихы, юкә кисәргә баручыларның урмандагы хәлләре киңрәк, ләкин артык натуралистик тасвирлана. Кульязманың соңгы өлеше яңа бер кисәк булып тора, ул кушымталар бүлегенә тәкъдим ителә.

Том өчен текст Һ.Такташның 1942 елгы «Әсәрләр» җыентыгыннан алынды.

[1] *Шәлче* – төрле җирләрдә йөреп сату итүче.

[2] *Вокзалчы* – вокзал тирәләрендә буфет, чәйханә тотучы. Такташ кульязмаларында «буфетчы», «вокзалчы» сүзләре бер үк мәгънәдәге сүзләр булып киләләр. Бер кульязмада язучы «буфетчы» сүзен куллана, шул ук текстның башка вариантында аны «вокзалчы» белән алмаштыра. Беренче сүзне сызып, өстенә икенче сүзне һәм киресенчә язган очраклары күп.

[3] *«...Аючыны саурып үптем...»* – «Аючылар» җырының варианты «Татар халык җырлары» китабында (Татар халык җырлары / төз. И.Надиров. Казан : Татар. кит. нәшр., 1965. 210 б.) бирелгән. Җырга аңлатма биргәндә, Такташның «Таң җиле» романыннан өзек китерелгән. М.Нигъмәтҗановның 1970 елда Мәскәүдә чыккан «Татар халык җырлары» (71) китабында да «Аючылар» җырының «Аючы Дәүли» исемле варианты бар.

[4] *«Савва»* – Л.Н.Андреевның (1871–1919) 1906 елда язган драмасы. Беренче тапкыр ул 1911 елда Мәскәүдәге «Знание» нәшриятының 11 нче җыентыгында басыла. 1919 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга.

1900 елда үзлегеннән өйрәнеп уйлап табучы (изобретатель) А.Г.Уфимцев һәм аның иптәшләре Курскидагы могҗизалы Гайса анасы иконасын шартлатырга булалар. Ләкин уйлары барып чыкмый.

Андреев бу фактны драмага нигез итеп ала һәм бунт, җимерү стихиясе белән тулы әсәр иҗат итә. Әсәрнең төп герое Савва – анархист-бунтарь. Ул дөньядагы тигезсезлеккә каршы, дингә каршы бунт күтәрә. Электән яшәп килгән бөтен тормышны инкарь итә һәм бөтен дөньяны яндырып көлгә әйләндереп, ялангач калдырып, аның урынына яңа тормыш төзергә һәм бу эшне берьялгызы булдырырга тырыша. Ләкин дини фанатизм ялгызак бунтарьның ниятеннән көчлерәк булып чыга. Иконаны шартлатырга әзерләнүен

белеп, «изге аталар» коткысы белән агуланган фанатиклар, диндарлар төркеме монастырь чаңнары һәм Пасха гимны-җырлары астында Савваны ерткычларча үтереп ташлыйлар.

М.Горький пьесаның прототибы Уфимцевны якыннан белгән, аны «фәнни техника өлкәсендәге шагыйрь» дип атаган (О писателях. М., 1928. 166 б.). Уфимцевны төрмәгә япкач, Горький аның төрмәдә уйлап тапкан эчке янулы двигатель сызымнарын Мәскәүдәге инженерларга күрсәтеп йөргән. Инженерлар сызымнарга югары бәя биргәннәр. «Я знал, что этот юноша из ряда тех прекрасных мечтателей, которые, – очарованные своей верой и любовью, – идут разными путями к одной и той же цели – к возбуждению в народе своем разумной энергии, творящей добро и красоту» (Шунда ук. 167 б.).

«Савва» драмасы уңае белән Горький Андреевның бу образны бозып күрсәтүен әйтә: «Мне было грустно и досадно видеть, что Андреев исказил этот характер, еще не тронутый русской литературой [...] Мы поспорили, и, может быть, я несколько резко говорил о необходимости точного изображения некоторых – наиболее редких и положительных явлений действительности (Шунда ук. 167 б.).

Такташның үз романының герое Рөстәмгә нәкъ шул «Савва» китабын «тоттыруы» һәм Рөстәмнең аны, кесәсенә салып йөртеп, җае чыккан саен укып һәм укыган битләре турында уйланып, фәлсәфә корып йөрүе очраклы түгел, әлбәттә. Рөстәм дә, Савва кебек үк, искелеккә каршы көрәшә, шуңа күрә Савва тибы аның өчен идеал булып тора. «Таң җиле»нең кульязма вариантларында Такташ моны тагын да ачыграк күрсәтә. Рөстәмне сурәтләп, ул болай ди: «Юл буеннан башын түбән иеп бөек анархист, җимерүче, даһи рәссам ялкау гына еракта күренеп торган урманга таба атлап килә. Кара чәчләре тузгып артка төшкән. Башы, авыр уйларын күтәрә алмаган төсле, түбән иелгән» (ТА. 2–12 п. 356 с.б. 1 б.). Яки: «Ул Савваның идеяләренең файдалы-файдасыз булуын тикшерми, аның үзе өчен яңа булган көчле сүзләре белән кызыкты» (ТА. 3–3 п. 430 с.б.). Рөстәмне бигрәк тә көрәшнең тышкы күренеше кызыксындыра, ул аның файдалы булу-булмавын, максатка алып килү-килмәвен тикшерми һәм аны аңлый да алмый.

[5] *Ике фәрештә* – ислам дине өйрәткәнчә, һәр кешене ике фәрештә саклый. Алар – яхшылык фәрештәсе һәм явызлык фәрештәсе – кешенең изге эшләрен дә, гөнаһларын да даими теркәп баралар.

[6] *...тәрәт-мәрәт алмицы... цмбурах...* – Такташ биредә бала чакта ук үзе сөйләп йөргән такмакны китергән. Һади 1911–1913 елларда Сыркыдыдан утыз чакрымдагы Пешли мәдрәсәсендә укый. Аны бала чактан белгән Низам Арсланов Һадиның бик шаян булуы, мәдрәсәдә бик каты тәртип белән дин укытылса да, «намаз укырга керешкәндә, балалар гына булса, Һади:

Тәрәт-мәрәт алмадым,
Мулла артыннан калмадым.
Мулла куда – я туда,
Чембурах, чембурах, –

дип, намазга керешкән була иде» ди (Госман Х. Һади Такташ эстетик идеяләренең үсеше: канд. дис. Казан, 1951. 26 б.). Х.Госман бу турыда соңыннан үзенең 1953 елда чыккан «Такташ поэзиясе» китабында да әйтеп үтә (5 б.).

[7] *Әлхәм колху* – «әлхәм», «колху» – Коръән сүрәләренең беренче сүзләре.

*Әлхәм* – әлхәмделлилаһ – Алланың ярдәме белән.

*Колху* – колхуаллаһу – Алла әйткәнчә (Алла кушса, Алла боерса).

[8] *«Марсельеза»* – француз революцион җыры, Франциянең дәүләт гимны. Сүзләре һәм музыкасы 1792 елда Страсбургта К.Ж.Руже де Лиль тарафыннан язылган.

Россиядә XIX гасырның 80–90 нчы елларында эшчеләр һәм интеллигенция арасында «Марсельеза» көенә җырлана торган революцион җыр таралган булган. Аны «Эшчеләр Марсельезасы» дип атаганнар. Текстын П.Л.Лавров язган. Җырның татарча вариантлары да бар. (Кара: Татар халык иҗаты. Казан : Татгосиздат, 1951. 509–510 б.)

[9] *Герман сугышы* – сүз 1914–1918 еллардагы Беренче бөтендөнья сугышы турында бара.

[10] *...янган элеваторның хәрабәләре...* – Такташ архивында бу бүлек кульязмасының икенче вариантында «яңа элеваторның хәрабәләре» дип бирелгән. Кульязмадан күчерелеп, язучының 1942 елгы «Әсәрләр» җыентыгына да шулай алынган. Әмма Такташның бу бүлек кульязмасының беренче вариантында «янган элеваторның хәрабәләре» диелгән. Язучы, кульязманы акка күчергәндә, хата җибәргән булса кирәк.

[11] *«Правда»* – Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты органы газетасы, 1912 елдан чыга.

[12] *Чека* (Чрезвычайная комиссия) –1917–1921 елларда спекуляциягә, саботажлыкка һәм контрреволюциягә каршы көрәшү өчен төзелгән Гадәттән тыш комиссия.

[13] *Габдулла белән Газиз* – Такташ бу кешеләрне башка урында «Хәмзә белән Сибгат» дип тә атый. Текстны әзерләгәндә, соңгылары да «Габдулла», «Газиз» дип алмаштырылды.

[14] Бу җырның соңгы дүрт юлы И.Надиров төзегән «Татар халык җырлары» китабында (Казан : Татар. кит. нәшр., 1965. 59 б.). «Каз канаты» исемле җырда бирелгән. Җырның варианты М.Нигъмәтҗанов төзегән «Татар халык җырлары» китабында (Казан : Татар. кит. нәшр., 1976. 68 б.) «Тәфтиләү» дип исемләнгән җырда да очрый.

[15] Шәлчеләр турындагы җырның вариантлары А.С.Ключаревның «Татар халык көйләре» (Казан : Татгосиздат, 1941. 56 б.) китабында, «Татар халык җырлары»нда (Казан : Татар. кит. нәшр., 1965. 67 б.) бирелгән. Соңгы китапта мондый искәрмә дә бар: «Себер якларында шәл сатып йөргәндә, азмы-күпме табыш ясап һаваланучы сәүдәгәрләрдән көлеп иҗат ителгән бу шаян такмаклар Мордва АССР... да (ягъни Такташның туган ягында. – *Л.Г.*) язып алынды».

[16] Узелчылар турындагы җырның варианты «Татар халык җырлары»нда (Казан : Татар. кит. нәшр., 1965. 66 б.). «Ал бәгърем, гөл бәгърем» исемле җыр текстында бирелгән.

[17] Бу җырның вариантын хәтерләтә торган куплетлар «Татар халык җырлары» китабында (М., 1970. 97 б.) «Далаларда егет печән чаба» исемле җырда бирелгән.

[18] Бу типтагы җырлар «Татар халык җырлары»нда очрый (М., 1970. 41, 48 б.).

[19] *Япон сугышы башланды.* – 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышы турында сүз бара.

*51 бит.*

**Кызыл галстук.** «Яшь ленинчы» газетасының 1925 елгы 11 март (4 нче санында) басылган.

Беренче тапкыр Һ.Такташның 1942 елгы җыентыгына (төзүчесе – Х.Хәйри) кертелгән.

1922 елның маенда ВЛКСМның Бөтенроссия конференциясе карары белән илнең төрле почмакларында пионер отрядлары оеша башлый. 1922 елның 19 мае пионер оешмасының туган көне санала. 1924 елдан, Ленин үлгәннән соң, пионер оешмасы аның исемен йөртә. Нәсер шул вакыйгалар уңае белән язылган.

Текст «Яшь ленинчы»дан алынды.

[1] *...14 нче елда сугышка алынды.* – 1914 елның июлендә башланган Беренче бөтендөнья империалистик сугышы.

*54 бит.*

**Ул аны онытты.** «Яшь ленинчы» газетасының 1925 елгы 9 апрель (6 нчы) санында басылган. Беренче тапкыр Һ.Такташның 1942 елгы җыентыгына кертелгән. Архивта бу нәсернең тулы булмаган караламасы бар (ТА. 2–14 п. 394 с.б.).

Текст «Яшь ленинчы»дан алынды.

[1] *Радик* – Һади Такташ белән Гөлчирә Хәмзинаның балалар йортыннан тәрбиягә алган кызлары. Авылдан балалар йортына китерелгәч, баланың үз исемен Радик дип алмаштырганнар. Такташның сеңлесе Хәнифә Такташева әйтүенчә, тәрбиягә алганда, бу бала 11–12 яшьләрендә булган. Такташларда ул 5–6 еллар яшәгән, гомумбелем бирү һәм музыка мәктәпләрендә укыган. Аннары Мәскәүгә күчкән. Радикның соңгы язмышы турында мәгълүматлар әлегә табылмады.

[2] *Егерме икенче ел кергәндә...* – 1921–1922 елларда Идел буе халкы ачлык кичерә.

*57 бит.*

**Троцкий.** «Октябрь яшьләре» журналының 1925 елгы 10 нчы (июнь) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*Троцкий* (1879–1940) – Л.Д.Бронштейн, революционер, 1917 елга кадәр меньшевик. Революциядән соң хәрби эшләр халык комиссары. В.И.Ленин вафатыннан соң хакимият өчен көрәштә И.В.Сталинның көндәше буларак, акрынлап дәүләт җитәкчелеге эшләреннән читләштерелә. 1929 елда илдән сөрелә. Сталин боерыгы буенча, 1940 елда совет разведкасы тарафыннан үтерелә.

*61 бит.*

**Кояш көлми дә, елмаймый да.** Язучының «Кояш көлми дә, елмаймый да» исемле җыентыгында (Казан : «Гажур» нәшр., 1926) басылган. Такташның үзе исән чакта чыккан 1931 елгы җыентыгына (Һади Такташ әсәрләре : тулы җыелма. Казан : Татиздат, 1931. 1 т.) кертелгән.

Такташ социализм системасында кешелекнең бөек киләчәгенә ышанган. «Ул, – дип яза Х.Госман бу нәсер уңае белән, – коммунизм гигантын күтәрү процессында халыкның үзе дә үсүен, күтәрелүен күрде. Йөз меңнәрчә, миллионнарча гади кешеләрнең культурага, сәнгатькә, матурлыкка омтылулары аны тирән сокландырды» (Госман Х. Һади Такташ эстетик идеяләренең үсеше: канд. дис. Казан, 1951. 143 б.).

Такташ халык талантларының үсүе турында язып, җырлап кына калмады, ә аларны эзләп табуга, үстерүгә үзеннән дә өлеш кертте. Ул бу вакытта «Авыл яшьләре» журналының җаваплы секретаре булып эшли. Һәм авылда туган халык талантларын матбугат битләренә алып чыга. Журналның һәр санында диярлек куш биттә «Авыл шагыйрьләре» дигән уртак баш астында яшь шагыйрьләрнең, хикәячеләрнең рәсемнәрен, аларның әсәрләрен урнаштыра. Кыюрак булырга өндәп, ничек һәм нәрсәләр турында язарга өйрәтеп, яшь язучыларга хатлар язып тора.

Текст 1931 елгы җыентыктан алынды.

[1] *II Интернационал кызы, Англия короленең икенче хатыны Макдональд* – Макдональд Джемс Рамсей (1866–1937), Англиядә лейбористлар (эшчеләр) партиясе җитәкчесе, II Интернационал җитәкчеләреннән берсе. Чиктән тыш оппортунистик сәясәт үткәрүе, шулай ук сыйныфларның үзара дус яшәүләре һәм капитализмның социализмга эволюция юлы белән күчә алачагы турындагы теорияне үткәрүе белән танылган сәяси эшлекле. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан империалистик буржуазияне ачыктан-ачык яклау юлына баса. 1924, 1929–1931 елларда Макдональд хөкүмәте (ул бу елларда премьер-министр) Англиядәге революцион хәрәкәткә, колонияләрдә җәелгән азатлык хәрәкәтенә һәм СССРга каршы көрәш алып бара.

Биредә Такташ Макдональдны эшчеләр партиясенә хыянәте һәм икейөзлелегенә ишарә итеп ирония белән искә ала.

[2] *Нижний* – Нижний Новгород.

[3] *Чемберлен* – Чемберлен Остин (1863–1937), Англиянең дәүләт эшлеклесе. 1924–1929 елларда чит ил эшләре министры. 1927 елның маенда СССР белән дипломатик мөнәсәбәтләрнең өзелүенә китерүдә һәм СССРга каршы хәрби интервенция оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе.

*65 бит.*

**Кыш җыры.** Язучының «Кояш көлми дә, елмаймый да» исемле җыентыгында (Казан : «Гажур» нәшр., 1926) басылган. Такташның 1931 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст 1931 елгы җыентыктан алынды.

[1] *Ленинның «Һәрбер асрау хөкүмәт белән идарә итә белергә тиешле» дигән җанлы лозунгысы...* – бу гыйбарә (гадәттә «асрау» сүзе урынына «кухарка» сүзе кулланылып) тарихка, сәясәткә, партиягә, әдәбиятка караган хезмәтләрдә, чыганагы күрсәтелмичә генә, бик еш кабатланып килде. Әмма, махсус тикшерүләр нәтиҗәсендә, В.И.Ленин томнарында мондый тәгъбирнең бөтенләй булмавы ачыкланды.

*69 бит.*

**Протоколлар эчендә хикәя.** «Кызыл Татарстан» газетасының 1926 елгы 4 сентябрь (200 нче) санында басылган. Беренче тапкыр Казанда 1927 елда чыккан «Такташ шигырьләре» җыентыгына кертелгән. Язылу вакыты һәм урыны «Сыркыды авылы, 1926 ел, июль» дип куелган. Соңыннан шактый өлеше («Минем иптәш мөгаллим миңа таба ашыгып килә...» дип башланган абзацтан алып ахырынача) 1930 елда «Ташкын» җыентыгында (Әдәби хрестоматия. I кис. / төз.: С.Борһан, Г.Нигъмәти, Ф.Әмирхан) басыла. Хикәя язучының үзе исән чакта чыгарылган 1931 елгы җыентыгына (Һади Такташ әсәрләре: тулы җыелма. Казан : Татиздат, 1931. 1 т.) урнаштырылган. Язучының 1942, 1952, 1953 елларда чыккан җыентыкларына хикәя беркадәр кыскартып кертелгән.

Нәсердә автобиографик моментлар бар. 1918–1919 елларда Такташ, туган авылы Сыркыдыга кайтып, мәктәптә эшли, китапханә оештыра, авыл советы әгъзасы була. Әсәрдә шул чордагы Сыркыды авылы тормышы чагыла. Хикәянең беренче басмаларында («Кызыл Татарстан»да һәм 1927 елгы җыентыкта) язучы «Сыркыды» сүзен хәтта текст эченә үк керткән. «Авыл советының диварында Ленинның рәсеме тора» дигән бүлекнең соңгы абзацы «Болар Сыркыды авылының иң алдынгы егетләре» дип башлана. 1931 елгы басмада «Сыркыды» сүзе төшерелеп, күп ноктлар гына куелган.

Истәлекләргә караганда, Такташ спекулянтларга, җитәкчелеккә үрмәләгән кулак дип саналган кешеләргә каршы рәхимсез көрәшкән. Ул, авыл советы сайлаганда, җыелышта иске рәискә каршы чыккан. Хикәядә сурәтләнгән авыл советы диварына куелган Ленин рәсеме дә булган. «Ул йорттан йортка күчеп йөргән һәм һәр йортта үзенә иң якты, иң кадерле урынны алган» (Надиров И., Кәримов Р. Такташ туган авылда // Совет әдәбияты. 1959. № 1. 51–58 б.).

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

[1] *Николай II* – Николай Александрович Романов (1868–1918), Россиянең иң соңгы императоры.

[2] *Третейский суд* – капма-каршы якларның бәхәсләрен чишү өчен үзләре тарафыннан сайланган суд. Такташ биредә бу сүзне ирония белән куллана.

[3] *Тимирязев институты* – Тимирязев исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясе күздә тотыла булса кирәк.

*75 бит.*

**Алар җиңелделәр.** «Азат хатын» журналының 1927 елгы 9 нчы (апрель) санында «Һәдия Хәйрулла кызы» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр 1942 елгы җыентыкка кертелгән.

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

[1] *Продразверстка* – хәрби коммунизм чорында (1919–1921) барлык артык игенне мәҗбүри рәвештә дәүләткә тапшыру турындагы дәүләт заданиесе.

*80 бит.*

**Караборынның дусты.** Хикәя 1927 елда төрле рәсемнәр белән бизәлеп, аерым китап булып басылып чыккан (Такташ Һ. Караборынның дусты : балалар хикәясе. М. : СССР халыкларының үзәк нәшр., 1927). Хикәянең язылу датасы анык билгеле түгел. Әлеге басма турында 1927 елның августында Такташ Мәскәүдән Фәхрелислам Агиевның (1887–1938, язучы-педагог; 1913–1916 елларда «Ак юл» исемле балалар журналының редакторы) «Караборынның дусты» дөнья күрде» дип белдереп язган хатын ала. Хатның язылу датасы –1927 ел, 11 август.

Беренче тапкыр язучының 1942 елгы «Әсәрләр» җыентыгына кертелгән. Моннан ары хикәя Казанда аерым китап булып та, мәктәп сериясендә басылган кечкенә җыентыкларда да күп тапкырлар чыга. Әсәр СССР халыклары һәм чит ил телләрендә дә басыла. Беренче башлап 1928 елда ук хикәя башкорт теленә тәрҗемә ителә (Такташ Һ. Каратанауның дусты. Уфа : Башкнига, 1928). Русчага китапны төрле вакытта өч кеше тәрҗемә иткән: 1. Друг Черномордого : рассказ для младшего школьного возраста / пер. Х.Абдуллина. Казань : Таткнигоиздат, 1957; 2. Друг Черноносого / пер. В.А.Осеевой. М. : Детгиз, 1958; 3. Друг Черномордого : повесть для детей младшего школьного возраста / пер. Я.Мустафина. Казань : Татар. кн. изд-во, 1974. Молдаван телендә, русчадан В. Мындыкану тәрҗемәсе: Друг Черноносого : повесть. Кишинев : Картя молдовеняскэ, 1963. Монгол телендә русчадан Шалданбалсан тәрҗемәсе: Друг Черноносого : рассказ. Монголия : Улан-Батор, 1959.

Текст 1927 елгы китаптан алынды.

*90 бит.*

**Иркә солдат.** «Походта» газетасының 1927 елгы 23 сентябрь (4 нче) санында, шуның белән бер үк вакытта «Авыл яшьләре» журналының 1927 елгы 9 нчы (сентябрь) санында басылган. «Походта» газетасындагы текст кыскарак. Биредә «Аның рәтсез, ашыгып-пошыгып киенгән аяклары...» дип башланган абзацтан соң түбәндәгечә тәмамлана: «Менә Сәрбие аны сагынып кырдан кайта. Ул бүркен кәкре киеп кырдан җырлап кайта...

– Сөбханалла! – Иркә солдат, уйлый-уйлый, үзе дә сизми чокырга килеп төште.

Ә еракта төнге, караңгылыкны ярып, кызылармеецларның:

– Кызыл гаскәргә штыклар булыр әле,
Большевиклар синсез дә торыр әле! –

дип җырлаулары ишетелә иде».

*«Походта»* – Зөя (хәзерге Свияжск) шәһәрендә маневрлар чорында бер ягы рус телендә, икенче ягы татар телендә чыгып килгән газета (ежедневная маневренная газета Политотдела Казанской стрелковой дивизии).

Такташ 1927 елның сентябрь аенда маневрларда була һәм анда ул «Походта» газетасында эшли. Язучының кайбер әсәрләре беренче тапкыр шушы газетада басыла.

Такташ җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Авыл яшьләре»ннән алынды.

[1] *Терармеецлар* – территориаль армиядә хезмәт итүчеләр.

*Терармия* (территориаль армия) – бер территориядә яшәүчеләрдән, ягъни җирле халыклардан оештырылган гаскәрләр. Гадәттә андый хәрби частьлар көзен оештырыла һәм аларны көзге маневрлар дип тә атыйлар.

[2] *Каптенар* (каптенармус) – армиядә азык-төлек, кием-салым һәм коралларны саклау һәм бирү белән шөгыльләнүче кеше.

[3] *Трещотка* – шартлау, шау-шу, еш һәм өзек-өзек тавышлар чыгарып, гадәттә, әйләнеп торучы җайланма, корал.

*94 бит.*

**Ул көннәрдә.** «Азат хатын» журналының 1927 елгы 14 нче (октябрь) санында «Һәдия Хәйрулла кызы» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр язучының 1942 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст «Азат хатын»нан алынды.

*98 бит.*

**Кияү.** «Азат хатын» журналының 1928 елгы 9 нчы санында «Хәйрулла кызы» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр язучының 1953 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст «Азат хатын»нан алынды.

*104 бит.*

**Соңгы елмаю.** «Азат хатын» журналының 1928 елгы 18 нче (октябрь) санында басылган. Беренче тапкыр Такташның 1953 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст «Азат хатын»нан алынды.

[1] *Волость* – патша Россиясендә һәм СССРда 1929–1930 елларга кадәр өяз составына кергән кечерәк административ-территориаль берәмлек; шул идарә урнашкан авыл, волость үзәге.

[2] *...әгъза булып йөри торган...* – «авыл советы әгъзасы» дигән мәгънәдә.

[3] *Кантон* – Татарстанда 1921–1926 еллардагы территориаль-административ берәмлек.

[4] *Ячейка* – башлангыч комсомол оешмасы.

[5] *«Әлхәм» сүрәсе* – Коръәннең 1 нче сүрәсе («Фатиха» сүрәсе).

*109 бит.*

**Сез икегез дә гаепле...** «Азат хатын» журналының 1929 елгы 1–2 нче (30 гыйнвар) санында «Хәйрулла кызы» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

ВАРИАНТЛАР, ПЛАН-СЫЗМАЛАР

*120 бит.*

**«Таң җиле» романының вариантлары.**

*120 бит.*

**Аючылар.** «Таң җиле» романының бер бүлеге варианты. 1942 елгы җыентыкта басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–12 п. 350 с.б.).

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

*123 бит.*

**Морат.** «Таң җиле» романының бер бүлеге варианты. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–12 п. 351 с.б.). Авторда бүлекнең исеме юк. Укыганда җайлылык өчен исем төзүче тарафыннан куелды.

Беренче тапкыр басыла.

[1] *«Воскресение»* («Яңадан туу») – Л.Н.Толстойның (1828–1910) 1900 елда чыккан романы.

*126 бит.*

**Юкәчеләр.** «Таң җиле» романының бер бүлеге варианты. «Рөстәм Дашкова белән очрашуының...» һәм «Габбас агай...» дип башланган бүлекләр архивта аерым дәфтәрләрдә саклана (ТА. 2–6 п. 335 с.б. һәм ТА. 11–1 п. 1141 с.б.). Эчтәлекләре белән бу бүлекләр бер-берсенең дәвамы булып аңлашылганга, алар тоташ бер кисәк итеп бирелә. Авторда бүлекнең исеме юк. Укыганда җайлылык өчен исем төзүче тарафыннан куелды.

Беренче тапкыр басыла.

*132 бит.*

**Хәмит белән Арыслан турындагы әсәрнең план-эчтәлеге.** Кульязмасы архивта саклана (ТА. 2–8 п. 346 с.б. 1–6 б.).

Беренче тапкыр басыла.

[1] *Палун* – руста: план яки позьма – өй, каралтылар, йорт урнашкан урын, усадьба. Такташ бу сүзне, гомумән, «йорт», «корылма» мәгънәсендә кулланган булса кирәк.

*137 бит.*

**Хәмит белән Арыслан турындагы әсәрнең язылган кисәкләре.** Кульязма каралама хәлендә архивта саклана (ТА. 2–12 п.с. б. 1–3 б.).

Беренче тапкыр басыла.

ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ТӘНКЫЙТЕ МӘКАЛӘЛӘРЕ

*140 бит.*

**«Оҗмах кошы».** «Эшче» газетасының 1922 елгы 1 сентябрь (16 нчы) санында «Һади Такташ» имзасы белән басылган. Шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнашның (1898–1946) шул исемдәге әкият-пьесасына рецензия. «Оҗмах кошы» 1922 елда Казанда Татарстан дәүләт нәшриятында аерым китап булып чыга.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Эшче»дән алынды.

[1] *«Күк кош»* – Бельгия язучысы Морис Метерлинкның (1862–1949) 1908 елда язган әкият-пьесасы. Әсәр шул ук елда русчага тәрҗемә ителә һәм театр сәхнәләре өчен бик популяр пьесага әверелә. 1909 елда С.Рәмиев аны татарчага тәрҗемә итеп бастыра (Бәянелхак. 1909. № 487–488).

[2] *«Суга баткан чаң»* («Потонувший колокол») – немец язучысы Гергарт Гауптман (1862–1946) әсәре. 1896 елда язылган. 1898 елда рус теленә тәрҗемә ителә һәм шул ук елда Мәскәү театрында премьерасы була. 1920 елда пьеса татар теленә тәрҗемә ителә һәм шул ук елда сәхнәдә дә куела.

[3] *Нигәдер Бурнаш иптәш, материалистларның «Сәнгать – тормыш өчен!» дигән әдәбияттагы шигарьләреннән читтә булып...* – Һ.Такташ, «Оҗмах кошы» әкият-пьесасына нигезләнеп, Бурнашны «идеалист шагыйрьләр юлы белән бару»да гаепли. «Оҗмах кошы» әсәре исә мондый ук кискен нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек бирми – әкият һәм миф геройлары да реалистик әдәбиятта сурәтләнергә хаклылар.

*141 бит.*

**Оперетта каһарманнары.** «Безнең байрак» газетасының 1923 елгы 10 апрель (12 нче) санында «Театр вә әдәбият» рубрикасы астында имзасыз басылган. Шагыйрь Әбрар Сәгыйдинең (1895–1939) «Сак-Сок» исемле драмасы буенча куелган спектакльгә рецензия. Пьеса беренче тапкыр 1923 елның 4 апрелендә сәхнәгә куела. Такташ мәкаләсендә шул чор репертуарларындагы аерым кимчелекләрне дөрес тотып ала һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын хаклы рәвештә хәзерге тормышның иң тирән җырләрен чагылдырырга чакыра. Шул ук вакытта мәкаләдә әдипнең «Башмагым», «Талир тәңкә» кебек үткән чорны яктырткан пьесаларны үтә кискенлек белән тәнкыйть итеп, урынсызга юкка чыгаруы да күренде.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Татар дәүләт театры* – хәзерге Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

[2] *«Башмак»* – Хәбибулла Ибраһимовның 1922 елда халык авыз иҗатына таянып язган «Башмагым» исемендәге музыкаль комедиясен көлеп шулай атый. Соңыннан бу әсәрнең Таҗи Гыйззәт тарафыннан эшләнгән яңа варианты буенча Җәүдәт Фәйзи оперетта иҗат итте.

[3] *«Пороховой Фатих»* – шагыйрь Кәрим Әмири (1893–1962) әсәре.

[4] *«Хәмит»* – француз драматургы Ж.-Б.Мольер (1622–1673) пьесасы. Г.Камал аны 1912 елда тәрҗемә итә. Үзенең истәлек язмасында ул бу пьеса турында болай ди: «Театр куюлар көчәя, ләкин пьесалар юк... Төркиядән алып кайткан китаплар арасыннан алып, «Пинти Хәмит» дигән нәрсәне «Саран» исеме белән тәрҗемә кылып, «Гасыр» көтепханәсе аркылы бастырып чыгарам. Ул Т.Кассап дигән бер бәндәнең Мольердан алып, төрек тормышына күчереп, үзенеке итеп язган бернәрсә булып чыга. Аның сере

ачылгач, Мольерны укырга тотынып, аннан берникадәр нәрсәләр тәрҗемә кылам...» (Камал Г. Әсәрләр. Казан : Татгосиздат, 1951. 2 т. 267 б.). Пьеса ул заманда «Саран», «Саран Хәмит», «Хәмит» исемнәре белән аталып йөртелгән.

[5] *«Талир тәңкә»* – Таҗи Гыйззәт (1895–1955) пьесасы, 1922 елда язылган, соңыннан, автор тарафыннан үзгәртелеп, «Чаткылар» (1934) исеме белән мәгълүм.

[6] *Бәлки, Алафузов, Мулланур Вахитов клубы заводына...* – Алафузов заводы клубы хәзерге Гладилов урамы, 51 нче йортта урнашкан булган. Октябрь революциясеннән соң завод эшчеләре үзешчән театр труппасы төзиләр, ул «Елга аръягы труппасы» дип йөртелә. Алафузов фабрикасы эшчеләр труппасы да аңа кушыла. Җитен комбинаты Мәдәният йорты дип йөртелә. 1996 елдан Татар яшьләр театрына бирелә.

Мулланур Вахитов клубы ул вакытта Мулланур Вахитов исемендәге химкомбинатның идарәсе урнашкан бинада эшләгән. 1922 елга кадәр «театр» исемен йөртә. 1927 елда клуб өчен агачтан махсус бина төзелә (хәзерге Тукай урамы, 148 нче йорт).

Такташ бу «клубларның заводы» дип әһәмиятлелеге ягыннан төрле дәрәҗәдәге пьесаларны сәхнәләштерү белән мавыгучы, ягъни спектакльләрне «эшләп чыгаручы» предприятие мәгънәсендә ирония белән атый.

[7] *Габитовлар* – артист, «Елга аръягы труппасы» әгъзасы, үзешчән художник Сафа Габитов турында сүз бара. Ул кайбер пьесаларны сәхнәгә куйган, спектакльләргә декорацияләр ясаган, үзе дә пьесалар язу белән шөгыльләнгән.

[8] *«Галиябану»* – драматург Мирхәйдәр Фәйзи (1891–1928) драмасы. 1916 елның көзендә языла. Пьеса сәхнәгә беренче тапкыр 1917 елның 19 мартында Оренбургта «Нур» труппасы тарафыннан куела. Әсәр беренче тапкыр 1922 елда Казанда Татарстан дәүләт нәшриятында аерым китап булып басылып чыга.

[9] *«Яшь йөрәкләр»* – шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнаш (1888–1946) драмасы. 1917 елда языла. Пьеса 1920 елда Казанда «Алга» китапханәсе басмасында аерым китап булып басылып чыга. 1918 елда беренче тапкыр сәхнәгә куела. 1935 елда Казанда әсәрнең төзәтелгән икенче басмасы аерым китап булып чыга.

[10] *...бер авылга «мулла» булып...* – Ә.Сәгыйдинең авылда мулла булуына ишарә. Ә.Сәгыйди муллалыгын ташлый, бу турыда газетада бастырып чыгара.

[11] *«Тәфтиләү»* – авторы әлегә ачыкланмады.

[12] *«Йосыф-Зөләйха»* – артист һәм драматург Кәрим Тинчурин (1887 –1947) драмасы. 1918 елда языла. Шул ук елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела. Комедия беренче тапкыр К.Тинчуринның 1969 елда Казанда чыккан «Сайланма драмалар һәм комедияләр» китабында басыла.

*143 бит.*

**Иҗадиятем турысында.** Шагыйрьнең беренче җыентыгы «Җир уллары трагедиясе»ндә (Һ.Такташ мәҗмугаи асаре. Казан : «Корылтай» ширкәте нәшере, 1923. 1 т. 1 кит.) шигырьләр бүлегенә сүз башы итеп басылган.

Текст 1923 елгы җыентыктан алынды.

Бу мәкаләсендә Һ.Такташның шул еллардагы катлаулы әдәби-эстетик карашлары чагыла. (Бу мәкалә турында түбәндәге әдәбиятны карагыз: Хәйри Х. Татар совет әдәбиятында реализм мәсьәләләре. Казан : Татар. кит. нәшр., 1960; Госман Х. Такташ поэзиясе. Казан : Татгосиздат, 1953; Юзиев Н. Татар совет поэзиясенең поэтикасы : докт. дис. 1971.)

Г.Халит бу мәкалә уңае белән болай дип язды: «Такташ декларациясе шул вакытларда имажинистлык һәм футуристлык рухында тәкъдим ителгән бөтенләй «яңа», бөтенләй «ирекле» шигырь турындагы карашлардан принципиаль ягы белән аерылып торды: анда сүз һич тә элекке поэзиянең барлык кануннарына каршы куелган «гаять нечкә аһәңле, гали гармонияле ирекле шигырьгә күчү» турында бармады, хәтта «ирекле шигырь» дигән атама да кулланылмады. «Татарның иске шигъри өслүбе җимерелергә тиешле» дигән принцип та әле Такташның гомумән иске поэзияне төбе-тамыры белән кире кагуы турында сөйләргә нигез була алмый. Киресенчә, шагыйрь яңа, заманга лаеклы поэзиянең стиле (өслүбе) һәм формасы үзгәрергә тиешлеген тоеп, традицион шигырьне яңарту кирәклеген, төгәлрәк әйткәндә, аның интонацион-ритмик ирекләлеген таләп итте һем шуны үз иҗат практикасында тормышка ашыра башлады» (Халит Г. Шагыйрь, чор, герой. Казан : Татар. кит. нәшр., 1971. 78 б.).

[1] *Кулыгыздагы мәҗмуга...* – 1923 елда басылган «Җир уллары трагедиясе» мәҗмугасы (җыентыгы).

[2] *Бакырганидан алып...* – сүз Урта Азия суфи шагыйре, Хуҗа Әхмәд Ясәви (1166 елда үлгән) шәкерте Сөләйман Бакыргани (Хәким ата, 1186 елда үлгән) турында бара. Идел буе халыкларына ул мәдрәсәләрдә иң күп таралган китапларның берсе булган «Бакырган китабы» исемле шигырьләр, хикәяләр җыентыгы-антологиясе (Казанда беренче тапкыр 1846 елда басылган) аркылы мәгълүм. Китапта Айкани (XIV), Кол Гобәйди (XVI), Бабарәхим Мәшрәб (XVII) һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләре белән бергә, «Хәким», «Хәким хуҗа», «Сөләйман», «Сөләйман Бакыргани» имзалары белән Бакырганиның да байтак шигырьләре урнаштырылган. Басылган әсәрләрнең күбрәге аныкы булган өчен, җыентык «Бакыргани китабы» дип атала.

*144 бит.*

**«Адашкан күңел».** «Татарстан» газетасының 1924 елгы 16 гыйнвар (11 нче) санында «Һади» имзасы белән басылган. Драматург М.Фәйзинең (1891–1928) шул исемдәге драмасына рецензия. Пьеса 1922 елның июнендә языла башлап, 1923 елның гыйнварында Уфада язылып беткән. 1923–1924 елгы сезонда әсәр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела. Пьеса беренче тапкыр М.Фәйзинең 1957 елда Казанда чыккан сайланма әсәрләрендә басыла.

М.Фәйзи шул мәкалә чыккан көнне үзенең көндәлегенә: «3 гыйнвар. «Татарстан»да Такташның тәнкыйте чыкты. Ифрат җәяүле рәвештә тәнкыйтенә хәйран булдым...» – дип язып куя. Көндәлектә число иске стильдә язылган (Казан дәүләт университеты, кульязмалар бүлеге. М.Фәйзи фонды. 56 дәфт.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Ильская ханым* – Фатыйма Ильская (1902–1984) РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы. Бу спектакльдә ул Хәдичә ролен башкара. Артистканың әлеге спектакльдә уйнавы турында Б.Гыйззәт болай яза: «Гәрчә Ф.Ильская мондый рольләргә күнекмәгән булса да, аның талантына романтизм сыйфатлары гына түгел, бәлки реалистик сыйфатлар да хас икәнлеге ачыла: рольне ул искиткеч осталык белән башкарып чыга» (Татар совет театры. 1975. 116 б.).

[2] *Вәлишин* – Вәлишин Мөхәммәт (1883–1932), артист.

[3] *Кугушева* – Мәрьям Сульва (1891–1966), актриса, ТАССРның атказанган артисткасы.

*145 бит.*

**Кари кичәсе.** «Татарстан» газетасының 1924 елгы 2 апрель (63 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Кичә бик зур әзерлек белән, күп көч катнашлыгында үткәрелә. Булачак кичә турында «Татарстан» газетасында өч тапкыр белдерү бирелә: 10 март (49 нчы) санында кичәнең кайчан булачагы һәм кемнәр катнашачагы хәбәр ителә; 16 март (52 нче) санында Г.Кариевның иҗат юлы тасвирлана һәм кичә уздыруның максаты әйтелә; 27 март (59 нчы) санында булачак кичәнең эчтәлеге бирелә. Кичә Кариевның туган авылы Күлбай Морасада (элеккеге Чистай өязе, хәзерге Нурлат районы) салынып ята торган халык йорты файдасына ясала. Артист Әсгать Мәҗитов мәкаләсендә (Татарстан. 1924. 16 март) болай диелә: «...авылдашлары – крәстияннәр ачлык вакытларга, авыр дәвер кичерүгә карамастан, үзләре арасыннан чыккан бөек Габдулланы мәңге онытмас өчен халык йорты салган булсалар, сәхнә аша Каридан тәрбия алган Казан халкы шул халык йортын тәмамлау өчен ясалачак кичәгә катнашулары белән материальный зур ярдәм күрсәтергә тиешләр. Кариевны яраткан, ул уйнаганда елаган, көлгән халык – барыгыз да дәүләт театрына рәхим итегез!»

Шушы кичәгә багышлап, Такташ «Карт артист» исемле шигырен дә яза, шигырь «Татарстан» газетасының 1924 елгы 31 март (61 нче) санында чыга.

[1] *Кари* – Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин, 1886–1920), артист, режиссер, татар профессиональ театрына нигез салучы.

[2] *«Чабатаңны кемгә тукыйсың?»* – язучы К.Нәҗми (1901–1957) әсәре, 1922 елда язылган. «Киләләр» трагедиясеннән бер монолог» дигән искәрмә белән К.Нәҗминең «Өермәләр» (1924) исемле җыентыгында басылган.

[3] *Уразиков* – Хөсәен Уразиков (1894–1970), РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты.

[4] *Тарханов* – Барый Тарханов (1892–1933), артист.

[5] *Бөдәйли* – Мәхмүт Бөдәйли (1895–1975), язучы, журналист.

[6] *Абруй* – Сәйфи Абруй (1890–1960), журналист, педагог, үзешчән артист, җырчы.

[7] *Маяковскийның «Сул белән» дигән әсәре* – рус шагыйре В.В.Маяковскийның (1893–1930) «Сул марш» («Левый марш», 1918) шигыре турында сүз бара.

[8] *«Яңа Печән базары»* – К.Нәҗми үзенең «НЭП елларында Печән базары» исемендәге шигырен, сәхнәләштереп, шулай атаган. Бу әсәр бераз үзгәртүләр белән язучының «Якты сукмак» (1951) исемле җыентыгына кертелгән.

*146 бит.*

**Кино – «Кызыл партизаннар».** «Татарстан» газетасының 1924 елгы 3 декабрь (235 нче) санында «Театрларда» дигән рубрика астында басылган. Замандашларының сөйләвенә караганда, Такташ кино карарга бик яраткан. Архивында аның яңа кинокартина карауга (просмотрга) килүен үтенеп язылган чакыру кәгазе дә, киноларга даими кереп йөри торган ике урынлык билет та саклана.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *«Унион»* – Казанның Бауман урамындагы хәзерге «Родина» кинотеатры элек шулай аталган.

[2] *Колчак* – Александр Васильевич Колчак (1873–1920), патша адмиралы.

*146 бит.*

**«Дантон».** Рецензия Казан дәүләт университеты гыйльми китапханәсендәге кульъязмалар бүлегендә Имай Насыйриның «Дантон» исемле әсәре (933. ТЭ № 4476) арасыннан табылган. Кульъязма шагыйрьнең русча һәм татарча «Һади Такташ» дип басылган, 9х19,5 см зурлыктагы хосусый бланкысына язылган. Аста «1925 ел, январь» диелгән. Такташ кул куйган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Насыйри иптәшнең «Дантон» дигән нәрсәсен...* – башкорт язучысы һәм журналисты Имай Насыйриның (1898–1942) шигырь белән язылган шул исемдәге трагедиясе. Кульъязма әсәр университет китапханәсенә Татарстанда нәшрият эшләренә җитәкчелек иткән, ТАССР Мәгариф министрлыгы каршындагы Гыйльми үзәк архивы белән кергән. Дәфтәр эчендә авторның әсәре хакында Татарстан Мәгариф комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәккә, Галимҗан Ибраһимовка (ул вакытта Ибраһимов – Гыйльми үзәкнең рәисе) мөрәҗәгать сүзләре бар. Гыйльми үзәк рецензия язу өчен кульъязманы шагыйрь Һади Такташка тапшыра.

[2] *Дантон* – Жорж Жак Дантон (1759–1794), XVIII йөздәге француз буржуаз революциясенең күренекле җитәкчеләреннән берсе, якобинчы. Ул бик көчле оратор һәм оештыручы булган.

[3] *Робеспьер* – Максимильен Мари Изидор де Робеспьер (1758–1794), француз буржуаз революциясенең күренекле җитәкчеләреннән берсе, якобинчы.

[4] *...Дантон белән Робеспьер арасындагы разногласие...* – сүз Франциядә буржуаз революцияне тормышка ашыру процессында алар арасында барлыкка килгән фикер каршылыклары турында бара.

*147 бит.*

**Эшче-крәстиян яшьләре әдәбияты.** «Октябрь яшьләре» журналының 1925 елгы 6 –7 нче саннарында басылган.

Редакциядән мондый сүзләр язылган: «Редакция Такташ иптәшнең авыл яшьләре өчен әдәбият кирәк, хәзерге шигырь язучылар шуны уйлана башласыннар дигән фикеренә кушыла һәм авылдагы иптәшләр укытучы, хәбәрчеләрдән редакциягә авылда сөйләнеп йөри торган хикәя, җырлана торган җырларның җибәрелүен көтә».

Такташ иҗатын өйрәнүче кайбер галимнәр, шагыйрь бу мәкаләсен 1925 елның 1 июлендә «Правда» газетасында партия Үзәк Комитетының «Художестволы әдәбият өлкәсендә партиянең политикасы турында»гы 18 июнь резолюциясе басылганнан соң, шуңа җавап итеп язган, диләр. Ләкин бу дөреслеккә туры килми. «Октябрь яшьләре» журналы 1924 елның май-июненнән (1–2 нче саннар) чыга башлый. 3–4, 5 нче (1924), 6–7 нче (1925) саннарында айлары күрсәтелмәгән. 8 нче саны – апрель, 9 нчы саны – май, 10 нчы саны июнь дип куелган. Димәк, бу мәкалә басылып чыккан 6–7 нче саннар 1925 елның гыйнвар-март айларына туры килә. Шул сәбәпле Такташ әлеге мәкаләсен 1924 елның ахырларында яисә 1925 елның башларында язган дигән нәтиҗә чыга.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *... милли каһарманнар тудыралар иде.* – Һ.Такташ Октябрь революциясенә кадәрге татар әдәбияты «милли байларга, милли муллаларга, милли миңлеләргә хезмәт итеп килде», «алган тормышы, язган нәрсәләренең каһарманнары да милли бай, милли миңлеләрдән булды», «теле, тормышы белән дә эшче-крәстияннәргә ят булды» дигән белән ялгыша. Мондый карашлар шагыйрьнең шул чор әдәбият атмосферасында аерым мәкаләләрдә яңгыраш тапкан пролеткультчылык рухындагы концепцияләргә иярүен күрсәтте.

[2] *... үз җырларын гына җырлыйлар иде.* – Эшче һәм крестьяннарның татар әдәбиятында сурәтләнүләре, аларның әдәби «репертуарлары» мәсьәләсендә дә Такташ бу мәкаләсендә дөрес үк фикер йөртми.

*149 бит.*

**Комсомол җырлары.** «Авыл яшьләре» журналының 1925 елгы 4 нче (октябрь) санында «Китаплар арасында» исемле рубрика астында басылган. Мансур Крыймовның шул исемдәге җырлар җыентыгына (М. : Нәшрият кооперативы нәшере, 1925) рецензия.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Крыймов* – Мансур Крыймов (1898–1938), татар совет шагыйре. 20 нче елларда «Эшче», «Яшь эшче», «Игенчеләр» газеталарының һәм «Ударниклар», «Кечкенә иптәшләр» журналларының актив язышучысы. Күпсанлы шигырь җыентыкларының авторы. 1961 елда аның «Шигырьләр, поэмалар» исемле җыентыгы басылып чыга.

[2] *«Кызыл Бәдәвам»* – М.Крыймовның 1925 елда Казанда «Нәшер» матбугатында чыккан шигырьләр җыентыгы.

[3] *«Кузнецы»* – биредә 1912 елда эшче шагыйрь Ф.С.Шкулев (1868–1930) сүзләренә язылган һәм революциядән соң халыкара революцион җыр булып киткән «Мы – кузнецы» дигән җыр турында сүз бара. Җыентыкта Крыймовның бу көйгә салып язган шигыре «Без – тимерчеләр» дип атала.

[4] *«Озату»* («Проводы») – 1918 елда композитор Д.С.Васильев-Буглайның Д.Бедный (1883–1945) сүзләренә язган җыры. Җыентыкта «Ана һәм кыз», «Без – комсомоллар» һәм «Озату» шигырьләре шушы көйгә атап язылганнар.

*150 бит.*

**И.Рәми хикәяләре турында.** «Совет әдәбияты» журналының 1933 елгы 11–12 нче (ноябрь-декабрь) саннарында басылган, ахырга «25.X.31» дип дата куелган. Мәкалә алдыннан редакция тарафыннан мондый сүзләр язылган: «Шагыйрь Һ.Такташның үлүенә ике ел тулу уңае белән Һ.Такташның басылмаган мәкаләсе (түбәндәге мәкалә) шагыйрь Һади Такташның үз иҗатының соңгы елларында совет әдәбиятының юмор-сатира тармагына ничек каравын характерлаган бер материал итеп урнаштырыла. Шуның белән бергә редакция Һади Такташның бу мәкаләсенең И.Рәминең көлке әсәрләрен һәр яктан тулы-киң итеп анализлаган, аның сыйнфый-иҗтимагый нигезен ныклап ачкан мәкалә булып җитмәвен әйтеп китә һәм алдагы саннарның берсендә бу турыда аерым тукталып үтүне кирәк саный».

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Исмәгыйль Рәмиев иптәшнең көлке хикәяләре җыентыгын карап чыктым.* – Исмәгыйль Рәмиев (1893–1969), журналист, библиограф. Аның бу җыентыгының басылып чыгуы турында мәгълүматлар юк.

[2] *Печән базары* – XVIII гасырның икенче яртысында барлыкка килә һәм 1930 елларга кадәр яши. Казанның хәзерге Мәскәү, Париж Коммунасы һәм Татарстан урамнарының шактый өлешен биләп, татар байларының эреле-ваклы кибетләре, складлары, харчевнялары белән беррәттән, газета-журнал редакцияләре, «Болгар», «Амур», «Сарай» кебек Ф.Әмирхан, Г.Тукай һ.б. күренекле кешеләр яшәгән кунакханәләр дә шул тирәдә урнашкан булган. Татарлар өчен яңалыклар белән уртаклашу, хәбәрләшү үзәге булып киткән бу атаклы базар һәм аның халкы – сатучылары, алучылары, гайбәтчеләре, алдакчылары Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Исхакыйларның әсәрләрендә тәнкыйть һәм сатира объекты булып хезмәт итәләр.

Җамал Вәлиди болай ди: «Печән базары» дигәч тә, гади бер печән сата торган урын дип уйларга ярамый. Анда татарның әдәби, икътисади хәяты тәмаркәз итә. Ул татар тормышының иң җанлы бер сәхнәсе. Анда безнең көленерлек, хурланырлык йиремез никадәр күп булса, мактанырлык, куанырлык йиремез дә шундадыр. Шуның өчен инде «Печән базары» дигән сүзне һәрвакыт бер истихкар вә истиһа мәкамендә кулланудан туктарга вакыт!» (Бер ел узгач // Вакыт. 1914. 6 февр.).

[3] *«Ялт-йолт»* – 1910–1918 елларда Казанда чыккан (демократик юнәлешле) сатирик журнал.

[4] *«Советский намаз»* – хикәя, «Чаян» журналының 1929 елгы 8 нче (август) санында «Ганкәбүт» имзасы белән басылып чыккан.

*151 бит.*

**Шигырьләр турында бераз әңгәмә.** «Авыл яшьләре» журналының 1925 елгы 6 нчы (декабрь) санында имзасыз басылган. Х.Госманның «Егерменче елларда татар поэзиясе» (Казан, 1964, 211 б.) китабында мондый юллар бар: «Мәкаләнең Такташ тарафыннан язылган булуын журналның шул вакыттагы редакторы Ш.Фәхретдинов имзасы белән раслады».

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*«Авыл яшьләре»* – Казанда 1925 елның июленнән 1930 елның февраленә кадәр шул исемдә, 1930 елның 2 нче санынннан 1938 елның февраленә кадәр «Колхоз яшьләре» исеме белән чыккан журнал. ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршындагы татар-башкорт яшьләр бюросы органы.

*153 бит.*

**«Әрә егете» үлде.** «Татарстан» газетасының 1926 елгы 21 июль (161 нче) санында басылган. Такташның 1953 елгы җыентыгына (Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр / төз. Х.Госман. Казан : Татгосиздат, 1953) кертелгән. Шагыйрь Исмәгыйль Закириның үлүе мөнәсәбәте белән язылган некролог.

Текст 1953 елгы җыентыктан алынды.

[1] *Исмәгыйль Закири* (1896–1926) – Татарстанның Яшел Үзән районы Әрә авылында туган һәм яшәгән, «Исмәгыйль Закири», «Инвалид Закири», «Әрә», «Әрә егете» дигән имзалар белән язылган шигырьләре «Татарстан» газетасында, «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре», «Азат хатын», «Чаян» журналларында басылган.

[2] *«Чаян»* – 1923 елның гыйнварыннан чыгып килгән сатирик-юмористик журнал. 1923 елда «Чаян» журналында И.Закириның «Куркам» (3 нче), «Җырлыйлар», «Эпиграммалар» (4 нче), «Шагыйрьләребез» (7 нче), 1924 елда «Мулла җыры» һәм «Авыл җырлары» (1 нче), «Яңа җырлар» (3 нче), «Кызыл сәүдәгәр җыры» (12 нче) һ.б. шигырьләре басылып чыга.

Исмәгыйль Закириның «Авыл яшьләре» журналында 1925 елда «Авыл кызының җыры», «Урак җырлары» (1 нче), «Безнең җырлар» (5 нче), «Көтүче җыры» (6 нчы), 1926 елда «Киндер күлмәк» (3 нче), «Авыл урамында», «Мәгъшука җыры», «Авыл кызы» (8 нче), «Киндер тукмаклаганда» (10 нчы) шигырьләре басыла.

Журналның 1925 елгы 1 нче санында Такташның Исмәгыйль Закири белән бергә язган «Авыл кызлары» исемле шигыре бар.

[3] *...редакциягә шундый бер хат җибәрде.* – Текст «Октябрь яшьләре» журналы идарәсенә хат» дигән баш астында шул исемдәге журналның 1925 елгы 8 нче санында басылган. Шунда ук Закириның «Яңа авыл җырлары» бирелгән. Текст «Авыл яшьләре» журналында күренмәде. «Октябрь яшьләре» журналы (1924, май – 1925, июнь – барлыгы 10 сан чыккан) «Авыл яшьләре»нең элгәресе булган. Такташ бу журналда да җаваплы секретарь булып эшләгән. Язучы биредә «Октябрь яшьләре» диясе урында, ялгыш «Авыл яшьләре» дип атаган булса кирәк.

[4] *Безнең журналга...* – «Авыл яшьләре» журналына.

[5] *Эрмитаж бакчасындагы Комклуб фотографына...* – Комклуб (Коммунистический клуб) хәзерге Щапов урамының үрге башындагы Эрмитаж бакчасында агач йортта урнашкан булган. Хәзер ул йорт сүтелгән. Эрмитаж бакчасы исә кечерәйтелгән килеш әле дә сакланган.

Исмәгыйль Закириның рәсеме журналларда күренмәде.

[6] *...империалистлар сугышы* – 1914 елның 19 июлендә (1 августта) башланган Беренче бөтендөнья сугышы турында сүз бара.

[7] *Эсперантский* – Мәгъҗан Эсперантский (1905–1925), яшь язучы. Әстерханда туган. 1919 елда типографиядә наборщик булып эшли. Шул вакытта ук газеталарда эшчеләр тормышыннан мәкаләләр яза. 1920 елда Әстерханда эсперанто оешмасы курсларында укый. Гаҗәп сәләтле Мәгъҗан тиздән эсперанто телендә чит ил эшчеләре, коммунистлары белән хат алыша башлый. Германиядәге эсперанто ассоциациясе җәмгыяте чыгара торган журнал һәм газетаны алып бара һәм үзенең дә мәкаләләрен шунда җибәрә.

Эсперантский Әстерханда, аннары Казанда партия мәктәпләрендә укый. Соңыннан Мәгъҗан ТКУга укырга керә. Физика, химия фәннәре белән кызыксына, рәсем ясарга сәләтле була. Икенче курста укыганда туберкулез белән авырый башлый. Берничә ай Казанда дәваланганнан соң, Әстерханга кайтып китә. Оста тел белән язылган мәкаләләрен, хикәяләрен «Кызыл яшьләр» газетасына, «Кызыл Шәрекъ яшьләре», «Октябрь яшьләре» журналына җибәреп тора. Эсперанто теле турындагы мәкаләсе «Кызыл Шәрекъ яшьләре»ндә (1924, 1 нче сан), «Эсперанто ничек языла» исемендә басыла. Һәм бу мәкаләнең ахыры «Эсперанто һәм Октябрь яшьләре» исемендә «Октябрь яшьләре» журналында (1924, 1–2 нче сан) чыга.

«Октябрь яшьләре» журналының (1925 елгы 6, 7 нче саннарында) Эсперантскийның рәсеме белән бергә «Үләр алдыннан» шигыре бар.

1926 елда Мәскәүдә Эсперантскийның бер шигырен һәм ике хикәясен үз эченә алган «Алар соңгы мәртәбә җиңелделәр» исемле җыентыгы басылып чыга. Төзүче һәм кереш мәкаләне язучы – Фәрит Яһудин.

*156 бит.*

**Татар хатын-кызлар матбугаты.** «Азат хатын» журналының 1927 елгы 5 нче (гыйнвар) санында «Гөлчәһрә Такташ» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *«Урал»* – 1907 елда Оренбургта чыккан большевистик газета.

[2] *«Фикер»* – 1905–1907 елларда Уральскида чыккан демократик юнәлештәге газета.

[3] *Фатих Әмирхан* (1886–1926) – татар әдәбияты классигы, прозаик, драматург, тәнкыйтьче, публицист. Такташ Ф.Әмирхан әсәрләрен һәм геройларын бәяләүдә шул елларда әдәбият белемендә киң таралган вульгар-социологик фикерләргә таянды.

[4] *«Сөембикә»* – 1913–1918 елларда Казанда чыккан журнал.

[5] *Сакаллы хатын язучылар* – журналда хатын-кыз имзалары белән әсәрләр, мәкаләләр чыгарган язучы-журналистлар күздә тотыла.

[6] *Багъбостан* – Багъбостан Мөэминова,  публицист, педагог.

[7] *Фәхрелбанат Сөләймания* (1857–?) – беренче татар публицист хатын-кызларыннан, укытучы, тәрҗемәче.

[8] *Мәһруй Мозаффария* (1873–1945) – шагыйрә, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

[9] *«Шәрекъ кызы»* – 1918 елда Казанда чыккан журнал.

[10] *«Азат ханым»* – 1917–1918 елларда Әстерханда чыккан журнал.

[11] *«Азат хатын»* – Казанда 1926 елның августында чыга башлап, Бөек Ватан сугышы чорында (1941 елда) тукталып, 1958 елның гыйнварыннан  чыгып килгән журнал. 1991 елдан «Сөембикә» исемендә чыга.

*159 бит.*

**Үзем һәм башкалар турында.** «Безнең юл» журналының 1927 елгы 6, 7 нче (июнь, июль) саннарында басылган. «Безнең юл» журналының беренче саны (1922, май) чыгуга 5 ел тулу уңае белән языла. «Язучылар үзләре һәм безнең әдәбият турында» дигән рубрика астында башта Г.Нигъмәтинең түбәндәге сүзләре бирелә: «Безнең юл»ның 5 елы тулганда каләм гаскәренең матур әдәбият армиясенә бераз туктап китсәк, урынсыз булмас. Матур әдәбият дигәч тә, мин бөтен матур әдәбиятыбызны алмыйм. Аның да һәммә солдатларын алмыйм. «Безнең юл»да язышып, шуның күкрәгендә тәрбияләнеп, шунда үсеп чыкканнарын алам.

Мондыйлар үзләре берничә дистәләргә тулыр. Шулар арасында хәзерге татар революция әдәбияты күгендә йолдыз урынын тота алырлыклары да инде дистәгә җитә яза. Әнә шулар арасыннан мин бишәүне алмакчы булам. Бу бишәү: Кави Нәҗми, Такташ, Туфан, Толымбай, Кутуй. Болар үзләренең әдәби үсешләренең имтиханнарын «Безнең юл» битләрендә бирделәр. Иң матур әдәби парчалары шушы журналда басылып чыкты». Аннан соң берничә бит дәвамында Г.Кутуй, Ш.Госманов, Г.Хәйри, Г.Толымбайский, К.Нәҗми, Һ.Такташларның рәсемнәре белән бергә мәкаләләре басыла.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Сыркыды* – Такташның туган авылы. Элек Тамбов губернасы, Спас өязенә караган, хәзер Мордва республикасы Тарбеево районына керә.

[2] *...үзен-үзе үтерүе турында хәбәр иттеләр.* – Илбарис Надиров һәм Рим Кәримов «Такташ туган авылда» исемле мәкаләдә, Мокамайның бертуганы Фатыйма апа авызыннан ишетеп, болай язалар: «Октябрь революциясеннән соң, 1920 елның җәендә булса кирәк, Мокамайны авыл кулагы Шатай Ибругының арба тәгәрмәчен урлауда гаепләп кулга алалар да авыл советының караңгы базына ябып куялар. Шунда кулаклар һәм алар яклы куштаннар, җыелып, Мокамайны үтергәнче кыйныйлар. Ахырдан, самосуд өчен бәлале булырбыз дип, арадан берсе Мокамай муенына пычак сала. Пычакны кулына тоттырып калдыралар. Хурлыгына чыдый алмый үзен-үзе үтерде дигән хәбәр тараталар.

– Һади булмады шул, Һади, – ди апа. – Ул каядыр укырга киткән иде. Һади булса, Мөхәммәтҗаныбыз исән калыр иде. Аны яклар кеше дә булмады... Мөхәммәтҗан үлгәч, Һадидан хат килгән иде, – дип дәвам итә Фатыйма апа. – «Йөрәгем өзелде инде, апаем, ятим калдым, нишләрмен», – дип ачыргаланып язган иде. Аннан миңа укучы балалар Һадиның Мөхәммәтҗан турындагы бәетен укып күрсәттеләр. Елый-елый күзләрем бетте... Һади да Мөхәммәтҗанны кулаклар үтергәнен белмәгән шул» (Совет әдәбияты. 1951. № 1. 51–58 б.).

Һадилар, Мокамайлар белән бергә үскән Искәндәр Нәдершин болай сөйли: «Бик оялчан иде Мөхәммәтҗан. Ләкин соңыннан батыр егет булды Мокамай. Авыл байларының нindидер кара эшләрен фаш иткәндә кыйнап үтерделәр аны» (Шәйхи М. Бу юллардан нәни Такташ йөргән... // Яшь ленинчы. 1981. № 1).

[3] *...шагыйрьлегемә әниемнең дә зур тәэсире бар.* – Шагыйрьнең әнисе Шәмсениса Фәхретдин кызы Аганина гомеренең соңгы елларын фаҗигале авыру белән үткәрә. Ул җиде ел буена урын өстендә ята. 1936 елның 18 апрелендә алтмыш өченче яшендә Сыркыды авылында үлә. Шәмсениса апаны якыннан белүчеләр аның телгә осталыгы, шагыйрь күңелле, зирәк акыллы хатын булуы турында сөйлиләр. Кече яшьтән авылдагы фаҗигале вакыйгаларга бәетләр чыгарырга яраткан Шәмсениса апа, инде балаларын үстереп, төрлесе төрле якка таралып беткәч тә, аларга шигырь белән хатлар яза. «Ул, яза торгач, ритмлы сүзләргә бирелеп, эчке хисләрен рифмалы юллар белән тезеп киткәли. Больницада дәваланып яткан чагында җибәргән бер хатында:

Әйдә, Һади, бер барыйк
Казан урам буена;
Больницага керермен дип
Һич килмәде уема, –

дип җырын язып куя (Хәйри Х. Һади Такташ. Казан, 1949. 8 б.).

Такташ үлгәч, анасы улына багышлап бәет чыгара:

Кай җирләрдә, балам, синең каберең?
Каен бармы каберең янында?
Рәсмең тора менә күз алдымда,
Үзең юк шул, балам, янымда.

Син утырткан ятим каеннарга
Күз яшьләрдән сулар сибәмен,
Таң алдында каен яфракларын
Җылы йөзең итеп үбәмен.

Таң җилләре, каен башын сыйпап,

Әкрен-әкрен итеп исәләр,
Син үлгәчтен никтер шиңмәделәр,
Каеннарың һаман үсәләр.

Каеннарга сөйлим моңнарымны,
Аңлаган күк тып-тын торалар.
Синең кулың итеп ботакларын
Гүя миңа сузган булалар.

Җәйләр җитте инде, ул каеннар
Яшел яфракларга төренде.
Алар кайгы белми, мәңге шатлар,
Тик әниең шашты, сөренде.

Таң җилләре, каен башын сыйпап,
Әкрен генә һаман исәрме?
Син үлгәчтен шаулап үскән каен
Мин үлгәчтен шулай үсәрме?..

[4] *Унөч-ундүрт яшемдә мәктәпкә әләгеп...* – Такташ Сыркыды авылыннан утыз чакрым ераклыктагы Пешли мәдрәсәсендә өч кыш белем ала. Бередә ул «Вакыт», «Йолдыз», «Ялт-йолт» газета һәм журналларын укый, Тукай, С.Рәмиев шигырьләре белән таныша.

[5] *Сәгыйть Рәми* (Рәмиев) (1880–1926) – татар язучысы, шагыйрь, журналист.

[6] *Егерме ике яшемнән үз өслүбем, үз аһәңчә үземчәлекне сиздем.* – Бу турыдагы фикерләрен Такташ үзенең 1923 елда басылып чыккан «Иҗадиятем турысында» дигән декларациясендә дә язган иде (шушы томның 143–145 нче битләрен карагыз).

[7] *Кави Нәҗми* (1901–1957) – татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе, СССР дәүләт премиясе лауреаты.

[8] *«Безнең юл»* – журнал, 1922 елның май аеннан 1930 елның июнь аена кадәр «Безнең юл», 1930 елның июль аеннан 1932 елга кадәр «Атака», 1933–1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елның июнь аеннан «Казан утлары» исемендә чыгып килә.

[9] *Туфан* – Хәсән Туфан (1900–1981), татар шагыйре, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.

[10] *Кутуй* – Гадел Кутуй (1903–1945), татар язучысы.

[11] *...аны футуризм принциплары үтерә язды.* – Футуризм – XX йөздәге буржуаз сәнгатьтә декадентлык агымнарының берсе. Классик әдәбият һәм сәнгатьнең бөек мирасын кире кагып, футуристлар поэзиядә кабул ителгән формаларга каршы чыктылар, ниндидер аңлаешсыз тел, мәгънәсез сүз әйләнмәләре уйлап чыгарырга омтылдылар. Гадел Кутуй 20 нче еллар урталарында, футурист шагыйрьләр тәэсирендә, шигырь телен үтә катлауландырган шигырьләр язу белән мавыга. Шул характердагы шигырьләренең җыентыгын («Көннәр йөгергәндә», 1925) чыгара. Соңрак Г.Кутуй футуризм принципларыннан читләшә.

[12] *«Безнең юл» мине үстерде.* – «Безнең юл»да Такташ шигыре беренче тапкыр 1922 елгы 4 нче санда басылып чыга («Урман кызы»). Шуннан соң әсәрләре даими рәвештә басылып килә (1923 елда гына да журналның җиде санында Такташ шигырьләре беренче тапкыр дөнья күргән). Шагыйрь журналның редколлегия әгъзасы да була.

*161 бит.*

**Хатынсыз ай, тотнаксыз тәнкыйть.** Х.Хәйринең «Һ.Такташ әдәби тәнкыйть турында» исемле мәкаләсендә (Совет әдәбияты. 1956. № 5), шулай ук аның «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» исемле китабында текст эчендә кыскартулар белән бирелгән (Казан, 1960. 94–101 б.). Архивта мәкаләнең шәмәхә карандаш белән язылган каралама-кульязмасы саклана (ТА. 2–16 п. 405 с.б.). Башына «Кызыл Татарстан» идарәсенә хат урынында» дип куелган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст бик аз гына кыскартулар белән кульязмадан алынды.

Такташ, әдәбият мәйданына килеп кергән көннәреннән башлап диярлек, әдәби тәнкыйть үзәгендә була. Хәтта «Җылтыр күз» имзасы белән «Шак-шок» шаир булды» (Чаян. 1923. № 4), «Берәү» имзасы белән «Инде ачык әйтергә кирәк» (Яңалиф. 1929. № 7) кебек оятсыз пасквильләр дә басыла. Г.Толымбайский Һ.Такташның «Кояш көлми дә, елмаймый да» исемле җыентыгы (1926) чыгу уңае белән язган мәкаләсендә болай ди: «Такташны байтак чәйнәдек инде. Бу чәйнәү, әлбәттә, юкка түгел иде. Бердән, ул әдәбият кырына килеп чыккан зур талант булса, икенчедән, аңарда хәзерге заман теләгенә җавап бирүдән читтә йөрү күренде. Әнә шул ике нәрсә булганга, боларга тагын Такташның көннән-көн хәзерге теләккә якын килүе өстәлгәнгә, Такташ байтак тәнкыйтьләргә очрады ки, соңгы заман язучыларының берсенә дә мондый шәрәф насыйп булганы юк әле. Бездә тәнкыйть эше юлга салынмаганга, очраган бер кеше тәнкыйтьче булырга тырышканга, әлбәттә, башкаларга булган кебек үк, аңар да урынсыз тәнкыйтьләр булгалады. Аңар булган урынсыз тәнкыйтьләрнең зурысы итеп Такташның пролетариат әдәбиятына килү адымнарына күз сала белмәүне, хәзерге язучыларга Такташ язмаларыннан күп кенә нәрсә өйрәнергә мөмкин булуны аермачык итеп әйтеп китәргә кирәк» (Кызыл Татарстан. 1926. 20 март).

Архивта Такташның шундый «тәнкыйтьче булырга тырышучы»ларга карата бер куплет шигыре бар:

Һәр өйрәнчек тәнкыйть язучылар
Һ.Такташны мишень итәләр,
Өйрәнчек яшь хирурглар кебек,
Минем әсәрләрдә «опыт» ясап,

Үтмәс пычак белән кисәләр...
Неужели үтерүдән курыкмыйлар?!

(ТА. 1–19 п. 242 с.б.)

Такташ үз иҗатына һәрвакыт зур җитдилек һәм ышаныч белән карый. Шулай ук ул башкаларның да аңа тиешле җитдилек белән карауларын таләп итә. Үз әсәрләренә бирелгән кайбер тәнкыйтьләргә җавап рәвешендә язылган, вакытында чыкмый калган бу мәкаләсе Такташның әдәби тәнкыйтьне ничек аңлавын ачык чагылдыра.

Хатның редакциягә тапшырылу-тапшырылмавы билгеле түгел. Мәкаләнең язылу датасы куелмаган. Биредә аталган әсәрләрнең һәм тәнкыйть мәкаләләренең чыгу вакытларына нигезләнеп, Такташ бу әсәрен 1927 елның икенче яртысында (июль-августларда) язган дип әйтергә мөмкин.

[1] *...Тамбов урманнары белән саубуллашу шигыре чыкты.* – «Инде бу кырларда...» дип башланган шигыре турында сүз бара, «Безнең юл»ның 1926 елгы 9 нчы (сентябрь) санында басылган.

[2] *Парсин* – Мөхәммәт Парсин (1899–1963), журналист, тәнкыйтьче.

[3] *Есенин* – Сергей Есенин (1895–1925), рус шагыйре.

[4] *Г.Гозәеров иптәш «Давылдан соң»га булган тәнкыйтендә...* – Гозәеровның бу мәкаләсе «Эшче» газетасының Казан китапханәләрендә сакланган саннарында очрамады.

*«Давылдан соң»* – «Безнең юл»ның 1925 елгы 4 нче санында басылган.

[5] *Галимҗан Нигъмәти* (1897–1941) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

Мәкаләдә Нигъмәтинең Такташ әсәрләренә кискенрәк, берьяклырак тәнкыйть белән каравы сизелә. Әмма Нигъмәти соңга таба шагыйрьнең олы талант иясе, чын новатор шагыйрь булуы турында төпле мәкаләләр язды. Такташның бу мәкаләдә чын күңелдән ачынып әйткән «бездә шагыйрьне очраклы «тәнкыйтьчеләрдән» яклаучы тәнкыйтьчеләр юк» дигән сүзләренә «колак салучы» һәм аны надан тәнкыйтьчеләрдән яклаучы да шул ук Г.Нигъмәти булды. Ул 1929 елда ук алда атап үтелгән «Инде ачык әйтергә кирәк» дигән пасквиль иясенә каты протест белән, Такташны яклап, аның «гали»леген күрсәтеп язды: «Ул [«Берәү»] Такташның элеккерәк еллардагы шигырьләре мәҗмугасын ала да, шагыйрьнең «Мәхәббәт тәүбәсе», «Югалган матурлык», «Мокамай», «Алсу» кебек яңа проблемалар күтәреп, яңа типлар биреп чыккан күренекле әсәрләреннән бөтенләй күз йома... Бу язылганнар «Берәү»нең тәнкыйте нинди максат һәм нинди хәзерлек белән язылганын күрсәтсә кирәк. Ул кеше үз исемен яшереп, үз язганнарыннан үзе куркып, почмак артыннан торып атарга азаплана. Марксистик тәнкыйтьнең бурычы – андый кешеләрне колакларыннан өстерәп чыгарып, шәрә көйләренчә көн алдына бастыру булырга тиеш... Л.Н.Толстой: «Гали кешеләрне һәм гали фикерләрне лакейның төшенмәвенә гаҗәпләнмәгез, чөнки лакей галилекне үзенчә аңлый», – ди. ...Без «Яңалиф» журналына да киләчәктә шундый мәкаләләрне басудан сакланырга киңәш бирер идек. (Имзасыз һәм җавапсыз мәкалә турында // Безнең юл. 1929. № 5).

Күренә ки, биредә Г.Нигъмәти элек үзе үк тәнкыйтьләгән «Мәхәббәт тәүбәсе»н күренекле әсәрләр рәтенә кертә.

[6] *«Нәни разбойник»* – «Безнең юл»ның 1926 елгы 1–2 нче (гыйнвар-февраль) саннарында басылган.

[7] *«Шлем киертербез айга да!»* – «Нәни разбойник» шигыреннән.

[8] *«Без шәһәргә кире кайтырбыз».* – «Әйдә, энем!» шигыре турында сүз бара. «Безнең юл»ның 1926 елгы 3 нче (март) санында исемсез генә басылган.

[9] *«Киләчәкнең тимер кешесен...»* – «Пи-би-би-бип» шигыреннән, «Безнең юл»ның 1926 елгы 7–8 нче (июль-август) саннарында басылган.

[10] *«Әйдә киттек балык тотарга...»* – «Картайдым шул» шигыреннән. «Кызыл Татарстан»ның 1926 елгы 20 июнь санында «Шәһәр җыры» исеме белән басылган.

[11] *«Кузгал, уян, ләгънәт ителгән...» – ди.* – «Интернационал» җырыннан өзек.

[12] *«Мәхәббәт тәүбәсе»* – «Безнең юл»ның 1927 елгы 2 нче (февраль) санында басылган.

*167 бит.*

**«Кызлар җыры».** «Азат хатын» журналының 1927 елгы 16 нчы (28 ноябрь) санында «Һ.Т.» имзасы белән «Әдәбият дөньясында» рубрикасы астында басылган. Берничә хатын-кыз авторның шул исемдәге җыентыгына рецензия. Җыентык «Азат хатын» журналына кушымта китапчык итеп чыгарылган (Кызлар җыры : шигырьләр җыентыгы / ред. Ш.Кәримова. Казан, 1927. 23 б. тиражы 4000.)

Җыентыкка нигездә «Азат хатын» журналында басылып килгән шигырьләр урнаштырылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *...Зәйнәп Бәширова үзенең көрәш җырларын җырлаган иде.* – Зәйнәп Бәшированың «Көрәш җырлары» җыентыгында (1923, Ф.Бурнаш редакциясендә) басылган шигырьләре турында сүз бара.

[2] *Аитова* – яшь шагыйрә. 1927 елда «Азат хатын»да аның «Алар инде үсеп җиткәннәр» (9 нчы), «Ул юк инде» (10 нчы) шигырьләре басылган. «Сагынып көтмә, әни!» шигыре журналның 1927 елгы 5 нче санында басылган.

[3] *Гайфуллина* – Галимә Гайфуллина – яшь шагыйрә. «Азат хатын»ның 1927 елгы 12 нче санында аның «Хат» исемле шигыре басылган.

[4] *Әминова* – Идеал Әминова, яшь шагыйрә.

[5] *Зәйнәп Зөбәерова* – яшь шагыйрә. 1927 елда «Азат хатын»да аның рәсеме белән бергә «Капитал төрмәсендә» (12 нче), «Әйт, жир шары?!» (15 нче) шигырьләре басылган.

[6] *Сәлимә Гыймадиева* – яшь шагыйрә. Әлеге «Уку иде теләгем» шигыре «Азат хатын»ның 1927 елгы 9 нчы санында басылган.

[7] *Гөлсем Рәсулова* – яшь шагыйрә.

*169 бит.*

**Ничек язарга?** «Азат хатын» журналының 1928 елгы 1 нче (15 гыйнвар) санында «Һ.Т.» имзасы белән басылган. Архивта тулы булмаган кулъязмасы саклана (ТА. 3–1 п. 408 с.б.). Ул үзгәрәк башлана: «Безнең «Азат хатын» журналы – бөтен СССРда берләнбер татар-башкорт хатын-кызлары журналы. Аның алган юлы киң катлау татар-башкорт хатын-кызларының файдасын күрсәтү, аларның көндәлек тормышларында юлбашчылык итү, аларны әдәби дә, сәяси дә тәрбияләү. «Азат хатын» журналы шул юлда икенче ел инде эшләп килә. Журналның укучылары арткан саен, аның бурычлары да зурая бара...»

Мәкалә астына «Калганы киләсе номерда» дип куелган булса да, алдагы саннарда дәвамы күренмәде. Язучының архивында «Хикәяне ничек язарга?» дигән мәкаләнең кулъязмасы саклана (ТА. 3–1 п. 407 с.б.). Кулъязманың: «Хикәяне ничек язуга килгән вакытта инде күбрәк туктарга кирәк була», – дип башлануы аның әлеге мәкаләнең дәвамы буларак язылу мөмкинлегенә ишарә итә.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Азат хатын»нан алынды.

*171 бит.*

**Хикәяне ничек язарга?** Кулъязма-караламасы архивта саклана (ТА. 3–1 п. 407 с.б.). Бу томга кертелгән «Ничек язарга?» исемле мәкаләнең дәвамы булса кирәк. Такташ ул мәкаләнең ахырына: «Калганы киләсе номерда», – дип куйса да, «Азат хатын» журналының башка саннарында дәвамы күренмәде. Бу мәкаләнең башлану рәвеше – беренче җөмләсе дә аның нәрсәнеңдер дәвамы булуын аңлата. Мәкалә тәмамланмаган.

Беренче тапкыр басыла.

Текст кулъязмадан алынды.

[1] *Галимҗан Ибраһимов* (1887–1938) – татар язучысы, галим, дәүләт эшлеклесе.

[2] *Шәриф Камал* (1884–1942) – татар язучысы.

[3] *«Кем гаепле?»* – Газизә Юлданованың «Азат хатын»ның 1927 елгы 11 нче (июнь) санында басылып чыккан «Саҗидә гаепleme?» исемле хикәясе турында сүз бара.

*174 бит.*

**Ничек үсәбез?** «Кызыл яшьләр» газетасының 1928 елгы 21 август (31 нче) санында басылган. Газетада редакциядән «Каләм көчле, каләм тимер, каләмнән зур эшләр көтеп була» дигән зур баш астында түбәндәге сүзләр язылган: «Әдипләрне, шагыйрьләрне иҗатларын көчәйтү өчен заводларга, коллектив хуҗалыкларны өйрәнергә җибәрү мәсьәләсен күтәрәбез». Шуннан соң, Такташның әлеге мәкаләсе белән бергә, Мөбарәкшинның «Уйларга да, башларга да вакыт», Г.Нигъмәтинең «Яшь әдәбиятыбыз», К.Нәҗминең «Үтеп барышлый әйтелгән уйлар», Г.Толымбайскийның «Язучының өч нигезе», Г.Кутуйның «Минем караш» исемле мәкаләләре урнаштырылган.

Беренче тапкыр Такташның 1942 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

*«Кызыл яшьләр»* – 1920–1937 елларда Казанда чыккан газета, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты органы.

*175 бит.*

**«Амантай шигырьләре» турында.** «Совет әдәбияты» журналының 1935 елгы 12 нче (декабрь) санында басылган. Редакциядән түбәндәге сүзләр язылган: «Һади Такташның хәзергә чаклы матбугатка чыкмаган бу язмасы Татгосиздатка бирелгән рецензияләр арасында сакланган. Ул Такташның поэзиягә карата кайбер әһәмиятле фикерләрен эченә алганга, без аны шагыйрь үлүгә 4 ел тулу уңае белән чыгаруны тиешле санадык». Рецензиянең ахырына «3.XII.28 ел» дип куелган. Бу язма – Такташның башкорт язучысы Габдулла Амантайның (1904–1943) Татарстан китап нәшриятына бастырырга тәкъдим иткән шигырьләр җыентыгына рецензиясе.

Амантай җыентыгының Татарстан китап нәшриятында басылып чыгуы мәгълүм түгел. 1936 елда Казанда аның 14 битлек «Маэмайлар» дигән шигыре генә аерым китап булып чыга. 1928 елда шагыйрьнең Уфада чыккан «Авыл малайлары», «Бәләкәй дустарга» исемле шигырьләр җыентыкларында Такташ рецензиясендә аталган кайбер шигырьләр дә урнаштырылган.

Г.Амантай укучыларга күпсанлы шигырьләре, очерклары, мәкаләләре белән дә, фольклор өлкәсендәге гыйльми-тикшеренү эшләре белән дә мәгълүм.

Шагыйрь Амантайның иҗатына Такташның йогынтысы зур булган булса кирәк. Аның «Көрәш еллары» (Шигырьзар корамаһы. Өфе : Башкнига, 1927) исемле җыентыгына рецензия язучы Касыйм Гыйрфанов, мисал китереп: «Форма ягыннан үзен Такташ шәкерте дип йөргән Амантай бу урында форма ягыннан гына түгел, мәгънә ягыннан да Такташка шәкерт булып китә», – дип яза (Башкортстан. 1927. 2 апр.).

Архивта рецензиянең караламасы саклана (ТА. 3–1 п. 414 с.б.) Такташ кулы белән: «Г.Амантай шигырьләре. 3 табак», – дип язылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст кулъязмадан алынды.

[1] *Жаров* – Александр Алексеевич Жаров (1904 елда туган), рус шагыйре.

*177 бит.*

**«Зәкуан мулла шәҗәрәсе».** «Кызыл Татарстан» газетасының 1929 елгы 16 апрель (84 нче) санында «Театр – музыка» рубрикасы астында басылган. Фатих Сәйфи-Казанлының шул исемдәге драмасы буенча куелган спектакльгә рецензия. Газетада бу мәкалә янәшәсендә «Сара ролендә – Кугушева» дип рәсем асты язылып, артистканың рәсеме бирелгән.

Архивта мәкаләнең кулъязмасы саклана (ТА. 2–15 п. 40 с.б.). Анда газетада чыккан текстка кадәр мондый юллар бар: «Европа буржуазиясе, театрны шантаннар, салоннар, ялангач хатын-кызлар биюенә алмаштырып, аны сәнгать аренасыннан куды. Бүгенге көндә Париж, Лондон, киң дөньяның иң зур шәһәрләрендә дә драма театрларының яшәмәве яки яшәгәннәренең караучылары 300–500 дән артмавы безгә бу нәрсәне ачык күрсәтә.

Европада драма үлеп килә. Яки үлү алдында. Чөнки драма ул идея белән, төрле идея белән үзенең бөек тарихын бизәп килде. Ә һәрбер идея буржуаның обыватель җилкәсенә суга, аның хайвани ләззәтләре белән генә сугарылырга өйрәнгән ашказанына ярамый. Аның тынычлыгын боза, кәефен җибәрә. Ә обыватель үзенең шәхсиятенә ягымлы булмаган нәрсәләр белән тынычсызлануны яратмый. Ул сәхнәдә кәефне бозмый торган, тук тәненә ял бирә торган яки аның хайван хисләрен кытыкландыра торган нәрсәләр генә күрәсе килә. Шуның өчен Европада драманың һәлакәте нигезендә ялангач хатыннар бии торган шантаннар, салоннар үсә.

Драма ул массаның идея трибунасы булганда гына аның җанлы типларын, бөек омтылышларын үзендә ингыйкас итә алганда гына бөеклеген югалтмый.

Безнең татар театрында Печән базары обывателе заказы белән язылган, бот кашып көлдерүгә ниятләнгән ярым фарс әсәрләр урын ала башлаганнар иде.

Бу елгы сезонда бу черек нигездән чыгуга, драманы идея белән бәйләп җанлы психологик типлар бирүгә зур омтылышлар күренде. Бу омтылышның уңышлыларыннан берсе итеп 12 апрельдә Татар академия театрында куелган, карт язучыларыбыздан Фатих Сәйфи иптәшнең «Зәкуан мулла шәҗәрәсе» дигән әсәрендә күреп була».

Кулъязмада мәкалә түбәндәгечә тәмамлана (бу өзек басма тексттан соң дәвам итә): «Гасыйм ролендә Шамильский шиксез матур иде. Шамильский ул – татар драмасында психологический рольләрне бик оста, бик шома уйнаучы артист. Аның паузалары урынлы. Ул бик күп нәрсәне тавышсыз-телсез рәвештә караучының йөрәгенә сөйли ала.

Сәлимҗан да, Уральский да, Кугушева да матур уйнадылар.

Девишев үзенең соңгы вакытларда һәм беренче постановкасы белән татар сәхнәсенә кирәкле һәм талантлы режиссер икәнен күргәзде».

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Кызыл Татарстан»нан алынды.

[1] *Фатих Сәйфи-Казанлы* (1888–1937) – татар язучысы, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

[2] *Девишев Гомәр* (1897–1964) – 1924–1929 елларда Татар дәүләт театрының баш режиссеры.

*179 бит.*

**Бүгенге матурлык һәм аны җырлаучылар турында.** «Кызыл Татарстан» газетасының 1929 елгы 6 октябрь (228 нче) санында басылган. 1929 елның 10 августыннан алып 18 сентябренә кадәр бер төркем татар язучылары пароходта тугандаш республика шәһәрләре буенча экскурсия-сәяхәт ясыйлар. Маршрутлары: Казан – Әстерхан – Махачкала – Баку – Ереван – Тбилиси – Батуми – Ялта – Симферополь – Харьков – Мәскәү – Казан. Экскурсиянең барышы турында «Кызыл Татарстан»да даими рәвештә (телефон аша үзхәбәрче хәбәр иткән) информация биреп барыла. Мәсәлән, 3 сентябрь санында «Беренче биш көн» исемле мәкаләдә Иделдә баруның соңгы көне алдыннан пароход салонында концерт бирүләре турында языла: «Сәйдәш пианинода уйнады. Рәми җырлады. Сәрвәр ханым җырлады. Такташ һәм Кутуй сөйләделәр». «Кызыл Татарстан»ның 28 август санында Г.Кутуйның «Язучылар экскурсиясе Азәрбайҗан үзәгендә» исемле мәкаләсендә «Гражданнар сугышы чорында дошман тарафыннан вәхшиләрчә үтерелгән 26 большевик каберенә венок куйдык» дигән юллар бар. Такташ архивында венок куйган вакытны төшереп алган фоторәсем саклана. Анда Такташ кулы белән: «Венокны Гомәр Гали белән Такташ тотып тора», – дип язылган.

Шулай ук язучылар тукталган шәһәрдәге өлкә газеталары да аларга карата зур кызыксыну, игътибар күрсәтә. «Бакинский рабочий», «Коммунист», «Яңа юл», «Заря Востока» (Закавказьеның үзәк газетасы) һ.б. газеталар татар язучылары турында хәбәрләр урнаштыралар. «Бакинский рабочий» газетасының 1929 елгы 195 нче санында «Писатели о себе» дигән гомуми баш астында язучылардан алынган интервью урнаштырыла. Такташ та үзе турында сөйли: кыскача биографиясе белән таныштыра, нинди әсәрләре басылып чыгуы турында әйтә.

Экскурсия турында тулы истәлекләрне Газиз Иделле язган (Беренче зур сәяхәт. Казан, 1980).

Такташ экскурсия вакытында көндәлек алып бара (ТА. 12 – 4 п. 152 с.б.).

«Кызыл Татарстан»ның 1929 елның 6 октябрь саны 6 битле булып чыккан, 3 бит тулысы белән экскурсиядән кайткан язучыларның мәкаләләренә багышланган, шул исәптән анда Такташның бу мәкаләсе дә басылган. Архивта тулы кулъязмасы саклана (ТА. 11 п. 1144 с.б.), мәкаләнең аерым абзацларын тәшкил иткән язма да бар (ТА. 11–4 п. 1146 с.б.). Беренче тапкыр Такташның 1942 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

[1] *Волховстрой* – СССРда ГОЭЛРО планы буенча төзелгән беренче гидроэлектростанция. Станциягә Ленин инициативасы белән 1918 елда нигез салына, 1926 елның декабрендә энергия бирә башлый.

[2] *Днепрострой* – Днепр елгасында, Запорожье шәһәре янында ГОЭЛРО планы буенча төзелгән гидроэлектростанция. Нигезе 1927 елда салына, 1932 елның октябрендә энергия бирә башлый.

[3] *Ильясовны гаеплэгэн кебек...* – Такташ замандашлары әйтүенә караганда, Габдулла Ильясов рус язучысы Гастевның «Без тимердән үсәбез» исемле нәсерен татарчага тәрҗемә итеп бастырган. Авторын күрсәтмәгән. Менә шул уңай белән ул матбугатта тәнкыйтькә эләгә.

[4] *ТАПП* (Татарская ассоциация пролетарских писателей – Татар пролетар язучылары ассоциациясе) – ТАПП ул РАППның (Российская ассоциация пролетарских писателей) Татарстандагы оешмасы иде. РАПП һәм аның җирле оешмалары ВКП(б) Үзәк Комитеты карары белән бетерелде (1932, 23 апрель).

*183 бит.*

**«Җавап».** «Кызыл Татарстан» газетасының 1929 елгы 8 декабрь (280 нче) санында басылган. Г.Кутуйның шул исемдәге драмасы буенча куелган спектакльгә рецензия. Беренче тапкыр Такташның 1953 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст «Кызыл Татарстан»нан алынды.

[1] *Гриша (Мәҗитов)* – Мәҗитов Илдар (1898–1952), ТАССРның халык артисты.

[2] *Булатова* – Галия Булатова (1906–1985), РСФСРның халык артисткасы.

*185 бит.*

**Безне берләштергән нәрсәләр.** «Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы 12 нче (декабрь) санында басылган. Мәкалә астына «20.VII.30» дип куелган; редакциядән мондый искәрмә бирелгән: «Такташның бу сүзләре Татарстан республикасының 10 еллыгында чуваш язучылары белән очрашканда сөйләнгән булырга тиеш». Язучының «Әсәрләр» (1942) җыентыгына кертелгән. Архивта кульъязмасы саклана (ТА. 3–1 п. 411 с.б.), кульъязмада шул ук дата күрсәтелгән. Шулай ук архивта чыгышның машинкада басылган тезислары да бар (ТА. 3–4 п. 442 с.б.).

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

[1] *Партиянең XVI съезды* – Партиянең XVI съезды 1930 елның 26 июнь – 13 июлендә булган.

*186 бит.*

**Тыңла, ТАПП!** «Атака» журналының 1930 елгы 2 нче (август) санында басылган. 1936 елда чыккан «Һади Такташ турында» җыентыгына (төзүче Ф.Кәрим) кертелгән. Такташның «Әсәрләр»ендә (1942) мәкалә «Донбасска баргач» исеме белән бирелгән. Архивта кульъязмасы саклана (ТА. 2–15 п. 404 с.б.).

Мәкалә Такташ 1930 елның 3–23 июнендә Донбасска иҗади командировкага барып кайткач языла. Донбасста вакытында язучы бик җентекле көндәлек алып бара. Такташның Донбасстагы эшчәнлеген характерлап, «Кызыл яшьләр» газетасының 1935 елгы 9 июль (168 нче) санында басылган «Бер истәлек» исемле мәкаләнең авторы Чербак болай яза: «Шагыйрь үзенең алдына үзен эшчеләр арасында танытуны бурыч итеп куймады. Ул барыннан да элек, шахталарга төшеп, эшчеләр арасына кереп, аларның көнкүреш шартларын өйрәнде. Такташ Донбасста үзенең күбрәк вакытын эшчеләрнең торакларында уздырды. Кайбер иптәшләр Такташның «Миңа монда көн бик кыска тоела» дигән сүзләрен әле дә булса хәтерлиләрдер.

Такташ үзенең кадерле эш сәгатьләрен зур хезмәткә бирде. Ул көндез шахталарда үзенең иҗат эшен алып барса, ә кичләрен аны шахтерлар белән тулган клублар көтәләр иде. Шагыйрь эшчеләр каршында, үз шигырьләре белән беррәттән, башка язучыларның да әсәрләрен укыды. Аерым язучылар белән массаны таныштырды. Татар совет матур әдәбиятының үсешләре турында беседалар үткәрде. Донбасс татар шахтерлары көчле алкышлар астында шагыйрьне өчәр сәгать үз алларында бастырып тоттылар. Такташ «назланмады». Ул һәрбер шигырен зур көч белән, рух белән укыды.

Такташ моның белән генә чикләнмәде. Ул ударникларны әдәбиятка чакыру өлкәсендә дә нык эшләде. Аның тырышлыгы белән Донбассның үзәк районнарында әдәбият түгәрәкләре төзелде».

Такташ шахтерларга алар тормышыннан алып әдәби әсәрләр язарга вәгъдә бирә. Донбасска бару тәэсирләре, материаллары нигезендә ул 1930–1931 елларда «Камил» драмасын яза.

Текст «Атака»дан алынды.

[1] *«Козгыннар оясында»* – Ш.Камалның «Козгыннар оясында» исемле повесте 1910 елда басылган.

[2] *«Атака»* – «Казан утлары» журналының элгәре (1930 елның июленнән 1932 елга кадәр шул исемдә чыккан). 1930 елның 1 нче (июль) санында Донбассның Сталино округы Бәрмә культура бригадасының «Пролетариат үз әдәбиятына наказ бирә» исемле мөрәҗәгате басылган. Анда түбәндәге юллар бар: «Бәрмә культура бригадасы ТАПП белән булган бәйләнешне ныгытуны киләчәктә бергәләп эшләүне, татар шахтерларының тормышларын ныклап өйрәнеп, Донбасс татар шахтерлары тормышыннан аерым матур әдәбият тудыру өчен бригадалар, шагыйрь, язучылардан аерым-аерым иптәшләрне җибәрүне кичектермәслек эш дип таба».

[3] *Шиһабетдинов* – Сәләхетдин Шиһабетдинов (1891–1948), шахтер, соңыннан ВКП(б)ның Сталино округы комитеты инструкторы. Такташ. Донбасска килгәндә Сталино округының татар укучылары өчен оештырылган бер айлык курсларга җитәкчелек итә. Округта шахтерларның Такташ белән очрашу кичәләрен оештыра. Шундый кичәләрнең беркетмәсеннән бер өзек: «Объединенное собрание татарских рабочих шахт «София», «Италия» 12 июня 30 г. в честь приезда признанного европейского писателя тов. Такташева...». «Атака» журналының 1930 елгы 2 нче санында Шиһабетдиновның «ТАПП башлаган эш киңәергә, тирәнәергә тиеш» исемле мәкаләсе («Донбасс вәкиле иптәш Шиһабетдиновның Татарстанның 10 еллыгы тантанасында сөйләгән сүзеннән») басылган. Бу чыгышның Такташ кулы белән язылган караламасы архивта саклана (ТА. 2–10 п. 404 с.б.). Язучы Шиһабетдиновка чыгышын төзергә ярдәм иткән булса кирәк.

[4] *Абязов* – Шакир Габбас улы Абязов (1899–1947), шахтер, соңыннан партиянең шәһәр комитеты инструкторы.

[5] *Чубаев* – укытучы, активист.

[6] *Яхин* – Гаделша Хәлиулла улы Яхин (1901–1974), Тау эшләре институты каршындагы татар рабфагы мөдире.

*190 бит.*

**Үзем турында.** «Красная Татария» газетасының 1931 елгы 24 май (119 нче) санында басылган. Мәкалә «Татарские писатели о себе» дигән гомуми баш астында М.Әмирнең мәкаләсе белән бергә ике авторның да рәсемнәре белән бирелгән. Мәкаләләрнең исемнәре юк, башларына бары «Мирсай Амир», «Такташ» дип куелган.

Татар теленә беренче тулы тәрҗемәсе (тәрҗемәдә текст «Үзем турында» дип исемләнгән) «Совет әдәбияты» журналының 1951 елгы 1 нче санында чыкты. Х.Госман тәрҗемәсе. Такташның «Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр» җыентыгына (Казан : Татгосиздат, 1953 / төз. Х.Госман.) кертелгән. Архивта караламасы (ТА. 3–1 п. 409 с.б.) һәм машинкада басылган нөсхәсе (1 бите юк) саклана (ТА. 3–3 п. 439 с.б.).

Текст 1953 елгы җыентыктан алынды.

[1] *...әсәрләремнең зур җыентыгы...* – язучының бу җыентыгы 1931 елда басылып чыга (Һ.Такташ әсәрләре: тулы җыелма. Казан : Татиздат, 1931. 1 т.).

[2] *...диалектик иҗат методын үзләштерү...* – «Такташ үз иҗат методын диалектик материализм методы дип атый. Бу Такташка «раппчылар» тәэсирендә килеп кергән хата билгеләмә. Асылда Такташ әдәби иҗат практикасында социалистик реализм иҗат методы юлы белән бара». Такташ Һ. Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр / төз. Х.Госман. Казан : Татгосиздат, 1953. 280 б.).

[3] *«Киләчәккә хатлар»* – поэманың «Беренче хат»ы «Кызыл Татарстан»ның 1930 елгы 12 апрель санында, «Икенче хат» 1931 елда «Яңалиф»нең 4 нче (апрель), «Азат хатын»ның 22–23 нче (декабрь) саннарында, «Хатның адресы» һәм «Өченче хат» 1931 елда «Яңалиф»нең 7 нче (июль) санында басылганнар.

[4] *...колхоз тормышыннан пьеса өстендә эшли башладым.* – Бу пьеса турында мәгълүматлар юк. Әмма Такташның авыл тормышыннан зур әсәр язарга планлаштыруы хакында аның көндәлек-язмаларында да очратырга мөмкин. 1931 елның июнь аенда Такташ гаиләсе белән Сыркыдыга кайта. 20 июньдә совет властена үчле кешеләр Сыркыды авылын ут төртеп яндыралар. Такташны тетрәткән шул вакыйга язучының әлеге хыялын тормышка ашыруга этәргеч ясаган булырга мөмкин. «Янгын» («Пожар») пьесасын ул 1931 елның сентябрендә яза башлый.

*192 бит.*

**Язучыдан.** 1931 елда басылып чыккан әсәрләре җыентыгына (Һ.Такташ әсәрләре: тулы җыелма / кереш сүз авт. Г.Гали. Казан : Татиздат, 1931. 1 т. Язылу вакыты «1931, 3 июнь» дип күрсәтелгән. Язучының 1942 елгы җыентыгына кертелгән. Архивта караламасы (ТА. 3–3 п. 418 с.б.), машинкада латин шрифты белән басылган кульязмасы саклана (ТА. 3–4а п. 440 с.б.). Икесендә дә шул ук дата күрсәтелгән. Кульязмада басма тексттагы соңгы абзац алдыннан мондый өстәмә бар: «Бу юлда Гомәр Гали иптәшнең минем шигырьләргә анализ ясаган сүз башы күп кенә ярдәм итәр дип уйлыйм».

Текст 1942 елгы җыентыктан алынды.

*194 бит.*

**Тәнкыйть турында.** Х.Хәйринең «Һ.Такташ әдәби тәнкыйть турында» исемле мәкаләсендә (Совет әдәбияты. 1956. № 5), шулай ук аның «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» исемле китабында текст эчендә кыскартулар белән бирелгән (Казан, 1950. 103–109 б.). Архивта кульязма-караламасы саклана (ТА. 2–15 п. 406 с.б.). Мәкалә тәмамланмаган. Исеме юк, укыганда җайлылык өчен исем төзүче тарафыннан куелды.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст бик аз гына кыскартулар белән кульязмадан алынды.

[1] *«Литературная газета»да тәнкыйть турында дискуссия...* – «Литературная газета» Мәскәүдә 1929 елның апреленнән чыгып килә. Газетаның 1931 елгы 34–37 нче саннарында (25 июнь, 30 июнь, 6 июль, 10 июль) «Почему отстает конкретная критика?» дигән рубрика астында язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләре басыла. Редакциянең хәбәр итүенә караганда, бу мәкаләләр авторларга алдан таратылган анкеталарга җавап рәвешендә язылганнар. Мәкалә авторлары еш кына очракта конкрет иҗади продукциягә тәнкыйтьнең конкрет булмавы, гадел булмавы, йә гомуми мактау, яки гомуми сүгү рәвешендә баруы, яхшы әсәргә надан кешеләрнең «тәнкыйть» язуы, начар китапларның һаман чыгып торуы, аларны күккә чөйгән тәнкыйтьләрнең дә дөнья күрүе хакында язалар. Газетада күтәрелгән мәсьәләләр соңгы елларда Такташны гел борчып киләләр. Аңа әлеге мәкаләсен язарга да шул дискуссия этәргеч ясаган булса кирәк. Югарыда китерелгән даталар Такташ бу мәкаләсен 1931 елның 10 июленнән соң язган дигән нәтиҗәгә китерәләр.

[2] *Переверзевщина* – Переверзев Валерьян Федорович (1882–1968), әдәбият белгече. 1928 елда аның һәм аның тарафдарларының «Литературоведение» исемле мәкаләләр җыентыгы чыгу «Переверзев мәктәбе»нә багышланган дискуссиянең тууына сәбәп була. Переверзевның методологик карашлары Г.В.Плехановның эстетик карашларына нигезләнгән була. Переверзевча, әдәби әсәрдәге характерлар системасы әсәр авторының сыйнфый хәле белән бәйле. Мәсьәләне болай кую Переверзевны еш кына әдәби күренешләрне вульгар-социологик яктан чыгып аңлатуларга китерә. Такташ Переверзевның менә шул карашларына ишарәли.

[3] *...Г.Г. дигән бер егет яза.* – Сүз Г.Гозәеровның «Коммуна» (Уфада татар телендә чыккан газета, хәзерге «Кызыл таң»ның элгәре) газетасында (1930, 2 нче сан) басылып чыккан «Яшьләр күтәрелү баскычында» исемле мәкаләсе турында бара. 1930 елның 15 июнендә Казанда «Татарстан яшь язучылары бригадасы белән Башкорстан язучыларының элемтә кичәсе» уздырыла. Кичәдә Ф.Мөсәгыйть

Такташ әсәрләренә анализ ясый, югары бәя бирә. Шуңа җавап итеп Гозәеров әлеге мәкаләсендә, кичәдә телгә алынган әсәрләрне үк алып, тискәре фикерләр әйтә. Ул мәкаләсен: «Давылдан соң», «Кояш көлми дә, елмаймый да», «Җир уллары трагедиясе», «Казан» шигыре Такташның безне, мохитебезне күрә алмавын, безнең арага килергә әле ерак торганын ачык күрсәтә», – дигән сүзләр белән тәмамлый.

[4] *Солтангалиевчеләр...* – Мирсәет Солтангалиев Хәйдәргали улы (1892–1940). Күренекле дәүләт эшлеклесе, милли дәүләт төзү теоретигы. Репрессияләнеп, 1989 елда аклана. Солтангалиевчеләр – 1920–1930 елларда татар, башкорт милләтеннән булган партия, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренә тагылган сәяси ярлык. Солтангалиевчелектә гаепләү утызынчы еллардагы репрессияләр өчен зур сәбәп булып торган.

[5] *Борондоков* – Микъдад Юнусович Борондоков (1896–1965), журналист.

*197 бит.*

**«Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында.** «Яңалиф» журналының 1931 елгы 10 нчы (октябрь) санында басылган. «Һади Такташ турында» исемле җыентыкка (төз. Ф.Кәрим. Казан, 1936), бераз кыскартулар белән шагыйрьнең «Әсәрләр» (1942) җыентыгына кертелгән.

Язучы үзенең эстетик карашлары җыелмасы булган бу әсәрен гаҗәеп зур тырышлык, җаваплылык белән, җентекләп, озаклап, төрле вариантларда һәм төрле исемнәр биреп язып караган. Архивта мәкаләнең 9 күчермә-кульязмасы саклана.

ТА. 3–2 п. 415 с.б. «Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында. Зур 9 биттә. «Һади Такташ» имзасы белән. Басма текст нигездә шуннан алынган. Бу вариант башкаларына караганда соңрак язылган булса кирәк.

ТА. 3–2 п. 416 с.б. Бу дәфтәрдә өч вариант каралама бар:

1. «Шигырьләр ни өчен үзләрен-үзләре үтерәләр». «Такташ» имзасы белән. Зур 7 биттә. Мисаллар азрак. Кырыйга үз кулы белән сорау билгеләре куйган, үзе өчен «Мәсәлән», «Ударниклар-башлаучылар», «Простота турында», «Карап күрүче генә түгел» кебек сүзләр язып чыккан.

2. Исеме юк. «Һади Такташ» имзасы белән. Зур 4 биттә.

3. Исеме, имзасы юк. 5 биттә. Шигырьләрдән мисаллар юк.

Һәркайсысын кыска һәм төгәлләнгән итеп язган.

ТА. 3–3 п. 417 с.б. «Ни өчен шигырьләр үләләр» (шагыйрьнең көндәлек дәфтәреннән, 2 биттә). Басма тексттан шактый аерыла.

«Минем алдымда үлгән, үлемгә хөкем ителгән шигырьләр ята. Алар төрле исемнәр астында төрле шагыйрьләр тарафыннан язылган шигырьләр. Ни өчен алар үлемгә хөкем ителгәннәр? Ни өчен алар үләргә тиешләр?

Мин ул шигырьләрнең эчендә булган авыруларын тикшерә башлыйм.

Бер шигырьнең үпкәләре дә үз-үзендә түгел, кан юллары да, эчәкләре дә чуалып беткән, куллары да, аяклары да үз-үзендә түгел, кыскасы, бөтен яратылышы белән авыру бер шигырь. Минем күз алдыма бу шигырьне язучы шагыйрь килеп баса. Ул бу шигыре басылуы белән башы күккә тигәндер. Эченнән генә үзен зур бер шагыйрь итеп санап куйгандыр. Шигыре басылган көнне ул һәрбер танышының күзенә:

– Бу минем шигырьне бүген укыгандыр, – дип карагандыр. Аңардан мактауны көткәндер. Иптәшеннән аның шигырен укуы турында бер сүз дә ала алмагач, шигыре басылган гәзитне кесәсеннән алып укыгандыр. Бәлки, көчәнеп, эт күңеле бер сөяк дип, иптәшеннән дөрес булмаган мактау сүзләре дә алгандыр... Ул, бәлки, менә бу юлларны язган вакытта да тагын бер шигырь тудырып ята торгандыр. Үзенең язып ята торган шигыренең дә туарга өлгерми үләчәге турында уйламый да торгандыр.

Ләкин аның ул шигыре дә үләчәк.

Мин уродларны яратмыйм. Мин көчле яратылышы белән бертөрле эш эшли ала торган нәрсәләрне генә яратам. Урод ул эшкә ярамый. Ул матур да түгел. Ул карауচыда ачу яки җирәнү катыш кызгану хисе уята. Урод шигырьләр дә шулай ук. Алар көрәш өчен дә, бүгенге бөек төзелеш өчен дә яраксызлар».

ТА. 3–4а п. 441 с.б. «Партиясез» һәм партияле әдәбият турында (иҗат хатлары)», машинкада латин шрифтында басылган, 13 бит, басма текст белән туры килә.

ТА. 11–3 п. 1143 с.б. Мәкаләнең кечкенә планы. «Шигырьнең формасы. Аның сүзләре, образлары, сюжеты. Буржуаз искусство белән безнең искусство. Шагыйрьнең элек әйтергә теләгән теләге булырга тиеш. Шул теләкне әйтер өчен форма эзләргә кирәк. Шул теләкне әйтүгә ярдәм итмәгән һәрбер сүз безработный».

ТА. 11–4 п. 1145 с.б. «Шигырьләр ни өчен үзләрен-үзләре үтерәләр». Мәкаләнең баштагы өлеше «Минем өстәлемдә...» дип башланган абзацка кадәр.

ТА. 11–5 п. 1147 с.б. «Партияле» һәм партиясез шигырьләр турында». Мәкаләнең ахыры. «Безнең кайбер язучыларда...» дип башлана һәм Теләшнең «Җиңү чоры» шигыре белән тәмамлана.

Текст кульязмадан алынды.

[1] *Кант шәкертләре* – Кант Иммануил (1724–1804), немец классик философы, галим. Декадентлар сәнгате һәм әдәбияты Кант идеалистик философиясенә таянып эш иткән. Кант реаль тормышны, дөньяны танып белеп булмый дип исәпләгән. Кант эстетикасы сәнгатьне сәясәттән һәм моральдән аерып, кешене җәмгыятьтән аерып караган. Идеалист Кант һәм аның артыннан декадентлар, сәнгать интуиция юлы белән генә, художникның эчке сихри көче белән илһамлану минутларында гына туа дип өйрәткәннәр.

Такташ биредә социалистик төзелештә актив катнашудан читләшкән язучыларга ишарә ясый.

[2] *Теләшев* – Габдрахман Теләшев (1909–1984), вакытында тезмә һәм чәчмә әсәрләр язган кеше. Такташ архивында аның «Ударлы көннәр» исемле җыентыгы (Казан: Татиздат, 1930. 60 б.) бар (ТА. 1283 с.б.). Такташ шул җыентыкка кергән шигырьләргә анализ ясый. Китап битләренең кырыйларында Такташ кулы белән түбәндәге язулар очрый: «Ни дигән сүз?», «Эшчеләрне партиядән аеру», «Ни әйтергә тели?» «Бу ике җөмлә арасындагы бәйләнеш», «Бу җөмләсендә кызыл йолдыз ни өчен үзенең йөрәген тартуын да белми»,

«Ике кара-каршы образлар», «Иҗаты нәрсәдә?», «Күмәк балку ни дигән сүз?», «Дөрестән дә, мәхәббәт җырлары шагыйрьгә язарга җиңел, социаль момент – авыр». Язучы кабатланган сүзләрне дә күрсәткән, шигырь юлларының асларына сызып-сызып куйган. Шигырьләр өстендә шулай эшләп чыкканнан соң, Такташ фикерләрен кәгазьгә төшергән.

[3] *Чан-Кай-ши* (1887–1975) – 20 нче елларның беренче яртысында революцион демократ Сун Ят Сен (1866–1925) тарафдары булып йөрсә дә, ахырдан реакционерлыгы ачыла. 1927 елның 12 апрелендә Кытайда контрреволюцион чыгыш ясап, реакцион диктаторлык режимы урнаштыра.

[4] *С.Рәфыйков* – Сөббух Рафыйков (1913–1971), татар язучысы. Аның «Сыйныф ордены» исемле шигыре «Атака» журналының 1931 елгы 7 нче санында басылган.

[5] *Бәдрүш Мокамай* – Бәдретдин Мөхәммәтьянов (1909–1944), Башкортстан язучысы. 1929–1931 елларда Мокамайның шигырьләре «Яшь юксыл», "Игенчеләр" газеталарында татарча басылган. 1939 елда «Шигырьләр» (Өфе : Башгосиздат), 1943 елда «Урал егете» (Өфе : Башгосиздат) исемле шигырь җыентыклары башкортча басылып чыга.

Бәдрүш Мокамайның әлеге «Кырдан бүләк» исемле шигыре «Игенчеләр» газетасының 1931 елгы 64 нче санында басылган. Бу сан Такташ архивында да саклана. Шигырьнең кырыена Такташ кулы белән төрле билгеләр, сораулар куелган.

*206 бит.*

**Сандугачларның сайрауларына рецензия.** «Кызыл Татарстан»ның 1931 елгы 6 ноябрь (258 нче) санында басылган. Х.Хәйринең «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (Казан, 1960. 89–91 б.) китабында текст эчендә бирелгән. Архивта акка күчерелгән кулъязмасы саклана (ТА. 2–16 п. 405 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Кызыл Татарстан»нан алынды.

[1] *Пантюркизм* – төрки халыкларның этник һәм мәдәни бергәлеген алгы планга куйган иҗтимагый-сәяси хәрәкәт. Бу хәрәкәт XIX гасырда Төркиядә барлыкка килгән.

[2] *Тарпищев* – Хөсәен Тарпищев (1884–1943), шул елларда дәүләт эшлеклесе.

[3] *Гаяз Исхаков* (Исхакый, 1878–1955) – татар язучысы, журналист, татар милли азатлык хәрәкәте лидеры.

[4] *...партияле «сандугачларның»...* – язучы биредә милләтчеләрне күз алдында тота.

[5] *«Интернационал» маршы* – халыкара марш, француз композиторы Пьер Дегейтер тарафыннан 1888 елда иҗат ителгән.

## ПУБЛИЦИСТИКА

*210 бит.*

**Бохарада уку һәм укыту эшләре.** «Олуг Төркстан» газетасының 1917 елгы 23 август (24 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*«Олуг Төркстан»* – «1917 елның 25 апреленнән 1918 елның 21 ноябренә кадәр Ташкентта һәфтәдә [атнада] 2–3 чыга торган сәяси вә әдәби гәзитәдер».

[1] *Бохара әмире* – әмир Әлимхан (1880–1946) – Мангыт династиясеннән соңгы Бохара әмире. Атасы Әмир Габделәхәт хан үлгәннән соң (1911 елда) тәхеткә утыра. Революцион вакыйгалар нәтиҗәсендә 1920 елның сентябрендә тәхеттән төшерелә. Соңгы көненә кадәр Әфганстанда яши.

[2] *Гласный* – революциягә чаклы шәһәр думасы әгъзасы (депутаты) яки земство әгъзасы.

[3] *... кружка илә сбор ясалды.* – «Халыктан йөреп ярдәм акчасы җыелды» мәгънәсендә.

[4] *Анатоли* – Төркиянең ярымутраудагы өлеше (Кече Азия).

[5] *Җидесу* (Семиречье) – хәзерге Алматы тирәсе.

[6] *Төрек әсирләре* – Беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшеп, Россия лагерьларында яшәүче төрекләр.

[7] *Кушбиге* – Бохара ханлыгында хәрби дәрәҗә.

[8] *Казый Кәлан* – баш судья.

*211 бит.*

**Бохара хәбәрләре.** «Олуг Төркстан» газетасының 1917 елгы 9 октябрь (31 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Милли Шура* – патша власте бәреп төшерелгәч (1917 ел, 27 февраль), IV Дәүләт Думасының мөселман депутатлары Петроградта Үзәк мөселман башкарма комитеты төзиләр. Мондый комитетлар урыннарда да төзелә. Соңыннан алар Милли Шура исемен алалар. Бу комитетлар Бөтенроссия мөселманнар съездын (корылтайларын) яки Милләт Мәҗлесләрен үткәрәләр. I корылтай Мәскәүдә 1917 елның 1–11 маенда, II корылтай Казанда 1917 елның 21 июль – 2 августында була, III корылтай Казанда 10 октябрьдә ачыла.

[2] *Мәскәү мөселман хәрби комитеты* – 1917 елның 17 июлендә Казанда барган Бөтенроссия мөселман гаскәрләре съезды Бөтенроссия мөселман хәрби шурасын төзи. Шуннан соң мондый хәрби шуралар (комитетлар) төрле җирләрдә, мөселман гаскәрләре булган урыннарда төзеләләр. 1918 елның мартында Үзәк мөселман комиссариаты карары нигезендә таратыла.

Халыкны яхшы тормышка, яктылыкка алып чыгуның бердәнбер юлы – укыту, белем бирү дип аңлаган уналты яшьлек Һади Такташ Милли Шура, Мөселман хәрби шурасының уку-укыту буенча оештырылган эшләрендә чын күңелдән ярдәм итеп йөргән.

*212 бит.*

**Бохара фаҗигаләре.** «Олуг Төркстан» газетасының 1917 елгы 20 декабрь (45 нче) санында «Төркстан хәбәрләре» дигән рубрика астында «Һади» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Караул биге* – каравыл башлыгы.

[2] *Кәнҗ бохарлылар* – 1916 елда Бохара ханлыгында барлыкка килгән милли хәрәкәттә катнашучылар. Алар җәдитчелекне яклаучылар буларак билгеле. 1918 елда оешма таркала, 1920 елның гыйнварында яшь бохарлыларның бер өлеше Ташкентта «Яшь бохарлылар-революционерларның Төркстан Үзәк бюросы»н төзиләр. Оешманың башында Ф.Хаджаев тора. Бу оешманың программасы – әмир властен бәреп төшерү һәм Бохарада демократик республика төзү. Бохара Коммунистлар партиясе, феодаль реакциягә каршы барлык демократик көчләрне бергә туплау максатыннан чыгып, «Яшь бохарлылар» белән килешү төзи. Әмир власте бәреп төшерелгәч һәм Бохара Халык совет республикасы төзелгәч, 1920 елның сентябрендә сул «Яшь бохарлылар»ның бер өлеше (Ф.Хаджаев, А.Кадыри, А.Мөхетдинов һ.б.) Коммунистлар партиясенә керәләр. Ә уң «Яшь бохарлылар»ның кайберләре басмачыларга кушылалар һәм совет властена каршы көрәш юлына басалар.

*212 бит.*

**Яңа Бохарада мохтарият кичәсе.** «Олуг Төркстан» газетасының 1918 елгы 7 гыйнвар (49 нчы) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Мифтахетдин һәм Низаметдин Арслановлар* – Такташның әнисе Шәмсенисаның бертуган апасы Зөһрә балалары. Низаметдин белән Һади бала чакта Пешли мәдрәсәсендә бергә укыганнар. Бохарада чагында Һади егетләрнең әтиләрендә – Фазлетдин Арслановта кибетче малай булып торган.

[2] *Галимҗан Акчурин* (1895–1933) – шагыйрь, революционер, җәмәгать эшлеклесе.

*213 бит.*

**Хива вәкилләре.** «Юксыллар сүзе» газетасының 1921 елгы 21 гыйнвар (15 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*«Юксыллар сүзе»* – 1920 елның 14 маеннан «Юксыллар хакыйкате» исеме белән бер сан чыкканнан соң, «Юксыллар сүзе» булып киткән газета. Оренбург губкомы янындагы Мөселман шөгъбәсе органы. 1919–1921 елларда Такташ бу газетада җаваплы секретарь булып эшләгән.

*214 бит.*

**Пожалуйста.** «Чаян» журналының 1924 елгы 9 нчы (февраль) санында «Аллан» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр 1926 елда Такташның «Кояш көлми дә, елмаймый да» исемле җыентыгында чыккан. 1931 елгы җыентыкка кертелгән.

Текст 1931 елгы җыентыктан алынды.

*215 бит.*

**Сират аюлары.** «Чаян» журналының 1924 елгы 10–11 нче (март-апрель) санында «Так-таш» имзасы белән басылган. Архивта кульъязмасының соңгы өлеше саклана (ТА. 10–14 п. 1118 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*217 бит.*

**Кояш белән Ай сөйләшә.** «Чаян» журналының 1924 елгы 12 нче (май) санында «Аллан» имзасы белән басылган. Кави Нәҗминең «Көзге әкият» (Безнең юл. 1923. № 2) шигыренә дусларча шарж. К.Нәҗминең егерменче еллар башында язылган кайбер шигырьләрендә тормыш вакыйгаларын артык абстракт рәвештә сурәтләү, формализм (имажинизм) белән мавыгу кебек кимчелекләр күренде. Мондый формалистик күнегүләр, үз вакытында тәнкыйтьләнеп, берничә фельетон өчен объект булып хезмәт итте.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*217 бит.*

**Менә нишләде.** «Чаян» журналының 1924 елгы 14 нче (сентябрь) санында «Аллан» имзасы белән басылган. Архивта кульъязмасы саклана (ТА. 2–9 п. 384 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*218 бит.*

**Авыл хуҗалыгы түгәрәкләренә җәйдә эш.** «Октябрь яшьләре» журналының 1925 елгы 9 нчы (май) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*«Октябрь яшьләре»* – сәяси-иҗтимагый, әдәби-фәнни рәсемле айлык эшче-крестьян яшьләре журналы. Казанда 1924 елның май аеннан алып 1925 елның июнь аена кадәр (барлыгы 10 сан) чыккан.

*220 бит.*

**Тән чисталыгы.** «Октябрь яшьләре» журналының 1925 елгы 9, 10 нчы (май, июнь) саннарында «Алланист» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*224 бит.*

**«Авылга йөз белән» ни дигән сүз ул?** «Октябрь яшьләре» журналының 1925 елгы 10 нчы (июнь) санында «Һади» имзасы белән басылган.

1925 елның 16 февралендә РКП(б) Үзәк Комитеты оргбюросы «Крестьян вакытлы матбугаты турында» карар кабул итә. Журнал редакциясе шушы уңай белән авыл тематикасын яктыртуны яхшырту юлларын билгеле, авылга багышлап махсус саннар әзерли.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *... Ленин иптәш үзенең бер мәкаләсендә...* – Такташ китергән тексттагы фикерләр Ленинның «Эшчеләрнең хезмәт иясе һәм эксплуатацияләнүче крестьяннар белән союзы» (Әсәрләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1961. 26 т. 321–322 б.) исемле һәм кайбер башка мәкаләләрендә очрый.

[2] *... Нух заманындагы кораллар...* – Нух – мифик пәйгамбәр; дини риваять буенча, дөньяны су басканда, Алла ярдәмендә гаиләсе белән көймәдә исән калып, кешеләрнең туфаннан соң килгән яңа буыны аңардан башланган. «Нух заманындагы...» гыйбарәсе халыкта «бик күптәнге, борынгы, иске» дигән мәгънәдә йөри.

*227 бит.*

**Ике хат турында.** «Авыл яшьләре» журналының 1925 елгы 1 нче (июль) санында «Һади» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*230 бит.*

**Кайтасы килми.** «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 елгы 10 октябрь (227 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Терармия* (территориаль армия) – бер территориядә яшәүчеләрдән, ягъни җирле халыклардан оештырылган гаскәрләр.

[2] *Сапрота* – саперлар ротасы.

[3] *Проломный* – хәзерге Бауман урамының элекке исеме.

[4] *Арча кыры* – якынча хәзерге М.Горький исемендәге мәдәният һәм ял паркыннан алып «Очкын» («Искра») тукталышына кадәр булган ара.

*232 бит.*

**Советларга сайлаулар.** «Авыл яшьләре» журналының 1925 елгы 5 нче (ноябрь) санында «Һ.Таш» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*234 бит.*

**Карусель.** «Чаян» журналының 1925 елгы 28–29 нчы (ноябрь-декабрь) саннарында «Аллан» имзасы белән басылган. Такташның 1953 елгы «Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр» җыентыгына кертелгән.

Текст «Чаян»нан алынды.

[1] *«Барабыз»* – Октябрь революциясенә кадәр һәм 20 нче елларда кыш көне авылдан Казанга килеп, җиңел ямщик булып йөрүче. Һәрвакыт: «Әйдә, барабыз!» – дип кычкырып, үзләренә утырып китәргә чакырганга, аларны «барабыз»лар дип йөрткәннәр.

[2] *Совнарком* (Совет Народных Комиссаров) – Халык Комиссарлары Советы.

[3] *Ташаяк* – һәр ел яз көне май аенда булып килгән ярминкә; Казанда Кремль янында, Үзәк стадион каршындагы урында булган.

*235 бит.*

**Мөяссәр дию һәм яман авыру микроблары.** «Чаян» журналының 1925 елгы 28–29 нчы (ноябрь-декабрь) саннарында «Һади туташ Тукташ» имзасы белән басылган. Такташ шул елларда кооператив төзүдәге кимчелекләрне тәнкыйть итә.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Өчиле* – хәзерге Мамадыш районына кергән авыл.

[2] *Волость* – патша Россиясендә һәм СССРда 1929–1930 елларга кадәр өяз составына кергән административ-территориаль берәмлек.

[3] *Бик Үти* – хәзерге Буа районына кергән авыл.

*236 бит.*

**Безнең хат.** «Авыл яшьләре» журналның 1926 елгы 7 нче (гыйнвар) санында «Һ.» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*237 бит.*

**Синеңчә ничек?** «Авыл яшьләре» журналының 1926 елгы 8 нче (февраль) санында «Журнал турында әңгәмә» рубрикасы астында имзасыз басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*238 бит.*

**Җанлы казармалар.** «Кызылармеец» газетасының 1926 елгы 16 сентябрь (36 нчы) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*«Кызылармеец»* – 1924–1926 елларда Казанда чыккан газета (Идел буе хәрби округы, Казан гарнизоны органы).

[1] *Октябрь казармалары* – Казандагы хәрби казармалар исеме.

[2] *Каргаполь казармалары* – Октябрь казармаларының элекке исеме.

*240 бит.*

**«Лотерея уены»нда кызык сораулар.** «Кызылармеец» газетасының 1926 елгы 26 сентябрь (38 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Милләтләр лигасы* – халыкара конфликтларны тыныч юл белән хәл итү өчен төзелгән халыкара оешма (1919 елда төзелеп, 1946 елга кадәр яши).

*241 бит.*

**Радио.** «Азат хатын» журналының 1927 елгы 7 нче (март) санында «Фән-техника» рубрикасы астында «Һәдия Хәйрулла кызы» имзасы белән басылган. Рәсемнәр белән бирелгән.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Коминтерн* – Коммунистик Интернационал (III Интернационал), халыкара революцион оешма, бөтендөнья эшчеләр хәрәкәтенең 1919 елдан 1943 елга кадәр яшәгән җитәкче үзәге.

*243 бит.*

**Бәхет барабаны.** «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 25 гыйнвар (21 нче) санында басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Нэпман* – 1921 елда яшь Совет дәүләтенең социалистик икътисадын ныгыту максаты белән кертелгән яңа икътисади сәясәт вакытында хосусый хуҗалыкта җитештерү һәм сәүдә итү юлына баскан кеше.

*250 бит.*

**Безнең беренче карлыгачлар.** «Азат хатын» журналының 1928 елгы 4 нче (февраль) санында «Һ.Т.» имзасы белән басылган. Журналның 1971 елгы 1 нче санында мәкалә кабаттан басыла.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Азат хатын»ның 1928 елгы 4 нче санынннан алынды.

[1] *...4 нче сессиясе...* – Татарстан Үзәк башкарма комитетының (VII чакырылыш) 4 нче сессиясе 1928 елның 12–14 февралендә була.

[2] *Ибрай агай* (Нәмүш Ибрае) – Такташның әтисе Хәйрулла белән туганнан туган Нигъмәтулланың улы. Хәнифә апа Такташева әйтүенчә, Ибрай агай чыннан да озак кына солдатта йөреп кайткан.

[3] *Абубәкәр* (Рәхмәт Бәкәре) – Һади Такташның балалык дусты, «Мокамай» шигыренең герое прототибы булган Мөхәмммәтҗанның атасы.

[4] *Әхмәтҗанова Фатыйма* – дөрес исеме Фатиха, хәзерге Сарман районы Рантамак (элек бу авыл тексттагыча Рангазар Тамак дип йөртелгән) авылында туа һәм эшли. 1933 елда колхозчы ударникларның I Бөтентатарстан съездында катнаша. Шунда аны Казанда эшләү өчен алып калалар. Фатиха Бөек Ватан сугышыннан соң Арчада эшли һәм шунда үлә.

[5] *Кукаркин* – Рантамак белән янәшә Элемтә авылында (хәзер Мөслим районына керә) яшәгән алпавыт.

[6] *Залипская иптәш* – сүз Ефросинья Васильевна Запольская (Колчина) (1899 – ?) турында бара. Хәзерге Алабуга районының Югары Шүрнәк авылында туып үскән. Атиаз авылына кияүгә чыккан. 1925–1929 елларда авыл советы рәисе булып эшләгән. Бер үк вакытта Черкас волостена делегат итеп тә сайланган. 1925–1928 елларда Татарстан Үзәк башкарма комитеты әгъзасы булган. Активист буларак, аны укырга җибәргәннәр. Казанда Совет төзелеше техникумында, Югары коммунистик мәктәптә укыган. Мөслим, Калинин, Кызыл юл райкомнарында хатын-кызлар бүлеге мөдире, пропагандист булып эшләгән. 1948 елларда Сәмәрканд өлкәсе Нарпай райкомында эшли.

Һади Такташ вафат булгач, почетлы караулда тора.

[7] *Рәхилә Мансурова* – аның турында мәгълүматлар әлегә табылмады.

*252 бит.*

**Сөйләшми торган вагон йөртүче һәм өч хулиган белән милли судья турында.** «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 28 июнь (173 нче) санында басылган. Архивта тулы булмаган кульязмасы саклана (ТА. 2–10 п. 366 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Суконный* (Суконный бистәсе) – хәзерге Суконный, Эсперанто, Луковский урамнары тирәсендәге урын.

[2] *«Динамо»* – Казан гарнизонының беренче укчы дивизия штабы типографиясе шул исем белән йөртелгән. Аннары ул «Динамо» спорт җәмгыяте типографиясе дип аталган. 1928–1929 елларда «Динамо» типографиясе Татполиграфка кушыла.

Казандагы «Кызыл күнче» заводы да 20 нче елларда «Динамо» исемендә йөргән.

[3] *Ослан* – хәзерге Югары Ослан районына кергән авыл.

[4] *Усия урманнары* – Казанканың Иделгә коя торган җирендә булган. Куйбышев ГЭСы төзелү белән, бу җирләр су астында калган.

*255 бит.*

**Сагынылган җирләрдә.** «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 29 июнь (148 нче) санында басылган. Бераз кыскартылып, язучының 1953 елгы җыентыгына кертелгән.

Мәгълүм булганча, 1928 елның июнь аенда Һади Такташ язучы Габдрахман Минский (1906–1983) белән бергә Әстерханга бара. Әсәр шул сәфәргә барып кайту уңае белән язылган. Такташ башта аны юлда барулары, Әстерхандагы тормышы турында көндәлек формасында язган булса кирәк. (Язучының ерак сәфәрләр чыкканда көндәлекләр язу гадәте мәгълүм. Мәсәлән, аның 1929 елда Татарстанның башка язучылары белән бергә СССРның көньяк республикалары буйлап сәяхәт вакытында, шулай ук Донбасска иҗади командировка вакытында язып барган көндәлекләре бар.

Г.Минский, ул көннәрне искә төшереп, болай ди: «Такташ белән мин 1926 елда Казанда таныштым. Дуслаштык. Такташ талантына табынучы буларак, мин аны үземнең туган җиремә – Әстерханга кунакка чакырдым. Ул бик теләп риза булды. Әстерханга мин пароход белән ике көн алдан кайттым. Ә Такташ поезд белән килде. Минем әтиләрдә тордык. 4–5 көннән соң Казанга пароходта бергә кайттык.

Әстерханда үз вакытында Г.Тукай, Ф.Әмирхан (Фатих абыйның Әстерхандагы «Аркадия» бакчасында коляскасында утырып торуын әле дә хәтерлим) булган, С.Рәмиев шунда эшләгән. Шундый традициясе, татар театры, татар әдәби көчләре булган Әстерханга Такташның килүе очраклы түгел иде, әлбәттә».

Такташның Мәхмүд Максудка язган хатында (1928 ел, 5 июль) мондый юллар бар: «...кичәне 9 районда үткәрергә туры килде... Син минем теге «Кызыл Татарстан»да язган чепухамны укып та сүгенгәнсеңдер. Редактор баскач, язган идем инде шунда...» (Совет әдәбияты. 1966. № 7. 104 б.). Һ.Такташ үзенең бу мәкаләсе турында әйбәт фикердә булмаса да, татар әдәби тәнкыйте әсәргә уңай бәя бирде. Х.Госман бу очерк уңае белән болай ди: «Такташ бөтен матурлыкның чыганагын тулысы белән азат хезмәткә, матурлыкның үзен исә хезмәт җимешләренә кайтарып калдырды...» (Һади Такташ – халык шагыйре // Совет әдәбияты. 1951. № 1. 12 б.).

Такташ архивында очеркның «Эчмә, җанкисәгем Василий!» дигән бүлеге караламасының ике бите саклана. Караламада бүлек «Эчмә, сөекле Василий» дип исемләнгән (ТА. 3–1 п. 413 с.б.).

Текст 1953 елгы җыентыктан алынды.

[1] *...сагынылган Тамбов урманнары күкрәгендә үскән зифа каеннарның...* – юлда барганда Такташ туган яклары, таныш урманнары буйлап уза. «Шагыйрьнең зәңгәр күзендә туган як мәхәббәте балкый һәм... шигъри юллар туа башлый:

Юл буенда яшь бер каен кызы
Тынып йоклый баскан көенә...»

(Минский Г. Зәңгәр күзле дус // Замандашларым. Казан : Татар. кит. нәшр., 1964. 54 б.) Менә шулай поездда Такташның «Үтеп барышлый» исемле шигыре языла (Кызыл Татарстан. 1928. 28 авг.).

[2] *ГПУ* (Государственное политическое управление) – Дәүләт сәяси идарәсе. 1922 елның февраленнән декабренә кадәр эшли, Такташ бу сүзне биредә «милиция» мәгънәсендә кулланган.

[3] *...«Авыл яшьләре» журналына биреп киткән идем.*– «Айга күптән инде мең яшь тулган...» дип башланган исемсез шигырь «Авыл яшьләре»нең 1928 елгы 6 нчы (июнь) санында басылган. Бу бишьюллык шул шигырьдән.

[4] *...зур әдәби кичә...* – Әстерханнан читтәрәк урнашкан эшчеләр бистәсе Тиякнең «Кызыл Шәрекъ» клубында уздырылган кичә турында сүз бара. Кичәдә Такташ доклад ясый, аннары үзенең шигырьләрен сөйли. «Кичә озакка сузылды. Сәгать 12 тулды. Зал һаман тыңлый. Ул укып бетергәч тә, китеп бармасын дигәндәй, гөрләп кул чаба. Шагыйрь тагын да укый. Аны тагын чакыралар, тагын, тагын да» (Минский Г. Замандашларым. Казан : Татар. кит. нәшр., 1964. 50 б.).

Һ.Такташ белән Г.Минскийның Әстерханга килүен Тияк бистәсе яшьләре белеп, көтеп алганнар. Әдипләр килү уңае белән афиша да чыгарганнар. Анда болай диелгән: «Казаннан Әстерханга ашыгыч телеграмма. Шул көннәрдә әдәби сәяхәт белән шәрекъка үтешли мәшһүр татар шагыйрьләреннән Һ.Такташ белән танылган яшь татар язучыларыннан Г.Минский Әстерханга туктыйлар. Алар Әстерханда Әстерханның әдәби көчләренең катнашы белән зур күләмдә шигырь-әдәбият-музыка кичәсе уздырачаклар. Шул көннәрдә. Тиздән!!!»

[5] *Иширәев Габдерәхим, Рәхмәтуллин Закир, Вальшин Якуб, Измайлов Сабир* – эшчеләр. Вальшин Якуб – «Кызыл Шәрекъ» клубы мөдире. Дүртесе дә «Кызыл Шәрекъ» клубы каршындагы үзешчән сәнгать түгәрәгенең иң актив әгъзалары. Сәхнә аша татар эшчеләре арасында аң-белем таратучылар.

[6] *Нобель заводы* – агалы-энеле Людвиг (1831–1888), Альфред (1833–1896) Нобельләр тарафыннан 1878 елда Бакуда нефть промышленносте предприятиесенә нигез салына (1879 елдан – «Агалы-энеле Нобельләр товариществосы»). Үз вакытында ул Россиядәге иң эре нефть фирмасы саналган. Каспий диңгезе буенда, Идел буенда, гомумән, Россиянең эре шәһәрләренең һәрберсендә диярлек бу фирманың заводлары үсеп чыккан. Әстерхандагы Нобель заводына XIX йөзнең соңгы елларында нигез салынган.

[7] *«Ермак» пароходы* – «Мануфактур-Советник» исемен йөрткән. 20 нче еллардан – «Ермак», 1936 елдан – «Колхозник», 1949 елдан «30 лет ВЛКСМ» исемнәре белән йөртелгән. 1959 елда йөрүдән туктый һәм Горький шәһәрендәге «Сормово» заводында сүтелә.

[8] *...мәхәббәт тәсбихы тартып бара.* – Бу урында озын-озак мәхәббәт сату хакында сүз бара.

[9] *«Көрәшнең матурлыгы, аның җырчылары»* – бу доклад текстының язмышы әлегә анык түгел.

*261 бит.*

**Кечкенә генә бәйрәм.** «Азат хатын» журналының 1928 елгы 13–14 нче (20 июль) санында басылган. Мәкалә «Азат хатын» журналының беренче саны (1926, август) чыгуга ике ел тулу уңае белән язылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *«Азат хатын»* – 344 биттәге искәрмәне карагыз.

[2] *«Крәстиян гәзите»* – 1924 елның апреленнән 1926 елга кадәр Казанда атнага бер тапкыр сигез битле булып чыккан газета.

[3] *МОПР* (Международная организация помощи борцам революции) – Революция көрәшчеләренә халыкара ярдәм оешмасы. Такташ үзе дә бу оешманың әгъзасы булган (әгъзалык билеты архивта саклана: ТА. 11–10 п. 1179 с.б.).

[4] *...фикер алышу бүлеге ачыла.* – «Азат хатын»ның 1928 елгы 15 нче (15 август) санында ук «Язышучыларыбыз белән сөйләшү» исемле редакцион мәкалә басыла. Анда «Журнал ничек эшләнә?», «Көтелгән хатлар» дигән бүлекчәләр бар.

*265 бит.*

**Сөйкемле кеше.** «Чаян» журналының 1928 елгы 7 нче (июль) санында «Аллан» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*268 бит.*

**Язышучыларыбыз белән сөйләшү.** «Азат хатын» журналының 1928 елгы 15 нче (15 август) санында имзасыз басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *...журналның ике еллыгына карата мәкаләләр...* – сүз «Азат хатын»ның 1928 елгы 13–14 нче (20 июль) санында басылган ике мәкалә – Кәримованың «Ике яшь тула», Такташның «Кечкенә генә бәйрәм» исемле мәкаләләре турында бара.

*270 бит.*

**Кара күләгә астында.** «Азат Себер» газетасының 1928 елгы 15 сентябрь (37 нче) санында басылган. Өскә «Нәни фельетон» дип куелган. Архивта ротапринтта басылган нөсхәсе саклана (ТА. 3–6 п. 452 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*«Азат Себер»* – 1919 елның 23 декабреннән Омскида чыга башлаган газета; «Русия коммунистлар партиясенең Омски вилайәт комитеты янындагы Мөселман секциясе һәм ревком тарафыннан чыгарыла торган әдәби һәм сәяси татарча гәзитә». Соңыннан Новониколаевск (хәзерге Новосибирск) шәһәренә күчерелеп, РКП(б)ның Себер бюросы янындагы «Татар-казакъ бүлеге һәм Себер ревкомы» органына әйләндерелә.

*273 бит.*

**«Опровержение».** «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 26 ноябрь (269 нчы) санында «Мокамай» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *«Кызыл Татарстан»* – хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасы 1924–1950 елларда шул исемдә чыга.

[2] *Чистка* – Коммунистлар партиясе әгъзаларының партия уставын, коммунистик әхлак нормаларын үтәүләрен тикшерү һәм аларның сәяси активлыгын көчәйтү, шулай ук сыйнфый чит элементларны, очраклы кешеләрне, партия һәм дәүләт дисциплинасын бозучыларны партия сафларыннан чыгару максатларында үткәрелгән чара.

*274 бит.*

**Чегән кызы колхозда.** «Чаян» журналының 1929 елгы 8 нче (август) санында «Аллан» имзасы белән басылган. Бер хатынга багып утыручы чегән кызы рәсеме дә бар. Архивта мәкаләнең кульъязмасы саклана (ТА. 2–12 п. 354 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

[1] *Шелангы* – хәзерге Югары Ослан районына кергән авыл.

[2] *Теньки районы* – элекке Тәмте районына кергән авыллар хәзер Кама Тамагы районына карыйлар.

[3] *Наркомпрос* (Народный комиссариат просвещения) – Халык мәгариф комиссариаты.

*276 бит.*

**Сәмигулла хәзрәт.** «Чаян» журналының 1929 елгы 11 нче (ноябрь) санында «Мокамай» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

[1] *Фәтва* – нинди дә булса бер эшнең дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирү.

[2] *Сахраи кәбир* – Сахара чүле.

[3] *Суллашу* – сәяси яктан кыюрак, кискенрәк һәм алдынгырак карашны яклаучы булып китү. Биредә «коммунистлаша» мәгънәсендә кулланылган.

[4] *Иманга көч килү* – дингә, Аллага ышанмый башлау.

[5] *Уңлашу* – биредә «Коммунистик партиягә, Совет хөкүмәтенә, социализмга дошман булу» мәгънәсендә.

[6] *Чин мәмләкәтенең җиһад игълан итүе* – Кытай дәүләтенең дин өчен сугыш игълан итүе.

[7] *Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ кавемнәре* – мифик ике халык (русларда Гог-Магог); дини риваять буенча Зөлкарнәй (Александр Македонский), стена корып, аларны башка халыклардан аерган; дөнья бетәр алдыннан стенаны җимереп чыгып, алар җир өстендәге барлык нәрсәне ашап бетереп барачаклар, имеш.

*278 бит.*

**Һадиулланың һәлакәте – отношение бәласе.** «Чаян» журналының 1930 елгы 1 нче (гыйнвар) санында «Хәйрулла улы» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*279 бит.*

**Эшлекле кешеләр.** «Чаян» журналының 1930 елгы 1 нче (гыйнвар) санында «Аллан» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*281 бит.*

**Тавыкбаев.** «Чаян» журналының 1930 елгы 1 нче (гыйнвар) санында «Мокамай» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*283 бит.*

**Җамали белән Камали.** «Чаян» журналының 1930 елгы 1 нче (гыйнвар) санында «Мокамай» имзасы белән басылган. Такташның 1942 елгы җыентыгына кертелгән. Архивта мәкаләнең баштагы өлешенең кульъязмасы саклана (ТА. 2–10 п. 367 с.б.). Анда «Күршеләр» дип исемләнгән.

Текст «Чаян»нан алынды.

*284 бит.*

**Алмаштырылмаслык кешеләр.** «Чаян» журналының 1930 елгы 2 нче (февраль) санында «Мокамай» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*285 бит.*

**Ударный көн.** «Чаян» журналының 1930 елгы 8–9 нчы (август-сентябрь) санында «Точка» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*287 бит.*

**Экономистлар.** «Чаян» журналының 1930 елгы 8–9 нчы (август-сентябрь) санында «Аллан» имзасы белән басылган. Балык тотып утыручылар рәсеме урнаштырылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*288 бит.*

**Перегибщик.** «Чаян» журналының 1930 елгы 8–9 нчы (август-сентябрь) санында «Мокамай» имзасы белән басылган. Рәсемнәр урнаштырылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*289 бит.*

**Гаеплеләр.** «Чаян» журналының 1930 елгы 8–9 нчы (август-сентябрь) саннарында «Мокамай» имзасы белән басылган. Рәсемнәр урнаштырылган. Такташның 1953 елгы җыентыгына кертелгән.

Текст 1953 елгы җыентыктан алынды.

*290 бит.*

**Көтәләр.** «Чаян» журналының 1930 елгы 10 нчы (октябрь) санында «Мокамай» имзасы белән басылган. Көлке рәсемнәр урнаштырылган. Кулъязмасы язучы Х.Туфан архивында саклана.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*292 бит.*

**Чиратлар патшасы.** «Чаян» журналының 1930 елгы 10 нчы (октябрь) санында «Мокамай» имзасы белән басылган. Рәсемнәр урнаштырылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*294 бит.*

**Тизлек нәрсәдә.** «Чаян» журналының 1930 елгы 11 нче (ноябрь) санында «Мокамайның якын кардәше» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмасы бар (ТА. 2–9 п. 391 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

[1] *«Колхоз гәзите»* – «Колхоз яшьләре» газетасы (1930–1933) күздә тотыла булса кирәк.

[2] *Татиздат* (Татарское книжное издательство) – Татарстан китап нәшрияты.

[3] *Бәхтияров* – Нәкыйп Бәхтияров, драматург һәм журналист. Соңрак «Чаян» хезмәткәре.

*296 бит.*

**Бюрократ.** «Чаян» журналының 1930 елгы 12 нче (декабрь) санында «Аллан» имзасы белән басылган.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

*298 бит.*

**Чәчләр аягүрә.** «Чаян» журналының 1931 елгы 2 нче (февраль) санында «Мокамай» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–10 п. 365 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*299 бит.*

**Төзәлмәслек летун.** «Чаян» журналының 1931 елгы 2 нче (февраль) санында имзасыз басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–9 п. 372 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*299 бит.*

**Акташ белән Актаныш трагедиясе.** «Чаян» журналының 1931 елгы 2 нче (февраль) санында «Гилия» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмалары саклана (ТА. 2–10 п. 363 с.б.). Икенче бер дәфтәрдә бу мәкаләнең «Чаян» идарәсенә хат» исеме белән түбәндәге варианты да бар: «Үтенәм хатымны басып чыгаруыгызны. Мәсьәлә болай, Чаян иптәш. Татарстанда ике район бар. Аның берсе Актаныш, икенчесе Акташ. Бу ике районның икесенең дә исеме минем фамилиям белән охшашлары булганга, миңа күп кенә уңайсызлыклар күрергә туры килә.

Беренчедән, Мәскәүдән миңа җибәрелгән Ленин мәҗмугаларының томнары, гәзит-журналлар күп вакытта Актаныш, Акташ районнарында сәяхәт итеп әйләнеп кайталар.

Икенчедән, Актанышка һәм Акташка китәргә тиешле кайбер гәзитләрне минем бүлмәгә ташлап китәләр.

Киләчәктә бу районнар белән минем арада җәнҗал чыкмасын өчен, «Чаян» аркылы бу ике районга исемнәрен алмаштырырга яки почтада утыручы кайбер бозык башларны булдыклырак иптәшләр белән алмаштырырга тәкъдим итәм» (ТА. 2–9 п. 386 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

[1] *Акташ районы* – элекке Акташ районы авыллары хәзер тулысы белән диярлек Әлмәт районына керәләр.

*299 бит.*

**Мөгезле дуңгызлар.** «Чаян» журналының 1931 елгы 2 нче (февраль) санында имзасыз басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–10 п. 364 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

[1] *Дарвин* – Чарлз Роберт Дарвин (1809–1882), инглиз табигать белгече. Табигый сайланыш юлы белән хайваннарның һәм үсемлекләрнең төрләре барлыкка килү турындагы эволюцион тәгълиматка нигез салучы.

*301 бит.*

**Үзенә эләкте.** «Чаян» журналының 1931 елгы 3 нче (март) санында «Дан» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2– 9 п. 384 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*302 бит.*

**Үзсүзле кеше.** «Чаян» журналының 1931 елгы 3 нче (март) санында «Тәрҗимов» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–9 п. 384 с.б.)

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*304 бит.*

**Идарәгә хат.** «Чаян» журналының 1931 елгы 3 нче (март) санында «Чаян»ның 1 нче пом. Кәрим» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмасы бар (ТА. 2–9 п. 380 с.б.). Кулъязмада имза: «1 нче пом. һәм аның дусты Кәрим» диелгән.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

[1] *Осоавиахим* (Общество содействия обороне и авиационно-химическому строительству СССР, 1927–1948) – СССРның Оборона һәм авиация-химия төзелешенә теләктәшлек җәмгыяте.

[2] *«Яшь ленинчы»* – ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының Республика советы органы. 1924 елның 10 октябреннән чыга. 1990 елдан «Сабантуй» исемендә басыла.

*305 бит.*

**«Чаян» холодильнигы.** «Чаян» журналының 1931 елгы 5 нче (май) санында «Чаян» имзасы белән басылган. Архивта кулъязмасы саклана (ТА. 2–9 п. 392 с.б.).

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Чаян»нан алынды.

*307 бит.*

**«Таң».** «Кызыл Татарстан» газетасының 1931 елгы 5 август (181 нче) санында басылган. Беренче тапкыр, бераз кыскартылып, Такташның 1953 елгы җыентыгына кертелгән.

Коллективлашу елларында шушы очеркны язар өчен барган бу командировка – Такташның истәлекле һәм соңгы сәфәре. Бу сәфәр турында Гөлчәһрә Такташева-Мансурова истәлекләрендә мондый юллар бар: «Сыркыдыдан кайткач, без Актанышка киттек. Һади ул районга командировка сорап алды. Актанышта без минем энем Камил Мансуровта тордык. Һади, Актаныштан көн дә Такталачык авылына барып, «Таң» колхозы хакында очерк язып йөрде» (Такташ турында истәлекләр. Казан, 1980. 19 б.). Такташ әсәрендә аталган авыл, колхоз исемнәре әле дә булса үзгәрмәгән. Д.Зөбәерова, язучы булган эзләрдән барып һәм язучы күтәргән проблемаларның үтәлешен чамалап, Такташ куйган бүлек башларына кадәр үзгәртмичә, «Таң» исемле мәкалә язды (Азат хатын. 1967. №10. 8–12 б.).

«Социалистик Татарстан» газетасының 1978 елгы 14 июнь (138 нче) санында басылган «Актаныш таңнары» исемле мәкалә дә (авторы – Х.Вәлиәхмәтов), газетаның 1980 елгы 13 март (62 нче) санында басылып чыккан «Актаныш якларында» исемле мәкалә дә (авторлары – Шәмси Хамматов, Габделбәр Ризванов) шул ук «Таң» колхозына багышланган. Авторлар, Такташ очеркына мөрәҗәгать итеп, анда куелган мәсьәләләрне искә төшереп, ул чагында яңа оешып килүче колхозлар арасында алдынгылардан саналган «Таң»

колхозының соңгы ярты гасыр эчендә ничек үзгәрүе, язучы игътибар иткән уңай башлангычларның ничек итеп үсүе, ныгуы һәм колхозның үрнәк хуҗалык булуы турында язалар. Д.Зөбәерова мәкаләсен болай дип бетерә: «Һади Такташ үзенең очеркын шундый теләк белән тәмамлаган: «Таң» колхозының тәҗрибәләре ныклап өйрәнелергә тиеш!» Бу фикер бүген дә үз көчендә һәм бик урынлы яңгырый».

Такташ архивында «Таң» очеркының латин шрифтында акка күчерелгән кульязмасы саклана (ТА. 3–4 п. 444 с.б. 2–16 б.).

Текст аз гына кыскартулар белән кульязмадан алынды.

[1] *...«уңышлардан баш әйләнү» чоры...* – колхозлашу чорында (1930 елда) партия директиваларын бозулар турында Сталин үзенең «Уңышлардан баш әйләнү», «Колхозчы иптәшләргә җавап» исемле мәкаләләрен яза (Сталин И.В. Әсәрләр. 1951. 12 т. 209–218 б., 221 – 249 б.). Мәкаләләрдә, нигездә, түбәндәге хаталар күрсәтелә: 1. Урта хәллегә ялгыш караш. 2. Колхозлар төзегәндә ленинизмның иреклелек принцибын бозу. 3. Колхоз төзелешенә карата СССРның төрле районнарындагы шартларның төрлечә булуы исәпкә алынмавы һәм колхоз төзелешенең методлары бертөсле булырга мөмкин түгел икәнлеген оныту.

1930 елның 14 мартында ВКП(б) Үзәк Комитетының «Колхоз хәрәкәтендә партия сызыгын бозуларга каршы көрәшү турында»гы карары чыга.

[2] *Колхозсоюз* – 1928 елның 10 маенда ВКП(б)ның өлкә комитеты бюросы карары белән Татарстанда авыл хуҗалыгы кооперацияләренең специальләшкән союзларын төзү тәртибе раслана: животноводсоюз, яичноптичный союз, хлебсоюз, бераздан колхозсоюз, маслосоюз һәм семеноводсоюз. Колхозсоюз коллективлаштыру, колхозлар төзү һәм аларга җитәкчелек итү белән шөгыльләнгән.

[3] *Наркомздрав* (Народный комиссариат здравоохранения) – Сәламәтлек саклау комиссариаты.

[4] *...25 мең исәбенә килгән.* – ВКП(б) Үзәк Комитетының 1929 елгы ноябрь Пленумы карары белән эшчеләр сыйныфының 25 мең иң алдынгы вәкилләре авылга җибәрелә. 1930 елның февраль аенда Татарстан районнарына 400 кеше килә. 25 меңчеләр Татарстандагы колхоз төзелешендә җитәкчелек итәләр. Шулардан 200 дән артыгы колхоз рәисе булып эшли.

[5] *Татарстан гыйльми-тикшерү институты «Таң» колхозының тәҗрибәләрен ныклап өйрәнергә тиешле.* – Такташның бу теләге 1931 елда ук тормышка аша. Казанда 1930 елның мартында ачылган Татар экономика гыйльми-тикшеренү институты хезмәткәре Н.Айдашевның «Таң» колхозы, Такталачык авылы, Актаныш районы, Татарстан» исемле китабы басылып чыга. Китапның редакторы Татколхозсоюз идарәсе әгъзасы Х.Бәшәров кереш сүздә болай ди: «Иптәш Айдашев тарафыннан төзелгән бу китап «Таң» колхозының оеша башлаган вакытыннан алып бу елның язына кадәр вакытны үз эченә сыйдыра. Татарстанда татар телендә татар колхозының беренче монографиясе буларак басылып чыга... Язучы тарафыннан «Таң» колхозы дөрес сайланган». Китапта колхозчыларга уңыш бүлү бәйрәменә «Кызыл Татарстан» газетасыннан да вәкилләр чакырылуы әйтелә. «Таң» колхозы турында китап язу мәсьәләсе гыйльми хезмәткәрләрнең, колхозсоюзның, журналистларның, шул исәптән Такташның да уртак теләкләре, киңәшләре белән хәл ителгән булырга мөмкин.

*318 бит.*

**«Татар түрә булса...».** Кульязмасы архивта саклана (ТА. 2–9 п. 394 с.б.). Исеме юк. Имзасы: «Мөхәммәд Кодрү». Мәкаләнең астында мондый юллар бар: «Кутуй! Минемчә, төзәтми, турыдан керт. Артык популяр ясарга маташма. Төзәтсәң – кертмә». Шул ук мәкаләнең бер өзеге караламасы да бар (ТА. 2–9 п. 381 с.б.). Анда мәкалә «Татар түрә булса, этен беренче класста йөртә» дип исемләнгән. Укыганда җайлылык өчен мәкаләгә исем шул өзектән алып куелды.

Беренче тапкыр басыла.

*319 бит.*

**Кооператив сүзлеге.** Кульязмасы архивта саклана (ТА. 1–19 п. 269 с.б.).

Беренче тапкыр басыла.

*319 бит.*

**Минем беренче критикларым һәм беренче укучыларым.** Кульязма-караламасы архивта саклана (ТА. 2–15 п. 403 с.б.). Язучы бу мәкаләсен төрлечә башлап караган. Әлеге тексттан алда мондый юллар бар: «Яшь чагымда мин бик авторитетсыз малай идем. Күршеләр дә, иптәшләр дә, әти-әниләр дә минем бер генә сүземә дә ышанмыйлар, күп вакытта сөйләгән сүзләремә...» Җөмлә өзелә һәм тагын башланып китә: «Балалык елларым артык авторитетсыз булып үтте. Чөнки...» Өзелә, тагын башлана: «Мин бик яшьли үземнең авторитетны югалттым».

Мәкалә М.Маминның «Һади Такташ поэзиясе» (Казан, 1952) китабында текст эчендә бирелгән.

Текст кульязмадан алынды.

Такташ томнарына беренче тапкыр кертелә.

## ЭЧТӘЛЕК


Төзүчедән

**Проза әсәрләре**

*Тәмамланмаган романның бүлекләре, нәсерләр, хикәяләр*

Таң җиле
Кызыл галстук
Ул аны онытты
Троцкий
Кояш көлми дә, елмаймый да
Кыш җыры
Протоколлар эчендә хикәя
Алар җиңелделәр
Караборынның дусты
Иркә солдат
Ул көннәрдә
Кияү
Соңгы елмаю
Сез икегез дә гаепле...

**Вариантлар, план-сызмалар**

«Таң җиле» романының вариантлары
Хәмит белән Арыслан турындагы әсәрнең план-эчтәлеге
Хәмит белән Арыслан турындагы әсәрнең язылган кисәкләре

**Әдәбият-сәнгать тәнкыйте мәкаләләре**

«Оҗмах кошы»
Оперетта каһарманнары
Иҗадиятем турысында
«Адашкан күңел»
Кари кичәсе
Кино – «Кызыл партизаннар»
«Дантон» ...................................
Эшче-крәстиян яшьләре әдәбияты
Комсомол җырлары
И.Рәми хикәяләре турында
Шигырьләр турында бераз әңгәмә
«Әрә егете» үлде
Татар хатын-кызлар матбугаты
Үзем һәм башкалар турында
Хатынсыз ай, тотнаксыз тәнкыйть
«Кызлар җыры»
Ничек язарга?
Хикәяне ничек язарга?
Ничек үсәбез?
«Амантай шигырьләре» турында
«Зәкуан мулла шәҗәрәсе»
Бүгенге матурлык һәм аны җырлаучылар турында
«Җавап»
Безне берләштергән нәрсәләр
Тыңла, ТАПП!
Үзем турында
Язучыдан
Тәнкыйть турында
«Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында
Сандугачларның сайрауларына рецензия

**Публицистика**

Бохарада уку һәм укыту эшләре
Бохара хәбәрләре
Бохара фаҗигаләре
Яңа Бохарада мохтарият кичәсе

Хива вәкилләре
Пожалуйста
Сират аюлары
Кояш белән Ай сөйләшә
Менә нишләде
Авыл хуҗалыгы түгәрәкләренә җәйдә эш
Тән чисталыгы
«Авылга йөз белән» ни дигән сүз ул?
Ике хат турында
Кайтасы килми
Советларга сайлаулар
Карусель
Мөяссәр дию һәм яман авыру микроблары
Безнең хат
Синеңчә ничек?
Җанлы казармалар
«Лотерея уены»нда кызык сораулар
Радио
Бәхет барабаны
Безнең беренче карлыгачлар
Сөйләшми торган вагон йөртүче һәм өч хулиган белән милли судья турында
Сагынылган җирләрдә
Кечкенә генә бәйрәм
Сөйкемле кеше
Язышучыларыбыз белән сөйләшү
Кара күләгә астында
«Опровержение»
Чегән кызы колхозда
Сәмигулла хәзрәт
Һадиулланың һәлакәте – отношение бәласе
Эшлекле кешеләр
Тавыкбаев
Җамали белән Камали
Алмаштырылмаслык кешеләр
Ударный көн
Экономистлар
Перегибщик
Гаеплеләр
Көтәләр
Чиратлар патшасы
Тизлек нәрсәдә
Бюрократ
Чәчләр аягүрә
Төзәлмәслек летун
Акташ белән Актаныш трагедиясе
Мөгезле дуңгызлар
Үзенә эләкте
Үзсүзле кеше
Идарәгә хат
«Чаян» холодильнигы
«Таң»
«Татар түрә булса...»
Кооператив сүзлеге
Минем беренче критикларым һәм беренче укучыларым

Искәрмәләр һәм аңлатмалар

Литературно-художественное издание

**Такташ** Хади
(**Такташев** Мухамметхади Хайруллович)

**СОЧИНЕНИЯ**

Издание второе, исправленное и дополненное

В трех томах

Том 2

Составление тома, подготовка текстов, примечаний и комментариев
**Гайнановой** Лены Рашитовны

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Ђдђби-нђфис басма

**Такташ** Џади
(**Такташев** Мљхђммђтџади Хђйрулла улы)

**ЂСЂРЛЂР**

Тљзђтелгђн џђм тулыландырылган икенче басма

Љч томда

2 том

Томны  тљзњче, текстларны, искђрмђ џђм аѓлатмалаларны ђзерлђњче
**Гайнанова** Лена Рђшит кызы

Мљхђррире *В.Р.Камалиева*
Рђссамы џђм бизђлеш мљхђррире *Р.Х.Хђсђншин*
Техник мљхђррир џђм компьютерда биткђ салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Г.М.Хђбибуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 9.02.2010.
Форматы 84×108 1/32. Шартлы басма табагы 20,16+вкл. 1,26.
Тиражы 2500 д. Заказ В-1966.

Татарстан китап нђшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдђмендђ ђзерлђнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нђшрият комплексы ААЌ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.